ISSN 0206—4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

12.2003



# КАЗАН ШӘҺӘРЕНӘ—1000 ЕЛ







Үткәнебез һәм бүгенгебез. Бер үк ноктадан бер гасыр аерма белән төшерелгән фоторәсемнәр.

*Хаҗи Абдулла Дубин коллекциясеннән.*

Казан утлары
Qazan utları

2003

12
(974)

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

*Татарстан хөкүмәте,*
*Татарстан Язучылар берлеге,*
*редакциянең хезмәт коллективы*

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Фоат Галимуллин**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Мирза Мәхмүтов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Лилия Гатауллина, Диләрә Максутова, Флера Сабирова, Тәслимә Сибгатуллина, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
Баш мөхәррир — 92-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 92-36-49.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 92-38-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 92-39-63,
гамәли хезмәткәрләр — 92-39-65.
Исәп-хисап бүлеге — 92-93-16.
**Факс** — (8432) 43-56-12.
**E-mail:** kazanutlari@telebit.ru

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

*Бу санда*

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Харрас ӘЮП. Без – Кояштан. *Шигырь* ..... 5
Кави ЛАТЫЙП. Әдрән диңгез. *Повесть-истәлек* ..... 6
Марат ЗАКИР. Кояшлы төн. *Шигырьләр* ..... 40
Халисә МӨДӘРРИСОВА. Яр. *Повесть* ..... 44
Госман САДӘ. Галәм «модуле». Шигырьләр. ..... 79
Зөфәр ДӘҮЛӘТОВ. Тәре баганасы. *Хикәя* ..... 83
Дифгат СИРАЙ. Утырып кына яңгыр ява. *Шигырьләр* ..... 100
Рафаил ГАЗИЗ. Ак болыт. *Эссе* ..... 121
Алмаз ГЫЙМАДИЕВ. Балалар өчен хикәяләр ..... 182

**ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫ–ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ**

Олег ШЕСТИНСКИЙ. Җирәнчәч. *Хикәя* ..... 90

**ТАТАР ХИКӘЯЛӘРЕ ХӘЗИНӘСЕННӘН**

Газиз МӨХӘММӘТШИН. Ике әби бәрәңге ала ..... 103

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Йолдыз ХӘЛИУЛЛИН. Дипломат язмалары ..... 111

**ФӘН**

Алсу ШӘМСУТОВА. М. Мәһдиев иҗатына бер караш ..... 137

**КАЗАННЫҢ 1000 ЕЛЛЫГЫНА**

Фәрит МИҢНЕГАЛИ. Казан урамнары ни сөйли? ..... 143

**ХАЛЫК ИҖАТЫ**

Илсөяр ЗАКИРОВА. Казанлыга сәяхәт ..... 146

**КИТАП КҮЗӘТҮ**

Факил САФИН. Гамьле гамәлләр кылыйк! ..... 155
Мансур ВӘЛИ-БАРҖЫЛЫ. Тәкъдир юллары ..... 160
Коръән татар телендә ..... 164

**ХӘТЕР**

Марсель ГЫЙМАЗЕТДИНОВ. Туган җирнең китмәс кошлары без. Шигырьләр (Н. Гамбәр кереш сүзе белән) ..... 177

Берлекнең яңа әгъзалары ..... 179
«Казан утлары» архивыннан ..... 180

2003 елда журналда басылган әсәрләр исемлеге ..... 184
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ..... 188

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: повести К. ЛАТЫПОВА «Адриатическое море» и Х. Мударрисовой «Берег», рассказ З. Давлетова «Надгробный крест», эссе Р. ГАЗИЗОВА «Белое облако»; стихи М. ЗАКИРА, Г. САДЭ, Д. СИРАЙ.
«Дружба литератур—дружба народов»: рассказ О. ШЕСТИНСКОГО «Рыжик».
«Из сокровищницы татарских рассказов»: рассказ Г. МУХАМЕТШИНА «Старушки копают картошку».
«Публицистика»: окончание статьи Ю. ХАЛИУЛЛИНА «Записки дипломата».
«Наука»: статья А. ШАМСУТОВОЙ посвящена творчеству М. Магдеева.
«К 1000-летию Казани»: статья Ф. МИННЕГАЛИЕВА «О чем говорят названия Казанских улиц?».
«Народное творчество»: статья И. ЗАКИРОВОЙ «Поверья и фольклор сибирских татар».
«Книжное обозрение»: рецензии Ф. САФИНА и М. ВАЛИЕВА на книги Мударриса Валиева и Марата Амирханова.
«Коран на татарском языке».
«Память»: стихи М. ГИМАЗУТДИНОВА (с предисловием Н. ГАМБАРА).
Из архива журнала.
Детские рассказы А. ГИМАДИЕВА.
Библиографический список произведений, опубликованных в 2003 году.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: работа художника А. Сайфутдинова «Татарская девушка»; поэт А. Исхаков.

## IN THIS ISSUE:

*The magazin edits monthly*

"Prose and Poetry" : stories by K. LATYPOV "Adriatic sea" and H. MUDARRISOVA "Bank", short story by Z. DAVLETOVA " Tomb Cross", essay by R. GAZIZOVA "White cloud", verses by M. ZAKIR , G. SADE, D. SIRAI.
"Friendship of literatures – friendship of peoples" : short story by O. SHESTINSKY "Ryzhik (ginger)".
"From treasury of Tatar short stories": short story by G. MUKHAMETSHIN " Old women are digging potatoes".
"Publicizm" – ending of the article by Yu. HALIULLIN " Notes of Diplomat"
" Science" : article by A. SHAMSUTOVA dedicated to creativity of M. Magdeev.
" To 1000th anniversary of Kazan " : article by F. MINNEGALIEV " What about speak names of Kazan streets ?"
" Folk –lore" : article by I. ZAKIROVA " Beliefs and folk-lore of Siberian Tatars"
" Books review" opinion of F. SAFINA and M. VALIEV on the books by Mudarris Valiev and Marat Amirkhan.
"Al - Quran in Tatar Language"
" Memory" : verses by M. GIMAZUTDINOV ( with foreword by N. GAMBAR)
From archives of the magazine
Bibliographic list of the works published in 2003
Dairy of public –cultural life
On our covers : work by artist A. Saifutdinov
" Tatar girl" ; poet A. Iskhakov

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 19-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 24.11.2003 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 $^{1}/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 7031. Заказ Я—800
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2003 ел.

**Харрас Әюп**

## Без—Кояштан

Без—Кояштан, Кояш яктысыннан,
Кояш нуры сеңгән каннарга,—
Шуңа кайнардыр без, кызурактыр...
Яктылыктан тора җаннар да.

Җирдә әле—без ясаган язлар,
Безнең назлар юлдаш сөюгә.
Сүнеп барган өмет кабынып китә
Кулларыгыз килеп тиюгә.

Гел аклыкта, гел пакьлектә ният,
Күңелдәге нурдан яралып,
Безнең хыял җәйге болыннарга
Чәчәк саен төшкән таралып.

Һәр бәхеттә безнең аклык нуры,
Һәр учакта безнең җылыбыз.
Каралыкка киртә булып баса
Януыбыз, тоткан юлыбыз.

Җаныгызга җылы кирәк булса,
Эзләмәгез башка урыннар,—
Хәят уты безнең йөрәкләрдә...
Без—Кояштан, Кояш нурыннан!..



## Кави Латыйп

# ӘДРӘН ДИҢГЕЗ

ПОВЕСТЬ-ИСТӘЛЕК

*1952 елның зәмһәрир суыгында мин Казанга килеп төштем. Милләтебезнең сөекле улы, үзе исән чакта ук матур риваятьләргә әверелгән мәшһүр композитор Салих Җамалетдин улы Сәйдәшев белән таныштым. Шул танышлык, шул эчкерсез дуслык мин—яшь офицерның эчке дөньясын үзгәртте. Маэстро яшәгән фатир җылылык, яктылык, нур, моң белән тулы иде. Яшь аермабыз шактый булуга карамастан, без аның белән бертуганнар шикелле якыннар идек. Башкалар кебек үк мин дә аның моңнарына гашыйк. Еш очраштык. Минем белән аралашып ул үз яшьлеген, гаскәри елларын, почетлы кызылармеец булып йөргән вакытларын күз алдына китергәндер. Без аның белән спектакльләр карадык, операларга йөрдек, Офицерлар йортына барып концертлар тыңладык. Кышкы бураннарда карга бата-чума Казан урамнарын урадык. Җәйге ял көннәрендә Идел буенда су коендык, балык тоттык. Пароходларның гудокларын, кошларның сайрауларын тыңлап бай табигатьнең хозурлыгына сокландык. Ул мизгелләр мәшһүр композитор өчен дә, мин—яшь офицерга да бәхет үзе иде.*

*Салих абыйның кешелеклелеге, гадилеге, тыйнаклыгы, күңел байлыгы, рухи бөеклеге, серле музыкасы магниттай үзенә тарта иде. Онытасым юк. Аның сихри моңнары ерак, бик ерак еллардагы хәтер-хатирәләрне искә төшерә, яшьлегемне Салих абый белән кат-кат очраштыра, иҗатыма илаһилык, илһам, күңел күтәренкелеге өсти.*

*Табигатьтә нинди генә зәмһәрир суыклар булмасын, тормышта, җәмгыятьтә нинди генә каршылыклар, борчулар тумасын, Салих Сәйдәшевнең үлемсез моңнары безнең күңелләргә җан җылысы өстәр.*

***Автор.***

—Уз, бәгырь, түрдән уз!.. Миңа таныш булган хәрбиләрнең һәммәсе дә кыю иде, ә син, күрәм, югалып калдың. Капитан килгән, Асюшка, ул—безнең уртак кунагыбыз.

—Уртак кунаклар белән уртак тел табуына мин шатмын, Салих,—диде хатыны.

—Шуның белән, Асюшка, мин бәхетлемен дә инде.

—Бәхет-сәгадәт турында аягүрә гәпләшмиләр.

—Алайса уртак кунакка самавыр куеп җибәр.

—Сабыр ит, бәгырь... Асюшка, өстәлгә ашъяулык җәясе иде. "Гафу!"—дип, композитор үз бүлмәсеннән чыгып китте, аның артыннан хатыны иярде. Мин япа-ялгызым калдым. Тынлык... Ак дивардагы фоторәсемнәргә күз төшердем, аларның карашлары гүя пианинога текәлгән. Әйтерсең лә,

---

Кави Латыйп (1927)—*шагыйрь, прозаик, «Вакыт канатында», «Хәтер йомгагы», «Иркен сулыш» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

алар маэстроның музыка коралы янына утыруын түземсезлек белән көтәләр. "Гомер—мизгелләрдән тора, һәр мизгеленнән файдалан, иҗтиһат кыл, маэстро",—дип әйтәләр сымак әлеге сурәтләр.

Композитор зур дулкынлану белән пианинода "Әдрән диңгез" көен уйнарга кереште...

—Җырлап та биримме... Хәлдән килгән кадәр, әлбәттә:

Әдрән диңгез, гүзәл диңгез,
Күп яуларны күргән диңгез.
Тау батыры Искәндәргә
Җан дәвасын биргән диңгез.
Әдрән диңгез, даулы диңгез,
Тирәләре таулы диңгез.
Хәлен җуйган син бөркеткә
Шифа бирсен изге диңгез-з-з...

—Җан дәвасын биргән диңгез! Искиткеч итеп әйтелгән. Ә көе күңелне үстерә, җилкетә, шул вакытта сагышка күмә. Әйтер идем, күңел үзлегеннән җырлап тора. Мең рәхмәт сезгә, Салих абый. Мәңге яшәгез!

Салих абый белән мин гел очрашам, ул яшәгән йорт юл өстендә генә. Аның янына мин узып барышлый да керәм. Йортның текә баскычларын саный-саный икенче катка менәм дә, маэстро белән Асия ханым яшәгән квартирның ишеген ачам. Аш-су белән кухняда маташкан Асия ханым мине елмаеп каршы ала: "Ә, син—яшь капитан икән, әйдүк!.. Салих абыең көтә үзеңне. Көтә генәме, сагына да. Телендә ике исем: берсе—Әдрән диңгез, икенчесе—син. Ишетәсеңме, әнә "Әдрән диңгез"не башкара. Аның моңнарын "Гөлнара" балетына кертмәкче. Ишеккә сөялеп, мин "Әдрән диңгез"не тыңлыйм. Көй, диңгезнең үзе шикелле, дулкын-дулкын: сурәте, тасвирланышы, холык-фигыле, мохиты белән дә. Диңгезнең үзе сымак ул җанлы, тере, алай гына да түгел, күзле, телле, серле. Менә, диңгез көй булып минем белән сөйләшә, серләшә. Кәләштәй иркәли, яшәргә, иҗтиһат итәргә көч-дәрт, илһам бирә. Шулай да көйне тыңлаганда, күңелдә ямансулык, моңсулык, юксыну хисләре өстенлек итә кебек. Мина әллә шулай тоела гынамы?.. Күңел—диңгез, диләрме әле? Алайса, Салих абыйның күңеле—океандыр... Бәләкәй чакта ул моң чишмәсендә коенмадымы икән? Моң аның тәнендә тугра-тамга булып калмадымы, күңеленә сеңмәдеме икән? Моң аңа Хак Тәгалә әмере белән күктән иңмәдеме икән?.. Сәйдәш моны әллә күктән йолдыздай җиргә атылып төшкән бер кошмы? Ә бәлки ул оҗмах кошы сайравыдыр?.. "Әдрән диңгез"не тыңлаганда айкалган-чайкалган диңгез күз алдына килә. Ул бер өермә-давыл күтәрә, бер тынып кала, елмая-көлә. Салих абыйны газиз анасы тудырып, диңгез бишегендә тибрәтә-тибрәтә үстермәгәнме?.. Юк, ул—Җир улы, Җир кешесе, чөнки хәят-тормыш үзе диңгез, гомер—дәрья ич, ага да ага...

Кинәттән генә ишек ачылу сәбәпле, минем уйларым өзелде...

—Ә син икәнсең, бәгырь,—диде Салих абый, пианино артында утырган килеш.

—Гафу итегез, ишек ачылуга мин гаепле...

—Сөялүне яратмый ул, түргә узган кешене хуп күрә.

—Иясенә охшаган, димәк... Кыскасы, гафу, Салих абый.

—Нәрсә гафуланасың... Кыюрак бул. Батырныкы замана икәнне онытма. Әйтергә кирәк, батырлык та, матурлык та—икесе дә горурлык, бигрәк тә синең кебек яшь чакта. Хәер, яшьлек—үзе матурлык.

—Бүлдердем мин сезне, Салих абый. Кичерегез!..

—Юкка хафаланма, "Әдрән диңгез"ен мин яңадан уйный алам.

—Уйнагыз, ялварып сорыйм. "Әдрән диңгез"не мин йөз мәртәбә дә тыңлый алам.

—Алай ук кирәкмәс, һәр нәрсәнең үз чамасы бар... Үзара әйткәндә, бәгырь, мин гомерем буе бер көйне язам, аккордлары, интонацияләре, бизәкләре генә үзгәчәрәк шикелле. Минем көйләрем аваздашлар... Идел-Җаек буйларында йөрмәсәм, Төркстан сахраларында булмасам, "Озын

сәфәр" дә, "Шәрекъ бию" дә, "Әдрән дингез" дә тумас иде. Яланнарда, далаларда, бер йотым суга тилмереп яткан яралы гаскәриләрне үз күзләрем белән күрдем. Күрдем генә түгел, җәрәхәтләрен үз кулларым белән бәйләдем. Гаскәриләрнең, бәгырь, йөрәкләрен дә бәйлисе бар иде. "Әдрән дингез" йөрәктәге ярага дәва, шифа ул. "Әдрән дингез"не язар өчен озын сәфәр, бормалы юллар үтелде. Әйдә, бәгырь, син дә кушылып җырла, йөрәк ярсулары басылмасмы?..

Әдрән дингез, гүзәл дингез,
Күп яуларны күргән дингез.
Тау батыры Искәндәргә
Җан дәвасын биргән дингез...

Тау батыры Искәндәрне син белергә тиеш, син хәрби кеше. Өстеңдә китель, баш киемең дингезчеләрнеке... Ә минем шуны беләсем килә: нинди яуларда булдың син, капитан?.. Искәндәр тау батыры, ә син кем?.. Үзең белән мине озын сәфәргә, Әдрән дингезгә алып китә аласыңмы?.. Инде, озын сәфәр чыгып, дингездәге кораблар кәрванын күрәсе килә. Бик килә!..

—Килгәнен беләм, Салих абый... Ләкин дингез—иксез-чиксез дәрья бит ул. —Менә шуны әйтмәкче: мин—капитан, ләкин дингезнеке түгел, ә җир капитаны.

Композитор утырган урыныннан сикереп торды:

—Ничек алай?

—Казан Кремлендәге дивизиядә хезмәт итәм мин.

—Кораб йөртмисеңмени?

—Кызганычка каршы, йөртмим, Салих абый.

—Минем шикелле пехотинец, димәк. Ә нигә алайса дингезчеләр киемендә?

—Чик сакчысы идем мин.

—Ничек чик сакчысы?

—Дингез буенда хезмәт иттем. Аннары милләтебез мәркәзе—Казанга кайту ниятеннән, үзем сорап пехотага күчтем. Хәрби званием—капитан.

—Алайса, мишәрләр әйтмешли, менә сиңа куласа-тамаша... Инде, бәгырь, Әдрән дингез белән нишлибез?

—Ул үз урынында кала.

—Син болай миңа ошыйсың. Тик менә минем шикелле үзең дә пехотинец икәнсең. Дингезче булсаң, кораб йөртсәң иде. Әдрән дингезне күрсәм, үләргә дә ризамын. Ярдәм ит син миңа яшьлек хыялымны тормышка ашырырга. Синең элемтәң зур, танышларың күп... Разведчик түгел микән син?.. Штрафниклар ротасына эләктем дип сөйләнәсеңдер генә әле. Инде штрафниклар белән эш итәсең икән, син мине, капитан, гади бер штрафник сыйфатында, корабка утыртып, Әдрән дингезгә алып кит. Күпме штрафник, хәтта әсирләр дә дәрьяларда йөзә, дөньялар гизә... Ялварып сорыйм, коткар син мине бу мәгънәсез, мәнсез тәэсирлектән, әсирлектән, моңга сусаудан... Татар—ул дөньяларга сибелгән. Әдрән дингез ярларында да безнең милләттәшләр гомер сөрәләрдер әле. Тау батыры Искәндәргә җан дәвасы биргән якларга бара калсак, безне алар:

Ничек килдегез сез безгә?
Батмаенча дингезгә?—

дип, җыру белән, каршы алмагайлары?! Әдрән дингезнең картасын табасы иде...

—Табарга тырышырмын, Салих абый...

* * *

Сүземдә тордым: бер очрашуда ана мин дингезләр һәм океаннар Атласын бүләк иттем. Әдрән дингезнең яр буйларына урнашкан, формасы-күренеше белән күн итекне хәтерләткән Апеннин ярымутравын күргәч, ул болай диде:

—Күн итектәй бәләкәй бер җирдә ничек яшәмәк кирәк, батмаенча дингезгә?! Бәндәләргә мәрхәмәтле вә шәфкатьле, изге дингездер бу!

## Фатыймаи–Зөһрә

Елдан артык якыннан аралашканнан соң, минем тышкы кыяфәтем вә эчке дөньям үзенә җәлеп иткәндерме, көтмәгәндә генә, Салих абый болай дип әйтеп куйды:

—Сине мин, бәгырь, бер гүзәл белән таныштырам. Таныштырам гына түгел, кавыштырам да. Башкодалык вазифаларын да үз өстемә алам. Үзеңне белмәгән, күрмәгән кәләш кулына биреп, ятлар кочагына кертәсем килми. Туеңда, ишек төбендә түгел, ә түрдә утырырга исәп тотам. Моны мин уйнап түгел, уйлап сөйлимен. Операга, "Чио-Чио-сан"га йөрисеңме?

—Йөрим.

—Димәк, ул сиңа ошый.

—Ошый.

—Операсымы, әллә артисткасымы?

—Операсы да, артисткасы да.

—Мин үзем дә, сагышлы опералар иҗат иткән, маэстро Пуччини музыкасын тыңлап, күңелемә ләззәт, шифа табам. "Тоска", "Богема", "Чио-Чио-сан" булсынмы?.. Сүз уңаеннан әйтим, "Кәккүк", "Рокыя", "Комсомол мөнәҗәте" дигән җырулары белән халыкка билгеле булган Солтан Габәши "Чио-Чио-сан"ны татарчага тәрҗемә кылган иде. Әмма сәхнәдә куелмады. Кульязма килеш калды. "Чио-Чио-сан" ролен башкаручы, сопрано тавышлы безнең уртак таныш солисткага килгәндә, ул гүзәл. "Чио-Чио-сан"ны күрсәң, миннән сәлам тапшыр үзенә һәм иҗатта да яңа уңышлар телә. Кем белә, Аллаһы Тәгалә боерган булса, бәлки минем музыкаль әсәрләр дә опера сәхнәсенә менәр? Ул солисткага әле минем тарафтан тудырылган арияләр дә башкарырга туры килмәгәе?.. Йә, Йода, шулай була күрсен иде. Үзем дирижерлык итәр идем. Без белгән "Чио-Чио-сан", әйе, гүзәл. Әмма ул сиңа пар түгел. Урыс драматургы Александр Островскийның "Бирнәсез кыз"ын караганың бармы?.. Лариса образы аша драматург хакыйкатьне учка сала, күзләребезне ача түгелме?..

Салих абый мине таныштырачак вә кавыштырачак кызның исеме Фатыймаи-Зөһрә икән. Фатыйма-и-Зөһрә!.. Ике исемле кыз мине сихерләде түгелме?.. Ул минем колак төбендә дә яңгырый, күңел түрендә дә яши. Шушы исем белән кояш бата, ай калка, йолдызлар җемелди, ак карлар ява, тәрәзәләргә кышкы сурәт, бизәк төшә. Урамнардагы диварлар, ташлар телгә килә. Пушкин урамындагы бер катлы кирпеч йортның ишеген ачып кергәч, мин Фатыйма белән Зөһрәне күрәм. Фатыйма апа мин яшәгән йортның хуҗабикәсе, ә Зөһрә аның бердәнбер кызы. Туры килә бит, беренчесенең мулла кушкан исеме Фатыйма булса, икенчесенеке—Зөһрә. Өчәүләшеп, өстәл артына чәйләргә утырдык исә, кылт итеп, минем исләремә Салих абый әйткән бер исем: Фатыймаи-Зөһрә төшә. Кайчак мин хуҗабикәнең кызына "Фатыймаи-Зөһрә" дип эндәшкәнемне үзем дә сизми калам.

—Соңгы вакытта син әллә нәрсә сәерләнден,—ди кызның әнисе. —Синең өчен мин хафалана башладым. Андый түгел кебек идең, күз алдында үзгәрдең. Әйтер идем, бик тә кыска вакыт эчендә. Синең белән әллә берәр нәрсә булдымы? Хезмәт иткән урыныңда дип әйтимме? Әллә авылда яшәүче әниеңнән берәр хәтәр хәбәр килдеме? Читтә, еракта, Кара диңгез буйларында калган хезмәттәшләреңнән күңелсез хат кермәдеме? Өстеңнән шикаять язмадыларммы? Берәр хәрбиең бәхетсезлеккә дучар булмадымы? Әллә, майтәм, берәр хатын-кыз башыңны әйләндердеме?..

Фатыйма апа миңа шушындый сораулар яудыра һәм җавап көтә. Чәйле чынаяк тоткан килеш миңа озак итеп карап утыра. Үзенең бер генә соравына да җавап ала алмагач, өстәл яныннан торып китә. Бүлмә буйлап йөри-йөри дә биленә таянып болай ди:

—Ничә айлар кузгалмаган билем кузгалды. Мин бит сине балам кебек якын күрәм. Кызым Зөһрә ул турыда белә, ә син ләм-мим, авызыңа су

капкансың. Сине композитор Салих Сәйдәш янында еш була, диләр. Әллә үзенне ул сихерләдеме?.. Аны Әдрән диңгезгә сәяхәткә китәргә җыена дип ишеттем, шул дөресме?..

Ниһаять, әнисенә кызы Зөһрә кушыла:

—Салих абыйның колагына әйт әле, мөмкин булса, ул миңа Әдрән диңгезне тасвирлаган күренешләрне алып кайтсын иде.

—Табигать күренешләренме?

—Әйе, шуларны.

—Чыннан да рәссам булырга җыенучы бердәнбер кызымны сөендер әле, Зөһрәнең бер хыялы бар.

—Нинди хыял?

—Әнием, зинһар, әйтә күрмә, ул тормышка ашмаячак...

—Нинди хыял, яшерми генә әйтегез инде...

—Зөһрә кызым Салих Сәйдәшнең сурәтен ясамакчы. Концерт вакытында...

—Әнием, яшьлек серемне ача күрмә.

—Ачам, кызым, күпме яшерергә мөмкин.

—Әйтәсенне әйтеп бетер, Фатыйма апа.

—Әйтәсе сүземнең ахыры шул: концертта Салих Сәйдәш дирижерлык иткәндә, кызымның ясаган эскизлары бар инде.

—Менә яңалык.

—Салих абыйның үзенә җиткерә күрмә, үтенеп сорыйм,—диде Зөһрә, дулкынланып.

—Гүргә кергәндә дә әйтмәмен.

—Сиңа үләргә иртәрәк әле,—диде Фатыйма. —Салих Сәйдәшне Әдрән диңгез якларына сәяхәткә озатасың бар. Изге сәфәрләр теләп икендедә дога кылачакмын.

—Минем күзаллавымча, композиторның скульптура сурәте болай булачак: шома ак маңгай, дулкынланып торган чәчләре, ап-ак якасына таккан кара күбәләге. Уң кулында тирә-якка аһәң таратып торган тылсымлы таяк. Өстендә ыспай гына дирижерлык костюмы. Пакь кеше сурәтенең төсе дә ак булырга тиештер. Бәлки мин аны ак мәрмәрдән эшләрмен. Мин аның ак бизәкле музыкасыннан пакь моңнар ишеттем. Салих абыйның көйләрен тыңлаганда җан да, тән дә чистара, сафлана. Әйтерсең лә алар сине ак ефәккә төрә...

—Оныта язганмын, сиңа хат бар,—диде Фатыйма ханым. —Менә ул.

Сәлам-хат, сугыш вакытында безнең Тау якларына Мәскәүдән күчеп килгән Гөләндәм туташтан иде. Аның белән мин үзем фронтка киткәнче, Татар Тимәше дигән күрше авылда укытучы булып эшләгәндә танышкан идем. Минем беренче гыйшкымны Нәкый ага Исәнбәтнең дә күргәне бар, алай гына түгел, алар танышлар да. Шул мин укыткан татар авылында танышканнар иде. 1943 елның ахырларында, каты сугыш барган көннәрдә, без—бер төркем яшьләр авыл клубы сәхнәсендә "Галиябану" пьесасын куйган идек. Гөләндәм—Галиябану, мин—Хәлил булып уйнадык. Безнең якка килеп чыккан язучы, тамашачы сыйфатында залда утырып, безне йотлыгып карады. Карады гынамы, шулай ук без—яшьләр уздырган мәҗлестә дә катнашты, түрдә Гөләндәм белән серләшеп утырды. Ул мәҗлестә Гөләндәм авыл яшьләре исеменнән Нәкый аганы туган көне белән котлады. Бу халәттән нишләргә дә белмәгән Казан кунагы каушавыннан Гөләндәмне үпте. Соңыннан белдем, Нәкый ага Тау ягына татар халык мәкальләрен туплау нияте белән килгән булган икән. Татар Тимәшенең күршесендәге Сериле авылы турындагы "Сериле—икмәк иле, он иле",—дигән әйтемнең өч томлык "Татар халык мәкальләре"нә керүе—авыз иҗатын халыкның үзеннән җыюына мине тәмам инандырды. Сүз уңаеннан әйтим, Нәкый агага кадәр безнең якта тагын бер мәшһүр кеше—мандолинада уйнаучы виртуоз Исмәгыйль Һилалов булган иде инде. Юк, сугыш барганда түгел, сугышка кадәр үк, утызынчы елларның ахырында Исмәгыйль аганың моңлы мандолинасын тыңлаганда мин малай гына идем

әле. Шулай да аның моңы күңелемә сеңеп калды. Чәчләремә чал кергәч, мин ул мандолина һәм анын уйнаучысы турында "Мандолина—яшьлек сазым" дигән шигырь иҗат иттем, ә Сара апа Садыйкова аңа көй язды:

Уйна, чынла, мандолина,
Яшьлегемне искә ал.
Озак яшәдек җанга-җан,
Тагын да янымда кал.
Мандолина, мандолина,
Юлдашым син гомергә.
Яшьлектә дә, чал чакта да,
Моңлы сазым, без бергә.
Акбүз атлар канат булган
Дәртле елларны сөйлә.
Сулар кичкән, утлар үткән
Данлы җырларны көйлә.

Унҗиде яшьтән миңа чын мәгънәсендә утлар-сулар кичәргә туры килде. Минем белән бер сафларда "Сериле—икмәк иле, он иле" егетләре дә бар иде. Гөләндәм шаһит, ул мине һәм минем шикелле аркага биштәр аскан мыексыз егетләрне, карга бата-чума, кырлар, яланнар аша, Канаш станциясенә кадәр җәяү озата килде. Безләрне, качмасыннар дип, коралы милиционерлар юл өстендәге авылларны читләтеп узарга мәҗбүр иттеләр. "Бозау" вагоннарын паровозга тагып, аларга без—рекрутлар утыргач та, якыннарыбыз белән саубуллашырга рөхсәт итмәделәр. Эшелон кузгалып киткәндә, минем Гөләндәмем, сөекле туташым, чуен баганага сөялеп калды. Шуннан бирле ул, өзелеп, минем белән кавышуны көтә... Аны мин оныта алмыйм, үзен дә, шигъри исемен дә. Ә Салих абыйның телендә (телендә генә микән?) икенче исем—Фатыймаи-Зөһрә!.. Аның теләге—кыз белән мине таныштыру гына түгел, ә кавыштыру да. Белгәнемчә, маэстро ике сөйли торганнардан түгел, үз дигәнен эшли, тормышка ашыра торган кеше. "Кирәкми! Таныштырма да, кавыштырма да. Исеме җыр сорап торган Гөләндәм исемле сөйгән ярым, өзелеп көткән кәләшем бар минем",—дип әйтәсем булган икән үзенә. Чыннан да, әйтеп салган булсам, кулы белән авызымны капламас иде әле. Ул андый кырыс-хирыслардан түгел. Юк, түгел! Шулай да үз сүзен сүз итә торган сыйфатлары күзгә күренеп, бәрелеп тора. Үз сүзен сүз итмәсә, теләгенә, максатына ирешмәсә, шундый илаһилыкка күтәрелә алмас иде. Юк, маэстро белән сүзгә килү, бәхәсләшү, анын әйткәнен кире кагу мөмкин түгел. Аның һәр сүзе, кем әйтмешли, каккан казык! Шигырь белән җенләнгән бер бәндә буларак, "казык" дигәч, аның белән янәшәдә "язык" сүзе булырга тиеш шикелле. Әйе, бер үк вакытта ике кызны сөю минем өчен языктыр, әлбәттә. Ә бит маэстро минем күңел түрендә гүя пәйгамбәр булып утыра. Шулай итеп, Фатыймаи-Зөһрә белән танышу-кавышу, ничекләр итеп, язык, гөнаһ булсын?!. Бигайбә! Тагын шунысы, Салих абыйның башкодалыгыннан баш тартсам, аны рәнҗетүем, кәефен төшерүем, күңеленә яра салуым ихтимал. Ә бу инде Салих абый тарафыннан шедеврлар язылмаячак дигән сүз. Юк, Салих абый кебек Салих абый булган кешене күңелсезләндереп, минем татар музыкасына аяк чаласым килми. Килми! Киресенчә, татар музыкасы чәчәк атсын иде. Әлеге кыз белән танышырга, кавышырга телимме, теләмимме, композитор үтенечен мин канәгатьләндерергә тиешмен. Тиешмен! Икеләнүләр, шикләнүләр бетсен, тузганаклардай очып китсен. Минем урында бүтән яшь кеше булса да Салих абый тәкъдименә ул баш-аягы белән риза булыр иде. Ничек инде шундый зыялының сүзен аяк астына саласың?! Юк, кыюлыгың, батырлыгың җитмәс... Моң-аһәң, музыка Тәңресе бит ул—Салих Сәйдәш!

Ни сәбәпләр белән Салих абый үз өстенә димчелек вазифаларын алмакчы әле? Ә бит кушу, әмер-боерыклар биреп гашыйк булырга мәҗбүр итү мөмкин түгел. Композитор моны аңламый микәнни? Мин теләмәсәм, ул кыз

миңа ошамаса, күңелемне җәлеп итмәсә?.. Уңайсыз, алай гынамы, четерекле хәлдә калдым түгелме? Бүтән яр кирәкми, минем үз Гөләндәмем бар, дип, Салих абыйга ничекләр итеп әйтергә?.. Йә, Хода, бирсәнә кыюлык! Әйтергә икән, әйтергә, бүген булмаса, иртәгә! Аннары соң булуы мөмкин. Әйе, мин ихтыяр көчемне югалтмаска, үз мәхәббәтемне саклап калырга тиешмен, хәтта мәҗбүрмен! Фатыймаи-Зөһрә белән безнең аралар тирәнәеп китсә, нишләрмен?. Мин бит ут белән су арасында: йә яначакмын, йә батачакмын—мәхәббәт утында, сөю дәрьясында. Мин Гөләндәмне өзелеп сөям: ничә елдан бирле үзе белән хатлар алышам. Ялга чыксам, тизрәк аны кайтып күрергә ашкынам. Күптән түгел генә аның туган авылында (Мәскәү кызы булса да, ул Татар Тимәшен туган авылы дип саный иде) очрашкан идек, сөйләшеп, серләшеп туя алмадык. Күзгә-күз карашып, күпме генә серләшсәк тә, әйтәсебез бетмәде, калды. Хәер, мәхәббәт серле ул. Тылсым артыннан тылсым, бигрәк тә берен Таһир, ә икенчең Зөһрә булганда... Яшьлегендә Салих абыйның мәхәббәте нинди булды икән? Ни исемле кызны үзенең беренче гыйшкы, күңел чәчәге итте икән? Беләсе генә иде. Спектакльләрдә Мәйсәрә, Сәрвәр, Гөлйөзем, Фәридә, Зөһрә... исемле кызларга җырлар багышлаган ул. Шул тикле кызларны ничек сөяргә мөмкин? Юк, Салих абый тәгаен берне генә сөйгәндер, аның мәхәббәте бер генә булган, күзләре, уйчан, зәңгәр күзләре шулай, диләр. Аның беренче тапкыр өзелеп, онытылып сөйгән яры ни исемле булды икән? Сафия дә, Асия дә түгелдер. Бәлки, шагыйрь Блок күкләргә чөйгән Валя-Валентинадыр?.. Сорыйсы гына иде Салих абыйдан. Әйтер микән? Әллә ул аның сереме, чишелмәс тылсымлы сереме? Ә бәлки әйтелмәгән васыятьтер? Ә бәлки әйтелгән васыятьтер? Кем колагына әйтте икән ул беренче мәхәббәтенең исемен?.. Юк, яшьлегендәге сөйгән ярының исемен сорап, Салих абыйны борчымаскадыр... Бәлки аның күңеле болай да яралыдыр... Ә менә Фатыймаи-Зөһрә белән маэстро очраштырсын иде. Минем Гөләндәмем буй-сынга, чибәрлеккә Фатыймаи-Зөһрәдән кимме, артыкмы?.. Гөләндәмнең холкы, сабыр тәне—сары алтын. Ә Фатыймаи-Зөһрәнеке нинди?.. Үз-үзен тотышы, эчке дөньясы, гомумән мәнфәгате, миңа карата мөнәсәбәте?..

Мин—яшь буйдак, Фатыймаи-Зөһрәне күрергә теләк белдергәч, Салих абый: "Сабырлык! Сабыр иткән морадына ирешкән",—дип әйтеп куйды. Минем өчен бу көтелмәгән җавап иде. Көннәр, атналар, айлар узды. Җәй җитте. Очрашкан, күрешкән саен Салих абый телендәге шул бер исемне—Фатыймаи-Зөһрәне искә төшерә:

—Таныштырам дигәч, бәгырь, таныштырам инде...

—Озаккарак китте түгелме?

—Озак—азак түгел әле ул.

—Фатыймаи-Зөһрә бәлки ул сезнең хыял гынадыр?

—Юк, хыял түгел, Фатыйма-и-Зөһрә бар ул, яши. Ул кайчандыр синең туган якларда, Сембер җирләрендә яшәгән.

—Ә хәзер кайда?

—Күк белән җир арасында, Зөһрә йолдыз шикелле, исеме дә Фатыймаи-Зөһрә бит аның. Төскә бик тә матур үзе.

—Эшкә ничегрәк?

—Анысын өйләнешкәч сынарсың инде. Күпме белеп, үзен эшләтеп караганым булмады. Тегү-чигүгә оста. Музыкант, моңлы милли көйләрне ярата. Үзе дә җырлый, тавышы бәгырьгә үтә. "Уел", "Сибелә чәчәк", "Зәңгәр шәл", "Һаваларда йолдыз", "Бәгырем" кебек халык җырларын башкарганын тыңлаганым бар.

—Җырчымыни?

—Җырчы... Әмма без белгән "Чио-Чио-сан" кебек арияләр башкармый, әлбәттә.

—Фатыйма-и-Зөһрәне музыкант та дип әйттегез, ә ул нинди музыка коралларында уйный?

—Нәкъ син әйткәнчә, берсендә генә түгел, әллә ничә коралда уйный белә ул: мандолина, скрипка, пианинода. Кыскасы, гашыйк булырлык кыз:

"Агыйделдә йөрсәң иде
Камыштан көймә үреп;
Былбыл булып, гөлгә кунып, бәгырем,
Сөйләшсәң иде күреп",—

дип, сиңа өмет итәргә генә кала. Юк, танышу вә кавышу минутларын көтәргә дә кирәк булачак. Сабыр җепләрең өзелә күрмәсен...

Июль аенда без кавыштык, әмма Фатыймаи-Зөһрә белән түгел, ә Гөләндәм белән. Юк, сабыр җепләре өзелүдән түгел, яшьлектә вәгъдәләр бирешкәнгә. Ә яшьлек вәгъдәсеннән дә изге вәгъдә бар микән? Юктыр! Гөләндәм белән өйләнешкәнче, Фатыймаи-Зөһрәне күрергә теләсәм дә туры китерә алмадым. Салих абый аның белән таныштыруны гел суза килде. Ә инде өйләнүемне үзенә хәбәр иткәч, ул миңа суынды, алай гынамы, минем белән очрашудан, гәпләшүдән кача башлады. Кыскасы, аның өчен мин ят бер кешегә әверелдем. Соңгы очрашуны санамаганда миңа карата Салих абый шушы мөнәсәбәттә, шушы халәттә үлеп китте. Ә минем халәтем гүргә керерлек иде. Үземне мин Салих абый алдында гаепле дип хис иттем. Үзем генә белгән гаепне ничәмә еллар күтәреп йөрдем. Шул озын вакыт эчендә Әмирхан Еникинең Салих Сәйдәшев мәхәббәтенә багышланган "Гөләндәм туташ хатирәсе" дигән әсәре басылып, укучыларның күнелләренә үтеп керде. Сәйдәшнең беренче сөйгән яры Гөләндәм исемле булган икән, дигән кыйсса бөтен җиһанга таралды. Әсәргә нигезләнеп, мин үзем дә фәкать шулай уйладым. "Кандыр буе"нда (К. Тинчурин, С. Сәйдәш музыкасы), "Чын мәхәббәт"тә (Т. Гыйззәт, С. Сәйдәш музыкасы) тикмәгә генә Гөләндәм образлары бирелмәгәндер дип сөенеп йөрдем...

Татар академия театры ишегалдындагы йорт, Сәйдәш вафат булганнан соң, ятим, үксез хәлдә калды. Шулай да аның ишеген, бигрәк тә караңгы төннәрен, йолдызлар сүнгән вакытларда кемдер ачып-кереп йөри кебек тоела иде. Бәлки, ул йорт иясе, Салих абый рухы булгандыр?.. Әгәр якынлашсам, минем белән очрашудан качып китәр кебек иде ул. Фатыймаи-Зөһрә өчен үпкә тота—дияр идем мин.

Ниһаять, Салих абый торган йорт музейга әверелде, тантаналы төстә ачылды. Әмма мин анда барырга ашкынмадым. Ятим, үксез йортта мәңгелек җанны, йорт иясен, Салих абый рухын яшәтәсем килде. Музей йорты ачылганда дөнья яңгыратып музыкалар уйналгач, төнге җан, йорт иясе, Салих абый рухыннан җилләр искәндер кебек. Шулай булып чыкты да, йорт-музейга әверелгәч, инде мин әлеге җанны Салих абыйның ишегалдында очрата алмадым. Әмма музей-йортның икенче катындагы диварда эленеп торган бер экспонатка—гарәп әлифбасы белән язылган язмага тап булдым. Салих абыйның беренче гыйшкы Фатыймаи-Зөһрә язмасы икән ул!!! Ул язманы диварга теге төнге җан, йорт иясе элмәдеме икән? Моны ул үз белдеге беләнме, әллә Салих абый рөхсәте белән эшләдеме икән? Тирән сер дөньяга ачылган ич! Шулай итеп, Салих абыйның гүргә кергәнче теленнән төшмәгән исем, беренче һәм соңгы сөйгән яры, Гөләндәм түгел, ә Фатыймаи-Зөһрә булган икән!!!

Фатыймаи-Зөһрә турында шундый риваять бар... Ул—Сембер кызы бер бай гаиләсендә туа, балачагы да шул шәһәрдә уза. Үсмер яшендә әти-әнисе белән Казанга күчеп килә. Мәркәзебездә яшәгәндә Сәйдәш, өйләренә йөреп, кызга музыка дәресләре бирә, милли җырлар өйрәтә. Шул еллар арасында ике яшь йөрәк гашыйк булып, кавышырга телиләр. Әмма кырыс язмыш аларның юлларын ике якка аера. Салих унсигез яшендә өстенә шинель, башына шлем-буденновка киеп, башта Оренбургка, аннары Төркстан якларына китә. Мәхәббәт уты белән янган кыю йөрәкле Фатыймаи-Зөһрә, сөйгән егете Салих белән кавышу теләгеннән, ерак шәрекъ җирләренә сәфәр тота. Кыз, Төркстанның атышлар барган, туплар яңгыраган төрле төбәкләрендә була. Әмма сөеклесен очрата алмый. Ниһаять, Ташкентта урнашкан милләттәшләре, татарлар арасында яшәп кала. Айлар гына түгел, еллар да уза. Сабыр канатлары сынарга җиткән чибәр туташ бер әфганлы

мөселманга кияүгә чыга. Ватан сугышы башланыр алдыннан, аның ире репрессиягә эләгә. Фатыймаи-Зөһрә чит җирдә ике кызы белән кала. Уйсагышка баткан сәгатьләрдә, хисле яшь ханым үзенең беренче мәхәббәте турында кызларына сөйли, ә кайчакларда, каләм тотып, истәлекләр яза. Тора-бара кәгазьгә төшкән язмалар берничә дәфтәргә әверелә... Ләкин ул көтмәгәндә каты авырып китә. Үләр сәгатьләре җиткәч, язмаларны кызларына тапшыра. Әниләренең үзләренә генә билгеле булган мәхәббәтен бәндәләргә, мир-дөньяга белдермәс өчен, кызлар дәфтәрләрне яндыралар. Шулай итеп, сөю уты сүнә.

Бер төркем татар һәм башкорт артистлары белән (Рәшит Ваһапов, Әсма Шәймөратова, Фәйзи Биккинин, Мәҗит Илдар) үзенең иҗат концертларын Ташкентта үткәреп йөргән көннәрдә, Салих Сәйдәшев Фатыймаи-Зөһрә Солтанова белән очрашкан дигән сүз йөри... Шулай булгач, Салих абый мине Фатыймаи-Зөһрә кызларының берсе белән таныштырырга вә кавыштырырга хыялланмадымы икән? Яшьлегендә Салих абый сөйгән Фатыймаи-Зөһрәнең бер кызы үз әнисенең исемен (Фатыймаи-Зөһрә булып) йөртмәдеме икән?..

## Ир канаты ат була

—Салих абый, сезгә мин олы бер мишәр агайдан сәлам алып килдем. Кабул итсәгез, тапшырам.

—Казан каласында яшәүче мишәрмени?

—Сәлам тапшыручы агай Казанныкы түгел, читтән килгән кеше.

—Син, бәгырь, килгән саен бер мишәрдән сәлам тапшырасың, күпкә китте түгелме?

—Димәк, сезне кырыкмаса кырык җирдә, кырык илдә кайнап торган самавыр көтә... Беләсезме, мин кемнән сәлам алып килдем?.. Якташым Зариф Бәширидән!..

—Хәтерлим мин Зариф абый Бәширине... Кәрим абый Тинчурин шикелле "Мөхәммәдия" мәдрәсәсендә укыды. Язучы иде. Шигырьләр, хикәяләр, әдәби мәкаләләр язды. Укымышлы кеше.

—Тукайны да, Такташны да күреп белгән икән ул. Алар турында дулкынланып сөйләде. Үзенә Тукайдан тәнкыйть сүзе эләгүен, Такташ белән нииндидер бер шигырь өчен низагка керүен дә әйтте.

—"Таң кызы" дигән шигырь өчен бугай, ул чакта мин дә Ташкентта идем. Минем шикелле ул да шәрекъ якларын күнеленә хуш күргән бер бәндә... Сәлам тапшырды дисең... Бәгырь, Зариф абый Бәшири исән димәк. Ә бит ул шактый олы яшьтә. Миңа абый булса, сиңа—бабай кеше. Сакал үстереп җибәрмәгәнме соң?

—Юк.

—Хәтерем ялгышмаса, Кәрим абый Тинчуриннан ул тик бер яшькә генә кече. Тукай замандашы. Тукай турында, замандашларына багышлап истәлекләр китабы язганын беләм. Туган тел китабында "Чуаш кызы Әнисә" дигән повесте да бар икән. Милләттәшләребез "Чуаш кызы" белән таныш. Ә син, бәгырь, ул әсәрне укыдыңмы?

—Кызганычка каршы, укырга туры килмәде.

—Шулайдыр, Октябрь җил-давылларына кадәр үк нәшер ителде бугай ул.

—Ә сез укыдыгызмы?

—Укыдым, Буада чуаш хоры белән җитәкчелек иткәндә укырга мәҗбүр булдым. "Чуаш кызы Әнисә" белән танышырга Фәтхи Бурнаш тәкъдим итте. Зариф абый Бәшири хәзер ниндирәк: кыяфәте, дөньяга карашы, хәлэхвәле, кәеф-сафасы дип әйтимме?

—Күңеле күтәренке дип әйтмәс идем. Өфе белән Казан юлын күпме таптыйм, ә замандашларым турында язылган истәлекләремне аерым бер китап итеп чыгару һаман унай хәл ителми, ди. Казандагылар аны яратып

ук бетермиләр дип хафалана. Илле еллык иҗат стажы булып та, ул әле Язучылар союзы әгъзасы түгел икән! Ә болай тышкы кыяфәте ыспай күренә: яңа костюмнан, галстуклы, башында фетр эшләпә. Зыялы, аксөяк икәнлеге күзгә бәрелеп тора.

—Чандыр гәүдәле, ябык чырайлы, йөзендә елмаю нуры.

—Элек тә шундый иде ул, үзгәрмәгән икән.

—Тау ягы авылыннан—Чүтидән икән ул! Минем үги әбием дә шуннан. Минем бабай, хатыны—ягъни әбием дөм сукырайгач, Чүтидән үги әбине икенче хатын итеп алган. Әниемнеке кебек үк исеме дә Сәйриҗиһан. Шуларга өстәп, әниемнең әтисе—Төхфәт бабай кече кызына да Сәйриҗиһан исемен кушкан... Кыз бала язмышы—канатлы кош язмышы: берсе еракларга очып китсә, барыбер Сәйриҗиһан исемле икенчесе янда кала икән. Шулай, көннәрдән бер көнне, кече Сәйриҗиһанны Чүти авылына җайдак егет урлап киткән. Өзәнге нәселеннән булмадымы икән ул егет, ди Зарифҗан мин сөйләгән кызның язмышы белән кызыксынып. Чүтидә Рәхим бабай нәселен шул кушамат белән йөртәләр. Беләсеңме, Рәхим кем булып чыга—Шәкүр каракның әтисе!.. Элек-электән, ат белән эш иткәнгә, Шәкүрләр нәселенә Өзәңге кушаматы бирелгән. Шәхсән мин үзем Шәкүрне "Карчыга" дип атый идем. Аның күзләре бик тә үткен, адәмне генә түгел, вә галәмне дә үтә күрә иде. Бала еласа, кинәттән үлеп китсә Шәкүрнең күзе тигән, дип әйтәләр иде. Бала белән генәме, мал-туар белән дә шулай. Ә Шәкүрнең күзләре чынында исә колынга, атка җан өрә, җан кертә иде. Шәкүр күккә караса, йолдыз атыла, һавада очкан кош җиргә кадалып төшә, дип тә сөйлиләр иде. Адәм белән генә түгел, галәм белән дә эш итәрлек, эш йөртерлек кеше, гөнаһ шомлыгына каршы, җиде ир туганы белән ялгыш юлга кереп китте, ат урлау белән шөгыльләнде. Җиде гөнаһкярнең җидесенә дә "Ат карагы" дигән бер мөһер сугылды. Шәкүр вә Зиннәтҗан Рәхимовлар атылды. Калган өч ир туганы: Әхмәтҗан, Хөснетдин вә Ади, ат урлаганда тотылып, Шәкүр белән Зиннәтҗаннан элегрәк, йә кыйналып, йә суга батырып үтерелде. Тагын ике ат карагы—Фәхретдин белән Алим һәрбере унбишәр ел патша төрмәсендә утырып чыкты. Рәхим картның бары бер улы гына—Мөхәммәтҗан гына приказчик иде, анысы да агалары урлаганны сатты. Бер ул гына, үз үлеме белән—үпкә авыруы белән үлде. Шәкүр карак, алтмыш алты ел гомер сөреп, шуның кырыктан артыгын ат урлауга багышлаган. Ә үзен Чуашстанга кергән Батыр өязендәге бер авылда тотканнар, чукынмаган чуаш хатыны йортында чәй эчеп утырган чагы булган.

Батыр—Җәлчек төбәгендә чукынмаган чуашлар да бар. Үзләре мәҗүсиләр, исемнәре төрки: Илбәк, Мирза, Назыл, Ахун... Кәримә, Сәлимә, Әнисә... Унтугызынчы гасыр ахырында яшәгән җырчы-шагыйрә Әминә дә чукындырылмаган чуаш кызы, Чүтидән унбиш чакрымдагы Өчиле авылыннан. Ә чукындырылган чуашлар ул авылны үзләренчә Вишпүрт дип атыйлар. Чукындырылмаган чуашлар татар җырларын үлеп ярата... Шәкүр дә алар янына борынгы татар җыруларын тыңларга йөргән. Авылдашлары сөйләвенчә, Шәкүр мәҗлесләрдә карчыклардан мөнәҗәтләр әйттергән. Тирә-як авылларда яшәүче ярлы-ябагайларга ярдәм иткәнгәме, аны изге кеше дип санаганнар. Бу, якты дөньядан битәррәк, Шәкүр теге дөньядан, ахирәттән курыккан. Үзен хаҗи дип исәпләп, мәчет картлары белән бергә намаз укыган, хәер-сәдака биргән, ураза тоткан, корбан чалган. Кирәк икән, динебез хакына канатлы атымны чалырга да ризамын, дигән. Чүти каһарманы Шәкүр вә аның бәбкәчләре турында төрле риваятьләр бар. Ул инде халык авыз иҗатының бер пәһлеванына әверелде. Шәхсән минем үземдә дә кыю йөрәкле авылдаш турында тарихи әсәр язарлык мәгълүматлар бар. Әмма ул конкрет образ "Зәңгәр шәл" музыкаль драмасында тамашачы күңеленә үтеп керерлек итеп тасвирланган. Пьесадагы ат караучы Миңлегалине тамашачы, сөйләгән сүзләрен ишетеп, сукыр булса да, таный. Сәхнәдә генә ул Миңлегали, ә чынбарлыкта, тормышта, валлаһи дип әйтәм, ул Шәкүр карак! Драматург, әйтерсең, Шәкүр каракның сүзен-сүзгә язып

алган!.. Искитмәле! Күпме гомер сөреп, үзем белгән кеше сурәтен сәхнәдә күрәм, сөйләгән сүзләрен үз колакларым белән ишетәм... Мәшһүр Сәйдәш безнең якта үзе булган, Шәкүр карак белән очрашкан, сөйләшкән, бер өстәл артында утырган, бер самавырдан, өф-өф итеп, чәй эчкән диләр. Әлеге чукындырылмаган инкә-җиңги йортында очрашканнар, имеш...

—Сәлам тапшыруың сузылды түгелме, бәгырь? Хәер, зыяны юк, чирек гасырга бер тапшырылган сәлам. Зариф абыйны, соңгы тапкыр, гастрольдә чакта, Ташкентта очраткан идем.

—Шәкүр карак белән сезнең хакта бер риваять бар икән.

—Кемнән ишеттең?

—Зариф ага Бәширидән.

—Ниндирәк икән ул?

—Болайрак ул, Салих абый... Сембер якларыннан бормалы вә сикәлтәле юллар белән кайтканда, көзге яңгырлы көнне, авыл кырыендагы бер йортка ике кеше килеп керә. Берсенең башында эшләпә, икенчесендә кәләпүш икән. Көтелмәгән кунакларны күргәч, өйдә аш-су әзерләп маташучы гарип бәндә бик нык кызыксына:

—Эт тә йөрмәс һавада сезне монда нинди җилләр ташлады? Нәрсә эзләп йөрисез?.. Мал табылсын дип, җаныгыз да җәл түгел, ә? Сәүдәгәрләрдер инде. Бикле тартмаларыгыз әйтеп тора. Алтын-көмеш белән тулганга охшый... Алла колы түгел, алтын-көмеш колы ул адәм дигәнең. Тартмаларыгызны ачыгыз!..

Эшләпәле белән кәләпүшле музыка кораллары тутырылган футлярларны ачарга мәҗбүр була.

—Нәмәрсә бу?—дип, каныгуын дәвам итә гарип-бөкре бәндә, борылмалы-сырылмалы, музыка коралын күргәч. —Җиз сыбызгы да буламыни?

—Сиңа җиз сыбызгы булса, чын исеме аның—быргы!—ди эшләпәлесе.

Олы тартма ачылып, төрле гармуннар күрсәтелә.

—Хаҗи йодрыгы хәтле генә гармун да була икән!—ди гарип. —Ә бусы кыңгыраулы гармун... Сәүдәгәрләр түгел, сез—музыклар икән, мин—мужикны гафу итегез!.. Мужиклар арасында яшәгәч, мужик булмый хәлең юк. Кем әйтмешли, ата мужик үзе дә, аның ата казы да мужиктан. Мужиктан мужик туа, музыктан музык була. Минем мужиклык сәләтем: ат җигү, ат иярләү... Сез мине бу гарип-бөкре димәгез! Минем дә хаҗи шикелле канатым—ат-аргамак. Каз канаты кат-кат була, ир канаты ат була!.. Нәкъ җырдагы сымак. Ә сез музыклар, нинди сәләткә ия?.. Әллә, мәйтәм, сез музык әйберләр белән сәүдә итүчеләрме?.. Алай икән, көмеш вә бакыр акчаларыгызны өстәлгә чыгарып салыгыз!

—Эшләпәлесе дә, кәләпүшлесе дә үзләрендә булган акчаларын тиенենә тикле өстәл өстенә куярга мәҗбүр булалар.

—Сез, җәмәгать, чыннан да музыклар икән!—ди гарип.

—Без артистлар,—ди кәләпүшлесе.

—Музыклар түгелмени?—ди гарип.

—Без вә музыкантлар да, вә артистлар да,—ди эшләпәлесе.

—Гармунда кайсыгыз уйный?—ди гарип.

—Мин дә, Салих та—икебез дә,—ди кәләпүшлесе.

—Ә җиз сыбызгыда кем уйный?

—Салих Сәйдәш!

—Хәзрәти...

Гарип әйтер сүзен әйтеп бетерә алмый, шул чак ишектә, үзе белән берничә кешене ияртеп, озын буйлы, киң җилкәле, таза гәүдәле сакалбай күренә.

—Хуш киләсез, Хаҗи!—ди хуҗабикә.

—Хаҗи бабай килде! Хаҗи бабай килде!—ди хуҗабикә кызы, аяк астында бөтерелеп.

—И, тәкъсир!—ди гарип.

—Әссәламегаләйкүм, абзыйлар!—ди мәһабәт кыяфәтле бәндә.

—Вәгаләйкем әссәләм!—ди өйдәгеләр, шул исәптән алар арасындагы ике музыкант та.

—Абзыйларны йөзләреннән таныйм, безнең милләт кешеләре,—ди пәһлеван гәүдәле сакалбай.

Хажи дип йөртелгән карт түргә барып утыра да:

—Дога кылып алыйк,—ди ул. —Хуҗабикә, син дә кушыл. Мәҗүсилектән ислам диненә күчәргә вакыт. Әйдә, кыз балаң белән бергә, син дә кабатла. Абзыйлар башладык... Бисмил-лаһир-рахманир рахим. — Хажинең догасына ике музыкант та кушыла...

—"Шараитэл-иман"ны беләсез булса кирәк,—ди хажи, сәламләү догасы укылгач.

—Без икебез дә мәдрәсәләрдә укыган шәкертләр,—ди кәләпүшлесе. — Мин үзем дә, Сәйдәш тә...

Сәйдәш исемен ишеткәч, хажи утырган урыныннан торып, мәшһүр музыкантка ике кулын суза:

—Йа рабби, хәзрәти Сәйдәшне дә күрергә насыйп икән,—ди ул.—Нурлы йөзенә күзләремне тутырып, туйганчы карыйм әле... Сөбханалла! Сөбханалла! Күз тимәсен, минем күзләрем каты, диләр. Минем бәбкәчләрем синең "Кара урман", "Зәңгәр шәл", "Казан сөлгесе" җыруларыңны бик тә яратып җырлыйлар. Ничек әле?.. Калдич, калдич Казан сөлгесе, апасыннан матур сеңелесе...

—Татарларда көй чыгару язык санала,—ди хуҗабикә.—Ә үзең минем күрәзәчем гарип белән парлап җырлыйсың. Бәләкәчең дә кушыла. Шулай булгач, язык, мәйтәм, казык башында,—ди Хажи.

—Хәзрәти Сәйдәш җыруларын мин урамда да, урманда да җырлыйм:

Карурман аша,
Кошлар сайраша,
Башлар адаша,—

дип кычкырып җырлап җибәрсәм, бөкрелегем онытыла,—ди гарип.

—Әйе, мин япа-ялгызым да, парлап та җырлыйм. Моны күпләр белә. Ә менә хәзрәти Сәйдәш җырлаганны тынлыйсы иде.

—Сүз тыңлап кына булса да җырла, хәзрәти Сәйдәш,—ди хажи.— Телисеңме, мин сиңа ир-егет канаты—аргамак бүләк итәм. Дәшмисең... Күрәзәчем, син дә, мин дә, без—икебез дә дивана!.. Хәзрәти Сәйдәшнең карыны ач, шул сәбәпле дәшми ул. Ач карынга ничек җырламак кирәк?! Алайса, ашап-эчеп алыйк. Табынга рәхим итегез, карендәшләр! Мужикмы син, музыкмы син—аштан беркем дә олы түгел. Юк, түгел!..

Ашап-эчеп алгач, хажи тагы үз сүзен дәвам иттерә.

—Йә, хәзрәти Сәйдәш, кәефең күтәрелдеме?

Сәйдәш тын гына утыра. Ә хажи үзенекен сукалый:

—Бушлайга җырлата дип уйлама, ир-егет бәхете җидедән—җидегәннән дигәндәй, сиңа мин җиде көмеш бирәм... Инде үз кулларың белән алырга риза түгел икән, Аллаһы боерса, Мәккәгә хаҗга баргач, сиңа исәнлек-саулык, иминлек теләп, ул җиде көмешне хәер-сәдака итеп бирәм, Кәгъбә ташын үбәм...

—Рәхмәт, кирәкмәс,—ди Сәйдәш. —Сүзегезне тыңлап, җыруларны гармун уйный-уйный җырлармын, дустым Фәйзи белән бергәләп, әлбәттә.

—Мең рәхмәт!—ди хажи.

Өч җыру өчесе рәттән уйнала да, җырлана да. Әлеге өч җырудан соң, "Баламишкин" башкарыла. Иң соңгысы итеп, "Казан каласы микән" җырлана:

Казан каласы микән,
Кама баласы микән?
Әллә кайтып китәргәме,
Әллә каласы микән?..

—Бәбкәләрем, чыннан да әллә каласызмы?—ди хажи, җыруны тыңлаганнан соң. —Калсагыз, үзегезгә һәр көнне кырык бәлеш пешерер идек.

Әмма ләкин музыкантлар калырга ризалык бирми...

—Шунын белән риваять бетәме?—диде Салих абый.

—Әйе, бетә.

—Юк, бетми, бәгырь... Хажи аларны—музыкантларны пар атлар белән Иделнең уң ярында урнашкан Зөя шәһәрчегенә кадәр озата килә. Үзе белән күрәзәчесен, гөнаһсыз жан гарипне дә ала... Юлда, хажи, тәфсилләп, бик тә тәмләп ат урлау турында сөйли... Белмисез, егетләр, ат урлауның рәхәтен, ләззәтен белмисез, ди. Менә караңгы төн, ди. Ындыр аркылы килеп, сырт капканың алдында туктыйсың. Йортта эт өрә башлый, син тыныңны чыгармыйча, күләгә төсле тын торасың. Шул арада аргамак жаныем абзарында пошкырып куя, йөрәкләр тиздән кавышуны сизгәнгә кытыкланып китә, сулышлар кысыла башлый. Капка астын казып йортка керәсең дә, салават укып, агуланган икмәк, ит кисәкләрен эткә ташлый торасың. Бер ярты сәгатьтән Аллага тапшырып эт жан тәслим кыла. Абзар ишегендә чабата хәтле йозак була. Бисмилла әйтеп, отмычка белән келт итеп борасың да, йозак шылт итеп борынын күтәреп куя. Абзар ишеге ачылуга, карабодай басуындагы төсле хуш исләр аңкып китә. Аргамак жаныем, күз кызлар төсле, кызыл билле прәннек кимергән кебек, кетер-кетер печән кимереп ята, сылу кызлар көлгән кебек, көязләнеп пошкырып куя. Барып ялыннан тотып сыйпагач, бәгырем, килденме дигәндәй, пуф итеп бер сулап ала. Шуннан иренен боргычлап, акрын гына сырт капкадан чыгарасың да, әгүзебисмилла әйтеп атланып, әйдә... Тфф! Менә шул чагындагы рәхәтне әйтәм, кыз куенына керүләрең бер якта кала шул. Калтырап, дерелдәп торган нык гәүдәсен аякларың белән шундый итеп кочаклыйсың. Таһир Зөһрәсен дә алай кочаклый алмагандыр. Йөрәкләрең ожмах рәхәтләрен сизә инде шул чагында. Сикергән саен бөтен гәүдәсе уналты яшьлек кызның күкрәкләре дерелдәгән төсле дер-дер килә. Менә шул дерелдәүләрдән йөрәк майларың эреп китә, әйтерсең лә, зәмзәм күлендә йөзәсеңмени, малай... Аның көчле күкрәгеннән болыт-болыт булып чыккан сулышларын, дулкын-дулкын булып уйнап торган ялларын, тояк тавышларын, матур кызлар кулында уйнаган кайчы төсле колак уйнатуларын, барысын-барысын да йөрәк белән сизеп торасың. Шул чакларда үзеңнең гәүдәңне аның гәүдәсе белән бергә туып үскән кебек итеп сизәсең. Аның жаны синең жаныңа тоташып, ат белән бер кеше була да кала. Шул кадәр жанлы якынлык була... Их, егетләр, ат урлауның тәмен, ләззәтен белмисез... Их, шайтан алгыры, тел юк аны аңлатырга!.. Шуңа күрә бик күп кеше аның тәмен дә белми... Көй-моң, жыру чыгарырлык ул ат урлауның тәме, рәхәте, ләззәте!.. Шушы чуклы-чуклы сөйләм сүзгә-сүз "Зәңгәр шәл"гә килеп керә...

—Димәк, Мәккәгә-хажга йөрүче пәһлеван гәүдәле мәчет карты—хажи шул ук Шәкүр карак дигән сүз?!

—Анысын мин өзеп әйтә алмыйм...

* * *

Мәшһүр язучы, Чүти кешесе, Шәкүр каракның авылдашы, замандашы Зариф Бәширинең раславына караганда, Тау ягы халкы композитор Салих Сәйдәшев вә Шәкүр хажи мәжүсилеккә инанучы чуаш инкәсе-жиңгие йортында очрашканнар дип сөйли килде... Салих абый Сәйдәшев вафат булганнан соң, мин үземнең яраткан жырчыларым Рәшит абый Ваһапов белән яшьтәшем Венера Шәриповаңы ияртеп, туган якка кайттым. Бер атна эчендә Батыр-Жәлчек төбәге аркылыга-буйга үтелде. Милләттәшләребез янында гына түгел, чуаш авылларында да концертлар бирелде. Шәхсән мин татар вә чуаш телләрендә шигырьләр сөйләдем. Жырчылар жырладылар. Кайда гына булсак та, Рәшит Ваһапов белән Венера Шәрипова башкаруында татарлар да, чуашлар да аеруча "Кара урман"ны, "Казан сөлге"сен, "Зәңгәр шәл"дәге Мәйсәрә жырын яратып тыңладылар, артистларны аягүрә алкышладылар. Өч авылда өч чуаш хатыны балачакта үз күзләре белән Сәйдәшне күрүләрен, әле генә уйналган көйләрне, жырланган жырларны композиторның үзеннән ишетүләрен әйттеләр. Икенче юлы әлеге

җырлар язылган тәлинкәләрне алып килүебезне үтенделәр... Әйтергә кирәк, бәхеткә каршы, үтәдем мин аларның үтенечләрен. Моңа чуаш Халык язучысы, якташым Илбәк шаһит... Шул ук елны, ягъни 1959 нын көзендә, авылындагы бер туган сеңелесенең йортында, Уфадан кунакка килгән, Зариф ага Бәширине эзләп таптым вә соңгы тапкыр аның белән күзгә-күз сөйләштем.

—Мәшһүр Салих Сәйдәшевкә минем сәламемне тапшырдыңмы?—диде ул.

—Тапшырдым.

—Сәйдәш замандашы булу үзе бер бәхет бит ул!

—Алайса, сездән дә бәхетлерәк кеше дөньяда юктыр?.. Сез, Зариф абый, Тукай, Такташ, Шәкүр караклар замандашы.

—Сәйдәшнеке дә!—диде язучы, үткен күзләре белән миңа карап.

“Шәкүр каракны күргән күзләр!”—дидем мин, уйга талып... Аннары, Урмайга күрше—Өчиле-Вишпүрт авылында туып үскән, шагыйрә Әминә[1] турында чуаш мәдәниятен, әдәбиятын биш бармагы шикелле белүче карт әдиптән сораша башладым...

Алты аргамак, бер акбүз ат—
җидесе җиде канат,—

дигән Әминәкәй үзенең “Уй-сагышларым” җыруында. Ир канаты ат булуын шагыйрә җиделәтә раслый түгелме?!

“Зәңгәр шәл” музыкаль драмасы сәхнәдә куелганда, аргамаклар-атлар дигән канатлы сүзләр ир-егетләр авызыннан кат-кат әйтелә, җырлана. Әйе:

Каз канаты кат-кат була,
Ир канаты ат була...

Аргамаклы, акбүз атлы-канатлы ир-егетләрнең тормыш юлы җыруларга тиң!..

Югары судның хөкем карары белән, барлыгы унике кеше, шул исәптән Шәкүр Рәхим улы Рәхимов (Шәкүр карак) вә тагын сигез ат карагы, бер тикшерүче, бер халык судьясы, бер авыл советы рәисе, 1926 елның 17 декабрендә, Советлар илендәге халыкның санын алу башланыр алдыннан төнгә каршы үтерелә. Шәхес культының бер корбаны булачак Кәрим Тинчуринның “Зәңгәр шәл” драмасы, Салих Сәйдәшев язган яңа оригиналь музыка белән беренче тапкыр сәхнәдә, шул канлы декабрьдән соң нәкъ биш көн узгач, 1926 елның 22 декабрендә куела. Гомерләре Вакыт-хөкемдар тарафыннан өзелү сәбәпле, унике татар кешесе, унике ир-егет, унике милләттәш, унике диндәш “Зәңгәр шәл” драмасын караудан мәхрүм булып, аның тылсымлы музыкасын тыңлый алмый. Унике татар, унике милләттәш илдәге халык санына керми кала. Тәгаен, шуңадыр Сәйдәш тарафыннан “Зәңгәр шәл” драмасына язылган музыка унике милләттәшебез истәлегенә еракларда матәм моңнары булып ишетелә. Юк, аларга гына түгел, ә бәлки мәшһүр композиторның үз истәлегенә дә. Әйткәнемчә, Шәкүр карак вә аның әшнәләре 1926 елның 17 декабрендә атыла. Ә Салих Сәйдәш әлеге милли фаҗигага нәкъ егерме сигез ел тулгач, яман шештән вафат була. Җандагы-тәндәге, җәмгыятьтәге-илдәге яман шешләр канатлы-аргамаклы җырлы-моңлы Шәкүрләрне, Сәйдәшләрне алып китә. Милләтебез өчен ике көн тоташ матәм көне:

1926 елның 17 декабрендә Шәкүр Рәхимовлар атылып үтерелә.

1954 елның 16 декабрендә Салих Сәйдәшев үлә.

Ерак еллар аша Идел, Чулман, Зөя, Карлы, Өбрә болыннарында аргамакларның үз җайдакларына тавыш-аваз биреп, кешнәүләре ишетелә... Аларга Сәйдәш җырулары-моңнары, Шәкүрнең көйләп әйткән азаннары, укыган догалары кушыла...

---

[1]Соңыннан мәҗүси шагыйрә Әминә турында, К. Латыйп тарафыннан поэма язылып, әсәр шул ук исемдә өч телдә: татар, чуаш, урыс телләрендә дөнья күрде *(авт. искәрмәсе)*.

...Шәкүр карак кебекләрне аларны халык тудыра. Әгәр Шәкүрнең исеме, җисеме Александр Пушкинга мәгълүм булса, йә Пугачевны, йә Дубровскийны тасвирлаган сымак, ул Шәкүр образын үзенең аерым бер әсәрендә, тәгаен сурәтләр иде. Ә бәлки Шәкүр карак турында рәсми мәгълүматлар туплап, аларны, "Пугачев тарихы" шикелле китап итеп тә чыгарыр иде.

Совет хөкемдарлары Шәкүр каракны ГПУ ярдәмендә юк итә. Бу сер түгел. Ул елларда советлар властына икмәк тапшырырга теләмәүче теге яки бу авылдагы крестьяннар төркеме дә бандитлар өере дип атала һәм хөкемгә тартыла. Әйтергә кирәк, бу гадәти хәл булып исәпләнә. 1921 елдан 1954 елга кадәр, ягъни утыз өч ел эчендә генә дә, Советлар илендә дүрт миллионга якын кеше хөкем ителә, шулардан—642980 кеше үлем җәзасына тартыла, ике миллион ярым кеше төрмәгә ябыла, 765180 кеше йә сөргенгә озатыла, йә яшәгән урыныннан куыла...

Үлем җәзасына тартылган 642980 кеше арасында Шәкүр карак та бар. ГПУ пулясыннан үлү—үзе бер каһарманлык ул. Шәкүр карак вә аның унбер милләттәше Казан төрмәсендә атыла.

Шәкүр каракның исеме миңа әниемнең җырлаган бишек җыры, күкрәк сөте, сөйләгән әкиятләре вә риваятьләре аша каһарманлык булып керде. Шулай булгач, мин гүрдә ятучы әниемә хыянәт итә алмыйм. Биш ир-бала дөньяга бүләк иткән әниемнең "Бәбкәләрем, ир канаты—ат була",—дигән канатлы сүзләре үземне белгәнемнән бирле күңел түремдә...

## Тәкъдир тактасы

—Син, бәгырь, минем полкташым бит әле...

—Ничек ул алай?

—Кем әйтмешли, алай түгел, калай... Казан Кремлендәге дивизия командованиесе, (комиссары Минһаҗ Сәйфи булган) "Кызыл Армия маршы" өчен, мине беренче тапкыр татар полкының почетлы кызылармеецы иткән иде. Шулай итеп, без синең белән полкташлар-яудашлар булып чыгабыз... Марш дивизиянең беренче татар укчы полкына багышланган иде. Дивизиянең бик тә сәләтле капельмейстры минем танышым иде, маршны, аның белән бергәләп, оркестрлаштырдык. Биш полкның гаскәриләре алдында, почетлы кызылармеец исеме турында приказ укылганнан соң, комдив Якуб Чанышев хәрби форманы миңа шәхсән үзе бүләк итте, ул ноталар белән бергә сандыкта саклана. Ә хәзер дивизия командиры кем?

—Полковник Автандилов.

—Нинди милләттән?

—Төгәл белмим, үзен, Дагстаннан бугай. Ә сугыш вакытында дивизиянең башында генерал Фатыйх Булатов торган.

—Пороховой Фатыйх түгел микән?.. Шул исемдә спектакль бар, музыкасын мин язган идем. Халык әйтмешли:

Буй-сыннарың бигрәк матур,
Исемнәрең Фатыйхкай;
Тешең энҗе, йөзең көзге,
Күзең йолдыз, кашың ай...

—Матур гына түгел, ә батыр да ул генерал Фатыйх Булатов... Минем командир аны күкләргә чөя.

—Синең командирың сугышта кем булган?

—Штрафной батальон командиры. Бер биеклекне яулап алган өчен генерал Булатов аның түшенә Александр Невский орденын таккан.

—Ә син үзең нинди гөнаһларың өчен штрафниклар ротасына эләктең?

—Казанда, милләттәшләрем мәркәзендә яшисем килгән өчен.

—Алайса, син, бәгырь, аңлы гөнаһкяр икән... Туган җиреңне әйтмәдең бит әле син?

—Элеккеге Сембер гөбернәсе, Буа өязенә кергән, хәзерге Чувашиядәге бер авылдан мин, Салих абый.

—Буа дигәннән, ак чехлардан азат ителгәч, анда мин бер музыкаль студия оештырып җибәргән идем. Мин фортепианода, ә дустым Фәйзи Биккининны скрипкада уйнарга өйрәттек. Оркестр оештырдык. Татар һәм чуаш хорлары төзедек. Чуаш каччаларының-яшьләренең "Веш, веш, куккук!"—җыруын сузып җырлаулары әле дә колак төбендә. Татарчасы: "Оч, оч, кәккүк!", бугай?

—Шулай, Салих абый.

—Әллә син, бәгырь, чувашча беләсеңме?

—Белмим дип әйтмәс идем. "Оч, оч, кәккүк"не чувашча җырлап биримме?.

—Алайса, мин пианинода уйныйм, ә син җырла... Асюшка, чуашюлдашның җыруын тыңларга чык...

Маэстро пианино артына барып утырды да, "Оч, оч, кәккүк"не көйли башлады...

Веш, веш, куккук, веш куккук...

—Булдырдык бит, бәгырь... Үзеңә рәхмәтләр яугыры...

—Мин сезнең әйткәнне үтәүче генә... Сезгә зур рәхмәт, Салих абый!

—Чуаш җыры "Оч, оч, кәккүк"не әйтәм, пентатоникага корылган, биш нотадан тора. Ул бигрәк тә борынгы татар, башкорт, чуаш халыкларының көйләренә хас... Минем дустым, драматург Фәтхи Бурнаш та чуаш җырларын белә иде: "Кай, кай Ивана..."—дип җырлап җибәрә иде. Фәтхи дусның "Хөсәен мирза" драмасына, "Камали карт" исемле пьесасына мин музыка яздым. "Хөсәен мирза"дагы "Бибисара" җыры бик тә матур чыкты:

Бөдрә талга басып сайрый
Сандугачның назлары.
Кунар урын таба алмыйдыр
Тулган күңлем зарлары.
Чын сөюдән кемнәр яна,
Гүр азабын шул ала.
Йөзеңә баккан, хәсрәт ала,
Бибисара-бичара...

Тирән фаҗигале драма ул, пьеса Сара үлеме белән тәмамлана. "Зифа буең михнәт өчен үстеме? Башларыңнан хәсрәт җиле истеме?.."—дип җырлый хор бәхетсез кызның мәете өстендә. Фатыймаи-Зөһрә шундый язмышка тап була күрмәсен иде.

—Кем соң ул Фатыймаи-Зөһрә?

—Онытa алмаслык гүзәл.

—Гүзәлләр күп, ә сөйгән яр бер генә дип әйтә торган иде әнием.

—Бик дөрес әйткән, ташка язарлык сүзләр. Ләкин язылмаячак, кыз балалар өчен дә, карт аналар өчен дә авыр замана... Аларга гынамы, иратларга да. Язылган җырлар җырланмый, пьесалар куелмый, китаплар укырга рөхсәт ителми. Мактаулы заман фаҗигасе.

—Пьеса дигәннән, Фәтхи Бурнаш сезнең исем-фамилиягезне үзенең "Ялгыз Ярулла"сына керткән. Ул пьесаны мин сугыш алдыннан аерым китап итеп басылгач, укыган идем. Анда көйләр чыгару белән мавыгучы берәү Яруллдан болай дип сорый... "Син Салих Сәйдәшевне беләсеңме?"—ди.

—Ә Ярулла нәрсә әйтә?

—Сәйдәшевне? Налоговой инспекторнымы? Тәкатемә тиеп беттең, беләм, ди. Юк, композитор Сәйдәшевне, ди музыкант.

—Ярулла ничек җавап бирә?

—Ә, көйләр чыгаручынымы? Беләм, ди.

—Шуның белән сөйләшүләре бетәме?

—Юк, бетми, мин сиңа аның "Кара урман"ын, "Наемщиг"ын, маршларын уйнаганым бар, ди көйләр чыгаручы... Теге моңлы көйләрне әйтәмсең?

Минем карчык аларны бик яратып тыңлый, ди Ярулла... Фәтхи Бурнаш гәүдәләндергән Ярулланы безнең якта карты-яше белә. Бусы бер хәл. Иң әһәмиятлесе, колхозга кирәргә теләмәүчеләр Ярулланы тормышта бар дип, үзләренең ияртеп баручысы итеп исәплиләр. Минем туган авылым Фәтхи Бурнаш туып үскән Кыр Бикшеге белән янәшәдә генә.

—Сезнең авылда әле дә колхозга керергә теләмәүчеләр бармы?

—Юк, дип әйтмәс идем, бар... Әтиемнең туган абыйсы Каюм бабай... Күршеләребез сулагай Фәттах белән бөкре Сөннәт бабай. Каюм бабай әшнәсе Җамалетдин карт. Сезнең әтиегез дә Җамалетдин исемле бугай.

—Әйе, әтием Җамалетдин исемле...

—Безнең авылда тагын бер колхозга кермәүче Җамалетдин бар әле.

—Җамали—белеп чамалый дип, дөрес әйтәләрдер, бәгырь.

—Бөлгәләнеп беттеләр инде безнең төбәктәге Җамалыйлар, Яруллалар... Ә Шәкүр каракның башын җуйдылар. Ләкин, якташлары вә яшьтәшләре алар белән горурлана!

—Безнең Өбрәдә дә төрле холыклы кешеләр яши... Тормышның авырлыгына да, яманына да, кешеләренә дә түзәр идек әле, сугыш кына була күрмәсен иде. Хикмәт менә шунда...

—Салих абый, сез соңгы сугышта катнаштыгызмы?

Утырган урыныннан торып, композитор бүлмәдә арлы-бирле йөри башлады. Аннары өстәл артына килеп утырды да минем күзләргә карап:

—Ә син үзең катнаштыңмы?—диде.

—Катнаштым Салих абый, Көнбатыш Украина җирләрен азат итүдә катнаштым.

—Кем идең?

—Башта элемтәче, аннары минометчы булдым. Карпат тауларында батальонның плитәсен күтәреп йөрдем.

—Кем әйтмешли, малай башың беләнме? Каты эләккән икән үзеңә...

—Каты, бик тә каты эләкте, Салих абый. Аберчылар, диверсантлар, террорчылар белән йөзгә-йөз килеп сугыштым. Шулай ук Бандера иярченнәре белән дә көрәшергә туры килде. Яндым, тундым, исән калдым, дигәндәй.

—Бохарада, янгын вакытында, мин дә яна яздым, чак кына көлгә әверелмәдем. Кино барганда бинага ут төрткәннәр, икенче каттан сикереп котылдым. Тавышсыз кинога музыка уйный идем. Пианино янды, ә мин исәнимин калдым... Салих абыеңның бәхете булган икән, диясе генә кала.

—Ә бәлки милләтебез бәхетедер?

—Кем белә инде, бәгырь... Ул каһәр янгыннан соң мине "чека" кешеләре аптыратып бетерде. Синең хакта шәрекъ вә гареп дөньясы кызыксына дигән мәгълүмат бар... Ибраһим-бәк исемен ишеткәнең бармы?.. "Ерак сәфәр" һәм "Ай, җилләр исәләр" дигән җырларың нәрсә турында?.."—дип, җаныма тиделәр. Тропик бизгәге генә коткарып калды дисәм, юк, ялгыш булмастыр...

Янгынга кадәр Ташкентта Такташ белән очраштык без, эскадронда хезмәт итә иде ул. Оренбургтан Бохарага килгәч, ул "Яшь бохаралылар хәрәкәте"ндә катнашкан икән. Шәрекъ яшьләре үзен "Муллахан" кушаматы белән йөрткәннәр. Моны мин аның үз авызыннан ишеттем. Хәер, Такташны мин болай да ишетеп белә идем инде. Мин оештырган шәрекъ музыка мәктәбенә йөрүче Оренбург яшьләре Такташны "Юксыллар сүзе" газетасы редакциясендә эшли дип сөйлиләр иде. Гаҗәп, без аның белән ничек очрашмаганбыздыр?.. Хәер, мин ул чакта, шигырь белән түгел, ә музыка белән саташа идем.

Ә менә Такташ белән очрашкач, шигырь вә милли көй—миңа пар канат булды. Бохарада күрешеп сөйләшкәндә, Такташның зәңгәр күзләрендә моңсулык, ямансулык иде. Аңа мин үземнең "Ай, җилләр исәләр" көен трубада уйнап күрсәттем. Ә саубуллашканда, без аның белән кайчан да булса, Казанда, Тукай кабере янында очрашырга сүз куештык...

—Казанга кайтасыгызга, Тукай кабере янында буласыгызга инандыгызмы?

—Үзебезгә инангандай инандык. Әмма мин авырып киттем... Тирмәдән күтәреп чыгып, дөягә атландырдылар да, ике яктан тотып, чүл аша станцага алып килделәр. Аннан, йөк эшелонының бер вагонында, кайдан килден, шунда кит дигәндәй, Оренбургка озаттылар. Шәрекъ якларына килгәнче, мин Оренбургта урнашкан Беренче Армиядә башта музыкант-кларнетист, аннары кыллы оркестр белән җитәкчелек иткән идем. Оренбург госпиталендә дәваланганнан соң, яраксыз дип, минем кулыма "кәҗә билеты" тоттырдылар. Ә син мине, бәгырь, соңгы сугышта катнаштырырга уйлагансын?

—Соравымны кире алам, Салих абый.

—Бигайбә!.. Оренбургтан мине Казанга, Татар дәүләт театрына эшкә Кәрим Тинчурин чакыртып алды. Аннан кайткач, Кәрим абыйның "Казан сөлгесе"нә сайлап алынган музыканы эшкәрттем. Пьеса шул музыка белән сәхнәдә өч ел барды, аннары мин аңа яңа көйләр яздым. "Казан сөлгесе" артыннан "Зәңгәр шәл", "Ил", "Кандыр буе" әсәрләренә музыка иҗат иттем... Казанга кайткач, 1922 ел бик тә инде хәтергә сеңеп калды... Халык ач, ялангач. Казанда гына түгел, бар Идел-йортта. Идел пароходлары мәет белән тулы иде. Әйтерсең лә Идел-дәрья күз яшьләре булып ага. Милләттәшләребезне саклап калу, күңелләрен ачу, күтәрү ниятеннән, Татар дәүләт драма театрында Хәбибулла Ибраһимовның "Башмагым" музыкаль комедиясе куелды. Спектакльгә оригиналь музыка язарга кирәк иде. Шулай да мин аның музыкасын халык көйләреннән генә эшләдем, ә биюләре минә үземнеке иде. Шулай ук "Пороховой Фатих" спектакленә музыка язылды, халык музыкасына нигезләнеп, әлбәттә. Музыкаль оформление әзерләгәндә, дары заводында эшләүчеләрнең-кантонистларның тормышын, җырларын өйрәндем. Пороховой бистәсендә туып үскән әнием кинәшләрен искә алдым. "Чегән егете белән Хәмидә" спектакленә музыка яздым. Чегәннәр җире-Молдовага сәфәр чыгарга да ниятләгән идем. Әмма ниятемнән баш тартырга туры килде. Барсам, кире кайта алмам дип шикләндем. Ул елларда поездларда талаш-үтереш, суеш иде...

—Туры килүен күрегез—Молдова җирендә мин ярты елга якын хезмәт иткән кеше.

—Язмыш җилләре үзеңне кайларга гына ташламаган икән, бәгырь. Ә кайчан хезмәт иттең анда?

—Сугыштан соң, әсирләрне сакладым.

—Кемнәр иде алар?

—Немецлар, власовчылар, бандеровчылар, мельниклар, бульбашлар, полицайлар, диверсантлар һәм башкалар, һәм башкалар. Алар роталарга бүленеп, бер батальонны тәшкил итә иде. Элеккеге солдатлар, унтер-офицерлар, сержантлар аерым бер ротада булса, икенчесендә—кече офицерлар, өченчесендә—өлкән офицерлар, дүртенчесендә—генераллар. Солдатлар, сержантлар, унтер-офицерлар, кече офицерлар ашарга казанда үзләре әзерләсә, өлкән офицерлар һәм генералларга солдатлар белән унтер-офицерлар пешекче булып хезмәт итәләр иде. Ә минә казаннан пробаларны генераллар гына ала иде. Сугышта алар корал белән ничек эш иткәннәрдер, анысын мин белмим, ә пробаны, кашык белән, минә дигән итеп ала беләләр иде. Аш тәмле булса, проба алучы генералның челеменнән чыккан төтен бөҗралары торналар очышын хәтерләтә торган иде... Без—сакчыларыннан да әйбәтрәк, тәмлерәк ашаучы әсир генераллар арасында уң кулын гел кесәсенә тыгып йөргән, куе кашларын җыерган, өстенә немец генералы формасын кигән бер атаман да бар иде.

—Нинди атаман?

—Бандеровчылар атаманы булса кирәк... Без әсирләрне төзелешләргә озатып йөрдек: кулларыбызда штыклы винтовка, бил каешында сапер көрәге... Олы тимер капкадан үзләрен санап чыгарабыз, санап кертәбез. Капканың ачылуын, ябылуын ишетмәгән, белмәгән кеше Кишиневта бар идеме икән?.. Эчке гаскәрләргә кергән частьтә мин минометчы, дөресрәге, аның чуен плитәсен күтәреп йөрүче идем. Безнең өйрәнү дәресләре триумфаль арка—Җиңү аркасы урнаштырылган олы бер мәйданда оештырыла

иде. Безнең “айт-два” басканны кайчакларда молдаваннар карап тора. Кишиневта хәрби хәл игълан ителү сәбәпле, бар шәһәр халкы безнең күзәтү астында торды: кешеләргә кичке унбергә кадәр генә урамда йөрергә рөхсәт ителде. Шул, билгеләнгән вакыттан соң, бер генә җан иясе дә: кешеме, этме, мәчеме—күренмәскә тиеш иде... Хәтерлим, патрульлек вазифаларын башкарганда, кала читендә, аулак урында мин бер яшь кешене очраттым, кулында кара тартма.

—Син кем?—дип сорадым мин аңардан.

—Филармония артисты, быргычы,—ди бу. —Тартманы ачыйммы?

—Ач, әйдә, бәлки анда бомбадыр?

—Быргы, ант итәм,—диде яшь кеше һәм чукына ук башлады.

—Ә мин татар, Мөхәммәдкә инанам,—дидем мин.

—Туган җирең кайда?

—Идел ярында, Сембер якларында. Милләтем белән татармын.

—Алайса син маэстро Салих Сәйдәшевнең милләттәше-якташы,—диде музыкант.

—Нәкъ шулай,—дидем мин, үзен кочарга җитеп. —Бер үтенечемне үти аласыңмы?

—Синең өчен, солдат, җаным фида.

—Алайса быргыңны ал да, үзең әйткән маэстроның бер көен уйна.

—Була ул!.. “Татар маршы...” —Киттеме—китте артист быргысын уйнатып, әйтерсең күктә йолдызлар бии. Мин түгел, Ай да тыңлый шикелле... Рәхмәт яусын, мәйтәм. Сүнгән күңелдә өмет чаткылары кабыздың... Хуш, мәңге яшә! Буне саре! Хәерле кич!—дип саубуллаштык...

—Нинди марш булды икән ул?

—Молдаваннар сезнең “Кызыл Армия маршы”н “Татар маршы” дип атыйлар икән. Аннары миңа ул маршны “Җәйге бакча” дигән театрда тыңларга туры килде, анда да “Татар маршы” дип игълан иттеләр.

—Маршны оркестр башкардымы?

—Оркестр, Салих абый... Быргычы уйнагач, марш моннары беренче мәхәббәттәй күңелемә сеңеп калды. Казармага кайткач та йокыга китә алмадым. Таң атты, иртә торган тешен казый дигәндәй, увольнительный алып, шәһәрне йөреп чыгарга булдым. Кая барырга? Мин беркемне дә белмим. Теге, маршны уйнаучы очрамасмы, мәйтәм?.. Әлеге театр тирәсендә йөрдем. Аннары үзәктәге бер бакчага кергәч, Пушкин бюсты куелган постамент тирәсенә җыелган кешеләрне күреп, алар янына килдем. Кызып-кызып сөйләшүләреннән шуны белдем: шагыйрьнең таш сурәтен алырга телиләр икән: “Безнең якларга сөрелгән яшь Пушкин дала кешеләре-чегәннәр белән күңел ачкан, шуңа чегәннәр турында әсәр язган, молдаваннарны читләтеп узган”,—диләр... Салих абый, сезнең белән дә шулай булмасмы, сез дә әнә чегән егетенә багышлап көй чыгаргансыз?..

—Тумаган балага күлмәк кигезмиләр... Бигайбә!.. Салих абыеңның бюсты куелмаган... Йә, бәгырь, сөйлә...

—Шәһәр базарына килдем: рәт-рәт җигүле үгезләр, мәһабәт чаннар тора. Нишләп йөрисең, егет, дигәндәй, үгезләре миңа акаеп карый. Ә хуҗалары кунакчыл: “Авыз ит, сольтат, менә сиңа тулы кәса шәраб, тот молдаван исәнлегенә!”—диләр. Молдаваннан-молдаванга, чаннан-чанга йөрергә иренмә генә, берсеннән-берсе уздырып сыйлыйлар, акча да сорамыйлар. Бер кәса, ике кәса, өч кәса эч—һәммәсе бушлай, исермә генә...

—Оҗмах икән!

—Сер шунда: сыйлаучысыннан, салып бирүчесеннән бигрәк, шәрабны мактарга, күкләргә чөяргә кирәк. Ә сыйлаучысына килгәндә, ул сөенечennән башындагы бәрән бүреген салып, “Ура!” кычкыра. Шәрабтан телең бәйләнмәсә, аңа кушылып, син дә бакырасың. Менә мәзәк! Менә кәмит!.. Күпме эзләсәм дә, ул көнне мин сезнең маршны уйнаган быргычыны очрата алмадым. Бер эзләп, ике эзләп, өч эзләп таба алмагач, өметләрем өзелде... Шәһәрдә күңелле, ләкин кая кушалар, кая җибәрәләр, солдат шунда. Инде мин Молдова башкаласыннан йөз илле километр чамасындагы Котовск

дигән район үзәгендә. Бу як урманлы, биредә солдатлар урман кисәләр икән. Ә без—өч солдат, кискән агачларны урламагайлары дип, сакларга килдек. Килгән сәгатьтә үк бер сукбай белән таныштык, ул безне ниндидер йортның лапас астына урнаштырды. Вакытлыча гына чегәннәр белән яшәтсәк, каршы килмәссезме, диде сукбай. Пушкинның "Чегәннәр" поэмасындагы романтика белән җенләнгәнгә, өч ай сөенеп яшәдек без чегәннәр белән. Бергә тукландык, бергә чәй эчтек, бергә саламда йокладык. Молдова якларының кояшы базарда шәраб белән сыйлаучы молдаван кебек, юмарт икән. Чегәннәр дигәннән, алар арасында кара күзле, кара кашлы, алсу йөзле, озын толымлы, бик тә гүзәл, кашыкка салган шифалы судай йотарлык бер чеген кызы бар иде. Туры килә бит, исеме дә Земфира үзенең. Тик аның Алекосы гына юк иде. Шуңамы мин үземне өч ай Алеко дип хис иттем. Мин Земфирадан шикләнә идем. Кызый бил каешында хәнҗәр йөртте. Беркөнне ул безнең белән кабан дуңгызы ауларга чыкты һәм мин атканнан соң, җинел яраланган дуңгызның йөрәгенә хәнҗәр кадады. Үтерелгән дуңгызны бәйләгән килеш колга белән дүртәү күтәреп кайттык. Аннары кисәк-кисәк казанда пешереп, чегәннәр белән бергәләп ашадык. Шәраб та бар иде—аны безгә теге сукбай табып китерә иде. Һәр йортның подвалында унышар мичкә шәраб. Подвалның берсе дә бикле түгел, кер дә чөмер, тустаганы да шунда ук, бауга бәйләп куелган. Минем коралдашлар ул подвалларда булгалады, үзләре әйтмешли, сыердай чөмерәләр иде. Сыйланучыларны беркем дә күрми, белми, хәер, күрсә-белсә дә сүз әйтми. Чөнки тамактан калган йөз яшьлек әбиләр дә мич башында, ләззәтләнеп, шәраб эчеп яталар иде. Андыйларны үз күзләрем белән күрдем, үзләре белән сөйләштем. "Тәһарәт алганда, мин шәраб файдаланам, озын борынлы чәйнектәге йөзем суы мине яшәтә һәм яшәртә",—диде миңа мич башындагы бер әби.

Ә теге сукбай гел безнең тирәдә чуалды—"Ватан сугышы вакытында немецлар Молдованы басып алгач, гражданнар сугышы герое Григорий Котовский һәйкәлен шартлаттым, тиздән мине чекистлар кулга алачак... Үзегезне төрле сортлы йөземнән эшләнгән шәраб белән сыйлап калыйм",—дип әйтә торган иде ул. Ровно төбәгендәге сазлыклардан соң, Молдовада хезмәт итү миңа бер ял сыман тоелды. Ә бит безне, Молдаваннар баш күтәрәчәк, дип, гел өркетеп тордылар. Ләкин күтмәгәндә, уйламаганда частебезне Көнбатыш Украинадагы Сколе шәһәренә күчерделәр. Биредә немецлар, власовчылар, банда белән йөзгә-йөз килеп сугыштым. Шулай да мин, Салих абый, бандеровчыларга үч тотмыйм...

—Мин дә, бәгырь, басмачыларга үч тотмыйм. Юк, тотмыйм!.. Әйтергә кирәк, шәрекъ дөньясына карата алар минем күзләремне ачты. Төркстан якларында мин шәрекълеләрнең диннәрен, холык-фигыльләрен, көйләрен, моң-зарларын, гореф-гадәтләрен өйрәндем, милли киемнәрен күрдем. Анда булмасам, "Шәрекъ биюе"н яза алыр идемме икән?.. Син дә Көнбатыш Украинада, Карпат тауларында күргән-белгәннәреңне кәгазьгә төшер, сөйләп кенә йөрмә.

—Рәхмәт, Салих абый, бигрәк тә мин сөйләгәннәрне түзеп тынлаганыгыз өчен.

—Син сөйләгән сугыш вакыйгалары мине уй дингезенә батырды. Төркстан далаларында үзем күргәннәрне, үзем кичергәннәрне янабаштан кичердем. Озын сәфәр искә төште.

—Озынрак итеп сөйләдем бугай, Салих абый.

—Озынны кыскартырга мөмкин, ә менә кысканы озынайтып булмый. Кеше гомере шикелле... Гомерләр кыска, бәгырь...

—Бакый Урманче белән бертуганның улы Бакый Рәхимов ак финнарга каршы сугышта егерме җиде яшендә һәлак була.

—Советлар Союзы Герое исеме бирелгән егетне әйтәсеңме?

—Аны.

—Ишетеп беләм мин ул каһарманны.

—Элек безнең Казан дивизиясе белән командалык иткән комдив Михаил

Кирпонос та бу югары исемгә лаек булган. Фин сугышы герое Украина җирендә немецлар белән сугышканда, чолганышта калгач, үзен-үзе атып үтергән... Казан Кремлендә аның истәлегенә такта куелган.

—Тактада үзен-үзе атып үтергән дип язылганмы?

—Юк.

—Геройны, түгелме—анысы тәре тактасына язылмый, тәкъдир тактасына языла шул, бәгырь...

## Үткән гомер бигрәк җәл

“Наемщик” төшенчәсе миңа кечкенәдән таныш. Миннән өч яшькә олы булган азгын абыема карата әнием “наемщик” сүзен еш куллана иде. Хәер, гаиләдә беренче ир бала булып якты дөньяга килүеннән файдаланыпмы, абый азына, иркәләнә иде. Шуны аңлапмы, аңламыйчамы, аңар әнием: “Әллә наемщикка әвереләдеңме?”—дип әйтә иде. Сүз—кош түгел, бер очса—тотып булмый диләр... Әни тарафыннан әйтелгән сүз авылда таралып, кушаматка әверелде: фронтка киткәнче, абыем мулла кушкан исем белән түгел, ә “Наемщик” кушаматы белән йөрде. Шулай итеп, мин якыннан белгән “наемщик”ларның берсе—туган абыем булды. Ә тагын бер “наемщик” Казанда урнашкан дивизиядә, ягъни, минем ротада хезмәт итте. Дөрес, урысча әйткәндә, действительный службада түгел, ә сборда гына. Бер башлап язучы иде ул. Туры килә бит, әлеге Ходаа бәндәсе, запастагы ефрейтор, минем ротага эләкте. “Мәшһүр композитор Салих Сәйдәш турында әсәр язарга ниятлим, тупланган мәгълүматлар үзем белән бергә, язар өчен шартлар тудырсагыз иде”,—дигәч, аңа мин: “Салих абый хакына кулдан килгәннең барысын да эшләрмен”,—дип кыска гына җавап бирдем.

Беренче нәүбәттә, милләттәш ефрейторны мин аерым бер палаткага урнаштырдым. Шунда башлап язучы җәй буе яшәде, үзе әйтүенчә, көн дими, йокы күрми, ял белми, Салих Сәйдәшев турында “шедевр” тудыра бирде. Шәхсән минем канат астына алынганга, ул “айт-два” басмады, тактик өйрәнүләрдә катнашмады, по-пластунскига түш белән шуышмады, атарга өйрәнү ниятеннән, төнге атышлар михнәтен күрмәде, ком тутырылган биштәр асып, походларда йөрмәде, бросок-ыргылышлар ясамады, үрә катып постта тормады, байрак сакламады, бәрәңге чистартмады, себерке тотмады. Аның кулында тик бер корал—каләм иде.

Фронтта штрафниклар белән җитәкчелек иткән, хәрби дәрәҗәсе белән дә, хезмәт урыны белән дә миннән югарырак булган командир, үзе әйтмешли, ул пәрвайсызны, “баснописец”ны ничәмә тапкыр гауптвахтага утыртырга җыенды. Әмма аны мин гел коткара тордым... Сбор тәмамлангач, “Наемщик”, өйгә килде дә, вакытлыча гына яшәп торырга урын сорады. Әлеге дә баягы, Әндрәйнең таягы дигәндәй, Салих абый хакына риза булдым. Яшермим, маэстро турындагы әсәрне бик тә укыйсым килә иде. “Сез көткән шедеврны ике ай эчендә тәмамлыйм, вәгъдә—иман!”—диде ул, пулеметтан аткандай. Кесәсендә сукыр бер тиен дә булмаган язучы кисәге—“Наемщик” миндә көн күрде вә тукланды: токмачлы аш, өчпочмак, пәрәмәч, кыстыбыйга кинәнде... Бала тугач, язарга комачаулый дип, “Наемщик” бездән китәргә мәҗбүр булды. Ләкин чәйләргә дә, майләргә дә көн аша килеп йөрде. Аннары килүе сирәгәйде, тора-бара ул тәмам югалды. Кайдадыр, кеше күзенә күренмичә, бикләнеп, Сәйдәш турында әсәр язуын дәвам итәдер, дип уйладым мин. Ләкин Сәйдәш хакында әлеге адәм түгел, аз-маз булса да, бүтәннәр иҗат итте. Ә бит мин ничә еллар буе анардан Сәйдәш хакында шедевр әсәр көткән идем.

Мин белгән тагын бер “Наемщик”ны әйтеп китмәсәм, “Наемщик” дип аталган новелла тулы булмастыр.

Әйе, минем ротада: “Мин—Салих Сәйдәш шәкерте!”—дип йөргән

һәвәскәр музыкант та бар иде. Ул да сборга килгәч, минем ротага эләкте. "Мин—Салих Сәйдәш шәкерте!"—дигәч, шикләнгән идем. Әмма татар халкының бөек композиторы белән бергә төшкән фоторәсемен күргәч, шигем югалды. Шул бердәнбер дәлилгә нигезләнеп, әлеге һәвәскәр композиторга иҗат итәр өчен кирәген эшләдем. Өч ай, ягъни сбор беткәнче, үзе белән алып килгән баянда, ул урман аланында көй чыгарды. Ә аның, винтовка тоткан, биштәр аскан, скатка (төрелгән шинель) вә сапер көрәге аскан коралдашлары противогаз киеп сугыш шартларына туры китереп үткәрелгән хәрби өйрәнүләрдә иза чикте. Көй чыгаручының җәйге лагерьдагы тормышы, шагыйрьчә әйткәндә, алан да балан иде. Шуңадырмы, гаскәриләр, беравыздан, "алан җырчысы"на "Наемщик" кушаматын тактылар... Ул шул кушамат белән өенә кайтып китте дә.

"Наемщик" кушаматын алган үз абыем да гүрдә—ерак Потсдам җирендәге каберДә. Гүргә кергәнче, тупчы абыем чигенде, җиңелде. Аннары, яралы килеш, Сталинградны яклауда катнашып, сугыша-сугыша Көнбатыш Германиягә кадәр барып житте. Юк, мин наемщик түгел, мин—каһарман, дигәндәй, үз сүзен сүз итеп гүргә керде. Исеме, эшләгән эше, узган юлы ак, пакъ булып калды. Инде, әнием фатыйхасы белән, "Наемщик" кушаматы энемә күчте. Ихлас әнием беренче улының кушаматын дәвам иттерергә теләде булса кирәк. Ә бит өченче улының кушаматы аның җисеменә туры килми, һич килми иде. Әнинең өченче улы, минем энем, үсмер чакта ук туган авылымның атаклы механизаторына әверелде. Аның эш өчен яралганын, кечкенәдән хезмәт сөйгәнлеген бөтен авыл белде. Ә бәлки өздереп гармун сайраткан мизгелләрдә "Наемщик" кушаматы аның күңеленә хуш килгәндер. Тәкәббер елмаюлары, кайчак, шуны сиздертә иде...

Ал яулык, зәңгәр шәл,
үткән гомер бигрәк җәл...

"Зәңгәр шәл" көенә җырланган әлеге сүзләрне мин беренче тапкыр, Казаннан безнең якларга килеп, тире җыючыдан ишеттем. Ә "Наемщик" абыем әлеге җыруны яуга-фронтка чыгып киткәндә җырлады. Инде ул бу җыруны немец җирендә, тар гүрдә җырлап ята шикелле. Ишетәм мин ул җыруны—еракта, әллә кайлардан, җир асларыннан килә ул:

...үткән гомер бигрәк җәл...

Ә менә Салих Сәйдәшев белән якыннан аралашкан, бергәләп яңа музыкаль комедия язарга керешкән теге шагыйрьне, минем ротага сборга эләккәч, уңайлы вә җайлы шартларда яшәтеп, "Наемщик" итәргә теләсәм дә барып чыкмады. Бу теләк кенә булып калды. Кинәттән авырып киткән, аңын югалткан әдипне, йөк машинасына матрас җәеп, хәрби госпитальгә илтеп салдым. Хәлен белергә дип килгәндә ул аңында иде инде. Авыруы турында сорагач, бизгәк дип әйттеләр.

Бизгәк! Бизгәк чире белән минем "Наемщик" абыем да авырды. 1942 елның июль аенда, сугышчыларын бихисап югалткан Кызыл Армиянең сафларын тулыландыру максаты беләнме, бизгәк тоткан абыемны, туплар янгыраган, бомбалар ярылган, снарядлар шартлаган якка, саламлы арбага салып, алып киттеләр. Бизгәк тоткан килеш, ул ишетелер-ишетелмәс кенә "Зәңгәр шәл"не көйләде...

...үткән гомер бигрәк җәл...

Ә кызыл сугышчы Салих Җамалетдин улы Сәйдәшев кяферләр—"өлкән туганнар" боерыгы белән шәрекъ якларында, басмачылар дип яман исем тагылган кан кардәшләренә каршы сугышып йөргәндә, тагын да каһәррәк бизгәк—тропик бизгәк белән авырый. Сирәк кенә булса да, Салих абый авыруы хакында сөйли торган иде. "...Тропик бизгәге белән авырганда, бәгырь, нәкъ биш тәүлек, кайнар чүлдә, тешләр тешкә тими, калтыранып яттым. Аннары үземне тирмәгә күчерделәр. Аста дөя мамыгыннан эшләнгән

түшәк, башта бүрек, аякларда жылы оекбашлар, әмма бизгәк тота гына бит. Баш авырта, косасы килә. Тән ут кебек яна, ә үзе туңдыра. Әйтәләр ич: берәү туеп сикерә, берәү туңып сикерә! Калтырата. Тамак көя, үрмәләп барып, арыктан су эчәсе килә. Әмма, атларга түгел, торып басарга да көч-дәрман юк. Әйтерсең лә мин ике аяксыз бер гарипжан. Тирмәдә, минем белән янәшәдә, наемщик сыйфатында басмачыларга каршы сугышырга килгән Сембер егете ятты. Ул әлеге каһәр чирдән үлде. Ә мин исән калдым. Тропик бизгәге белән авырмасам, наемщик-егетнең үлемен үз күзләрем белән күрмәсәм, күнелем аша тирәннән кичермәсәм, "Батыржан җыры", гомумән, "Наемщик" драмасы язылыр идеме? Юктыр, бәгырь. "Наемщик" башта сәхнәдә музыкасыз гына барды. Ә инде музыкаль драмага әверелгәч, ул ике авторга—Тажи абый Гыйззәткә дә, миңа да популярлык китерде. "Зәңгәр шәл" белән дә шулайрак булды. Инде барысын да сагынып сөйләргә, көйләргә генә калды, бәгырь, нәкъ җырдагыча:

Ак яулык, зәңгәр шәл,
үткән гомер бигрәк җәл...

## Тәңре ядкаре

—Үпкәләттегез мине, Салих абый...
—Ни булды, бәгырь?
—Лагерьны ачу тантанасына килмәдегез. Дивизия оркестры белән, атаклы маршыгызны уйнап, каршы алырга теләгән идек үзегезне. Әйе, теләгән идек, бик теләгән идек, барып чыкмады... Иртәдән алып, тантаналы минутларга кадәр, меңнәрчә күзләр Казан белән Усад авылы арасындагы юлда булды.
—Усад түгел, бәгырь, Әсәд. Алланың арысланы дигән мәгънәне аңлата. Шул арыслан йөрәкле бәндә ул авылга нигез салган. Инде сез—хәрбиләр анда икән... Димәк, бәгырь, дуслык бетте димәкче? Әллә алай ук түгелме? Ничек кенә булмасын, сабырлык, бәгырь. Үпкәләшүдән сиңа да, миңа да, зыяннан башка, бер тиенлек файда юк. Ишеттеңме?
—Сез мине бөтен дивизия алдында уңайсыз хәлдә калдырдыгыз... Еларга җиттем... Кабатлап әйтәм, оркестр үзегезне атаклы маршыгызны уйнап каршы алмакчы иде. Ничә көн, ничә төн дип әйтимме, тынлы оркестр урман аланында репетиция ясады. Урман, тирә-як шаулап-гүләп торды. Әйтерсең лә Тәңре үзе, җир тетрәтеп, күк күкрәтеп: "Сәйдәш килә-ә! Сәйдәш килә-ә!"—дигән, бәгырьләргә үтәрлек, сөенечле хәбәр биреп торды. Сез мине гафу итегез, кадерле Салих абый... Турысын әйтәм, үзегезнең кадерне сез үзегез белмисез. Юк, белмисез... Ни өчен сез үзегезгә карата шулай битараф?.. Комиссарларча сүз алып баруым өчен, зинһар, гафу итегез...
—Сөйлә, бәгырь, сөйлә. Эчендәгене бушат, әйтеп бетер, үзеңдә калдырма... Әйе, мин гаепле, бик гаепле! Ләкин тантанагызга килә алмауның сәбәбе бар...
—Нинди сәбәп?
—Солдаттагы улым Нәүфәл, алдан белгертми генә, бик тә кыска вакытлы ялга кайткан иде. Аны озаттым.
—Теге Байкал күле аръякларында хезмәт итүче улыгызмы?
—Нәкъ шул үзе.
—Тантанага аның белән килергә булган.
—Тантана башланган сәгатьләрдә озаттым да инде мин улымны.
—Димәк, иртәнге ун сәгатьтә...
—Нәкъ шул вакытта. Шулай да мин гаепле, бик гаепле. Бигайбә... Мөхәммәт-бәгырь тантанада булдымы соң?
—Юк, ул да булмады, каты авырып китте. Йөк машинасы белән үзен хәрби госпиталь табибларына илтеп тапшырдым. Сборда гына димәссен—

өстендә өр-яңа гимнастерка, иңнәрендә җемелдәп торган укалы погоннар, аягында көзгедәй ялтыраган хром итекләр, башында менә дигән фуражка. Әйтерсең лә туй генералы инде!

—Гали Хуҗи лагерьны ачу тантанасында катнашты. Ул да безнең дивизиядә сборда. Анысы минем ротада түгел, ә дивизия газетасында.

—Ул газетада элегрәк елларда Кави Нәҗми мөхәррир булып эшләгән иде бугай... Гали дигәннән, аның "Халисә" дигән җыр текстына мин—Алла колы көй чыгарып маташам...

Маэстроның озын, нәфис бармаклары пианино клавишлары өстендә сикерешә башлады:

—Тыңла, бәгырь, җырлыйм...

Киң кырларда үтә синең яз көннәрең,
Ямьле җәйләр, алтын көзләрең;
Чәчәкләрнең матур зәңгәрләрен
Хәтерләтә синең күзләрең...

Моңнар өермәсенә ияреп, мин Салих абыйны тыңлыйм: туган авылымның басулары күз алдыма килә... Әнә, кыр бригадиры әтием, аның янында ай-урагын уйнатып, арыш уручы зәңгәр күзле әнием... Юк, хыялга чумудан бигрәк, мин көй чыгаручыга игътибар итәм: кара чәчләре тузгып, маңгаена төшкән, күзләрендә очкыннар...

—Йә, ничек?—ди Салих абый.

—Иркен сулышлы көй бу... Гали абыйның үзенә әйтеп күкләргә сикертим әле!

—Сикертмә, сөенче ал.

—Кыскасы, сөенече уртак булыр... Әнвәр Давыдов тантанага түгел, сборга да килә алмады,—дип әйтә куйган идем, сүзем тагын җырга барып тоташты.

—Зыя Ярмәкинең якташы икән ул.

—Кем?—дип, кайтарып сорарга мәҗбүр булдым.

—Әнүәр-р... Зыя Ярмәкине мин күреп беләм, Уралда—Богырысланда, шәрекъта—Фирганәдә очраштык, яшьлек елларын искә алдык... Миңа ул үзенең "Ак каен" шигырен яттан сөйләгән иде.

Кайчагында мин үзем дә карт каен түгелмен микән?—дип, уйга талам. Гомер дәрьясы ага да ага... Алтынчы дистәне "ваклап" җибәрдем бит инде. Ә менә балалар күрсәм, яшәреп киткәндәй булам. Бигрәк тә миңа балалар бакчасында күңелле, шагыйрь әйткәнчә, алар белән мин әйлән-бәйлән уйныйм. "Ак каен" шигыре үзе көй, үзе моң. Ул көйгә салуга мохтаҗ түгел. Әйе, бәгырь, шушындый шигырьләр дә була. Ләкин сирәк, бик сирәк... "Чио-Чио-сан" тантанага килдеме?

—Сезнең мәшһүр марш яңгырап торганда, ул, сәламлый-сәламлый, сугышчыларның сафлары алдыннан узды.

—Аның өчен шатмын. Әйе, сәнгать йолдызы ул "Чио-Чио-сан".

—Үзе генә түгел, әнисе белән килгән иде.

—Димәк, янында бүтән кеше юк аның. Ә бит, бәгырь, кайда "Чио-Чио-сан", анда капитан булырга тиеш. Капитанның кем икәнлеген әйтмәсәм дә билгеле инде.

—Ә кем?

—Син, әлбәттә.

—Парадтан соң, "Чио-Чио-сан" сугышчылар алдында, лагерьны яңгыратып "Матур булсын"ны җырлады:

Син дә җырла, батыр егет,
Син дә җырла, матур кыз.

—Җыр Җәүдәт Фәйзи эшкәртүендә җырланса да көе-сүзе халыкныкы икәнен беләм.

—Тантанада катнашучылар "Чио-Чио-сан" башкаруында җырны "Ура!" кычкырып, алкышладылар.

—Без—артистлар өчен шуннан да зур сөенеч юк ул... "Йөрәктән чыккан—

йөрәккә үтә",—дип тикмәгә генә әйтелми. Жырның сүзләрен дә, көен дә халык үзе чыгарган, ә композитор эшләнешендә ул үзенә янадан җәлеп итә. "Ямьле Зәйнең буйлары" да шундыйрак җыр. Бусын Александр Ключарев эшкәртте. Үзләре тарафыннан кайбер эшкәрткән көйләргә композиторлар шагыйрьләрдән сүзләр яздырта. "Фазыл чишмәсе" җыры халыкка әнә шулай кереп китте. Фәйзи махсус сорап Сибгат Хәкимнән сүзләр яздыртты... Андый очраклар минем иҗатта да булгалады. Бу уңай күренеш. Димәк, Тукай васыяте тормышка ашырыла дигән сүз. Көй чыгаручымы, шигырь язучымы, җырчымы, без барыбыз да Тукай шәкертләре... Мин дә, Җәүдәт тә, Сибгат тә, Мөхәммәт тә, "Чио-Чио-сан" да, шулай ук син яшь шагыйрь дә, дивизиядә сбор узучы Гали Хуҗи дә... Ул әнә сүзендә торды. Ә син, ничә тапкыр сорап һаман минем заказны үтәмисен... "Фатыймаи-Зөһрә" турында сүзләр кирәк!

—Кем соң ул, шәрекъ кызымы, әллә Идел-йортныкымы?

—Гүзәл кыз ул... Минемчә хыялый шагыйрь өчен шул җиткән... Гали Хуҗи әнә синең шикелле төпченеп тормады, "Халисә"не язды да кулга тоттырды. Иҗат ул кыюлыкны ярата. Андый түгел икән, йә төшеп каласың, йә үзеңне таптап узачаклар... Мәхмүт Хөсәен әнә, җыр яз дип, тигәнәктәй ябыша. Әнүәр Даут үзенең бер поэмасын либретто, Мөхәммәт-бәгырь "Ак күгәрчен"ен музыкаль комедия итмәкче... Соңгы вакытта көн-төн миндә, башымнан сыйпап йоклатмый гына... Иҗат шундыйрак нәрсә ул... Яхшы шагыйрьнең бер шигыре үзе бер генералга тора.

—Сезгә мин үзем, мәсәлән, кулымнан килсә, генералиссимус исемен бирер идем, музыкадагы хезмәтегез өчен, әлбәттә.

—Кирәкмәс, бәгырь, мин халыктан аерылырга теләмим. Бик югарыга, биеккә күтәрелгәч, аннан җиргә кадалып төшүең мөмкин. Ә минем җир улы, җир кешесе булып яшисем килә. Мин Бакалтайда, Маркизда, Кызыл Байракта булырга яратам. Сулар чәчрәтеп, Иделдә коенасым, уйныйсым, туган якларыма кайтып, Өбрә елгасыннан кармак белән балыклар тотасым килә... Әле менә берничә көнгә ялга кайткан Нәүфәл улым белән дә Иделдән балык тоттык. Кызыл Байрактагы матур вә бай табигать җир йөзендә бүтән юктыр ул. Хәер, мин үзем аны Яшел Байрак дип атыйм. Яшеллекне яраткан балалар ял итә анда, пионерлар лагере бар. Почетлы кызыл сугышчы гына түгел, почетлы пионер да мин. "Пионерлар маршы" балалар белән очрашуның җимеше ул. Кызыл Байрактагы пионерлар лагеренда әле узган айда гына булган идем.

—Безнең лагерьга килә алмадыгыз.

—Сүз шуннан башланды да инде, бәгырь.

—Ә бит минем сезнең җәйге хәрби лагерьда булганым бар.

—Кайчан?

—Сугышка кадәр дә, сугыштан соң да. "Кызыл Армия маршы" мине кемнәр белән генә очраштырмады инде. Ул марш 1934 елны Кызыл мәйданда, Кызыл Армия парады вакытында да уйналган.

Дөрес, мин аны 1929 елның 23 февралендә Кызыл Армиянең унбер еллыгына багышланган тантаналы кичәдә беренче Татар укчы полкы командованиесенә бүләк иткән идем. Ә дивизия командиры Якуб Чанышев иде.

—Ана кадәр гаскәриләр өчен марш язганыгыз булдымы?

—Юк, булмады, тырышып карадым, әмма элегрәк никтер барып чыкмады. Гаскәри марш—үзенчәлекле жанр ул, аның литавра вә трубадан чыккан аһәңнәре кешедә киләчәккә ышаныч, тормышка өмет белән карау уятырга тиеш. Ә мин энем, белгәненчә, хисле бер лирик кына.

—Булдыргансыз бит, Салих абый, ничек кенә әле!

—Сез гаскәриләрнең батырлыгын олылау ниятеннән тырыштым инде. Куллан килгәнчә тырыштым.

Ә болай маршлар язмадым түгел, яздым. 1927 елның 28 февралендә, "Хезмәт батыры" исеменә лаек булган режиссер, артист, минем дустым Нури Сакаев вафат булды. Мәрхүм белән саубуллашу төнендә, мин, театр сәхнәсендәге пианино артына утырып, шәм яктысында, "Сакай маршы"н

иҗат иттем һәм аны оркестрга салып, шушы матәм маршын уйнап, сөекле дустым белән бәхилләштем. Әйтергә кирәк, минем әле үз гомеремдә андый каһарманлык башкарганым юк иде. Дуслык әнә нишләтә ул! Андый югалту бүтән кабатланмасын дигән идем, ләкин, бәхетсезлеккә каршы, кабатланды. Егълаган "Сакай" маршын уйнап, икенче якын дустымны—Һади Такташны соңгы юлга озаттым. Бик тә авыр булды. Күз яшьләренә буылып, табут артыннан бардым. Зәмһәрир суык иде... Аерылышу сәгатьләре, еллары ераклашса да, Такташ белән бергә булган чаклар күңел түрендә саклана. Такташ белән бергәләп, "Камил" дигән опера да иҗат итәргә уйлаган идек. "Камил" драмасын сәхнәгә куярга әзерләгәндә, режиссер Хәким Сәлимҗанов белән берничә тапкыр Такташның өендә булып, үзе белән сөйләштек. Алай гына түгел, бәхәсләштек тә. Хәер, мин үзем бәхәсләрне яратмыйм. Минем күңелемә көлке-мәзәк, тамаша хуш килә. Әйтер идем, алар миңа бер шифа, җан дәвасы.

—Ә музыка?

—Анысы бөлзәм. Җиһанда музыка югалса, мин шундук үләр идем.

—Такташ бәхетле идеме?

—Юктыр, тормышта да, гаиләдә дә, иҗатта да...

—Ә сез бәхетлеме, Салих абый?

—Бәхет—ул, мин сиңа әйтим, маршлар, алкышлар белән генә килә торган төшенчә түгел. Бәхет—Тәңре ядкаре. Шулай икән, Аллаһы Тәгалә тарафыннан бәндәләргә бирелгәненнән дә артыгын сорамыйм. Милләттәшләрем бәхетле икән, мин дә бәхетле, алар бәхетсез икән, мин дә бәхетсез. Мин, бәгырь, адәмнең түрәлегенә карамыйм, даһиме ул, гадиме ул—минем өчен барыбер. Ул кул сузса, анар елмаеп, мин дә кул сузам... Инде иҗат кешесенә килгәндә, фаҗигале шәхес кенә бөеклеккә ирешергә мөмкин. Моңа Тукаебызның тормыш вә иҗат юлы үрнәк. Мин үзем дә фаҗигале шәхес, әмма мин Тукай түгел, аның бер шәкерте генә... Тукай җәмгыятьтә үзен читлектәге сайрар кош сымак хис итеп яшәгән. Ә мин, тормышның таш диварына күпме генә сугылсам да, бәрелсәм дә, барыбер Тукай түгелмен. Тормыш—ул тамаша, мәкәрҗә, ә без тамашачылар гына... Мәкәрҗә дигәннән, үсмер чакта анда күргән тамашалар минем күңелгә мәңгегә сеңеп калды. Анда мине—унбиш яшьлек музыкантны күчмә труппаның җитәкчесе Габдулла Кариев белән җизнәм Шиһап Әхмәров алып барган иде. Идел буйлап, ак пароход белән юл тотуыбыз әле дә истә. Камил Мотыйги жырлый-жырлый, Кәрим Тинчурин шигырь сөйли-сөйли барды... Гармуннар патшасы Фәйзулла Туишев минем "Зиләйлүк"не уйнаганны тыңлады. Алай гынамы, миңа ул гомерлек ядкарь—гармун бүләк итте. Шулай итеп, мин ниндидер дәрәҗәдә Заһидулла Яруллинныкы гына түгел, ә Фәйзулла Туишев шәкерте дә. Ә алар икесе дә Тукай шәкертләре. Фәйзулла абый, минем шикелле, кәмит-мәзәк-фокус ярата икән. Илаһи мон-музыка тартмаса, бәлки мин бер фокусник булыр идем. Милли, төсле моңнар мине сихерләде...

—Ә ул моңнар нинди төстә?

—Зәңгәр моңнар алар, бәгырь... Яшьлегем моңнарының бизәкләрен, төсләрен әле дә күрәм, аһәңнәрен әле дә ишетәм:

...И мөкатдәс моңлы сазым,
Уйнадың син ник бик аз?..

Мин пианинода уйнаганда "Тәфтиләү" көенә кушылып, Габдулла Тукай үзе жырлады. "Kah-h! Kah-h!"—ютәлли-ютәлли жырлады. Шуннан соң күп тә үтмәде, 1913 елның 15 апреленә каршы төндә, 8 сәгать 25 минутта, вафат булды. Олуг әдип Фатих Әмирхан үтенече буенча, мәрхүм Габдулла Тукайны күмүне Шиһап жизни оештырды. Аны жирләүгә Габдулла Кариев, Кәрим Тинчурин, Гафур Коләхмәтов, Галиәсгар Камал, Заһидулла Яруллин һәм башка зыялылар килде. Олы мещан, Әби-патша Екатерина, Фәрештәләр урамында, Бишбалтада, Бакалтайда, Яңа бистәдә яшәүче яшьтәшләрне вә малайларны ияртеп, бөек Тукай женазасы артыннан мин дә бардым. "Тәфтиләү"—матәм, бәхилләшү жыруына әверелде. Тукайга багышлап,

Заһидулла абый Яруллин "Тукай хатирәсе" дигән марш иҗат итте. Торабара ул "Тукай маршы" исемен алды. Без балачакта Тукайның "Туган тел"ен Сәлим бабай көе"нә җырлый идек. Шулай итеп, бәгырь, "Кызыл Армия маршы"ның чишмә башы дип, "Тәфтиләү"не, "Тукай хатирәсе"н, "Сакай маршы"н әйтергә була. "Кызыл Армия маршы"ннан тыш мин әле "Пионерлар", "Каршылау", "Поход", "Ватан марш"ларын иҗат иттем. Соңгы икесе дәһшәтле Ватан сугышы барган көннәрдә язылды.

—Ә "Кандыр буе" спектакленә язылган "Без кабызган утлар" җыры ничегрәк?

—Күтәренке рухта язылды ул. Син, бәгырь, ул җырның сүзләрен беләсенме?

—Белми ни!

Без кабызган утлар сүнмәс алар,
Сүнмәс алар хәтәр җилләрендә;
Без кабызган утлар якты янар,
Якты янар хезмәт илләрендә...

—Кәрим абый Тинчурин драматург та, режиссер да, артист та, музыкант та, шагыйрь дә иде. Аның Алла белән Адәм, ягъни кеше-бәндә арасындагы мифологик сюжетка корылган "Зар" трагедиясе тулысынча шигырь белән язылган. Ул, әйтер идем, Такташның "Җир уллары трагедиясе"нә тиң. Ике әсәр дә шул ук елларда иҗат ителгән. Авторлар әйткәнчә, фаҗигада катнашучылар да шул ук Алла, шул ук Адәм, шул ук Газазилләр, Җәбраилләр, Дәҗҗаллар, Зобанилар... "Зар"—бәни адәм фаҗигасы алты пәрдәдән, "Җир уллары трагедиясе" алты күренештән тора. "Зар"да Нәби дигән архиб: "Тәңре исеменнән низамнар төзеп йөрүем өчен Җир угылларына күренергә дә оялам",—ди. Әйе, икесендә дә җир уллары язмышы гәүдәләндерелә, бер үк вакытта "Язмыштан узмыш юк", дигән тәкъдир вә тәкбир тәкъсирләп әйтелә. "Җир уллары трагедиясе" Такташ белән безнең уртак дустыбыз Әсгать Мәҗитов бенефисында куелды. Газазилне уйнаучы артист кинәттән авырып киткәч, баш рольне Такташ үзе уйнады. "Җир уллары"ның куелышы, ялгышмасам, ураза көннәренә туры килде бугай. Спектакль мәчет картларының ачуын чыгарды. Шулай итеп, "Җир уллары трагедиясе" сәхнәдә уңыш казанмады. Ә "Зар" бәхетсезлеккә каршымы, бәхеткә каршымы, ул вакытта куелмыйча калды. Мин аңа музыка язармын дип хыялланган идем. Таҗи Гыйззәтнең "Каһәрле мөһер"е белән дә шулай булды, музыкасыз гына уйналды. "Каһәрле мөһер"не мин 1923 елны Сембер шәһәрендә караган идем. Билет таба алмаган тамашачылар спектакльне күрер өчен тәрәзәләрне ватып керделәр. Эчтәлеге болай... Үзбәкләрнең Бабур-ханын Фирганәдән Шәйбаниләр ыруы куалагач, ул үзенең калган гаскәре белән башта хәзерге Төркмәнстан иленә, аннан Иранга кача. Качканда алтын бишектәге ир баласының кулына мөһер сугып, аны калдырып китә. Баланы карт белән карчык табып алалар да тәрбияләп үстерәләр. Бала үзенең кулындагы мөһер турында сорашып, карт белән карчыкның тенкәләренә тия. Карчык әйтергә мәҗбүр була. Үсмер егет, әтиәнисен эзләп, илдән илгә йөри. Дөнья гизә-гизә Һиндстанга барып чыккач, Һиндстан ханы Бабурның кызына гашыйк була. Кызый да аны сөя. Ике яшь йөрәк гыйшык уты белән яна. Бабур-хан моңа каршы. Илгизәр вә ярлы егетне үз янына тотып китерергә әмер бирә. Менә егет Бабур-хан сараенда. Егетнең башы киселә, Бабур-хан җәза мәйданында моны үзе карап тора. Баш кисүчеләр егетнең уң кулындагы мөһерне күреп, ул хакта Бабур-ханга әйтәләр. Хан мөһерне таный һәм йөрәге ярылып үлә. Шулай итеп, бала да, ата да каһәрле мөһер-язмыш кушуынча фани дөнья белән саубуллаша... Каһәрле мөһер кемнәргә генә сугылмаган?! Зар елаучы Кәрим абый Тинчуринга да, "Сөрелгән" яки "Сыркыды" дип аталган аз җирле авылда туып үскән фаҗигале Такташ маңгаена да сугылган ул—каһәрле мөһер! Без—бәндәләр барыбыз да каһәрле мөһерлеләр, ул мөһердән, ул каһәрдән Җир-Ана куенына кереп кенә котылып буладыр... Инде дөньядан китә калсам, минем бишек җырым, матәм маршым, теге молдаван әйткән "Татар маршы"[1] булсын иде... Шулай да бәхилләшмибез,

бәгырь: яшик әле, яшьник әле, армый-талмый эшлик әле: Аман, аман, әл аман!.. Кеше—Тәңре ядкаре... И бәгырь! Уйнап-көлеп яшәүләргә ни җитә... Безләрне кырык өйдә кайнап торган кырык самавыр көтә!..

### Ак бию

Ирек мәйданындагы Офицерлар йорты. Бию залы, тәрәзәләр шар ачык. Оркестр вальс уйный... Йөзләгән күз ыспай киемле, зифа гәүдәле вә җинел сөякле берәүгә сокланып карап тора. Ул ак туфлидән, ак күлмәктән, якасында кара "күбәләк". Маэстро бу!.. Рәссам кыз Зөһрә белән парлап бии ул. Юк, гади бию түгел, ак бию. Вальс ритмнарына ияреп, минем күнелдә шигъри юллар туа:

"Ак бию,
саф бию,
пакъ бию.
Мине чакыр,
мине чакыр.
Тик бер тапкыр,
тик бер тапкыр..."

Юк, нәфислеге белән әкият кызын хәтерләткән Зөһрәкәй, ак биюгә, пакъ биюгә мине түгел, ә күнеле илаһи Салих абыйны чакырды. Әнә алар, сигезле санына охшатып, борыла-сарыла вальс әйләнә. "Татар вальсы" бу, авторы—биюче үзе—Салих Сәйдәшев!.. Мәһабәт зал сөенеч белән тулы. Тамашачыларның күзләрендә нур, йөзләрендә елмаю балкый. Сүз белән генә әйтеп бетерә алмаслык сөенеч! Әлегә кадәр бу залда булмаган балкыш: Сәйдәш бии! Сәйдәш белән бергә шат күнелләр, музыка вә балкыш үзе бии: биредә—колонналы ак залда, якында—Ирек мәйданында, еракта—Бакалтайда, Идел аръягында. "Татар вальсы"на Сөембикә манарасы, Казан каласы, Җир шары әйләнә... Ә Ялгызлыктан котылып дөньяга чыккан маэстро парлап бии, кулдашы—зәнгәр күзле, алтын чәчле Зөһрәкәй... Шаһзадәләр гашыйк булырлык туташ! Ә Салих Сәйдәш—падишаһ, татар музыкасының короле! Ул милли музыка патшалыгына нигез салучы. Безнең профессиональ композиторларның династиясе аңардан башлана. Димәк, исеме әлегә билгеле булмаган гади бер рәссам кыз белән музыка короле бии!

Казан кызы Зөһрә өчен туган каласында соңгы бию бу... Минем белән бер батальонда хезмәт иткән өлкән лейтенант Едисан ("Жиденче сан", ягъни жиденче бала) үзенең кәләше Зөһрәне туган иленә—Босния вә Герцеговинага алып китә. Едисан Югославиядән, мөселман. Аны Советлар Союзындагы бер пехота училищесына укырга җибәргәннәр. Укуын тәмамлагач, лейтенант дәрәҗәсе белән Казандагы мотоукчылар дивизиясенә килгән... Инде Едисан өлкән лейтенант, чираттагы бу хәрби дәрәҗәгә минем күз алдымда, ягъни өч елдан соң ирешә. Едисан коңгырт сары бөдрә чәчле, кылыч борынлы. Атлаулары белән ул озын аяклы торнаны хәтерләтә. Холык-фигыле, сөйләшүләре, үз-үзен тотышлары, яшәү рәвеше белән ул минем ротадагы тагын бер якташы—капитан Милошевичка капма-каршы кеше. Йолдызлы погоннары булмаса, аны бер мәхлук дип кенә әйтер идең. Күк күкрәсә дә, җир тетрәп тирә-якның асты өскә килсә дә, аның исе-акылы китмәс, тыныч калыр, үз уйлары белән генә мавыгып яшәр. Ләкин ул тыштан гына шундый булып күренә. Эчке дөньясы, күнеле, белеме белән якташыннан күпкә өстен. Аның өчен маршал Тито да әллә кем түгел—власть яратучы бер бәндә генә. Рәссамнарга, шагыйрьләргә—менә кемнәргә баш ия Аллаһы Тәгаләнең тугрылыклы улы Едисан. Босния вә Герцеговинаның башкаласы—Сараевода әтисенең житен фабрикасы бар икән. Мин—фабрикант-капиталист

[1]"Кызыл Армия маршы" күздә тотыла.

улы, ди ул. Белгәнемчә, өлкән лейтенантның взвод белән командалык итүе бик тә чамалы булганга, офицер вазифаларын аның ярдәмчесе, полкомвзвод башкара. Ул взводта гел "ЧП" булып тора: әле карабин, әле автомат, йә противогаз югала. Беркөнне кул пулеметы юкка чыга. Өч көн, өч төн эзлиләр, таба алмыйлар. Дивизиянең ату-өйрәнү урыны начальнигы китереп бирә, шунда онытып калдырганнар икән. Атыш вакытында өлкән лейтенант Едисан рәсем ясап утырган. Едисан этюдлар белән мавыга. Казанның Офицерлар йортыннан ашыгыч заказ алдым, Сталинның һәм КПСС Үзәк Комитеты Президиумы әгъзаларының портретларын ясыйм, Сараевога кайтырга акча туплыйм, әтиемнән юлга акча сорыйсым килми, ди. Хәбәр итсә, тәгаен, ярдәм итәчәк. Байлыгы белән Балканда билгеле кеше ди аның әтисе, Әдрән дингезендәге КРК утравында аерым йорты бар икән.

Едисан Коръән сүрәләрен яттан белә.

—Кайда, ничек өйрәндең син аларны?—дип сорадым мин аңардан.

—Мин Мисыр мәдрәсәсендә алты ел укыдым, мөселман дөньясын яхшы беләм,—диде ул. —Мәккәдә булдым, Кәгъбәне күрдем. Мисыр мәдрәсәсеннән соң, Италиядә, Римда, аннары Франциядә Сорбонна колледжында белем алдым...

Безгә белгертми генә ураза да тота ул. Мин аны Фатыйма апа уздырган Корбан бәйрәме мәҗлесенә чакырган идем. Шул чакта хуҗабикәнең сылу кызы рәссам Зөһрә Едисанга гашыйк булды да куйды...

Без—ике офицер: мин вә Едисан уйланып басып торабыз. Ә ак бию дәвам итә.. Әнә Салих абый... Әнә капитан Чинчикас... Әнә капитан Милошевич парлашып әйләнә. Ике офицер—ике капитан. Беренчесе Литвадан, икенчесе Югославиядән. Милошевич черногорец, авылда туып, әбисендә үскән. Ун яшеннән көтү көткән. Аннары гимназиягә укырга кергән, матди ягы авыр булгач, боксит-кургаш-цинк руднигында эшләгән. Ватан сугышы башлануга, Верховный башкомандующий Тито җитәкчелегендә Югославиянең Халык Армиясендә гитлерчыларга каршы сугышкан. Гитлер Германиясе җиңелгәч, үз иленең армия сафларында хезмәт итеп, өлкән лейтенант дәрәҗәсенә җиткән. Аннары Милошевичны Советлар Союзына, хәрби курсларга озатканнар. Курсларны тәмамлагач, ул капитан булып безнең дивизиядә хезмәт итә башлаган. Тито җитәкчелегендәге армия сафларында "айт-два"га басып йөрүдән баш тарткан. Милошевич буйдак кеше ул, гүзәл туташларны һәм хатыннарны үлеп ярата. Үзе әйтмешли, һәрберсенә бер күрүдә гашыйк була. Сөйләве буенча, теләсә нинди туташ, йә ханым белән уртак тел таба, таныша ала. Аларның женси яктан "йомшаклыгын" кулларыннан тоеп белә икән. Куллар тоя, куллар сөйли, куллар сөя. Куллар: "Мин синеке!"—дип икърар итә. Куллар: "Мин сине яратмыйм!"—дип инкарь итә. Бөтен хикмәт кулларда... Мәхәббәт—куллар хисе, куллар эше, ди ул. Капитан Милошевич озын буйлы, кара бөдрә чәчле, житез хәрәкәтле. Холык-фигыле, буй-сыны, йөзе белән чегәннәргә тартым. Танышканнан соң туташ, йә булмаса ханымнар белән күп дигәндә, ике атна гына бергә була ала. Аннары янгыннан качкандай тая, кача, артына да борылып карамый. Инде икенче, өченче мәхәббәт башлана. Аннары дүртенчесе, бишенчесе... Казанда гына да ул әллә ничәләп хатын-кызның кулларыннан тоткан һәм чегәннәрчә сихерләгән... Үзенчәрәк әйтсәк—капитан Милошевич бу яктан маршал Титодан үрнәк ала. "Сугыш барышында таулар арасында яшәүче Титоның берничә сөяркәсе бар иде, хәер, ул Мәҗнүн генә түгел, арыслан йөрәкле кеше иде, анар тикмәгә генә ике тапкыр Югославия Халкының Герое исеме бирелмәде",—ди капитан Милошевич...

Безнең дивизиянең медицина капитаны Чинчикас та парлап бии. Әнә, биюче кызына елмая. Юк, ясалма елмаю бу! Капитан Чинчикас, елмаюдан битәр, күбрәк елый: аның үзе белән Вильнюс дәүләт университетында бер факультетта укыган сабакташы, сөйгән кызы, беренче мәхәббәте—Юрате исемле милләттәше әбисе белән сөргендә... Кемгә генә, кайларга гына язмадык без, Чинчикаска кәләше белән очрашу өчен рөхсәт бирүләрен сорап. Ниһаять, сөргенгә барып, Чинчикас кәләшенең кайда икәнлеген төгәл белеп кайтты. Ләкин аны бары тик ачык зонага чаклы гына керткән-

нәр, ә кызы Юрате, әбисе белән, ябык зонада икән. Тагын Мәскәүгә хат артыннан хат яуды. Ялындырып кына бер җавап килде: "Совет Армиясендә хезмәт итүче В. В. Чинчикаска ябык зонада яшәүче Ю. А. Спириндитс белән ачык зона территориясендә очрашырга рөхсәт ителә..."

Менә, Чинчикас сөргендәге кәләше янынннан әйләнеп кайтты. Шатлыгы эченә сыймый, Юрате белән очрашкан. Өч тәүлек эчендә унсигез сәгать буе бергә булганнар. Ниһаять, Юратены ябык зонадан ачык зонага чыгардык. Ул хәзер бөтенләй икенче дөньяда яши. Ничекләр итеп Юратены тоткынлыктан азат итеп, Казанга кайтарырга?.. Моның өчен нәрсәләр эшләргә?.. Чинчикаска мин Кыр гаскәрләре башкомандующие, ике тапкыр Советлар Союзы Герое, маршал Иван Степанович Коневка хат юлларга тәкъдим иттем. Инде хат Мәскәүдә, нинди җавап килер—анысы билгесез?.. Чинчикас бии, ә йөрәгендә ут аның...

Парлап биючеләр арасында якыннан аралашкан Советлар Союзы Герое да бар, ул полковник Иван Григорьевич Кобяков. Мин торган фатирда еш була иде ул. Рәссам Зөһрә аның портретын ясарга керешкән иде, аннары туктапып калды... Нинди генә язмышлы бәндәләр юк биредә!.. Һәммәсе ак биюгә бии... Ниһаять, ак бию тәмам...

—Йә, бәгырь, ничек биедем?—ди Салих абый.

—Талант!

—Талант, әмма югалганы, чынга ашмый калганы. Мин бит, бәгырь, оста биючеләргә үлеп гашыйк. Музыка әһелләреннән аталы-уллы Штраусларга, Гурилевларга баш иям. Кем әйтмешли, биеп торган музыка мине үзенә җәлеп итә. Композитор Кальманның чардаш королевасы—"Сильва", "Цирк принцессасы", "Монмартр миләүшәсе", "Марица" оперетталарында мадьяр көйләре, биюләре таң калырлык итеп бирелгән. Сиңа, бәгырь, сер итеп кенә әйтәм. Үземнән беркем белмәгән, ишетмәгән "Гөлнара" дигән балетым бар. "Әдрән диңгез" белән аһәндәш... Күңелне җилкетеп, сөякне җиңеләйтә торган күтәренке көйләрне яратам мин. Профессионал биюче була алмадым шул, җыр-музыка өстенлек алды. Ә син, бәгырь, ни өчен минем вальска биемәдең?

—Чакыручы булмады, Салих абый... Хәер, минем үземдә дә бию дигәндә ниндидер талант чаткысы бар. Ә сез чын талант!

—Тырыштым инде... Чибәр кыз алдында сынатасым килмәде. Аны син беләсең булса кирәк...

—Минем хуҗабикәм Фатыйма апаның кызы ул.

—Ни исемле?

—Зөһрә...

Кызның исемен әйтүгә Салих абый сискәнеп китте...

—Озат син мине, бәгырь... Асюшка көтәдер...

Менә без, Салих абый белән, икәүдән-икәү аның фатирындагы йокы бүлмәсендә... Бер-ике сүз алышканнан соң, караватт янына килеп, маэстро мендәр астыннан нәрсәдер алып карады.

—Нәрсә ул, Салих абый?

—Сер, бәгырь...

—Әллә инде миннән шикләнәсез?

—Юк, шикләнмим. Үзе саклангганны гына Алла саклый, диләр түгелме?

—Әйе, шулай диләр. Минем әни дә шулай ди.

—Мендәр астында беләсеңме нәрсә?

—Белмим.

—Белмәсәң, яхшырак булыр.

—Ә нигә алай?

—Белмәгәннең беләге авыртмый.

—Белгәннең авыртамы?

—Авырта, ничек кенә әле!

—Димәк, әйтергә теләмисез?

—Юк, теләмим. Синең дә йөрәгеңне авырттырасым килми, син яшь әле. Ә мин—яшисемне яшәгән, ашыйсымны ашаган. Әйдә, бәгырь, авырта бирсен.

—Алай димәгез, үз-үзеңне чагу яхшыга алып бармый...

—Мендәр астындагыны бик тә беләсең киләме?
—Юк, беләсем килми, күзләрем күреп калганга гына әйттем.
—Беләсенме нәрсә ул?.. Күчермә...
—Нинди күчермә?
—Дастан күчермәсе.
—Нинди дастан?
—"Идегәй" дастаны. Чал бер әдип-агай күчермәдән күчереп бирде. Син, бәгырь, гарәп әлифбасын танйсыңмы?
—Балачакта әнием өйрәткән иде, хәзер инде оныттылды.
—Онытмаска кирәк иде.
—Кирәк иде дә бит, туган туфрактан аердылар. Сабыр канатлар каерылырга житте.
Мендәр астыннан кульязма алып, аны кычкырып укырга кереште:

И Идел-йорт, Идел-йорт,
Идел эче имин йорт,
Атам кияү булган йорт—
Иелеп тәзем кылган йорт;
Анам килен булган йорт—
Иелеп сәлам әйткән йорт;
Кендегемне кискән йорт,
Кемем-коным югаӊ йорт;
Бия сауган сөтле йорт,
Кымыз эчкән котлы йорт;
Идел-Жаек арасы
Елкы белән тулган йорт,
Казан—Болгар арасы
Кала белән тулган йорт;
Ашлы белән Ибраһим
Ашлык белән тулган йорт,
Ата-бабам тоткан йорт,
Котлы булсын туган йорт!..

—"Тәзем" сүзен аңлыйсыңмы?
—Юк, аңламыйм.
—Олылау дигән сүз ул.
—"Ашлы белән Ибраһим" дигән юл нәрсәне аңлата?
—Үзем дә агайдан сорап кына белдем: Идел буендагы калаларның исеме икән алар... Дастанда Такташ улының исеме "Аван" да бар... Исемне, тәгаен, шуннан тапкан.
—Аван—чувашча яхшы дигән сүз. Ишеткәнемчә, Такташның икенче улына исемне Казан шәрекъ педагогия институтында укучы яшь бер чуваш шагыйре кушкан. Ә үзенә Казанлы—Хузангай исемен псевдоним итеп алган. Такташ белән Хузангай дуслар булганнар. Такташ вакытсыз үлеп киткәч, дустына багышлап Хузангай шигырь дә язган:

Начар эш ул—
Үзе исән калып
Күмсә шагыйрь үзенең
жырларын...
Сине мәңге якын итәр
халык,
Син үлемсез жырлар
жырладың.
Ышанам мин:
Йөрәк китабында
Мәнге яшәр синең хак
сүзләр.
Якты балкып сиңа һәр
таңымда
Күренерләр зәңгәр,
шат күзләр!..

Салих абыйның зәңгәр күзләре шат түгелләр иде.
—Дастанга "ханнар-феодаллар эпосы" дигән каһәрле мөһер суктылар,—диде ул, авыр сулап. —Нинди нахак сүз!
Салих абый икенче мендәр астыннан иске портфель тартып чыгарды:
—Бусы да бар әле!
—Анысы нәрсә тагын?
—Танымыйсыңмыни? Игътибар белән кара.
—Таныйм, бик таныйм, "Урыс хатыннары" хөрмәтенә тост күтәрткән Мәхмүд Максуд портфеле ич бу! Ә хуҗасы кайда?
—Алитет таулары арасына күчкән дип сөйлиләр.
—Тәрҗемәче агай сезне буш портфель сакчысы итмәкчеме әллә?
—Аз дигәндә кырык мең анда, Мәхмүт яшьти шулай дип әйтте.
—Ул кырык меңне Мөхәммәт абый белән Мәхмүд Максудиның сеңелесенә илтеп тапшырган идек бит инде без. Портфельдәге акчаны бер сәгатькә якын санадык, үзегез шаһит.
—Сез илтеп тапшырган, ул киредән китергән.
—Ул дигәнегез кем?
—Кем булсын, шул инде—Мәхмүд... Ике-өч айга Казаннан китәм, акчалы портфельне, яшьти, синдә калдырам, диде. Портфельдә ничә сум дип сорагач, ул: "Кырык мең!"—дип җавап бирде. Нишләргә инде бу акча белән? Алитетка посылка белән җибәрергәме әллә үзенә?
—Сез ничектер, Салих абый, "Урыс хатыннары" хөрмәтенә касә тота-тота, мин уңайсыз хәлгә калдым.
—Юк, син түгел, яшьти хөрти хәлдә калды. Чак кына үзен милиционер алып китмәде. Ярый әле син офицер киеменнән идең! Синең хакка калдырдылар. Бик тә ялвардың шул: "Әтиемне алып китә күрмәгез, ул карт инде!"—дидең. Милиционер ризалашкач, син аңар рәхмәтләр яудырдың... "Урыс хатыннары" үзен чак кына күңелсезлеккә дучар итмәде... Некрасовның "Урыс хатыннары" дигән поэмасын тәрҗемә иткән өчен гонорарны шәп түләгәннәр. Ну аңа барысын да берьюлы алмаска кирәк иде. Бәла аяк астында инде, бәгырь, мин ул "Урыс хатыннары" өчен изаланам. Портфельне мендәр астыннан табып алып урлап чыксалар нишләрмен?
—Мөхәммәт абыйга әйтергә кирәк, Мәхмүд агайның сеңелесенә кире илтеп тапшырсын.
—Әйт әле син аңа, бәгырь, коткарсын ул мине шушы бәладән... Портфельдәге акчаны янадан санап, сеңелесенең кулына тоттырырбыз... Тормышта, мәйтәм, нинди генә тамашалар, мәзәкләр юк!.. Бактың исә, Мәхмүд Максуд әле һаман да аэропорт ресторанында утырмагае?.. Алитетка очарга аэроплан көтеп, әлбәттә... Янында озатучылары да бардыр...
—Кемнәр?
—Син беләсең аларны... "Памир" тәмәкесеннән башка яши алмый торган Гамир Насрый вә аның әшнәләре Шәраф Мөдәррис, Әнүәр Даут...
Акчага килгәндә, Салих абыйның үз акчасы булмадымы икән әле ул?.. Кырыкмаса кырык ел шул хакта баш ватам...

## Бәхилләшү

...Күпме генә хыялланса да, гүзәл диңгез, изге диңгез дип, җиһанны җырлатып елатса да, ни үкенеч—Салих абый Әдрән диңгезнең үзен күреп өлгермәде... Ә менә халык диңгезендә булды.
Зәмһәрир суык көн. Халык диңгез булып җыелган—Татар музыкасын тудыручы, аңа нигез салучы, Тукай сымак үзенең сөекле вә бөек улы—Салих Сәйдәшев белән бәхилләшә... Тыкрыклар, борылышлар, мәйданнар, урамнар халык диңгезенә күмелгән. Балконнарда, тәрәзә төпләрендә—бабайлар, сеңелләр... Өй түбәләрендә—яшь егетләр, үсмерләр, малайлар.. Таш диварларга сыймас халык ташкыны урамнарга агыла да агыла... Ир-егетләр иңнәренә алган табут, диңгездәге бер кораб сымак, зиратка соңгы юл тота.

Сулкылдаулар, үксеп-үксеп елаулар ишетелә... Мәрхүмнең васыяте буенча, “Кызыл Армия маршы” бәхилләшү-матәм моңына әверелде. Музыка, моңзар булып, аяк асларына сибелә, каладан Идел аръякларына китеп, тугайларга, болыннарга чәчелә... Аннары еракларда, Идел ярларыннан, кара урманнар шаулаган яклардан кайтаваз булып әйләнеп кайта:

Кара урман шаулый,
Йөрәкләр ярсый,
Йөрәкләр ярсый...
Кара урман шаулый,
Эчтә ут кайный,
Эчтә ут кайный...

Җил елый, ил елый... Идел-йорт, җиһан, Җир-ана елый... Беравык үле тынлык урнаша да тагын шул җыру-сыкрау кабатлана: “Сәйдәш-ш-ш үлгән-н-н! Сәйдәш-ш-ш үлгән-н-н!.. “Зәмһәрир суыкта маңгайдан кайнар тир бәреп чыга, тамак төбенә ачы төер утыргандай тоела. Аһ, бу әҗәл-үлем, күз яшьләре тунарлык суыкта җылы җанлы нинди адәм баласын караңгы гүргә алып китә! Салкын вә кансыз әҗәл, үзе кебек, Җир-бишегебезне дә суытырга тели... Җил-давыл, буран кубара, карлы өермә каршыга килә... Әҗәл белән, җиһандагы бүгенге халәт белән гыйсъян җаннар риза түгел: “Сәйдәшнең яшисе, яшьнисе бар! Аны хәзерге мизгелдә кырык өйдә кайнап торган кырык самавыр көтә!” Хәят белән әҗәл тартыша...

Гадигә дә, даһигә дә өч аршын җир... Кулыма бер уч туфрак алып, аны өч аршын җир иясенең тәкъдир тактасы өстенә сибәм: “Авыр туфрагың җиңел булсын, бәхил бул, сөекле Салих абыем!” Учлап сибелгән җиртуфрактан гүр-үр хасил була. Тезләнеп, бәндәләр тарафыннан дога укыла. Мин дә үз күңелемдәгене укыйм:

“Җир-ана үзе сиңа баш ияр,
минем куенымда йоклый Ул дияр...”

Башымны аска иеп, каберстанның тар сукмагыннан капкага таба атлыйм, ә күз алларымда Салих абый, тере Салих абый... Соңгы очрашу күз алдыма килә... Әнә ул, төнге фонарь яктысында, татар театрының ишек төбендә уйга талып тора: өстендә макинтош, башында эшләпә, ап-ак күлмәктән, кара галстуктан...

—Бәгырь син... Югалдың! Әллә, мәйтәм, үпкәләдеме бу яшь мишәр?..

—Юк, мин түгел, сез үпкәләдегез бугай, Салих абый... Хәер, мин аның сәбәбен беләм...

—Йә, дөресен әйт, Гөләндәм ничегрәк?

—Жүләр хатынын мактар, Гөләндәмне мин ун ел беләм.

—Димәк, белеп өйләнден?

—Өйләнү—сөйләнү түгел, белми, сөйми өйләнү мөмкин түгел.

—Фатыймаи-Зөһрә дә сөймәслек кыз түгел иде, юк, түгел иде.

—Соң инде, Салих абый.

Шул вакытта, театр ишеген киң ачып, Хәким ага Сәлимжанов чыга:

—Гафу, Салих!.. Бәрелмәдеме?

—Борчылма, ишек бәрелүдән генә үлмиләр. Син аны, бәгырь, үзең дә беләсең. Чирек гасыр бер коридордагы фатирда гомер сөрдек.

—Ә нәрсәдән үләләр?

—Ачлыктан, чумадан, ядрәдән, хәнҗәрдән, пычактан... Кыскасы, кемгә нинди үлем язган бит?..

—Бәгырьләр, әйдәгез, өйгә кереп сөйләшик, аягүрә сөйләшә-сөйләшә, сул аяк таякка әверелде инде...

Баскычтан икенче катка күтәрелеп, квартирага керәбез.

—Син тылсымлы, Салих—клавишларга басып, ак күгәрченнәр очыра аласың,—диде Хәким ага әңгәмәгә романтик рух өстәргә теләп.

—Нинди ак күгәрченнәр турында сүз бара?—дидем мин, аңлашмыйча.

—Салих “Ак күгәрчен” дигән музыкаль комедия язып ята.

—Комедия дигәннән, ул минем өчен трагедиягә әверелмәгәе әле...
—Авызыңнан җил алсын!—диде Хәкимҗан абый.
—Үз хәлемне, бәгырь, үзем генә беләм.
—Белсәң дә алай димә, кем әйтмешли, диварның да колагы бар.
—Хафаланма, дүрт дивар да үземнеке, берсе дә сынатмас.
—Хәер, син, Салих, диварга да "сез" дип эндәшәсең. Пианино синең өчен "Әфәнде!"
Асия ханым: "Шәфкать туташы килде. Салих, укол кадарга вакыт!"—дигәч, маэстро, теләр-теләмәс бүлмәдән чыгып китте. Тынлык урнашты...
—Яраткан Салих абыеңны туйганчы күреп кал,—диде Хәкимҗан абый, тынлыкны бүлеп. —Башкаланың медицина фәннәре академиясе каршындагы мәшһүр хирургия институтына юк-бар авыру белән чакырмыйлар. Пычак астына керә! Түземлелек, сабырлык, озын гомер телик үзенә.
—Диварлар ишетерлек итеп әйтик, Хәкимҗан абый!
—Мең рәхмәт! Алтын күрше ул Салих... Унбер кешелек гаиләмнең олысына да, кечесенә дә, "бәгырь" дип кенә дәшә. Бала-чагага да "сез" ди. Тормыш иптәшемнең апасы, ике баласы белән авылдан килгәч, шәфкатьле Салих абыең аларны үзенең бер бүлмәсенә урнаштырып, йорт кенәгәсенә яздыртты...
Кинәт Салих абый килеп керде:
—Нәрсә син мине күкләргә чөясең... Бик теләнә салынма! Бушка вакыт уздырганчы, "Ак күгәрчен"нән бер көй уйныйммы?
—Уйнагыз, Салих абый... Йөрәккә май булып ятар иде...
Ниндидер салмак вә сузык көй уйналды. Маэстроның күңеле һаман жырлап туймый иде әле.
Соң иде инде. Саубуллашырга кирәк. Бер-беребезгә озак карашып торганнан соң, Салих абый мине озатырга булды. Менә әкрен генә баскычтан төшәбез...
—Баскычларны әйтәм, текәләр дә инде,—дидем мин.
—Текәләр—китүләрне көтәләр... Кайтуларны көтәрләрме?..
Капкага җиткәч, тукталып калдык.
Көтмәгәндә яңгыр коя башлады, төнге яңгыр...
—Хуш, бәгырь-рь... Бәхилләшмибез, имин-аман булыйк, безләрне кырык өйдә кайнап торган кырык самавыр көтә... Әллә көтмиме? Хәер, төн бит, җәйге төн, июль төне...
Төн уртасында хәрби лагерьгә юл тоттым. Казан болытлы һавада елап калды. Көзге шикле, шомлы җәйге төндә Салих абый белән саубуллашсак, кышкы зәмһәрир вә афәтле көндә мәңгегә бәхилләштек...
Мәскәү табибы әйтүенчә, авыр операциядән соң, шомарып беткән култык таяклары Сәйдәшкә хыянәт итмәсә, таеп китеп таш баскычка егылмаса, тәнендәге җәрәхәт җепләре өзелмәсә, җөйләре ачылмаса, ир уртасы Салих абыйның йөрәге тибүдән туктамас, гомере бәлки кинәт өзелмәс тә иде әле?!.. Текәрәк булган ул таш баскычлар!.. Әйе, аның өчен йорт баскычлары да, тормыш баскычлары гел текә булды. Шул текә баскычлардан йөри-йөри, биеклеккә вә бөеклеккә менә-менә егылды ул. Егылды, әмма еламады. Салих абый өчен милләт вә халык бер кешедәй булып елады. Мин дә шул халыкның берсе...
Кышкы ачы җилләрдә, ташбаганага сөялеп, кырык ел элек елаган тавышымны ишетәм.
Ишетәм дә тетрәнеп китәм. Бәрелмим-сугылмыйм, егылмыйм дип, Тәңредән мәрхәмәт вә шәфкать көтәм...



## Марат Закир

### КОЯШЛЫ ТӨН

*"Каләм! Кальбеңдә ни сер бар?.."*
Дәрдмәнд

**Кемне көтәсең, минеме—
Чатырыңда—кемне, төн?
Ярым-йорты булсам көндез,
Төннәрдән мин—гел бөтен...**

**Ике күзем яна минем—
Әйтерсең лә—ябалак!
Залим көннең җансыз нуры
Ташлый мине ярала...**

**Төнлә генә бөтен шул мин—
Кичалсам төксе көнне...
Төн-әнкәм бул үксезеңә,
Җәлләмә тик сөтеңне.**

**Олы ТӨНгә барган чакта
Синдә яши сабыең.
Синнән башка инде янә
Кемгә, төнем, сыеныйм!?**

**Синнән башка инде янә
Кемгә, төнем, табыныйм!?
Синнән башка, якты төнем,
Кемгә барыйм тагын мин!?**

**Кара дулкын толымыңны
Ташла, төнем, таратып!
Садә, серле кояш синең
Күзләреңнән тама күк.**

Марат ЗАКИР (1969)—*шагыйрь, прозаик, Татарстан язучылар берлеге әгъзасы. Казанда яши.*

Хәтерләтеп көннең дә бит
Дөньяда барлыгыннан
Якты ут яна тибрәнеп,
Тетрәнеп карыныңда.

Залим көннәр мәхшәрендә
Адашып йөргән җаным
Синдә генә таба үзен,
Синдә генә—маягым.

Төнем, төнем—газиз төнем,
Син минем—бердәнберем!
Кальбем минем сиңа тугры,
Кояшлы, якты төнем!

Каләмем дә тугры кала
Каударланмыйча гына!—
Карыныңнан авырттырып
Ал таң яралганчыга...

◉

...Яратылуын яратылганбыз:
Шәрә килеп шәрә китәсе...
Әмма килә икән фанилыкның
Шәрабеннән авыз итәсе:

Бер тутый кош—тутык тавышлымы?—
Читлегеннән тышка ашкына.
Ашкынма син, кошкай, туңарсың бит—
Бәйрәм итә анда кыш кына.

Ашыкма син, тутый, ташланырга
Таш каланың салкын карына:
Язлар түгел, зәмһәрир зат хуҗа
Бүген Казан урамнарына.

Тутык тавышлы и тутый кошым,
Шушындамы синең торагың?!
Төпсез чәркәләрнең һәркайсына
Кора монда бәла тозагын...

Төпсез Җәмшид касәсеннән[1] дәме
Төпсез чәркәле бу "хәрчәүнә"?!—
Үзе белгән ләхәүләсен укыр
Хәрчәүнәдән чыккан һәр шәүлә...

"Туктап калган могҗизаи мизгел"
Төпсез чәркәләрдә ләбаса!
Ләм-мим дәшми карап торсаң, тәмләп,
Ләззәти бер рәхәт ләм баса...

...Хозыр Ильяс белән култыклашып
Чыгып бара кызый, йә Ходам!
Татлы шәраб сыман елмаюы
Арындырды мине йокыдан.

---

[1]Җәмшид касәсе—риваятьләр буенча, бу савытның төбендә бөтен җир йөзе, тереклек чагылган.

Әмма йоталмадым елмаюын:
Төер тыгылды бугазыма, зар.
Каба калса җанга ялкын әгәр,
Дары сыман коры бүген кар.

## Бәллүр көймә

Ага дәрья ташлар аша
Бәргәләнеп ярсу көйгә.
Бу дәрьяның уртасында
Тыпырчына бәллүр көймә,
Тыпырчына бәллүр көймә.

Оча дәрья ташлар аша
Сөңге булып бәгырькәйгә.
Сөңге сынгач, таш ватарга
Бардыр, бәлки, бер-бер хәйлә:
Бардыр, бәлки, бер-бер кәйлә?—
Башын вата бәллүр көймә...

Гөрли-гөрли шаша, үрли,
Кадый дәрья ташлар аша!
Тамчы булып бәгырькәйдән
Тама нидер, тама ласа...

Ага дәрья ташлар аша
Бәргәләнеп ярсу көйгә.
Инде ничә еллар үтте?—
Кичеп кара бәрелмичә!—
Үрсәләнә бәллүр көймә...

## Бәһа

Һәрнәрсәнең бәһасе бар!
Һәрнәрсәнең бәһасе бар!!
Килер бер көн—бәһаләргә
Заман үзе бәһа куяр.—
Заман үзе бәһа сугар!
Бәһасен белгәнче генә
Сатылмыйча тора тауар...

## Көзге гамь

А-
чыр-
га-
ла-
нып
Аваз салды
Өзелеп төшкән каен яфрагы.
Егыласыңны белеп егылулар
Авырдыр ул... авыр, ахры.

Йолдызларга үрелгән чаклар
Мизгел генә икән ләбаса!
Нинди ВАКЫТ бу?! Колагыңнан
Югарыга тарта, йә—баса...

Нинди вакыт бу?! Дөнья куып
Чиксез киңлек җиткән бер мәлдә
Биләп алыр да сары сагыш,
Селкеп салыр дымлы җирләргә...

Сабыры беткән көзге җилнең
Салкын карашы да—битараф.
Яшь аралаш яфрак елмая:
Җил—җил бит ул, аңа ни—караш?

Какса да, сукса да, җил бит ул—
Табигать әмерен үтәүче.
Яфрак кебек җаным аркылы
Күпме җилләр әле үтәсе...

•

...Әллә ниләр кирәк сыман
Бу адәм баласына.
Барысы ла сынау ласа,
Сынау, юкса, барысы да.

Сыгылмый ул, сыгылмаса.
Сыгылмый... сына гына.
Сына икән, түзалмыйча
Дөньяның сынавына.

Агы, күге, карасы да—
Бер адәм баласына.
Өметләнеп яши, бахыр,
Умырып аласына.

Азның азы кирәк сыман
Бу адәм баласына.
Кала бары шул кирәкне,
Кала... табасы гына...

## Мөһаҗир

Биектә лә, аһ, биектә
Аккошларның кәрваны.
Чыңлап тора бу илдә дә
Җырлары вә моң-зары.

Бара-бара тоныкланыр
Зарларың, әй, ак кәрван:
Күкнең каурый болытлары
Калмас сезнең артлардан.

Ни эзлисез кара төндә,
Кайда сезнең оягыз?
Юк кәрваным,
Юк канатым—
Калам инде мин ялгыз.

Кемне, кемне чакырасыз
Кара төндә, аккошлар?
Калам инде мин чарасыз,
Калам инде, аһ, кошлар...

Кошкайларым, озаккамы мин
Туган җирдән еракка?
Очсагыз да, үпкәләмим—
Сынау язган ир-атка.

Мөлдер-мөлдер мөлдерәмә
Яшьне тыю—мөхаль[1] тик.
Егылырмын кайтып мин дә:
—Туган җирем, нихәл?— дип...

[1]Мөхаль—мөмкин түгел.

# Çəçmə əsərlər
# Чәчмә әсәрләр



## Халисә Мөдәррисова

### ЯР

ПОВЕСТЬ

Халиковларның гаилә тормышы кыл өстендә иде. Тыштан ал да гөл, җылы һәм тыныч булып күренгән мөнәсәбәтләр астында күптән инде киеренкелек хөкем сөрде. Моны гомер буе вакыт җитмәү белән җәфаланган Радмир да, киресенчә, вакытын кая куярга белми интеккән Зөбәрҗәт тә аңлыйлар иде. Аларның тормышы рельсларга утыртылган поезд, яки эләккән тормозсыз машина шикелле тәгәри дә тәгәри, тәгәри дә тәгәри.

—Алло, тынлыйм,—йокы аралаш, Радмир иртән-иртүк шалтыраган телефон трубкасына дәште.

—Радмир Әмирович, хәерле иртә! Леон бу. Сөйләшүләр уңышлы үтте. Тагын өч көннән йөкне төйи башлыйбыз, килешүләр безнең файдага.

—Күпмегә?

—Сез әйткән бәянең күрсәткече безнең файдага ике шкала тарта.

—Молодец, Леон! Котлыйм, булдыргансың, егетләрчә бу. Товарны кабул итү каналларында яшел ут яна. Рәхим ит! Ничек, анда кызлар шәбрәкме әллә? Хәтерлә аны, теләсә нәрсә ияреп кайта күрмәсен.

—Что сез, Радмир Әмирович, мин бит суфый.

—Беләм, беләм мин синең суфыйлыгыңны. Ярар, көтәм.

—Зөбәрҗәт Шәмсиевнага күп сәлам.

—Рәхмәт, житкерермен.

Трубкада кыска гудоклар яңгырады. Радмирның кәефе күтәренке иде. Әгәр дә бу комбинация башлангандагы кебек уңышлы тәмамланса, бар булган чыгымнардан, түрәләргә бирелгән ришвәтләрдән соң да кесәдә шактый гына мул өлеш кала иде.

Ә акча, акча ул—яшәү көче, кояш астындагы урының, азатлык, бәйсезлек, хакимлек билгесе.

—Яһүд, яһүд инде, эш майтара белә,—дип уйлап куйды ул Леон хакында. Ходай акыл да, төс тә биргән үзенә, житмәсә, шулар өстенә нәзакәтле тәрбия һәм акча ярату да китереп өстәгән. Шулай да аң булу кирәк бу егет белән, артык акыллы, хәйләкәр һәм комсыз.

---

Халисә Мөдәррисова—*шагыйрә, прозаик, «Көмеш дага», «Җәй уртасы», «Балан» һ.б. китаплар авторы. Башкортстанда яши.*

Кәефе бүген иллә дә яхшы иде аның. Ул уртак юрган астына чумды. Хатынының тәне кайнар һәм тансык иде. Бар дәртне кузгатып, тыелгысыз тарту белән үзенә әйдәп, борынына татлы хатын исе килеп бәрелде.

Ул Зөбәрҗәтне ыграк кочты, кайнар тәне белән хатынына елышты, чалкан әйләндерде.

—Уян, гүзәлем, сине сагынучылар бар,—диде ул мырлап кына.

Зөбәрҗәт күзен ачмый гына иренә буйсынды.

«Нәрсә җитми бу хатынга,—дип уйлады, соңыннан душта коенганда Радмир Зөбәрҗәт турында. Бөтен нәрсә бар, «ашау байдан, үлем ходайдан», дигәндәй, кием-салым зиннәтле, гаражда бер түгел, өч машинасы тора, өйдәге хезмәтчеләр һәр теләген «баш өсте»—дип, үтәп кенә баралар. Үзе дә хатынына игътибарлы кебек, ләкин Зөбәрҗәт карышмый да, ризасызлыгын да белдерми, барыбер арада мөнәсәбәтләр киеренкелеге, салкынлык, ә иң хәвефлесе—битарафлык сизелә.

«Бала кирәк, бала,—дип ачынып уйлады Радмир.—Бу хатын туеп сикерде, күкәй эчендәге сары кебек кенә яши, дөньяның җил-давылы, кары-янгыры тигәне юк. Шөгыль кирәк, өй тулы тренажерлар, теннис кортлары, аэробика, театр, концертлар гына җитми, бала кирәк».

Әйе, аларга бала кирәк иде. Җиде ел буена бергә яшәү нәтиҗәсе булып бүгенге көндә диван-креслоларда үзе зурлыгы йомшак уенчыклардан, бүлмә саен урнашкан дүрт кеше сыярлык аквариумнардагы балыклардан һәм аз сүзле иң яхшы чит ил йортларында гына күнектерелгән тыңлаучыл хезмәтчеләрдән башка өйдә җан әсәре юк иде.

Иң яхшы белгечләргә күренеп, иң яхшы шифаханәләрдә дәваланып карасалар да, табиплар анык кына кем гаебе аркасында бала юклыгын әйтә алмадылар.

«Һай, бу шайтан кочкыры тормышны, әллә күпме дөнья байлыгын кешеләре-ние белән бергә сатып алырлык акча булса да, барыбер нәрсәдер җитми».

Радмир ап-ак йомшак халатка төренеп душтан чыкканда Зөбәрҗәт йорт артындагы бассейнда су коена иде. Аның кояшта янган, манекенчы сылуларныкыдай озын, ныклы аяклары, матур беләкләре, тар гына сары тасма белән капланган йомры күкрәкләре, сыгылмалы тыгыз эч мускуллары чалкан йөзгән чакта бер калкып, бер батып бассейнның зәңгәр суында ымсындыргыч тибрәлә иде. «Гүзәл хатын, чукынчык, һәм ул минеке»,—дип зур канәгатьлек белән уйлап алды Радмир.

Соңгы вакытта араларының салкыная баруы торган саен ыграк борчый иде аны, һәм моның сәбәбенең нидә икәненә уйлап-уйлап та анык кына җавап табалмагач, ул Зөбәрҗәткә урын алыштырып торырга, аны вакытлыча каядыр җибәреп алырга, бераз аерым яшәп алырга кирәк, дигән фикергә килде. «Сагынсын, юксынсын әле мине»,—дип уйлады ул.

Бассейн янындагы радиотелефоннан шалтыратып өйдәге хезмәтче хатынга Җанаганы табарга кушты. Үрелгән бамбук креслога утырып Зөбәрҗәтне күзәтә башлады.

Бассейнның мәрмәр ярына чыгып басу белән, Зөбәрҗәт резин башлыгын салды, иңнәренә көлтә-көлтә булып алтынсыман чәчләр ишелеп төште. «Нинди матурлык»,—дип, ирексездән тагын сокланып куйды ир.

—Утыр, гүзәлем, безгә сөйләшергә кирәк.

Зөбәрҗәт креслода яткан йомшак сөлгегә уранып сүзсез генә Радмирның каршысына килеп утырды.

—Минем эш күп икәнен үзең дә беләсең, ә сиңа аз вакыт бүлгәнемне мин үзем дә аңлыйм. Ләкин башкача булмый. Шушы кызулык белән бармасаң, хәтта бер адымга алгарак та бармасаң, дөнья арбасыннан төшеп калырыңны көт тә тор. Бу каһәр суккан бизнес акрынайганны, темп югалтканны, мәлҗерәп калганны яратмый. Бу—комарлы, аяусыз ау шикелле, тирә-якта бер көтү этләр өере, син дә шулар арасында. Алда киек чаба, бөтен өер шуңа ташлана, кем шәбрәк, җитезрәк, аяусызрак—табыш шуныкы. Көчленеке—замана!

Кыскасы шул, сөеклем, синең эчен поша, күнелсез, безгә беразга аерылып торырга, сиңа миннән ял итәргә, мине сагынырга кирәк. Мин сиңа ике вариант тәкъдим итәм: теләсә нинди шифаханә сайла, бераз дәваланып, ял итеп ал, яки иртәгә үзең теләгән илгә—туристик путевка белән китеп бераз җилләнеп йөреп кайт.

Радмир бераз тынып торды...

—Ләкин минем шарт—Җанага белән!—диде ул аннары.

Зөбәрҗәтнең ирен читенә сизелер-сизелмәс кенә мыскыллы елмаю чыкты. Җанаганың кем икәнен ул бик яхшы белә иде. Радмирның тугры эте—иң аяусыз овчаркасы, хезмәтчесе, карачкысы иде ул.

Ул арада алар янына ныклы спортчыларча бәдәнле, уртача буйлы, кыска итеп кистерелгән җирән чәчле, урта яшьләрдә булуга карамастан, җитез, сыгылмалы каплан хәрәкәтле Җанага килеп басты.

Аның күзләрендә һәрчак салкын рәхимсезлек ята, шуңа да аңа туры карау авыр, ирексездән тән чымырдап китә иде.

—Тыңлыйм, хуҗа.

—Зөбәрҗәт, җавабыңны көтәм.

Зөбәрҗәтне кинәт бер секунд эчендә бу кешеләрне—үзенең ирен, Җанаганы, бу зур сарайны, байлыкны куралмау дулкыны күмеп китте.

Ләкин ул күп еллар буена үзенең бай ире кулында матур уенчык булып яшәгән, кирәкле һәм дәрәҗәле кешеләр белән банкетларда, эшлекле сөйләшүләр үткәннән соң «ныгытып кую» кичәләрендә, туган көннәрдә, кабул итүләр эчендә кайнаган, шуңа да кичерешләрен яшерергә өйрәнгән иде инде, бу юлы да нәзакәтле генә:

—Ә өченче вариант мөмкинме,—диде.

—Әйт, нинди?

—Мин үземнең авылга, туган нигезгә кайтып берәр ай торып килергә теләр идем.

Радмир тынып калды. Бераз торгач:

—Ә нигә, бу да вариант,—диде,—тик син, иркә ханым, черкиле, чебенле, сыер-сарыклы, кара мунчалы авылга кайтып, резина итексез йөри алмаслык урамнарда ничек йөрерсең икән, өең буш тора, беркемең дә юк анда, сәер теләк,—Радмир рәхәтләнеп көлеп җибәрде,—сотовый да алалмый, җәһәннәм бит ул як.

—Мин шушы вариантка гына риза, тик минем дә шартым бар: «тугры этеңне» миңа ияртмә. Ул күз кырые белән ымлап бераз читтә торган Җанагага ишарәләде. Радмир тынып калды, дөньяның яхшысын, аннан да бигрәк яманын күп күргән, үзе шуларны кылып йөргән Радмирның бу дөньяда бернәрсәгә генә иманы камил иде: һәммәсе дә сатыла һәм алына. Ә Зөбәрҗәт Радмир өчен кадерлеләрдән дә кадерле, кыйммәтлеләрдән дә кыйммәт, һәммәсе бәһаләп бетермәслек җәүһәр иде.

Зөбәрҗәтне Радмир инде ир уртасы булгач, дөньяның ачысын-төчесен күп татыгач, бизнес дөньясында шактый ныгып, үз капиталын саллы гына хәстәрләгәч тапты. Тормышында хатын-кызлар булмады түгел, булды аның. Өйләнергә генә батырлыгы да, вакыты да җитмәде. Әллә ул очраган һәрбер хатын-кызның сатылу-хыянәте куркытты аны, әллә инде башка нәрсә—кырыкка җитә язганда гына очратты ул Зөбәрҗәтне, очратты һәм, халык әйтмешли—«капланды» да.

Ә эш болай булды: Радмир әле товар эзләү, әле аны аткару, эшлекле очрашулар, килешүләр белән илнең бер чигеннән икенче чигенә, бер илдән икенче илгә чабудан арып, офисында креслога чумып, аякларын өстәлгә куеп кофе эчә-эчә бераз ял иткәндә, секретарь кыз бер кочак почта кертте. Ул игътибарсыз гына үз эшенә кагылышлы гәзит-журналларны күтәргәләп карады, иренеп кенә хатларга күз ташлады. Шулчак гәзитләр арасыннан хөрт кенә кәгазьгә басылган, бик тә сыйфатсыз ачы буяу исе анкып торган, милли телдә басылган юка гына гәзит аяк астына килеп төште. Бу, башка басмалар белән чагыштырганда, аккошлар арасына эләккән карга баласын хәтерләтә иде. Ничек ул монда килеп кергәндер? Шушы аермалык Радмирны

үзенә җәлеп итте дә инде. Ул иелеп гәзитне алды, беренче битендә башына таҗ кигән сылу кыз рәсеме басылган иде.

Астына: «Үткән елның республика чибәре! Иганәчеләр, рәхим итегез! Бу елда Чибәрләр конкурсы шәһәребезнең иң зур мәдәният сараенда үткәрелә, әгәр сездән безгә ярдәм булса, бездән сезгә—реклама!»—диелгән иде.

Радмирның ирен читенә мыскыллы елмаю чыкты, аннан кинәт: «Ә нигә катнашмаска», дигән уй чагылып үтте. Аның компаниясе очсызлы, фәкыйрь гәзит рекламасына мохтаҗ түгел-түгелен, ләкин гәзитнең беренче битендәге кыз чыннан да чибәр иде. «Ичмаса, бу эшләрдән котылып бер-ике сәгать ял итәрмен, онытылып торырмын»,—дип уйлады ул. Ничә еллар инде аның концертлар, киноларга йөргәне дә юк икән бит.

Сәркәтибенә шалтыратып, тиз генә Леонны табарга кушты.

Леон керү белән, Радмир:

—Ну, ябрәй, азрак бушка акча чыгарып алабызмы?—дип мут елмаеп куйды.

Леонның баш түбәсендәге кара бөдрә чәчләре селкенеп китте. Кырынган, зәңгәрләнеп торган шома бит мускуллары уйнап алды, текә ак маңгаенда сизелер-сизелмәс сырлар күренеп китте, нечкә, озын, ыспай гәүдәсе тагын да киеренкеләнебрәк басты, озын кара керфекләр белән уратылып алынган зур каражимеш кебек күзләрендә аңлашылмаучанлык чагылды:

—Не понял, шеф...

—Аңламасаң, менә укы!

Ул гәзитне Леонга сузды. Леон гәзитне алып бер алдын, бер артын әйләндергәләп карады да:

—Шеф, мин бит сезнең телдә түгел, ивритта да берни дә сукаламыйм. Яшәсен үземнең урыс теле, әйләндереп бир, зинһар.

Эшнең нәрсәдә икәнен аңлагач, Леон тагын ныграк гаҗәпләнде.

—Соң, шеф, бу бит выеденного яйца не стоит, юк әйбергә игътибар гына китәчәк, ә игътибар белән бергә—азмы-күпме алтын бәрабәренә булган вакыт та! Тиздән Италиягә очасы. Андагы эшлекле затлар белән сөйләшүләр азагына якынлаша. Товар кирәк.

—Төкерәм товарына, Леон, мин арыдым.

—Соң, шеф, арысаң, как всегда, мигом «расслабка» эшлибез. Кайда ял итәргә изволите? Мунча, сауна, кызлар—барысы да сезнең карамакта.

—Леон, син мине аңламадың...

Кинәт Радмирның күзләрендә аны урап алган кешеләр генә аңлый торган усал яшен яшьнәп үтте.

—Понял, шеф, эшлибез, хәзер үк шөгыльләнә башлыйм. Кирәкле җиргә шалтыратам. Тик ниндиерәк чыгым диярсез?

—Күпме кирәк, шулкадәр, тик, в пределах разумного.

Леон чыгып китеп күп тә үтмәде, кычкырып көлә-көлә кире керде.

—Шеф, спонсорствоның бәясе беләсезме, күпме?

—Артык күп каералармы әллә?

—Көлке, шеф!

Ул бәяне әйткәч, Радмир да кычкырып көлеп җибәрде:

—Бу бит бер уч борчак бәясе генә.

—Анысын да курка-курка гына: «шул хакны кертә алмассызмы икән, бик күп дисәгез, яртысы да ярый»,—ди оештыру комитеты рәисе, әле җитмәсә—«без сезнең компанияне рекламировать итәргә ярдәм итәр идек»,—ди, анекдот прямо, юк эштер бу, шеф, әллә булашмыйбызмы? Бу акчаны сез бер кергәндә ресторанда да туздырып чыга аласыз, бик теләсәгез.

Радмир тагын җитдиләнеп китте:

—Леон, мин шулай телим.

—Бетте, шеф, бетте, мәшәкатьләр белән кем шөгыльләнәчәк?

—Җанагага әйт!

—О, шеф, Жанның сылукайлар белән булашуы филне табак-савыт кибетенә кертү белән бер булмасмы соң?

—Булмас, аның тамырларында әрмән каны ага. Ул кызларны таный.

—Шул-шул...

—Леон, хәер, үзең шөгыльлән, әйдә, син хатын-кыз ягына мастер.

Леон баш иеп тиз генә чыгып китте. Шефның холкын белә иде ул. Радмир ачуланса, Жанага ише генә түгел. Радмирның карашы кадалса, арка сабагыннан суык йөгереп үтә. Ә тормышта Радмир гади, кайсы чакта хәтта хискә бирелүчән, әсәрләнүчән була ала. Тыгыз эш арасында «йомшару» вакытларында, ягъни «тайм-аут»ларда кайнар мунчадан, яхшы коньяктан йомшарып, яхшы түләүгә махсус чакыртылган артистлардан халык җырларын җырлата, шәрә Леонның муенына кунган миннек яфрагын алып ташлап, «Туган авылым», «Күбәләк» җырларын мөгрәп ала иде. Караңгы үткәннәре өченме, шуна да чакматаш кебек ныклы, тимер куллы, зиһене кылыч кебек үткер иде аның.

Бизнес дөньясында аның исеме бик тә билгеле һәм хөрмәт катыш курку беләнрәк телгә алына иде. Аның дуслары күп, ләкин дошманнары аңа караганда да күбрәк. Радмир үзенә кагылмасалар, кешегә тимәскә тырыша, булдыралган кадәр гадел эш куарга тырыша, салымнар вакытында түли, хокук хезмәткәрләре белән килешеп яшәргә өйрәнгән, ләкин аның юлына аркылы төшүчеләр йә бөлә, йә бөтенләй юкка чыга иде. Кушаматы да аның эшкуарлар дөньясында «төгәл» Радмир иде. Ул дошманнарына һәрчак көтмәгәндә, күзлекле елан кебек төгәл һөҗүм итә, принцибы да анык: «Ерткычка тимә, тисән, бетергәнче сук, чөнки исенә килү белән ул сине бетерәчәк.

Менә шушы тирә-якны дер селкетеп, дусларына терәк, дошманнарына бизгәк булып яшәгән кешенең бер генә йомшак ягы пәйда булды: хатыны—Зөбәрҗәт, ул аңа баш була алмый, чөнки—ярата.

Ә Зөбәрҗәт карышмый, кыек басмый, бер генә ялгыш гамәле белән дә Радмирга үзен битәрләрлек сәбәп бирми иде. Ир өчен иң авыры шул—Зөбәрҗәт көннән-көн аннан ераклаша, үз-үзенә бикләнә, ул аңа—битараф.

Баштарак Радмирның моңа ул кадәр исе дә китмәде—вакытлыча тук изрәү дип уйлады, ләкин көннән-көн аралар ераклашу аны сагаерга мәҗбүр итте. Боекмасын, күнелсезләнмәсен бу, дип ул аңа күбрәк вакытын бүләргә тырышты. Затлы бүләкләр—беләзекләр-йөзекләр бүләк итте, кеше уйлап чыгарган бар булган дөнья рәхәтләрен бирергә әзер тора һәм булдыра ала иде. Затлы кешеләргә, кабул итү мәҗлесләренә алып барды, бик сайлап кына үзләренә дус-иш, түрә-мазарлар, эшкуарлар чакырып Зөбәрҗәтнең хуҗабикә ролендә күңелен күтәрәсе, кызыксындырасы килде. Ходай Зөбәрҗәткә акыл, чибәрлек белән бергә эчке сиземләү, нәзакәтлелек, иң югары җәмгыять катламында да үзен тота, аралаша, сөйләшә белү сәләте биргән. Шуңа да Радмирның хатыны күпләрдә соклану, гаҗәпләнү, көнләшү уятты. Бу исә үз чиратында Радмирның горурлыгын назлый, мин-минлеген иркәли иде.

Байлык, эштә унучанлык янына җәүһәр кашлы йөзек кебек хатын да аның кулында булгач, ул аеруча дәртләнеп, җигелеп эшкә ябышты. Көн-төн эш мәшәкатьләре, зур-зур сату-алу проектлары бар булган энергияне, нервларны сарыф иткәнгә, Радмирга чыннан да тылның нык булуы кирәк иде.

Kahәре, иң кирәкле эшлекле проектларны төзү барышында, уч иткәндәй кинәт кенә хәтеренә хатыны, аның еракка төбәлгән битараф карашы килеп баса, уйларны чуалдыра, акыл үткенлеген тупасландыра, күңелгә шом сала. Зөбәрҗәт хәзер беренче күрешкәндәге Зөбәрҗәт түгел. Уйнап башланган эш күңелендә шундый кайнар хисләр уятыр дип, Радмир һич кенә дә башына китермәгән иде.

Чибәрләр конкурсы буласы көнне, эшләреннән бераз арынып, затлы ресторанның бильярд залында шактый озак шар куды ул.

Зур комар белән уйный иде ул бу уенны. Үзенең янында бер адым калмаган Жанага шарларны җыеп, тезеп торырга өлгерсен генә! Әмма дә уен бүген аның файдасына түгел иде. Компьютерлар короле эшкуар Натан әфәндегә бүген партияләрнең күбесендә яшел ут янды. Шактый акча оттырды Радмир. Эчтә котырган ачуын чак басып, ул, гадәттәгечә, илтифатлы елмаеп, уен ахырында Натанга сак кына баш иде.

—Ничего, сынок, не везет в бильярде, повезет в любви,—дип карт яһүд

күз кырые белән генә хәйләкәр елмаеп куйды.

—Һич шикләнмим,—дип әдәпле генә төрттерде дә Радмир, спорт белән шөгыльләнеп ныгыган кулын өстән аска карап чандыр гына буйлы, тәбәнәк Натанга сузды.

—Дай бог, дай бог, не забудь пригласит на свадьбу.

—Без проблем.

Кәеф төшкән иде.

—Аракы!—диде ул Җанагага карамыйча гына.

—Шәраб?—диде Җанага аңламыйча, чөнки ул Радмирның каты эчемлекләр эчмәгәнен белә.

—Аракы, дип әйттем,—дип тамак төбеннән чыгарды Радмир.

Җанага «ым» какты, шундук бармен подноста йөгертеп кенә «Абсолют» китерде. Радмир тулы рюмканы этеп куйды да, зур бокалга тутырып аракы салды, бер тында эчеп куйды, лимон телеме капты.

Бик иртә атасыз-анасыз калып, детдомда үскән, аннан ничә качып, ничә яңадан тотылып, тагын качып, подвалларда, канализация юлларында, гаражларда кунып, урлашып, тамак туйдырып, бәләкәйдән үзен-үзе яклап, кирәк булса кешенекен каерып алып, кирәк дип тапса, соңгы кыерчыгын кешегә биреп, яшәү өчен ачы көрәштә, урам джунглиенда тормыш мәктәбе үткән, бу кояш астында үзеннән башка беркем дә ярдәм итмәячәген аңлап үскән малайга физик көч белән берлектә акыл, фикер үткенлеге, хәйлә һәм мәкер дә хас иде.

Шуңа да ул җиңелүен авыр кичерә, бәләкәйдән ятимлек аркасында җанының бер почмагына кереп оялаган үз-үзенә ышанмаучанлык комплексы сирәк кенә җиңелгән чакларында яңадан баш калкыта һәм үз-үзенә ышанычы таш бәреп ватылган пыяла өлгесе кебек коелып төшә иде. Бу минутларда ул кечерәеп, югалып кала, хәтта гадәти чакта кеше белән сөйләшкәндәге ышандыргыч сөйләү куәсе югала, тотлыга башлый иде.

Мобиль телефон шалтырады. Леон иде бу:

—Шеф, кичә башлана.

—Ш-ш-шайтан, нинди кичә?

—Соң, сез иганәче түгелмени, чибәрләр концерты. Мин мәдәният сараенда.

—П-п-шел ты, чибәрләрең белән.

—Понял, шеф.

—Хәер, тукта, хәзер барып җитәм.

Бильярдта отылу гарьлеген басар өчен ниндидер шөгыль кирәк иде. «Җан, машина!»—диде ул җансакчысына. Швейцар, нәзакатьле елмаеп, бөгелә биреп, бронза белән нәкышьләнгән саллы ишекләрне ачты.

Мәдәният сараенда кичә башланган иде инде. Аны Леон каршы алды. Жюридан ерак түгел генә иң хөрмәтле урынга кертеп утырттылар. Сәхнәдә талгын гына музыка агыла. Менә, ниһаять, караңгыдан прожекторлар яктысына ярымшәрә 12 кыз пәйда булды. Ерактан алар бер-берсенә охшап торалар иде. «Шайтан, болар бит игезәкләр кебек»,—дип уйлап алды Радмир.

Ләкин тамаша барышында һәр кызның үзенчәлекләре ачыла барды. Күпне күргән Радмир өчен бу тамаша үзешчән сәнгать чыгышы шикелле генә тоелды. Нәзакатьлелеккә дәгъва белән атлап йөрергә тырышкан кызларның ким дигәндә унысы авыл сәхнәләрендә концерт алып барырлык кына сәләткә ия иде. Ә икесе нәфис, чибәр генә, үз-үзләрен тотышларында да ниндидер үзенчәлек, табигыйлек бар. Шул икәүнең берсе бигрәк тә нык җәлеп итте аны.

Алтын чәчле, зур зәңгәр күзле, кара кашлы, озын кара керфекле, кылыч борынлы, зифа буйлы, елмайганда энҗе кебек ак тешләре ялтлап янып китә, ә иң җәлеп иткәне—өске ике теше арасында бөтен йөзенә нур чәчеп торган сөйкемле аралык бар. Радмир үзе дә сизмәстән, бар вөҗүде белән шул кызның уңышын тели башлады. Конкурс артыннан конкурс үтә торды, кызлар биеп тә, җырлап та, шигырь укып та, кичке күлмәктән дә, эш костюмыннан да балкып алдылар, киенеп тә, чишенеп тә күрсәттеләр.

Милли конкурс булуга карамастан, Европа стандартына ияреп, озын буйлы, такта кебек эчләре-эчкә береккән, яссы күкрәкле кызларны җыйганнар иде монда. Ә Радмирга охшаган кыз киресенчә,—йомры гына, калку күкрәкле, нечкә билле, озын аяклы, буйга калганнарга караганда чак кына калышса да, аннан үзенә тартып торучы гүзәллек, нәзакатьлелек, затлылык бөркелә иде. «Яхшы токым сизелә»,—дип уйлап куйды Радмир.

Кызның исеме Зөбәрҗәт иде. Ул Леоннан бинокль сорап алып кызны күзәтте. Күпме ир-ат оятсыз, ач күзләре белән капшый хәзер мескен кызларның шәрә бот, күкрәкләрен, тыелгысыз хайваннарча теләк, азгын уйлар кагыла мескен яшь кызларның тәннәренә. «Галәм алдына, меңләгән күзләр астына, прожекторлар яктылыгына нинди ата-ана, яхшы мал кебек, кызын чыгарып бастыра икән»,—дип ачынып уйлап алды ул. Ә бит чын гүзәллек беркайчан да сәхнәгә, прожекторлар астына чыкмый, ул энҗе бөртеге шикелле, хуҗасы табылганчы калын диңгез дулкыннары астында ята, төптәрәк, тирәндәрәк була, ныграк саклана.

Конкурс азагына якынлаша иде. Ул Леонга:

—Бар, белеп кил, Гран-при кемгә икән?—диде. Жюри янына барып килгән Леон Гран-при һәм урыннарның инде күптән конкурс башланганчы ук бүленеп куелганлыгын әйтте. Призерлар арасында Зөбәрҗәт юк иде.

—Шайтан алгыры, Леон мин аның җиңүен телим!

Леон тагын жюри кырына чапты. Озак кына бәхәсләшкәннән соң ул тагын килеп, урыннарны берничек тә үзгәртә алмаячакларын, һәрбер кыз артында бик абруйлы кешеләр торганын әйтте. Радмирның ачуы кузгалды.

—Леон, Гран-триның бәясен ике тапкыр күтәр, жюридагыларның һәрберсенә кыйммәтле бүләк әзерлә, тик, минемчә эшлә!

Иң катлаулы килешүләр төзегәндә дә Леон Радмирның бу кадәр дулкынланганын, ярсыганын күргәне юк иде.

Бик озак киңәшкәннән соң, ниһаять, бу четерекле хәлдән чыгу юлын тапты жюри. «Иң миллилек, иң сөйкемлелек өчен» дигән яңа номинация игълан итте. Кичә азагында жюри рәисе—чәче агарып, теше төшеп, комы коелып беткән, элек бик популяр булган карт композитор—сәхнәгә калыкты.

Иң беренче булып өченче, аннары икенче, беренче урыннар игълан ителде, һәм, ниһаять, Гран-при белән бер дәрәҗәдәге приз иясе Зөбәрҗәт сәхнәгә чакырылды.

Бүләк тапшырырга иганәчене үзен сәхнәгә чакырдылар. Радмир бу эшне Леонга тапшырды. Чекка Гран-при дәрәҗәсеннән ике тапкыр артык сумма язып бирде дә, кызның кем икәнен, адресын, бер сүз белән әйткәндә, бар досьесын табарга кушып, залдан чыгып китте.

Иртән ул махмырдан башы чатнап уянды. Кичәге хәлләр кылт итеп исенә төште—бильярдта оттыру, чибәрлек конкурсы. Матур тешле чибәр кыз. Ул үзенең кичәге юмартлыгын исенә төшереп аптырап куйды, тик түгелгән акчасы җәл кебек тоелмады аңа. Башы авыртуга карамастан, ул елмаеп куйды. Торып өстәлдән минераль су алып эчте, аяклары батып торган йомшак ак келәмнән юлбарыс сыгылмалылыгы белән атлап душка кереп китте.

* * *

Бу көтелмәгән, үз өстенә ишелеп төшкән бәхет-байлыктан Зөбәрҗәт югалып калды. Ул иң яхшы номинациядә җиңүче иде! Аның кесәсендә шулкадәр сумма акчага чек ята!

Конкурс алдыннан ятактагы бүлмәдәш кызлары Зөбәрҗәтнең конкурста катнашу теләгенә көлеп кенә карадылар. «Чибәрсең син, Зөбәрҗәткәй, чибәрсен, сүз дә юк, ләкин ул конкурс конкурс башланганчы ук була бит, шуны да белмисеңмени,—диделәр. Ул: «Ярый, кызлар, бәхетемне сынап карыйм әле, авыру нәнәемә дару алырлык булса да акча эшләп булмасмы икән»,—диде һәм эшләде. Яшиләр болай булгач! Акчаны алу белән иң беренче әбисенә кирәкле даруларны алып илтеп бирер, бәлки дәваханәгә да салып булыр. Өстенә-башына алыр. Кышкы киемнәре дә беткән, итекләре

тапталып, әллә ничә тапкыр замоклары да алыштырылган, яңа ялтлап торган итек алыр, бүрек, сумкага да акча җитәргә тиеш. Ә иң теләгәне—инде бәләкәй чакта аласы килгән, хыялында йөрткән уенчыгы бар анын—йомшак, зур аю. Шул тыгыз аюга рәхәтләнеп кочаклап сыенасы килә. Иптәш кызлары: «Бу синең ятим үсү комплексы, психологиядә шулай аңлаталар моны»,—диләр.

Әйе, яшьли ятимлек ачысын татыган ул. Әнисе аңа өч яшь вакытта үлгән, әбисе тәрбиясендә генә калган кыз атасының ничек итеп көннән-көн түбән тәгәрәгәненә, өстерәлеп йөреп эчкәненә шаһит булып үсте.

Башта әле әтисе бер-ике тапкыр өйләнеп тә карады. Бигрәк тә беренче апа Зөбәрҗәткә яхшы мөнәсәбәттә булды. Чәчләрен ал бантик белән ике якка ярып үреп мәктәпкә җибәрә иде.

Икенче класска күчкәч, үги әнисе аңа өр-яңа, ялт-йот килгән, коңгырт төстәге, аяк йөзе аша тимер аел белән эләктереп куешлы йомры башлы шыгырдап торган лаклы туфлиләр алып кайтып бирде. Зөбәрҗәт туфлиләрне күрү белән «аһ» итте. Ай, матур да иде алар, ай, ничек ялт итеп торалар иде лә сон! Ул туфлиләрне кия дә, ишекле-түрле йөри, адым унаена туфлиләр үзләренең затлылыгы белән мактангандай: «Менә без нинди матур, менә без нинди көяз»,—дип шыгыр-шыгыр килләр иде. Тик шунысы гына Зөбәрҗәтне бераз сагайта: туфлиләр анын баш бармагын төртебрәк торалар иде.

—Кысмыймы, унайлымы,—дип сорый үги әнисе,—кысса, икенчегә алыштырырбыз.

—Юк, юк, әйбәт рас кыналар,—ди ул кабаланып. Кысканнарын әйтсә, туфлиләрне алып китәрләр дә башка алып кайтмаслар, дип курка ул. Туфлиләрне нәнәсе кадерләп кенә яулыкка төреп сандыгына салып куя.

Шул матур туфлиләр хакында гел генә уйлап йөри ул. Онытса, исенә төшү белән куанычлы рәхәт бер уй күнелен биләп ала.

Шуннан, намазлыктан күтәрелгән нәнәсе янына килә дә: «Нәнәй, тагын бер генә киеп карыйм инде»,—ди. Нәнәсе: «Ай, Аллам, кызым, кимәс борын туздырып бетерәсен бит инде»,—дия-дия, сандыгын ачып тагын туфлиләрне алып бирә. Туфлиләр тагын идәнле-түрле: «Менә без нинди матур, менә без нинди шаян»,—дип шыгыр-шыгыр килеп йөреп алалар.

—Кысмыймы сон, кызым?»,—ди ана дәү әнисе.

—Юк, юк, нәнәй...

Беренче сентябрьгә мәктәпкә ул туфлиләрне киеп баралмады, иске сандалиенда китте.

—Байлыгын яшергән—бөлгән, чирен яшергән—үлгән,—диде аңа нәнәсе.

Кызганычка каршы, үги әнисе дә тиздән үле бала табып, өзлегеп гүр иясе булды. Бу хәлдән соң әтисе кара көеп йөрде-йөрде дә, алны-артны, сулныунны белмичә тагын эчә башлады. Өстерәлеп йөреп эчте ул, бер тиен акчасын да өйгә алып кайтмады, кызын да, әнисен дә бар дип тә белмәде.

Ниһаять, ана тагын бәхет елмайгандай итте. Читтән кайткан, ирдән аерылган бер балалы хатын килеп керде аларга. Әтисе дә эчми башлады. Зөбәрҗәт әнисенә ияреп килгән кызчык белән дуслашкандай булды. Әлфия иде анын исеме—илгәзәк булды ул. Зөбәрҗәт белән бар булган уенчыкларын, киемнәрен уртаклаша торган булды. Бергә уйнадылар, бергә мәктәпкә йөрделәр. Әлфия акыллы, бик башлы кыз иде. Бигрәк тә математикадан яхшы укыды, Зөбәрҗәткә дә ярдәм итә иде. Бер-ике ел матур гына яшәделәр, ләкин гөнаһ шомлыгы, әтиләре ни өчендер тагын эчә башлады.

Тракторынын тавышы әле түбән очтан гына ишетелә башласа да, үги әнисе белән нәнәсе анын инде исерекме, айныкмы икәнен чамалыйлар иде. Ни хикмәттер, трактор өй кырларына килеп туктаганчы, әтисе руль артында төп-төз утыра. Тракторнын кабинасыннан төшү белән «гәрс» итеп җиргә ава. Нәнәсе, үги әнисе, Зөбәрҗәт, Әлфия аны ничек кирәк алай өстерәп алып кереп идән уртасына салалар. Ул мазутка буялып беткән, каешланып-ялтырап каткан бармакларын йодрыкка йомарлап идәнгә шап та шоп суга, үзе сүгенә, үзе әллә ниләр кычкыра, бераздан:

Алып бирдем алтын тарак,
Маңгай чәчең тарарга...

дип, җыр мөграп җибәрә, аннан соң еларга тотына: «Зәйнәбем, Зәйнәбем»,— дип, Зөбәрҗәтнең әнисенең исемен кабатлый-кабатлый елый, тагын җырлый башлый, тагын елый, аннары авыр, тынычсыз йокыга тала. Ул йоклаганда, өйдә барысы да аяк очларына гына басып йөриләр. Уяна гына күрмәсен. Таң атар-атмастан аталары уяна, песи кебек кенә торып тышка чыгып керә. Гөнаһлы кеше кебек кенә хатыны янына килеп чума. Өйгә мазут исләре белән бергә сасы, ачы махмыр исе тарала...

Зөбәрҗәт җиденче класска җиткәч, Маһира әнисе дә, Әлфияне ияртеп, китеп барды.

Әтисе, хатыны киткәч, беркавым айныган кук булды. Артларыннан юллап барып та карады. Ләкин алар инде ерак районнарның берсенә, төпкел авылга күчеп киткәннәр иде. Шулай итеп: «иртә уңмаган кич уңмас, кич уңмаган һич уңмас» гыйбарәсен хак дими, ни дисең!? Өйдә исерек әти дә, аның белән җәфаланырга тагын Зөбәрҗәт һәм дә янә нәнәсе генә калды. Ләкин язмыш сынаулары әле алда булган икән. Тиздән исерек әтисе авыл буасы аша салынган күпер аша чыккан чакта тракторы белән мәтәлеп төшеп суга батып үлде. Тракторны күтәргәндә бөтен авыл белән шыш-пыш килеп: «Мәңге исерек булды, үзе дә котылды, мескен, инәсе белән кызы да котылды»,—диештеләр.

Зөбәрҗәтнең әбисе улы үлгәч бик елады: «Улым, улыкаем, бәхетсезем, газизем минем»,—дип иңрәде. Ә кызы менә һич кенә дә елый алмады. Ул бу хакта уйларга да курыкты: аның күңелендәге бер почмакта, ниһаять, җиңел сулау, бу мәхшәрдән котылу шатлыгы яшеренеп ята иде.

Эченә йомылып, уйчан, тыныч, тырыш булып үсте ул. Яшь кызларның һәркайсысы шикелле үк, ул да хыялланырга яратты. Хыялы аны әллә кайларга алып китә, әлләниләр вәгъдә итә, офыклар җәелдерә, офык артларындагы киңлекләрне ача: ул иң гүзәл, иң горур кыз, имеш, аны батыр, зирәк, акыллы әкият егете кебек егет ярата. Ул Зөбәрҗәт өчен җанын да җәлләми, гомерен дә кызганмый, әле аны уттан, әле судан тартып ала. Ул классташы Шамил дә кебек, әллә нинди чит егет тә кебек. Ул бер уйлаганда үзен артистка, бер уйлаганда табип, бер уйлаганда укытучы итеп тә күз алдына китерә. Менә ул үсеп җитеп, кеше булып нәнәсенә зур чемодан тулы бүләкләр—күлмәкләр, яулыклар, читек-кәвешләр, тәмле-тәмле ризыклар белән йортлары янына шәп машинада кайтып төшә, искиткеч шәп ире машинасының ишеген ачып кына Зөбәрҗәтне чыгара, имеш. Дус кызлары Рита белән Гүзәл йөгереп килеп җитәләр, имеш.

Хыяллар, хыяллар, хыяллар! Уналты яшьлек кыз хыяллары... Тик менә тормыш кына хыяллардан түгел—чынбарлыктан тора икән шул.

Кышны бик авырлык белән чыгалар иде алар. Әбисе улы үлү кайгысыннан бик биреште. Кышкы ачы суыкларда утын кертеп өйне җылыту, сыерны карау (җитмәсә, ул шактый иртә—февральдә үк бозаулады), аны саву, астын алу, печән төшерү, тирес чыгару, су ташу кебек эшләрнең барысы да әле буыны ныгып бетмәгән Зөбәрҗәткә төште. Ә җәйләрен бераз акча эшләп булмасмы, дип фермага сыер саварга йөри иде. «Түз инде, кызым,—диде мәктәпне тәмамлыйсы кышны нәнәсе.—Кыш чыккач, сыерны сатып җибәрербез, сиңа бирәр җиргә укырга да керергә кирәк булачак, өс-башына, юлыңа-ниеңә дә кирәк булыр»,—диде.

Укытучы булачак ул, әллә артистка микән? «Чибәрсең, бик чибәрсең»,— диләр иде аңа тирә-якта. Ә Зөбәрҗәт көзгедән карап үзенең әллә күпме җитмәгән җирләрен таба. Маңгае бик зур бугай аның, кашлары да артыграк куе шикелле. Маңгаен чәч белән дә каплап була, кашын да йолкыр анысы, ә менә өске ике теш арасындагы аралыкны нишләтергә—киртә теш ич ул, моны болай гына төзәтеп булмый бит инде. Әбисенә зарланса, әбисе аңа: «Ике тешең аралы, шуннан баллар тамамы, күңелемә нурлар үтә, бер елмаеп карале»,—дип әйткән шагыйрь, кызым, бик килешле үзеңә, шул мәрҗән

кебек тешләрең йөзенә нур бөркеп тора, бер дә хафаланма»,—дип юата да куя. Юатыр өчен генә әйтә шул ул аны...

Чыгарылыш имтиханнарын яхшы гына тәмамлаганнан соң, кутәрәмгә кала язган арык сыерны бозавы-ние белән очсыз гына хакка күрше авыл мариеңа сатып жибәрделәр. Елады нәнәсе сыер чыгып киткәннән соң: «Ашатучы, киендерүче китте»,—дип уфтанды ул. Ләкин нишләмәк кирәк? Акча кирәк иде, акча.

Нәнәсе белән район үзәгенә базарга барып өс-башын юнәтеп кайтырга булды. Район үзәге якын гына, Идел аша гына, аның йортлары да, ныклабрак карасаң, тау өстендә урнашкан урамнарыннан җилдергән машиналары да, хәтта арлы-бирле йөрешкән кешеләре—һәммәсе дә күренеп тора. Тик бәла шунда гына: ансат түгел аларга район үзәгенә бару. Шактый киң, әле үзе тирән һәм салкын сулы, тиз агымлы Караидел елгасы аша чыгарга кирәк. Шулай итеп, бер генә транспорт йөри җүнле жиргә—ул да булса—көймә. Ләкин халык моңа өйрәнеп беткән инде. Жәй көне көймә белән, көз көне боз калынлыгына карап (күзгә калынлыгы булса ярый) җәяү тибрәлеп һәм шыгыр-шыгыр килеп торган боз өстеннән, яз көне боздан-бозга сикергәләп, кыш көне ат белән, ныклап катырса, хәтта машиналар белән дә чыгалар, ел саен боз астына төшеп китүчеләр дә бар, ферма сөтен райүзәккә май заводына илтеп кайтканда буш фләгеләр төялгән көймә капланып, әнә шул буш фләгеләргә атланып батмыйча калучылар да, мәтәлеп төшеп, батып үлүчеләр дә булып тора.

Әмма дә ләкин бу юлы авылны зур тормышка тоташтыручы бердәнбер юл иде. Шуңа да бу юлдан халык өзелми, туктамый, сират күпере кебек ике ярны тоташтыручы мескен колхоз көймәсе көн-төн теге якка да, бу якка да кеше ташып, үз язмышы белән килешкән карт алаша шикелле, карышусыз гына шыгыр-шыгыр, мыгыр-мыгыр килеп, ревматизмлы карт ишкәкләр дулкын яра иде. Кичү—бер-берсенә тоташып диярлек урнашкан ике авыл арасында. Берсе аның мари авылы. Гомер-гомергә аралашып яшәгәнгәме, ике халык та бер-берсенең телендә яхшы ук аңлашалар, бигрәк тә китапка язылырга ярамаган сүзләр белән үзара тиз аралашалар иде.

Бүген дә су буена кеше хәтсез үк җыелган, көймәгә чират иде, үрдәрәк үз сәгате сукканны көтебрәк, шәхси көймәләрендә, акча эшләү ниятендә бала-чага ымсынып тора, тик халык колхоз көймәсенә эләгергә тырыша, чөнки монда бушлай чыгып була, ә шәхси көймәгә түләү—замана уеннарына карамастан, бәя ныклы—бер ипи хакы.

Идел өстендә томан әле күтәрелеп бетмәсә дә, көймә инде колхоз сөтләре белән бер юл ясап өлгергән иде. Хәзер икенче партия китәчәк. Аякларыннан җәйле-кышлы резин итек төшмәгән ферма сөтен ташучы какча гына, ләкин чаган кебек нык ике мари егете «ялт» итеп ярдагы соңгы җиде фләге сөтне ике як колагыннан тотып көймәгә җилләделәр.

Ә көймәдә буйга калкурак (көчлерәк тә булырга тиеш), нык бәдәнле, Зөбәрҗәтнең классташы баянчы Шамил шунда ук җинел генә күтәреп фләгеләрне көймәгә урнаштыра иде.

Зөбәрҗәт ирексездән егетнең таза гәүдәсенә, житез хәрәкәтләренә сокланып карап торды. Шамил нык, унган егет кенә түгел, искитмәле яхшы гармунчы да иде. Ул кичләрен авылның бер башында уйнап җибәрсә, чирмеш авылының иң аргы ягындагы нечкә күнелле мари апаларына кадәр, тәрәзәләрен ачып: «Үсепеснең Шамил сиптерә»,—дип әсәрләнеп, күзләрен яулык очы белән сөрткәләп тыңлап торалар иде.

Охшый иде бу егет Зөбәрҗәткә. Шамил да Зөбәрҗәттән күзен алалмый, кичен клубтан төн уртасында озатып килгән чаклары булды. Шамилне Зөбәрҗәт ошатса да, күнеле белән патша малаен көтә иде. Һичшиксез аның егете ак атка атланып, йә булмаса затлы машина белән аны алып китәчәк, бәхетле итәчәк иде. Көймә кузгалды да, томан арасына кереп югалды, аның урап килгәнен хәзер ким дигәндә ярты сәгать көтәргә кирәк иде.

Зөбәрҗәт Идел буена төште, танкеткаларын салып чуер ташларга аяк

басты, рәхәт, салкынча көймә дулкыны, шуышып килеп, аның аяк очларын үбеп алды.

Томан ярып ярдан-ярга Идел акчарлаклары оча, якындагы текә кызыл ярга оя корган яр карлыгачлары нәни генә оя тишекләрендәге балаларына жим ташый, яр читендә үскән йөз яшәр өянкеләр көмеш толымнарын агымсуда чайкый, бүртәеп, бирчәләнеп, шәрәләнеп беткән тамырлары ярга чат ябышып жирне кочкан, алар жиргә сыгылса да, сынмыйча үҗәтләнеп аяк өсте калырга тырыша.

«Барысы да яр эзли,—дип уйлап куйды Зөбәржәт,—дөнья иркен, агым күнелле, ләкин нигәдер бөтен нәрсәгә дә яр кирәк».

Кинәт аның шушы елгага чумасы, иртәнге дулкыннарда иркәләнәсе, колач салып йөзәсе килде. Ул Караиделне йөзеп тә чыгала, ул су кызы, су Зөбәржәтне, Зөбәржәт суны ярата, бер генә тапкыр аркылы-буй йөзеп чыкмады инде ул бу Иделне, тик нәнәсе бар шул, аннары—киемнәре дә.

Еракта моторлы көймә тавышы ишетелде. «Балыкчылар»,—дип уйлады ул, йә браконьерлар шулай төнге ауда, качып-посып балык тоталардыр... Идел өстеннән борынны кытыклап чи балык исе килә иде.

Ярда халык артканнан-арта бара. Менә титаклый-титаклый бригадир чатан Ярулла абзый килеп житте. Ул бик эшлекле кыяфәттә чиратның алдына ук үтте.

Халык бер сүз дә әйтмичә түбәнчелек белән аңа юл бирде. «Райсоветка,—диде ул, эре генә,—печән өсте житә, планнарны белешергә дәшәләр, ә сез кая, агай-эне? Сине, кызым, Зөбәржәт, шәһәр ягына тая, дип ишеттем, шәп түгел, шәп түгел, син бит жир кызы, кулың ныклы, йөрәгең ярсу, дигәндәй, бәхет эзләп әллә кая киткәнче, карт нәнәң янында калсаң, зәррә дә шәп булыр иде, фермага савучылар кирәк, эшне жир җимертеп эшлисең, хатын-кызның бәхете ирдән ул, унган егетләр үзебездә дә житәрлек, читләр чит инде ул, «иргә ышанма, Иделгә таянма»—дигәннәр, туган як—яшел яр, үзебездә генә кал да куй, ятимлек кайда да бер—кара сакалың кая барса да ияреп йөри, монда ичмаса барысы да үзебезнекеләр, кыерсытырга бирмәбез».

—Юкны сөйләп торма, Ярулла, юлын кисмә яшьләрнең, гомер буе үзебез шушында чиләнгән дә житкән, гомер сыер коерыгын саклап үтеп китте, ярты фермаң эчә, таң тишегеннән тездән тизәк ярып без ни күрдек тә, ни белдек, Ходаем, бөтен күргән бәхетебез, дөньябыз шушы каһәр суккан кичү дә, райүзәк—Яшел яр, китсен, йөргән таш шомара, бәхетне әкияттә генә көтеп алалар, эзләмәсәң, алма булып авызыңа төшми ул, укысын кызым, кеше булсын, томаланып шушы тишектә ятмасын.

—Кызма әле, кызма, Санияттәй, бәхет әзерләп читтә кем көтеп тора соң кешене хәзер? Монда, ичмаса, үзебезнең арада, диюем генә.

—Шулай булмыйни, сина сыер савучылар кирәк, тел төбендә—менә ни.

—Рәхмәт, Ярулла абый, укыйсым килә минем, укытучы буласым килә, укуны тәмамлау белән үзебезгә кайтам мин, нәнәйне дә карарга кирәк, Караиделемне барыбер бөтенләйгә ташлап китәлмәм мин.

Сөйләшүне бүлеп, ул арада көймә дә чыгып житте. Иң беренче Ярулла абый көймәгә кереп урнашты, аның артыннан әллә хан заманыннан ук, әллә беренче бөтендөнья сугышыннан гына кайткан, төсен аерып кына әйтеп булмаган яшел-соры-коба солдат капчыгын биштәрләгән Мәскәүдә түти кереп урнашты, ул һәр иртә районга көнбагыш сатарга йөри иде. Күрше авыл мариларыннан арзанракка ала да, кыйммәтрәккә чыгарып сата. Көнбагышы точ, эре, майлы. Гомумән, иң яхшы көнбагыш булып мари көнбагышы санала. Үстерә беләләр көнбагышны марилар. Җәйләрен аларның бәрәңге бакчасы шау сап-сары чәчкәдә, читтән карасаң, комбайн төшереп урдырырга була кебек, көнбагышны бәрәңге арасына, яки бакча тирәли читән буена чәчәләр. Тирә-якта дан тоткан мари көнбагышын район халкы Мәскәүдә түтидән алырга тырыша. Чөнки ул көнбагышны бар шартына китереп юып, кирәк-кадәр (ягъни ким тә, арттырып та җибәрмичә генә) киптерә. Сатканда көйләп тә ала: «Сөйгәнем мари, мари, мари булса да ярый, Мәскәүдә апа көнбагышы әҗәл даруга ярый».

Аның артыннан яңагын яулык белән бәйләгән, кайчандыр зәңгәр төстә, хәзер инде яка, җиң, корсак тирәләре пычак кайрарлык булып ялтырап каралган, салават күперенең бар төсләрен үзенә җыйган пинжәк кигән, яр буенда үскән өянке тамырларын хәтерләткән, бүлтәеп, тубырланып беткән куллары белән көймә кырыена тотына-тотына чирмеш карты Биктубай үрмәләде. Күренеп тора, иртә-таңнан бүлнискә тешкә талон алырга ашыга бу, аның артыннан Зөбәрҗәт белән нәнәсе, соңыннан классташлары Рита белән Гүзәл кереп чумдылар, икесенең дә кулында пакетка салынган кәгазьләр, киемнәрнең дә яхшырагын кигәннәр, димәк, болар документларын тапшырырга шәһәргә үк җилдерәләр. Көймәгә тагын ике кеше сыя ала иде әле.

Шулвакыт яр башына берсеннән-берсе кечерәк дүрт баласын ияртеп, бишенчесен күтәреп ах-вах килеп, житез Такинә килеп житте. Житез Такинә—чөнки яшь булуына карамастан (аңа нибары егерме бишләр тирәсе генә) ел саен бала таба иде. Ул арада бер-бер артлы төрле калибрдагы балалар саранча кебек, көймәгә үрмәли дә башладылар. Көйменең кырыена кадәр су күтәрелде.

—Такинә апа, шулай булмый бит инде. Биктубай бабай бүлнискә бара, Сания әби белән Зөбәрҗәт базарга, Гүзәл белән Рита Уфа автобусына, кемне генә төшерим соң, бераз көтегез,—диде ишкәкче Шамил.

Такинә, әйтерсең, ишетмәде дә, кулына күтәргән яшь ярымлык баласы белән көймәгә менеп тә утырды.

—Какое мое дело, мин многодетная мать, төшсеннәр әнә, миңа собеска барырга кирәк, дидем бит инде, пособиене вакытында түләмиләр.

Аның теле телгә йокмый иде, ул күзе белән кешегә тишеп үтерерлек итеп карый, менә аның күзләре Мәскүдә түтинеке белән очрашты. Бер сүз әйтмәсәләр дә, Мәскүдә түти дә кызып китте:

—Төшәм, төшми ни менә, көтеп тор, син итәк тутырып,—ул Такинәнең лосинасына ымлап күрсәтте,—ыштан тутырып бала тапканга мин гаеплемени, синең балаларны хөкүмәт карый, мин көнбагыш сатып тамак туйдырам, пособие, имеш, ирең Себердә себереп акча эшли, эшләпә белән йөзеккә житми инде сиңа.

Такинә тагын чәрелдәргә кереште:

—Тимә минем палаларга, кысып ятмаска, сиңа да табарга иде, карт көнендә көнбагыш сатып йөрмәс идең, палаларың карар иде.

Бу инде Мәскүдә түтинең авырткан жире иде, чөнки гомер буе ир белән яшәсә дә, ул бала китерәлмәгән иде.

—Тфү, оятсыз, йөзе кара, олы кешегә нәрсә дип әйтә!?

—Төкермә миңа, карт пикәр, көймә аша ташлыйм мин сине хәзер, спекулянт.

—Хәзер спекулянтлар юк, Такинә килен, коммерсантлар гына,—дип кыяр-кыймас сүзгә кушылды Биктубай бабай.

—Син тик кенә утыр, сүләмә, пелмәсәң, Биктубай папай. Үз мариеңны кыерсытканда яклый алмагач, дәшмә!

Биктубай карт телен тешләде.

Жәнжәл нәрсә белән беткән булыр иде, Гүзәл белән Рита сүзсез генә көймә төбенә чүмәкләгән балаларның аякларына басмас өчен кыек-мыек атлап көймә кырыена тотына-тотына ярга төшеп киттеләр, алар төшү белән Такинәнең дүрт баласы дәррәү килеп аларның урындыкларына менеп кунакладылар.

Елганы чыгып житкәнче беркем бер сүз дәшмәде, кәефләр кырылган иде.

Сыер саткан акчага Яшел Яр базарында нәнәсе Зөбәрҗәтне баштанаяк дип әйтерлек киендерде. Кара итәк, ак блузка, аягына җәйге туфли, кышкы итек, жылы куртка алды. Үзенә яңа калушлар, бәйләм күлмәк, аптекадан кереп нәнәсенә күзлек алдылар. Чәй-шикәр, тәм-том җыйдылар, шәһәргә барып урнашырлык акча да калды бераз.

—Артистлыкка ризалыгым юк, кызым, укытучы яки врач булырсың,—диде нәнәсе.

***

Менә, ниһаять, июнь азагы житеп, ул Уфага юлланды. Нәнәсе аны урамга чыгып, таягына таянган килеш күздән югалганчы карап калды. Зөбәржәт, борылып-борылып, борылмага кереп күмелгәнче нәнәсенә кул изәде, ак яулыклы нәнәсе ул борылма артына кереп югалгач кына ике күзеннән аккан яшьләрне сөртеп алды. Кичүдә беркем дә юк иде. Яр читендә бәйләп куелган ялгыз көймә чайкала. Көймәче Шамил читтәрәк суга иелгән өянкегә атланып, балык кармаклый, арырак ялкау гына койрыгын болгап, чебен куа-куа Актүш черем итә, үлән арасында чикерткәләр черкелди, дымсу урында күрән-үләннәрдән әкәм-төкәмнәр югарыга үрмәли, әйтерсең лә алар күкнең үзенә житмәкче, яр өстендәге ташта кояшта оеган жирдән кара сыртлы житез кәлтәләр «ялт» итеп үлән арасына чума, Идел өстендә, кояшта ялтырап, көмеш балыклар сикерешә.

—Балык күп эләктердеңме, Шамил?

Шамил ялт итеп борылып карады, агачтан сикереп төште.

—Балыкчының тамагы ач, арты юеш, ди минем әти. Китәсеңдәмени, Зөбәржәт?

Ул монсу гына көймәне чишә башлады.

—Авылны, Караиделне ташлап китү кызганыч түгелме соң? Мин менә киталмим, әти авырый, әнине, туганнарны да карарга кирәк. «Көзгә фермага малчы булып килерсең»,—диде Ярулла абый. Гүзәл белән Рита да китмәскә булганнар.

Ул көрсенеп куйды. Көймә киң колачлы, ныклы мускулларга бирешеп, дулкын яра башлады. Алар Идел уртасына килеп життеләр. Шамил ишкәкләрне агымга аркылы куеп ишүдән туктады, күтәрелеп Зөбәржәтнең күзләренә карады һәм кинәт тәвәккәллеген жыеп, кистереп:

—Китмә, Зөбәржәт, мин сине яратам, өйләнешик, яңа йорт салып чыгарбыз, нәнәңне дә үзебезгә алып карарбыз, син сыер саварсың, мин малчы булып эшләрмен, дөнья көтәрбез, балалар үстерербез, мин үз кулларым белән бишек эшләрмен, малаебызга, йә кызыбызга... Синсез мина дөньяның бер кызыгы да калмас бит...—Ул үз тәвәккәллегеннән үзе гажәпләнеп тотлыгып калды. Зөбәржәт тә югалып китте.

—Юк, Шамил, мин монда калырга теләмим, минем укыйсым, дөнья күрәсем, илләр гизәсем, канатланасым, очасым килә. Сагынырмын, билгеле, авылымны да, Иделемне дә, сине дә... Тик мине жаным еракларга тарта, минем бәхетле буласым, дөньялар гизәсем килә. Ә син... син—яхшы егет, син менә дигән кызлар табарсың, яратырсың әле. Бишекне дә башка кыз белән эшләрсез...

Көймә ярга килеп терәлгәнче алар башка сүз сөйләшмәделәр.

—Хуш, Зөбәржәт, мин сине көтәрмен, мин сине барыбер көтәрмен.

Зөбәржәт йөгерә-атлый тар сукмактан яр өстенә—олы юлга менеп китте.

Озак та үтмәде, имтиханнарны уңышлы тапшырып, Зөбәржәт институтта укый башлады. Көндезләрен лекцияләрдә утырса, кичләрен сукырлар жәмгыятенең мәдәният сараен жыештырды, бераз акча эшләде, өс-башын юнәткәләде, ә икенче курсны бетергәндә «Чибәркәй» конкурсына игълан күреп бәхетен сынап карамакчы булды.

Бәхет аңа бу юлы елмаймаган шикелле иде...

* * *

Жанагага Зөбәржәтне авылына, өенә кадәр илтеп кую бурычы йөкләтелгән иде. Арткы урындыкта чит ил машинасында бәвелеп кенә барган Зөбәржәт Жанаганың инде шактый коела башлаган жирән чәченә, яхшы атларныкы шикелле сыланып торган колакларына, имән кебек муенына, ныклы мускулларына, йон баскан зур тимер күсәктәй кулларына карап барды. «Бу куллар муеныңнан бер тотса, киләшчә кебек өзеп алала»,—дип уйлап куюга Зөбәржәтнең тәне чымырдап китте.

Жанага күп сөйләшми, кеше белән дә аралашмый, хатын-кыз белән

чуалганы да сизелми, гомумән, Зөбәрҗәт аның хакында аз белә, ләкин бар булмышы, бар инстинкты, хатын-кыз сизгерлеге белән Җанага ягыннан үзенә куркыныч янаганын сизә иде.

Җанаганы күрү белән Зөбәрҗәтне эчке киеренкелек биләп ала. Ул үзен читлек эчендә елан авызына карап утырган тычкан кебегрәк хис итә иде.

Радмирның Җанагадан да ышанычлырак кешесе юк икәнен Зөбәрҗәт белә. Төп эшләр, бизнес, сөйләшүләр, көйләүләр Леон белән бергә хәл ителсә дә, Радмир эшчәнлегенең кайбер четерекле якларында Җанаганың хәлиткеч роль уйнаганын Зөбәрҗәт сизенә иде.

Бигрәк тә эштә, бизнеста, куркыныч килеп туса, сөйләшүләрдә уңышсызлыклар, көтелмәгән югалтулар булса Радмир Җанаганы дәшеп ала, кабинетта икәүдән-икәү калып ни хакындадыр бик сак һәм бик җитди сөйләшәләр, икенче көнне үк Җанага кайдадыр китеп хәтсез генә югалып тора.

Шулай итеп Җанага Радмирның тугры хезмәтчесе, җан сакчысы, күзеколагы, бер сүз белән әйткәндә—сүзсез күләгәсе иде. Ул аны үз баласы кебек саклый, чөнки аларны күп еллар элгәре булган дуслык, якынлык тоташтыра иде.

* * *

Детдомнан качып, базардан-базарга кесә чистартып, урлашып йөри торгач, ундүрт яшьлек Радмир балалар колониясенә килеп эләкте. Дүрт малай бергә таласалар да, бөтен гаепне Радмирга өйделәр. Менә шунда танышты Радмир Җан белән. Чын исемен берсе дә, хәтта Җанага үзе дә белми иде шикелле, рәшәткәле дөньяда Җан инде үз кеше. Гәүдәгә нык, чит ил боевикларындагы герой образын башкаручы Ван Дамм мускулларын булдыру хыялы белән янган, унҗидесе тулып килгән Җан көнетөне мускул уйната, спорт белән шөгыльләнә иде. Радмирны ул беренче күрүдә үк ошатты, үз канаты астына алды, башка малайлардан кыерсыттырмады, үзе белән спортзалына ияртеп йөрде, сугышу, көрәш ысулларына өйрәтте. «Ике генә көч бар кешедә: берсе—акыл, берсе—мускул, кайсы чакта акылның өч тиенгә дә кирәге юк, мускул хәл итә»,—дип аз сүзле Җан Радмирның миенә сеңдерде.

Милләтенең кем икәнен үзе дә анык кына белмәгән урам малае Җан искиткеч кансыз иде. Үзара чыгып торган җәнҗәл-сугышларда ул ниндидер бер эчке ләззәт белән малайларны изә иде.

Ел ярымнан, яше чыкканлыктан, Җанны төрмәгә күчерделәр, Радмир белән Җанның юллары аерылып торды.

Колониядән чыгып, кайда урлашу, кайда алдашу белән, Радмир шактый гына капитал туплагач, законлы бизнес эшенә күчәргә тырышты, чөнки легаль булмаган юл белән ерак киталмаячагын ул бик яхшы аңлый иде. Чүпрәк-чапрак, тәмәке, сыра алып сату эшләреннән акрын-акрын гына үргә үрмәләде. Яшь булуларына да карамастан, урам мәктәбе аңа шактый гына тәрбия һәм белем биреп өлгергән иде. Ул бу дөньяда тәвәккәллектән дә ныграк отышның булмавын, үз-үзенә ышанганда, күзне йоммыйча, баш әйләндергеч афераларга барганда гына эш уңышлы чыгасын төшенгән иде. Холкы, омтылышы, күзлекле елан шикелле көтелмәгәнчә тиз һәм тәвәккәл булганы өчен бизнес дөньясында тиздән аның даны китте, кушаматы да «Төгәл Радмир» иде.

Тиздән ул җинел автомобильләр алып-сату эшләре белән шөгыльләнә башлады, акрынлап энергетика хуҗалыгына да капитал урнаштыра башлады, байлыгы артты, дәрәҗәсе күтәрелде.

Көтмәгәндә, уйламаганда бер көнне ресторанда ул Җанны очратты. Чираттагы «ходкадан» ул күптән түгел генә чыккан иде, бераз гәпләшкәннән соң Радмир Җанны үз янына алды. Ул Радмирның аерылмас күләгәсенә әверелде, тиздән аңа хөрмәт катыш курку белән Җанага дип дәшә башладылар. Алыштыргысыз кеше иде ул Радмирга. Менә шушы Җан Зөбәрҗәтне бүген аның авылына озатып бара иде дә инде.

* * *

Кичүгә килеп җиткәч, Зөбәрҗәт машинадан чыгып, яланаяк Идел комына басты. Менә ул аның җырланган, күңелләрдә сакланган, йөрәкнең иң нечкә кылларын кагып үзенә чакырып торучы туган елгасы—Караиделе!

Һай чиста да, һай салкын да инде аның суы, чиста, чөнки бу яклар кыргый табигатьле, сәнәгать шаукымы белән пычратылмаган, мәсхәрәләнмәгән, салкын сулы, чөнки ул ярларының буеннан-буена Каратау итәкләреннән мәңгелек бозлык куеныннан, йөзәрләгән тау асты мәгарәләреннән саркылып, сөзелеп чыккан көмештәй саф, тешләрне камаштырырлык чишмәләр һәм кечкенә елгачыклар белән туена. Зөбәрҗәт су кырына ук килеп басты, теге як яр читендә берничә көймә арлы-бирле йөзә иде. Ул кул изәп: «Әй... Аһа-һа-һай!» дип кычкырды. Аргы ярда аны шундук ишетеп алдылар. Бер-бер артлы ике көймә бу як ярга йөзә дә башлады. Җанага яр буйларын, елга буендагы яланнарны күзәтә иде. Зөбәрҗәтнең аякларын энә чаклы гына бихисап вак балыклар сырып алды. Алар сабый кызыксынуы белән борыннарын аның аякларына төртеп алалар. «Әй, син кем, ни эшлисең монда, бу бит безнең дөнья, ни кирәк, ни кирәк»,—дип дәшкән шикелле, бармакларын кытыклыйлар иде, аз гына хәрәкәт ясау белән алар шундук яшен тизлегендә тирә-якка сибеләләр. Рәхәт иде Зөбәрҗәткә. Менә яр буенда үскән йөз яшәр көмеш чәчле таллар. Аларны биш кеше дә кочаклый алмый. Алар күпне күргән, күпне белә. Нинди генә җил-янгыр, кар-давыл кичермәгән алар. Кайберсен рәхимсез картлык аударган, кайберсен аяусыз яшен кискән, тик аларның күбесе ауган килеш тә үләргә теләми, кәүсәсенең бер кабыгы, бер тамыры гына өзелеп бетмәсә дә, яткан килеш булса да һаман бөре бүртерә, яфрак яра, яфрак коя иде. «Туган ярларыннан аерыласылары килми»,—дип уйлап алды Зөбәрҗәт. Кәүсәләре тубырчыкланып, орыланып, яргаланып беткән, оланнары карт кешенең бүрткән тамырлары кебек буй-буй керешләнгән. Тик боларның барысы да үргә, кояшка тартыла, ә яшь ботаклары ак-яшел төстә ялт-йолт килеп нур коена, әйтерсең, елгадагы көмеш чабаклар. Яфрак очларыннан баллы тамчылар тама.

Ул арада алдагы көймә ярга килеп борынын төртте. Ишкәк артында тугыз-ун яшьлек кенә малай иде.

—Исәнме, туганым, безне чыгарасыңмы?

—А как же,—дигән булды малай егетләрчә, шәһәрдән кайткан кешеләр алдында ул үзен бу дөньяның хуҗасы кебегрәк тотарга тырыша иде,—утырыгыз!

Алар көймәгә керергә әзерләнгән арада, җир астыннан калыккандай, берсеннән-берсе ваграк тугыз баласын ияртеп унынчысын күтәреп, Житез Такинә пәйда булды.

«Әй, туктагыз, мин беренче, мин многодетная мать, хөкүмәтебез үзе права бирде мина, палаларны күттүрүп туралмаем пит инде мин,—дип көймә янына ук килеп басты. Ул арада балалар кырмыска көтүе шикелле көймәне сырып та алдылар. Олы малае, солдатларына дәшкән сержант кебек, тугыз баланы өчкә бүлеп: «Беренче тройка, Күгебай, Пагул, Айбилсу вперед», диюе булды, өч бала да көймәгә кереп кунаклады, аның артыннан, «Икенче тройка Әптий, Точмапий, Ведега», диюе булды, шундук тегеләре көймәгә үрмәләде, өченче төркем—Аялче, Көрши дә көймәгә кереп чүгәләде, иң соныннан имчәк баласын күтәреп, генерал кебек, Чехов геройлары кия торган кинкырлы алсу эшләпәсен җилдән саклый биребрәк, кыска шорты кигән, кояшта янган ныклы ботларын ялтыратып Такинә үзе дә көймәгә узды.

Зөбәрҗәт белән Җанага, авызларын ачып, берни әйтәлмичә, яр буенда басып калдылар. Бераздан ярга икенче көймә килеп туктады. Ун яшьләрдәге кыз танавын тарткалап ишкәк артында утыра иде.

—Хакы күпме, туганым?

—Биш инде, биш, апа. Ипи хакы.

Зөбәрҗәт көймәгә кереп утырды. Җанага машинасын бикләп көймә янына килде һәм озын юл буена беренче тапкыр телгә килде:

—Олы кешене чакырырга кирәк, бу пацанканың батырып куюы да бар.

Зөбәрҗәт көлеп җибәрде:

—Курыкма, Җан, алар ана карыныннан туры Иделгә төшә, йөри башлаудан алда йөзәргә, сөйләшә башлаудан алда ишәргә өйрәнәләр, кер әйдә, утыр, курыкма.

...Идел уртасына килеп җиткәч, көчле агым көймәне аска каера башлады, агымга бирешмәс өчен кызыкай кинәт көймәне борып җибәрде. Көймә янтаеп китте. Бер мизгелдә Зөбәрҗәт Җанаганың күзләрен күреп шаккатты: ул күзләрдән ниндидер шашынулы курку хисе бөркелә иде. Ирнең авызы чалшайган, куллары белән чытырдап көймә читенә ябышкан. Таштимер кебек Җанаганың да куркыр нәрсәсе бар икән. Зөбәрҗәт Җанагадан: «Куркасың түгелме, әллә йөзә белмисең»,—дип сорады.

Җанага ишетмәмешкә салыштымы, әллә чыннан да ишетмәдеме—җавап бирмәде.

* * *

Нәнәсеннән калган өй тузып бара иде инде. Тәрәзә капкачлары кадакланган, җил капка каерылган, ихатаны бәбкә үләне баскан, бакчаларда алабута, әрем шаулап утыра, читән буйларын кычыткан сарган, ишек йозакта, сарай башына менә торган ишек каерылып төшкән, аның караңгы авызы гына ниндидер сер саклаган кебек томырылып, караеп тора. Кайчандыр монда кеше яшәгәнен хәтерләтеп, тутыккан тимер кыршау белән әйләндереп алынып чылбырга тагылган кое чиләге генә җил уңаена чылтыр-чылтыр килеп зарлана иде. Зөбәрҗәткә хәзер аның нәнәсе йөгереп чыгып каршы алыр кебек тоелды. Ләкин аны күгәненә аркылы тимер куеп бикләнгән амбар йозагы каршы алды. Ул яшьләрен күрсәтмәскә тырышып сумкасыннан йозак ачкычын алды. Нәнәсен күмгәннән соң бу йортка беркемнең дә аяк басканы булмаган.

Җанага тәрәз капкачларын ача башлады. Өй эченә бөркелеп кояш керде. Тәрәзәгә эленгән пәрдәләр саргаеп, тузанланып беткән. Тәрәзә пыялалары тонykланган, тышта җылы булса да, ай салкынча, мәет чыккандагы кебек күңелсез, монсу иде.

—Бәлки кире уйларсыз, кайтырсыз Уфага,—диде Җан.

—Юк, рәхмәт, сумкаларны керт тә, син кире китсәң дә була, көймәчеләр көтеп торадыр үзенне.

Җанага сүзсез-нисез генә сумкаларны өйгә кертте дә, чыгып китте. Зөбәрҗәт тәрәзә аша аның пеләшләнеп килгән башын, нәрсәнедер тотып кысарга, буарга әзерләнгән кебек тырпаебрак торган көчле бармакларын, зур йодрыкларын, юлбарыс кебек сыгылмалы, астыртын йөрешен тәннәре чымырдап карап калды.

Авылда хәбәр тиз йөри. Зөбәрҗәт урнашып та өлгермәде, сыйныфташ кызлары Гүзәл белән Рита йөгереп килеп тә җиттеләр. Гүзәл фермага кичке савымга китәргә тора икән, Рита медпунктта җыештыручы булып эшли, кичкә идән юарга барырга җыена.

Китте чырк-чырк көлешүләр, ах-лар, вах-лар. Зөбәрҗәткә сокланулар. «Һай, кызый, нинди чибәр син, нинди затлы, нинди матур киемнәр кигәнсең, озакка кайттыңмы, кайчан китәсең, ирең кем, нигә ул да кайтмады»— һәм башкалар һәм башкалар...

* * *

Чибәрләр бәйгесеннән соң икенче көнне Зөбәрҗәт яшәгән тулай торакка килеп, Леон аны ялтлап торган машинага утыртып Радмирның офисына алып китте. Зөбәрҗәт каршында утыз биш яшьтән узган, йомшак аксыл дулкын чәчле, алсу-ак чырайлы, спортсменнарча нык гәүдәле ир утыра иде. Елмайганда күз койрыкларында кош тәпиен хәтерләткән сызыклар барлыкка килсә дә, күрер-күзгә Радмир сөйкемле

генә иде. Ул өстәл артыннан торып, Зөбәрҗәткә каршы барып елмая, елмая: «Менә бит, безнең чибәркәйне якыннан күрү бәхетенә дә ирештек»,—дип каршы алды.

Йомшак кәнәфиләргә утырдылар. Кнопкага басып секретаршасына кофе кертергә боерды. Азга гына бүлмәдә киеренке тынлык урнашты. Жир йөзендә нык басып торган, әмерләре бер бармак кыбырдату белән үтәлә торган, дөнья урамнарының һәр чатында алар өчен һәрчак яшел ут янган байлык ияләре, ул гына да түгел, күп кешеләр язмышын үзгәртер кодрәткә ия булган кешеләр каршында, аларның ачыктан-ачык кызыксыну катыш бәяләүле карашлары астында Зөбәрҗәт югалып калды. Аның колак очларындагы ике бөртек очсызлы пыяла алкаларына кадәр кызарган кебек булды. Ирексездән ул үзен сатарга чыгарылган мал кебегрәк хис итте. Ул хәтта сәхнәдә меңәрләгән карашлар астында, су коену костюмыннан басып торганда да үзен шулкадәр яклаучысыз итеп тоймый иде. Сәхнәдә ул өстә, халык белән аның арасын рампалар аера, ә бүген ул ике ят ирнең күз карашы астында үзен шыр-ялангач итеп хис итте. Уң тезе өстендәге итәгенең ярыгын бар көче белән ныграк капларга тырышып тарткалый, тик тар итәгеннән беленеп торган йомры, тыгыз ботлары тыңлашмаска теләгәндәй һаман ныграк беленергә тырышалар кебек тоелды аңа. Үз-үзенә ачуы килеп, ул аскы иренен тешләде. Хәзер үк бу бүлмәдән чыгып китәсе, әллә кайларга йөгерәсе килде аның, ләкин калырга кирәк иде, акча кирәк иде аңа, бик кирәк иде.

Ниһаять, тынычлыкны Леон бозды:

—Шеф, мин кирәк кәгазьләрне әзерләп алып керимме?—диде.

Радмир ризалыгын белдереп ияк какты.

Кыз чибәр иде. Бер күрү белән үзенә тарта иде. Әллә нинди бик тансык иде ул, бик үз итәсе килгән, кочакта эретәсе килгән нәзәкатьлелек катыш ир-ат теләкләрен кузгатып җибәрүче хатын-кыз көче бар иде бу ыспай гына гәүдәдә. Радмирның башы әйләнеп китте. Ул чак кына, итәгенең ерыгын капларга тырышучы, йомры нечкә озын бармакларга үрелмичә калды. Секретарь кыз кофе кертте.

Радмир үзен-үзе кулга алып кыздан аның әти-әнисен, туган ягын, гаиләсен, укуын сораштырды. Аның талгын, йомшак тавышында, итагатьлелегендә тынычландыручы, күңелне иркәләүче көч бар иде. Зөбәрҗәт акрынлап тынычланды. Артык нечкәлекләргә тукталмыйча үзенең тормышын сөйләп бирде.

Ул арада Леон да керде. Кәгазьләрне Радмирга сузды. Радмир аларны карап чыкканнан соң: «Зөбәрҗәт, сылукаем, монда тагын бераз гына формальность бар бит әле. Кәгазьләр әзерлеккә—әзер, тагын бер моментны гына килешеп аласы бар, без иртәгә очраша алабызмы?—диде. Зөбәрҗәткә кыен булып китте, аның бар өмете бүген акчаны алып, тизрәк кирәкле даруларны сатып алып нәнәсенә кайтарып бирү иде.

Ләкин, ни эшләмәк кирәк, акчаны каерып алып булмый. Ул ризалык белдереп баш какты.

«Леон сезне барып алыр»,—диде Радмир. Кыз чыгып киткәч Леон: «Шеф, кәгазьләр тәртиптә ич, но мин анламадым, бу кыз сезнең күңелдә очкын кабызды бугай»,—диде ул ирен читендә ике мәгънәле елмаю чагылдырып.

—Иртәгә кичке җидегә минем дачага алып килерсең,—диде.

—Кайсысына?

—Болынлыга.

—Понял, шеф, не дурак.

Әллә нинди ике төрле хис белән чыкты Зөбәрҗәт Радмир офисыннан. Ошады да кебек аңа бу яшь бай. Мөлаем да кебек, кешелеклегә дә ошаган, ягымлы да, аннары тышкы кыяфәте дә килешле. Киемнәре—кыйммәтле: журналларда басылган затлы костюмда. Яңаклары шоп-шома итеп кырылган, чәчләре дә килешле генә, тик түбә башы чәче генә бераз сирәгәя барганын белдереп бала йонына әйләнә башлаган. Леон белән сөйләшкәндә кырт кисеп, өзек-өзек боерык бирүләре, телефон шалтырагач кемнеңдер хәбәренә риза булмыйча күзләрендә чагылып киткән кискенлек, тавышы-

ның тимер кебек чынлап алуын, күреп-ишетеп торгач, Зөбәрҗәт Радмирның беркатлы кеше түгел икәнен аңлаган иде. «Һи, нәрсәгә инде ул миңа. акча бирсәләр, аларның миңа ни хаҗәте?»—дип юатты үзен. Тик күңеленең ин төбендә шик дисәң, шик түгел, курку дисәң, курку түгел—ниндидер бер шөбһәләнү кебегрәк нәрсә кыймылдый иде.

Сөйләшенгән вакытка тулай торак алдына Леонның затлы машинасы килеп туктады. Гади генә, әмма гәүдәсенә килешле костюм, юка ветровка кигән Зөбәрҗәтне Леон әллә кайдан күреп алды. Бу кыз Леон күңелендә дә бураннар уятып җибәргән иде. «Кемне сайларга белә, каһәрен», дип уйлап алды Леон хуҗасы турында. «Юкка гына аны «төгәл» димиләр, һөҗүме кобраныкы кебек, бу бала да башка бик күпләр шикелле елан авызындагы тычкан гына»,—дип уйлап алды ул. Хәтта күңелендә бу кызга карата аз гына кызгану хисе дә уянып киткән кебек булды, ләкин шунда ук: «Үзе гаепле, җинел акча юкка гына бирелми ул, урысча әйткәндә: «Бесплатный сыр только в мышеловке»,—дип уйлады.

Шәһәрне чыга башлагач Зөбәрҗәт аптырап китте. «Кая баралар алар, нигә шәһәрдән ераклашалар, нигә офиска бармыйлар».

—Борчылма, чибәркәй, эш көне бетте бит инде, офис ябык, Радмир абыең бүген сине үзенең особнягында көтә, эштән чирләбрәк кайтып китте, курыкма, акчаңны алу белән үзем илтеп куярмын,—диде аңа Леон.

Зөбәрҗәт бераз тынычланган кебек булды. Ләкин эчендәге икеләнү, шикләнү хисен барыбер җиңә алмады. Дача шифаханәләр зонасында икән. Урман арасында. Биек коймаларга килеп терәлгәнче асфальт юл салынган, Язгы кич әле җиләсләнергә өлгермәгән. Өч тиен акча кебек кенә зурлыкта агач яфраклары арасыннан җил уңаена дулкын-дулкын сирпелеп төшкән кичке кояш нуры күзләрне чагылдыра. Урман эченнән черегән яфрак, дәррәү калыккан умырзая, кәккүк чәчәкләре исләре, тагын мең-мең төрле башка исләр борынга килеп бәрелә. Шул исләргә өй артыннан күтәрелгән зәңгәр төтен, кыздырылган шашлык исе килеп кушыла.

Капканы баһадир гәүдәле, спорт киемендәге кырык яшьләр тирәсендәге кеше ачты. Аның күзләре Зөбәрҗәтне без кебек үтәдән-үтә тишеп карый иде. Зөбәрҗәт куырылып китте, үзе дә сизмәстән, ярдәм эзләгән шикелле Леонга таба тайпылып куйды.

«Курыкма, бу—Жан»,—диде үтеп барышлый гына Леон Зөбәрҗәткә. Абалап ике эт килеп чыкты. Жан аларга бер генә кычкырды. «Пшел, на место!» Бу кычкыруда әллә нинди кодрәт, аяусызлык һәм көч бар иде. Шунда ук бүре зурлыгы этләр өрүдән туктап, талатмаганга ризасызлык белдергән шикелле чинап, койрыкларын кысып күздән дә югалдылар.

Йорт матур иде. Ике катлы. Кызыл керәч кирпечтән эшләнгән. Ишек алдын, өйнең түбәсен мәрмәр белән тышланган дүрт колонна тотып тора, тәрәзә яңаклары, йөзлекләре төсле орнаментлар белән комаланган. Алар европа стилендә карангылатып эшләнгән ишекләрдән йорт эченә үттеләр. Хуҗа үзе каршы алды.

Бүлмә уртасында—йомшак мебель, кечкенә өстәл. Радмир Зөбәрҗәтне шул креслоларның берсенә утыртты. Ул арада Леон икенче бүлмәдән шампан шәрабе куелган көмеш чиләк күтәреп чыкты. «Йә, чибәркәй, синең җиңү өчен азрак тәмләп карыйк»,—диде Радмир бокалны Зөбәрҗәткә сузып.

—Мин эчмим.

—Бөтенләй дәме?

—Юк.

—Алайса, минералка, рәхим ит!

Бераз утыргач ул: «Аш әзерме, кунакның карыны ачкандыр, студент халкы бик байдан яшәми, аш бүлмәсенә рәхим итик»,—диде.

—Мин, кайтыйм инде, мөмкин булса, тизрәк эшне бетерик тә.

—Мөмкин, бик мөмкин, ник мөмкин булмасын, тик «аштан олы булып булмый»,—дигәннәр картлар, булганыннан азрак авыз итик инде, анда Жан агаң шашлык кыздыра бугай, студент кешегә ярап куя ул. Леон, син кәгазьләрне әзерлә, чибәркәебез белән исәп-хисап ясарга кирәк.

Леон: «ярый»—дигәнрәк өн чыгарды да, баскычтан икенче катка күтәрелде. Радмир Зөбәрҗәтне әйдәләп сул яктагы ишектән аш бүлмәсенә алып керде. Аш бүлмәсенең уртасында ун-унике кешелек озын ашъяулык белән ябылган ныклы өстәл тора иде. Андагы сый, нигъмәт! Барысы да бик нәзакатьле, зәвык белән киселгән һәм тезелгән. Ирексездән бу йортта Леон белән Жаннан башка тагын кемнеңдер барлыгы сизелә иде.

Болай матур итеп өстәлне бары тик хатын-кыз гына бизи алыр кебек. Зөбәрҗәтнең эченә җылы йөгерде, димәк, ул бу йортта бу әзмәвер кебек ирләр белән берүзе генә түгел, тагын хатын-кызлар булырга тиеш. Кыз кыюсыз гына Радмир күрсәткән урындыкка килеп утырды. Ул арада икенче каттан ниндидер кәгазьләр алып Леон да төште.

—Ярый, ашау эш калдырмый, куеп тор, Леон, кәгазьләрне, әйдә, кушыл, —дип бокалларга ниндидер эчемлек коя башлады. Радмир үзенә һәм Зөбәрҗәт бокалына куе кан төсендә кып-кызыл шәраб салды. «Безнең гүзәлебез, иң милли, иң сөйкемле, акыллы һәм тыйнак Зөбәрҗәт туташ өчен»,—дип Радмир бокалын эчеп куйды. Леон аракы эчте.

—Бер генә тәмле, ул исертми,—диде Радмир,—иганәче абыеңа хөрмәт йөзеннән генә.

Шулай дигәч, Зөбәрҗәт бераз эчеп куйды. Шәраб чыннан да тәмле иде. Сусап килгәнгәме, ул лимонад кебегрәк тоелды. Икенче тостны да Радмир әйтте:

—Синең нәнәңнең тизрәк терелеп, озак яшәве өчен!—Бу тост өчен аз гына капмый булмый инде.

Зөбәрҗәт тагын уртлады.

Ул арада Жан дымланып-төтенләнеп торган шашлык кертте. Радмир бик игътибарлы иде. Ул Зөбәрҗәткә әле тәмле салат, әле кыздырылган балык, әле тәмләткечләр белән томалап пешерелгән куян итен сузды.

—Үзегез аттыгызмы, ничек ашамак кирәк бу мескен куянны,—диде Зөбәрҗәт яшь тулы күзләрен Радмирга төбәп.

—Әйе, үзем, үзем, кибеткә барып ике күзем белән атып, «Зөбәрҗәт сылу килүгә куян өресе пешерергә кирәк, китерегез куянны»,—дип акча биреп атып алдым,—дип шаяртып, тавышларын үзгәртеп җавап бирде Радмир. Алар кычкырып көлеп җибәрделәр, табын артында күңеллерәк булып китте. Ул арада Леон да урман җәнлекләре турында ниндидер анекдот сөйләп алды. Тагын көлеш китте, тагын бокалларга шәраб коелды. Зөбәрҗәткә бу кешеләр бик күптәнге таныш, бик яхшы кешеләр кебек тоела башлады. Үзе дә нәрсәдер сөйләргә маташты. Тагын көлешкән булдылар. Зөбәрҗәтнең рәхәт кенә итеп башы әйләнә, бар тәнендә рәхәт изрәү, җылылык иде. Радмир да ана ошый кебек тоелды. «Әллә исердем инде»,—дип уйлады ул куркып. Тышка карады. Урамда әллә агач ышыгы булганга, әллә чыннан да соң иде, карангыланган иде инде.

—Радмир абый, мин кайтыйм инде, соң бит, Леон мине илтсен инде,—диде ул, кинәт кенә уянып киткәндәй аптырабрак. Чөнки өстәл артында аларның икесеннән башка беркем дә калмаганын күрде.

—Ярый, Зөбәрҗәт, менә чегың, ул әзер, син бу акчаны банктан хет иртәгә кереп алаласың,—дип, хуҗа өстәл өстендә яткан чекны кызга сузды. Зөбәрҗәт рәхмәт әйтеп чекны сумкасына салып куйды да, урыныннан кузгалды.

—Леон хәзер кайта, мин аны йомыш белән җибәрдем, тиздән ул монда булачак, хафаланма. Әйдә, мин сиңа йортымны күрсәтәм, вакыт та тизрәк үтә торыр.

Алар дачаның икенче катына күтәрелделәр. «Менә ял бүлмәсе, менә бильярд залы, менә кунаклар өчен бүлмә»,—дип, күрсәтеп йөрде ул Зөбәрҗәткә йортын. Иң соңыннан ул аны бик зәвык белән җыештырылган иркен бүлмәгә алып керде. Бүлмә түрендә киң ятак тора, янында тумбочка, өстендә төнге лампа, идәндә авызын зур ачып, ап-ак бармак буе тешләрен күрсәтеп, нәкъ тере кебек кап-кара күзләре белән Зөбәрҗәтне тишеп карап бик зур, озын йонлы аю тиресе ята иде.

Зөбәрҗәт куркып китте. Ирексездән артка чигенде һәм Радмирның кочагында калды.

—Чибәрем син минем,—дип кайнар пышылдады Радмир аның колагына. —Курыкма, беркемгә дә бирмим мин сине.

Ул Зөбәрҗәтнең муеннарыннан, битләреннән үбә башлады. Зөбәрҗәт айнып китте, аннан ничек тә тартылырга, котылырга, кочагыннан чыгып ычкынырга тырышты, терсәкләре белән Радмирның күкрәкләреннән этәрде, тыны кысылды, куркудан бигрәк ул ачуланган иде.

—Җибәр, Радмир абый, кычкырам, җибәр,—диде ул ачыргаланып.

—Кычкыр, беркем дә ишетми, монда беркем дә юк. Ошыйсың син миңа, Зөбәрҗәт, бер күрүдә ошаттым мин сине, алтынга күмәм мин сине, бәләкәчем минем, тик ярат кына мине, ярат кына.—Ул көчле куллары белән Зөбәрҗәтне бала шикелле генә күтәреп киң ятакка ыргытты.

Зөбәрҗәт иртән таң беленгәндә берни сизми йоклап яткан Радмирның кул астыннан шуып чыгып, теләсә кайда умырылып ташланган киемнәрен җыйнап, аннан-моннан гына киенде, сумкасын ачып Радмир биргән чекны ятак өстенә ыргытты да акрын гына чыгып китте.

Шәһәргә ничек, нәрсә белән, кайчан кайтып кергәнен дә хәтерләмәде. Аның бар өметләре, бар ышанычы, хыяллары челпәрәмә килеп ватылган иде.

Бу төн Зөбәрҗәтнең киләчәккә бар ышанычын, өметен пыран-заран китерсә дә Радмирның, киресенчә, алдындагы пәрдә кинәт ачылып, кояш чыккан кебек булды. Аны бигрәк тә үзе уянып киткәч Зөбәрҗәтнең янында юклыгы һәм ул биргән чекның ятакта аунап ятуы гаҗәпләндерде. Ә бит моңа чаклы гел киресенчә иде. Соңыннан кызлардан котылып булмый, ә акчаны ничек тә күбрәк каерырга тырышалар иде. Эш анда да түгел, эш Радмирның үзендә иде. Ул көн буе мыңгерәүләнеп йөрде. Аның бар булмышы Зөбәрҗәт белән тулы иде. Тәненең һәр күзәнәге Зөбәрҗәтне сагына, аны юксына, аны таптыра башлады. Сыгылмалы-сынлы назлы, карышу тулы, ләкин шул ук вакытта назга җавап бирергә әзер торган тәне башларны әйләндереп үзенә чакыра. «Әллә ашыктым инде,—дип уйлады ул.—Бу кыз бер көнлек күбәләккә охшамаган».

Вакыт үтә торды. Эш муеннан: яңа сөйләшүләр, яңа клиентлар, яңа долларлар арта, өстәлә торды. Ләкин язгы дым белән тулы искиткеч шул төн Радмир күңеленнән китмәде.

Леон да хуҗасына гаҗәпләнә иде. Теге кыз белән очрашканнан соң нидер булды шефка. Аз сөйли, күбрәк уйлана башлады. Әллә сихерләп китте инде үзен? Хәер, сихерләмәслек тә түгел иде шул кыз. Леонның күңеленә дә вәсвәсә салды ул. Үзенең Зөбәрҗәтне эзләп табасы килде.

Ә нигә тапмаска, элек-электән кайбер халыкларда тәүгелек хокукы булган бит, башта килен хуҗа белән йокларга тиеш булган, аннары насибы белән. Бу очракта ул ире булмаса да, (ире булырга җыенмый да) сылукайның кайнар тәнен татып карау теләге Леонны да эчтән кимерә башлады. Һәм ул тәвәккәлләде. Һич көтмәгәндә кызның тулай торагына килеп керде. Зөбәрҗәт идән юып йөри иде. Леон килеп кергәч, ул куркып, гаҗәпләнеп китте.

—Нәрсә кирәк сезгә?—диде ул күптән көткән кешесен яңа күргәндәй.

—Әгәр мөмкин булса, мин сезне бүген ресторанга чакырырга килгән идем.

—Хуҗагыз чакырамы?—диде Зөбәрҗәт ишетелер-ишетелмәс кенә.

—Юк, юк, нигә ул, аның моңа кадәр бер кызны да ике тапкыр чакырганы юк, мин үзем, минем белән...

Зөбәрҗәтне әйтерсең җен сукты, ул бер секунд кына Леонга карап торды да яшен тизлеге белән иелеп идән юган сулы бидрәне Леонның башына каплады.

Көннәр үтә торды. Зөбәрҗәт акрынлап һушына килә башлады. Ул үзенең ничек итеп шулай оста алдануына аптырап бетәлмәде. Ничек тиз ышанды ул Радмирга, ничек оста җәтмәгә каптырды ул аны. Артыннан йөргән егетләр булмады түгел, булды аның. Ләкин алар барысы да аңа малай-шалай булып күренделәр. Тозсыз сүзләр сөйлиләр, ике сүзнең берендә сүгенәләр. Барысы-

нын да уйларында модалы кием, әти-әни акчасын сырага, сигаретка, хот-дог, кока-колага туздыру, кызлар белән типтерү һәм, урысчалап әйткәндә, любовь белән заниматься итү иде. Ә Зөбәрҗәт башкачарак, авылдагычарак тәрбияләнгән иде. Иртә ятим калганга, кемнеңдер нык күкрәгенә терәләсе, имән шикелле ир-егетнең канаты астына сыенасы, ышаныч, таяныч булырлык кешене табасы килә иде аның.

Ике күрүдә үк, күнеленең иң эчке бер тоемлавы белән, Радмирның шундый кеше була алу мөмкинлеген ул чамалаган иде. Хәтта күнеленең иң түрендә аңа карата ниндидер җылы хис тә уянган кебек иде.

Ләкин Радмирның үзен шундый кыргыйларча, көтмәгәндә мәкерле алдавы, сатып алырга теләве аның бөреләнеп кенә килгән хисләрен кырау шикелле куырды да алды. Ул бу хакта уйламаска тырышты. Тик уйлар үзеннән-үзе шул төнгә кире кайта, кабат-кабат кино тасмасыдай кабатланып күз алдыннан үтә, Радмирның кайнар пышылдавы, котырып, авырттырып үзен «яратуы» нәфрәт һәм чуалышлы хисләр уятты.

Аяз сентябрь көнендә республика китапханәсеннән чыгып Ленин урамы буйлап килгәндә кинәт Зөбәрҗәт янына иномарка килеп туктады. Ишек ачылып, аның каршысына Радмир килеп басты.

—Зөбәрҗәт, исәнме, сиңа сүзем бар иде,—диде ул берни булмагандай елмаеп.

Зөбәрҗәт аның исәнлеген дә алмыйча, пединститут ягына каеручы урамга борылды.

—Зөбәрҗәт, безгә сөйләшергә кирәк иде.

—Нәрсә, бу юлы күпмегә чек язарга чамалыйсыз?

—Гафу ит, бу минем исәрлек, аңла, монда бөтенләй икенче нәрсә. Гафу ит мине, зинһар!

—Хушыгыз!—Зөбәрҗәт ашыгып институтына кереп китте.

Шушы көннән соң Радмирны алмаштырып куйдылармыни!? Ул беркемне дә күрмәс, сөйләшмәс булды. Эшен тулысы белән диярлек Леонга тапшырды. Иртән дә, кич тә аякчылары артыннан Зөбәрҗәткә кочак-кочак чәчәкләр ташытты. Тулай торакның коменданты белән дуслашып алды. Ял бүлмәләрендә телевизор ватык икән, өр-яңа төсле телевизор, утырып карарга йомшак диван, креслолар китертте. Зөбәрҗәт яши торган катның кухнясына өр-яңа «Индезит» газ плитәләре куйдырды, коридорына кып-кызыл келәмнәр җәйдерде. Подвалда урнашкан душ бүлмәләренә ремонт ясаттырды, стеналарына кафельләр ябыштыртты. Ул боларны бер көтү эшчеләр алып килеп үзе карап торып эшләтте, әйтерсең башка бер эше дә юк иде аның. Кызлар үзләре укуда вакытта берничә сәгать эчендә Зөбәрҗәт яшәгән бүлмәнең обойларын алыштырып, яңа, унайлы агач кроватьлар керттерде. Ләкин Зөбәрҗәт таш кебек иде. Бу эшләрнең кем өчен эшләнгәнен барысы да беләләр һәм ике якта барган көрәшнең ни белән тәмамланасын кызыксынып көтәләр иде.

Радмир Зөбәрҗәтне очраткан саен:

—Зөбәрҗәт, чык миңа кияүгә, бүген үк язылышабыз. Барысы да син теләгәнчә булыр, мин синсез яши алмыйм,—дип кабатлый иде.

Чыннан да, ул аңа барысын да бирергә әзер иде. Бу гыйшкы аны зәһәр ялкын шикелле бар булмышын яндыра, көйдерә, төшләрендә ул аның назлы тәнен тоя, йомшак чәчләренә уралып, ике теш арасыннан нур чәчкән елмаюына коена, ә уянып китсә, тагын үҗәтләнеп Зөбәрҗәт артыннан чаба иде.

—Исәрләнгән, дип беркөнне Леон Җанагага Радмир хакында сүз катты,—шаккатарсын, чакматаш кебек кешене бер чәчби балавызга әйләндерде дә куйды, минсинайтим!

Галәтенчә, Җанага бер сүз дә дәшмәде, ул бу кызга ни өчендер ышанмый, күнел түрен ниндидер шик корты кимерә дә тора иде. Бу кыз ызгыш алмасы булмагае!—дип курка иде ул.

Озакка сузылган каршы торулар беркөнне җинел генә хәл ителде дә куйды.

Радмир, Зөбәрҗәтнең әбисе кайда яшәгәнен белеп, авылга кайтып, чирле

карчыкны республиканың иң дәрәҗәле клиникасына дәваларга алып килде. Үзе бу хакта Леон аша Зөбәрҗәткә дә хәбәр иттерде. Зөбәрҗәт дәваханәгә йөгерде. Әбине министрлар ятып дәвалана торган палатага салганнар, тирәягында ике-өч табиб йөгерешә.

Бу хәлне күргәч, Зөбәрҗәт еларга да, көләргә дә белмәде. Нәнәсе аңа:

—Кызым, кияү шушы булыр инде, бик итагатьле, бик инсафлы, бик киң күңелле бала икән, минем көннәрем санаулы калды, мине хәзер бәлнис ятагы түгел, алтын тәхет тә терелтәлми, кара ләхет тә куркытмый. Яратам кызыңны!,—дип өзелеп тора бит, шуңа чык та куй, яшең дә җиткән, үзеннән олы да, кадереңне белер. Мин үлсәм, башка кешең калмый, ирең булса, тынычланып гүр куенына китәр идем,—диде.

Йөзе сап-сары булып киткән, бәләкәй генә калган нәнәсенә карап Зөбәрҗәтнең күзләренә яшьләр килде. Гомер буе рәхәт күрмәгән, иреннән иртә калып бердәнбер улының да изгелеген күрмичә дөнья авырлыкларын бөгелә-сыгыла күтәреп, бердәнбер өмете булган оныгының бәхетен күреп үләсе килгән карчык шуны тели, бик тели иде.

—Син тыныч кына дәвалан, мин яшь бит әле, өлгерермен.

—Нинди яшь, ди ул, нинди яшь ди, унтугызда, тиздән егермегә китәсең, картаясың, йоклап йөрсәң, егетеңне эләктерергә торучылар күп булыр.

Радмир әбекәй янына көн саен диярлек барып йөри иде, алар Зөбәрҗәт белән дә еш кына әбинең палатасында очрашалар. Үзләре дә сизмәстән, бер гаилә кебек әбинең авыруы турында сүз алышалар, ашарына кыстыйлар. Шулай иттереп әби Радмир белән Зөбәрҗәтне тоташтыручы бер җепкә әйләнде.

Палатадан бергә чыгып китәләр, Радмир юл уңаенда Зөбәрҗәтне тулай торагына илтеп куя, итагатьле генә машина ишеген ачып төшерә, тәртип белән генә хушлаша, гомумән, үрнәк егеткә әйләнде.

Табиплар ничек кенә тырышмасыннар, әби көннән-көн сүнә бара. Моны сизү Зөбәрҗәт белән Радмирны тагын да якынайтып җибәрде. Бер кич, икесе дә янында утырганда, әби тырышлык белән генә күзен ачып:

—Зөбәрҗәт кызым, мин китәм, бәхил бул, кияү сиңа да рәхмәт, бик изгелекле бала икәнсең, туегызны гына күралмам инде,—диде.

—Күрерсең, нәнәй, күрерсең,—дип бертавыштан юаткан булдылар алар әбине. Таңда әби дөнья куйды.

Әбинең үлеме аларны тагын да ныграк якынайтты. Радмир әбине авылга алып кайтып җирләүне үз өстенә алды. Матәм машиналары, алар артыннан берничә иномарка әбине салып авылга юл алдылар.

Нәнәсен күмгәч Зөбәрҗәт туры Радмир янына кайтты. Әбинең кырыгыннан соң Радмир бар шәһәрне шаулатып туй үткәрде. Туйда затлы машиналар «Россия» ресторанын сырып алдылар, мәҗлес бай һәм мәртәбәле итеп әзерләнгән иде.

Туй кылмәгенең матурлыгы һәм баш әйләндергеч бәясе хакында бай хатыннары колактан-колакка пышылдаштылар.

Иң беренче теләкләрне компьютерлар сату фирмасы хуҗасы Натан Маркович әйтте: «Шундый гүзәлнең аяк астына, хөрмәтле Радмир Әмирович, бар байлыгыгызны түшәвегез сезгә мәртәбә генә өсти, эшегез уң булсын»,—диде.

Аннары кәрәзле телефоннар челтәре хуҗасы: «Гүзәл Зөбәрҗәт ханым—сездән биш карапуз көтәбез»,—диде. Аннары шәһәрнең зур төзелеш компаниясе директоры, эреле-ваклы нефть, газ корольләре, яңа байлар матур-матур сүзләр әйтеп бүләкләрен бирделәр.

Түбән табында утырган Леон гына, исереп алгач: «Сучка продажная»,—дип мыгырданды. Зөбәрҗәтнең Радмирның байлыгы өчен генә кияүгә чыкканына аның иманы камил иде.

* * *

Зөбәрҗәт кичкә кадәр иртәгә өй юу өчен чиләк, таз, юкә мунчала әзерләде, кибеткә барып сабын, кер юу порошоклары, башка кирәк-ярак сатып алып кайтты. Артык-портык комачаулаган, чыланырлык

әйберләрне өйалдына, лапас астына ташыды, тәрәзәдән тузанланган пәрдәләрне, ишек чаршауларын салдырды, түшәк-юрганнарны киртәгә жилләргә элде. Көтү кайтып сыерлар савылу белән өйгә житен чәчен икегә ярып үргән зәп-зәңгәр күзле какча гына жиде-сигез яшьлек кызчык йөгереп керде.

—Зөбәржәт апа, әнием әйтә, чәй кайнады, коймак пеште, апаңны алып керсәң дә ярый,—ди.

—Кем кызы буласын соң син?

—Мин, ни, Мортаза абыйның кызы—Ләлә булам.

—Нинди Мортаза?

—Әй, шуны да белмисеңмени?—диде кыз нык гажәпләнгәнен белдереп.— Таза Мортаза абый инде, гер күтәрә торган...

—Ә, ә...—дип Рита кызы икәнен аңлап алды Зөбәржәт. Ул арада кыз чыгып та югалды. Зөбәржәт сумкаларын ачып алып кайткан күчтәнәчләрен алды да, өен бикләп, Риталарга кереп китте.

Күчтәнәчләр белән, коймак белән тәмләп чәй эчкәннән соң, Зөбәржәт Ритадан сорый куйды:

—Медпункт юган өчен үзенә күпме түлиләр соң?—диде ул.

—Мин бит ике жирдә эшлим, ярты ставкага клубны да юам. Акчасы бар инде анын, алты йөз егермене медпункттан, ике йөз утызны клуб юган өчен алам.

—Нәрсә—доллармы?—дип сорады Зөбәржәт.

—Нәмәстәдәй доллар?—Рита, аңламыйча, карашын Зөбәржәткә төбәде. Зөбәржәт уңайсызланып куйды.

—Шул акчага ничек яшисез?

—Житә ул. Авылның яртысыннан күбесе эшсез, өйдә утыра, бер тиен акча да килми. Өйләрендә карт-коры булганнарга рәхәт, пенсия килеп тора, байлык инде ул. Тоташ гаиләләр шул пенсиягә карап торалар. Эчмәгән кешегә житә ул. Аллага шөкер, минем Мортазам эчми әле.—Ул бик горур һәм канәгать төстә Зөбәржәт алдына очсызлы кәнфитләр салынган пыяла савытны этебрәк куйды.—Безнең чәйлек-шикәрлек бар. Сирәк-мирәк балаларның өс-башына да алгалыйм. Менә Моратка көзгә жылы итекләр белән куртка алырга акча жыябыз. Ай саен икешәр йөз салып барам. Яртысы жыелды инде...

Зөбәржәткә йокларга шыгырдап торган чип-чиста урын-жир әзерләгән иделәр. Бик озак йорт тирәсендә ыгы-зыгы тынмады әле. Ара-тирә Моратның «ах-ух» килеп гер күтәргәне,Ританың кул сепараторын әйләндергәне, бозау эчергәне, чиләк-кәстрүл юганы, балаларны ашатып-эчереп, юындырып яткырганы ишетелеп торды.

Иртән Зөбәржәт уянганда Рита инде сыерын савып малларын куган, ишек алдына чәен әзерләгән иде.

—Чәйне ишек алдына әзерләдем,—диде ул гаепле сыманрак итеп,—Морат тавышка йоклый алмый, йокласын йокысы туйганчы, бик арый көн буена.

Аннан-моннан чәй капкалап алар иртә таңнан Зөбәржәтнең өен юарга кереп киттеләр.

Гүзәл ни өчендер килмәде.

Ах, ул сабынлап, кырып, юкә мунчала белән юып чыкканнан сон таралган агач өйнең хуш исләре! Мондый ис беркайда да юк, бу ис үзенчә, бу ис бернинди искә дә охшамаган. Бу истә табигый тәм дә, пакьлек, чисталык та, гаделлек, самимилек тә, дөньяның, яшәешнең асылы да бар кебек. Ул исне күкрәк сөтен имүче яшь бала исе белән генә чагыштырып буладыр. Ул арада Зөбәржәт казан астына чыбык-чабык өстәде, кайнар плитә өстендәге чүлмәккә Ритадан алып чыккан бәрәңге белән суганны турады, ит төнәтмәсе салып аш өлгертте.

Кырып юылган сап-сары имән өстәл өстенә гәзит жәеп чәйнеген куйды, үзе белән алып кайткан нигъмәтләрне чыгарды. Затлы шәраб ачты.

—Бусы артык булмасмы,—диде Рита, кыенсыныбрак.

—Бәй, өй юунын йоласы шул инде, дускаем, шуна да өмә дип атыйлар бит аны.

Ул арада еш-еш танау тартып Ләлә белән Рөстәм дә кереп җитте. Алар алдына Зөбәрҗәт мул гына итеп тәм-том, җиләк-җимеш, нигъмәтләрен куйды.

—Моратка да әйтмибезме?—диде Рита кыяр-кыймас кына,—бүген әбит әзерләп торып булмады, ачыккандыр инде.

Зөбәрҗәт Ләләне әтисе артыннан йөгертте. Гер күтәрә-күтәрә тирләп-кызарып чыккан Морат килеп керде:

—Өйне юганда иң элек сабынлы су белән чылатып чыгарга, аннары гына юкә югыч белән ышкырга, бигрәк тә вак кына тимер сетка белән ышкысаң, ул ап-ак була инде,—дип акыл өйрәтә башлады Таза Мортаза.—Ну болай ничего булган бу, әйдәгез. кызлар, сезнең исәнлеккә,—ул ярты стакан вино салып эчте дә, аш соса башлады.

Чолан ишеге шыгырдаган тавыш ишетелде. Өйгә Гүзәл килеп керде.

—Оһо-һо, миннән башка гына кунак булып утыралар болар,—диде, ул килеп керү белән. —Иртә килгән—урын өчен, соңга калган—тамак өчен, бәхетем бар минем тамактан, кая, сал әле, подрушка,—диде ул Зөбәрҗәткә тәккәллефсез генә. Гүзәл шактый нык исерек иде.

—Мин киләлмәдем инде, кичә син кунарга килерсең, бәлки, дип күрше авыл марые Шумадал карттан бер шешә көмешкә алып кайткан идем,—дип исерек хатын сүзен дәвам итте.—Градусы бармы икән, дип тәмләп караган идем, ни инде, «башланган эш—беткән эш» ди, төбенә төшкәнмен дә куйганмын. Иртән чак эшкә бардым. Шамил сукранып калды, сукранса, балаларын үзе ашатсын, базда бәрәңге бар, мин дә эштә, ул да, минем эш авыррак әле, мин—сыер савучы, ул малчы гына. Чагыштырып булмый. Малчы сәнәк белән эшли ул, көрәк белән, ә без, без савучылар—менә шушы яргаланып беткән мескен бармакларым белән күпме сыер имчәген юам, күпме саву аппаратларын, чиләк, фләкләрне, у-у-у... сызлыйлар төнлә,—ул сүгенеп җибәрде.

Морат аңа: «Эшләмә соң, өйдә ят»,—дип дәшүе булды, Гүзәл котырып ябышты:

—Дәшмә, мокыт, Таза-Мортаза, центнер ярым гәүдәң белән чепи генә бер хатынынның муенына менеп атлангансың, оятсыз,—дип кызып китте.

—Чү, Гүзәл, чү, алай димә,—дип Рита уңайсызланып аны туктатырга тырышты .

—Ә син, тик тор, җебегән, җыбыткы, шул бугаеңны бәбәй урынына көйлисең, сабанга җигәрлек гәүдәсе белән, фермага җибәр әнә, минем ир янына, тизәк түксен, транспортерлар ватык хәзер, җигәргә кирәк шулар урынына үзен. Таза Мортаза кечерәеп калды, мыштым гына торып: «Тиле белән тапма да, өләшмә дә»,—дип үзалдына мыгырданып сызу ягын карады. Гүзәл Зөбәрҗәткә күчте:

—Менә син, дускаем, чибәрсең, гүзәлсең, байсың, ә мин менә—кем. Тирес исе килеп торган савучы, ә бит кыз чакта мин синнән чибәрлеккә калышмый идем. Чибәр булмасам, син дип авыз суын корыткан, синең арттан чапкан Шамил, син тәртәләреңне боргач, миңа өйләнмәс иде. Ләкин нәрсә бирде ул миңа? Итәк тутырып бала ясады. Чыгып китик шушы каһәр суккан авылдан, шәһәргә күчик, киткәннәр берсе дә кайтмый әле, дидем, тыңламады. «Туган нигез, туган нигез», диган булды. Нәрсә калды туган нигездән, чуртым. Җимерелеп барган өй, хәерчелек, колхоз ел ярым акча түләми эшләгәнгә. Анда-санда азрак онын-фуражын, итен биргәлиләр инде. Ә бит аңа гына яшәп буламыни? Балаларга кәнфит тә, печенье дә кирәк. Менә син эчкән кебек яхшы вино да эчәсе килә. Кая вино-аракысын да эчә алмыйбыз. Шумадалның сасы самогоны—безнең иш. Кем гаепле?—Ир гаепле! Чыгып китик, дидем мин аңа, китик дидем, ух, хәсис, йөзе кара, катмый да, пенсиясен алыр идем, ичмасам. Теге чакта кичүдә бер көтү балалары белән Такинә Рита белән мине көймәдән куып төшермәсә, без дә Уфага барып документларны биреп, шәһәрдә урнашкан булыр идек. Синең кебек тәтәй киенеп кырт-кырт басып авылга кунакка гына кайткан булыр идек.

Зөбәрҗәт исерек хатынның ачы хакыйкатен башына сугып мәңгерәүләткән кеше кебек тынлап утырды. Бигрәк тә Гүзәлнең Шамилгә әйткән каты сүзләре рәнҗетте аны.

—Гүзәл, бу хәлне бит эчеп кенә җиңеләйтеп булмый, башка юл табарга кирәк,—диде ул борчылу белән.

—Нинди юл, мина яңадан туып, яңадан кияүгә чыгарга кушасыңмы, алайса, алышыйк ирләрне, бир миңа миллионерыңны, ал әнә Шамилеңне үзеңә. Ир гаепле, ир.

Ул арада йортка, Гүзәлне эзләп, Шамил килеп керде. Керде дә, кыенсынып ишек төбендә туктап калды.

Шул ук Шамил дә, түгел дә кебек иде. Буйга да кечерәеп калган кебегрәк, ябык, күз кырыйларында җыерчыклар күренә, күзләре моңсу, ниндидер бер һәлакәтчә дучар ителгәнлек сизелә, киемнәре тузып, керләнеп беткән, оегы тишек. Кайчандыр дулкынланып, бөдрәләнеп, матур йөзен, ныклы муеннарын камап торган чәчләрендә иртә чал күренә. Зөбәрҗәтнең йөрәге кысылып куйды. Ул арада әтиләре артында җиде-сигез яшьлек малай һәм кыз да күренде. Әтиләренә охшап аларның да чәчләре кара, бөдрә иде. Исәнләшкәннән соң ул:

—Кайтыйк, Гүзәл, әйдә, ял ит, йоклап ал, кичке савымга барасы бар бит,—диде.

—Һа, килденме, әйдә уз, утыр, менә минем подружка кайткан, хәер, сиңа күчтәнәч калмаган инде,—Гүзәл, буш бутылканы алып стаканына түнкәреп карады.—Бәлки тагын табарсың?

—Юк, башка юк, Гүзәл, син кайт, ял ит, чыннан да сиңа эшкә бит,—диде Зөбәрҗәт.

Балалары да: «Әни, әйдә инде кайтыйк, кайтыйк инде, әнием»,—дип, килеп аны тарткалый башладылар. Гүзәл авыр гына кузгалып: «Күз нурларым»,—дип балаларын җилкәләреннән кочып ишеккә юнәлде. Чыгып озатып калганда Шамил кыенсынып:

—Гафу ит инде, Зөбәрҗәт, гел эчми ул эчүен, ләкин ычкынса, шулай кеше көлдереп йөри инде,—диде.

Бик авыр тәэсир калдырды бу очрашу. Әйе, Шамил—аның үсмер чактагы иң беренче бөреләнеп килгән хисләрен уятучы иде. Мәхәббәт булдымы икән ул, әллә тәүге тыелгысыз талпыну, ашкыну, дөньяга үзеңнең кеше буларак бар икәненне, яшәргә, тормыш дәвам иттерергә бирелгәнеңне аңлау идеме?

* * *

Зөбәрҗәтнең Радмирга булган нәфрәт катыш тартылуы өйләнешү белән битарафлыкка әйләнде. Радмир исә аны шашып яратты. Күпне күргән, күп язмышларны үз кулында уйнаталган Радмирның үзе өчен барысын да эшләргә әзер торганын Зөбәрҗәт белә иде. Хәтта кайчакта куркып та куя. Ул аның баш түбәсеннән алып аяк бармакларына кадәр үбә, иркәли иде. Бүлмәгә килеп керү белән ул әллә нинди исләр арасыннан хатынының исен танып ала. Бүлмәдә Зөбәрҗәт булганмы-юкмы икәнен шунда ук әйтала иде.

—Син эт кебек,—дия иде ана шаяртып Зөбәрҗәт.

—Әйе, мин эт, мин бульдог, түгел, мин бүр-р-р-е,—дия иде ире аңа.

Ләкин бер нәрсә белән җәфаланды Радмир. Ул үлә язып Зөбәрҗәтне көнли иде. Бөтен кешедән дә, хәтта Леоннан да. Ә бит Леон иренең иң ышанычлы кешеләренең берсе иде. Ләкин жанвар сизгерлегенә ия Радмир Леонның Зөбәрҗәткә ниндидер аерым бер мөнәсәбәте барлыгын, гәрчә берниндн сәбәп бирмәсә дә, күнеленең иң нечкә бер тоемлавы белән тоемлый.

Хәйләкәр яһүд Радмирның үзенә бик ышанып җитмәгәнлеген тоя. Зөбәрҗәткә теге вакытта сүз кушарга тырышканын, моның өчен үз башына бер чиләк пычрак су эләккәнен, билгеле, ул онытмый иде. Күнеленең иң төпкеленә бу хатыннан үч алу, аны түбәнсетү теләге кереп оялаган иде.

Вакытында Мәскәү университетының хокук-икътисад факультетын тәмамлаган егет туган шәһәренә эшкә кайту белән түләүле теш дәвалау

кабинетын тотучы бай атасы аны башкаланың иң шөһрәтле, иң ышанычлы дип йөртелгән банкына эшкә урнаштырды. Радмир шушы банк аша эш йөртә иде. Шунда якынаеп киттеләр алар. Искиткеч елгыр, зирәк акыл, табигый хәйләкәрлек, алдан күрә белү тойгысы Леонга үз вакытында Радмирның капиталын саклап калырга ярдәм итте.

Банк «шартлау» алдыннан гына Радмир исәп-хисап счетларын икенче банкка күчерергә өлгерде. Леон Радмир компаниясенә эшкә чакыртылып, тиз арада аның иң ышанычлы кешеләренең берсенә әйләнде.

Өйләнешеп бай тормышта яшәү Зөбәрҗәткә башта мавыктыргыч тоелды, институтның соңгы курсларында аның үз машинасы, кесә телефоны, сумкасында кыйммәтле косметика, кирәк кадәр акча, бизәнү-төзәнү әйберләре бар иде.

Әледән-әле эшлекле очрашуларда—үзләрендә үткәндә—игътибарлы, нәзәкатьле, кунакчыл, чибәр хуҗабикә була белүе, иң дәрәҗәле кешеләр белән аралаша алу сәләте, кунакка барсалар—бик мөлаем, ихтирамлы булуы һәм зәвыклы итеп киенүе Радмир тормышына нур, бизнестагы абруена куәт өстәде.

Еллар үтә торды, ләкин бу алтын читлек эчендәге тормыш иреккә талпынган Караидел карлыгачы кебек табигать баласын чын-чыннан интектерә, газаплый башлады. Үзенең күләгәсе кебек, кая барса, шунда бер тотам калмый аны саклап йөрергә беркетелгән Жанага бер бокал коктейль өчен күңел юатып гәпләшеп утыра торган иптәш кызларын да куркытып, биздереп бетерде.

Зөбәрҗәт өч катлы зиннәтле сараенда, күл кадәр бассейнда кресолардагы йомшак уенчыклары һәм аквариумдагы балыкларын һәм сүзсез-нисез күләгә кебек кенә жыештырып, әзерләп китүче хезмәтчеләрен исәпкә алмаганда, берүзе калды. Кичекмәстән аларга бала кирәк иде, ә ул—юк. Нигә юк, аны үзләре түгел, табиблар да әйтә алмыйлар.

Аралар салкыная төште. Арага киеренкелек кереп канат җәйде.

* * *

Зөбәрҗәтне иртәнге бишенче яртыда тәрәзә шакыган тавыш уятты. Тәрәзә артында бригадир Ярулла абый тора иде.

—Зөбәрҗәт сенлем, ярдәм ит. Кичә савымчыларга азрак аванс кебегрәк бер нәрсә биреп ташлаган идек, бүген ярты бригада исереп, сыер саварга кеше юк. Син бит җәй көннәрен савымчы булып эшли идең, онытмагансыңдыр бит, зинһар, үтермә,—диде агай ялварып.

Зөбәрҗәт: «Абый, киенеп кенә алам»,—дип тиз генә өйгә кереп китте. Ашыгып-ашыгып сумкаларын актара башлады. Бик кулай булмаса да, ярар тагын , дип фирменный джинсы, кыска җиңле ак футболка киде, чоланнан нәнәсеннән калган тирән галушны эләктерде, ул арада өч-дүрт савымчы, дүрт-биш мал караучы төягән «Беларусь» килеп тә туктады, Зөбәрҗәт трактор арбасына менеп кунаклады.

—Әйдүк, әйдүк, шәһәр кунагы, яшь чакларыңны искә төшереп бераз тирес исе иснәп кайт әле безнең белән,—диештеләр хатыннар көлешеп.

Арба читендәрәк утырган Шәмсия генә бер сүз дә дәшмәде, бүтән вакытта шөлтерәп торган бу апаның сүзсезлеге аны бераз гаҗәпләндерде.

—Исәнмесез, Шәмсия апа, танымадыңмыни мине, мин бу, Зөбәрҗәт,—диюгә, шундук Вафира атлы савымчы:—Куй, дәшмә, пошаманда ул, туганым, йөрәк эше анда, йөрәк эше, диде.

Шундук икенчесе эләктереп алды.

—Нинди йөрәк эше булсын? дип аты юлы белән сүгенеп тә җибәрде.

Вафира апа:—Куй, Әсма, ир бирмәк җан бирмәк—шаяртма алай, диде, үзе иелеп Зөбәрҗәтнең колагына:

—Аның ире Нәзир күрше авылдагы мари хатыны Памачкага ияләшкән, менә шуңа пошына ул бүген. Кунарга кайтмаган.—Барысы да Шәмсиянең кайгысын уртаклашкан шикелле тынып калдылар. Малчылар арасында Шамил дә бар иде. Ул Зөбәрҗәткә уңайлырак булсын дип, трактор

арбасының почмагында яткан чиләкне әйләндереп утырырга урын хәзерләде.

Трактор чокыр-чакырлы урман юлы белән авылдан ике чакрым ераклыктагы җәйләүгә юнәлде.

Яшь чакта өйрәнгән һөнәр онытылмаган икән, Зөбәрҗәт Гүзәлнең кара халатын киеп алды да, җиңнәрен сызганып, шланглардан су агызып, Гүзәл төркемендәге сыерларның җиленнәрен юды. Аннары сыер имчәкләрен сөртеп саву аппаратларын тоташтырды. Трубкалар буйлап шаулап сөт китте.

Шамил, Гүзәл өчен үзен гаепле хис итебрәк, Зөбәрҗәткә булышырга тырышты. Эш бетүгә, моңарчы, шау-гөр килеп эшләгән җирдә кинәт кенә тынлык урнашты. Ферма янына Шәмсиянең ире Нәзир килеп маташа иде. Вафира, иелә биреп, чиләк юып торган Шәмсиягә:

—Әнә, азгын айгырың кайтып килә,—диде.

Нәзир, гаепле кыяфәттә, асты юеш бала кебек, хатыны янына килеп туктады. Сакал-мыегы җиткән, күзләре эчкә баткан, киемнәре тәпәрләнеп беткән иде. Шәмсия:

—Айгырмыни ул, алаша, адәм актыгы, алаша да түгел, кәҗә тәкәсе, эзең булмасын монда, тай шул Памачыңа, өйгә аяк бастырасым, кочагыма кертәсем юк син хәсисне моннан соң,—дип тезеп тә китте.

—Шәмсия, Шәмсия, кызмале, ни бит, эчкән баштан, адашканмын... берни юк, берни юк,—дию булды тегесенең, хатын зәһәрләнеп иренең өстенә үк ташланды:

—Өзеп алам бит мин синең теге нәмәстәкәеңне, миңа булмагач, бүтәннәргә дә булмасын, азгын тәре!

—Чү, чү, кеше көлдермә, Шумадал бабайларда куныл калганмын, көмешкәсе аяктан еккан, әллә тавык тизәге кушып эшләгән, тезләрнең хәле беткән дә киткән,—дип артка чигенә башлады.

Шәмсия аның саен:

—Җирбит, балаларың җитеп беткән, минем баштан көләсең, кайсы җирем шул Памачтан ким минем, тотсаң билем, үпсәң битем янып тора, син хәсискә әрәм генә булдым, кемгә ярамаслык җирем бар,—ул, үзен-үзе җәлләп, буылып-буылып еларга керешге.

—Җитәр, Шәмсия, җитәр, синең нәрсә эшләп бирәр җирең Памачныкыннан ким булсын, артыграк та әле...—Ул тотлыгып калды.

Шәмсия, елаган җиреннән туктап, күзләрен шар ачып иренә карады.

—Чынлап, чынлап, мин бит исәрлек белән, аларныкы аркылы дигәнгә, кызыксынып кына... синнән дә шәп хатын юк икән...—Ул бөтенләй буталып бетте.

Халык моннан соң ни буласын сагаеп көтте, тынлык урнашты. Ләкин, Ходаның хикмәте, халык көткәннең нәкъ киресе килеп чыкты.

Шәмсия кинәт иренең күкрәгенә капланып: «Чынмы, шулаймы? Мин шәбрәкме, беркемгә дә бирмим мин сине, ташлап китмисеңме, мине генә яратасыңмы?»—дип такмакларга керешге.

—Тфү,—диде Вафира,—Ир белән хатын—уч белән алтын,—дип юкка гына әйтмәгәннәр икән.

Халык бу мәзәкнең ахырын көтмичә, көлә-көлә таралышты.

Гүзәл бер атна буе бертуктаусыз эчте. Үгетләп тә, тиргәп тә, ялынып та караган иренең:

—Балаларны уйла, аларны кызган, ичмасам,—дигән сүзенә, ул:

—Все, бетте, бүген генә эчәм тә, иртәгәдән ташлыйм, билләһи, валлаһи,—дип җавап бирә дә, Шамил эшкә китү белән тагыннан мыштым гына күтәрелеп эзләнә башлый. Өйдә бер грамм да калмаганын белсә дә, ышанмыйча, шкаф, өстәл тартмаларын, караңгы почмакларны карый, чоланда тезелешеп торган буш шешәләрне түңкәреп чынаяк төбенә тамчылап җыярга маташа, болай да эш чыкмагач, өйгә кереп кичә үзе исергәч кулыннан ире тартып алган шешә төбендә азрак калган сәмәйнең булырга тиешлеген томанлы гына хәтерләп, тагын да эзләнә башлый. Инде өчәрдүртәр тапкыр карап чыкса да, янә өйне тентергә керешә, ниһаять, мич эченә кулын тыгып кирпеч артыннан кичәге шешәне тартып чыгара.

Ниндидер бик әһәмиятле нәрсәсен тапкан, күп тапкырлар җәтмә салып та буш чыкканнан соң, ниһаять, алтын балык эләктергәндәй эчке олы шатлык белән күрше авылдагы чирмеш Шумадалның болганчык сасы сәмәен кыры китек чәшкегә салып, калтырана-калтырана эчеп җибәрә.

—Ух,—менә эзләгән, бөтен җаны, тәне таптырган кадерле эчемлек бугазы буйлап аска төшә, менә ашказанына җылы рәхәт акрын гына гәүдәсенә тарала, шуып—дулкын булып баш миенә килеп бәрелә, күзләре ачылып, айнып киткән кебек була, рәхәт тибрәлдереп җибәрә.

...Гүзәл берни белми, сизми генә изрәп йоклап яткан балалары янына килде. Аталары аларны Гүзәл исерек чакта да яхшылап карый, өс-башларын юа, тамакларына ашатырга тырыша, тәрбияле иде. Алар әйтерсең лә ачылырга бөреләнгән ике чәчкәне хәтерләтәләр. Кап-кара бөдрә чәчләрен бер-берсенең башына терәгәннәр, йөзләре алсуланган, кызчыгы уң янак астына кулын куйган, ирен читеннән аз гына селәгәе агып төшкән, улы нәкъ атасы—каракучкыл тәнле, әле кечкенә булса да, гәүдә төзелеше, ныклыгы, хәтта йодрыкларында да атасы чалымнары бар аның. Бер аягы юрган астыннан чыккан...

Гүзәлне кинәт кенә балаларын җәлләү, кызгану хисе биләп алды, ул акрын гына, уятмаска тырышып юрганын әйбәтләп ябып куйды, аннары өстәл артына килеп утырды да, ике кулы белән башын тотып тавыш чыгармаска тырышып исерек үксү белән елый башлады. Үксеп туктаганнан соң тагын: «Бүген генә эчәм тә, иртәгә туктыйм»,—дип чормадан какларга эленгән соңгы казны алып пакетка тыкты, Шумадал картның самогонына китте.

Зөбәрҗәт фермадан кайтып юынып, өстен алыштырып бераз хәл алгач, көтмәгәндә Шамил килеп керде. Ул бик пошаманга төшкән, йөзе борчулы иде.

—Нәрсә булды, әллә бер-бер күңелсезлекме?

—Гүзәл сездә юкмы, беркайдан да табалмадым, чыгып киткән, бүген көн буе өйдә булмаган, балалар караусыз, сыер савылмаган, белмим инде, белмим, нәрсә эшләргә бу хатын белән, ничек акылга утыртырга моны, әйткәнне дә аңламый, сугып булмый бит инде аңа, мал түгел... Шул эчә-эчә бавыр, бөерен дә бетерде, коса, дәваланырга кирәк бит аңа.—Ул утыргычка утырып башын ике куллары белән тотты.—Балалар җәл...

Бу әзмәвердәй, типсә—тимер өзәрдәй ирнең бу каһәр суккан аракы алдында шулай көчсез, гаҗиз булып утыруы, иңсәләренең кинәт салынып төшүе, ике бала атасының нарасыйлары өчен үрсәләнүе Зөбәрҗәтне әрнетеп җибәрде.

Аның Шамил янына киләсе, дулкын-дулкын кара чәчләрен сыйпыйсы, кайгысын җиңеләйтәсе, юатасы килде. Тик ул хисләрен кулга алды һәм бик эшлекле кыяфәттә:

—Шамил, әйдә, дәваланырга салыйк без аны, бөтенләй беткән кеше түгел бит әле ул, күпләр хәзер шулай котыла бу заман чиреннән, ул гына беренчесе, ул гына соңгысы түгел, бетеренмә болай,—дип әйтеп куйды.

—Каян алыйм мин шулкадәр акчаны, Зөбәрҗәт, аның өчен бит бер-ике генә йөз акча китми.

—Кайгырма, мин бирәм сиңа,—хатын, сумкасын ачып, өстәлгә акча салды.

—Юк, мин алмыйм, бу кадәр акчаны тиз генә түләп бетерәлмим. Миңа моның өчен күпме эшләргә кирәк, сыерны сатсам гына инде,—диде ир бик тә кыенсынып.

—Кайгырма, баегач түләрсең, Гүзәл минем дә сыйныфташ кызым бит, аны аякка бастырыр өчен мин дә үз бурычымны үтәргә телим, ә сыерыңны сатма, балалар ризыгы ул. Иртәгә үк «ай-ваена» карамыйча, Уфага алып кит үзен, мин монда дөньяңны, балаларыңны карап торырмын,—диде.

* * *

Зөбәрҗәтнең авылга кайтуына бер ай булып килә иде инде. Гаҗәп хәл шул: бер ай эчендә ул Радмирны бер-ике тапкыр гына исенә төшерде. Әйтерсең лә беркайчан да авылыннан да чыгып китмәгән, бай хатыны

булып зиннәтле йортларда да яшәмәгән, беркайчан да аның тормышында шау-шулы приемнар, кыйммәтле машиналар, Радмир да, Леон белән Жанага да булмаган. Ул үзен бераз читлектә яшәп, ниһаять, үз иркенгә чыгарылган кош кебек хис итте. Гүзәлне Уфага хастаханәгә салганнан соң, ул Гүзәл төркемендәге сыерларны сауды, балаларын ашатты. Карады, юатырга тырышты, юыштырды, җыештырды.

* * *

Шамил белән Зөбәрҗәт эш бетереп фермадан чыкканда инде савымчылар да, терлекчеләр дә җәяүләп кузгалганнар, ватык «Беларусь»ны төзәткәнче атлый торалар иде. Шәмсия үзенең Нәзиреннән тотам калмый, артыннан терек-терек бара, Вафира белән Нурия алдан ук кузгалганнар.

Кич җылы, кояш баеган, ләкин әле караңгы төшеп өлгермәгән. Йөзне рәхәт иркәләп Идел җиле исә. Мәңге кипмәгән урман юлында трактор ясаган канау чокырындагы пычракка батмас өчен Зөбәрҗәт Шамилгә тотынды. Шамилнең беләге буйлап кузгалган кайнар дулкын күкрәк читләгенә бәрелде. Йокысыз төннәр, яшьлек мәхәббәте кичерергә мәҗбүр иткән кадерле Зөбәрҗәте янында гына, ул аның беләгенең җылысын тоя, аның йөрәк тибеше дулкын-дулкын булып беләгә аша үз йөрәгенең тибешенә килеп кушыла...

Урман юлы караңгы. Арттан «Беларусь» тракторы тавышы ишетелде, алар бер сүз дә әйтмичә икесе берьюлы унга каерылдылар, аяклар үзләреннән-үзләре агачлар арасына тартты. Аларның тракторга утырасы килми иде. Шулай бара торгач, юлдан хәтсез генә читтә яткан Иске Идел янына килеп җиткәннәрен сизми дә калдылар. Яр буе комлыгына баскач, Зөбәрҗәт аяк киемнәрен салды, кояш җылысын үзендә саклаган ком аяк табаннарын иркәләп тәненә йөгерде.

—Әйдә су коенабыз,—диде Зөбәрҗәт һәм җавап та көтмичә, чишенеп елгага кереп тә китте. Су җылы, яна сауган сөт кебек. Кайчандыр Караидел моннан аккан, ләкин ни өчендер юлын үзгәртеп, бер уйдык кына калдырып яңа юлдан киткән, монда тыныч, агым акрын, шуңа да су тыныч та, җылы да.

Ай нурында су коенган Зөбәрҗәтне Шамил таң калып күзәтеп утырды. Ул әкияттәге су кызы шикелле серле, матур иде.

Калкынып йөзгәндә аккош канаты кебек янып торган ак беләкләре суны кочып-кочып ала, мәрмәр шикелле ак, ялангач инсәләреннән терекөмеш кебек су йөгерек дулкыннарга коела, көчле матур аяклары ялт-йолт килеп уйнап ала. Алтын чәчләре чыланып, укмашып елан шикелле су өстендә бөтерелә.

Зөбәрҗәт яр буена чыкты, Шамил үзе дә сизмәстән аңа таба атлады, аяклары аны үзеннән-үзе бу ымсындыргыч зат янына алып баралар. Зөбәрҗәт, ялангач күкрәген каплый төшебрәк, калтыранган тавыш белән:

—Кит, Шамил, ул кадәр туры карама,—диде, ә күзләре аны үзенә чакыра иделәр. Агачлар арасыннан күтәрелгән тулы ай Зөбәрҗәтнең күзләренә тулды. Шамил көчле беләкләре белән акрын гына Зөбәрҗәтне кочып үзенә тартты. Ул карышусыз-нисез генә аңа сыенды. Иреннәр иренгә кушылды.

Җылы елга комы, Зөбәрҗәтнең ялангач тәнен рәхәт иркәләп, үз өстендә урын бирде. Аларның аяк очларында акрын гына шыбырдаган дулкыннар яшәешнең мәңгелеген исбатлап, бу тыелгысыз назның, бер-берсенә тартылуның, теләп кушылуның шаһиты булып акрын гына, инсаф белән генә, оялыбрак кына кабат-кабат, кабат-кабат, кабат-кабат ярга бәрделәр...

***

Зөбәрҗәтнең авылга кайтуына ай ярым вакыт үтеп китте. Ул үзен инде авылныкы итеп хис итә иде. Рита белән ара-тирә нәкъ авылча бер-берсенә йомышка-мазарга кергәлиләр, берсе тәмле әйбер пешерсә, бер-берсенә кертәләр, авыл гайбәтләрен сөйләшеп алалар.

«Таза Мортаза» һаман үҗәтләнеп-үҗәтләнеп гер күтәрә, үзе: «Мин Америка президенты булсаммы, мин Англия короле булсаммы...»—дип шапырына.

Каршыдагы күрше Габидин абзыйлар йорт күтәреп яталар иде. Моратның:

—Шулай эшлиләрмени аны, ниргәне тегеләй салалар, болай салмыйлар, мин булсаммы...—дигән сүзенә Зөбәрҗәт:

—Кеше өйрәткәнче, җил капканны рәтләп куй, адәм рәтле бик яса, юкә бау белән элдерәсең, хатын җилкәсен кимереп мускул үстереп ятасың шунда,—дип ычкындырды.

Морат көтелмәгән атакадан башта аптырап калды. Аннары бурлат кебек кызарды да, чәрелдәп җибәрде:

—Монда кайтып кеше хатыннарын бозып ничу акыл өйрәтергә, ирең бар өстеннән чит ирләрне аздырып йөрисең, синең Шамил белән пыш-пышыңны бөтен авыл сөйли, тай Уфаңа, минем хатынга якын киләсе булма, хәзер бозасың син аны, тагын икегезне бергә күрсәм,Ританы бәреп үтерәм, Уфага иреңә хәбәр итәм мин сине, сөйрәлчек. Мин синең ирең булсаммы...

Зөбәрҗәтне яшен суккан кебек булды.

Чыннан да авылда Шамил белән алар хакында гайбәт таралып өлгергән иде инде.

Гел бертөрле аккан авыл тормышын җанландырып җибәрер өчен, моннан да кызыклырак һәм серлерәк сенсация юк иде.

Имеш, Шамил Гүзәлне ташлый икән, имеш, Зөбәрҗәт иреннән качып кайтып киткән икән, имеш, икесе шәһәргәме, аннан да еракkaракмы китәргә җыеналар икән. «Мескен Шамил рәхәт күрмәде инде, унмады шул эчкече хатыныннан, аны аерып яңа дөнья корса да, гаепләрлек эш юк»,—диләр иде берәүләре, икенчеләре: «Өстерәлгеч, оятсыз, Зөбәрҗәтне әйтәм, ир җитмәгән кебек, Уфасын ташлап кайтып, менә дигән гаиләне боза, себерке»,—диләр иде.

* * *

Радмирның йокы бүлмәсендә соңлап кына телефон шалтырады. Ул яткан җиреннән иренеп кенә үрелеп трубкасын күтәрде.

—Сәлам, снайпер,—диде Натан Маркович Радмирга «Төгәл» дигән сүзгә икенче мәгънә салыбрак,—хәл-әхвәл ничек?

Алар күңел булсынга бераз гәп куертышкан арада, Радмирның миеннән яшен тизлегендә мең төрле уй үтеп китте: «Ни өчен шалтырата әле бу аңа төн уртасында? Хәл белешер өчен генә шалтыратмавы көн кебек ачык. Илтифат өчен генә шалтыратмас ул. Бераз анысын-монысын сөйләшкәннән соң, Натан карт бернинди кереш сүзсез-нисез кинәт кенә әйтеп салды:

—Радмир дус, шома егетеңне—Леонны дим, караштыргала бераз, хәтерлә, артыңны шәйлә...

Радмир бераз тынып торганнан соң:

—Аңламадым, хөрмәтле патриарх,—диде.

—Аңламасаң аңларсың, счетларын тикшер, егетең ике уен алып бара...

Киеренке тышлык урнашты. Бу инде бик җитди гаеп иде.

—Нигә мине кисәтергә булдыгыз?—дип сорамый кала алмады Радмир.

—Өйрәнгән яу сугышырга яхшы, без синең белән гадел уйныйбыз, бу молокосослар өскә калыкса—ә тизрәк өскә калкучан—дөнья хәлен белеп булмый. Яшьләр кеше өстенә кояш чыгармаска да мөмкиннәр. Ярар, мин—әйтәм, калганы—синең эш. Шулай диде дә карт яһүд, сүзен тәмам кылды.

Радмир өстәл лампасын кабызып торып ук утырды. Күңеленә мең төрле шик төште. Кайда, кайчан саксызлык җибәрде ул? Чынмы бу? Әллә Натан карт, Радмирның бизнесыннан көнләшеп, оста, зирәк, эштә алыштыргысыз булганы өчен Леонның башын бетерергә телиме?

Дөрес, Радмир элек тә Леонга бик үк ышанып бетми иде. Бик тә шома, бик тә үткер иде егет. Елгырлык, искитмәле оста гамәлләр кору ягыннан аңа җиткән кеше юк. Башкарган эшендә черки борын да төртерлек түгел. Шул ук вакытта сак Радмир Леонга, аңа гына түгел, бөтенләе белән Җанагага да

ышанып бетми иде.

Ул икенче көнне үк Леонны үз янына чакырып алды.

—Син, дускай, авылга барып минем хатынны алып кайт, ай ярым узып китте, сагындырды,—диде ул дусларча җилкәсенә кулын салып.

Ул авылга чыгып китү белән үк, хуҗа үзенең каналлары аша Леонның счетларын тикшерә башлады, компьютерына керде һәм... башын тотты. Кайсы гына банкта юк иде аның капиталы! Хәтта чит ил банкларында да!

—Падло,—дип сүгенде ул эченнән генә,—сатлыкҗан, бур.

Ул шундук Жанаганы чакыртты.

* * *

Леон барып кергәндә Зөбәрҗәт өйдә юк иде. Аны шундук койма аша Морат күреп алды.

—Өйдә юк, сыер сава,—диде ул герләрен җиргә төшереп. Леон аңламады:

—Нинди сыер?

—Нинди булсын? Иптәш кызын хастаханәгә салдылар, аның урынына ферма сыерларын сава.

Шуннан соң ул койма янына якын килеп үк:

—Мин аның ире булсаммы...—дип сүз дә башлады.

Зөбәрҗәт кайтканда Леон, күтәрмәгә утырып, «Мальборо» тарта-тарта, Морат белән көлешә-көлешә ни турындадыр гәпләшәләр иде.

Берничә минут сөйләшкәннән соң Леон, мыек астыннан мыскыллы елмаеп, Моратның күптәнге танышы кебек кулын кысып, Зөбәрҗәтсез генә кичүгә төшеп китте. Зөбәрҗәт исә бирәр атнадан кайтасын әйтеп торып калды.

* * *

Леон, Уфага кайту белән, түкми-чәчми Морат сөйләгән хәбәрләрне Радмирга җиткерде.

Радмир ачуыннан бурлат кебек кызарды, ул көнләшүеннән, үзендә «мөгез үсү» гарьлегеннән кая керергә белми ишекле-түрле йөренде. Леон чыгып киткәч:

—С-с-сука,—дип ысылдады,—өстерәлчек, себерке, үтерәм мин аны, үз кулым белән буам, ботарлыйм, изәм кәнтәйне!

Ул ярсуына чыдый алмыйча, яралы ерткыч кебек бәргәләнде. Ә Леон соң, Леон, ничекләр тәмләп, эчтән генә шатланып җиткерә аңа бу хәбәрләрне!?

«Падло»,—дип уйлады ул Леон турында,—«козгын, бөҗәк, җитмимени аңа Радмир түләгән акча, ул акчаны бүтәннәр төшләрендә дә күрми, ә ул аның артында урлаша, хәшәрәт!» Шундук ул Жанаганы чакырып кертте.

—Әзерлән, иртәгә авылга Зөбәрҗәтне алырга китәбез, ә бүген...—ул пышылдап кына Жанагага нииндидер боерык бирде.

Икенче көнне иртән Затон күперен чыккан җирдә, текә яр астыннан, металл өеменә әйләнгән машинасы эченнән, автоген белән кисеп, Леонның үле гәүдәсен тартып чыгардылар. Аның күзләре зур булып ачылган, аларда бу хәлгә ышанмау һәм тирән гаҗәпләнү катып калган иде.

* * *

Иртәдән бирле үзәкләрне өзә торган сәбәбе күренмәгән шомлы сагыш, чарасызлык болытлы көн кебек Зөбәрҗәтнең күнелен айкады. Ул үзенә урын таба алмый арлы-бирле йөренде, кулы бер эшкә дә бармады. Эчке бер сизенү белән котылгысыз афәтнең якынлашуын тойды, йөрәге янды, гаҗизлектән күзләренә яшь тулды.

Ул Караидел буена төшеп китте. Менә аның балалык еллары, үсмер чаклары, бөреләнеп яфрак ярган яшьлегенең шаһитләре—йозьяшәр көмеш өянкеләр. Алар Идел җиленә ялбыр чәчләрен тирбәтеп суга иелгәннәр. Әйтерсең алар тере җанлылар, йөрәклеләр. Алар Зөбәрҗәтне аңлыйлар. «Чит мин монда, ят мин хәзер бу кешеләргә, инде киселгән икмәк мин монда, ничек кенә үз булырга тырышсам да, минем инде бу җирләрдән

тамырларым аерылган. Жилгә коелган яфрак кебек кая, кемгә барып бәрелергә белмичә җаным өзгәләнә. Бәхет дигәне, сөю дигәне нинди бәя хакына анык булырга тиеш? Бик зур түгелме ул бәя, Рәшә, мираж гына түгелме? Зур хата эшләде ул. Радмир иркенә буйсынды. «Өйрәнермен, яратырмын»,—дип үзен юатса да, акылына үзе хуҗа булса да, тән хәтерен җиңә алмады. Үзен көчләп буйсындыру төне өчен ул Радмирны берничек тә гафу италмады.

Иң кайнар минутларда да бар булмышы, гәүдәсе, җаны тораташ булып ката да куя. Иренә моны белдермәскә тырышса да, Радмир сизми калмый, үзен гаепле итеп хис итә. Бер сүз белән әйткәндә, Радмир Зөбәрҗәтне хатын буларак ача да, уята да алмады.

Бүген Идел бигрәк тә тыныч, давыл алдыннан булганча тын иде. Хәтта балык та уйнамый, тирәнгә качкан. Яр буена дулкын ыргыткан йомычка, агач ботаклары, яфрак, үлән җыелган. Арырак, текә урында ара-тирә кубарылып, шыгыр-шыгыр елгага кызыл балчык коела.

Өстәрәк, кеше аягы басалмас җирдә—текә ярда кечкенә генә тишекләрдән яр карлыгачлары очып чыгалар да, эшлекле кыяфәттә ояларына җим ташыйлар иде. Идел үрендә урнашкан сусаклагыч күптән инде су җибәрмәгәнгә охшаган, кызыну урыны булган комлык шактый зурайган. Идел артка чиккән. «Яр!»,—дип уйлап алды Зөбәрҗәт,—кемгә дә яр кирәк, никадәр генә иркә, гүзәл булмасын—Иделгә таяну мөмкин түгел, оя корыр өчен, таяныч табар өчен яр кирәк. Кайда аның яры? Теге яктамы ул, бу яктамы?

Иске Идел буендагы мәхәббәт төне Зөбәрҗәтне дә, Шамилне дә янадан тудырган шикелле булды. Алар бер минут та бер-берсен уйламый, бер-берсен сагынмый, теләми торалмыйлар иде инде хәзер. Күпме еллар ир белән яшәп тә, аның ни-нәрсә икәнен аңламаган Зөбәрҗәт кинәт йокыдан уянгандай булды. Ул теге айлы кичне янадан исенә ала, һәр мизгелен барлый, күңеленнән тагын-тагын кичерә һәм шул ук вакытта курка-курка, үзе белән көрәшә-көрәшә моның кабатлануын тели иде. Һәм кабатландылар ул кичләр! Шамил балаларын карый, ашата, йоклата да, кеше аягы басылгач Зөбәрҗәтнең ишеген шакый.

Сөю һәм сөелү тулы минутлардан соң Зөбәрҗәт сөйгәненә сыена да, авыр уйларга бирелә. «Нәрсә бу? Нәрсә булып бетәчәк моның ахыры, тиздән терелеп Гүзәл хастаханәдән кайтачак, Шамилнең ике баласы өйләрендә үзләре генә йоклап ята, инде айдан артык вакыт үтте, димәк, тиздән ул да Уфасына китәргә тиеш булачак, теләсә-теләмәсә дә, Радмир аны каерып алып китәчәк, ул тагын шул ук курчак роленә керергә тиеш булачак: яхшы машина, затлы киемнәр, приемнар, кирәкле кунаклар, ә төннәрен—күзне йомып, үзенне-үзең мәҗбүр итеп Радмир иркенә буйсыну—бу уйлардан Зөбәрҗәтнең тәне чамырдап китә иде.

—Нәрсә булды, кадерлем?

—Куркам мин, Шамил, ничек бетәр моның ахыры? Алда бер яктылык та юк бит...

—Мин дә уйлыйм ул турыда. Беләсеңме, Гүзәл терелеп кайткач, нәрсә булса да уйларга кирәк. Синсез яши алмыйм инде мин. Икәүләшеп кайдадыр башны алып чыгып китәргә кирәк безгә.

Зөбәрҗәтнең йөрәге кысылып куйды: «Китәргә, китәргә, качарга кирәк еракларга!—Тик кая? Иренең озын кулы аны кайдан да табачак, иң соңгы чиктә башкисәрен—Җанаганы өстерәчәк ул аңа».

Көннәр үтә торды. Бәлки ире бөтенләй килмәс әле? Шундый кечкенә өмет белән ул күңелен юата иде.

Шактый вакыттан соң Зөбәрҗәт үзендә үзгәреш сизде. Күкрәкләре тулышып, авыртып киткән кебек булды, башы әйләнде, күңеле болганды. Аны баш әйләндергеч шатлык чолгап алды. Ул авырлы иде! Ниһаять, ниһаять, ничә еллар көтеп! Аның артыннан ук күңелен курку биләде. Нәрсә булыр моннан соң?

Бу төнне ашкынып, түземсезләнеп көтте Зөбәрҗәт Шамилне. Маңгаен тәрәзәгә терәп бик озак карап торды ул урамга. Караңгы пыялага җилләп-

җилләп янгыр килеп бәреләә, чиләктән койган шикелле коя, әйтерсең, яумый, болыт үзе җиргә ята кебек. Авыл салкыннан, юештән күшеккән зур җанвар шикелле сыртын бөгеп оеп утыра, этләр дә ояларына поскан, җан әсәре сиздермиләр. Кара көз кебек, караңгы һәм шомлы яңгыр иде бу. Инде берничә көн яуган яңгырдан сукмаклар җебегән, уйдык-уйдык күлләвекләр өстенә күбек калка, димәк, яңгыр тиз генә туктамаячак иде.

Ниһаять, барысы да тиздән, иртәгә үк хәл ителәчәк. Зөбәрҗәт икеләнеп тормаячак хәзер. Алар Шамил белән еракка-еракка, беркем дә табалмаган җиргә үз бәхетләрен эзләп чыгып китәчәкләр!

Бу караңгы төндә ерак бәхет йолдызы кебек үзенә чакырып торган Зөбәрҗәтнең тәрәзә утына итекләре белән шаптыр-шоптыр су ярып Шамил атлый. Менә ул ерак та түгел, якын гына—кул сузым ара гына алар арасы, җан тарткан, күнелен әйдәгән, Ходай тарафыннан анык итеп яратылган Зөбәрҗәте! Якын ул, бик якын, хәзер бер генә тыкрык үтәр дә, аны үз кочагына алыр. Иркәләр, сөяр. Тик якынмы соң ул? Янда гына булса да, атлап та, очып та чыгалмаслык упкын түгелме алар арасында? Иң якын кешеләре—ике бала язмышы, яман авыруга дучар булган Гүзәл язмышы ятмыймыни алар арасында? Кемгә кирәк алар аннан башка? Кая бара, кемгә барып сыена ала ул якын кешеләр Шамилсез? Авыр иде бу уйлар күнелгә. Ул үзен ике яр арасында калган ялгыз көймә итеп хис итте. Ар якта ниндидер машинаның көчле фаралары бу як ярны айкап алды.

—Сөенче,—дип каршы алды Зөбәрҗәт аны серле генә итеп.

—Ни булды, кадерлем,—дип, Шамил, кочаклаган килеш аның колак артындагы чәчләрен иреннәре белән иркәләде.

—Сөенче, Шамилкәем, сөенче, безнең балабыз булачак!

Кинәт тынлык урнашты, Шамил, арткарак каерылып Зөбәрҗәтнең күзләренә карады.

—Чынлапмы,—аның тавышы калтыранып китте.

—Чын, чын, без хәзер мәнге бергә, мин риза, иртәгә үк китик моннан, еракка, Себер ягына чыгып китик, беркем дә табалмас җиргә.

Авыр тынлык урнашты.

—Китәргә,—диде Шамил акрын гына.—Ә балалар? Алар кемгә кала, исерек Гүзәлгәме? Терелеп кайткан очракта да, ул аларны миңа бирмәячәк, ә мин аңа ышанып аларны калдырып китәлэммe?

Өйдә кабер тынлыгы урнашты, тәрәзәгә бәрелгән янгыр тавышы гына: «Шулай, шулай, шулай»,—дип шаулый иде.

Кинәт ишек ачылып китте. Ишектә Радмир, аның артында Җанага күренде. Шамилне күрү белән Радмирның күзләрендә хәтәр вакытта гына була торган зәһәр яшен ялтырап үтте.

—Йә, бичә, озакладың, көттерден, син бит миннән бер ай гына вакыт сораган идең, әллә бик эшен тыгыз булдымы?—диде ул мыскыл катыш нәфрәт белән. Шамил чыгып китәргә теләде, ләкин Радмир аның алдына төште.

—Мобиль телефон эшләмәсә дә, сезнең турыда хәбәрләр миңа килеп житте, ну, ничек минем хатын? Шәпме?—Ул яшен тизлегендә Шамилне үзенә тартып алды, маңгае белән маңгаена бәреп җибәрде, Шамил очып өстәл артына барып төште.

—Кагылма аңа, тимә, синең хакың юк,—дип кычкырып җибәрде Зөбәрҗәт һәм тагын Шамил өстенә килгән Радмирның юлына аркылы төште.

—Яратмыйм мин сине, китәм мин синнән, мин сине беркайчан да яратмадым, калдыр безне, тимә аңа, мин аны яратам,—дип ачыргаланып кычкырып җибәрде Зөбәрҗәт.

—К-к-кәнтәй,—диде аңа Радмир тотлыгып һәм ысылдап,—өстерәлчек, бер уч акчага сатып алдым бит мин с-с-сине, колагында җемелдәгән бриллианттан алып трусигына кадәр минеке. Кайда китәсең син, крышка сиңа, өйдә бикләп, чылбырлап, тышаулап яшәтәчәкмен мин с-с-сине, себерке, ә төннәрен, те-те-теләсәм кочагыма алам, теләсәм бикләп куям,

чөнки син—ми-ми-минеке! Ханбикә буласың килмәгәч—кәнизәк булырсың —кол!—диде.

Зөбәрҗәт Радмирның беркайчан да бу кадәр чалшайган йөзен, зәһәр күзләрен, ерткычка охшаган чыраен күргәне юк иде.

Радмир артына борылып карамыйча гына, Җанагага ымлады: «Бетер үзен, ләкин эзен калдырма, ә бу өстерәлчекне богаулап алып чык, мин теге як ярда машинада көтәм».

Ул борылып чыгып китте. Җанага ушсыз яткан Шамилне җилкәсеннән өстерәп ишеккә юнәлде. Зөбәрҗәт аның артыннан ташланды. Җанага чыннан да кул богавы чыгарып Зөбәрҗәтнең бер кулына кидерде дә, икенчесен ятак тимеренә ябыштырып куйды.

Зөбәрҗәт ачыргаланып кычкырды, кулын тартып, кыршаудан чыгарырга тырышты, ятакны, ишек янына кадәр өстерәп алып килде, ишекне аягы белән тибеп ачты, тагын кычкырды, яңгыр тавышы, еш-еш яшен ялтлап күк күкрәве, төн караңгылыгы аның тавышын үзенә йотты.

Җанага кергәндә Зөбәрҗәт тимер ятак башын салдырып маташа иде.

—Ерткыч, җибәр мине, хуҗаның табанын ялаучы эт, кагылма миңа,—дип бар көченә тарткалаша башлады Зөбәрҗәт.—Кайда куйдың Шамилне, нәрсә эшләттең аны, мин барысын да әйтәчәкмен, көчләп алып кайтсагыз да качачакмын мин сездән, төрмә көтә сезне, төрмә.

Җанага, артка каерып, аның кулларына богау кидерде, беләгеннән тотып караңгыга, яңгыр астына алып чыгып китте.

Яр өстеннән алар тая-тая, егыла-егыла төшеп су буена килделәр. Көймәләр чылбыр белән ярдагы казыкларга бәйләнгән иде. Җанага кесәсеннән пистолет чыгарып йозакка төбәп атып җибәрде, чылбыр чылтырап җиргә коелды, Зөбәрҗәтне төртеп көймәгә кертте. Үзе ишкәкләргә ябышты. Зөбәрҗәт күз кырые белән Җанаганың гомерендә дә ишкәк тотканы булмаганын чамалады.

Җанага ишәргә азапланды, ләкин ни өчендер көймә аны тыңламый, атна буе бертуктаусыз яуган яңгыр, аның өстенә сусаклагыч суын җибәрү аркасында Караидел язгы ташу вакытындагы шикелле ташкан, ярларына тулышып бөтерелеп-бөтерелеп ага иде.

Җилкәсенә тимер белән сукканнан соң Җанага Шамилне текә ярдан суга ыргытты. Көчле агым аны яр буйлап бөтерә-бөтерә агызып алып китте. Бәхеткә каршы, салкын су егетне ушына китерде. Шактый ара агып барганнан соң гына ул көч-хәл белән ярга чыга алды.

Каршы якта көчле прожекторларның су өстен айкаганын, Идел аша дулкыннар белән көрәшә-көрәшә көймә чыгып барганын күрде Шамил. Ул көймәдә Зөбәрҗәт иде. Шамил көч-хәл белән аягына басты, егыла-егыла кечү янындагы ярга үрмәләде, өйгә аның ау мылтыгы бар. Беренче уе шул булды аның, тик яңгырдан сабын кебек майланып торган кызыл балчыклы яр аны үз өстеннән инде менеп життем, инде менеп життем дигәндә генә тагын-тагын аска шудырып төшерде.

Агым көчле булса да, үгез кебек Җанага, ниһаять, ишү җаена төшеп, көймәне каршы якка—Идел уртасына куа. Теге як ярдан машина фаралары көймәгә коридор ачкан төсле ут бөрки иделәр.

«Шамилне үтерделәр»,—дигән ачы уй Зөбәрҗәтнең миен утлы камчы кебек яра. Бу канәчкеч бәндәләрнең аны исән калдырмаячакларын аңлый иде ул.

Бар дөньяны, бөтен кешене сатып алып булуына инанган Радмир һәм аның ышанычлы эте Җанага җиңелергә өйрәнмәгәннәр. Алар өчен дөнья малы гына түгел, кеше язмышлары да бер тиенгә дә тормый, аларга каршы килүчеләр—чүп, төкерек, бетәргә, юкка чыгарга тиешләр. Зөбәрҗәтнең кыска гына вакыт эчендә күз алдыннан бала, үсмер чаклары чагылып үтте.

Менә алар жылы комны казып үзләре сыярлык кына күлчекләр эшлиләр, аннары шул күлчекне елгачык казып Идел белән тоташтыралар, Идел суы чокырга кереп тулу белән елгачыкны ком белән күмәләр. Күлчектәге су кояш нурлары астында бик тиз җылына, алар җылы суга кереп ваннада

яткан кебек рәхәтләнеп, кинәнеп бик озак яталар, аннары эшләпәләре белән Идел буеннан вак балык сөзәләр. Балыклар су читенә үк килеп аяк бармакларын тәмләп карыйлар, аннары пыр итеп качалар да бетәләр.

Менә үсә төшкәч, алар иске Идел буендагы камышлык төпләреннән кыр үрдәге ояларын эзлиләр, су җылы, тик камыш кына аякларны пычак кебек кисеп-кисеп ала. «Кыр үрдәге ояларын туздырырга ярамый, алар бәләкәй бәбкәләр чыгаралар, аларга тисәң, әнкәләре каргый, бәхетсез булырсыз»,—дип әйтә иде нәнәсе аңа. Ул ирексездән карынында яралган баласын уйлап куйды: «Үрдәк каргышлары төштеме икән миңа?»—дип уйлады ул әрнеп һәм күзләреннән аккан яшь яңгыр тамчылары белән катышып, яңаклары буйлап тәгәрәде.

Ә көймә бара да бара, акрын гына Идел уртасына якынлашып килә.

Ә күз алды тагын өмет тулы. Институтка кергән чаклары... «Чибәрләр» конкурсында катнашу, тормышында башланган бәхетсезлекләр—бай, күнелсез һәм мәгънәсез бушка үткән гомере. Ләкин барыбер язмыш аңа качып-посып булса да сөю һәм сөелү сәгатьләре бирде. Кыска гына, ләкин бар гомеренә торырлык бәхет бүләк итте. Шамил белән үткәргән көннәре моннан ары беркайчан да, беркем белән дә кабатланмас инде...

Көймә Караиделнең уртасына килеп җитте. Зөбәрҗәт торып басты, бер аягын көймәнең кырыена куйды.

—Нишлисең, тиле, утыр,—дип ырылдады Җанага.

—Әйдәле, җинелү белмәс, канэчкеч Җан, йөзеп карыйк, нинди батыр икән син, күрсәт осталыгыңны, ул сиңа коралсыз кешеләрнең җаннарын кыю түгел, көрәш минем Караиделем белән.—Шулай диде дә Зөбәрҗәт бар авырлыгын салып көймә кырыена басты. Көймә чайкалып китте.

Бу хәлне ярдан фаралар яктылыгында күзәтеп торган Радмир бөтен көченә машина сигналына басты. Ә икенче ярдан чигәсеннән кан аккан Шамил кычкыра иде: «Зөбәрҗәт, кирәкми, кирәкми, Зөбәрҗәт!» Ләкин яңгыр вә Идел шавы бу тавышларны үзенә йотты.

Көчле агым көймәне борып җибәрде. Зөбәрҗәт аягында басып торалмыйча, көймә кырыена гәүдәсе белән килеп төште. Җанага, ишкәкләрне ташлап, чытырдатып көймә утыргычына ябышты.

Ләкин Иделне инләп-буйлап йөзеп үскән Караидел кызы үз эшен белән иде. Икенче мизгелдә көймә инде әйләндереп капланган иде, куркудан чалшайган йөзле Җанаганы Идел дулкыннары бөтереп-бөтереп агызып алып китте.

Агым көчле иде. Куллары бәйләнгән Зөбәрҗәт бергә-бер Идел белән калды. Идел бар дөньяга, бөтен кешегә ачуланган, бөтен нәрсәне бөтереп алып китәргә, яшерергә, онытырырга теләгәндәй ярсу, усал иде бүген.

Зөбәрҗәт тончыга-тончыга су өстенә калыкты, күзләрен уң як ярдан төшкән галоген фаралары чагылдырды, яр буенда гаҗизлектән нишләргә белми арлы-бирле Радмир йөренә. Яр сөзәк тә, йөзеп чыгарга ара ерак, агым Зөбәрҗәтне тагын бөтереп алды. Су өстенә акчарлак канатлары шикелле алтын чәчләре калыкты, ул бар булмыш көчен җыеп сул як ярга ыргылды. Текә яр өстендә басып торган Шамилнең гәүдәсен ул яшен яктысында шәйләп алды. Ләкин... Әмма дә ләкин бу яр да бик текә, бик ерак, һай, бик еракта иде шул...

❦



## Госман Садә

### Галәм «модуле»

*«Эйнштейн законы уч төбенә сыя...»*
Зөлфәт.

**Бер күкләргә карап, әйтче, Шагыйрь:**
**«Килдеме соң безгә көткәне?»**
**Бер тузаны булып мәңгелекнең,**
**Сизелми дә гомер үткәне...**

**Малайчакта Син дә көтү көткән...**
**Чалкан ятып Күкне күзәткән...**
**Әнә шулай Күкләр чиксезлеге—**
**Галәм сере уза үзәктән...**

**—Чиксезлекнең, димен, чиге бармы?—**
**Шул сорауны бирәм Зөлфәткә...**
**Шигырьләрне коеп куйса да ул,**
**Койган һәйкәл түгел, әлбәттә.**

**Ул эндәшми... Нидер сыза-боза...**
**Тасма итеп кисә кәгазьне.**
**Сүз вә кәгазь генә Мәңгелеккә**
**Тоташтыра шигъри һәр язны...**

**Шул тасмадан сәер Божра чыкты...**
**Әй мәрәкә Шагыйрь шөгыле!..**
**Әйтте Зөлфәт:**
**—Уч төбенә сыйган**
**Шушы булыр Галәм модуле.**

**Каләм белән шушы Божра буйлап**
**Эзләп киттем тәүге ноктаны...**

Госман САДӘ (1949) — *шагыйрь, «Мәхәббәт елы», «Җиләкле тәрәзәләр», «Тайфун күзе» исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

Берәүнең дә, хәер, булганы юк
Мәңгелекне куып тотканы.

Бер Зөлфәткә карыйм...
Бер—кәгазьгә...
Кәгазь тасма—чалыш тәгәрмәч...
Мәңгелекнең сере менә кайда!—
Бер йомарлам кайнар пәрәмәч!

Малайчакта күпме күккә бактым
Көткән чакта авыл көтүен...
Мәңгелектән Галәм күзләп тора
Адәмнәрнең килеп китүен...

Чиксезлекнең серен шагыйрь ачты:
Уч төбенә сыя чиксезлек...
Шагыйрь белән—чиксез Галәмгә тиң
Бер йомарлам якты сүз тездек...

## Аргамак

*Мөнир Әһлиуллинга*

Әй кешнәде... Кыз-кыркынның
Онытылды төшләре.
Әй кешнәде—түрәләрнең
Коелганчы тешләре...

Кешнәү әле тешләү түгел...
Югыйсә, тешли ала...
Кешни-кешни таңга чаба!
Сокланыйк: «Сөбханалла!»

Кешни алмый төн кошлары,
Җырлый белми ярканат.
Төн карасы аңа нигә?
Кешнәп туймый Аргамак!

## Тәкъдир

Җирдә туды.
Җирдә яшьнәп яшәде.
Күккә менде. ...
Хәзер Айда җәсаде.

## Елан елы шигыре

Ютаганда юеш томан иде...
Шаяртуын алдым уенга.
Тере камчы кебек сыргаланып,
Ул сарылды минем муенга.

Пышылдады шашып: «Килә янып
Сөеләсем, сөеп каласым»...
Тоймадык та томан таралганын,—
Узгангадыр бераз чамасын.

«Очкын алып шәмнән, учак тергез—
Кайнарлыгың белән юандыр!»
Күкләрдәнме җиргә аваз иңде:
«Адәм түгел, абау, еландыр».

Ишетмәдем Күкләр кисәтүен...
Аңламассың адәм баласын,
Каян белсен уен уйнаучының
Елан булып соңын чагасын.

Ютаганда юеш томан иде,
Мунчасында иде сандыгы.
Сандыгында, абау, күлмәк түгел,
Ята утыз елан кабыгы.

*

Килер бер көн: кем өчен дә
Үз сәгате сугачак...
Ләкин белмим: ә минеке
Кайда, кайчан булачак?..

Һәрбер иртәм, һәрбер кичем
Сузылып юлга ята...
Алар мине тик мин белгән
Бер илгә якынайта.

## Әби патша җавабы

*(сонет)*

Зәһәре кубудан сызланып,
Сырлады Атакай шикаять:
«О патшам! Сез безне кызганып,
Кылыгыз бер гамәл, ниһаять.

Бу сасы, поганый татарва
Ник шаша, котыра узынып?
Куйдылар мәчеткә манара
Ун чиркәү гөмбәзен уздырып...

О патшам! Бирегез бер фәрман:
Базмасын бу йолкыш басурман
Күкләргә тәрәзә ачарга».

...Бер айдан Атакай алды хат:
«Ачсыннар, кушканча Шәригать!
Күкләр бит буйсынмый патшага...»

## Син күтәрдең кемгә балта?

Мәкер белән мине җиңеп булмый,
Сабырлыгым килә күкләрдән.
Берәүгә дә әмма синең кебек,
Тиләләнеп балта күтәрмәм.

Балта белән бездә йорт бурыйлар,
Балта кирәк утын ярырга.
Тик язмасын, берүк, балта тотып
Дусларыма каршы барырга.

Ирексездән ямчы балта алган
Арган атын бүре куганда.
Охшап куя икән бүреләргә
Туган белән кайчак туган да.

Балта тотып, әйе, сугышканнар
Ирек даулап ерак заманда.
Балта гына бүген коткарырмы
Заман үзе юлдан язганда?

Һәрнәрсәнең була үз урыны,
Озын сүзнең әйбәт кыскасы.
Балта тоту сине бизәр иде,
Әгәр булсаң балта остасы.

Мәкер белән мине җиңеп булмый
Сабырлыгым килә күкләрдән.
Ялгышып та күкләр тарафына
Синең кебек балта күтәрмәм.

Хөсетлеләр генә мәкер саклый,
Дуслар гына дуска тартыла.
Син шулай да кичен күкне күзлә:
Балта түгел, йолдыз атыла.

## Ярату ява

*Әлфия Сәлмән кызына*

Канатсызга канат биргән
Бер сүз - Ярату.
Шул сүз белән туа җанда
Иман яңарту.

Иманымны син яңарттың,
Хәләл җефетем.
Суга салып яндырдың да,
Утта җебеттең.

Син дә кошлар нәселеннән,
Күгәрчен кызы.
Күмердән дә кайнар-кызу
Гомерем кузы.

О кайнарлык! (Күз тимәсен)—
Табамын дәва.
Урман арты аланында
Шифалы һава.

Аңлыйсыңдыр, шәт, үзең дә—
Син бит табибә.
Ярату ул үзе иман—
Гали, гади дә.

Эзләгәннәр эзләгәнне
Барыбер таба.
Көн дә күктән дога булып
Ярату ява.

●

**Зөфәр Дәүләтов**

## ТӘРЕ БАГАНАСЫ

ХИКӘЯ

Шулай беркөнне, эштән кайту нияте белән, автобус тукталышында торам. Автобус көтүчеләр берничәү генә иде. Шуларның берсе таныш кебек тоелды. Чыннан да, элеккеге дустым Һарун түгелме соң бу? Шул ич. Моннан унбиш ел элек бер оешмада бергә эшләп, аралашып, дуслашып йөргән идек. Юкка-барга пошмас, кушканны гына үтәп, башкасына исе китмичә, мәзәкләр сөйләштергәли торган, күңелле генә бер егет иде ул. Бу якта ни эшләп йөри икән?

—Әй, Һарун дус, син түгелме соң бу?! Безнең тирәдә ни югалттың? Әллә «сулдан» кайтышың инде!?—дип шаяртып сөйләнә-сөйләнә, тегенең җилкәсенә кулымны шап итеп салган идем, кагылганыма, урынсыз шаярганыма үкенеп куйдым. Егетнең йөзе сулган, борчулы. Аска иелгән башын авыр гына күтәреп, очрашуга исе китмичә, салкын гына елмайды. Менә сиңа вәйт!—бергә эшләгән чаклардагы шук, шаян Һаруннан берни дә калмаган. Әллә ул түгелме соң бу, дип, күзләремне чекерәйтә төшеп, кабат карап алдым: шул үзе, җор күңелле дустым, кем булсын инде, йә!?

—«Сулга» йөрүемне күрүең белән куркыта алмассың ла...—дип, әйтер сүзенең яртысында туктап калды бу. Сизәм, нидер булган, нидер кичерә, ләкин әйтергә бик үк теләми, яки теләп тә җаен тапмый.

—Гафу ит, уйларыңнан бүлдердем ахрысы...—дип, кыен хәлдән чыгарга ниятләп, сүзне икенчегә борырга тырыштым мин.

—Юк ла, гафу үтенерлек берни дә кылмадың ич, Зариф,—ди бу.—Бу якларга килеп чыгуымның сәбәбе бар. Улым янына бардым. Йөрүгә килгәндә, «сулга» йөрмәгәнемне электән үк белә идең бит, ә бүген минем барыр җирем сулга да юк, уңга да юк... Өметнең өзелгән мәле, дускай, яшисе килми торган чагым.

—Ничек инде юк?!

—Менә шулай, ялгызым гына мин хәзер. Тулай торакта, эшче яшьләр белән гөрләшеп яшәп ятам.

—Ышанмыйм! Шаяртасың! Син теге чакларда ук әйбәт ир идең ләбаса. Хатыныңа... ым-м—Ксения исемлеме әле? Ксюшам, дип, бик яратып, назлап кына дәшә идең түгелме? Хатынкаем Хәтимәм бит син минем, дип ул иркәләүләрең... Татарча сөйләшергә өйрәтеп йөргәннәрең дә хәтердә, дидем мин. Ул башын күтәрә төшеп:

—Булды! Барысы да булды. Яратуым да, назлавым да, татарчага өйрәтергә маташуым да. Тик ул татарча бер генә сүз дә әйтергә теләмәде, дип сөйләргә кереште.—Ә мин, аңа ярарга тырышып, урыс телендә аралаша торгач, үземнекен

онытып ук бетерә яздым. Хәер, сөйләп торуның кирәге дә юк инде хәзер. Барысы да артта калды. Шулай итеп, бу тирәдә очраклы кеше түгел абзаң. Яшьләр урамында законлы пропискам бар.

—Теге, эшкә керешкән чакларда бергә яшәгән тулай торактамы? Беләм, беләм. Хәтердә. Яшьлегенә кире кайткансың икән алайса, чәчәк кебек чакларыңа. Яшәргәнсен, ызначит.

Һарун елмаеп куйды:

—Үзен дә шул чакларга сәфәр кылырга теләмисеңме соң? Экскурсовод булам. Мина бераз җинеллек тә китерерсең. Ялгызлыктан да кыен нәрсә юк икән. Башка төрле-төрле уйлар килә, гаҗиз булдым, малай.

Күрәм, дустымның башына бик авыр хәсрәт килеп төшкән.

Кайчандыр бергә эшләгән, яшәгән һәм хәзер ниндидер бәла-казага юлыккан дустың чакырып, гозерләп торганда, сүзенә ничек колак салмыйсың инде?! Риза булдым, әлбәттә.

Һарун, тукталыштагы кибет ягына ишарәләп:

—Очрашу хөрмәтенә берәр тотар нәрсә эләктереп чыксам, ярап торыр иде, билгеле. Тик әйтергә дә оят, кесәмдә җил уйнаган чак. Өйдә бераз рәт бар-барын...

—Юкка борчылма, Һарун. Мин эчмим ич.

—Беләм, беләм. Яшь вакытта икебез дә «трезвый образ» дип яшәдек. Бәлки, кем белсен, хәзер тоткалый башлагансыңдыр. Эшең дә катлаулы, борчулы, аңлавымча.

—Борчуларны тоткалау белән генә басарга калгач, тормыш булмый инде ул. Безнен ише эшләп кенә тапкан кешегә эчми дә бик таманга туры килә. Кайчан җинел булганы бар...

—Ә мин кайчак шуның белән басам. Файдасы тия.

—Ярар соң, бик хаҗәт икән, бер шешәлек кенә рәт табарбыз. Сырасынмы, кызылынмы, нәрсә алыйм, ниндиерәген?

Без, шулай сөйләшә-сөйләшә, кибеткә таба атладык.

Бер «ярты»ны кыстырып, тулай торак бүлмәсенә кайтуга, Һарун, кыенсынып кына, янә сүз башлады:

—Син борчылма! Һарун дустыңның «НЗ» складлары бөтенләй үк ярлы түгел...

Һарун аш бүлмәсенә чыгып киткән арада, вакытны ничектер тизрәк уздыру нияте белән, күземне бүлмә буйлап йөртеп чыктым. Бу бүлмәдә әллә ни бай кеше яшәмәгәнен бик тиз төшенергә мөмкин. Өстәл, өч-дүрт урындык... Шулай да күңелне җәлеп иткән, хәтта үзенә тартып, кызыксындырып торган нәрсәләр дә бар икән әле бүлмәдә. Төсе уңган обойлы стенага эленгән зиннәтле картина үзенә җәлеп итә. Ак күбекләрен югарыга чөеп дулкынланган диңгез өстендә су ярып йөзүче җилкәнле ак кораб сурәтләнгән анда. Кысасы да зиннәтле итеп эшләнгән. Мондый затлы нәрсә шушы өтек бүлмәгә ничек килеп эләккән икән, дип гаҗәпләнеп тә куясың. Әйтерсең лә әлеге сурәттәге кораб давылда баткан да, диңгез гизүче адәм аннан шушы әйберне генә коткарып, бирегә китереп элгән төсле. Хәер, кораб батулар бер диңгездә генә буламыни?! Аннары күзләрем стенадагы фоторәсемнәргә төште. Фотоның берсендә Һарунның яшь чагы сурәтләнгән. Диңгездә хезмәт иткән чоры. Йөзе малайларныкы кебек кенә. Ә өстендәге, башындагы киеме үзенә бик килешеп тора. «Тын океан флоты» дип язылган пар тасма үзенең хезмәте белән горур яшь диңгезченең күкрәкләре өстенә җилфердәп төшкән. Һарун икәнен әле хәзер дә йөзендә сакланган төсмерләреннән танып була. Ә менә бу сурәттә кем? Күзләрем белән карап түгел, күңелем белән уй йөртеп төшенергә телим. Һаруннын малаедыр инде. Әлбәттә, ул! Чыраенда әтисенең чалымнары бар. Ул да хәрби киемдә. Хәзерге Рәсәй армиясе хәрбиләре формасында. Иң гаҗәпләндергәне—муенындагы бантик булды. Бу берниндн кысага да сыймый. Гаҗәпсенеп һәм кызыксынып, карт солдат буларак, нәфрәтләнгәндәй итеп шушы бантикка кагылсам... Кагылган гына идем—төште дә китте. Болай гына эләктереп куйганнар икән. Берәр балачага шаярткандыр инде, дисәм... Бантик төшеп киткәч, ачылып калган күкрәк өлешен күрүгә, башыма икенче уй килеп туды. Хәрби егетнең күкрәгенә асыл муенсадан көмеш тәре эленгән иде. Бусы да ябыштырып куелгандыр дип бармак очларым белән генә кагылып алдым. Тик идәнгә төшеп китми тәре. Димәк, чынлыкта да шунда тора икән. Бармагым салкын тимергә тигәндәй, чымырдап куйды. Менә эшләр ничегрәк икән дип, мин бик тә четерекле, бик тә гыйбрәтле вакыйга булганына ышана төштем. Күзләремне тизрәк читкә, икенче сурәткә күчерергә

ашыктым.

Бу сурәттән егерме-егерме ике яшьләр тирәсендәге кыз карый. Леонардо да Винчиның Джокондасы кебек, көлми-елмаймый, шул ук вакытта йөзеннән ниндидер эчке бер нур төсмере агыла. Кызны чибәр дип тә булмый, ямьсез диярга дә тел әйләнми: йөзендә ягымлылык бар. Сурәткә бөтен йөзен күрсәтеп туры карап төшкән булса, бәлки матурлыгы тулырак та ачылыр иде. Ләкин яны белән басып төшкән шул. Бөек грек философы Гомер, урысның шанлы яу башы Кутузов, күренекле язучы Островскийлар кебек, ян-ягы белән тора. Нигә шулай иткәндер? Тегеләрен рәссам тән төзелешләрендәге хилафлыкны күрсәтмәс өчен, ягъни сукырайган күзләрен яшерү өчен шулай язган. Ә бу ять-яшь кызга үзенең нурлы йөзенең яртысын нигә яшерергә кирәк булган инде, йә!?

Тукта, бу кызыкайның йөзе таныш бит! Маһинур түгелме соң бу?! Әйе шул. Нәкъ үзе! Сурәтне стенадан алып, тизрәк кем икәнен беләсем килеп, артына язылган сүзләрне йотлыгып укыдым.

> Һарун дускаем!
> Яратсаң, түшеңә так,
> Яратмасаң, ертып ат!
> Син дип өзелүче Маһинурың,

—диелгән.

Әйе, әйе, инде шикләнергә урын калмады: рәсемдә—Һарунның яшьлек мәхәббәте Маһинур!

Тукта, тукта! Менә шушы торакта яшәгән вакытта алар яратышып йөргәннәр иде ич. Ләкин, көтмәгәндә, Һарунның Ксениягә күзе төшеп, аның белән чәчләре чәчкә бәйләнеп китте. Һарун, Маһинур белән араларын өзеп ташласа да, аны йөрәгеннән чыгарып ата алмый йөргән иде. Ә Ксения, иренең киемнәрен юганда шушы рәсемгә юлыккач, Һарунның ике яңагын да каты фото кәгазе белән чәбәкләде. Чәбәкләде дә, аның күз алдында урталай ертып идәнгә ташлаган иде. Кызык, Маһинур Һарунга сурәтен кабат бирде микән әллә? Бирмәсә, монысы каян килгән алайса?

Мин, криминалист кебек, фотосурәтне җентекләп тикшерә башладым. Икеләнер урын юк: шул үзе. Әлеге ертып ташланган фото. Бик оста кул белән яңадан ябыштырганнар да, ертылган урындагы эзне кеше сизмәслек итеп буяп чыкканнар.

Маһинурның бер физик кимчелеге бар иде: сул күзе яшьтән имгәнүле, начар күрә иде аның. Шуңа да сурәткә яны белән басып төшкән. Ә Һарунны шундый өзелеп яратты ул. Шундый яратты! Егете өйләнүгә үк, хезмәтен, яшәгән урынын, көнкүреш уңайлыкларын ташлап, каядыр Себергә китеп барды.

Ишектә Һарун күренде.

—О, Зариф дус! Күрәм, мин изге җаннар гына нигъмәтләнә торган сыйлар әзерләгән арада, вакытыңны бушка үткәрмәгәнсең. Буйдаклар торагындагы шәхси музей буйлап экскурсия ясап ятасың икән. Гидка сораулар тудымы?

Һарун үзенә хас җор күңеллелек белән, ярым шаяртып сөйләсә дә, күңел төбендә тормыш калдырган калын юшкын ятуы, кемгәдер—дусларынамы, яшәешкәме, әллә үзенәме—үпкә, киная бик сизелеп тора иде.

—Буйдаклар музеен карап чыкканнан соң, сораулар туа дисең инде, ә?—дип дәвам итте ул.

—Әйе, туа шул. Әле ничек кенә туа, Һарун дус. Ничек яшисең? Балаларың дигәннән, берсен белә идем.

—Шул берәү генә инде. Марҗам бүтәнне тапмады бит.

—Алайса мин Ренатыңны таныймын.

—Хәтерең яхшы! Берсен дә онытмагансың! Ие, Ренат исемле иде.

—Ничек инде «иде»?

—Әйе шул, «иде» диярга генә калды хәзер. Юк минем Ренатым. Менә хәзер синең белән очрашканда шуның кабере өстенә чәчәкләр куеп кайтышым иде.

Ул, кап-кара яңгыр болытларыннан авыр тамчылар биткә бәреп яуган кебек, күптән җыелып килгән эре күз яшьләрен тыя алмыйча, сөйли башлады:

—Чәчәндә һарап булды бит. Рәсәй империясе башын ашады. Их, улымның хәтәр юлга чыгып, язмышы шулай бетәсен күңелем сизгән иде. Бер дә җибәрәсем килмәде. Әнисе үзенчә, мин үземчә җибәрмәскә тырышып карадык. Акча түләп хезмәттән калдырырга хурландым. Татар Иҗтимагый Үзәгенә чыктым. Күңелем

начарны сизә, үземнен дә, үзебезнең мөселман халкының да канын койдырасым килми, коткарыгыз малайны сугыштан, дип гозерләгәч, ризасызлыгыгызны белдереп гариза язгыз, диделәр. Хатын каршы килде, кул куймады. «Улыбызның башын «татар авантюрасына» тыгасым юк!»—диде. Ренат хезмәткә алынгач, хәтәр хәбәрләр еш кына килеп торса да, хезмәт срогын, шөкер, үлем-китемсез генә тутырды. Инде кайтыр чагы житә дигәндә генә хат язды бит: «Калам, сверхсрочныйга, контракт буенча калсам, бик яхшы түлиләр. Кайткач адәм рәтле квартира, машина алырбыз. Кешечә яши башларбыз!»—ди бу. «Анда башкисәр булып йөрмә, кайт!»—дип, бик каты гына итеп җавап хаты яздым. Ә әнисе, малайның кайтуын шашынып көтсә дә, шәп квартира, иномарка дигән сүзләрне ишеткәч, күзе тонды: «Ике ел исән-сау йөргәнне, тагы бер елда гына берни булмас, әйдә тәвәккәллик!»—дип, хәер-фатихасын бирде. Чыннан да, берничә ай дигәндә, малаебыз шактый калын кесә белән кайтып төште. Ялга. Бүтән җибәрмим, мин әйтәм. Ә улым: «Не сможешь не пускать, контракт»,—дип кенә тора. Әнисе дә, «Алтын балык» әкиятендәге теге комсыз әби кебек, тәмам азынды: «Бер-ике террорист башы киселсә дә файдага. Зато улыбыз исән-сау әйләнеп кайткач, гөрләп яшәрбез!»—ди. Ләкин... үзең беләсең, ул янадан кайтмады. Тимер табутта җансыз тәнен генә алып кайттылар.

Бәла үзе генә килми, диләр бит. Килсә, бер-бер артлы килә икән ул. Яшәүнең рәте китте. Рәте китте генә түгел, тормышыбыз тәмам ишелеп төште. Өйләнешкәннән соң гаилә тәнендә сыткылар гына булып күренгән «авырткан жирләр», зур чуаннар булып шешә барып, бер-бер артлы шартлап тишелә, ага башладылар. Их, нигә әнкәй әйткәннәрне тыңламадым икән, дип үкенергә тотындым. «Өйләнмә марҗага! Ана үз халкының кешесе, урыс егете өйләнсен! Ә син татар кызын ал! Маһинурны! Үзенә унган хатын, мина ипле килен булыр!»—диде бит. Ә мин колакларыма тикле чумып гашыйк идем. Яратам, әни, мәйтәм. Ксениям бигрәк чибәр бит. Мин аны яратам, ул—мине. Тагы ни кирәк?

—Сон, Маһинур күбрәк тә ярата,—ди әби.

—Булса ни, ә мин алай ук өнәп бетермим. Маһинур, кәнишне, ягымлы кыз. Аны да хөрмәт итәм. Үземнән артык күрәм. Тик мина бер күзе белән генә карый ич ул. Димәк, яратуы да бер күз белән генә.

—Юләр! Сине күнел күзе белән ярата ул! Ксения матур дип һушың киткән. Матурлык туйда гына кирәк. Ә акыл-унганлык көн дә кирәк, гомер буена кирәк! Ә мәхәббәт ул, балакаем, иртәнге томан кебек кенә. Тан жиле чыгуга, кояш күренүгә, тарала да бетә. Бераздан үзебезнең гореф-гадәтләрне, йолаларны сагына башларсың. Токмачлы аш пешерә торган татар хатыны кирәк булыр. Балаларыннын үз телендә сөйләшүен, икс учына карап дога кылуын теләрсең, ә соң булыр,—диде әни.

Ксенияне бер күрүдә гашыйк булып күзләрем тонды, сихерләде марҗам. Анын гүзәллеге алдында, сөю алдында көчсез идем. Җаным белән дә, тәнем белән дә яраттым. Яраттым! Күз алдына китер әле, чәч толымнары бөтен иненә таралып төшкән. Өйгә кайткач кына баш өстенә өеп куя. Бүтән чакта гел тарау. Урамда йөргәндә жилдә уйнаклап бара. Аларны үзенә сиздерми генә күпме иркәләдем бит мин. Житендәй толымнарын ничек яратканымны белмисең генә син. Әмма хикмәт чәч толымнарында гына түгел иде, әлбәттә. Кызымның бөтен жире дә сокланырлык. Сокландырды да. Яктырып китәргә торган йөзләре, кичке күлдәй ике күзе, мин йөзә идем шул күлләрдә. Бу кыз минеке бит, минеке генә, дия-дия исереп йөрим. Нигә дип шундый гүзәлне яраттым? Юк идемени җирдә бүтән? Бу яратудан акылдан язып булыр иде. Ничекләр язмый калганмындыр. Хәтта күктәге Ай да Ксениямнән нур алган кебек тоела. Шул нурларга үзенекен дә өстәп, без урамда йөргәндә, янадан өстебезгә түгә иде сыман. Йөрәккә ут капкандай, янында басып торганда һава житмәгән кебек. Кан кайнарлана, йөрәк ашкынып тибә, сонгы тапкыр тибәмени! Сөйгән кызымны кочаклап күпме генә йөрсәм дә, туйдырмас төсле тоела иде.

...Ә хәзер жанда бушлык, йөрәк өзелеп төшкән кебек, яшәүдән туктаганмын сыман. Ана булган мәхәббәтем күктәге тургай: яшьлек язынын айлы кичендә сайравын һаман да ишетәм. Ә үзе, үзе генә ерак-еракта. Бер ноктага әйләнде дә югалды. Юкка чыкты. Югалмаслык иде бит югыйсә. Безне кол иткән, икебезне бер иткән, суыкта—жылыткан, эсседә—жиләслек биргән, канатлар үстергән, төннәрне озайткан, кичләрне озайткан, «аһ» иттергән, жилкеткән, иләсләндергән, тилерткән, менә хәзер юк иткән, сөю дигән мәңгелек газап кайда? Бар иде бит ул безнен, бар иде. Янып беттекме, күкләргә ашар өчен тотенгә әйләндекмени?!

Һарун тагын елап җибәрде.

Ксениясен кайчандыр өзелеп яратуы, араларыннан салкын җилләр үтүе, сөю хисенең инде битарафлык, хәтта нәфрәт белән алышынуы турында ачынып сөйләгәндә стенадагы фотосурәтләргә, үсмерчак мәхәббәте Маһинурга карап һәм, аның каршында зур гөнаһ эшләгән кебек, оялчан карашларын тизрәк читкә күчерә дә, авыр сулап куя:

—Мин Ксенияне югалтмаганмын, ә Маһинурны югалтканмын икән. Менә нәрсәне аңладым шушы олыгаеп килгән көнемдә. Беләсеңме, Зариф, күке үзенең йомыркасын башка кошлар оясына салып, шуларның җылысы белән чыгарттыра. Аннан соң кәккүкнең баласы, урман кошлары ташыган җимне ашап, бик тиз үсеп китә. Бар җимне үзенә генә алу өчен теге кошның балаларын оядан төрткәләп төшерә дә, берүзе калып, бар ризыкны үзе генә ашап ята икән. Ксениям дә шушы кәккүк баласы кебек минем күңелемә оялаган тыйнак, сабыр, юл куючан Маһинурны бәргәләп чыгарып җибәргән булып чыкты бит. Ярата идем мин Маһинурны. Дөрес, алай шашып ярату булмагандыр да инде ул. Әмма да матур-матур уйлар корып йөри идек. Ә менә Ксенияне күрдем дә, бар дөньям шундук асты-өскә әйләнде. Мин аның матурлыгына буйсынып, ихтыяр көчемне җуеп җибәргәнмен. Ә бит ул моны белә торып, аңлы рәвештә безнең арага килеп керде. Маһинур тулай торакта юк чакта, «Сине Маһинур чакырды» дип дәшеп китерде. Ул чакыра—мин киләм. Күрәм, Маһинур да, башка бүлмәдәшләре дә юк. Кайда кызлар, кайда Маһинур, диюемә, алар авылга кайтып киттеләр, ди. Мәйтәм, нигә Маһинур булмагач дәштең, дим. Ә ул, берүземә күңелсез, ди. Сиңа минем белән ямансу булмас, курыкма, аларның миннән бер артык җирләре дә юк». Шулай итеп, күңел түремә юл сала башлады. Маһинур белән аралар суынганнан-суына барды. Мин исә, үземчә: «дөрес эшләдем, гаилә кору хокукын алу өчен кәрәштә көчлеләр җиңәргә тиеш һәм шулай булды да»—дип исәпләп йөрдем.

Егерме ел буе бар нәрсәне уртак итеп яши торгач, бер-беребезгә ияләшеп беттек. Ә ике көндә һәммәсе дә юк булды. Бу йөрәк нигә түзә, түзмәсә, бәлки, җиңеләер иде. Егерме ел бар булып, ике көндә юкка чыккан нәрсәне ни диим икән! Хәзер тоташ газаплардан торабыз. Ксения минсез, мин ансыз, ә улыбызның цинкланган табуты өстенә биш кубометр балчык өелгән.

...Балабыз тугач, сугышта һәлак булган бабаем хөрмәтенә, аның хакына Салихҗан дип исем кушарга булдык. Әни шулай дип киңәш биргән иде. Ә маржам якын да килми. Аңа да киңәш бирүчеләр бар бит. Петр дигән исем сайлаганнар. Бусына мин бик нык протест белдердем. Шулай тарткалаша торгач, ике якка да ярарга тырышып, русча да, татарча да булмасын дип, компромисска килеп, Ренат исеме куштык. Соңрак әни сөннәткә утыртырга дигәч—анысына да юл куймадылар. Ә мин, шул ярату аркасында, берни дә эшли алмадым. Сөйгән кешенә каршы әйтеп буламыни. Яратуыма аның яратуы ирешмәгән, шуңа күрәдер, аңа минем хәтерне калдыру берни дә тормады. Беребезгә дә әйтми, сиздерми генә улыбызны чиркәүгә алып барып чукындырган бит, әй!

Бусын да соңыннан, Ренат солдатка алынып, аннан үле гәүдәсе кайтып җирләгәндә генә белдем. Бәла килгәч, улыбызны кая, ничек итеп күмәргә дигән сорау калкып чыкты. Мин әйтәмен, аның исеме, атасының исеме, бары да татарча, шулай булгач, мөселман зиратына җирләнергә тиеш. Ә хатын, улыбыз чукынган ич безнең, дип, аяз көндә башыма яшен ташыдай китереп сукты. Мулла да, хәзрәт тә, бүтән картлар да, чукындырып кына христиан диненә табынучы итеп булмый, диләр. Бала үз гомерендә бернинди дә христиан диненә туры килә торган гамәлләр үтәмәгән, аны белми йөргән. Шуңа күрә дә аның урыны мөселман зиратында тиеш булган икән. Мин боларны бик соңарып белдем. Дөрес итеп җирләмәгәннән чәчем агарды. Бер көндә. Ләкин, Зариф дус, үзең беләсең, динсезлек заманы иде бит. Барыбыз да атеист идек. Аллага ышанмаска куштылар. Ни өчен соң алайса гасырлар буе кешеләр Аллага табыналар? Халыкны тиле дияргә—ул тиле түгел. Табыналар икән, кирәк. Кемдер Аннан дәрәҗә сорый, берәүләр—байлык, икенчесе хакыйкать булсын, ди. Аңа табынган кеше һичкайчан гөнаһ кылмый. Табынуның иң зур файдасы шушыдыр инде. Безне партиягә, Ватанга ышанырга өйрәттеләр. Ә хәзер ышанасы килсә дә, юк ул ышаныч, юк!

Әгәр дә шушы үлем фаҗигасе килеп чыкмаса, яшәгән булыр идек әле. Ил таркалгач кына катнаш никахлыларга ләгънәт укый башладылар. Әлек без почетта идек. Икебез ике диндә, балабызны ничек итеп тәрбиялик дигән уй башка да килмәгән. Исем кушулары, аннары кая барырга—чиркәүгәме, мәчеткәме? Ничек

итсәң дөрес була? Үлем-китем булганда кайсы зиратка күмәргә? Мулланымы, попнымы чакырырга? Шушы хәсрәтне күтәрә алмый күпме еладым, тик берни дә эшли алмадым. Үз кулларым белән урыс зиратына илтеп, урыс кануннарына туры китереп поминкалар ясый-ясый җирләдем. Чардуганның почмакларына ярым айлар ясатып куйган идем. Хәрәм гамәл, дигәч, кисеп ташларга туры килде. Болар узып та өлгермәде, үземә тагын бер рухи газап китереп бәрде. Кабер өстенә утыртырга тәре ясар өчен имән баганалык кирәк иде. Хатыным инде сорап, ялынып тормый, боера гына. Бер иптәшем белән урманга киттем. Үзем агач кисәм, үземнең күзләрдән яшь ага. Күрәм, калын, төз имән агачы без юнәлдергән якка түгел, ә икенче яккарак, нәкъ безнең өскә ава башлады. Әллә нинди күк күкрәгән, яшен яшьнәгән тавышлар чыгарып, тәп тирәсе шартлап өзелгәне, ботаклары сынганы ишетелә. Аннан читкәрәк тайпылсак та, безнең өскә ава бара. Иптәшем кырыйга чыгып өлгерде. Ә минем башка яшен тизлеге белән, әллә шушы агач астында калыйммы, дигән уй килде дә керде. Хәсрәт тә, газапланулар да бетәсе... Шунда, ышансаң-ышан, малай, Мәһинур, күз карашлары сабырлыгын җуеп, миңа карап куйды төсле. «Читкә тайпыл, Һарун, харап буласың бит! Минем хакка булса да, җәллә үзеңне, гомереңне әрәм итмә!»— дия иде кебек ул миңа. Читкә сикергәндә агачның очы гына башыма тиеп кепкамны бәреп төшерде. Иптәшем минем исән калуыма шатлануын белдерүдән битәр, яланбашыма карагач—сүзсез калды. Сүз табалмый тора.

—Нигә?—дим.

—Әй, әй... Син... Син башка кара әле! Юк, юк, үз башыңа үзең карый алмыйсың ич инде. Көзгедән!—Ул атылып машинасына таба агачларга абына-сөртенә алпан-тилпән китеп барды.

Килгәнен көтеп тормадым, акылдан язгандай баштан бер учма чәчне йолкып алдым. Да! Күзенә күренмәгән икән. Көзгесен алып килеп дәшми генә минем кулыма тоттырды.

—Кара әле, үзең кара! Бәлки миңа гына шулай күренәдер—ди бу. Үзе башын чайкый.—Их, малайкай, күрдең-күрмәгәнне. Синең чәчләрең, синең чәчләрең ап-ак ич!

—Шуннан соң нишләдегез инде?—дим.

—Дустымның машинасына утырдык та, бернигә карамый, әйдә өйгә! Пычкыны шунда болгап ыргыттым. Хәзер инде минем күз алдымда Мәһинур гына калды. Ах, никадәр гаепле мин аның алдында! Минем аркада бөтен гомерен ялгыз үткәрде бит ул. Берәүгә дә кияүгә чыкмады. Берәүне дә янына китермәде. Башкалардан әйбәтрәк булганмын—шуңа микән... Көткән мин ишәкне. Шул кирәк миңа. Бераз шулай йөргәч, үсмер чаклардагы ахирәт дус кызы янына кереп, адресын алдым да, киттем мин моның яшәгән җиренә. Бара торгач, шактый җир үтәргә туры килде. Казакъстан далаларына, элек чирәм җирләр үзләштергәндә төзелгән, хәзер инде искереп, таушалып калган, ни авыл түгел, ни шәһәр булып җитмәгән бер бистә кебек җиргә китереп чыгарды мине барыр юлым. Бу казакъ авылы да, урыс яки татар авылы да түгел. «Милләтләр бетәчәк»,—дип» единый советский народ» тантана иткән чорда барлыкка килгән бу бик үк зур булмаган җир үзенә әллә ничә дистә милләт вәкилен җыеп ята икән. Түземсезләнеп, Мәһинурны сораштырам. Тизрәк күрәсе килде. Бөтен үткәннәргә салават кылып, аннан башка уздырган шушы чал башымны кылганлы, җаныкаем яшәгән җиргә, матур чакларын ялгызы үткәргән дала җиренә орып, Мәһинурдан гафу үтенәсе, калган гомерне бергә-бергә үткәрик, дип, нурлы сыңар күзенә карап ялынасым, алдына тезләнеп гафу үтенәсем, яратканны белдереп, «әйдә кайтабыз» дип ялварасым килде.

Шунда бер адәм:

—О, у нее в жизни большие события!—дип җавап биреп, мине аның барак тибындагы йорты капкасына тикле китерде:

—А вы кто, ее родной брат или знакомый какой? Что-то запоздали на торжество,—ди.

Аңламыйм әле. Берни дә, миңа кагылмыйдыр сыман.

Мин бу әйтелгәннәргә колак та салмый, җилкапка аша узып, атап чакырганнар диярсең, ашыга-ашыга болдыр баскычыннан күтәреләм. Каршыма икәү чыктылар. Кергәнемне күргәннәр икән. Берсе, әлбәттә, Мәһинурым. Тик ни эшләп мин аңа, Мәһинурым, дип дәшмәкче булам әле? Ул бит берүзе генә түгел. Янында култыгыннан тотып илле-илле биш яшьләр тирәсендәге сары чәчле, зәңгәрсу күзле бер ир-ат басып тора. Мәһинурым, минем аңа карап торуымны күргәч, сүзгә килде, беренче булып исәнләште.

—Исәнме, Һарун! Таныш бул, бу минем ирем—Григорий, фамилиясе Мелехов. Әле бергә яши башлавыбызга атна гына. Исеме «Тын Дон» героеныкы кебек булса да, алай легендар кеше түгел. Фронтның бер ягыннан икенчесенә күчеп, кылыч болгап йөргән сугыш каһарманы да булмаган. Сугышмый дип әйтүем. Менә бер атна яшәп, әле бер дә кул күтәргәне юк. Ә безгә хатын-кызга тагын ни кирәк инде!

Үзе миңа карап «нигә соңга калдың?» ди сыман.

Маһинур, «яшь» киявенең иң мөһим шушы уңай ягын горурлык белән әйтеп куйганнан соң, ирен минем белән таныштырмакчы була. Ул таныштырганчы ук ире минем күзләремдә Маһинурымны күреп аңлагандыр...

—Һарун. Мой земляк и друг юности.

Исәнләшкәч, Григориенә сиздерми генә аңа текәлдем. Кочаклап аласым, очрашу бәхетеннән акырып елыйсы килде.

—Әйе шул. Яшьлек дустың булудан да уза алмадым. Болай дию ең өчен дә рәхмәт, Маһинур! Сине күрер көнем дә бар икән. Тагы ярты сәгатьтән автобус кире китә, миңа өлгерергә кирәк. Синең күзеңә... күзләреңә бер карау өчен генә килгән идем... Соңарганмын икән. Озак йөргәч—шулай була ул.

Күзеңә... күзләреңә, дип тоткарланып калуымның сәбәбе бар иде. Шулай дип әйткәндә Маһинурга күтәрелеп карасам, ике күзе белән миңа сагышлы, ягымлы, мәгънәле итеп каравын күргәч, телсез калгандай булдым. Әллә күземә генә күренә инде. Йә, Хода! Мин бәхетсез иткән Маһинурмы бу?

—Гриша күземне савыктырырга булышты. Украинадан ул үзе. Шунда нәсел-нәсәбеннән калган зур гына өйләре булып, хуҗасыз калган икән. Шуны сатты да, мине Чабаксарга алып барып, кайчандыр бәхетсез иткән күземә операция ясатты. Үзең күрәсең, күзләремне тутырып карый алам хәзер. Шушы тикле изгелек эшләгәч, аңа кияүгә чыгарга ризалык бирми бер чарам да калмады.

Ул еларга җитешеп:

—Ә мин сине көттем, Һарун. Бик озак көткән идем. Хәер, мондый сүзләр сөйләп, әллә ниләр өмет итеп, Ксения белән ике арагызга чөй бәреп маташмам инде. Бәхетле генә яшәгез! Ә ул бәргән чөйләр гомер буена җитәр. Сиңа да бәхетсез булырга димәгән...

—Минем синнән башка беркемем дә юк хәзер, Маһинур,—дим, соңгы өмет чаткысын дөрләтеп җибәрергә тырышып,—әйдә, онытыйк та, туган якларга кайтып китик. Барысын да яңабаштан башлыйк. Бардыр ул бәхет дигәнең, бардыр!

—Бәлки, алай да эшләп була торгандыр,—ди Маһинур авыр сулап. Ләкин мин—тугрылыклы хатын. Без Гриша белән гомеребезнең соңгы көненә кадәр бергә булырга ант иттек. Ул авыру. Хәмер зәхмәте тормышын нык агулаган, тәүбәгә килеп, ташларга соң була язган. Гомере кыл өстендә торганда таныштык без аның белән. Яратуга килгәндә, анысы бер генә тапкыр була торгандыр инде. Кемне гаепләргә—үзең ярата, яраттыра белмәгәч. Яратусыз гына яшәп ятарга туры килә инде хәзер. Кем уйлаган, мәхәббәттән казакъ даласына качып, баракта гомер үтәр дип? Үзең күрәсең, рәхәттән чыкмадым. Хәзер ни файда: бала да табалмыйча, килмәгән кешемне көтеп гомер үткән. Ләкин, беләм мин синең нигә килгәнеңне. Син дә мине аңла. Шундый авыр чагында аны ташлап китә алмыйм, Һарун. Үзеңне дә кумыйбыз. Әйдә, өйгә кер. Теләсәң, кунак булып китәрсең. Әйдә, әйдә! Юлдан ачыгып, сусап килгәнсеңдер. Ял итәрсең... Язмышларны үзгәртеп булмас шул...

* * *

Маһинурга шушы бәхет кошы белән юанып яшәвенә комачауламас өчен Һарун кабат үзенә әйләнеп кайткан. Ксениясе янына инде бүтән кермичә, тулай торакта яшәп яткан чагы.

* * *

Тышта саратан ае. Эссе. Тузан тын юлына керә дә, тамак төбенә утыра. Дустымның кайгылы чагын күреп, аның тар бүлмәсеннән чыккач, бу күренеш миңа җәннәт багыдай тоелды. Ул нишләп калгандыр. «Хат язып кара...»—дип киңәш бирергә дә онытканмын. Аның белән чагыштырып карасам, мин бәхет иясе кебек. Ә бәхетле булуыңны белми йөргне ничек диләр икән? Шуны аңларлык кына булса да акыл бир, Ходаем! Бу синең рәхмәтең булыр иде. Ә ләгънәтеңне кеше җилкәсендә тату да әҗәл газабы кебек икән бит. Боларны төштә дә күрсәтә күрмә берүк!

И, Һарун дускай, син түз инде. Мин сиңа сабырлыклар теләп торырмын. Чыда берүк!

*Әдәбиятлар дуслыгы–халыклар дуслыгы*

## Олег Шестинский

# ҖИРӘНЧӘЧ

ХИКӘЯ

Блокаданың беренче елында укуны калдырып торгач, унынчы сыйныфта тавышларыбыз калынайган, кыяфәтебездә ирләр чалымы сизелә башлаган, мыек төртеп килгән егетләр идек инде.

Ул чорда өлкән сыйныф укучыларын файдалы җәмгать эшләренә тарту гадәткә кергән иде. Моның төп сәбәбе шул: җимерелгән Ленинградны тиз генә янадан торгызып бетерү мөмкинлеге юк. Шуңа күрә без носилкалар белән вак таш ташыйбыз, агачлар утыртабыз, чәрдәкләнеп беткән иманнәрнең төпләрен кубарып алабыз... Шәһәрне аякка бастырганда эш бетәрлекмени соң? Һәм, әлбәттә, безнең бу гамәлләребез дәресләрдән соң эшләнә. Ләкин без ялкауланып мыгырданмыйбыз, чөнки блокададан соңгы Ленинградны безнең өчен беркем дә төзекләндереп бирмәскә иманыбыз камил иде.

Шуңа күрә тәнәфестә завучыбыз сыйныфташым Фролов белән мине үз кабинетына дәшеп алганда ни өчен икәнен шәйләгән идек инде.

Фролов аз сүзле, тыныч холыклы егет. Күпереп торган җирән чәчле һәм бите тулы җирән сипкелләре булгангамы, ул үзенең табигый төскыяфәтеннән унайсызлана шикелле, башка малайлардан читләшебрәк йөри. Укуын бик тырышып укый—гел генә бишлеләр ала. Аның әти-әниләре һәлак булган, ул битләрен җыерчыклар баскан сөйкемле әбисе белән генә яши иде.

Фроловның кушаматы—Җирәнчәч. Ул аны үз исеме кебек кабул итә, үпкәләми генә, дусларча җавап кайтара:

—Әү!—ди.

—Йә, Җирәнчәч, кузгалдык!—дидем мин.—Безне җимерекләр чистартырга ыргытырлар хәзер.

Без завучның ишеген шакыдык. Завуч апа башта миннән сорады:

—Укуың ничек?

—Гел бишлеләр генә.

—Молодец! Ә кирпечләр биреп торырга бара алырсыңмы?

—Әлбәттә.

—Молодец,—дип янә кабатлады ул.—Ярар, дәресләрдән соң эшчеләр янына ашык, яме! Өенә кайтып, кием алыштырып килергә онытма!

—Киттек,—дидем мин Фроловка таба борылып.

—Фролов калып тора,—дип аны тоткарлады завуч.

Шунда гына мин кабинетның бер читендә утырган хатынны шәйләп

---

Олег ШЕСТИНСКИЙ (1929)—*рус шагыйре, тәрҗемәче. "Вижу берег столетия!", "Поле", "Блокадные новеллы" һ. б. китаплар авторы. Мәскәүдә яши.*

алдым. Аның өстендә—төсе уңып беткән күлмәк, үзе кулларын тезләре өстенә чалыштырып куйган да тын гына безне күзәтә.

Мин чыгып киткәч, завуч Жирәнчәчтән дә сораган:

—Гел бишлеме?

—Әйе.

—Мин сине һәрвакыт акыллы, ярдәмчел егет итеп күрәм,—дигән завуч ягымлы гына итеп.—Сиңа безнең гадәти булмаганрак бер йомышыбыз бар.

Жирәнчәч гаҗәпләнеп кашларын җыера.

—Менә Валентина Ивановна,—дигән завуч, теге хатынга төртеп күрсәтеп.—Ул трамвай-троллейбуслар паркында диспетчер. Аның бишәр яшьлек ике игезәге бар, ә ире сугышта хәбәрсез югалган. Иртән ул әле балаларын балалар бакчасына кертеп китәргә өлгерә, ә кичләрен, эш көне озын булганга күрә, вакытында барып ала алмый кала. Балалары зарыгып бетә, елаша... Кызларыбыз барысы да төрле эшкә бүленеп беткән. Син шул балаларны бакчадан өйләренә озатып куярга алынмассыңмы икән? Анда әниләре әзерләп калдырганны җылытып, ашатып та алырсың. Без барыбыз да сугыш елларында бәлагә тарган кешеләр бит, үзең беләсең,—дип сүзләрен йомшата төшә завуч.—Нәрсәләр майтарырга икәнен дә чамалый алмыйбыз...

Жирәнчәч урындыкта тораташ катып утырган хатынга тиз генә карап ала. Хатын бары тик күлмәк җиңен генә бөтереп утыра. Гап-гади хатын, зәп-зәңгәр күзләре генә өметләндереп чакыра шикелле.

Жирәнчәч:

—Мине дә кирпечкә җибәрсәгез иде,—дип үтенә.—Балалар карый алмам мин...

—Кирпечне кем дә ташый аны,—ди завуч.—Ә балалар... Каршы аласың, ашатасың... Син бит ярдәмчел, ягымлы егет.

—Ә, бәлки, кирәкмәстер,—дип хатын да сүзгә кушыла.—Башка берәрсен эзләп карармын. Яшь әле бу, уйнап йөреп туймаган...

Анын бу сүзләре Жирәнчәчкә барып кадала. "Бер дә алай таш йөрәк түгел инде мин. Ире дә сугышта югалган..."—дигән уй күңеленнән узып китә.

—Алынып карыйм,—ди ул.—Тик бу хакта мәктәптә сүз таратмассыз. Көләрләр.

—Ахмакларга игътибар итсәң...—дип аны бүлдерә завуч.—Ә син соңыннан нинди изге эш эшләгәнеңне гел искә алырсың. Молодец!—Завуч Жирәнчәчне тагын шулай бер майлап куя.

Жирәнчәч теге хатын белән мәктәптән чыгып китә.

—Алар минем шук-шаян түгелләр. Үземнең һич вакытым җитми. Бөтереләм дә бөтереләм. Мин сине хәзер алар белән очраштырырмын. Өйдә инде алар,—дип сөйләнә хатын.

Жирәнчәч хатынга тагын бер күз атып ала, хатын аңа шактый карт төсле күренә. Битләре дә төссез-тонык. Шулай да почык борыны белән зәңгәр күзләре яшәртеп тә җибәрә шикелле үзен.

Балалар, Коля белән Паша, килеп кергән абыйга карап, тынып кала.

—Ул сезне бакчадан алып кайтып йөрер,—ди әниләре.—Исеме...—ди дә төртелеп кала.

—Жирәнчәч,—дип, Фролов үзе дә сизмәстән мыгырдап куя. Аңа бит әбисе белән укытучылар гына чын исеме белән дәшә.

—Жирәнчәч! Жирәнчәч!—дип куаныша-такылдаша балалар.—Ә син кубиклардан өй ясый аласыңмы?

—Алам,—дип аларга иелә Жирәнчәч, үзенең вазифалары артачагын да шәйләп.

Жирәнчәч Коля белән Пашаны балалар бакчасыннан алып кайта, ашата, алар белән бераз уйный, аннары, Валентина Ивановна кайтып җиткәнче, калдырып та китә.

Ләкин көннәрдән бер көнне алар ишектә бәрелешә язалар. Хатын Жирәнчәчне чәйгә чакыра. Үзе өстен алыштырып, өйдә кия торган халатын

кия. Аның җитез куллары оста гына итеп табын әзерли: варенье, конфетлар, келиндерлар тезә, куе итеп чәй ясый.

—Мин бүген бераз иртәрәк кайттым,—ди ул.—Ә беләсеңме, ни өчен? Бүген минем туган көнем бит.

—Котлыйм,—дип гөрелди Жирәнчәч, үзе бер бүләге дә булмаганга үкенеп куя. Хатынга ничә яшь тулганын сорарга кыенсына.

—Ә миңа утыз яшь хәзер,—дип күңелле генә елмая хатын, аның егет алдында бер дә алай матур итеп елмайганы булмый әле: яңакларында сөйкемле чокырлар хасил була, күзләре уйнаклап ала, маңгаена йомшак чәче ишелеп төшә.—Ә сиңа ничә?

—Унтугыз...—дип мыгырдый Жирәнчәч, хатынның үзенә әни булырлык түгеллеген, булса, апасы гына булырлыгын чамалап.

—Сиңа яшәргә дә яшәргә әле... Әйбәт кенә кыз да табарсың... Тормыш та җайланыр әле...

“Кыз табарсың” дигәнне ишеткәч, Жирәнчәч сагаеп кала. “Ә нигә кыз турында әйтте соң әле ул?”—дип уйлап ала. Һәм, үзеннән-үзе куркытып, ташып чыккан хис-тойгыларын тыя алмыйча, эсселе-суыклы булып китә. Валентина Ивановнага каш астыннан гына егетләрчә дәртсенеп карап куя: аның дерелдәп торган күкрәкләренә, иңнәренә кадәр ялангач кулларына күз сала, хатын кухняга чәй алырга чыгып йөгергәндә, сыгылмалы билләрен күздән кичерә.

Алар шулай тәмләп чәй эчәләр. Валентина Ивановнаның өстәл астындагы аягы ялгыш кына үзенекенә кагылып киткәндә, егет кызарынып кабына, күз карашларын аска төшерә.

Ә хатын әкрен генә сөйли дә сөйли:

—Мин май аенда кияүгә чыктым, июньдә сугыш башланып китте. Митяны да алдылар. Ул Колпиноны саклашты. Өчпочмаклы берничә хаты да бар. Балага узганымны язып, сөендерергә дә өлгердем үзен. Ә шуннан соң—бушлык. Военкоматның сүзе бер генә: “Хәбәрсез югалды”,—диләр. Ә ул Колпино тирәләрендә кемнәрне генә кырып салмаганнардыр... Кем аларны санаган?—Валентина Ивановна көрсенеп куя.

—Мин сездә озак тора алмам,—ди Жирәнчәч.

—Ә нишләп?—дип, Валентина Ивановна аны сүзгә тарта.

Нәрсә әйтергә дә белмәгән Жирәнчәч:

—Шулай инде...—дип кенә мыгырдана.

Валентина Ивановна исә өметләндергеч-ымсындыргыч тавыш белән әкрен генә көйли:

—Безне алай ашыгып ташлап китмә инде... Берәр кыз күзләгәнче, дим... Анда инде чынлап та безнең кайгы калмас синдә... Ярата башларсың... шулай булыр дип уйлыйм...

—Сез бернәрсә дә уйламыйсыз!—дип үртәлеп әйтә Жирәнчәч.

Валентина Ивановна аны йомшартырга тели:

—Син миңа “син” дип, “Валя” дип кенә дәш.

—Әйтә алмыйм...

—Соң, мин сиңа апа кебек кенә ич...—Егет аның тавышында көлемсерәү чаткылары сизә.

—Шулаймы?—дип югалыбрак кала ул.

Инде ничәнче чынаяк чәй эчелеп беткәндер, өйгә, әбисе янына кайтып китәргә кирәк Жирәнчәчкә. Ә менә чыгып кына китә алмый...

Пашка белән Коля икенче бүлмәдә күптән инде йокыга талган иде.

Валентина Ивановна өстәл яныннан кузгалды:

—Бераз кызылдан авыз итикме әллә? Минем туган көнем ич бүген!

Үз гомерендә әле бер эчемлек тә кабып карамаган Жирәнчәч баш кына какты:

—Эчеп карыйк соң...

Хатын кечкенә рюмкаларга ниндидер хуш исле, иреннәрне өтеп ала торган татлы эчемлек салды. Шәрабне йоткалый-йоткалый, тагын нәрсә

әйтергә белмичә, шул ук вакытта әйтеләсе сүзләрен эчләренә җыеп, алар кара-каршы шактый озак утырдылар.

Беренче булып тынлыкны Валентина Ивановна бозды, тәвәккәлләп әйтеп куйды:

—Авыр миңа ирсез...

—Сон, мин ярдәм итәм ич,—дип тончыкты Жирәнчәч.

—Итүен итәсең...—дип пышылдады Валя.—Миңа бит башкача авыр... Кайвакыт төннәрен бөтен тәнемне нәрсәдер бөтереп ала шикелле, куркып калам. Синең шулай булганы бармы?

—Бәлки, алай ук түгелдер дә...—Жирәнчәч сүзләрен сыгып чыгарды.—Нәрсәдән икәнен әйтә алмыйм...

Валентина аны зәңгәр күз карашлары белән өтеп алды, төнге газапларыннан туган турылык белән, чыбыркы сыдыргандай сыдырды:

—Минем белән яшәргә телисеңме?

—Ничек?—Жирәнчәч уттай кабынып китте.—Әбием бар бит...

Шуннан соң алар сүзсез-нисез генә бер-берләренә елыштылар.

—Сал күлмәгеңне, рәтләп бирим әле,--дип, һәр сүзен сузып кына әйтте Валя. Үзе егетнең яка төймәләрен ычкындырды, йомшак кулы жирән төкләр баскан таза, шома күкрәген иркәләп сыйпады.

Жирәнчәч катып калды. Ә Валя, артка авышып утны сүндерде дә, аңа сыланды.

—Малайкаем минем, малайкаем...—дип кайнар пышылдады ул. Аннары кинәт кенә, кире кага алмаслык катгый итеп:—Ят!—дип боерды.

Жирәнчәч төнге караңгылыкта шәйләнгән ап-ак гәүдәнең житез генә чишенгәнен күз кырые белән тотып алды, хатынның баш әйләндергеч, ымсындыргыч татлы тән исеннән исереп, юрган астына чумды.

Әмма Валя аннан алдарак шунда иде инде. Аларның балтырлары ирексездән үрелештеләр, егет, түшәмгә карап чалкан яткан килеш, үз тәненең аңга буйсынмаслык ниндидер көч белән тулышканын тойды. Хатынның жинел йомшак кулы аны капшый башлады һәм комсызланып аның оят жиренә төшеп житте, аек акылында булса, Жирәнчәч Валяның бармакларын ул тирәдән тибәреп жибәрер иде. Ләкин барысы да буйсынмастан, ирексездән эшләнде, әйтерсең лә, аны кайнар һава белән өреп тутырдылар һәм егет очып китәр шикелле булды. Шунда гына Валяның ыңгырашып инрәгәнен абайлап алды.

—Менә шулай... менә шулай... бәгырем...

Жирәнчәч ерткыч бер инстинкт белән үзен шушы хатынның хуҗасы итеп тойды, сытып үтермәгәем тагын дигәндәй, терсәкләренә таянып, аны изә башлады һәм, ярларына дулкын арты дулкын каккандай, Валя өстендә мәхәббәт уены уйнарга тотынды. Бу гамәл, бер көчәеп-бер кимеп, аннары янадан тыелгысыз дәрт белән чиксез озак дәвам итте.

Егет, кинәт тишелгән шар шикелле, бушап-йомшап калды, хатынның муенына төртелеп еш-еш сулады, алга таба нәрсә эшләргә кирәклеген дә анышмый иде ул. Аның колагына гади-гадәти сүзләр килеп керде:

—Бар, ваннага кер...

Һәм ул, таныш түгел коридор буйлап чайкала-чайкала, капшанып атлады.

Аннары алар озак кына янәшә яттылар. Хатын исе китеп әйтте:

—Нинди көчле икән син! Минем әле мондый рәхәтлекне беркайчан да кичергәнем юк иде... Син мине ташламассың бит?..

—Юк,—дип гырылдады Жирәнчәч.—Ә шулай да нәрсәдер куркыта шикелле, авырта да кебек...

Валя аны ишеккә кадәр озата чыкты, ә ул, саубуллашырга дип борылды да, Валяның тезләрен каплар-капламас ачылып киткән халатына карап алды һәм аны, мамык күтәргәндәй җинел генә күтәреп, бүлмәгә илтеп салды, чәчләрен, бармакларын үбә-үбә:

—Рәхмәт...—дип сузенә тончыкты.

Валя хатын-кызларга гына хас бер буйсындыручы көч белән аны янадан үз өстенә аударды. Үрелеп кенә утны сүндерделәр...

—Сина, мөгаен, нянька булып йөрү житкәндер,—диде завуч апа, күпмедер вакыттан соң Жирәнчәчне үзенә чакырып алып. Егетнең йөзе суырылып калган, күз төпләре күгәребрәк тора иде.—Кызлар бушады инде. Аларга кулайрак булыр...

Шуннан соң Валентина Ивановна мәктәпкә үзе килде, кыскартылган эшкә күчтем, дип ялганлап, кызлар ярдәменнән баш тартты.

—Ярар алайса,—завучның бармаклары өстәл өстендә биешеп алды.—Шулай булырга тиеш тә иде. Акылдан шашкан заман бит. Һәркем үзенекен эзли...

Валентина Ивановна унайсызланып кызарынды, завуч аны кызганып:

—Ә минем Павел Николаевичым сугышның соңгы көнендә һәлак булды. Никадәр мәгънәсезлек!—диде һәм кульъяулыгы белән күз яшьләрен сөртте. Кульъяулыкны йөзеннән алмый гына әйтеп куйды:—Барыгыз, сезгә ак бәхетләр!

Валентина Ивановна мәктәптән, жәза камерасыннан атылып чыккандай, атылып чыкты. Үз-үзен шелтәләп-гаепләп, шул ук вакытта Жирәнчәчен тизрәк кочагына алырга хыялланып, өенә ашыкты.

Алар ташлашмадылар. Жирәнчәч элеккечә үк балаларны карады, ашаттыэчертте, юк кына уеннарына да катнашып, һаман да алар белән мәш килде, аларны гел үзенеке итеп тоя башлады.

Бервакыт ул Валяга туп-туры әйтте:

—Ничек инде һаман да болай! Әйдә өйләнешәбез. Сугыш дәвам иткән булса, мин дә сугышта булыр идем бит инде.

—Ни сөйлисең син!—дип, кечкенә йодрыгы белән аның күкрәгенә төртте Валя.—Тагын нинди сугыш! Миңа анын монысы да гомергә житәрлек булды.—Шуннан соң ул тынып калды, булмаганча бик озак дәшми торды. Күзләре өстәл өстендәге жаймәгә текәлгән иде, әйтерсең, ул жаймәне яңа сатып алып кына кайткан.

—Мин бит ир хатыны. Әгәр дә ул исән булса? Миңа нишләргә кала? Ике ир белән яшәргәме?—Ул бу сүзләрен авызында чуер ташлар тәгәрәткәндәй тәгәрәтеп чыгарды.

—Син минеке!—дип киреләнде Жирәнчәч.

—Синеке, синеке генә... Ләкин анла...—Валя калганын әйтеп бетермәде.

Бер айдан соң Жирәнчәч Валяны әбисе белән таныштырырга теләде.

—Мин аны яратам. Ә ул минем тагын кемемдер барлыгын сизенә. Барып килербез, яме,—дип кайнарланды ул.

Очрашуга барырга Валя дулкынланып әзерләнде. Ярлы гына әйберләре арасыннан сугышка кадәрге бәхетле еллардан бирле киелмәгән кара бәрхет күлмәген сайлап алды. Якасына брошка кадады. Аксыл-сары чәчләрен әйбәтләп исле сабын белән юды, аны тарап, якалары өстенә таратып жибәрде. Аягына бәйрәмнәрдә генә кия торган оегын киде, иреннәрен әз генә буягандай итте, кершән ягынды.

—Йә, ничек мин?—дип Жирәнчәч каршысына килеп басты ул.

Жирәнчәч соклануыннан бер мизгелгә тынсыз калды. Анын каршысында кыланчыкланып бер искиткеч гүзәл кыз басып тора иде. Булса, үзеннән бераз гына өлкәнрәктер, бераз гына...

—Могжиза!—дип шаккатып әйтте ул.—Әйдә, тизрәк барыйк. Бу матурлык беткәнче, дим.

—Ә нигә бетсен? Мин синең өчен гел генә шушындый ич.

Әби аларны борынгычарак каршы алды. Баш ия-ия исәнләште, күчтәнәчләре өчен рәхмәт укыды, нарат жиләгеннән пешергән пирог чыгарды, үзе ясаган шәрабне өстәлгә куйды, аннары Жирәнчәчне мактарга тотынды: ул акыллы да, ул булган, тик менә тормышы гына ялгыз үтә иде, имеш.

—Ә бит кызны ярминкәдә сайлагандай сайлап тапкан,—дип куанды әби.—Хәзергеләр арасында мондыен таба да алмассың. Миңа хәзер үлсәм дә була. Бу балакаемны кайгыртасым калмады.—Әби карчыкларча туптуры итеп Валядан сорады:—Яратасыңмы аны?

Урысча ачык йөз, кунакчыллык күрсәткән әби алдында Валя да тартынып тормады:

—Әйе. Яратам.—Шуннан ул башында туган хәвефле-житез уйларында чуалып калды. "Яратам" дигән сүз беренче тапкыр әйтелде бит, әле тормышы яңа башланып кына килгән шушы егетне чын йөрәгеннән яратканын аңлады. Үзе бит аның язмышына сорамый-нитми бәреп кергән иде— киләчәктә шатлыкка булырмы икән бу?

—Мин сезгә икона тотып фатиха бирәм. Карт бит инде мин. Янадан күрешербезме-юкмы? Анысын бер Ходай беләдер. Йөрәгем читлектәге кош кебек талпына...

Жирәнчәч белән Валя башларын иделәр. Мәрьям ана сурәтле иконаның бакыр кысасы аларның кайнар йөзләренә кагылып үтте.

—Менә,—диде әби.—Гел дә үзебезчә булды.

Соңыннан алар озаклап фоторәсемнәр тезелгән альбомнарны карап утырдылар: кечкенә Жирәнчәч, аның әти-әниләре, бабасы белән әбисе... Валя болар арасында кайчан да булса үзенә дә урын табылыр шикелле итеп тойды.

Жирәнчәч, унъеллыкны тәмамлаганнан соң, төзелеш һөнәрен сайлап алды: гади эшче-ташчы булып эшләде, техникумда укып чыгып, прораб булып китте.

Валя белән тормышлары тыныч кына бер эздән, үпкәләшүләрсез, низагларсыз гына ага торды. Әби үлгәч кенә кайгырышып алдылар, васыятен үтәп, аны тиешле йолалары белән жирләделәр.

Әбинең квартиры Жирәнчәчкә калган иде. Бераздан аны тәртипкә китерделәр, юдылар-жыештырдылар, үз иттеләр. Бер-берсенә дәрт-теләкләре кабынганда, Валя әйтмешли, еш кына шул "ояларына" килеп йөри башладылар. Анда инде, үсеп килүче балалар ишетүеннән курыкмыйча, сакланып-нитеп тормыйча, мәхәббәт ләззәтенә бирелә иделәр.

Кирза итекләр, брезент эш киеме дә киеп жибәргәч, үзе дә калынаеп киткән Жирәнчәчкә чын ирләр кыяфәте кергән иде. Бервакыт, ул төзелештә бетон плиталар күчертеп йөргәндә, аның янына, очып дигәндәй, тыныкөне беткән Валя килеп житте. Чәчләре тузган, битләренә кызыл таплар бәреп чыккан, үзе нык каушап калган.

—Син бушый аласыңмы?—дип кабаланып сорады ул.

—Алам,—диде Жирәнчәч, нәрсәдер булганын сизенеп.—Ни булды сина?—Ул, эшне күзәтүне урынбасарына тапшырды да, Валя янына килде. Алар якындагы бер кечкенә бакчага кереп утырдылар. Жирәнчәч баш киемен салып, тирләгән маңгаен сөртеп алгач, кабатлап сорады:

—Йә, ни булды?

—Митя исән! Мине военкоматка чакырып әйттеләр: аның умырткалары сынган, үзе хәрәкәтсез-телсез икән, шул хәлендә Валаам утравындагы госпитальгә озатканнар. Шунда янадан теле ачылган, ул табибларга үзенең кем, кайдан икәнлеген сөйләп биргән, гаиләсенең Ленинградта яшәгәнлеген дә әйткән. Военкомат белешкән: ул бөтенләй хәрәкәтсез ята, аны шул госпитальдә калдыра аласыз, әгәр теләсәгез, өй шартларыгыз мөмкинлек бирсә, алып та кайта аласыз, диделәр. Мин шундук тәвәккәлләп: "Алабыз",—дип ычкындырдым да, менә синең янга йөгереп килдем. Ничек телисең, шулай эшлә. Сина артык йөк йөклисем килми, гөнаһ булыр.

Жирәнчәч бер генә сүз әйтте:

—Алырбыз,—диде. Үзе гаилә өстенә табигый рәвештә котылгысыз кыенлыклар төшәчәген чамалап уйга калды.

Алар, икәүләп үз хисапларына юллама юнәттеләр дә, теплоходта Валаамга китеп бардылар. Юлда үзара бик аз сөйләшеп, һәркайсысы алдагы тормышы турында уйланып барды.

Теплоход Балтыйк суын ярып бара, офыкта мүкләнеп беткән зур-зур ташлар, йөзәр еллык наратлар, жимерек монастырь бинасы булган утрау

шәйләнде. Шул җимерек йортлар госпиталь икән, шунда үз-үзләренең кем икәнлекләрен дә оныткан сугышчылар—гарип-гораба мескеннәр көн күреп ята икән.

Валя белән Җирәнчәчне бер бүлмәгә алып керделәр. Анда аларны корышып беткән, такта кебек катып калган, чәчләре кырып алдырылган, тере мәет кебек бер кеше каршы алды. Ул аерым коммунистик диңгез батальонының элекке командиры Митя иде. Валя аны танымыйчарак торды. Аннары, керфекләрен челт-челт йомгалап, иренә ташланды да, кагылыр-гамы-юкмы дигәндәй, туктылып калды. Митя хатынын күздән кичерде:

—Шушында калдырырсыңмы?—дип ят, карлыккан тавыш белән сорады, ул инде күптән үзенең шушы язмышы белән килешкән иде.

—Ни сөйлисең син?!—дип кычкырып җибәрде Валя.—Менә без сине алырга килдек,—дип Җирәнчәчкә ымлады, үзе аның белән таныштырып та тормады.

Җирәнчәч санитарлар ярдәмендә Митяның җиңел гәүдәсен носилкага салды. Аннары носилканы Валя белән икәүләп күтәреп алдылар.

—"Үрдәк"не алырга онытмагыз,—диде Митя, башы белән битараф кына ымлап.

Носилканы теплоход палубасына кертеп куйдылар, үзләре аның янына чүгәләделәр. Пассажирлар палубаның аргы башына юнәлде, шунда көлешеп, шәраб эчеп, гармун тартырга, җырлашырга, кызларга бәйләнергә теләделәр булса кирәк.

Валя белән Җирәнчәч Митядан нәрсә булса да сораштырырга кыенсындылар. Ә ул күзләрен күккә текәгән, йөзе бераз хәрәкәтләнүеннән генә үзе белгән ниндидер уйларга батканын чамаларга була иде.

Менә ул Җирәнчәчкә күз төшерде дә:

—"Үрдәкне"...—дип үтенде. Аның, күрәсең, бәвеле тотмый иде.

Тегесе, ашыга-кабалана, саплы пыяла савытны уңайсызланып кына Митяга якынайтты, аны каплап, кечкенә йомышын үтәгәнен көтеп торды.

Ленинградка кайтып җиткәч, Митяны пристаньнан өйгә кадәр носилкасында күтәреп кайтырга туры килде, чөнки тораташ такта булып каткан гәүдәне трамвайга да, таксига да кертеп булмый иде.

Паша белән Коля авыру әтиләрен алып кайтачакларын белә иделәр, шуңа күрә носилка тирәсенә елышып, аптырап та, кызыксынып та, бөтенләй таныш түгел кешене күзәттеләр.

—Балаларммы?—дип сорады Митя, бер мизгелгә генә күзләрен йомып.—Икесе дә минекеләрме?

—Әйе, әйе,—дип кабаланды Валя.—Игезәкләр!

Юлда чиксез арган-йончыган Митяны ана уңайлы булган киң ятакка салдылар, ә Павел белән Николайның кроватьларын аның янәшәсенә, кухняга керә торган аралыкка сыйдырдылар.

—Соңыннанрак җайларбыз әле тагын,—диде Валя.

Җирәнчәч кунарга әбисе фатирына кайтып китте. Икенче көнне иртән килгәч, Митяның гадәттәге сүзен ишетте:

—Бераз ашыга төшсәң икән. "Үрдәкне"...

Җирәнчәч, авыруга булыша алуына куанып, ярдәмгә ашыкты.

Беренче көн ыгы-зыгы беләнрәк үтте. Валя әле ялда иде, ул ирен ашатты, бер сүз дә дәшмичә, озаклап янында утырды, сорауларын көтте.

Сорау тиз яңгырады:

—Егет белән яшисеңме?—дип кистереп бәрде Митя.

—Әйе,—Валя төкереген йотып куйды.

—Дөрес эшлисең. Мин хәзер бернигә яраксыз тере мәет. Ә ул әле яшь күренә, төртмәле дә түгел шикелле.

—Түгел,—дип раслады Валя, үзе җиңел сулап куйды.—Сиңа кәгазь килгән иде бит... "Югалды" дип...

Митя бер сүз дә әйтмәде. Аннары бераздан сорап куйды:

—Мине күпме карарсың икән?

—Гомер буе,—диде Валя ихластан.—Жирәнчәч безнең гаиләкешесе ул.
—Дөрес,—диде Митя тагын күзләрен йомып.—Мин хәзер бернигә дә яраксыз...—дип баягы сүзләрен кабатлады.

Бер атнадан соң, Жирәнчәч “үрдәк” китергәч, Митя:
—Утыр әле,—дип үтенде.—Син бу йортта хуҗа. Ә мин фатирда торучы кебек кенә. Валяга әйт, минем белән аерылышырга гариза бирсен. Язылышырсыз.
—Нигә алай?—дип аптырап калды Жирәнчәч.—Болай да яшәп була ич әле.
—Ярамый,—диде Митя.—Балалар үсеп килә. Алар икебезнеке дә. Мина дөнья сасытып күп яшисе калмаган, үзең күреп торасың...
Дулкынланган-каушаган Валя, иренең ихтыярын үтәп, контордан-конторга чапты, аңлатты, ниндидер кәгазьләргә кул куйды, Жирәнчәчне алып барып та күрсәтте—янәсе, менә ул нинди. Контор-кәнсәләрдәге хатын-кызлар да аны гаепләмәде, төртмә сүзләр әйтмәделәр, кайгысы өстенә бәхет тә килгәненә куаныштылар, киңәшләр биреп, кәгазьләренә кул куйгач, загска җибәрделәр:
—Әйбәт хатын син, гарип иренне дә алып кайткансың. Ә Жирәнчәчең әнә шул игелек-изгелекләреннең әҗере ул сиңа,—диде загс мөдире, шундук аларны язылыштырып та куйды. Валя түзмәде, загс бүлмәсендә үк елап җибәрде, чөнки күңелендәге икеләнү-шикләнүләре бик озак тинтерәткән иде бит.
Ә бередә бөтенләй чит-ят мөдир, Валядан өлкәнрәк, тәҗрибәлерәк булгангамы, мәсьәләне әнә ничек тиз хәл итте дә куйды.
Туй кәмәле дә үткәрделәр. Митя караваты янында ук. Павел, Николай, Валя һәм Жирәнчәч.
—Син мина лимонадка берничә тамчы шәраб тамыз, табиблар аны катгый тыйдылар тыюын. Әмма берничә тамчыдан гына зыян булмас. Без дә бит кешеләр!
Митяның соңгы сүзләрен бигүк аңлап бетермәделәр, шулай да, чәкешеп, эчеп куйдылар. Соңыннан Митя, тиздән мәңгелеккә күчәсен сизенгән кебек, васыять шикеллерәк итеп әйтте:
—Миндә бер көнләшү хисе дә юк. Балалар да синеке, Жирәнчәч. Ә мин озакламый аяк сузармын инде. Кая инде миңа хәзер...—Ул бу сүзләрен шундый ышандырырлык итеп әйтте ки, берсе дә аңа каршы төшә алмады. Валя исә аның лимонадына тагын өч тамчы шәраб тамызды.

Ләкин йортка борчу керде—Жирәнчәч өйдән югалып-югалып тора башлады. Үзе авыз ачып бер сүз дә дәшми. Павел белән Николайны Митяга “үрдәк” бирергә генә өйрәтте. Ул инде кичке ашка да кайтмый, Валя белән дә йокламый иде.
—Менә шулай, Митя, Жирәнчәч белән аралар өзелде шикелле. Үзенә яр булырлык берәр кыз тапкандыр, күрәсең...
—Соң, ул синең ирең бит... Сөйләшеп кара...
—Әй!—дип кул гына селкеде Валя.—Анысы аның кешеләр өчен генә бит.
Тугызынчы Май—Җиңү көне килеп җитте. Жирәнчәч бер күренде дә тагын чыгып югалды. Валя газаплана, дөреслекне белүдән курка: “Кемең бар синең?”—дип сорарга да кыюлыгы җитми.
Тугызынчы Майга каршы төндә дә кайтмады ире. Ә иртән сәгать җиделәр тирәсендә, шалтыр-шолтыр килеп, җыела торган тимер арба күтәреп кайтып керде.
—Митя өчен,—диде.—Слесарь Ванька белән ясадык. Бүген Митя безнең белән бәйрәмгә чыгачак...
Валя түзмәде, аның муенына ташланды, елый-үбә, сүзләренә тыгыла иде ул:
—Димәк, мине беркайчан да ташламаячаксың?
—Билгеле, беркайчан да. Әле тагын да ныграк ярата төшәрмен,—дип, Жирәнчәч аның чәчләреннән сыйпады, шунда берничә чал бөртекләр дә күреп алды, ләкин бу хакта ләм-мим бер сүз дә әйтмәде.

Митя исә шатлыгыннан нишләргә белмәде:

—Орден-медальләремне түшемә кадагыз. Гвардия билгесен дә...

Аны өйдән носилкасына салып алып чыктылар, теге тимер арбаның арты бөгеп эшләнгән иде. Митя бераз гына күтәрелгәндәй итте, аны арбага күчерделәр. Бәйрәмгә куанычлары йөзләренә чыккан халык арасыннан, кызыл байраклар җилфердәве астында аны тартып алып та киттеләр. Митяның пинжәгендәге орден-медальләре күнелле чыңлый, ветераннар үзен елмаеп сәламли, аларның да орден-медальләре чыңлап ала иде.

Алар Ленин исемендәге паркка кадәр бардылар, шунда бер буш эскәмиягә утырдылар. Митя яңа тәртеп чыккан яшел үләннәргә комсызланып-сокланып карый, чыркылдашкан кошларны тыңлый, киенгән-ясанган халыкны күзәтә.

—Әнә шулай да Жиңү безнеке! Безнеке бит, аңлыйсызмы? Мин дә, имгәтелгән, яраланган командир, үзебезнең Генералиссимус байрагы астында барам. Шулаймы?

—Шулай, Митя, шулай!

Ул куанычлы тәэсирләреннән бик нык талчыккан иде, әмма сүзсез бәхетле йөзендә һаман да елмаю иде.

Митя кайтуга йоклап китте. Бик озак йоклады. Икенче көнне дә аны уята алмадылар. Аның кулына кагылган Валя куркынып читкә атылды, Митяның кулы калай кебек сап-салкын иде инде.

Каберe өстенә тәре куеп җирләделәр аны, нигезенә кызыл йолдыз да беркеттеләр, чөнки ул һәрвакыт махсус коммунистик диңгез батальоны командиры булуы белән горурлана иде бит.

Валя белән Җирәнчәчнең дә тормышлары, миллионлаган совет кешеләренеке шикелле үк, бер эздән җай гына тәгәри торды.

Җирәнчәч инженерлыкка укып чыкты, ә Валя исә тәки үзенең трамвай-троллейбус паркындагы эшен ташламады.

Павел белән Николай да үсеп җитте. Берсе әтисе юлыннан китте—инженер булды.

Ә Николай, Дипломатик Академияне тәмамлагач, Бельгиядәге СССР Илчелегенә эшкә тәгаенләнде һәм әти-әниләренә шуннан еш кына әле тегесен, әле монысын җибәрә торды.

Җирәнчәч тагын да калынаеп-авырaeп китте, аның уттай янып торган чәчләре уна төште, пеләшләре сизелә башлады. Борыны да киңәебрәк киткәндәй булды.

Валя үзен яшь кызлар нәзбереклеге-пөхтәлеге белән карый, косметика кабинетына йөрергә дә акча кызганып тормады. Ул ябыга төште, һич тә илле биш яшьлек калынайган хатыннар чалымы юк иде үзендә, киресенчә, тагын да зифарак күренә башлады ул.

Ә Җирәнчәчкә кырык биш яшь тулды. Алар шау-шулы мәҗлесләрне яратмыйлар, шуңа күрә бу вакыйганы да, бер-берсе белән ашыкмый гына сөйләшә-сөйләшә, икәү генә билгеләп үттеләр.

Әмма бу көнне көтмәгәндә генә Валяның эченә корт керде, йөрәге, нәрсәдер сизенгәндәй, борчылып-шөһбәләнеп тырпылдый башлады. Ул каршысында утырган Җирәнчәченә текәлеп карап торды: "Тәмам өлгереп җитте бу ир!"—дип пошынып уйлады. Иренең шакмаклы күлмәге астындагы мускуллары уйнаклап тора, бераз май куна башлаган киң күкрәге көч-куәтен сиздереп бер күтәрелә—бер төшә, зур башы әле бер якка, әле икенче якка борылгалый иде.

"Китәр! Китеп барыр инде хәзер! Аның чәчәк атып утырган каендай яшь хатын-кыз тәнен бөгәр-сыгар чагы җитте, мин ана хәзер нигә кирәк, ди. Ул кемнендер аз гына ачылып, дерелдәп торган иреннәренә хисләнеп сөлектәй кадалыр, үзен дәртсендереп әле кул тимәгән берәр яшь тәнне иркәләр. Никадәр гомер бергә үткәргән булсак та, мин аңа ниемә кирәк? Ул хәзер шау чәчәктә кебек, ә минем, ничек кенә үземне сакларга тырышсам

да, чәчәгем коелып бара бит инде. Мин аның өчен гадәтләнелгән бер хатын гына бит...”

Ул моң-сагыш тулы күзләрен иренә текәгән килеш катып калды, Жирәнчәч бу карашны сизенде:

—Йә, нәрсәдән риза түгел син?—дип сорады.

Хатыны тумыштан килгән гадәте буенча ярып салды:

—Хәзер син миннән китеп барырсың инде. Мин сине менә дигән ир итеп өлгерттем, синдә шундый көч-куәт ташып тора, теләсә кайсы хатын-кызны бөгеп кенә салырсың... Тормыш кануны шулай ул!

Жирәнчәч үз гомерендә беренче тапкыр аңа жикеренеп кычкырды:

—Юләр!

Ул урындыгын бәреп жибәрде, өстәлне әйләнеп чыкты да, Валяны жилкәсеннән тотып шундый итеп жилтерәтте, хатын күтәрелә төшкәч, бәйрәм күлмәген умырып төшерде, идәнгә шылтырап төймәләр коелды. Куркынып үзеннән ычкынырга азапланган хатынын урын өстенә атып бәрде, иреннәре белән аның ачылып киткән күкрәгеннән тәртеп торган һәм бүртенгән “йөзем жимешләренә” сак кына кагылып узды. Гадәттәгечә түгел, ә нииндидер ярсу бер көч белән аны изә-сыта башлады, хатыны әллә бәхете ташудан, әллә авыртынудан, әллә бәреп чыккан дәрт-теләгеннән татлы ыңгыраша гына иде...

—Йә, нәрсә, “китәрменме”?—дип, Жирәнчәч тимердәй каты тәне тыныбрак торган арада әйтеп куйды:—“Китәрменме”?—ул хатынын кызганусыз-нисез һаман да изә иде әле.

—Сөеклем...—дип кенә әйтә алды Валя.—Сөеклем... беркая да... үлгәнче бергә...

Еллар үтә торды. Алар әле һаман да бер-берләренә якынайганнан-якыная гына баралар шикелле иде. Кайчандыр дулкынландырып-борчып торган яшь аермасы үзеннән-үзе эреп бетте, ул буш бер нәрсә булып кына калды.

Мин Жирәнчәчне байтак еллар күрми яшәдем. Көннәрдән бер көнне халык арасында ул мине үзе туктатты.

—Синме бу?—дип гажәпләнде ул, әйтерсең, мин инде жир йөзендә бөтенләй булмаска тиештер кебегрәк итеп кенә.

—Син?—минем дә гажәпләнүем аныкыннан ким түгел иде.

Без, бер-беребезне бүлдерә-бүлдерә, иптәш сыйныфташ укучылар турында истәлекләргә биреләдек: хәзер кем кайда икән, ә?

—Исәнлегең ничек?—дип кызыксындым мин, ниһаять.

—Үгез кебек!—дип мактанды Жирәнчәч.—Миңа ни-нәрсә булсын. Ә син ничегрәк?

—Миңа төрле авыру-чирләр эт кебек ябышырга гына тора. Менә йөрәк тә шаярта башлады хәзер...

—Шәп түгел,—диде күңелсезләнгән Жирәнчәч.—Мин кайвакытларда син язганнарны укыштыргалыйм, зур кеше булдың бит, ә үзең “йөрәк” дисең. Элегрәк очрашкан булсак, мин сиңа авырмаслык бер киңәш бирер идем дә...

—Ә ничек итеп?—дип кызыксындым мин.

—Бик гади ысул ул. Гомерең буе бер хатынны гына яратырга кирәк. Башка берәүгә дә карамыйча, чәчелеп-түгелеп йөрмичә. Гомерең буе...

—Синең шулай килеп чыктымы?

—Күреп торасың ич!

—Әйе, сиңа бәхет елмайган. Көнләшәм. Тик менә сине соңга калыбрак очраттым шул, Жирәнчәч!

*Марс Шабаев тәрҗемәсе.*



## Дифгат Сирай

### УТЫРЫП КЫНА ЯҢГЫР ЯВА...

*Бу бәйләмдәге шигырьләр мәрхүм шагыйрь Дифгат Сирайның иҗади мирасыннан алынып, аның 70 еллыгы уңае белән тәкъдим ителә.*

*Дифгат Сирай Татарстанның Алабуга районы Камай авылында туган. Шунда урта мәктәп тәмамлагач, Совет Армиясендә хезмәт итә; аннары Минзәлә, элекке Калинин район газеталарында эшли; партия райкомы инструкторы, колхоз парткомы секретаре була. Читтән торып Алабуга педагогия институтын тәмамлагач, мәктәптә балалар укыта; 1965 елдан Балтач район газетасында җаваплы секретарь, аннары редактор булып эшли. Мәскәүдә Югары партия мәктәбендә укып кайткач, ул озак еллар дәвамында—вафатына кадәр "Социалистик Татарстан" газетасында бүлек редакторы вазифасын башкарды (Д. Сирай—1985 елда вафат булды).*

*Шигырьләре—башта район газеталарында, "Татарстан яшьләре"ндә, "Үсү юлы" альманахында һәм "Яшьлек таны" исемле күмәк җыентыкта басыла, 1967 елда "Тан сызыла" исемле беренче мөстәкыйль китабы дөнья күрә. Аннары—"Саумы, тормыш" (1968), "Кушнарат (1969), "Кыяларга үзем менәм" (1972), "Кеше турында җыр" (1974), "Мәхәббәтем" (1983) исемле китаплары басылып чыкты. Вафатыннан соң, лирик шигырьләре "Туган як җыры" (1987), юмор әсәрләре "Тәрәзәгә чиртер мизгел" (1986) кебек күмәк китапларда басылды.*

*Дифгат Сирай—авыл, табигать, туган як һәм үз чорының гади кешеләрен җырлаучы житмешенче еллар шагыйре иде—укучыларыбыз моны бу бәйләмдәге шигырьләреннән дә яхшы тоячак дип ышанабыз.*

**Хәтәр җилләр, шаулы диңгезләр,**
**Зәңгәр күкләр, үткен кыялар,**
**Илләр, гөлләр, чыклар, болытлар—**
**Ничек болар җиргә сыялар?!**

**Сөю, көю, шатлык, сагышлар,**
**Кайнар яшьләр, татлы тойгылар,**
**Сугыш, үлем, ачлык, мохтаҗлык—**
**Бер йөрәккә ничек сыйдылар?!**

Гомерендә шундый сорауны
Бирмәгәндер нинди ир генә!
Сыйдыра бу йөген дөньяның
Кеше генә, изге җир генә.

⊠

Утырып кына яңгыр ява,
Урам иңләп көтү кайта:
Сыер, сарык, кәҗә атлый,
Тездән сазга бата-бата...

Утырып кына яңгыр ява,
Мунча керә олы-кече:
Чаж-чож килеп, аркаларда
Уйный каен себеркесе...

Утырып кына яңгыр ява,
Авыл йоклый—арыгандыр...
Кургаш яуган еллар булды,
Тыныч кына яу син, яңгыр!
Утырып кына яу син, яңгыр!

## Тал

Синең белән буй сынашып үстем,
Болытларга килде җитәсем.
Ямансулап бүген карап торам:
Күптән мине узып киткәнсең.

Күккә таба һаман сузыласың,
Галәмгәме әллә үрләвең?
Кырык елдан артык вакыт узган,
Уңмаган бит хәтта күлмәгең.

Элеккечә һаман ямь-яшел син,
Шуңа ахры мине моң сарган:
Язлар саен син гел яшәрәсең,
Ә мин язлар саен... агарам.

## Көн кузгалган

Көн кузгалган олы сәфәргә,
Сакка алып кояш нурларын.
Алып килә үзе белән ул
Чәчәк исен, тургай җырларын.
Саргылт дулкыннары арышның
Йөгерәләр аның артыннан.
Каеннарын яшел урманның,
Наратларын монда чакырган.
Саф җилләре белән килә ул,
Агач яфракларын тирбәтеп.
Килә җиргә горур басып ул,
Бөтен яктылыкны ияртеп.
...Көн кузгалган изге сәфәргә,
Кешеләр дә юлда гомергә.
Омтылалар җирдә алар да
Яктылыкны күбрәк күрергә.

■

Җир өстендә яшел нарат ята,
Ботакларын җәеп як-якка.
...Нарат кебек күпме егет ауган,
Һөҗүмнәргә барган вакытта.
Күпләр кабат аягына баскан,
Кабат яу өстенә ташланган...
Җир өстендә япь-яшь нарат ята,
Давыл аның башын ашаган.
Ә шулай да тамырлары исән,
Җирдән йолкып ала алмаган.
Шул тамырлар, гүя, тартып аны
Торгызырлар кебек яңадан.

■

Нинди юлларны урап кайтсам да,
Нинди каладан кайтсам да йөреп,
Басу юлыннан киңе юк кебек,
Безнең авылдан зуры юк кебек...

■

Адымнарың, дисең, ипле чакта
Дус-иптәшкә кытлык һич тә юк,
Абынганда, егылганда ләкин
Таянырлык терәк—җилкә юк.
Андый чакта тик үз йөрәгеңә
Таян, диләр, таян, хак булса...
Тик син үзең ышанычлы терәк
Булырлыкмы, кем дә абынса?

■

*Татар хикәяләре хәзинәсеннән*

## Газиз Мөхәммәтшин

# ИКЕ ӘБИ БӘРӘҢГЕ АЛА...

Сентябрь азаклары. Кояшлы, җылы көн. Ике әби яулыкларын арттан гына бәйләгәннәр, бишмәтләрен салып көнбагышка элгәннәр, чүлпыларын чылтырата-чылтырата, ашыкмыйча-кабаланмыйча гына, үз җайлары белән генә бәрәңге алалар.

Әбиләрнең берсе җитмеш биш яшьтә, икенчесе аңардан яшьрәк—җитмеш бердә генә. Алар казыган бәрәңгене сиксән биш яшьлек бабай ындырдан ишегалдына ташып тора. Ул лапас капкаларының икесен дә киереп ачып куйган. Капчыгына өчәр чиләк бәрәңге сала да, җилкәсенә күтәреп, сукмак буйлап кайтып китә. Шулай әкрен генә әйләнеп, әбиләр белән өй арасында йөри дә йөри. Әбиләр белән сөйләшми. Тегеләре бертуктаусыз «ләчтит сатсалар да», тукта, ни сөйлиләр икән, тыңлап карыйм әле, дими. Бәлки, тыңлар да иде—ишетми. Колагы катыланганга унбиш еллап бар инде.

Ә безнең колаклар, Аллага шөкер, ишетә бит әле. Шулай булгач, әйдәгез, бу форсаттан файдаланып, әбиләрнең сүзен тыңлап карыйк...

Яшь әби, «эһ-эһ» дип, көрәгенә ике-өч тапкыр баса да, бәрәңге төбен актарып чыгара.

—И Алла, бигрәк тирәнгә утырткансыз быел. Моңа көч тә җитмәй, беләксез калырсың, исәркәем. Бәрәңгесе булса ярар иде тагын. Гупчим юк бит. Безнең бәрәңге кер беләге хәтле. Былтыргының яртысы да чыкмас моннан.

Карт әби көнбагыш тамырына көрәге белән бәргәли.

—Чыкма-ай. Менә бит, бигрәк юк бит. Бәрәңгемени бу! Әле аның да яртысы җиргә күмелеп кала.

—Тырмаларсыз инде. Сонга таба. Эш беткәч.

—Миннән булмый. Җизнәң караса карар. Без үзебез җизнән белән аена бер пот бәрәңге дә ашамыйбыз. Малга, кош-кортка ашатып бетерәбез. Көн дә иртән казанга ике бидрә бәрәңге салам да, шуны төеп, көрпә белән болгатам, көрпә булмаганда он салам—шулай итеп ашатабыз.

—Нәмәкәйгә интегәсез шул хәтле? Бер кортка белән бер картка күп кирәкмени? Бик интегеп ятар идем мин булсам! Малайларым, кызларым җибәргәнне тик ашап ятар идем рәхәтләнеп бер дөньясында.

—Мал асрамый ничек яшәйсең! Ни белән дөнья көтәсең! Чәркә күтәреп көн дә кешедән сөт сорап йөрерсеңмени, исәр? Без гомер буена малсыз тормадык, Аллага шөкер. Абзар тутырып сарыгын асрадык. Икешәр сыер сауган чаклар булды. Аның янында тагы танасы, бозавы. Сугыш вакытында

да ниндәен нәрәт кайтса, иң башта безгә килеп керделәр, бездән алдылар. Жизнән Сталинград фундына гына да дүрт сарыкны житәкләп китте.

—И түтәй, кичә син үрдәк тазартып йөргәндә, яңа гәжит кайтты. Жизнәй укып күрсәтте. Япун белән Кытай ягында әле дә бик каты сугыш бара икән.

—Әмерикәнме?

—Әмерикән. Шул тагын бик нык сугыша икән. Бер бәләкәй генә Вьетнам дигән халыкны буйсындырам, дип әйтә ди. Сез кайчан да булса барыбер минем кул астымда булырсыз, дип әйтә ди, мөртәт.

—Ходай күрсәтмәсен! Бәләкәй халыкка рәт юк бу дөньяда. Алла ярдәм бирсен мескеннәргә! Бу Әмерикәне дә яшь әтәч кебек сугышырга кыҗырай да тора, кыҗырай да тора. Өендә тыныч кына чәй эчеп утырса ни булган!..

—Беләмени алар чәй тәмен! Ул якларда иртән торсаң—куфи ди бит... Кара әле жизнәкәйне. Нәмәгә безгә карап торасың, жизнәй? Әзрәк ял итеп ал!

—Мине сөйләми микән болар, ди инде. Аңларга тырыша. Юк, юк, сине сөйләмибез—сугышны сөйлибез, сугышны. Сугышлар булмасын, тынычлык, иминлек белән яшәргә язсын, дибез. Сиңа әйтәм, син бар, кер, чәй эчеп чык. Самавыр суынмагандыр әле, яңа гына гөжләп утыра иде.

—Бер үзе эчмәй бит ул.

—Ю-ук! Эчерерсең аны! Мин кич ашка китәм. Самавырга күмер салып кайнатып китәм. Эч тә ят, интегеп утырма, йокла, димен. Тәки мине көтеп утыра. Нигә мин бер үзем чәй эчеп ятаем, дие. Менә дивана түгел диең син аны.

—Дивана булыр ул! Күңеле тартмый. Нишләп ялгыз башы чәй эчеп утырсын. Илле тугыз жыл бергә яшәп, бер түшәктә җоклап, икегез бер кешегә әйләнеп беткәнсез инде. Ходай тагын гомерегезне бирсен. Ул балаларыгызны әйтәсенме! Берсеннән-берсе унган, берсеннән-берсе тәүфыйклы, берсеннән-берсе олы урыннарда эшлиләр. Миннән булмады инде. Утыз яшьтән ятим калып. Укыта алмадым. Үзләре дә ялкау булды, каһәр суккан нәмәкәйләр. Мин укыр китте диеп торыр идем, ул кибән артында тәмәке тартып ята ие, иптәшләре кайтканда гына шуларга ияреп кайтыр ие, бер нәмәкәй дә булмагандай күзен тондырып, инә-әй, үләм, корсагым ачты, давай, ашарга бир, диеп. Имансыз! Менәтерә бүгенге көндә бозау көтеп йөри үз башын үзе кадерсез итеп. Укыса, зур урыннарда эшләмәс идемени? Өстәл башында тилефүн чылтерәтеп кенә утырыр ие. Үзе кешеләрне кушып...

—Нахак бәлаләр тагасың. Бик әйбәт эшләй бит. Тагын ни кирәк? Эчмәй. Катын-кыз, димәй, азмай-тузмай.

—И түтекәем, анысына мең шөкер итәм инде. Намаз артларында теләем, катын-кызлары аның хәзер катын-кыз төслемени? Заман ахыры житкәндә, ире, катыны хайван суратенә кереп бергә йөрер, дигән сүзләр дөрескә килдеме—килде!

—Килми ни! Менә минем Акбай киленен ал. Югыйсә, карап торуга акыллы гына төсле бит инде, укыган кеше дә. Былтыр шуларның Кәме буендагы дачаларына бардым. Анадан тума шыр-шәрә тик йөри. Ике төшенә тар гына ике чүпрәк каплаган. Карап торсаң—адәм тәганәсе менә! Тефү, тефү, ташка үлчим. Төшенә керә күрмәсен. Киленкәем, дидем, ник болай йөрисең адәм араларында оялмаенча, дидем, әллә күлмәккәйләрең юкмы, ана бит—күзең күрмәймени—күпме ирләр йөри тирә-ягында, дидем. Бар тизрәк, кеше-кара нәгаләт укыганчы, өстенә киен, дидем. Әллә мина кояшта кызынырга да ярамыймы, диеп мыгырданып такта өйләренә кереп китте. Менә, исәр, күрәселәрең булса, күрәсең аны. Картайгач та күрсәтә.

—Шулай булмай, түтекәем. Әйттенме соң, без яшь чакта бер дә шәрәләнеп кызынып ятмадык, дидеңме? Өстә чүбек жебеннән үзебез сугып кигән күлмәк-ыштан, аякта тула оек белән чабата булыр ие, кулда—йон беләкчә, башта—төшереп бәйләгән яулык. Шуның белән көн буена кызу кояшта урак урасың бит әле, инәкәеннен башыкае, бала имезәсең. Анысы бакырып чүмәлә төбендә ята. Кайда ул кояшта кызынып ятулар! Ә хәзер ирәяләр, түтекәем, авызларына бөтен нәрсәне хөкүмәт каптыргач. Шулай ирәя, шулай бозыла бала-чага.

—Сабан туеннан соң, әбекәем, бабыкаем, бик сагындым, дигән булып Нәфиганың олы кызы Хания кайтып киткән булды бит әле. Инде дүрт-биш ел кайтканы юк иде. Менә шул адәм рисвае итеп китте бит, имансыз нәрсә. И Илаһым, җизнәңнең дә, минем дә нирвыларыбызны калдырмады, исәркәем. Төн буена капка төбендәге утыргычта утырып чыгалар. Иртән мин кәҗә саварга торгач кына кереп ята. Күлмәккәе бөтенләй юк диеп әйтерлек—арт йомрыларын да капламаган, ристаннын. Җизнәң шуны күрде дә кайтып керүенә эт итеп сүкте. Алланың каһәре суккан нәрсәкәй, әбиең белән бабаңны картаймыш көннәрендә бөтен авылга рисвай итәргә кайттын-мыни күзенне-башынны тондырып, дие, менә әпекәйдер! Самавыр да куя алмыйсың, идән дә юа алмыйсың, бер нәмәкәй дә эшләй алмыйсың бит, иелдеңме—шәрәң күренә, болай йөремә минем алдымда, кайтып кит бүген үк, намаз артыннан каргармын, дие.

—Ә үзе нәмәкәй дие шуннан соң җизнәкәйнең сүзенә каршы?

—Нәмәкәй дисең! Хәзер жегерменче вик, дие дә тора, имансыз.

—Вик дигәне нәмәкәй микән соң аның? Әллә ниткән пулитик сүз булмасын.

—Белмәем. Сорарбыз әле. Көчкә кайтарып җибәрдек. Инәсеннән хат килде. Картая-картая котырып беткән икән наше дедушке, диеп кайтып әләкләгән.

—Аларны әрләп тә, кыйнап та булмый хәзерге вакытта. Суксаң, хәзер бакырып кәнсәгә чабалар. Закун үзе шулай дип тора.

—Бабалары шикелле җитмеш җыл дөнья көтсәләр, ни әйтерләр ие микән? Бабай дүрәк түгел, акыллы—без үзебез дүрәкләр, диеп әйтерләр ие нибуч.

—Карале, түтәй, шушы атнада Әзәрбәйҗанга да илле яшь тулган дие. Радио әйтте.

—Кайсы ул тагы?

—Теге... бар бит әле тау халыгы. Нифтене дә бик күп чыгарган җир. Минагратлы як. Кафиянең кызы шуннан бер тартма минаграт җибәргән иде бит. Килгәнче череп беткән—утынлыкларына чыгарып түктеләр...

—Ә-ә-ә, аны әйтәсең икән. Дәүләт булып оешуларына илле җыл булган шул. Шул көнгә хөкүмәт бурычларын да үтәп бетерделәр, дие, укытучы әйтә.

—Телевизор да сөйләгән ди бит.

—Нигә аны тиле диделәр икән соң? Хәтәр акыллы сүзләр сөйләй бит ул.

—Син әле ниең әйт, пучтыга кереп тиле грам сугыйм, дисәң, анысы тиле. Челтерәтәем, дисәң тиле фуны—тагын анысы да тиле.

—Бала-чага куша инде аны, юри, мыскыл итеп. Үзләрен генә акыллыга чутлап йөри бит алар.

—Шулайдыр ул, түтәй, чыннан да. Быелтыр—Оркыяларга барып ай ярым торып кайттым бит. Шунда моның мин барган көнне үк ярты миске сөтле ашы калды. Җылытып бирсә, үзем дә ашаган булыр ием, әрәм итмәсием. Ә үзем гәзләрен бора белмәдем, курыктым. Эштән кайтты да шул ярты миске ачымаган-нитмәгән менә дигән тәмле ашны түәлит дигән бүлмәләренә керде дә гөпердәтте дә тишеккә салды. Кызым, дидем, мин бу түәлиткә керергә бүтән йөрәгем җитмәй, моннан бүтән тишегенә дә утырасым юк, дидем, аш өстенә утырсаң, корышып катарсың, давай миңа билет ал, килгәндәге шикелле тәкси дигән машина чакырт, минут тормаем, хәзер үк кайтып китәм, дидем. Менә бит, диванакай, гәзне борала бит ул. Җылытып бирсә, үзем ашаган булыр идем. Ә Оркыя көлә, аңа көлке. Инәй, кайгырма, ул токмачлар әллә кайчан Кәмегә агып китте инде, дие. Беләсеңме, түтәй?!

—Белмәй ни! Безнең киленнәр дә шулай. Әй ташыйлар мәхәзиннән ситке-ситке, сумкы-сумкы нигъмәт. Калбасасын, балыгын, прәннигеен, маен-шикәрен, җимешен, төрле-төрле кәнсирләрен. Аша, әнкәй, дигән булалар. Аша, диюләренә рәхмәт инде. Яртысын ашап каламмы-юкмы, кич кайталар да калган барын җыеп, каткан инде болар, диеп, тыштагы тартмага чыгаралар да түгәләр. Үзләре тагын ситке тотып мәхәзингә чыгып китәләр. Ә ул калган продухтыга ни булган? Аны миңа ашарга ярамыймыни? Элек ярты сынык әпекәй күрмәенчә ачка интегеп яткан чаклар да була

иде, дип сөйләсәң, берсе дә ышанмый, көлә генә. Дөньяда шундый тормыш буламыни, әкият бу, әбекәй, диләр.

—Карале, түтәй, әкият, дигәннән, безнең рәкит айга менеп кесәсенә ком салып алып төшкән, дие. Син ишеттеңме?

—Ишетмәй ни! Кичәдән бирле бөтен радиу, тилевизер шаулап тора.

—Чыннан да шул нәрсәкәй дөрес микән?

—Ай ул бер нур гына бит. Анда ниндәй ком булсын?

—Рәките ничек менеп житсен, диең. Ничәмә-ничә млиун чакрым бит ул. Иге-чиге юк бит аның. Әбугалисина әфсенен генә өйрәнмәгән булсалар, һи-һи-һи...

—Рәкитесе менсә дә, кайда аның лумы балчык ватарга? Һә-һә-һә!..

—Лум белән ватып түгел—бораулап алган диләр, түтәй.

—Бораударга айда нинди борау булсын!.. Һә-һә-һә!

—Балчыгын учлап алсын ди! Кая ул рәкитнең кесәсе—балчыгын салырга! Һи-һи-һи-һи!..

—Язалар бит, сөйлиләр! Әкият!.. Һә-һә-һә!..

—Томаналар ышана инде аңа. Бала-чага гүпчим ышана. Тач шулай булган икән, дие... Һи-һи-һи...

Яшь әби белән карт әби, җир йөзендә теләсә нәрсәгә ышанып йөрүче беркатлы кешеләрнең булуына гаҗәпләнеп, үзләренең андый кешеләрдән акыллырак, хәйләкәррәк булуларына куанып, бәрәңге алуларыннан туктап, рәхәтләнеп кет-кет көләләр. Болар нигә көлә микән, шуны беләсе иде, дигән шикелле кызыксынып күзләренә карап торган бабайга да, берсен-берсе бүлдерә-бүлдерә, кычкыра-кычкыра, хәлне төшендереп бирәләр.

—Ә-ә-ә, аны сөйлисез икән. Рәкит айга барып кунып, ай туфрагын алып төште шул, төште,—ди бабай.—Анысы дөрес. Булдырып тора хәзерге халык, булдырып тора-а.

Шулай ди дә, капчыгына өч чиләк бәрәңге салып, кайбер урыннарында көнбагыш төпләренә абынгалап, лапаслар ягына юнәлә.

Әбиләр тагын сүзгә керешәләр.

—Сина әйткән идем микән, Айбикәнең түтәсе килеп китте бит әле,—ди карт әби, буразна арасыннан алабута чүпләштереп.—Мәсүфәсе Карамалы Күлдән.

—Юк әле, түтәй, ишетмәгән идем.

—Шул Мәсүфә беркөн безгә килеп утырды. Сарыкларны яңа гына ябып кереп ашка утырган идек. Нәмәкәй эшләп хәҗәйстуасын бер дә карамый ул Айбикә, дие. Бөтен әйберләре ватык та җимерек, дие. Сәгатьләрен җибәрәм, дигән идем—сәгатьләре йөремәй, тукмагына трахтыр тимерләре тагып бетергәннәр; тик утырганчы яулыгымның читен бөгеп алыйм әле, дисәм—машиналары текмәй, алганнан бирле май чырае күрмәгән, калтыр да колтыр, энәсе күгәреп беткән; ятып тораем, дисәм—караваты кәкшәннәп беткән, пружинасы янбашына кереп китте, дие; убырныйлары ун якка кыйшайган, дер-дер селкенеп, авып китәргә генә тора, хәзер басып үтерә бу мине, диеп куркып, кергән җиремнән кире чыгып йөгердем, дие, радиуларын сөйләтәем, дип борсам—сөйләмәй, эченә үрмәкүч оялап беткән; сикереп кенә менеп атланаем да урман буйларыннан бер чаптырып урап кайтаем әле, дисәм—лилсәпитләренең тыны чыгып беткән, дие. Менә, җүләр, ишетәсе колакларың булгач...

—Э-э-э, Мәсүфәнеке шикелле умарта гәүдә белән сикереп кенә радиуга менеп атланырсың? Җиде пот бит ул...

—Нишләп дөнья күтәргә тырышмый ул Айбикә, дие.

—Ничек көтсен! Бар тапканын малае талап алып эчеп баргач.

—Шулай шул. Аның бәләкәй кызы, бабакай, әбекәй, диеп гел бездә ята. Бөтен нәрсәләрен сөйләп бара. Әтәң кая китте, дисәң, Мөслимгә, дие. Нигә китте, дисәң, эчәргә, дие. Әтәң кайттымы, дисәң, кайтты, дие. Нишләй, дисәң, әбекәй белән талаша, дие. Нәмәкәйгә талаша, дисәң, эчәргә акча сорай, дие.

—Эчкән кешедә өмет юк инде. Убырнаең түгел, өең авып төшәр. Безнең

авылның да чын леснигы эчә-эчә алькожуликка әйләнде бит. Хәзер булнискә барып беләгенә укул кадатып йөри.

—Нигә эчмәскә, эчәм шул. Урмандагы агачларның һәр ботагы саен бер бүтилкә эленеп тора миңа, диеп әйтә диеп сөйләгәннәр ие—шулмы?

—Шул үзе. Катыным кеше белән йөргән сыман тоела. Шуны үтерәсем килә, диеп әйтә дие тагын. Ходаем, үзең сакла!.. Чамасын белеп эчәргә кирәк, чамасын белеп эчсәң—дару, белмәсәң—агу бит ул дөмеккере нәмәкәй.

—Мин аның пивасын үзем дә эчәм. Кунакка барган саен малайлар акча бирә. Мә, инәй, урамда йөргәндә рәхәтләнеп пива эчеп йөре, курыкма, монда синең белән ашка йөргән ахирәтләрең юк, диләр. Иплэп кенә урамга чыгам да берәр бакал пива эчәм дә кайтам. Килен сизми дә кала. Аларның фатиры парк дигән бакча янында гына. Шуның капка төбендә генә гел пива сатып торалар.

—Булса бик эчәр идек тә, монда кайтармыйлар шул пиваны...

—Кичә Мөсәянны эт урынына сүгеп кайттым әле.

—Бәрәч, нигә тагын? Бик акыллы малай, диләр бит аны.

—Амбар алдына барсам, янгыр коя. Амбар ишегалдында тау хәтле тары өелеп ята. Өстенә, ичмасам, салам да капламаганнар. Жырганак белән агып ята. Үзе каравыл өенә кергән дә утырган, кладавщик башы белән.

—Нәмә диде соң, син әйткәч?

—Бар, бар! Үбирәйс, кайтып кит! Дилаң булмасын монда, дие. Менә имансыз!

—Алланың каһәре суккан нәстә икән!

—Тәуфыйксыз! Әллә нәмә күреп үләр әле.

—Әпекәйнең кадерен белмәгән кеше—кешемени ул!

—Прсидәтелгә әйтәм әле мин аны. Әләкләде, дисә, дияр. Ник куркып тораем аннан, прсидәтел капка төбеннән үткән саен машинасыннан төшеп: «Нихәл, бабакай, нихәл, әби»,—диеп, кулын биреп исәнләшмичә китмәй. Бик нык әйтәм әле мин аны.

—Бәй, шулай булмай, тутәй. Әйт, бик ныклап әйт... Жизнәй эндәшә түгелме? Ә? Нәмәкәй?

—Бүген көндез чәй эчмәйбезмени, дие. Хәзер керәбез. Син кереп самавырынны гөжләтә тор. Менә бу буразнаны гына чыгыйк инде. Керә тор, керә тор, димен. Самавырны гөжләтә тор. Бар, бар!..

—Жизнәй дә картайган инде. Бакчый, жилкәләре төшкән, билләре бөкрәйгән. Алла гомерен бирсен!

—Картаймый инде. Яшең сиксән бишкә житкәч. Үзе шулай булса да би-ик көчле ул, исәркәем. Жәй көне тагын алты чана печән чапты. Ат сорап аны ташыды. Лапас түбәсенә өйде. Тамагына ашый бит ул. Аның менә гомер буена, ашказаным авырта, дип жүри дә әйткәне булмады. Ә менә холыгы үзгәрде, анысы бар. Картайган саен кешенең холыгы әшәкеләнә икән, хикмәт.

—Нирвыдан икән ул, тутәй, карт кешенең нирвысы бетә икән.

—Шулайдыр. Нирвысы бөтенләй юк инде аның хәзер. Син килгәнче генә әле мунча ягып кергәниек. И ләүкәдә утыра жизнәң, и чабына, и чабына. Эссе сал да эссе сал, дие. Янып үләсең бит инде, Ходаем, төш тизрәк, диеп кычкырам. Төшү исендә дә юк. Бер аягыма үтмәй, нишләп микән, син ныклап чабып карале, дие. Чабаем, дип карасам—бер аягының оегын бөтенләй салмаган, үтмәй дә үтмәй, диеп шул жон оегын чабып утырган. Аннан көч-хәл белән төште, хәер. Төшкәндә аягы шуып китте дә кайнар су салган бидерәгә утырды. Әллә-лә, үлдем, үлдем, баш бетте, диеп кычкыра. Мин бидерәгә кулымны тыгып торган булам, менә бит гүпче кайнар түгел, менә бит, дигән булам. Аннан көчкә коендырдым. Киенә башлады бу хәзер. Син ыштанны тар итеп тегәсең, сыймай, Алла бирсә, өч метр ситсы алам да Нажиягә илтеп киң итеп тектерәм, диеп жикеренә башлады. Кил әле, кигерт, дие. Кигертәем, диеп барсам, аягына күлмәген киеп утыра, бер жиңен ничек кирәк алай тезенә хәтле кигән, икенче жиңен бөтенләй кия алмый, тарта да тарта. Алланың каһәре суккыры, ыштан

балагын тар итеп гомер буена интектерден, дие. Аннан чыкты та, нирвысыннандыр инде, бал белән, лимун белән берүзе бер самавыр чәй эчеп бетерде. Мин эчәлмәй дә калдым.

—Нирвыдан, нирвыдан бу, түтәй. Безнең авылның Мөхетдин нишләде дисең кыш көне? Ул да, сугыштан нирвым бетеп кайттым, дие бит. Печәнгә барган да, печән төягәндә бер киез катасы аягыннан салынган да чыккан. Оегы да киез катасы эчендә калган. Шәрә үкчәсе белән карга тек-тек басып, чанасы артыннан көлә-көлә кайтып килгән була, дие, мескенкәй. Үзе шуны сизмәй, ди. Киез катасы лапасларында печән бушаткан чакта гына килеп чыккан. Менә бит ул, нирвың бетсә! Нәмәкәйләр кыланмый кеше!..

—Патпискәгә язылдыгызмы әле? Пучты кердеме?

—Керде. Килен быел бик күп язылды, әллә уноч, әллә унбиш тәңкәлек.

—Безнең жизнәң быел язылмады бугай әле. Әллә онытып йөри микән. Кәлиндәр дә кирәк.

—Әнә су буеннан бер машина килә. Балалар кайтмый микән?

—Кая? Ә-ә-ә... Юк, бу мәхәзингә товар китерә торган машина бугай, индийский чәй дә булса ярар иде... Балалар тилеграмнарында әйткәннәр бит, төштән соңгы самолетка утырабыз, дигәннәр. Ә ул сәгать уночтә генә килә. Кичсез кайтып житмәсләр әле.

—Мескеннәр, ниндәен ерак жирләрдән ел саен бәрәңге алырга кайткан булалар. Әтәйләр, инәйләр интекмәсен, дия торганнардыр инде.

—Шулай диләр. Бәрәнге дә утыртмагыз, мал да асрамагыз, диләр. Күпме кирәк булса да, акча жибәреп торырбыз, диләр. Интегүмени ул? Тән таза булганда әле, Аллага шөкер, бәрәңге дә утыртмай, печән дә чапмай, утын да кисмәй ничек ятасың дие. Жизнәңнең аның гомер буена утырып торганы юк.

—Син үзең дә шулай инде, түтәй—тынгысыз. Икегез дә бертөрле.

—Тынгысыз булмасаң, дөнья көтеп булмай бит.

—Әле менә бу бәрәңге соң! Балалар жүри шуның өчен бәрәңге алырга кайтабыз диеп тилеграм суккан. Кайтып керсәләр, шаккатып бот чабарлар инде, кайда бәрәңгегез, диярләр.

—Бәй, кем аларны көтеп тик утыра. Хәл кадәренчә кыймылдый тораек, диеп кенә тотынган иек тә... бер башлагач, әкренләп кими инде ул эш.

—Кимү генә түгел—хәзер бетә бит инде бөтен бакчагыз. Монда, күп булса, ындыр табагы хәтле жир калды.

—Әйдә, бик ару булды, Аллага шөкер... Аларга бәрәңге алдырып ятарга... Рәхәтләнеп ял итеп, туйганчы йоклап китәрләр.

—И-и-и, шәһәр халыгы тәк тә йоклап кына ята инде ул. Иртән торып сыер савасы, көтү чыгарасы юк. Эшләре дә сминәләп кенә.

—Шулай инде. Су да чыгып аласы юк бит аларның. Тоткасын бордисәң—үзе челтерәп ага... Карале тегене, жизнәңне... Тагын баскычка чыгып баскан. Мин каршысында утырмасам, тамагыннан үтми инде аның. Әйдә, хәзер чыгабыз инде бу буразнаны, хәзер керербез.

—Шулай итәек, түтәй, жизнәкәйне зарыктырмаек...

Көз. Көн кояшлы, жылы. Яулыкларын арттан гына бәйләгән ике әби чулпыларын чылтырата-чылтырата бәрәңге ала. Алар артыннан, суалчан чүпләп, кызыл кикрикле ак тавыклар ияреп йөри. Бакча башындагы күрән читендә оя-оя каз-үрдәкләр ял итеп утыра. Авылның югары очында туктук яна бура бурыйлар. Амбар алдында келтер-келтер бодай жилгәрәләр. Басу түрендә тракторларның жир сөреп йөргәннәре күренә, һавадан кыйгак-кыйгак кангылдашып, торрыйк-торрыйк торкылдашып, киек казлар белән торналар очып бара.

Күкләр тыныч.

Жирләр, илләр тыныч!

Тыныч жирдә, тыныч илдә ике әби бәрәңге ала...

*1967*

ИСКӘРМӘ

Газиз замандашның йөзеннән елмаю киткән чагын күргәнем булмады минем. Кешеләргә ягымлы-сөйкемле итеп елмаерга ярата иде ул. Мөлаем елмаерга исә шәхеснең үзенчә осталыгы да кирәк, ягъни елмая белү—бик тә үзенчәлекле осталык.

...1966 елның май азагында Балтач төбәгендә әдәби атналык булды. Язучылар, ике төркемгә бүленеп, район халкы белән һәр көнне икешәр-өчәр очрашулар уздырдылар. Атналык Балтач ягындагы иң зур авылларның берсе булган Янгул клубында йомгакланды. Анда атналыкта катнашкан һәр язучы сөйләде. Газиз Мөхәммәтшин кыска гына сүзендә:

—...Һәм кырык хикәя язганмын икән,—диде.

Моны ул гадәтенчә елмаеп әйтте, әйе, укучылары алдында имтиханын сөенечле елмаеп тапшырды әдип. Кызганыч, мондый имтиханнар тотуны еш кабатлый алмады, иҗаты колачын киңәйткәннән-киңәйткәндә арабыздан китеп барды Газиз...

1971 елның азагындарак «Чаян» журналы редакциясенә (мин шунда эшли идем) аның берьюлы дүрт хикәя китерүе хәтеремдә, шуларның өченчесен бастырганда, авторның исем-фамилиясен кара рамга алырга туры килде... Ә дүртенче хикәясе ул чакта басылмады. Мин аңа:

—Монысын бастырмаячакларын беләсең ич,—дигәч, Газиз, башын югары күтәреп, елмаюын ирләрчә чибәр йөзенә җәелдерә төшеп, хикәясен горуранә кире алды.

Бу биш бит чамасы әсәр Советлар илендә ясалган балалар уенчыкларының күпчелеге сугыш коралларына бәйле икәнлеге турында иде. Соң, «тынычлык сагында торучы» Советлар Союзының котырып кораллануы, балаларны, елмаюдан мәхрүм калдырып, сугышлы уйнарга мәҗбүр итүе турындагы хикәя Главлит тирәсендә шиксез тоткарланачагы мәгълүм лəбаса. Газизнең елмаюында шушы хәлне аңлавы, әмма караны беркайчан да ак дип әйтмәячәге анык сизелде. Ә соңрак бу хикәя укучыга барып ирешәчәгенә, шулай булачагына ышаныч төсмере дә бар иде Газизнең әлеге елмаюында.

Газиз Фазлый улы Мөхәммәтшин (1932—1972) Татарстанның Минзәлә районындагы Яңа Бикчәнтәй авылында туа. Авылы мәктәбендә укый, Минзәлә педагогия училищесын һәм Казан педагогия институтын тәмамлый. Түбән төбәгендәге мәктәптә укыта, «Чаян» журналы редакциясендә эшли, башта «Ялкын» журналының, аннары «Казан утлары» журналының баш мөхәррире була. Аның язган хикәяләре соңыннан, әлбәттә, кырыктан күпкә артты, «Йөрәктәге эзләр» исемле романы, повестьлары һәм пьесалары бар, болары да оста язылган. Шушы олы хезмәтләрен истә тотып, Газиз Мөхәммәтшинның тууына җитмеш ел тулу туган төбәгендә киң билгеләп үтелде.

Ә «Ике әби бәрәңге ала...» исемле хикәясе укучылар тарафыннан аеруча җылы каршыланды, һәм аны бер укыгач-тыңлагач онытмыйсың. Әдипнең авылның «чыбыксыз телефоны» ярдәмендә заманын сыйдыра алган бу әсәрендә дөнья хәлләренә образлы бәя бирелә, ике татар әбисе чәй тәмен белүгә дә, «рәкитнең айга менеп кесәсенә ком салып алып» төшүенә дә һәм башка әкәмәтләргә дә битараф түгел.

Әйе, сөендергеч елмаюлы хикәя бу. Газиз Мөхәммәтшинның үзе кебек.

*Әсәрне журналда бастыруга*
*Мәгъсум ХУҖИН әзерләде*
*һәм искәрмә язды.*

**Йолдыз Хәлиуллин**

# ДИПЛОМАТ ЯЗМАЛАРЫ

## Дипломатия һәм дипломатлар

Башкаларны да кеше итеп күрсәң генә,
Үзең дә кеше булырсың.
А. Н. Радищев.

### Дипломатиянең чишмә башы һәм хәзерге заман

ДИПЛОМАТ ул—айсберг, ягъни судагы боз тавы кебек: өске өлеше—әйтергә-сөйләшергә яраганы, су астындагысы—аның белгәннәре, диләр. Бәлки, шулайдыр да. Ләкин дипломатлыкны шул рәвешле генә шәрехләсәк, бу язмалар һич тә тулы булмастыр.

Гасырлар аралыгында һәм яңа меңьеллык башында күпьяклы дипломатлык дөньяның тотрыклылыгы һәм куркынычсызлыгы өчен көчле бер корал булып тора. Хәзерге заманда, мәсәлән, БМО канаты астындагы бик күп илләрнең дипломатлары тырышлыгы Җир шарының теләсә кайсы почмагында әзер торган сугыш мөмкинлекләрен кире кагарга сәләтле. Дөньядагы алдынгы илләрнең күп кенә галимнәре һәм сәясәтчеләре фикеренчә, кешелек алдында торган мәсьәләләр буенча XXI гасыр яңа тарихыбыздагы иң авыр гасыр булачак. Димәк, киләчәктә дипломатия-дипломатлыкның роле, әһәмияте дә күп тапкырлар артачак. Ул барлык дәүләтләрнең бергәләшеп тырышулары аркасында гына бөтендөнья һәлакәтен булдырмый кала алачак.

Дипломатик эшчәнлек әле кешелек дөньясының таңында ук башланып киткәндер. Бу уңайдан бөек шагыйрь Гомернең атаклы әсәре «Одиссея»дә дипломатлык миссиясен гаҗәеп көч белән ышандырырлык итеп сурәтләве безне таң калдыра. Одиссей белән Менелайның, төрле ысуллар кулланып, Троя сугышын булдырмый калу өчен үзләренең дипломатик сәләт һәм талантларын эшкә җигүләре сокландыргыч. Ә бит ул вакыйгалар моннан утыз гасырлар диярлек элек булган!

«Дипломатка тел уй-фикерләрен яшерер өчен бирелгән» дигән гыйбарә киң таралган. Әмма «Дипломатлар—үз дәүләте файдасына алдашучы иң намуслы

---

Ахыры. Башы журналыбызның 10-11 саннарында.

халык» дигәне тагын да дөресрәктер.

Без бередә борынгы Рим империясе, Британия, Франция, Италия дипломатиясенең ул заманнардагы нечкәлекләренә кереп тормыйбыз. Юкса сүз озынга китәр.

Рус дипломатиясенең чишмә башы Киев Русендә князь Святослав хакимлек иткән чорларга барып тоташа. Рус дипломатиясенең халыкара иң зур казанышы, әлбәттә, Киев Русе белән Бөек Болгар дәүләте арасында төзелгән Шартнамә булган. Ул шул замандагы барлык халыкара хокукый кагыйдәләрне тайпылышсыз истә тотып төзелгән. Шунысы да кызык, бу борынгы дипломатик Шартнамә шигъри әсәрләр язуга да этәргән. Узган гасырның сиксәненче еллары азагында күренекле татар шагыйре Ренат Харис әлеге Шартнамәнең мең еллыгына багышлап поэма язган иде. Анда шундый юллар да бар: «әгәр дә колмак суга батса, балта өскә калыкса...» Ягъни бары тик шундый шартларда гына бу Шартнамә юкка чыгарга мөмкин, дигән сүз бу. Шул рәвешле, поэмада рус һәм татар халыкларының борын-борыннан ук дус-тату яшәүләренә дан җырлана.

Шулай ук Нурихан Фәттах, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Флүс Латыйфи һәм башка кайбер татар язучыларының тарихи әсәрләрендә дә дипломатлыкны тирән аңлап язу-сурәтләү күзәтелә.

Рус дипломатиясенең башка тарихи хәлләренә тукталып тормастан, турыдан-туры совет чоры дипломатиясе турында берничә сүз булса да әйтеп үтик.

Сиксәненче ел урталарына кадәр СССР Тышкы эшләр министрлыгы һәм аның чит илләрдәге оешмалары хакында бик аз языла, ул «алып булмаслык ныгытма» иде. Аннары боз эри башлады. Хәзер халыкка ил-дәүләтнең тышкы эшләре турында шактый тулы мәгълүматлар бирелә.

Янә бер мәсьәләгә тукталып үтәргә кирәктер: без хәзер дипломатиянең гаять катлаулы бурычлар алдында торганын күрәбез. Ул хәзер үзенә элек һич тә хас булмаган өлкәләргә, эш-гамәлләргә дә үтеп керә. Әйтик, хәрби сугыш хәлләрен булдырмау, дөньяны коралсызландыру, экология, галәм-космос, диңгез-океаннарны халыкара хокукый тәртиптә бүлешү-җайга салу һ. б. һ. б. мәсьәләләр. Хәзер дипломатик телләргә «күпкырлы дөнья» гыйбарәсе үтеп керде. Шулай итеп, халыкара икътисади хезмәттәшлек һәм халыкара иминлек мәсьәләләрен күпьяклы дипломатик чаралар белән хәл итү әһәмиятле гамәл булып көн тәртибенә килеп басты.

Хәзерге дипломат үткен аналитик фикерле, үзе эшләгән илнең рәсми шәхесләре әйткән сүзләргә һәм белдерүләргә тиз һәм ялгышусыз бәя бирергә сәләтле булырга тиеш. Ул, үзе җыеп алган мәгълүматларны тәртипкә салып, шулардан нигезле-дәлилле нәтиҗәләр дә чыгара алырга тиеш. Үзе эшләгән илдәге тормышның төрле якларын өйрәнгәннән соң, үз хөкүмәтенә бары тик дөрес бәя һәм нәтиҗәле мәгълүмат бирергә тиеш. «Тиешләр» күпкәрәк киттеме? Әле аларның әйтелеп бетмәгәннәре дә бихисаптыр. Бередә тормыш чынбарлыгын онытмаска, теге яки бу дәүләтнең гамәли мәнфәгатьләрен туктаусыз анализлап, ул дәүләтнең икътисадын, мәдәниятен һәм тарихын яхшы белергә дә кирәктер.

Күрдегезме никадәрле таләпләр?!

## Шәрекъ һәм Гареп

ЯГЪНИ Көнчыгыш белән Көнбатыш илләре арасындагы мөнәсәбәтләр дигән сүз бу.

Хәзерге заманда теләсә кайсы илнең башкаласында башка илләрнең дистәләгән илчелекләре һәм йөзләгән дипломатик хезмәткәрләре бар. Алар үз хөкүмәтләренең тышкы сәяси мөнәсәбәтләрен хәл итәргә бурычлы. Аларның эш тәртибе һәм эшчәнлек шартлары дипломатик аралашулар турында 1961 елда Венада кабул ителгән конвенциядәге кагыйдәләргә нигезләнә.

Шуның өстенә, әлбәттә, дипломатик хезмәткәрләр үзләре эшләгән илләрнең кануннарын, гореф-гадәтләрен дә тайпылышсыз үтәргә тиеш.

1997—1999 елларда мин үзем Алма-Атада эшләдем. Шул уңайдан, күз алдымда гаҗәеп тизлек белән аякка басып, үсеп килүче Казакъстан

дипломатиясе турында әйтеп үтәсем килә. Аның төп маякларын Казакъстан президенты Нурсолтан Назарбаев үзенең «Мөстәкыйль дәүләт буларак, Казакъстанның аякка басу һәм үсеш юллары» дигән зур күләмле мәкаләсендә билгеләп куя.

Бүгенге урта буын казакъ дипломатларының берсе минем даими арадашчым, утыз җиде яшьлек Тәлгат Габдулла улы гомуми белеме белән дә, һөнәре белән дә югары әзерлекле кеше иде. Ул өч телне әйбәт белә: рус телен—Бәйсез дәүләтләр илләренең дипломатлары белән аралашу өчен, төрек телен—төрки телләрдә сөйләшүче алты ил дипломатлары белән аралашу өчен, инглиз телен—калган бөтендөнья дипломатлары белән аралашу өчен. Аның эш өстәлендә миникомпьютер тора, шуның ярдәмендә ул рус һәм инглиз телләрендә сөйләшә булса кирәк. Күрәсең, әле компьютерда казакъ теленә «тәрәзә» ачуы кыендыр.

Шәрекъ илләре турында уйланып, аларда бүген була торган хәлләрне аңларга тырышканда, мин еш кына күптәнге чыганакларга мөрәҗәгать итәм—XX гасырның беренче чирегендә яшәгән шәрекъче рус һәм совет галимнәре Н. Я. Марр, И. А. Орбели, И. Н. Крачковский, В. В. Бартольд, А. П. Баранников, В. М. Алексеев—болар бит гасыр башында шәрекъчеләр йолдызлыгында балкыган гаҗәеп шәхесләр! Аларның һәммәсе, Шәрекъне өйрәнмичә торып, дөнья мәдәнияте тарихын, гомумән, кешелек тарихын дөрес күзалларга мөмкин түгел, дип исәпләгән. Алар Шәрекънең тарихи тәҗрибәсе Гарепнекенә караганда күпкә баерак һәм тирәнрәк дип санаганнар. Әмма шул ук вакытта алар Шәрекъне тулысынча аңлау өчен иң элек Гареп, ягъни Көнбатыш мәдәниятенең төп асылын үзләштерү дә кирәк дип тәкрарләгәннәр.

Ни кызганыч, XX йөзнең уртасына без, төрле сәбәпләр аркасында, Шәрекъне һәрьяклап өйрәнүне оныттык, хәзерге заманны өстән-өстән генә сукалап, Шәрекътән сабак алуны да ташладык.

Шәрекъне Гареп шикелле, бер бөтенгә укмаштырып, бер төшенчә итеп аңлатуы гаять кыен. Гарәп вә ислам мәдәниятен, Һиндстан вә индуизм белән, буддизм, Кытай вә конфуцианлык белән кушып кара әле! Болар һәркайсысы, Европа халыкларын берләштергән христианлыктан аермалы буларак, үзләре бер дөнья. Аннары шунысы да бар, Шәрекъ белән Гареп бер үк социаль-икътисади хәлләрдә җәмгыять төзелеше белән бөтенләй аерылып тора. Шәрекъ җәмгыятендәге күптөрле бизәкләрне европалылар тиз генә аңлап та бетерә алмый. Аны аңлау өчен Шәрекъ илләрендә айлар гына түгел, еллар дәвамында яшәү һәм өйрәнү-тикшерену кирәк. Кызганыч, безнең белгечләребез, анда берничә ел яшәп тә, Шәрекъ кешесе тормышын, теге яки бу илнең гореф-гадәтләрен тулаем аңлап та бетерә алмыйча, китеп баралар. Шул ук вакытта кайбер әдипләребез һәм җәмәгать эшлеклеләребез, ул якларда озын-озаклап тормастан, Шәрекъ тормышын Гареп аңына яраклаштырып калын-калын китаплар яза.

Узган гасырның алтмышынчы елларыннан башлап Россиядә Шәрекъ дигән төшенчә, шәрекъчелек фәне, шәрекъче белгечләр дигән тәгъбирләр бөтенләй сызып ташланды диярлек. СССР Фәннәр Академиясенең ничәмә-ничә еллар дәвамында яшәп килгән Шәрекъ институтын да Азия вә Африка илләре институты итеп үзгәртеп маташтылар. Дөрес, берничә елдан соң, бу хатаны танып, институтка үз исемен кайтардылар. Бу аңлы-аңсыздан эшләнгән гамәлләрнең кирәкмәс җимешләрен без әле дә булса тоеп торабыз. Илдә хәзер шәрекъче галимнәрнең дә, фәнни хезмәткәрләрнең вә гамәли эшләүчеләрнең дә җитенкерәмәгәне үзен нык сиздерә.

Соңгы ике гасыр дәвамында, егерменче йөз урталарына кадәр, шәрекъ төшенчәсенә гадәттә Төньяк Африка һәм Океания якларындагы галәмәт зур җирләр вә илләрне кертеп исәпләгәннәр. Ә Гареп илләре хисабына Европа һәм хәтта Төньяк Америка илләрен керткәннәр. «Шәрекъ вә Гареп» төшенчәсе нәкъ шушы илләрнең үзара мөнәсәбәтләрен искә алып килгән. Ләкин узган гасырның 60-70 нче елларында бу төшенчә буталып беткән. «Шәрекъ вә Гареп»не сәясәтчеләр болай аңлата башлаган, янәсе, Шәрекъ илләре Европаның социалистик лагере, ә Европаның (шуңа әле АКШ һәм Канаданы да кушып!) калган илләре капиталистик лагер!

Алга таба «Шәрекъ вә Гареп» төшенчәсен тагын да ачыклау өчен «Төньяк—Көньяк» дигәнен уйлап табалар. Янәсе, бай Төньяк илләре һәм ярлы Көньяк илләре. Төньякка алга киткән кырыклап ил керсә, Көньякка Азия, Африка һәм Латин Америкасының йөздән артык иле керә.

Хәзерге заманда, СССР таркалганнан соң, бөек ил-дәүләт дип бары тик АКШны гына саный башладылар. Соңгы вакытта икътисады алга киткән Японияне дә шул җөмләгә керткәлиләр. Бу уңайдан «көчеш икътисадлы илләр» дигән яңа төшенчә дә барлыкка килде.

Дипломатлык эшчәнлеге үзе дә үзгәрә бара. «Тар» дипломатлыкның традицион формалары киңәя, аңа иҗтимагый даирә вәкилләре дә күпләп җәлеп ителә. Икътисад, сәясәт һәм мәдәни багланышларның дөньяда хәзерге тизлек белән интернационаллашуы дипломатлыкның традицион формаларына гына йөз тотудан баш тартырга этәрә. Кешеләр арасындагы әхлакый мөнәсәбәтләр яктылыгында халык дипломатлыгы киң җәелә бара. Халык дипломатлыгы белән актив шөгыльләнүчеләр дипломатлар булып калудан битәр үз илләренең һәм халыкара җәмәгатьчелекнең югары әхлаклы гражданнары булырга тиеш. Авиация һәлакәтендә һәлак булган америкалы кыз Саманта Смит шундый «халык дипломаты»ның ачык мисалы. Мин аны балалар дипломатлыгының беренче карлыгачы дип тә санар идем.

## Дипломатка тел бирелгән...

ДИПЛОМАТИК хезмәткәрнең дипломатик телне дә үзләштерергә тиешлеге үзеннән-үзе билгеле. Дипломатик тел дигәндә гадәттә сөйләшүләр алып барыла торган тел түгел, ә махсус термин-төшенчәләр һәм аерым фразаларның җыелмасы, күп гасырлар буена дәүләтләр арасындагы мөнәсәбәтләрдә урнашкан традицияләр нәтиҗәсендә тупланган, гомумкулланышка кергән дипломатик сүзлек күз алдында тотыла. Ләкин мин бу очракта башка халыкларның мәдәни байлыгын аңлап, алар белән багланышларны ныгыту өчен кирәкле телләрне белүнең әһәмияте турында сүз алып барам.

XVIII—XIX гасырларда Россиядә алдынгы Европа илләренең—француз, немец, инглиз—телләрен белү бары тик аристократик тар даирәләр өчен генә булганлыгын истә тотарга кирәк. Совет чорында да чит телләрне белү эшчәнлекләре белән чит илләргә бәйле, зур булмаган элитар төркем кешеләр (Тышкы эшләр министрлыгы, Тышкы сәүдә эшләре министрлыгы, Тышкы разведка хезмәте, тәрҗемәчеләр) өчен генә мәҗбүри санала иде. XX гасыр азагына бу хәл тамырдан үзгәрде—Мәскәүдә һәм башка зур шәһәрләрдә чит телләрне тиз генә үзләштерү курслары ачылды, алар хәзерге бизнесның аерылгысыз бер өлеше.

XVIII—XIX йөзләрдән аермалы буларак, Европа илләре арасында аралашу өчен француз теле урынына XX гасырда зур тизлек белән инглиз теле алга чыкты. XXI гасырда исә, минем уемча, инглиз теле тагын да күбрәк урын алачак. Инглиз теленең халыкара мөнәсәбәтләрдә аралашу чарасы буларак алга китүенең кайбер сәбәпләрен дә әйтеп узыйк. Беренчедән, ул инде шактый элек, Англиянең колонияләр яулап алу чорында ук Азия, Африка, Америка, Австралия кыйтгаларында хакимлек итүче даирәләрнең һәм җирле байларның аралашу теленә әверелгән. Икенчедән, XX гасырда АКШның һәм технологик, һәм икътисади дәүләт булып үсеп килүе дә дөньяда инглиз теленең тоткан урыны кискен үзгәргәнен күрсәтә. Өченчедән, өч меңенче еллык башына халыкара мәгълүмат челтәрен программалаштыру буенча да инглиз теле бердәнбер тел буларак өстенлек алды. Башка телләр Интернетның мәгълүмат челтәреннән дә читтә калдылар.

XXI гасыр башына дөньядагы вәзгыять шулай килеп чыкты ки, сәнәгать өлкәсендәге һәм көнкүреш техникасының барлык техник документациясе инглиз телендә таратыла һәм бер миллиардка якын халык тегеләйме-болаймы көн саен төрле инструкцияләр-белешмәләр белән инглиз телендә танышырга мәҗбүр. Күпчелек илләрнең (Кытай, Россия, Бәйсез дәүләтләр илләреннән кала) хакимият башында утыручы түрәләре, кагыйдә буларак, инглиз телендә иркен аралаша ала.

Шунлыктан, бүген дипломат яки берәр эре компания вәкиленең инглиз телен

белмәвен күз алдына да китерергә мөмкин түгел. Барлык кыйтгаларда, барлык илләрдә инглиз телендә рәхәтләнеп сөйләшә-аралаша аласың. Күп кенә Россия һәм чит ил дипломатлары шуңа күрә дә, шәрекъ һәм башка телләрне өйрәнеп тормыйча, күбесенчә инглиз телендә сөйләшә. Шул ук вакытта үзе эшли торган илнең телен белү, һичшиксез, дипломатның да, башка чит ил кешеләренең дә мөмкинлекләрен арттыра, хакимият түрәләре һәм иҗади зыялылар белән ышанычлы багланышлар урнаштырырга ярдәм итә. Көньяк Азия илләре— Пакистанда, Бангладешта, Непалда һәм Шри-Ланкада озак еллар буе эшләгәндә миңа урду һәм һинд телләрен иркен белүем нык ярдәм итте, хезмәт вазифаларымны үтәгәндә генә түгел, ә чит-ят җирдә хатыным белән икебезгә дә яшәү өчен уңайлы шартлар тудырды.

Чит телләрне, бигрәк тә шәрекъ илләре телләрен андагы халык белән даими аралашып тору хисабына һәрвакыт камилләштерергә кирәк, юкса сүз байлыгы бик тиз кими, образлы фикерләү югала, сөйләм теленең ритмикасы һәм музыкальлеге бетә, әдәби сөйләм теленең яңалыкларын сизми башлыйсың. Әмма дипломатлар үз язмышларына үзләре хуҗа түгел, алар бер илдән икенчесенә, бер кыйтгадан тагын икенчесенә күчеп эшләргә мәҗбүрләр. Һәм еш кына сирәк очрый торган шәрекъ телләрен үзләштерергә сарыф ителгән тырышлыкларың җилгә оча. Шундый хәлгә, сиксәненче еллар башында Балкан илләрендә дүрт ел эшләү дәверендә, мин дә тап булдым. Инде үз булып беткән Көньяк Азия илләреннән аерылган идем бит. Румыниядә мин һинд телләрендә аралашу сәләтемне бик тиз югалта барганымны тойдым. Шул куркынычны булдырмас өчен Бухарესттагы дипломатлар арасында һинди һәм урду телләрен белүчеләр өчен үзенә күрә бер клуб оештырдым. Клуб уставында инглиз һәм башка телләрдә сөйләшү тыела, дип язылган иде. Һәр ай саен чәй эчүләр оештырып, шул телләрдә фикер алыша идек. Кайвакыт ул очрашуларга Һиндстан, Пакистан, Бангладеш илчеләреннән егермеләп дипломат хатыннары белән бергә җыела торган булды. Рәхәтләнә идек сөйләшеп үзебез белгән телләрдә!

Бухарестта румыннарның рәсми кешеләре белән аралашканда мин нигездә өч тел—инглиз, француз һәм рус телен куллана идем. Румын телен исә аз-маз «ипи-тозлык» кына үзләштердем, анысы да массакүләм мәгълүмат чаралары ташкыныннан сәяси мәгълүматлар сөзеп алырга гына кирәк була иде. Тормыш-көнкүрештә кулланыла торган румын сөйләм телен өйрәнүнең кирәге булмады (ихтыяҗ туганда исә хатыным һәм кызымнан сораша идем). 1997—1999 елларда Алма-Атада Россия илчелеге киңәшчесе булып эшләгәндә дә шул ук ысулны кулландым. Әмма казакъ телендә бер дә сөйләшмәсәм дә, «Төркестан» газетында шактый гына сәяси мәкаләләр бастыра килдем, җирле радио һәм телевидениедән дә сәяси хәбәрләрне даими тыңлап бара идем.

Әйтергә кирәк, үземнең дипломатлык хезмәтемнең башлангыч чорында мин тел мәсьәләсендә тагын да катлаулы хәлгә тарыдым. Бик кыска вакыт эчендә миңа индонезия телен өйрәнергә кирәк булды. Ул вакытта мин яшь белгечне Пакистан башкаласы Исламабадка җибәрергә әзерләгән иделәр. Әмма соңгы көннәрдә генә идарә җитәкчелеге мине үзем һич тә өйрәнмәгән, телен бөтенләй белмәгән Индонезиягә җибәрергә карар кылды. Ул заманнарда тәртипләр кырыс—синең теләгеңне беркем дә сорап тормый иде. Миңа, ул илдә өйрәнчек дипломат инглиз теле белән дә аралаша алачак, диделәр. Әмма һич тә алай булып чыкмады. Ул чорда Сукарно хөкүмәтенең артык киеренке сәясәте аркасында, Индонезия белән Англия, Америка һәм Малайзия дәүләтләренең арасы бик бозылган, рәсми кешеләрнең берсе дә инглиз телендә сөйләшергә теләми иде. Мин тизләтелгән үз алымым белән ашыгыч рәвештә индонезия телен өйрәнә башладым. Үзем өчен 2000 иң кирәкле, киң таралган рус сүзләреннән сүзлек төзедем һәм рус-индонезия сүзлеге ярдәмендә көн саен 40-50 сүзне ятлый идем, аннары ул сүзләрне һәр очраган индонезияле белән «сөйләшкәндә» кулланырга тотындым. Телләре грамматикасын үземә биргән җавaплардан һәм газет мәкаләләреннән өйрәнә килдем. Шунысы гаҗәп, ярты елдан соң тәрҗемәчебез авырып илгә кайтып киткәч, мин инде үзебезнең консулның Калимантан губернаторы һәм Индонезия Кораллы Көчләре генераллары белән әңгәмәләрендә тәрҗемәче сыйфатында катнаша

башладым. Мондый тәвәккәл адымга хәзер мин һич тә бара алмас идем—индонезия телен белүем шул кадәр генә иде бит.

Чит телне белү ул телдә иркен сөйләшүне, аңлауны, билгеле бер төгәллек белән укый-яза алуны да сорый. Аны тулысынча үзләштергәндә генә син шул телдә иркен фикер йөртә аласың, тәрҗемә һәм грамматик кагыйдәләр турында уйлап та тормыйча, теләсә нинди текстны үз телеңдә шикелле табигый укыйсың. Сүз уңаеннан шунысын да әйтергә кирәк, үз туган телен яхшы белмәгән кеше чит телләрне дә камил үзләштерә алмый.

## Шигъри тәрҗемә хикмәтләре

ТЕЛЛӘР өйрәнү һич тә үзмаксат түгел, алар сайлап алган һөнәреңне камилләштерү чарасы буларак, аң-белемеңне киңәйтү, шәхси омтылышларыңны канәгатьләндерү, әйтик, әдәби әсәрләр тәрҗемә итү өчен кирәк.

Мин инде Пакистанда татарчадан урду һәм инглиз телләренә Г. Тукай белән М. Җәлилнең берничә шигырен тәрҗемә итеп бастырып чыгаруым турында искә алып узган идем. Пакистан укучыларының алар белән үз туган телләрендә беренче тапкыр танышуларыннан да канәгать калган идем. Соңрак мин Мәскәү нәшрияты «Прогресс» өчен татар шагыйрьләренең өч буыны вәкилләре—Г. Тукай белән Дәрдмәнд, М. Җәлил белән Х. Туфан, Г. Зәйнашева белән Ф. Сафиннарның шигырьләрен инглиз теленә тәрҗемә итеп кечкенә генә җыентык та әзерләгән идем. Хәзер мин ул китапның чыкмый калуына да чын күңелемнән шатмын. Мин ул эш белән башка беркайчан да шөгыльләнмәячәкмен, чөнки шигъриятне тәрҗемә итү сәнгате искиткеч катлаулы эш икәнен аңладым инде. Гадәттә тәрҗемәчеләр чит телдән үз туган телләренә тәрҗемә итә, ә туган телеңнән чит телгә тәрҗемәләү икеләтә кыен, бөтенләй өметсез «һөнәр».

Шулай булса да, күптән түгел мин сукыр татар шагыйре, тумышы белән безнең Искек Кызылярдан булган якташым Фазыл Шәехнең үземә ошаган бер шигырен инглиз теленә тәрҗемә итеп Интернет челтәренә кертеп җибәргән идем. (Хәзер инде ул вафат. Тәрҗемәче искәрмәсе.)

Укучыларның рәхимле булуларына өметләнеп, мин ул шигырьнең оригиналын һәм инглиз теленә тәрҗемәсен китереп үтәм:

### Иң кирәкле...

Иң кирәкле бер сүз табылмады
Күңеленә барып җитәрлек.
Иң кирәкле фикер табылмады
Юлларыңа нурлар сибәрлек.

Иң кирәкле учак ягылмады
Җылысыннан рәхәт алырлык.
Иң кирәкле бер җыр җырланмады
Хәтереңә сеңеп калырлык.

Иң кирәкле хисләр кабынмады
Йөрәгеңне ялкын итәрлек.
Иң кирәкле бер юл табылмады
Гомер буе бергә китәрлек.

*Фазыл Шәех. Күзгә күкрәү.—Казан, 1993.—6 бит.*

Инглизчәсе болай:

### Untold Words...

No splendid words that time I could find,
I wonder, why songs escaped my mind.
Believe me, those words, if were told
Could live in your—they were gold.

I failed fo expose my feelings before you,
They have already passed—what snall I do?
No beams in your eyes I can return,
They are flown, I deeply concern.

The good times are past, ourjoys are gone,
The rest of life I should pass alone.
The unspoken words, surely—my mistake,
Fortunately if so happened for your own sake.

Хәзер бу тәрҗемәне нинди принциплардан чыгып эшләвемне аңлатып китәм. Тәрҗемәгә керешкәнче, иң элек мин шигырьнең төзелешен, ритмын, интонациясен һәм һәр строфаның фикер агышын өйрәндем. Фазыл Шәех биредә ун иҗекле юлларның тугыз иҗекле юллар белән аралашып килүче, татарча «бармак» дип йөртелгән классик силлабик үлчәмен куллана. Һәр строфа абаб рәвешендә ритмик рифмаланган дүртюллыклардан тора. «Иң кирәкле» сүзләренең уңай гына бер көйгә уңышлы кабатланып килүе шигырьгә бер моңсулык та өсти.

Шигырьнең төп мотивы—«үкенеч» бөтен әсәр буе яңгырап тора, әмма ачылып бетми, уйланырга да урын калдыра. Минем күзәтүемчә, «үкенеч» темасы соңгы ике буын татар шагыйрьләрендә төрле вариантларда бик актив үстерелеп килә.

Фазыл Шәехтә ул исә әйтелеп бетмәгән драматик эчке бер хис белән, үзенә генә хас булган үзенчәлек белән бирелгән. Шигырь мине нәкъ шул яклары белән үзенә тартты да.

Һәр ике телне—татар һәм инглиз телләрен белгән укучы (әгәр андыйлар табылса) минем һәр юлны сүзгә сүз тәрҗемә итәргә омтылмаганымны җиңел аңлар. Мин бары тик Ф. Шәех әсәрендәге интонацияне, яңгырашны, төп мотивны бирергә генә тырыштым. Шулай итеп инглиз телен белүчеләрнең күпмедер дәрәҗәдә шагыйрьнең эчке дөньясына, күңеленә үтеп керүен теләдем.

Тәрҗемәдә мин татар шигыренең авазлар яңгырашын, аның «хуш исен» бирергә тырыштым. Шигъри әсәрләрне тәрҗемә иткәндә, минемчә, аның музыкаль яңгырашы иң кирәкле, әһәмиятлесе булырга тиеш.

Тәрҗемәнең соңгы ике юлы «яшь байрончарак» яңгыраш алып, үземчә «отсебятина» ясавым—шагыйрьнең хат-мөрәҗәгать рәвешендәрәк язылган фикерен («message») бирергә теләвем булгандыр. Бу сүзләремне раслау өчен мин шигырьнең соңгы юлларын инглизчәдән татарчага яңадан тәрҗемә итеп карадым:

Иң кирәкле сүзләр әйтелмәде,
Бу, әлбәттә минем зур хата.
Бәлки, минем икеләнеп калу
Сине саклап калган шул чакта.

Тәрҗемә һәм тәрҗемәчеләр турында сүзне дәвам итеп, шуны әйтергә кирәк, безнең буынның рус телендә укучылары Шекспир һәм Бернс әсәрләрен С. Маршакның искиткеч тәрҗемәләре аша укып танышты, күп кенә Европа шагыйрьләрен дә В. Левикның матур тәрҗемәләрендә укыйлар. Авар шагыйре Рәсүл Гамзатовны безгә кемнәр ачып бирде? Әлбәттә, тәрҗемә осталары Н. Гребнев белән Я. Козловский.

Г. Тукай шигъриятен рус теленә һәм башка телләргә тәрҗемә итү өчен шундый көчле тәрҗемәчеләр табып булдымы икән? Рус теленә, бәлки, булгандыр да, күпмедер дәрәҗәдә, диюем. А. Ахматова, В. Звягинцева, Р. Моран, В. Тушнова, В. Ганиев—бу исемлекне тагын да тулыландырып булыр иде. Хәтта С. Маршак та Г. Тукайны тәрҗемә итүгә өлеш керткән. Нинди оста тәрҗемәче шагыйрьләр!

Әмма шунысы да бар, Г. Тукай әсәрләрендәге музыкаль аһәңне, аның иркен ритмын, хис-тойгылар бизәлешен башка телдә бирү—чиксез авыр эштер. Бөек татар шагыйренең шигырьләрен, милли төсмерләрен дә югалтмыйча, шул ук вакытта, әйтик, рус яки инглиз телендә яңгырата алу гаҗәеп катлаулы бурыч.

Кызганыч ки, урта гасыр шәрекъ шагыйре Гомәр Хәйямне искиткеч тәрҗемәләре белән «бөек инглиз шагыйре» итә алган Фицджеральд шикелле даһи тәрҗемәчеләр Г. Тукай өчен табылмаган әле. Алтмышынчы елларда Гомәр Хәйям әсәрләрен Фицджеральд тәрҗемәләрендә инглиз телендә укып танышканнан соң, нинди генә яхшы тәрҗемәчеләр ничек кенә оста тәрҗемә

итмәсен, мин аларны укый алмыйм инде.

Шигърияттә минем күңелемә аерылгысыз булып өч бөек шагыйрь кереп утырган: Байрон—Лермонтов—Тукай. Инглиз, рус һәм татар шигъриятенең алтын баганалары булган шушы бөекләрнең әсәрләре миңа даими илһам бирә, эстетик зәвыгыма һәм рухи ихтыяҗларыма шулардан җавап табам.

Соңгы 190 еллар дәвамында Байронны рус теленә өч йөзләп кеше тәрҗемә иткән («The Corsair» шигыренең беренче тәрҗемәсе 1815 елда ук басылып чыккан). Әлеге тәрҗемәчеләр арасында В. Жуковский, М. Лермонтовтан алып С. Маршак, Б. Пастернак кебек бөекләр дә бар. Инде безнең көннәрдә дөньяда дан казанган үзебезнең Рудольф Нуриевыбыз, Байронның «Манфред» трагедиясен сәхнәләштереп, үзенең ялгызлык фаҗигасен һәм бунтарь рухын да ачып салды. Аның 1979 елда Париждагы «Гранд опера» сәхнәсенә «Манфред» балетын П. Чайковский музыкасы белән күтәрүе, Р. Нуриевның баш герой ролендә биюе—балет сәнгатенең шедеврлы буларак кабул ителде.

Пушкин белән Лермонтовны да Байрон илһамландырган, алар аша ул Тукай шигъриятенә дә үтеп кергән.

Пушкин белән Лермонтовтан үрнәк алам,
Әкрен-әкрен югарыга үрләп барам,—

дип егерме яшьлек Тукай язган бит!

Соңрак дөнья шигърияте югарылыгына күтәрелә алган Тукай әсәрләре бөтен төрки халыклар әдәбиятына да зур йогынты ясаган. Мин ышанам, килер вакыт—татар шигърияте классигы бөек Тукаебыз Европа һәм дөнья шигъриятендә дә үзенең лаеклы урынын алачак. Тукай әле үзен колачларлык, тәрҗемә сәнгатенә бөтен гомерләрен багышлаган бөек тәрҗемәчеләрне көтә.

Дөнья шигъриятендә барлык кыйтгаларны һәм илләрне иңләгән, легендаларга әверелгән, күп кенә халыкларның милли мәдәнияте һәм әдәбиятында үз урынын тапкан, милли рухи байлыкка әверелгән әсәрләр бераз дистәдән артмыйлар. Алар инде күп кешеләрнең язмышларын гомер буе озатып бара һәм мөстәкыйль тормыш белән яши башлый. Рус әдәбиятында, мәсәлән, шундый хөрмәтле язмыш Пушкин шигъриятенә туры киләдер.

Кайчандыр техникумда укыганда Пушкинның «Евгений Онегин» әсәреннән ятлаган өзекләр мине—унбиш яшьләрдәге үсмерне имтиханнарда йолып калып, уку елы ахырынача стипендия алырга мөмкинлек биргән иде. Шуннан бирле ярты гасыр дәвамында мин бу үлемсез әсәрне кайтып-кайтып укыдым һәм аның дөнья шигърияте дулкыннарында җиңүле йөзүен күрдем-шәйләдем дә шикелле.

1973 елда Карачи (Пакистан) китапханәсе «British Counsil»—да мин, кызыксынып, «Евгений Онегин»ның инглиз теленә тәрҗемә ителгән дүрттомлык нөсхәсен караштырып чыккан идем. Аны ике телле—рус һәм инглиз телләрендә язучы танылган әдип Владимир Набоков прозага әйләндереп тәрҗемә иткән икән. Мин шул чакта Пушкинның гаҗәеп нәфис, кыска һәм искиткеч музыкаль, 150 биткә сыеп беткән шигъри әсәренең 1500 битләр чамасы күпертелеп, дүрттомлыкка әверелдерелгәнен аптырап та укыган идем. Баксаң-күрсәң, аның 1000 биттән артыгы тәрҗемәченең үз комментарий-аңлатмалары икән! Ул укучыларга әсәрнең һәр юлын шәрехләп бирә, хәтта аерым бер юлны берәр биткә дә сузып аңлата. Мин, В. Набоковның үз сүзләре белән әйткәндә, гомере буе эшләгән бу титаник хезмәтенең кимчелекләре яки уңышлары турында фикер йөртергә җыенмыйм. Әмма, ике телне дә яхшы белгән әдипнең бу тәрҗемәсе, күрәсең, инглиз телле укучыларны да күләме белән куркыткандыр, ул алар күңеленә үтеп керә алмый калган шикелле.

«Евгений Онегин» әсәренең инглиз телендәге икенче басмасы белән мин нәкъ ун ел үткәч, 1983 елда шулай ук «British Counsil» китапханәсендә, әмма инде Балканда—Бухарестта очраштым. Мин берничә көн буе мавыгып-сокланып лорд Чарльз Джонсонның менә дигән шигъри тәрҗемәсен укыдым. Ул тәрҗемәче дә бу эшкә ун елдан артык гомерен сарыф иткән, барлык инглиз телле дөньяда куанып-алкышлап кабул итәрлек «саф инглизчә шигъри роман» тудырган. Инглиз лордына оригиналны кыска (160 бит) һәм Пушкинча музыкаль ритм белән иҗат итү өчен аристократик нечкәлек-нәзбереклек тә кирәк булгандыр дип уйлыйм.

Менә шул рәвешле, үзенчәлекле ике телдә—рус һәм инглиз телләрендә—Пушкинның бөек Онегины Иске Кызыляр авылында туып үскән татар егетенең күңеленә гомерлеккә кереп утырды. Бөекләрнең бөек иҗатына сокланырга гына кала!

## Дипломат хатыны булу җиңелме?

ҮЗЕМНЕҢ дипломатлык эшчәнлегемдә булган казанышларым өчен мин күп дәрәҗәдә хатыным Наидага бурычлыдырмын. Хатын-кыз матурлыгына мөкиббән китүем бик вакытлы, институтны тәмамлап чыгу алдыннан туды. Ул күпбалалы Бари абзый белән Банат апаларның өлкән кызы Наида иде. Мин аны 1964 елның февралендә беренче тапкыр күрдем дә, шундук гашыйк та булдым. Миңа аның һәр җире: тышкы кыяфәте, сөйләшүе, тавышы, елмаюы, киемсалымы—һәммәсе ошый иде. Мин диплом яклаганның икенче көнендә үк без язылышып та кайттык. Менә шул 1964 елның 29 маеннан башлап утыз еллап вакыт үтеп киткән дә икән. Без әле, вак-төяк савыт-саба шалтырауларны исәпкә алмаганда, һаман да тату-матур гына яшәп ятабыз. Хәзер миңа, кайвакытларда үзара киеренке хәлләр туганда, үземнең артык хисчәнлегем сәбәпче булгандыр һәм хатын-кыз психологиясен белеп бетермәвем дә булгандыр кебек тоела. Икенче сәбәп—чит илләрдә хәрбиләрчә тормыштарак яшәвебездән дә килгәндер.

Мин болар белән үземне һич тә акларга теләмим. Бәлки, хатын-кыз йомшаклыкларына һәм теләкләренә бераз гына игътибарлырак, ягымлырак һәм түземлерәк булырга кирәк булгандыр да—нишлисең бит... Югыйсә аның ул теләкләре безнең мөнәсәбәтләребезгә һич кагылмый, ә иң кыйммәтлесе—ул минем йогынтыма буйсына килә иде. Бик оста ир була алсам, ике арадагы мөнәсәбәтләребез ал да гөл булыр иде шикелле. Кызганыч ки, тормыш алай без уйлаганча гади генә түгел шул, еш кына бер-беребезгә юл куя алмыйбыз, килешә дә белмибез. Үземнең кайбер уйланып җитмәгән адымнарым өчен мин әле дә оялам, вөҗданым газаплана...

Безнең холык-табигатьләребез төрле, көндәлек тормышка карашларыбыз да төрлечәрәк, әмма иң мөһим мәсьәләләрдә без һәрвакыт уртак тел таба беләбез.

Наида—«ябалак», ул соң ята, иртән йокларга ярата. Ә мин—«тургай», иртә ятам, гадәттә биш-алты сәгать йоклыйм да, бер эшем булмаса да, кояш чыкканчы торам.

Яшьлегендә Наида шат күңелле, кешеләр белән тиз аралашып китүчән иде. Ә миндә андый сыйфатлар юк, мин йомыкайрак, егетләр арасында да тиз генә ачылып китә белми идем.

Чит ил дипломатлары еш кына Наиданың шәрекъчә матурлыгын, ихтирамлы ягымлылыгын, вакытында һәр кунакка игътибар күрсәтә белүен башка хатын-кызлардан аерыбрак күрсәтә килделәр. Рус хатын-кызлары төрле кабул итү мәҗлесләрендә күбесенчә үзара сөйләшеп утыра, алар чит телләр дә белми. Ә Наида инглизчә сөйләшә ала. Пакистанда аны хәтта күпләр һиндустани (урду) телен дә аңлый дип уйлый иделәр. Бервакыт Һиндстанда дистә еллар эшләгән бер дипломат белән бер мәҗлестә әңгәмәләшеп утырганда, Наида урду телендә берничә җөмлә кыстырып, кунагыбызның исен дә китергән иде.

Наида балачагыннан ук биергә яраткан, пионер елларында халык биюләре һәм бал биюләре түгәрәкләренә йөргән. Пакистанда һәм Индонезиядә илчелекләребездә үткәрелә торган бәйрәм кичләрендә ул һәрвакыт, чегән биюен биеп, беренче бүләкләрне ала килде. Ул төрле көйләрне дә бик җиңел отып ала, миңа калса, аның йомшак-ягымлы тавышы да бик матур. Наида йөзләгән рус-совет җырларын белә. Монысы да кызым белән икебезнең, румынчарак итеп, «мамико» дип мактануыбызга бер сәбәп иде.

Мин үзем һәрнәрсәдә—киемдәме, ашау-эчүдәме, дуслар сайлаудамы, хатын-кызлардагы матурлык-ягымлылыкны бәяли белсәм дә, алар белән мөнәсәбәтләрдәме—кабатлап әйтәм, һәрнәрсәдә бер генә тапкыр гашыйк булучан кеше. Беренче очрашуыбыздан ук Наида минем өчен хатын-кыз матурлыгының, нәфислегенең иң буй җитмәс идеалы булып калды. Башка хатын-кызлар белән аралашканда да (дипломат бит!), мин ирексездән аларны

Наидам белән чагыштырам һәм һәрвакыт: «Менә бу король яки солтан хатыны кайсы ягы белән минем Наидамнан артык?»—дигән сорау куям. Бу соравыма әле булса да уңай җавап ала алганым юк!

Наида минем дипломатик эшчәнлегемдә бердәнбер алмаштыргысыз ярдәмчем булып кала һәм калачак дип беләм. Аның үзенә генә хас сыйфатлары күп кенә илләрдә үзара гаилә мөнәсәбәтләре урнаштырырга, аралашырга да зур ярдәм итә иде. Мәсәлән, Пакистанда без Гхаус Бакш Талпур гаиләсе белән дус булдык. Ул үзе парламентта бик абруйлы кеше, аның өлкән абыйсы оборона министры иде. Аннары безнең дуслар арасында тукымалар магнаты Синда Алам, Пенҗаб эшмәкәрләреннән Рафикъ белән Җаханара Миан, Хәйдәрабадның эре сәнәгатьчеләре Инаятулла белән Һидаятулла Вәлибһаилар һәм башка бик күпләр булды. Без шулай ук Пакистан президенты Әйюб Ханның якын туганы генерал Хәбибулланың гаиләсе белән дә дус-таныш идек. Атаклы-абруйлы кешеләрнең гаиләләре белән аралашу хезмәтемдә бик булышып килде. Болар, әлбәттә, Наида аркасында иде.

Бухарестта яшәгәндәге бер вакыйга искә төшә. Анда Наида тиешле мәгълүматларны алуда бик зур эшлеклелек күрсәтте. 1982 ел башында Һиндстан премьер-министры Индира Ганди беркем дә көтмәгәндә кинәт кенә Бухарестка килеп төште. Аның килүе Һиндстанның Румыниядәге үз илчесе өчен дә, барлык башка дипломатлар өчен дә гел көтелмәгән, гаҗәеп бер вакыйга иде. Мәскәү бездән аның шулай алдан тәгаенләмичә генә килеп төшүе турында кичекмәстән мәгълүмат бирүебезне сорады. Индира Гандиның Николай Чаушеску белән ни өчен очрашу максатларын һич ачыклап булмады. Румыннар, бу очрашу ике арадагы сер дип, нәрсә дә булса әйтүдән баш арттылар. Бөтен өмет мин аның туган теле һиндида аралашкан Һиндстан илчесенә генә калды, булышса, шул гына булыша ала иде.

Индира Ганди килеп киткәннең икенче көнендә Голландия илчесе бары тик дипломатик вәкилләрне генә чакырып кабул итү мәҗлесе үткәргән иде. безнең илчебез В. Дрозденко, үзенең кәефе китеп торганын әйтеп, чакыру кәгазен миңа тапшырды. Ул миннән, ничек кенә булса да, И. Ганди белән Н. Чаушеску арасындагы сөйләшү-килешүләрнең нәтиҗәсен белешергә һәм кичекмәстән аны Мәскәүгә хәбәр итәргә кирәклеген белдерде. Без Наида белән шул мәҗлескә китеп бардык. Һиндстан илчесенең мин яратмаган бер гадәте бар иде. Ул мине еш кына күп телләр белүче КГБ офицеры дип атый иде. Ул бу сүзләрен башка илләр, бигрәк тә көнбатыш дипломатлары алдында кабатларга ярата. Ләкин мин аның бу уйдырма төртмәле сүзләренә түзеп торырга, аларны ишетмәмешкә салынырга тиеш идем, юкса ул илчене бөтенләй үземнән биздерергә дә мөмкин бит. Дөрес, аның хатыны Шримати Рани белән без дустанә җылы мөнәсәбәтләрдә булдык. Яшь, чибәр ул ханым миңа карата һәрвакыт ягымлы иде. Аның сүзләренә караганда, ул кайвакыт иренең бик ышанычлы кәгазьләрен дә күчереп баса икән. Аларның кайберләренең эчтәлекләре сүз уңаенда миңа да билгеле була.

Һиндстан илчесе мәҗлес азагында гына күренде, аны шундук башка илчеләр уратып алды. Янына һич үтәрлек түгел иде. Наида бу хәлләрне кызыксынып күзәтә һәм вакыт-вакыт миңа сүзгә кушылып китү мөмкинлеге бармы-юкмы икәнлеген татарчалап кына әйтеп тора. Кыскасы, без илчене ике яклап «мушкада тотабыз». Ниһаять, Һиндстан илчесе безгә әле Индонезиядән үк таныш булган отставкадагы генерал, Индонезия илчесе белән күзгә-күз генә калды. Без алга ыргылдык. Мин Һиндстан илчесе безгә әле Индонезиядән үк таныш булган отставкадагы генерал, Индонезия илчесе белән күзгә-күз генә калды. Без алга ыргылдык. Мин Һиндстан илчесе белән сүзгә кушылып киткәнче, Наида генералның игътибарын үзенә җәлеп итәргә тиеш иде. Наида генералга турыдан-туры индонезия телендә: «Апа кабар?» («Ничек яшисез?»)—дип мөрәҗәгать итте. Генерал аңа таба борылып, Наиданы сәламләргә мәҗбүр булды. Мин исә шундук Һиндстанлыны үзем кызыксынган сораулар белән күмеп ташладым.

Икенче көнне иртән үк СССР җитәкчелеге Индира Ганди белән Николай Чаушеску арасындагы сөйләшүләрнең ничек үткәнлеге турында хәбәрдар иде инде. Эш сәясирәк булса да, бик гади икән! Алдан килешенгән буенча, И. Ганди

Мәскәүдә ике көн эчендә Л. Брежнев белән сөйләшүләр алып барырга тиеш була. Чөнки И. Ганди тиздән Вашингтонга барырга җыена, аңа Һиндстанның да ике бөек дәүләт арасындагы ролен күрсәтергә кирәк. Әмма соңгы минутта гына безнең картаеп-сәлперәеп беткән җитәкчебез яңадан авырып киткән. Сәбәбен әйтеп-нитеп тормастан, Мәскәү И. Гандиның визитын кире каккан. Ул заманнарда безнең җитәкчеләрнең авыруы бик зур сер итеп саклана иде. Күрәсең, Индира Ганди Мәскәүне бу әдәпсез кыланышы өчен бераз «өтеп алырга» теләгәндер. Шуңа күрә ул Мәскәү өчен тыңлаусыз коммунист саналып, социалистик лагерьны таркатырга тырышучы Н. Чаушеску белән очрашырга карар кыла. Бу гамәл бик яшерен һәм аерым бер тантана белән үткәрелсә дә, сөйләшүләрендә искитәрлек бернәрсә дә булмый.

Хатыным Наиданың дипломатик эшемдәге катлаулы хәлләргә катнашып, аерым хезмәт күрсәткәнен сөйләгәндә, кызым Гөлнара турында да берничә сүз әйтеп китүне кирәк табам. Наида Джакартадан Мәскәүгә кайтып киткәндә, мин аңа: «Малай көтмим, үзең шикелле үк чибәр кыз көтәм»,—дидем. Кыз тапса, бриллиант кашлы йөзек тә бүләк итәргә вәгъдә бирдем. Бу вәгъдәмне соңлабрак үтәргә туры килде. Чөнки кызымны мин аңа ике ай тулганда гына беренче мәртәбә күрдем. Мин чиксез бәхетле идем, кызым да әнисенә бик охшаган төсле тоелды.

Үзебез «чегән тормышы» белән яшәгәнлектән, без кызыбызны тәрбияләү белән дә юньләп шөгыльләнә алмадык. Бер илдән икенчесенә күчеп йөрергә туры килгәнгә күрә, Гөлнара да мәктәпләрен гел алыштырып торды. Ул Бухаресттагы илчелегебез каршындагы урта мәктәпне тәмамлады. Аннары Мәскәү югары уку йортларының берсендә укыды. Аның инглизчәсе искиткеч әйбәт, әле бала чагыннан ук мин аны төрле уеннар аша инглиз теленә өйрәткән идем. Бу, мөгаен, минем аңа педагогик белем бирүемдәге бердәнбер казанышымдыр. Без Непалда һәм Шри-Ланкада хезмәт иткәндә, кызыбыз Мәскәүдә калып, бер мәктәптә инглиз теле укыта иде инде. Җәйге каникулларында ул безнең янга Катмандуга да килеп йөрде. Коломбага да килгәләде, әмма инде тәрҗемәче сыйфатында килә иде. 1995 елда Гөлнара өч кыйтгада—Азия, Европа, Америкада йөреп кайтты. Соңгы икесендә ул ире Шамил Расих улын озатып йөрде. Мин Алма-Атага китәр алдыннан аларның игезәк балалары туды: кызлары Алия белән уллары Минтимер. Шулай итеп, без Наида белән әби-бабай булып куйдык.

## «Казан утлары» елъязмасы

*(декабрь)*



50 ел элек (1953) **Рафаил Төхвәтуллинның “Таныш гөрелте”** хикәясе, **Мирсәй Әмирнең “Ялантау кешеләре”** романынын азагы,
45 ел элек (1958) **Әхмәт Фәйзинең “Тукай”** романыннан өзек журналда дөнья күргән.



## Рафаил Газиз

# АК БОЛЫТ

ЭССЕ

Кече Кирмән авылына баруым. Бригадир Нургали абый җибәрде.

—Бар, Саяф, басудагы күчмә мехотрядтан мичкә ал да, Аръяк урамына төш. Гаяз абыең белән Мамадыш нефтебазасыннан тракторларга керәчин апкайтырсыз,—диде.

—Өйгә кереп чыгам да.

—Бар, бер аягың монда, икенчесе тегендә булсын.

Чаптым шулай өйгә. Әни төенчеккә нәрсәдер җыештыра. Энем, сеңлем белән өчәүләп ат җигәбез. Дөресен әйткәндә—мин җигәм, алар дилбегәләрне китереп бирә. Селкенәләр инде балакайларым, тамаклары туярлык ризык эләксә, йөгереп тә йөрерләр иде. Юк шул, ашау җан асрарлык кына эләгә.

Ерак юлга исәпләнгән чабатаны җылы оекбаш белән киям дә, әтидән калган чалбар балакларын киндерә белән ыспайлап бәйлим.

Әни белән, Ходайдан хәер-фатыйха сорап, дога кылабыз. Миннегәрәй белән Әлфия дә кояш нурында үтәли күренә торган нәни бармаклары белән битләрен сыпыра.

Бер урамлы, кырык йортлы туган авылымның моңсу тәрәзәләре мине озата бара. Урамның ике ягында да авылга күченгәч утыртылган каеннар. Утыртучыларның унжидесе каеннарны да, безне дә ятим калдырып сугыш кырларында ятып калды, югалды. Менә шуңа моңсу безнең каеннар да, тәрәзәләр дә, әниләр дә.

Урман почмагыннан колхоз үзәгенә биш чакрым; юл кырыеннан буй урман атлый. Урман дигәч тә, сабый әле ул. Биш яшьлек урман буламыни, безнең юеш борынлы Миннегәрәй дә бу агачлардан ике тапкыр олырак. Тик шулай да, әллә инде үзем дә утыртышканга, миңа моннан да кадерлерәк каенлык юк, билгеле. Таныйлар шул мине каенкайлар. Кем су сипте аларга, мичкә белән ташып?—Саяф абзыйлары. Кем төпләрен йомшартты?—Саяф абзыйлары. Кем чүпләрен утады?—Шул ук Саяф абзыйлары. Ә бу эшләрне башкарырга энем

Рафаил ГАЗИЗ (1947)—*шагыйрь, берничә шигъри җыентык авторы. Мамадыш районының Кече Кирмән авылында яши.*

Миннегәрәй белән мине кем мәҗбүр итте?—Беркем дә. Үзебез эшләдек. Баш селкиләр каенкайлар, бөгелә-сыгыла әллә нинди серле бию башкаралар. Кәүсәләре чәнти бармак юанлыгы гына, югыйсә. Көннәрдән беркөнне менә шушы каеннар сыман тезелеп, әтиләр кайтып керсә икән...

Су-Елгадан Кече Кирмәнгә теркелдәсәгез, иң беренче булып каршыгызга Ризван каеннары чыгар. Әнә, аларның очлары да җемелдәп түгелме? Өч каен. Каян белә дисезме? Нишләп белмәскә! Мин бит Кече Кирмәннең атаклы мәктәбендә укыган, җиденче классны бетергән егет. Әй, андагы укытучылар! Әй, андагы Хәләмгөл исемле кыз!

Бераз баруга, заманында Кирмән ханлыгының төньяк-көнбатыш чиген саклаганда кече хәрби нығытма булган авыл төсмерләнә башлар. Үргә күтәрелгән саен кинәя баручы офыклар аны әз-әзләп, бүлеп-кисәкләп кенә тамаша кылдыра.

Беренче булып Югары зират игътибарыгызны җәлеп итәр. Зур булса да, бу авылның бердәнбер зираты икән дип алдана күрмәгез тагын, монысы яшь зират бит. Агачлары да уртача юанлыкта гына, яфраклары да сарык бәрәне йоны сыман бөдрәләнеп тора. Агачлардан язгы ташу чәбесен агызып алып киткән, тешсез авызын ерып утыручы буадагы берән-сәрән калган казык кебек корган ботаклар да ыржаеп тормас. Чөнки яшь агачларда корыган ботаклар булмый ул.

Тагын бер-ике атлауга зират белән Яке урамы арасындагы басу күренер дә, Ходай халкыбызга мәңгелеккә бүләк иткән ислам байрагы төсендәге яшел уҗымын болгап, җаныгызны рәхәтләндерер.

Хәзер шулай, ә менә утызынчы еллар башында басу урынында ике чакрымга сузылган, тәрәзәләрен күзгә-күз текәп яшәгән ике урам, көндәлек мәшәкатьләргә күмелеп, халкының актан-ак, пакьтан-пакь күңелен чагылдырып, якты моржаларыннан төтен әләмнәре болгап, тынгысыз тормыш дингезендә тирбәлгән. Өчиле базарына юл тотучы Кирмән алыпсатарлары нәкъ шушы урамнар аша йөргән, серле урман ешлыкларына кереп киткән дымлы урман юлларын гасырлар чоңгылыннан күтәрелүче моң белән сугарып, урман куелыкларына, Кардон чишмәсе буенда сыгылып-бөгелеп, мәдрәсәдә дога көйләп утыручы шәкертләр сыман атынучы талларга сандугачлар бүләк иткән. Бу урамнарның яшел чирәмендә үзләренең иң беренче дошманнары итеп ыштанны санаган шәрә сабыйлар тәгәрәшкән. Урамнарның алтын салам белән ябылган түбәләрендә ашыгып-кабаланып узып баручы җәйге яңгыр болытлары таеп егылган да, житез гөрләвекләр Кирмән җиренең бәрәкәтле туфрагын сугарган.

Урамнарның берсендә Мохсин бабасы яшәгәнне дә белә Саяф. Ярый әле, бабалары исән-имин генә Су-Елгага күчеп калганнар.

Әйе, кулак дип нахакка рәнҗетелеп Себергә сөрелгән Кучи Кашабы туган авылына сөргеннән качып кайтканчы яшәгән бу урамнар. Кайткан Кашап, үзен авылдан олактырган коммунистлардан үч алырга. Кара көеп, нәфрәтеннән Ходайдан курыкмаслык дәрәҗәгә җитеп. Бер атна туганында аскы урамда качып яткан, шуңа күрә ул урамга кагылмаган да. Җил борылып урам уңаена исә башлаганны көткән, мөртәт. Аннан ике урамның да кырый өйләренә ут йөгерткән.

Салам белән ябылган, салам белән шыкланган, бер сүз белән әйткәндә, Йонлач Пәеттин сыман салам белән төрелгән йөз сиксән алты өйне ут ялмап кына алган. Бу сәгатьтә Кирмән кешеләренә бар дөньяны ут каплаган сыман тоелгандыр.

Авылның янгынын Кашап тау башыннан, Ризван каеннары яныннан тамаша кылган. Каеннан-каенга иләсләнеп йөргән дә:

—Куырылыгыз, колхоз этләре!—дип кычкырган.

Дистә еллар үткән. Үләренә ун минут кала, туган җиренә кайту түгел, аның изге исемен балаларына, хәтта оныкларына да телгә алырга рөхсәт итмәгән кырыс карт нәрсәдер әйтмәкче булып тыпырчына башлаган. Күптән телдән язган әтисенең авызына колагын куйган улы:

—Теге вакытта Кече Кирмәнемне мин ут төртеп яндырдым бит,—дигән соңгы ухылдавын гына ишеткән.

Янгын Татарстанның беренче Советлар Союзы Герое Гафият Ярмөхәммәт улы Нигъмәтуллинның өен дә әйләнеп үтмәгән, унтугыз яшьлек егетне авылыннан күчеп китәргә мәҗбүр иткән.

Тагын бер-ике атлауга Яке урамының өйләре күз алдында биешә башлый.

Әхмәтсафа байның ике катлы, калай белән ябылган мәһабәт өе игътибарны җәлеп итә. Кибетләр тоткан Әхмәтсафа, сәүдә иткән. Татарның канында йөрүче кәсәбәчелек оеткысы ана кешечә яшәргә, авылдашларына кирәк булган тауарны җилдән җитез атларга төяп, Казан, Оренбур якларыннан кайтаруны насыйп әйләгән. Күршесе Мөхәммәтсафа да сатуда йөргән.

Берчакны урманда аның атларын караклар туктаткан. Мөхәммәтсафа наганын тартып чыгарган да:

—Кәкәләр![1] Ходайдан ялварам. Алла хакы өчен сезне атып үтерергә насыйп итмә, дип. Кагылмагыз! Җибәрегез. Гөнаһка батырмагыз.

Караклар, чигенә-чигенә, урманга кереп югалган. Мөхәммәтсафа кулында уенчык наган булган. Бу вакыйгадан соң иптәшләре:

—Их, Мөхәммәтсафа! Йөрәк тә бар икән үзеңдә. Ләкин мактанма, алар синең наганыңнан түгел, кәкәләр дигән сүзеңнән курыккандыр, чөнки бу сүзне бары Мамадыш төбәгендә генә аңлыйлар,—дип шаярта торган булганнар.

* * *

Әтисе Миңнәхмәтнең сугыштан өч кенә хаты килде. Гаиләдә өч бала. Әнисе Маһинур, тегенди-мондый биш-алты ирне бер якка быргый торган хатын булса да, очын-очка ялгап кына яшәделәр. Шул да файда иткәндер: Су-Елга авылы егерменче еллар уртасында гына күченгән. Урман төпләп, яткын җирләрне сөреп ясалган басуларда иген бик уңган.

Әтисенең киемнәрен кисеп-ялгап, ямап-төзәтеп кигән малайны мәктәп ят итмәде. Укытучы Фәүзия апасы, парта арасыннан үтеп-сүтеп йөргәндә башыннан сыйпаса, шул бик җиткән иде ятим малайга.

Берзаман фронттан ир укытучылар кайтты. Әтисен көтә-көтә көтек булган Саяф мәктәпкә ир-атларны, фронтовикларны, сугышта һәлак булган әтисен төсмерләргә бара иде. Ул бит әтисен хәтерләми, карточкасы да юк. Әтисеннән калган бүрекне сыйпаштыргалый анысы, вакыт-вакыт бүректән нindидер җылылык та бәреп тора, тик сугыштан орден тагып, офицер булып кайткан Мәхмүт абыйсын, сынар аяклы Мөнип абыйсын күрүгә җитәме соң!

География, физкультурадан керүче Мәхмүт абыйсы кебек булгандыр аның әтисе. Билгеле инде: үзе чибәр, үзе төз гәүдәле. Кыңгырау шалтырауга, Мәхмүт абыйсын күрү өчен Саяф йөгереп чыга, коридор башындагы ишек артына кача да күзли башлый.

Бераздан түр бүлмә ишеге ачыла. Кулына журнал, күрсәткеч таяк, китап-дәфтәр тоткан укытучы күренә. Киң җилкәле, гимнастерка кигән, билендәге каеш прәшкәсе ялт-йолт итә, елкылдап торучы күн итеге белән Саяфка таба килә. Килгән саен күн итек тавышы көчлерәк яңгырый. Күнитекле сәгать килә сыман. Күкрәгендә Кызыл Йолдыз ордены! Дәрескә керергә кыңгырау шалтыраганчы ишек артында чүгәләгән килеш утыра Саяф, аннан, качкан җиреннән чыга да, дәрескә ашыга...

Көннәрдән бер көнне ул Кече Кирмәннең зәп-зәңгәр күгендә йөргән япаялгыз ак болыт күрде. Берәү генә булгангамы, аңа күпләр игътибар иткәндер. Бигрәкләр дә ак, бигрәкләр дә якты иде бу болыт. Әйтерсең лә, ул болытның эченә барлык изге затларның, фәрештәләрнең, җитмеш бер мең әрвахның җан аклыгы җыелган иде.

Күктә кешене ике әйбер җәлеп итә. Берсе—җиһанны җылылык, яктылык, ризык белән тәэмин итүче Кояш булса, икенчесе—кешеләрне серлелеге белән ымсындыручы төпсез Зәңгәрлек. Болар икесе дә күп тапкырлар күргән, ияләнгән, ләкин һәрдаим рәхәтлек бирә торган манзара булса, өченчесе, бәлки, мең елга, гасырларга бер тапкыр күренә торган Изге Болыт булгандыр. Бу болытта туган җирнең, анда яшәгән кешеләрнең язмышы, киләчәге чагыла икән, дип сөйлиләр. Кешеләрдән яшерелгән дөреслек, тарих чоңгылында югалган илләр, шәһитләр турында да хәбәрдар икән ул. Изге Болытның җинаять юлына баскан, башкалар өлешен ашаучы халыкларны юк итүче, һәлакәт алдында торса да, динен ташламаган халыкларга юл күрсәтүе, мантып китү серләрен ачуы да мәгълүм, ди.

---

[1]Кәкә—Мамадыш төбәгенең Кече Кирмән авылында үзеңнән кечерәк кешегә олылап эндәшә торган сүз.

Ул Болытны мәктәп ишегалдында койма кадаклаучы Мәхмүт тә күрде. Кулыннан чүкечен төшереп җибәрде, чүкечнең аяк бармагын янчүенә дә игътибар итмичә Болытка текәлде. Киресенчә, болыт анын күз карашын койма кебек кадаклап куйган иде. Әллә бу Болыт фашистларга каршы сугышта шәһит киткән йөз кырык ике ир-атның, тылда ачка үлгән ике йөз уналты авылдашның изге рухы булып килгәнме? Беркая да акмыйча, мөлдерәп күзгә текәлеп тора. Әллә ул бөтен СССР буенча шулай йөреп чыга микән? Аны һәр авылда, һәр шәһәрдә көтеп торучылар җитәрлектер.

Һәлак булган Вакыйф һәм Нәсыйх абыйларының җаны да туган җиргә кайткандыр.

Мәхмүтнең башындагы тимер ярчыгы кинәт кымшанып куйды, күз аллары караңгыланып китте. Белә Мәхмүт: юкка бимазаламый ул ярчык, гөнаһысы бар икәнне тоя.

Беркөнне Нигъмәт абыйсы очрады. Ул аны бик тә хөрмәт итә. Абзый Мәхмүттән ун яшькә олы. Сугышкан, яраланган. Сабан туйларында мәйдан тоткан ир. Сүз иярә сүз чыгып, әңгәмә колмагы әтисе Васыйл мулла язмышына уралды. Нигъмәт абый күзенә караса, аңа ялганлап булмый. Мәхмүт нинди көч тапкандыр, әллә фронтта үлем белән күзгә-күз килү коткардымы, тагын гөнаһка батты. Әтисен шахтада басылып үлде дип ычкындырды. Алапай шахтасында таш басып үтергән Әһлиулла абыйсы кебек, янәсе.

Әтисе үлгәнгә күп еллар узса да, Мәхмүт дөреслекне әйтә алмый азаплана. Һаман да төнге уникедә килеп алып китүләр дәвам итә. Солдатларын Сталин исеме белән атакага күтәргән взвод командиры Мәхмүт Васыйлыч Сталин исеме белән авыз чайкарга тиеш түгел. Аның взводында рядовой булып сугышкан полковник икәүдән-икәү генә калгач:

—Мин курыкмыйм, югалтасын югалттым, гаиләмне бетерделәр, үләсемне беләм, ләкин сиңа әйтеп үләм—барысына да халыклар атасы—Сталин гаепле, шул исәптән синең әтиеңне үтерүдә дә, Васыйлыч,—дип кырт кискән иде.

Әтисен кулга алгач, әнисе алты бала белән калды. Алла рәхмәте беләндер, ярый әле өйләреннән куып чыгармадылар. Әнисе кара кайгыны күтәрә алмыйча чирләшкәгә әйләнде. Казандагы туганнары кайтып алдылар алуын да, дәвалаудан эш узган булган. Әниләрен Казан зиратына җирләгәннәр.

Әтисен кулга алуларын да хәтерли кебек, аңа инде ун яшь булгандыр. Колхозга көчләп кертелгән игенчеләрнең карганып-сукранып йөргән көннәре иде. Инкыйлабтан соң меннән артык йорты булган авыл Су-Елга, Өләүкә, Хәсәншага күченгәч тә зур иде, бик зур иде. Волость үзәге булган салада кануннарны белүче, замана җиленең кай яктан исүен тойган зыялы ирләр яшәгән. Бер сүз белән әйткәндә, кечекирмәнлеләр гомер-гомергә тирә-юньдәге авыллардан бер башка югары булдылар.

Шуна күрә, әгәр дә колхозны таратуга ирләр күтәрелсә, башның тагаракка тәгәрисен чамалаганнар. Ир-атлар һөҗүмгә хатын-кызларны җибәргән. Ул чакта хатын-кызга ут та юк, суд та юк, дигән мәкаль егәрендә булган. Беренче эш итеп хатын-кызлар Мамадыштан килеп йөрүче уполномоченныйны сафтан чыгара—тегермән күперендә саклап тора да, аты-тарантасы белән буага каплый. Аннан, үзләрен исемлектән сызу өчен, колхозга язылганнарны теркәгән кенәгәне таптыру башлана. Активлар да дурак түгел. Хисапчы Мәликне кенәгә белән арба төбенә салалар, өстенә тирес төйиләр дә авылдан чыгарып качыралар.

Хатын-кызлар кәнсәләрдә җыелыш җыя. Көн тәртибендә бер генә мәсьәлә: үз иремнән башка ят ирләр белән уртак юрган астында ятасым юк, колхоздан чыгабыз.

Ораторлар чиратлы-чиратсыз чәрелдәгән арада, активлар тирәсендә йөрүче ирдәүкә, тавык тизәге ыргытып, ягылган мичне томалый да, чыгып сыза. Хатын-кызлар исерә, чирли, баш күтәрүчеләр армиясе таркала, ухылдап өйдә ята.

Мамадыштан тикшерүчеләр агыла, милиция килеп тула.

Карчыклар кулга алына. Нәрсә кычкырганын колагы ишетмәүче Зариф Гайниен дә сорау алырга китерәләр. Сыйнфый дошманны табу максаты белән килгән НКВД тикшерүчеләре, намаз карчыкларыннан үзләре көткән җавапны ала алмагач, бар өметне Зариф Гайниенә баглыйлар. Чөнки бу хатынның өендә өченче мәхәллә мулласы фатирда торуы мәгълүм була.

Гайниҗамал тикшерүчегә дөресен сөйли. Аны беркем котыртмаган. Колхозга биргән сыерым, атым, тимер сукам, умарталарым кызганыч, ди. Шуңа колхоздан

чыгарга теләдем, минем ялкау күршем Нәгыймулла бернәрсәсез керде дә, кыл да кыймылдатмыйча, буталып йөри. Үз жирендә эшлисе килә икән Гайнижамалның, шуңа колхоздан чыга да.

—Әле мулла абзый: "Алла хакы өчен карганып, колхозны таратабыз дип йөрмә, Гайнижамал, башымны бетерәсең, мин котыртты дип әйтәчәкләр", дип, ап-ак чалмасы, яшел чапаны белән алдыма килеп тезләнде, менәтрәк. Фәрештә кебек, күзләрендә мөлдерәмә яшь иде. Уйламадым, тынламадым, чыгып киттем.

—Кем котыртсын, юк, юк, үзем йөрдем.

—Гайнижамал апакаем, син мәктәптә укыдыңмы?

—Юк, балакаем, кая инде безгә уку.

—Ә шулай да, күренеп тора, бик килешле сөйләшәсең. Мина Мамадыш авылларында күп йөрергә туры килде, әмма дә ләкин синең кебек килештереп сөйләшүче апаны очратмадым. Төскә-биткә дә бик чибәр икәнсең, абыстай. Юкка гына мулла абзый алдыңа килеп тезләнмәгәндер.

—И, балакаем, Ходай биргәнен яшереп булмый инде аның, картым да бик күпләр арасыннан сайлап алды.

—Гайнижамал апакаем, колхозлар турында китапларда язылган бит, менә син, китап укымагач, белмисең инде аны. Мулла бабайның китаплары бармы?

—Бар, булмаган кая...

—Менә шул китапларда язылган ул колхоз турында. Мулла бабай китапта нәрсәләр язылганны сөйләштерәме соң?

—Сөйли, сөйләмәгән кая. Аны тыңлап торсаң, эш эшлим димә инде син.

—Ярар, кул куй, Гайнижамал апакаем.

—Яза белмим бит, балакаем.

—Тамганны сал, алайса.

Зариф Гайнинең беркетмәгә тырнаган бөтәркәсе авылның өч мәхәлләсен житәкләгән мөхтәрәм, гөнаһсыз, изге муллаларын бөтереп алды, кулларына богау салды, төрмәгә олактырды. Аларның берсе Мәхмүт исемле ун яшьлек малайның газиз этисе иде.

Кыйнаулар, имгәтүләр, ач тотулар да ил картларын сындыра һәм гаепләрен таныта алмады. Изге Ходайның илаһи сабырлыгына таянган муллалар, гомер шәмнәре сүнә барган саен, күкнең чираттагы катына күтәрелә баралар иде. Ап-ак чәчле, ап-ак сакаллы өч карт утырган төрмә бүлмәсендә ут кабызу да кирәк булмагандыр. Аларның рухы шундый нык, бер-берсенә карата ихтирамы һәр кәлимә сүз, күз караш, ишарә саен көчәя барды. Бөек Аллабызга булган инануның эчкерсезлеге аларны бер тән, бер жан итте, рухи игезәкләргә әйләндерде. Петропавловск төрмәсендәге Батыршадан Кече Кирмәннең өч мулласына күчкән бу Ныклык, Иман алга таба жәлилчеләргә тапшырылгандыр.

Төрмәдәге өч фәрештә үлемне дә халкыбызга хас сабырлык, фидакарьлек белән каршылады. Атарга алып чыгу өчен конвой кергәч: "Аллаһу әкбәр! Аллаһу әкбәр!"—дип, тәкбир әйтә башладылар.

Бу илаһи авазны төрмәдәге тоткыннар ишетте. Башта уннар, аннан йөзләр, соныннан меңнәр—халкыбызның йөз аклыгы булган зыялылар—Аллаһу әкбәргә кушылды. Бөтен татар халкы шушы төрмәгә ябылган микәнни соң?!.

Дәһшәтле тәкбир тавышы төрмәнең какшамас диварларын, тимер рәшәткәләрен, калын ишекләрен чатнатты.

Төрмә күселәре, ачкычларын шалтыратып, мылтыкларын өстерәп, куркудан ялтыраган күзләренә урын тапмыйча тегендә-монда чабыштылар. Камераларга кереп тоткыннарны кыйнадылар. Аллаһу әкбәр тынмады. Тегеләр, жинелүләрен урыс аракысы белән томалау өчен, эш бүлмәсенә кереп аудылар.

Намаз вакыты житкәч, теткәләнеп беткән ак күлмәкләрен идәнгә намазлык итеп жәйгән, сәждәгә киткән өч мулланы төрмә сакчылары кылыч белән тураклады. Бер үк күренеш, бер үк гамәл. Аерма тик шунда: 1552 елда Казан ханлыгының баш Сәете Кол Шәриф кулында кылыч булган...

Шушы ачы хакыйкатьне авылдашларына сөйләмәгәнгә Мәхмүт абыйсы үзен зур гөнаһлы санавын күрше авыл малае Саяф кайлардан белсен икән?!

Күктәге Ак Болыттан үзенә этисе караганын тойды Мәхмүт. Мулла малае дип комсомолга кабул итмәүләрен, укырга алмаганнарын да, әле офицер дәрәжәсе биргәндә дә телгә алуларын хәтерләп газапланды. Ак Болыттан нәрсәдер ява иде. Әллә этисе Васыйл карт нәселен аклаган баласына—Мәхмүткә—савап яудырамы?

1941 елда кырык бер өйне көл иткән янгында алар да бернәрсәсез калды. Бакча башындагы аягүрә йокласаң гына сыешлы өйгә күченделәр. Югалмадылар. Сугышта да сынатмадылар. Вакыйф, Нәсыйх абыйлары башларын салса, энесе Мәсгут белән ана исән кайтырга насыйп булды. Хәзер икесе дә, Васыйл мулла эшен дәвам итеп, мөгаллимлек италәр, сеңелләре Наилә дә укытучы. Иң кечеләре Ләмига гына укымады, сугыш комачаулады. Мәхмүт, авыр сулап, башын иде, әйтерсең, Ләмиганы укыта алмаганга үзен гаепле саный иде.

Исенә килеп башын күтәргәндә Ак Болыт гаип булган, ул торган урында зәп-зәңгәр күк иде.

Саяф та күрде ул Ак Болытны. Җентеклəбрәк карагач, болыт эчендә мәчетләр абайланган сыман булды. Бу теге Мәтә Гәрәфе сөйләгән Кече Кирмән мәчетләре түгел микән? Совет власте мәчетләргә һөҗүм башлагач, Кече Кирмәндә дә манараларны аударырга кеше эзлиләр. Бер генә юньле бәндә дә мона бармый, жыен әтрәк-әләм, эчкече, жинаятьчене барлыйлар. Табалар, чүп-чар кайда да ауный бит ул.

—Менә мин сиңа шуны әйтәм, Саяф, киселгән манара гөрселдәп җиргә ауды. Жыелган халыкның күкрәгеннән ыргылган ухылдау көчлерәк булды. Аннан шуны әйтәм, кем манара кисте—берсе дә рәхәт күрмәде. Барысының да язмышын беләм, кайсы үз-үзенә кул салды. Әмма дә ләкин мин берсенең генә язмышын сөйлим. Аны үтермәде дә, калдырмады да.

Ул ярты гомерен Хәсәншада үткәрде. Өе—яртылаш җиргә чумган землянка иде. Мин леспромхозда атлы эштә йөрим, Хәсәнша аша агач ташыйбыз. Теге бәндәнең йорты яныннан узабыз. Тәрәзә янына килеп утырган булыр, кулын Коръән өстенә куйган булыр. Кич белән кайтабыз. Шул ук хәл, тәрәзә төбенә куелган Коръәнгә кулын салган бу. Үзе—дөм сукыр. Ничә дистә еллар буена шулай утырды, үлгәнче.

Ә шулай да, Мәхмүт абыйсына кагылышлы тагын бер вакыйганы белә Саяф.

Мәхмүт абыйсы мәктәп директоры, хатыны Кәшифә апа кызлар торагында тәрбияче. Торакта торучы Хәсәнша, Өләүкә кызларын тәрбияләү, саклау Кәшифә апаларына йөкләнгән. Кайсы өч, кайсы дүрт-биш ел соңарып укучы кызлар көз көне агачыннан өзелеп төшәргә җиткән алма кебек мәмрәгән иде.

Мәктәпнең капкасыннан керүгә һәр сау-сабагай малайның аягы сулга каера башлый. Чөнки дүрт-биш атлауга торак ишекләре оҗмах капкасыдай ачылырга тора. Ә анда яшәүче кызлар бүлмәләрне чиккән-бәйләгән әйберләр белән чыннан да оҗмахка әйләндергән иде. Ул кульяулыкларның нинди генә юк, кайсы бәхетле егеткә тәтер микән инде бу кульяулыклар?!

Бай яшиләр кызлар. Шулай булмыйни! Алар бит Хәсәнша, Өләүкә кызлары. Алар сугыш чорында да ачыкмады. Яңа гына сөрелә башлаган, мең еллар буена егәр җыйган яткын җирләр биш авылны туйдырырлык нигъмәт бирә иде.

Озын торыклы, яшьтәшләреннән соңрак укырга кергән Гафиятулла да кызлар торагына сукмак салды. Андый җиргә сәфәр чыгу, билгеле инде, серле кичләрдә була. Бөтен изге эшләр караңгыда эшләнә, диләр. Күрсә, мәктәптән куарга да күп сорамас Мәхмүт абыйлары, хатыны торакта эшләгәч, бигрәк тә. Сак булу комачауламас.

Күз атып йөргән Сөембикәсенең икенче катта өстәмә дәрестә утырганын күрде Гафиятулла. Дөм караңгы төнне балаларны шулай озак утыртмаса, нәрсә булган инде Фәүзия апасына?

Укытучылар ишетмәсен дип баскычтан мәче сыман гына тәпиләде малаен. Торак болдырының почмагына посты. Мәктәп коридорында аяк тавышлары дөбердәде, баскычтан төште дә, кемдер торак ишегенә таба атлады. Кар шыгырдавыннан чамалады Гафиятулла—болай кәс-кәс атлап Сөембикә генә йөрергә мөмкин. Кызык итим әле үзен. Өялдына кергән җыйнак гәүдәне кочагына состы Гафиятулла. Аһ итте кызый, ваһ итте. Хәтәр генә тыпырчына да башлады. Ычкындырыр Гафиятулла! Аның кулларын тракторга тагып аерсаң гына инде. Ычкындырмый да, йомшак җирләрен капшарга да өлгерә.

Шактый әүмәкләшкәч, кыз ишек тоткасын эләктергән, җан-фәрманга ишекне каерып та ачты, Гафиятулла белән икесе бусагадан тәгәрәп идәнгә аудылар. Ишектән кергән салкын пар эчендә Гафиятулла берни дә күрмәде. Берзаман күзен ачса: аның белән идәндә аунап ятучы, әле һаман да Гафиятулланың тимер келәшчәләренә кысылган кешенең торак тәрбиячесе Кәшифә Абдулловна икәнен танып өнсез калды.

Янакка чалтыратканнарын хәтерли Гафиятулла, башкасын хәтерләми.

Берничә көн мәктәпкә бармады. Чегән чишмәсенә су алырга төшкән Сөембикә әйтте:

—Юләрләнеп, укуыңны ташлый күрмә, Гафиятулла,—диде.

Дөрес, ул егетләр арасында герой иде. Директор хатыны Кәшифә Абдулловнаның бер капшамаган җирен калдырмаган кешеләр Кече Кирмәндә генә түгел, бөтен дөньяда да икәү генә. Берсе Гафиятулла, икенчесе—Мәхмүт абыйсы. Үз хатынынны капшау ир-ат арасында дәрәҗә саналмаганга, Гафиятулла Мәхмүт абыйсына караганда да бер башка өстен иде, әлбәттә. Очраган берсе: "Хәзер бажайлар инде сез директор белән",—дип, ярага тоз сала. География дәресен Мәхмүт абыйсы хәзер болайрак башлап җибәрә:

—Исәнмесез, балалар. Йә, энем Әхмәт, әчәбез инде аны чәйне әйбәтләп...

Өченче җөмлә Гафиятуллага әйтелә:

—Йә, Гафиятулла, минем хатынны кочаклау рәхәт булдымы?

Кызарынган-бүртенгән Гафиятулла ярылса җир тишегенә кереп китәр иде дә, Сөембикәсе кисәтте:

—Рәхмәт—мәктәптән кумагач, һәм дә бәреп үтермәгәч,—диде.

Түзә, түзде, түзәчәк Гафиятулла. Ул Тәхиятулла абыйсында яши. Әти-әнисе үлде. Аның хыялы—укып бетерергә дә читкә, шахтага китеп, кеше булу.

Саяф дилбегәне әз генә каккан иде, ат Ташлы Үзән елгасы борынлаган үргә менеп тә житте. Борынгы зират күренде. Кече Кирмәнне түбәтәйләгән зәңгәр күкне Алып кебек тотып торучы, һәр ботагы авыл урамнарындагы теләсә кайсы агачтан да юанрак булган, кәүсәдәге ярыкларына качышлы уйнаганда балачага кереп югала торган мәһабәт тал-тирәкне шәйләп, үзенең агач кабыгындагы ярыкларга ябышып күккә үрмәләвен хәтерләде. Хәләмгөлнең абыйсы Габделбәр алып кергән иде зиратка, шул тирәк белән мактанырга. Зираттагы серле язулы, биек кабер ташларының күп булуына гаҗәпләнгән иде.

Саяфка авыл уч төбендәге кебек күренә. Югары оч урамы гына тау артына качкан. Бакырчы чишмәсе турыннан узуы икән. Бакыр базы казыганда бәреп чыккан чишмә бит ул. Саяфның борынына бакырчы чишмәсен коймалаган бөтнекләрнең исе бәрелде.

Сул якта Казыган Тау, XIX гасыр уртасында Кырым сугышына әзерләнгәндә төзелгән тау күренә. Ул Әби патша салдырган Себер юлына чыга. Аны центнер ярымлы хатын-кыз инженер төзеткән дип тә сөйлиләр. Көнне-төнгә ялгап эшләгән атчылар тәүлегенә илле тиен акча алган. Ә бит ул вакытта ат бәясе бары өч кенә сум торган. Менә ничек түләгәннәр! Саяф та йөри тәүлек буе, түләве дә юк, тамакка да такы-токы, өс-баш та үзе үргән чабатадан узмый.

Ат, теркелди-теркелди, сугыш чорында хәрби өйрәнүләр үткәрелгән окопларга килеп житте. Хәләмгөлләрнең сөйкемле өен эзләде Саяф. Ни эшләп йөргән була микән ул кызыкай? Кульяулык чигәдер, чиксә—кемгәдер бит әле...

Гаяз абыйларны табу кыен булмады, капка төбендә кәрәчин мичкәсе салынган арба тора. Ат кешнәгән тавышка капкадан баһадир гәүдәле чибәр ир күренде. Аягында дегет белән чем-кара итеп буялган кирза итек, өстендә таза мускуллары йөгергәндә киерелеп шартлау хәленә килүче гимнастерка, солдат чалбарыннан. Киң каешның җиз пәрәшкәсе кояшта ялт-йолт итә.

—Кәкә, син Саяф буласыңмы, Маһинур апа малаемы?

—Әйе.

—Күрешик алайса, бергә сәфәргә чыгабыз икән.

Абыйның тимер келәшчәләре кулларымны шыгырдатып кысты. Бармаклар гына сынмаса ярар иде. Капкада Латыйфәтти күренде. Ай-ваема карамыйча, өйгә алып керделәр. Табынга парлары түшәмгә тиеп бөдрәләнүче бер табак бәрәңге, ипи, коштабак белән катык килде. Катык шулкадәр салкын, бәрәңге шулкадәр кайнар. Басудагы уҗымнан да яшелрәк суган кыяклары. Булган хатын икән Латыйфәтти. Андыйлар турында минем әни: "Уңган хатынның ризыгы үзеннән бер чакрым алда йөри",—дип әйтергә ярата.

Ул Латыйфәттинең кыстаулары, минем оялып кына табакка үрелүләрем. Җиде чакрым килеп, әле Мамадышка кадәр теркелдәячәк Саяфка бик тә ярап куйды бу ризыклар. Әппәр итеп, рәхмәт әйтеп урамга чыктык. Латыйфәтти: "Исән-сау йөрегез, балалар, бер-берегезгә күз-колак булыгыз. Ай, текә бит ул Саурыш таулары, Арташ үрләре!"—дип офтанды. Дога укып, хәерле юл теләде.

Киттек таудан төшеп, каршыда Урыс Юлы күренде, инештә атларга су

эчердек тә, аркалыкларны күтәреп, тауга таба кузгалдык.

Бу тауның ни өчен Урыс Юлы дип аталганын сез белмисез, билгеле. Әни аңлатмаса, мин дә белми идем. Йә, тыңлагыз, алайса.

Кече Кирмән бик зур авыл булган шул. Әле хәзер дә зур. Ә Яке авылы ягындагы ике урам янып, кешеләре ялланып читкә киткәч тә, Арьяктан Сәләхи тавына кадәр сузылучы урамда яшәүчеләр Су-Елга, Хәсәнша, Өләүкә авылларына күченгәч тә, йөзләгән йортлары калган. Унҗиденче елда меңдә уналты йорты булган Кече Кирмән, волость үзәге булу белән бергә, олы базары белән дә дан тоткан. Авыл базар көннәрендә корт аеручы умарта сыман гөҗләп торган. Алабуга, Мамадыштан урыслар, Саба, Кукмарадан итекчеләр товар китергән. Урыслар авылга менә шушы таудан килеп-китеп йөргәнгә, тауга Урыс Юлы исеме бирелгән дә. Тау итәгендә киндер фабрикасы эшләгән.

Бара торгач, кеше аяк басмаган, шомлы Бурсык урманы кырыеннан Арташ авылына борылдык. Гаяз абый бер сүз дә дәшми, минем сөйләшәсе килә дә, икебез ике арбада шул. Сугыш турында сөйләсә икән, бәлки, ул сугышта минем әтием Миннәхмәтне дә очраткандыр. Кайтканда булса да сорашырга кирәк. Миннегәрәй энекәш бик тинтерәтә, әтидән хат килми башлагач туган бала шул...

Гаяз абый минем әтине белергә дә тиеш, әти дә Кече Кирмәндә туып-үскән, шунда икееллык мәктәп бетергән.

Арташ зиратының шомлы чокырыннан авылга төштек. Гаяз абый һәр кеше белән исәнләшә, мин дә шулай. Әнә бер кыз миңа ялт итеп борылып карады, кара күзләрендә ялтыраган яшен миңа китереп сукты. Мондый кызы булган авыл матур да матур инде ул.

Матур булса да, артта калды Арташ. Ат юлы үргә үрмәләде, куе урманга югалды. Өләүкә авылында коры куак булып коры куакны келәймәләп йөрүче урманчы Зәкиҗан бар иде. Җелеккә төште ул. Үз тормышы да авыр, ишле гаиләсе ачыга, намуслы ләнгәр[1] сыман хәерчелек чоңгылында тота иде.

Көннәрдән беркөнне лесничий Ивановка бара бу. Ни хәлләр итим, ачыгабыз, эшли алмыйм бит, иптәш Иванов, ди. Иптәш Иванов әйткән моңа: "Зәкиҗан туган, син гел аяк башына гына карап йөрмә, вакыт-вакыт өскә дә күтәрелеп кара. Сезнең Өләүкә янында Кыз урманы бармы? Бар. Авылыңнан чыгып юл Кыз урманына кергән урында бик мәһабәт имән үсәме? Шул имән очында күнитек һәм бер тәпән бал эленеп тора. Хәзергә шуларны ала тор, кабат тагын килерсен",—дигән.

Килгәндерме Зәкиҗан абыйсы Иванов катына, Саяф анысын белми, соңыннан, Хәсәншага күченеп, таза тормышлы хуҗалыкта гомер иткәнен генә белә.

Дымлы урман һавасын ерып озак барды атчылар. Ике урында җир мае исе дә сизде Саяф, вакыты булса гөмбәне эзләп табыр иде дә, үги әтисе Габделкаюмга алып кайтып бирер иде. Ул бит шул гөмбә белән дәвалана.

Кинәт юл урман аланына сикерде. Бу авыл аша узганы бар малайның. Демьян авылы, сынар күзе белән Озын Басуга карап тора. Саяфның үзегенә үткән басу бит. Хәзер уналты яшьтә булса да, моннан ике ел элек йөз яшькә картайды ул бу басуда.

Илле беренче елда җидееллык мәктәпне тәмамлады. Иптәшләре белән Түбән Ушмы урта мәктәбенә укырга бардылар. Кем башлаган коткы булгандыр, шоферлыкка укырбыз әле дип, мәктәпне ташлап кайттылар.

Бер урамлы авылда кеше авызыннан чыккан сүз өйдән-өйгә кереп, колактан-колакка, телдән-телгә күчеп бәргәләнә дә, ахырда басу капкасы баганасына кыңгырау булып асылына дип, юкка гына әйтмиләрдер. Унҗиде ир-атны сугышта югалткан, аксак-туксак, ярты-йорты ирләренә дә колхоз нужасын өстерәткән авылга унбиш яшьлек үсмер укуын ташлап кайтсын да ди, шул хәбәр бригадир Нургалиенең мыегына барып уралмасын, ди.

Килде, керде, күрде, боерык бирде Нургали. Заманасы сатулаша торган замана түгел иде.

Арык, шунадырмы юаш, мескен генә ат бирделәр Саяфка. Кар яумыйча, салкын җилләре белән җелекне суырган ноябрь аенда Саяфны Мамадышка кәрәчингә җибәрделәр. Иптәшләре дә бар иде. Алдылар кәрәчин белән салидул-

---

[1] Ләнгәр (борынгы татар сүзе)—якорь.

ны. Озын Басудан кайтканда Саяфның аты арды. Тегеләй иттеләр, болай иттеләр, ләкин ат яткан җиреннән тормады.

Кәрәчинне вакытында алып кайтмасалар тракторлар туктап каласын, эш рәшәткәле тәрәзәгә барып җитәсен белгән атчылар, Саяфны бер ялгызы калдырып, кайтып киттеләр.

Яткан атны тарткалап та, сыйпап та карады малай. Кычкырырга, таяк күтәрергә намусы кушмады. Атның да, аның да кабыргалары бер чамада тырпайган, үпкәләре шул кабыргаларга ябышкан иде.

Көньяк-көнчыгыштан исүче үзәккә үтә торган җилне каплап ат янәшәсенә ятты Саяф, чикмәнен атына да, үзенә дә япты. Җил чикмәнне генә түгел, чабата белән чолгауны да, әтисеннән калган чалбарын да үтәли узып, шыр сөяктән һәм тиредән генә торган тәненә керә, калтырата иде. Аттан бәреп торган җылыга әле бер ягы, әле икенче ягы белән борылган малайның бар кайгысы—ат үлсә, үги әтисе Габделкаюм кебек, төрмәгә утыртырлар дип курку иде. Әнисе һәм ике баланы аннан соң кем туйдырыр?

Үги әти дигәннән. 1948 елда өйләре янды, урам уртасында утырып калдылар. Нәрсәгә үрелсәң—шул юк. Габделкаюм абый булмаса, беткән иделәр. Әнисе фәрештәләр, изгеләр дип авыз ачса, Габделкаюм абыегыз дип тә өстәргә ярата. Өйле дә, өйрәле дә итте күрше абый. Сугыш ятимнәрен урам уртасында калдырмады. Әлфия белән Миннегәрәй Габделкаюм абыйларына шулкадәр ияләштеләр, күрше абый тирбәтеп чыгып китмәсә, йокламый башладылар. Сөйкемле сөяге бар иде бу кешенең. Балалар үзләре Габделкаюм абый бездә яшәсен, дип хәл иттеләр.

Кулы терсәктән өзелгән Габделкаюмның. Күп кан югалтуына карамастан, сигез чакрым шуышып, үзебезнекеләр ягына чыккан солдат ул. Әле өзелгән кулын да дошманга калдырмаган, куенына тыгып алып чыккан. Гангрена башланган кулын култыктан ук кисәргә бирмичә әсәрләнгән чакта Ходай аңа юньле врач насыйп иткән. Туган авылына кайтып ауган фронтовикны колхоз рәисе эшкә дәшкән: "Тамагың тук булыр, әвендә көлтә киптерергә куям",—дигән.

Габделкаюм олы йомры ташлардан мич әмәлләгән, шалаш корган, әвен ясаганнар. Әвенгә көлтә ташып башаклы ягын эчкә каратып өйгәннәр.

Габделкаюм мичкә яга, җылы ташлар арасыннан чыга да көлтәләрне киптерә, көлтәләрдәге башаклар суктырырлык дәрәҗәгә җитә. Аннан көлтәләрне сугу машинасына ташыйлар. Көшелләр үсә тора, хөкүмәткә китә тора.

Җиде яшьлек Миннегәрәй белән тугыз яшьлек Әлфиянең ачыгуын күрү Габделкаюмны гөнаһка этәрә. Арыш өлгерә башлау белән башак уып алып кайта. Шуннан әнисе Маһинур Саяфны балалар белән су буена озата. Ишектән чыгу белән Саяф өйне тыштан, капканы эчтән бикли. Аннан, урамга чыгып, бау белән кечкенә капканы бәйләп куя.

Белә Саяф: өйдә калган әнисе базга төшәчәк тә кул яргычында арыш тартачак. Ә алар су буенда кәҗә сакалы, кукы, кузгалак, мәче борчагы, кычыткан эзлиләр. Балалар, вакыт-вакыт өй ягына каерсалар да, тиз генә кайтырга ярамый. Зырылдасын әле баздагы кул ярчыгы, әйләнсен...

Бәла агач башыннан йөрми диюләре хак икән. Өйләре янып бер ел үттемеюкмы, үги әтисез дә калды Миннесаяфлар. Бер мәлне үги әтиләре: "Норма тегермәненә ашлык тартырга төшәбез, рәистән ат сорадым",—дип, сөенче алган иде. Миннегәрәй сөенче бүләгенә Габделкаюм абыйсына ике кукысын да кызганмады.

Җыендылар тегермәнгә. Арбага җыйнак капчыклар салган ирләр ат артыннан теркелдәделәр. Габделкаюмга тамагың да тук булыр, дип әйткән колхоз рәисе чакырткан милиционерлар, активлар авыл башында көтеп торган икән шул.

Арбадагы икмәктән башлаган милиционерлар бер уч йорты булган авылны йон теткән кебек тетеп чыктылар. Биш йорттан суктырылмаган башак табылды. Бу бәхетсезләрнең берсе хезмәт ударнигы, кулын Герман җиренә күмеп кайткан, өч ятим баланың ачыгуына түзә алмыйча, әвен эченә коелган берән-сәрән башакларны кесәсенә салган, "Су-Елга" колхозының бар ашлыгын киптергән сынар куллы Габделкаюм иде. Аны кулга алгач, фронтта һәлак булган Миннәхмәтнең өч ятим баласына нәрсә буласын Сталин бабай уйламады да, күрмәде дә. Кремль ерак, үлем якын иде.

Шуның өстенә Маһинурның абзарыннан сыерын да алып чыктылар.
Әнисе ничә тапкыр Верховный судка язды, җавап бер иде: "Мамадыш судының карары—гадел".
Рәхимсезлеге белән Гиннес рекордлары кысасына да сыймаган совет суды Габделкаюмга 15 ел бирде.
—Миңа ничек тә ярый, сыер гына..—дигән икән соңгы сүзендә Габделкаюм абыйлары.
Әнисенә зур гәүдәле, күркәм холыклы, күп сөт бирүче сыерны Түбән Ушмыга "Кызыл Флаг" колхозына төшеп күрергә генә калды. Сөтлебикәне суд карары белән шунда тапшырганнар иде.
Арган атның арык гәүдәсенә сыенып, шыр сөяктән торган тәнен җылытырга азапланганда, менә нәрсәләрне хәтерләде Саяф. Ул инде ничә сәгать, ничә тәүлек аты белән янәшә ятканын да хәтерләми. Әнисе үз авызыннан өзеп җибәргән күмәчне дә атка каптырды. Озак карашып тордылар бахбай белән малай. Икесенең дә күзе мөлдерәмә, күктән аларга багучы түгәрәк ай сыман иде.
Торып басты ат, атлап та китте, нинди генә җылы сүзләр әйтмәгәндер аңа Саяф. Төне буе Демьян урманы, басулар, авыллар аша теркелдәделәр. Ачлыктан, арганлыктан, йокысызлыктан йончыган, күз аллары караңгылангач арба кырыена ябышучы малай тик бер әйбер өчен генә шүрләде: мичкә арбадан тәгәрәп, кәрәчин агып, Габделкаюм абыйсы сыман төрмәгә генә тыкмасалар ярар иде.
Ходай Тәгалә ташламады! Арташ зираты янындагы шомлы чокыр да бер сүз әйтмәде, ат аннан җинелрәк тә менде, кем булышкандыр. Саяф эткән сыман итте инде, анысы. Саурыш тавын да тезәнлекләп алдырды бахбай, тезләре канап беткәндер мескенкәйнең.
Урыс Юлына җиткәндә таң сызыла башлады. Үз вакытында кайтмагач, әнисе бик өзгәләнәдер. Авыл башындагы кое сиртмәсенә тотынып көтеп торадыр. Шул якка күз салгач, нииндидер ак шәүлә шәйләгән сыман булды. Җеп өзәр хәле калмаган, күзләре әлҗе-мөлҗе килгән малайның саташам ахыры, дип уйлавы булды, ак шәүлә очып килеп тә җитте, кочаклап та алды, кычкырып елап та җибәрде.
Малайны дөньялыкка кайтарган бу тавыш, һичшиксез, әнисе тавышы иде. Аның яңакларын учына салган кул, сугышның бар михнәтен сеңдерсә дә, җылылыгын, назын югалтмаган, һәр күзәнәгеннән яшәү дәрте бәреп торган гүзәл татар хатынының кулы иде. Бу мизгелдә күктәге изге ай—бар яктылыгын, таң җилләре—бар сафлыгын шушы Анага биргәндер.
Авыр тормышның кара җәбере җанына үткән, күңеле менә сынам, менә сынам дип торган малай бу изгелеккә түзә аламы соң?! Елады да җибәрде Саяф, үзен тыеп кала алмады.
Ә ай тау түбәсендәге бу манзарага карап күккә кадакланды.
Онытма тарих: Үрә сулап торган үтә күренмәле ат. Улын күкрәгенә кысып таң аттырган Ана.
Озын Басуда: "Исән калсам, кабат ат җикмим, хуҗалык көтүен алам",—дип ант иткән Саяф сүзендә нык торды. Бригадир Нургали абыйсы да аңлады аны, сатмады. Ат җигәргә атлыгып торучы малай-шалае да булгандыр.
Демьян авылын чыккач, Озын Басудан барганда Саяф менә шуларны хәтерләде.
Хуҗалык көтүе алса да, башка көтүчеләр кебек, өй чиратыннан ашап йөрергә горурлыгы рөхсәт итмәде. Беренчедән, кешеләрнең үзенә дә юк, икенчедән, ул кунак сыенда йөзгәндә, әнисе, сеңлесе, энесе ач утырсынмы? Көз көне исәп-хисап ясарбыз, дип килештеләр.
Тагын бер ел узды. Илле өченче елның мартында Сталин үлде.
Юлбашчыны юксынып елаудан бүртенгән март көннәре, теләсәң-теләмәсәң дә, язга таба тәгәрәде. Көтү алгач тыныч яшим Алла боерса, дип йөргән Саяфның антын боздырды Нургали абыйсы. Ни үткен әнисе дә кайгылы айда бригадирга каты бәрелергә кыймады.
Саяф тагын ат җигә, Сәрдәхуш елгасында каерылып-каерылып чалгы селти дә, җәйнең үзен тәяп ишегалдына апкайтып аудара. Җәйне Әлфия китап битләренә кыстыра, җиләк итеп Миннегәрәй чүпли-чүпли дә әнисенә чәй эчәргә алып кирә, табын уртасына утырта.

...Менә тагын Нефтебазада Саяф. Кәрәчин агыза. Әнә, Гаяз абыйсы янына

шәһәр маржалары килгән. Урамга чыгуга, арба төбендәге арышны сатып та җибәрделәр.

Кибеткә кереп ашарга алдылар. Тамак ялгагач, чүмечләп аракы сатучы абзыйның да хәлен белделәр. Абзыйның хәле шәп иде, шәп абзый янынннан чыкканда Гаяз абыйсының да, Саяфның да йөрәге шәп—дөпелдәп типте.

—Йә, нишлисең?—диде Гаяз абыйсы. Капкан нәрсәсе булмаса да, Гаяз абыйсы белән нәрсә эчәргә дә риза булган Саяф бер стаканны түнтәрде шул. Кыюлык өчен эчәләр аны дип ишеткәне бар иде. Әтисе турында сорашу өчен дә кыюлык кирәк булмагае...

Тәненә аракы шаукымы таралган, кыюланган малай Гаяз абыйсына эндәшәсе итте:

—Гаяз абый, әтине очратмадыңмы син сугышта?—дип пышылдады.

Гаяз абыйсы малайның хәлен аңлаган кеше буларак, инбашына кулын салды. Нишләп аңламасын ул Саяфның хәлен? Беренчедән, үзе дә, әтисе исән килеш, ятим үсте. Житмәсә, әтиләре белән өйләре терәлеп тора иде. Аның әтисе икенче хатын белән гомер итте. Ул хатыннан туган балалар: "Әт-т-т-и!"—дип кычкырганда аның да бугаз ярып кычкырасы килмәдеме әллә?!. Икенчедән, хәзер үзенең дә гаиләсе бар. Хатыны Миннур белән ике бала үстерәләр. Мәдинәсенә февральдә биш, Рифатына майда өч яшь тулды. Әти булган кеше ят кеше баласының да хәлен аңлый шул. Менә шуңа малайның җилкәсенә кулын салды, кочаклап утырды. Әтисенең мәңге кочаклыйсы юк ич бу ятимне.

—Саяф, кәкә, әтиең бик яхшы кеше иде, шуны онытма. Мин сугышта күргәннәремне сөйлим, бәлки, соравыңа да җавап табарсың.

Мине унҗиде яшемнән сугышка алдылар, кырык икенче елның башында ук. Гәүдәле идем, яшьне сорап та тормадылар. Бераз наводчиклыкка укыттылар да, Сталинград далаларына ташладылар. Башта снаряд бирөп тордым, көчле идем, снарядны уйнатып кына йөртәм. Боезапас бетә башласа, командир тылга җибәрә, буш әйләнеп кайтмасымны белә. Снаряд китерүче ездовойларны да, аш ташучыларны да мина теткәләп аткан көннәр булды.

Бер сугышта наводчик та, командир да үлде, кайсы яраланып тылга озатылды. Кукмара егете Сорокин белән икәү генә калдык. Туп артына мин бастым, наводчик икәнемне онытма. Җиде кеше булганда ничек атты туп, шулай сугышырга тырыштык. Немецларның солдат, офицерларын күп кырдык, берничә танкны яндырдык.

Сугыш тынгач, безнең позициягә генерал килде, сугыш кырын карады, икебез генә икәнне күргәч, шаккатты.

—Ребята, к ордену представлю, спасибо, хорошо воюете,—дип, икебезне дә кочаклап үпте, җирәнмәде. Тирдән сасып, балчыкка, канга буялып беткән идек.

Шуннан соң Сорокин орден тагасы көннәр бар әле, дип, җибәргәли иде. Соңыннан борынын салындырып килде бу. Орден вәгъдә иткән генерал шул ук көнне һәлак булган икән. Сталинградны саклаучыларның батырлыгына ияләнеп беттек. Адым саен бугазга-бугаз килеп сугышасың, ужәтләнеп Иделгә ыргылган немецларны прямой наводка белән чебен урынына кырган көннәр дә, орден бирәм дип кәгазь тутыру түгел, тәүлек буе ашамаган чаклар да булды. Көн юк, төн юк, сугыш бара.

Ашау кайгыртып трибуналга эләгә язган кеше әле мин, бер гыйбрәт менә. Көне буе аш китерүче булмагач, сугыш тынып торган арада, командир Сорокин белән мине тылга озатты. Снарядлар да китерегез, ашарга да, ди. Киттек. Олаулар таптык, снарядлар төядек. Ашны термоска салып кузгалдык кына, безнең туп тирәсендә китте шартлау, китте атыш. Ничек кисәк башланса, шулай кисәк тынды да.

Сугышта иң куркыткан тынлык икәнне белмисең әле син, энекәш. Сугыш барганда дошманның кайда икәнен чамалау җиңел. Ул тавыш чыгара: ата, гүли, кычкыра, ракета чөя. Тынып калгач шикләнә башлыйсың, нинди мәкер кора ул? Разведчиклар килеп, чәнчеп, йә булмаса әсирлеккә алып китүләре мөмкинме? Бик мөмкин. Йә сине саклаучы пехота кырылып бетә. Мөмкинме? Ничек кенә әле! Дошман чолгап алырга да күп сорамый. Круглый оборона тотып сугышкан чаклар да була.

—Тукта, мәйтәм, земляк, атларны шушы чокырда калдырыйк, агачка бәйлә. Что-то не то безнен анда. Син монда кал, мин позицияне карап килим әле.

Тауга мендем дә шуышып киттем, үткер тимер кисәкләре эләгеп гимнастер-

каны тишә генә бит. Ул Сталинград җирендәге тимер-томыр бар дөньяга житәрлек булгандыр. Чү, немецча сөйләшәләр түгелме? Безнең туп тирәсендә немец солдатлары йөри. Гут, гут, диләр. Киткәннәрен көттем дә шуышып бардым. Йөрәгем кысып алды, биш кешенең берсе дә исән түгел. Документларын җыйдым. Тупны карыйм—тәп-тәзек. Замогы да алынмаган. Замогын алдым да Сорокин янына кайттым. Шундый-шундый хәлләр мәйтәм, нишлибез? Трибуналом пахнет. Туп немец кулына төшсә, командир тылга җибәрде дип исбатлый алмыйбыз, командир һәлак булган. Безгә—вышка! Уйла, мәйтәм, земляк.

Җилле-давыллы төн иде. Бәхеткә күрә җил немецлар ягыннан исә, сөйләшкәннәре, котелок кырган тавышларына кадәр ишетелә. Немец төнлә йөрми, тупны алып чыгыйк, мәйтәм.

—Башта ашыйк-эчик, тәүлек буе авызда бер валчык ипи дә гулять иткәне юк бит,—ди Сорокин. Берәр стопка спирт та җибәрдек. Башлы нәрсә Сорокин. Кабат болай эшләдек. Атларны тугардык та тупны тартып алып кайтырга киттек. Ничек азапланганны, туп тәгәрмәче баткач көрәк белән ничә тапкыр җир казыганны хәтерләрлек тә булмады. Аннан арбага төяп иптәшләрнең гәүдәләрен алып кайттык, снаряд чокырына күмдек. Исем-фамилияләрен язган такта куйдык.

Тан атар-атмас особый отделдан килеп тә җиттеләр. Тубыгызны дошманга биргәнсез, мин сезне подтрибунал, дип җикеренә офицер, пистолетын тартып чыгарып борын төбендә болгаган була. Маңгаена бер чиртүгә үтерәм инде мин аны, югыйсә. Борча инде менә, анын да уртачадан бәләкәе әле.

Алып барып күрсәттек, башта иптәшләрнең каберен, аннан өстенә ботаклар япкан тупны. Гафу да үтенә белмәде, тыловая крыса!

Иптәшләрне искә алып утырдык земляк белән, аларның да менә синең кебек бер көтү балалары калгандыр. Аракы эчкән егет түгел идем сугышка кадәр. Сугыш бозып бетерде, энекәш. Атака алдыннан йөз грамм спирт эчертеп юләрләндереп кертеп җибәрәләр солдатны, исән калсаң, үлгәннәргә поминка. Көн аралаш шулай.

Сигез ел үтсә дә сугыш һаман төшкә кереп саташтыра, җәфалый. Бергә сугышкан, күптән һәлак иптәшләр белән төннәрен кычкырып сөйләшәм икән. Туп атканда кычкырып сөйләшмәсән, бер-береңне ишетеп булмый бит. Менә мин шуңа кычкырамдыр. Миннур апаң да, балалар да куркышып бетте. Вакыт-вакыт чоланга чыгып йоклыйм, анда да күршеләр ишетә.

Мин сугышта үлемнән курыкмадым, "гарипләндереп кеше күзенә каратып яткырма"—дип, Ходайдан сорый идем. Аллага шөкер, гозеремне ишетте Ходай.

Сталинград сугышының бер көненә чыдаган солдатка орден бирер идем. Тик чигенгәндә орден өләшмиләр шул. Сугышның соңгы ике елында ике Кызыл Йолдыз ордены, "За отвагу" медале бирделәр. Сталинград янындагы сугыш белән берсен дә чагыштырырлык түгел шул, кәкә. Анда бит бер исән тау, бер исән агач калмады, кая кеше...

Туктадык та, кибеттән алган консерваны ялт иттердек. Флягасыннан су эчкәндә Гаяз абый тагын бер вакыйганы сөйләде:

—Шул Кукмара егете Сорокин белән инде, земляк белән, соңгы снарядка кадәр аттык, мылтык патроннарын да атып бетердек. Тупны немец танкысы үтүкләде. Далада снаряд чокырына качтык, без генә түгел, авыр яралы солдатлар да җыелды. Берничә гайрәтле солдат чокырдан чыгып йөгергәннәр иде, пулеметтан кырып кына салдылар.

Биш-алты яралы тиздән ыңгырашудан туктады, үлделәр. Каннары агып бетте, берни белән ярдәм итәрлек булмады. Ә без җиңел яралы идек, канны туктата алдык. Дала буйлап немецларның үлем командирлары иснәнеп йөри, авыр яралыларны аталар, йөри алганнарын әсир итәләр.

Сорокинга әйтәм: үлекләр астына кереп ятыйк, атсалар да үле гәүдәләр саклар, дим. Шулай эшләдек тә. Пуля тисә дә тынынны чыгарма, тоткын булганчы үлгәнең мең өлеш артык, дидем. Ул да шул фикердә.

Кырт-кырт сөйләшкән тавышлар якынлаша. Килеп бастылар чокыр кырыена. Берсе һавага атты, көлгән була. Исәннәр бармы дип тикшерә, янәсе. Капут махен!—дип китеп бардылар.

Ике тәүлек яттык шул чокырда, мәетләр астында. Немецлар үтеп-сүтеп йөриләр. Әле берсе автоматтан да сиптерде. Сорокин, кычкырмаска тырышып, иренен тешләп өзгән иде. Ә пулялар минем өстәге мәетне теткәләп бетергән.

Эссе көн, мәетләр исләнде. Тамак кибүгә чыдый алмыйча чокыр төбендәге канлы, сасыган яңгыр суын эчәбез. Яшисе килә бит, энекәш. Менә сиңа ничә яшь?

—Уналты, Гаяз абый.

—Миңа унжиде иде. Әле генә без синең белән үзебезнең Трайт чишмәсенең суын эчтек. Су түгел ул, энем, ширбәт. Ике тапкыр канлы су чөмергән кеше мин. Берсен ишеттең. Икенчесен, Днепрны кичеп плацдарм алгач, шул җир кисәген тотып торганда эчтем. Ничә тәүлек буе канлы су аккандыр, әйтә алмыйм. Бүтән су юк иде, кан тәме килгән Днепр суын чөмердем...

Гаяз абый кинәт тынып калды. Карашы еракка—Мамадыш тарафына юнәлгән, кай җиредер бик хәтәр авырткан шикелле йөзе җыерылган, әйтерсең лә, сугыш михнәтләре тагын бер тапкыр аның җанын, рухын сыта, хәтерен тетрәтеп эчке дөньясы аша уза иде.

Мине үз итеп, тиң күреп сөйләшүеме, иңнәремә куйган саллы кулымы, минем арык тәнемә терәлеп утырган тау кадәрле гәүдәсеме—Гаяз абыйны әтием Миннәхмәт итеп тоюга китергәндер.

—Шунысы рәнҗетә, энекәш, башкаларны әйткән дә юк, кайчагында, мин сөйләгәннәргә Миннур апаң да ышанмый. Бит үземне герой итеп күрсәтү өчен сөйләмим, бары бушанасы килә. Сигез ел үтте, җандагы сугыш йөгенең сигез граммга да җиңеләйгәне юк әле...

Без ун чакрымлы Озын Басуны узып Демьяновкага якынлашабыз икән. Ат җикмәсәм, Гаяз абый белән очрашмаган булыр идем, бригадир Нургали абыйга да рәхмәт инде.

Демьяновкада Фатыйх абый белән Хәнифә апа яшәгән өйгә кердек. Хуҗалар табынга хәзинәдә булганның барысын да тезде. Сүзне Кече Кирмәннең Түбән очыннан башладылар, Югары очтагы Аксак Хәсән абыйның капкасын дөпелдәтеп япкач кына туктадылар. Бик сагынганнар иде шул туган авылларын Фатыйх абый белән Хәнифә апа. Мәҗлес ахырында барыбыз да чиксез иркенләп, табынга әле генә китереп утыртылган уалма бәрәңге кебек таралып, шул бәрәңгедән ургылып чыккан парга ияреп күкнең җиденче катына менеп җиткән идек.

Иң якын туганнары шикелле озаттылар Гаяз абыйны. Авыл кырыендагы имәнгә сөялеп, Кече Кирмәнгә кайтып баручы авылдашларының бәхетеннән көнләшеп кул болгап калдылар. Күзләрендәге моңсулык Фатыйх абый белән Хәнифә апаны имәннәргә сөялдергәндер.

Арташ чокырын менгәндә Гаяз абыйның әйткән сүзләре хәтеремә уелды, зираттан шикләнгәнемне сизде, ахыры.

—Кәкә, зиратлардан курыкма. Бу сугышта Европа тоташ зиратка әйләнде, исәннәрдән куркыйк,—диде.

Урман почмагында атларны ял иттереп, печән ашатырга да онытмады Гаяз абый. Хәнифә апа тыгып җибәргән дучмакларга да чират җитте. Чыннан да, әллә ашадым, әллә юк, юньләп хәтерләмим дә. Аракы миемне томалаган булгандыр.

—Энем, син аракы эчмә. Бүген дә мин гөнаһыга батырдым, ахыры, сине,—диде Гаяз абый.

Бурсык елгасы янынннан үткәндә, Мамадышны аклар алгач, Кече Кирмәнгә һөҗүм итсәләр, сугышасы була дип казылган окопларны күрсәтте бугай.

Урыс Юлы тавында тормозлар куйдык та, атлар арбаларын тартып төште. Инешне чыгып бара идем, әллә салган баштан дилбегәне ялгыш тарттым, әллә атның су эчәсе килде, арбаны кырт борды да куйды. Кәрәчинле мичкә инешкә "бух" итеп килеп тә төште. Ат, куркудан чыгымчылап, Гаяз абый аты янына чапты.

—Болай итик, энекәш,—ди Гаяз абый.—Минем мичкәне синең арбага күчерик, аннан минем ат белән инешкә төшеп, синең мичкәне саласы булыр.

Шулай эшләдек тә.

—Ә суда яткан авыр мичкәне арбага салу өчен әнә теге, мунчала кабыгы саклаучы ирләргә дәшеп кил.

Без постта дип, башта ирләр тыңламады. Аннан килеп мичкәне салыштылар тагын. Изге кешеләргә рәхмәт укыдым. Атым янына менгән идек, аһ иттек. Әти төсе булган, җиз тәнкәләр белән бизәлгән ат дирбияләренең берсе дә юк, урланган иде.

Тотылмаган—карак түгел, ди. Кемгә бәйләнәсең? Гаяз абый өеннән төрле

бау кисәкләре алып төште дә атны җиккән кебек итте.

—Норма авылына Әсгать дуска илтеп куя алмассыңмы, Гаяз абый,—дидем мин.

—Борчылма, Саяф, дөнья малы—дуңгыз каны, баш сау булса, бар да табылыр,—диде абзый.

Әсгать дустым мине бик җылы каршы алды. Гаяз абыйга рәхмәт әйтеп саубуллаштым. Кабат миңа Гаяз абый белән шулай озаклап аралашырга туры килмәде. Илле ел вакыт узган да киткән. Абзый инде күптән вафат, ләкин мин һаман да аның инбашыма салынган саллы кулын, минем кебек маңка малайга, бүтән беркемгә дә сөйләмәгән эч серләрен ачып, үз итеп сөйләшүен хәтерлим. Минем сугыш ветераннарына булган олы хөрмәтем Гаяз абыйдан башланды! Бәхәссез.

Дустым Әсгать белән төн буе юкә дирбияләр ясадык. Икенче көнне ап-ак юкәдән киендерелгән атым белән мин Су-Елгага теркелдәдем. Күчмә отрядка кәрәчинне тапшырдым, механик Шакирҗанов Гаяз абый хәлемне сорашты, рәхмәт әйтте...

Күп сулар акты, күп яфраклар коелды. Ярты гасыр вакыт узды. Өстәлгә аракы килүгә мин Мамадыш нефтебазасына кәрәчингә баруымны, шунда тәүге тапкыр аракы эчүемне, аның зәхмәте аркасында мичкәне инешкә аударуымны, газиз әтием төсе булган җиз дирбияләрне урлатуымны хәтерлим. Шунда алган сабак исергәнче аракы эчүдән гомерем буе тыеп торды.

Илле өченче елның көзендә суык тидергән энем урынына, хуҗалык көтүенә чыктым. Хәзер әбиләр чуагы дип йөртелүче гаҗәеп җылы, ямьле көз иде. Сәрдәхуш елгасы башындагы каеннардан берән-сәрән генә яфрак оча. Мин, әтидән калган фуфайканы җиргә түшәп кырын-ярын яткан килеш, җил тавышын тыңлыйм. Камылларга бәргәләнеп аккан тыгыз һава нинди генә аваз чыгармый. Мәче мияулаган, тычкан чыелдаган тавышлар яңгырый, ә урманнан әллә кайларда, еракта өргән этнең саңгырау тавышы. Габделкаюм абый алып кайткан арышны өй базында тартучы кул тегермәне зырылдавы да, Гаяз абый белән далада снаряд чокырына качкан авыр яралы солдатларның тешләрен шыгырдатуы да ишетелә сыман.

Тамак тук. Сыерлар Сәрдәхуш елгасындагы яшел курпыны умырып ашыйлар. Ә саргая башлаган кыяклар, җил искәндә әле сулга, әле уңга авышып, район уполномоченные алдында бишкә бөгелүче колхоз рәисен хәтерләтә.

Сердәш чишмә челтери дә челтери. Сугышка киткән әтиемнән үле хәбәре килгәч тә, мин шушы чишмәгә сыенган идем. Хат ташучыга публик килгәнне әнигә әйтмәскә куштым. Кара хатны әнә теге каен төбенә күмдем. Мин түгел, каен да кайгыга чыдамады, корыды, әнә, ботакларын коеп, көзге җилдә ыңгырашып утыра.

Үги әтине кулга алгач та шушында үкси-үкси еладым бит. Аулакта инде. Габделкаюм абый дип йөргәч тә, анысы форма өчен генә инде аның. Кешенең ике әтисе булмый, ди Габделбарый. Ә мин була дим. Чөнки үз әтиемне юньләп хәтерләмим дә. Ә менә Габделкаюм абый үзе төрмәдә черсә-череде, ә безне исән калдырды.

Нәрсә генә уйлый башласам да, уем шул Габделкаюм абыйга әйләнеп кайта. Нигә шулай икән ул, ә?

Ул төрмәгә киткәч, шушы чишмә янында белгән-өйрәнгән догаларымны укыдым. Сеңлем Әлфиянең чулпысыннан өзгән көмеш акчаны чишмәгә салдым. Әле дә шунда ятадыр. Файдасы тиде микән, дүрт ел вакыт узса да, үги әтидән бер хәбәр дә ишетелми. Исән микән?

Тамак ялгап, акыллы күзләре белән әмер көткән Актүшне дә туйдыргач, аяк язып, йөреп киләсе иттем. Көн җылы булгач юка киенгән идем, атлаулары да очып барган сыман. Менә Саяф, мәйтәм, уналтыны да тутырдың, Аллага шөкер. Әниең исән, сеңлең, энең исән. Хәләмгөл кызыкайны да күрәсең киләдер, син кич белән Кече Кирмәнгә кыякла. Билгеле инде: Габделбәр дусның хәлен белү сылтавы белән, изге ялган табып. Хәләмгөлгә бирәр бүләк элэктереп бармасаң, юкка-бушка, юл тиреслап йөрү булмасмы? Кибеттән нәрсәдер сатып аласы булмагае. Акчаң бар. Урманда эшләүче авылдашларына атың белән булышкач, кесәңдә акча чыңлаган тавышлар да ишетелә. Кем ничек тели, шулай түли, Саяфның булышуы хак булсын.

Акча сикертә, диләр бит. Шуңа җил-җил атлап очынамдыр, дип, Саяф елмаеп

җибәрде. Туган авылы ягына күз салган иде, бирегә таба килүче кешене абайлап, туктап калды. Атлар-атламас килүче бу оялчан йөрешле ир-атның адымында хәтер капкасын кагып ачарга азапланучы дулкын омтылышы бар иде. Туктале, туктале. Кем куллары, аяклары белән һаваны болай уймаклый сон? Әллә кешесе ерак булды, әллә киемнәре таныш түгел—Саяф Юлаучыны танымады. Ләкин мосафирның аның янына килүе бәхәссез иде. Тирә-юньдә бер адәм заты юк, бу тарафтан юл да узмый.

Елганың теге ягына чыгып каршылыйм әле дип, тирән чокырга төшеп китте Саяф. Ярдан йөгереп менүе булды, теге кеше белән маңгайга-маңгай бәрелә язды. Ах!—дип кычкырып җибәрде дә, ябык гәүдәле, мескенлеге кыяфәтенә чыккан, нәрсәдәндер куркып калган таныш һәм шул ук вакытта таныш та булмаган ирне шытырдатып кочаклап алды. Аның киеменнән бөтен Азияне дер селкетеп ауган Себер кедры исе дә, ГУЛАГ лагерының кандалалы сәкесенә сеңгән ачы хәсрәт тә, миллионлаган гөнаһсыз тоткыннарны кызганудан җаны өшегән, аларның күз яшьләреннән мәңгелек тунга әйләнгән Себер җиренең өшеткеч салкыны да килеп бәрелде.

—Габделкаюм абый, кая, өйдән килүенме?

—Юк.

—Бар өйгә кайт, сине анда әни көтә.

Шулай дип әйтүем булды, Габделкаюм абый бар гәүдәсе белән калтыранып, үксеп-үксеп елый башлады, сыгылып төште дә, төбенә этинең үле хәбәре күмелгән, корыган каенга барып ябышты. Ә каен төптән сынып гөрселдәп җиргә ауды. Бу да ухылдап елаучы ирне туктата алмады.

Мин аны кочаклап алдым да таза, кем генә килеп таянса да чыдатырлык, Хәләмгөлгә ошатып йөргән ябалдаш каенга сөялдердем. Әле ул каенга шук энем үткен пәкесе белән Маһинур, Саяф, Әлфия, Миннегәрәй дип тә язган иде...

Елап җибәрү оятыннан үзен кая куярга белмәгән Габделкаюм абый бәгыреннән бер генә сүз кысып чыгарды:

—Кабул итмәссез дип курыккан идем.

Ул биштәреннән сабы төсле ташлардан тезеп ясалган пәке чыгарды, анда "Саяфка" дип язылган иде. Сынар кулы белән мине кочаклап торды да Су-Елгага таба атлады. Оча иде Габделкаюм абыйсы, бауга кибәргә эленгән күлмәк кебек талпына иде. Бу инде Саяф күргәндәге туктар-туктамас килүче, оялчан адымлы мосафир түгел. Аның сынар кулы кылыч сыман һаваны тураклый, аяклары җир шарының әйләнешен тизләтә, сөенечтән балкыган күз карашы Су-Елганы прожектор сыман яктырта иде.

Габделкаюм абый белән без ятимлекне тоймадык, каралты-курабыз кешенекеннән ким булмады. Ул безне шулкадәр якын итте, хәтта үлүенә кырык ел узгач та аны искә төшерсәм күңел тула, күзгә яшь килә. Утырган урынымнан кымшана башласам да: "Нәрсә кирәк, Саяф?"—дип ягымлы җылылык белән эндәшүче үги әтием Габделкаюм мине гомер буе кешеләргә изгелек эшләргә этәргәндер. Урыны оҗмахта булсын.

Армиядә хезмәт иттем дә Уралга, апаларга кайттым. Паспорт алдым, колхозда бушка эшләү коллыгыннан котылып, үземне кеше итеп тоеп, Су-Елгага кайттым. Үги әтидән дә уздырып сөенүче булмагандыр.

Миннегәрәйгә дә паспорт юнәттем.

"Кызыл партизан" күмәк хуҗалыгы рәисе Сафин Закир абый колхоз эшенә чыкмасагыз утыртам,—дип янаса да, минем курка торган күлмәк тузган иде. Икебез дә леспромхозда эшләдек, хуҗалыкны бөтәйттек.

Хәләмгөл гүзәлкәйгә өйләндем дә Бакал шәһәренә барып эшкә урнаштым, акчаны көрәп алабыз, өйгә дә салабыз. Су-Елгага кунакка кайтабыз. Үги әти белән күрешү тагын бер елга куаныч өсти, шатлык бирә иде.

1962 елда Кариб кризисы башланды. Мине янадан армиягә—переподготовкага алдылар. Воркута янында локаторда тәүлекләр буена дежурда торабыз. Яңа, өченче бөтендөнья сугышы башланырга бер адым калган иде.

Мине армиягә алуны ишеткән үги әти, чирләп, урын өстенә яткан. Яңа сугыш башлана дип тетрәнү, өзелгән кулын куенына тыгып, шуышып, үзебезнекеләр ягына чыккандагы кичерешләр, балакайларым ачка үлә дип башак урлап, унбиш елга төрмәгә эләгү, җитмәсә, аның аркасында бердәнбер сыерыбызны тартып алуда үзен гаепле санау Габделкаюмны түшәккә бәреп салгандыр. Йөрәге чыдамаган. Күмгәннәр. Үләр алдыннан: "Их, Саяфны тагын бер күрсәм, үлсәм

дә үкенмәс идем",—дигән. Ә мин шактый соңлап ишеттем. Воркутага хат килгәч кенә. Үги әтиемне күмә алмаганга гомер буе үкенеп яшим.

Менә тагын Уралдан Су-Елгага кайттык. Кыш көне булса да, Хәләмгөлне ияртеп, Сәрдәхуш елгасындагы Сердәш чишмәгә, исемнәребез уелган каен янына менмичә булмас.

Каен, нарат, карагайлар моңсуланып утырган зиратка баруым. Авыллар белән зиратлар мәңге янәшә. Әни янына, Габделкаюм исемле Изге Зат янына дога пышылдарга килүем.

Сукмактан атлаучы Саяфны ниндидер көч күккә күтәрелеп карарга мәҗбүр итте. Зәп-зәңгәр күктә моннан илле ел элек күренгән Ак Болыт эленеп тора иде. Аннан гимнастерка кигән Гаяз абыйсы, култыгына журнал кыстырган Мәхмүт абыйсы, сыңар кулына сугылмаган башаклар учлаган Габделкаюм абыйсы, бер сүз белән әйткәндә, Ватанны саклаганда кан түккән изге затлар карап тора иде.

Барысы да күкнең җиденче катында икән дип сөенде Саяф. Урал заводында эшләгәндә фидакарь хезмәтләре өчен орденнар алганда да ул бу кадәр дулкынландыргыч, илаһи мизгелләр кичермәгән иде. Гаяз, Мәхмүт, Габделкаюм абыйларының күз карашы бөтен гомере буена җыелган борчуларын каз каурые белән сыпырган сыман койды да төшерде.

Искиткеч җинеллек, гаҗәеп рәхәтлек кичергән Саяф күккә күтәрелеп караганда Ак Болыт гаип булган, аның урынында иксез-чиксез зәңгәрлек җәйри иде...

* * *

Ә бу вакытта Ходай иңдергән изге диненә, тарих насыйп иткән авыр язмышына, Кече Кирмән дигән изге исеменә тугры калган авыл, ике йөз чишмәсеннән җанга сихәт бирүче саф суларын челтерәтеп киләчәккә бара иде.

Гасырларны йөзтүбән каплаган шарлавыклар, илләрне йоткан чоңгыллар, дәверләрне җир өстеннән кырып-үтүкләп киткән бозлыклар, кыйтгаларны теткәләгән бусагалар аша исән-имин чыккан бу авылга тарихта алга таба да Ак Кирмән ханлыгының дәвамчысы булырга язгандыр.

Ул алышынып торучы, ләкин гамәлләре бер чамада булган хакимиятләр, авыр яралаган арыслан шикелле, җанын дәвалап үзенең элгәресенә—диненә, кыйбласына, мәсләгенә юл сабарга талпына иде.

Кинәт, Сукыр урамның берьяклап кына салынган өйләренә капма-каршы итеп, затлы Арча кирпеченнән күтәрелгән ике катлы өйдә бала тавышы яңгырады. Авыл өстенә якты сирпеп утыручы каеннар да, борынгы зират та, күк гөмбәзен Алып кебек тотып торучы тал-тирәк тә, түбәсеннән кар эшләпәләре асылынган Казыган тау да: "Бәрәкалла!"—дип кыйблага табан борылды. Бу—башта Ходай, аннан Сабый дип яшәүгә ишарә иде...

*2003 ел.*

# М. МӘҺДИЕВ ИҖАТЫНА БЕР КАРАШ

Мөхәммәт Мәһдиев—татар мәдәнияте тарихын яхшы белгән галим, укытучы да, күпләрнең яратып укый торган повестьлар авторы, язучы да. Аның әсәрләрендә тирән фәлсәфә белән бергә, халкын яратуы, аны сөеп, ачуланып яки оялтып асыл сыйфатларына кайтарырга теләве чагыла.

М. Мәһдиев татар әдәбиятына “Без кырык беренче ел балалары” (1968) повесте белән килеп керде. Сонрак “татар халкы өчен асыл дөнья булган авыл хәятын фәлсәфи-әхлакый пландарак аңлату һәм күрсәтүне максат итеп, ул “Каз канаты” романын, “Кеше китә—җыры кала”, “Торналар төшкән җирдә”, “Ут чәчәге”, “Исәнме, Кәшфи абый”, “Бәхилләшү”, “Ачы тәҗрибә” повестьларын иҗат итә. Бу әсәрләрдә язучы “аеруча туган җиргә, аның хезмәтчел һәм тыйнак кешеләренә мәхәббәт һәм хөрмәт хисләрен чагылдыра” *(Закирҗанов Ә. Яшьлеген сагынучы әдип// Мәгариф.—2000.—N 2.—34 б.).*

Әдәби тәнкыйтьтә М. Мәһдиев иҗаты турында фикерләр күп әйтелде. Әдәбият белгечләре һәм тәнкыйтьчеләр—Ф. Миңнуллин, Т. Галимуллин, Р. Мостафин, Р.Мөхәммәдиев—аның әсәрләренә хас җылы лиризм, табигыйлек һәм тормышка якынлыкны искәртәләр, табигатькә дусларча мөгамәләгә, “аерым кеше белән олы дөнья күренешләре арасында тирән якынлык, эчке уртаклык таба белүе”нә игътибарны юнәлтәләр *(Миңнуллин Ф. Яшьлекне сагыну/Миңнуллин Ф. Талантлар юлы.—Казан: Тат. кит. нәшр., 1984.—180 б.; Мөхәммәдиев Р. Якутлар табыладыр вакыт белән.—Казан, 1983.—278 б.; Галиуллин Т. Кеше китә—җыры кала// Мәгариф.—1995.—N 10.—17-20 б.).*

Мөхәммәт Мәһдиевнең иҗатына хас бер моментка игътибарны ныграк юнәлтәсе килә. Ул, демонстратив рәвештә диярлек, социалистик реализм дип аталган методтан, аның әсәрнең поэтикасын тудыруга булган таләпләреннән, характерларны һәм вакыйгаларны тудыруда сәбәп-нәтиҗә бәйләнешеннән, ягъни әсәрне бер сюжетка корудан читкә китә.

“Әдипнең күпчелек әсәрләрендә башыннан ахырына кадәр сызылып бара торган сюжет сызыгы юк”,—ди Ә. Закирҗанов. Вакыйгалар да монда бер-бер артлы, хронологик тәртиптә бирелми, алар кучеп йөри. Нәтиҗәдә, язучының әсәрләрендә сюжет үзенең традицион ролен югалта, аның вазифасын бүлекләрнең лейтмотивлары башкара, хикәяләү фрагментар рәвештә бара. Бүлекләрне исә, үз чиратында, ассоциатив моментлар, бүлек ахырларында бирелгән автор фикерләре-нәтиҗәләр һәм дә автор образы үзе бәйләп тора.

Мәсәлән, “Бәхилләшү” повестен алыйк. Укучы алдында, башка язучылар әсәрләрендә күреп күнеккәнчә, бер вакыйганың үстерелеше түгел, ә чынбарлыкның өзек-өзек һәм төрле чордагы төрле вакыйгалары пәйда була. Шул сәбәпле, тормыш ул калейдоскоп кебек гел үзгәрүчән дигән тәэсир ныгып урнаша.

Повестьтагы бүлекләрнең алмашынуы, авторның бер вакыйгадан икенчесенә сикерүе логик яктан нигезләнмәгән кебек тоела. Вакыйгаларны бирүдә гомум линияләр һәм ялтыравык детальләр өстенлек итә. Вакыйганың агышы турында уйлыйсы урында, укучы әлеге вакыйгадан алган кичереш белән тәэсирләнә. Композициянең төзек түгеллеге, тәмамланмаганлыгы, эпизодлар рәвешендә булуы, төп фикернең әйтеп бетерелмәве язучы тарафыннан махсус сайланылган, чөнки чынбарлыкның өзек-өзек кисәкләре, беренчедән, хәтер киштәләрен берәм-берәм актаруга ишарә,

икенчедән, ул тормышның да әнә шулай төзек түгеллеген, татар авылының гына түгел, татар характерының үзгәрүен, катлы-катлыга әверелүен, татар кешесендә эчке бер ныклы үзәкнең булмавын күрсәтә.

Әлеге моментлар М. Мәһдиев иҗатында импрессионистик эстетиканың чагылыш табуы хакында сөйли. Импрессионистик эстетика һәм әлеге юнәлеш вәкилләре тарихи чор атмосферасын мөмкин кадәр тәэсирле итеп, тормыш-чынбарлыкның тулы картинасын, җәмгыятьнең гомум халәтенең кешеләр характерына, аңына йогынтысын сизелерлек итеп сурәтләүне максат итеп куйдылар.

"Бәхилләшү" повестенда бирелгән характерлар тормышның үзендәге кебек үк төрле һәм күп. Әлеге характерлар үзләре бирелгән вакыйгалар эчендә югалып калалар, вакыйгалар һәм ситуацияләрнең байлыгы, колорит бу вакыйгаларның тарихи агышын оныттыра. Болар барысы да тормышны хаос рәвешендә тасвирлауга хезмәт итә. Әсәрдә бирелгән Исламгали, Хәерниса, Хәмит, Зариф, Фәләхетдин кебек геройлар һәрберсе шәхес буларак кабул ителә, ләкин алар да нәкъ менә шушы вакыйга эчендә билгеле бер моментта гына кызыксыну уята. М. Мәһдиев үз геройлары хакында сөйләгәндә аларның үзгәрүчән холкын, кәефләренең төрле булуын тасвирлый. Автор образына бәйле рәвештә исә кешенең төрле кичерешләр эчендә януын ассызыклый.

Сурәтләүдә импрессионистик техника алымнарын куллану язучы иҗатының поэтикасын һәм проблематикасын ачык чагылдырып кына калмый, әдипнең дөньяга карашы, әһәмиятле идея-эстетик кыйммәтләре, принциплары һәм, ахыр чиктә, язучының тормыш-чынбарлыкны шул рәвешле кузаллавы хакында сөйли.

"Бәхилләшү" повестенда социалистик реализм кануннарына туры килмәгән тагын бер момент бар. Бу—әсәрне беркетеп торучы идеологик үзәкнең үзгәлеге. Күрәсең, тормыш-чынбарлыктагы вакыйгаларның агышын читтән карап торучы автор образы язучыны канәгатьләндерми, ул үзе үк әсәрнең, ягъни үзе тудырган дөньяның, эченә кереп китә, анда катнаша. "Бәхилләшү" повестенда хикәяләүче авторның аңы,—хикәяләү, вакыйгаларны бәян итүне оештыру алымы гына түгел, ә нәкъ менә язучының этик һәм әхлакый позициясе ачык чагылган идеологик үзәк тә.

Повестьның идея эчтәлеген сурәтләнгән вакыйгаларга карата төрле геройларның карашлары да тулыландырып тора. Мәсәлән, Хәмитнең үз баласын тәрбияләүдә япон методикасын куллануына бер Исламгалинең генә мөнәсәбәте китерелми әсәрдә, авыл халкы, Исламгалинең хатыны, авторның үз карашы һәм хәтта укучының да шәхсән фикере чагыла монда. Ләкин әлеге карашларны берләштереп тә булмый, алар бары тик дөньяның әнә шулай "төрле тавышлы" булуын, бербөтен түгеллеген тагы бер кат икърар гына итәләр.

Милли характерларны тудыру остасы саналган Мәһдиев үзе белгән татар менталитетының акрын-акрын гына җимерелә баруын төрле гореф-гадәтләрнең югалуында, онытылуында да күрә. Язучы, фәлсәфи чигенешләр, публицистик өзекләр белән әлеге җимереклекне тулыландырырга, кайчандыр бербөтенне, ныклы үзәкне тәшкил иткән күренешләрне бәйләргә теләгән кебек. Шул ук вакытта хәтердәге вакыйгаларны барлау һәм, бүгенгегә кайтып, аларга бүгенге көннәр күзлегеннән карау аша, бүгенге көн геройларының репликалары, фикерләрен китерү ярдәмендә моның мөмкин түгеллеген дә күрсәтә. "Син, чего-то, авыл, дип мактанасың. Ә бит синең авылыңда иң таза хуҗалык ул—зират. Калганнары беткән. Зират бит ул яшәү өчен түгел. Ә син миңа "авылны яратырга кирәк, авылны сакларга кирәк..." Ну, ничек",—дигән сорау яңгырый авторның улы булган автобиографик образ авызыннан.

"Бәхилләшү" повестенда М. Мәһдиевнең дөньяга һәм кешегә, татар халкының үткәненә һәм киләчәгенә, татар кавеменең дәвамчысына карата үзенчәлекле карашлары чагылыш таба.

Милли мәдәни традицияләргә, ислам дине фәлсәфәсенә һәм кануннарына нигезләнеп яшәгән һәм үзенчәлекле бер микрокосмос тәшкил иткән татар дөньясы Ватан сугышы алдыннан инде тамырдан үзгәргән, шартлатылган. Ләкин ныклы рухи нигезне саклап калучылар һәм татар характерын, менталитетын үзгәртү юлында хезмәт итүчеләр белән ике арада яшерен каршылылык ятканлыгы ачык күренә. Бу көрәштә исән калу, үз асылыңны, бөтенлегеңне, җан тынычлыгыңны саклап калуның төп чарасы үз карашың белән яшәү, үзеңчә көн итү икәнен без Исламгали, Хәрниса, Нәзәһәт кебек геройлар мисалында күрәбез.

Мәһдиев иҗатына импрессионистик эстетиканың тәэсире хакында сөйләгәндә, без аның повестьларында реалистик типиклаштыру принципларының булмавына да игътибар итәбез. Реализм, иҗади метод буларак, детерминизмны таләп итә, вакый-

галар, күренешләр һәм характерлар арасында теге яки бу дәрәҗәдә ныклы конкрет сәбәп-нәтиҗә бәйләнешен алга куя. Мәһдиевтә исә без, аеруча "Бәхилләшү", "Ачы тәҗрибә" әсәрләрендә, менә шундый катгый детерминизмны күрмибез. Әсәрдә бирелгән вакыйгаларның һәрберсендә төп рольне үтәгән бер конкрет сәбәп аталмый. Әйтик, Хәернисаның язмышы шул рәвешле булуда яки Исламгалинең улы Хәмиднең "зур кеше" булып китүендә яки Нәзәһәтнең тормышы аянычлы корылуында язучы, беренче чиратта, иҗтимагый сәбәпләрдән тукылган типик вакыйгаларны түгел, ә шәхеснең үзен җаваплы итеп күрсәтә.

Мәһдиев иҗатында кулланылган импрессионистик поэтика язучыга кануннар нигезләнүенә корылган реалистик эстетикадан читкә китәргә, нәтиҗәдә "тере", җанлы, кызыклы әсәрләр тудырырга мөмкинлек бирде. Әдипнең яшәү принциплары, социалистик реализм кануннары таләп иткәнчә, чынбарлыкта булмаган яна дөнья моделен тудыруны, аны матурлап, арттырып-бизәкләп бирүне кабул итми. Ул тормышны ничек бар шулай тасвирлау юлын сайлый. Нәтиҗәдә, аның "Бәхилләшү" повесте да халык массаларының тормышы, яшәеше, язмышы кебек кабул ителә.

"Бәхилләшү" әсәренә карата повесть (кайбер мәкаләләрдә ул роман дип тә бирелә) төшенчәсе туры килеп тә бетмәгән кебек, чөнки монда тормыш картинасы кисәкләргә бүленгән, әсәрне берләштереп торучы бер сюжет сызыгы, идеологик үзәк юк, вакыйга-ситуацияләр мозаика хасил итә, аларның төрле тәртиптә бирелеше, авторның төрле вакыт аралыгында иркен һәм еш хәрәкәте хаос тудыра. Әсәр бу яктан орнаменталь прозага якыная. "Бәхилләшү" поэтикасындагы бу элементлар төп геройның, шәхеснең язмышын вакыт агышы эчендә сурәтләүне алга куйган повесть жанрының сыйфатларын танырга комачаулыйлар.

Шулай да әлеге әсәрнең повесть жанрында язылганлыгы бәхәссез. Гәрчә, төп сурәтләү предметы булып язучының "Хикәяләүченең, төп геройның, тормыш-чынбарлыкны кабул итүче аңы торса да, шәхес язмышы, аның тормышы нәкъ менә шул субъектив аңның хатирәләрендә ачылып бетә. Әсәрдә хикәяләүне оештыру поэтик принципка нигезләнә, бу үз чиратында повесть текстының композицион төзелешенә туры килә.

Саф импрессионистик проза әсәрләреннән аермалы буларак, "Бәхилләшү" повестенда автор образы, аның сюжет төзүдәге һәм геройларны характерлаудагы субъектив позициясе ачык күренә, чөнки әлеге повесть—ул автобиографик характердагы повесть. Шуңа да анда авторны ачыктан-ачык күреп, танып була. Күп очракта автор хикәяләүче ролендә чыгыш ясый һәм өченче заттан сөйли. Шуңа да автор позициясе һәм хикәяләүче арасында дистанция, аермага басым ясап булмый, чөнки хикәяләүче автор фикерләрен, идеяләрен чагылдыра. Төп герой белән хикәяләүченең дә вакыт-вакыт бер-берсенә керешеп китүе аларның тормышны, әхлак, гомумкешелек кыйммәтләрен кабул итүдәге уртаклыгы белән билгеләнә.

Әсәрдә автор позициясен ачыклаучы иң беренче момент—ул автор бәяләмәсе. Барлык образларга, вакыйгаларга, предметларга авторның карашы-мөнәсәбәте сеңгән. Мәсәлән, кайбер геройларга автор уңай да, тискәре дә бәя бирә. Әйтик, Сәмигулла образына. Сәмигулланы Хәернисаны "харап итүче" дип атап, аны тискәре яктан сурәтләгән булса, хакыйкатьне ачып, Хәернисаның баласын үзенекедәй каравын әйтеп, ул аны олылый, аның бу адымы алдында баш ия. Шулай да Сәмигулланың балалары мисалында әлеге геройга карата негатив мөнәсәбәт сүнеп бетми, чөнки, беренчедән, алар Сәмигулла каны, нәселе, икенчедән, Сәмигулла аларны тәрбияли алмаган.

Мәһдиев әсәрендә фикер йөртү башта, алдагы бүлекләрдә бер кешегә, авторга гына бирелгән кебек тоелса да, соңрак "полифония" урын ала, ягъни хатирәләрне бирү тәртибендә автор әсәргә керткән геройлар үзләре үк "фикер йөртә", "сөйләшә" башлыйлар. Беренче бүлектә без хикәяләүче сөйли дип кабул итәбез, ләкин ныграк уйлаганда, хикәяләүченең Исламгали образы белән керешеп китүен тоябыз. Мәсәлән, Хәерниса, Хәмит һәм аның улы белән бәйле урыннарда хикәяләүче өченче заттан сөйләгән кебек тоелса да, монда Исламгали карашлары, аның фикер, позициясе чагылганы аңлашыла. Шуннан чыгып, без М. Мәһдиев әсәрләрендәге хикәяләүчене икегә бүлеп карый алабыз.

Беренчедән, шәхси хикәяләүче—үз тарихын, үзе күргән вакыйгаларны үзе сөйли. Ул Исламгали дә, Сәмигулла да, Хәерниса, Нәзәһәт тә һ. б. булырга мөмкин. Икенчедән, гомумән хикәяләүче. Монда вакыйгалар өченче заттан сөйләнелә, хикәяләүче читтән карап тора, вакыйгаларда ул үзе катнашмаган яки катнашмый.

"Бәхилләшү", автобиографик лиризм белән сугарылган әсәр булганга, анда һәм

документальлек, һәм субъектив хикәяләү аралашып бара. Кайбер галимнәр әдәби әсәрне тудырган автор әлеге әсәр белән объектив идарә итү көчен югалта, үз геройларына инде тәэсир итә алмый дип саныйлар *(Бахтин М. Автор и герой//Бахтин М. М. Работы 20-х гг.—М., 1996.—176 б.).* М. Мәһдиев "Бәхилләшү"дә, шулай ук "Кеше китә—җыры кала", "Торналар төшкән җирдә" һ. б. әсәрләрендә дә, үзе тудырган геройларга тәэсир итү, алар белән идарә итү максатын куймый. Әсәрләрне укыганда бу сизелә. Мондый әсәрләрдә геройлар мөстәкыйль, тормыштагыча артык реаль кабул ителәләр.

Рус галиме В. В. Виноградов "Проблема авторства и теория стилей" хезмәтендә автор образын "Это центр художественно-речевого мира, обнаруживающий эстетические отношения автора, к содержанию собственного текста",—дип билгели. XX гасырның 20-30 елларында яшәгән икенче бер рус галиме М. Бахтин авторны үз әсәренең катнашучысы итеп карый, шулай да әсәрнең эчке мөстәкыйльлеген саклау кирәклеккә басым ясый. "Автор должен находиться на границе создаваемого им мира как активный творец его, ибо вторжение его в этот мир разрушает его эстетическую устойчивость" *(Бахтин М. Эстетика словесного творчества.—М., 1979. 166 б.).*

Димәк, автор—ул, беренче чиратта, үз биографиясе булган язучы яки шагыйрь шәхесе. Ул тормышка охшаш башка чынбарлык, ягъни сәнгать әсәрен тудыра. Шул мәгънәдә караганда, автор үз чорының иҗтимагый-мәдәни вакыйгаларында катнаша, башка авторлар белән мөнәсәбәткә керә. Мөхәммәт ага Мәһдиев тә әнә шундыйлардан. Болар әсәрдә чагылмый калмаган. Ул язучылар йортында, Пицундада ял итә, шуңа әлеге әсәрне яза, яки менә ул авылга кайта, Казан урамнарында танышлары белән трамвайда, паркта очраша, тагын әлеге повестен дәвам итә һ. б.

Тудырылган чынбарлыкның, ягъни әдәби әсәр авторының һәрвакыт күзәтеп торучы шәхес булуын әсәрне укыганда без сизеп торабыз, чөнки бу әсәр нәкъ менә автор теләгәнчә төзелгән. Мәсәлән, "Бәхилләшү" повестенда авторның берничә "йөзе" бар. Ул әтисен алып киткәнне күреп торучы, шуның газабы, кайгысын гомере буе күтәреп йөрүче малай да, педучилищены тәмамлап, мәктәптә яңа гына укыта башлаган егет тә, язучылар йортында ял итүче әдип тә, авылга кайтып хатирәләр яңартучы карт интеллигент та һ. б.

Ләкин бер кызыклы момент бар автор холкында: ул иҗтимагый-тарихи процесснын агышын бозмый, ягъни процесс һәм аның нәтиҗәсен дөрес тәртиптә сурәтли. Башта вакыйгаларны бирә, соңыннан аның тәэсире хакында сөйли, ахырдан гына конкрет нәтиҗәсен, дөресрәге, чын хакыйкатьне әйтә. Мәсәлән, икенче бүлектә сүз Хәерниса турында, аның язмышы, иренең, балаларының язмышы хакында бара. Хәернисаның фаҗигасендә хикәяләүче, ягъни шул чорда әле яшүсмер булган автор, башта Сәмигулланы гаепле итеп күрсәтә, чөнки хикәя авыл кешеләре позициясеннән торып сурәтләнә. Укучы да авторга ияреп бара, вакыйгаларның, анда катнашучыларның чын асылын ул әле белми.

Ләкин бүлек ахырында текст тышындагы автор, ягъни язучы үзе, Хәерниса вакыйгасыннан хәбәрдар булуын күрсәтә. Язучы әлеге вакыйганың хакыйки асылын укучысына ачып бирә. Мондый фәлсәфи-публицистик чигенешләр әсәрдә шактый.

Вакыйгаларның тәэсирлелегеннән "тәм табучы" язучы әсәрдә иҗат лабораториясенә "экскурсия" оештыра, үзенең ни рәвешле иҗат итүен күрсәтә. Аның үз максаты бар: М. Мәһдиев монда дөньяны кабул итү рәвешен генә түгел, сәнгать дөньясы һәм чынбарлык арасындагы мөнәсәбәтне дә яктыртырга омтыла.

"Автор" дигән персонаж беренче тапкыр әсәрнең чыпчыкларга багышланган һәм аллегорик чыпчык образына тирән фәлсәфә салынган, шул ук вакытта сатира белән сугарылган бишенче бүлегендә килеп керә. "... Мин инде язу өстәле янына утырган идем",—дип башланып китә яңа бер абзац. Шунда аңа "тәнкыйтьче" дигән персонаж "дәшә": "Болар турында ник яздың, инде язар нәрсәң беттемени?". "Автор" һәм "тәнкыйтьче" персонажлары арасындагы әңгәмәдә Тукай иҗатына бәйләп, сүз талант хакында, әдәбият белеме өлкәсендәге галимлек хакында бара.

"Автор" дигән персонаж әлеге әсәрне язучы шәхеснең үзен сурәтли, аның уйфикерләрен чагылдыра. Укучы монда сәнгатьчә шартлылыкны, әдәбиятның тормыш белән тәңгәл түгеллеген күрә. Шул ук вакытта әлеге эпизодта импрессионист язучының тормыш һәм әдәбиятны бербөтен итеп кабул итүдә чагылган дөньяга карашы күренә. Язучы өчен бу ике дөнья бер-берсенә керешеп китә ала, чөнки автор аларның һәр икесендә дә иркен хәрәкәт итә.

"Бәхилләшү"дә авторның үзе хакында сөйли, аның индивидуаль йөзен, көнкүреш һәм иҗади язмышын күрсәтә торган аерым өлешләр күп. Мәсәлән, алтынчы бүлек.

Монда язучы үзенә "автор" дип, читтән торып карап сөйли, үзен сурәтли. "Шулар арасында—бу әсәрнең авторы. ... Һәм бәгырьне телгәләгән көннәрдә автор бөек материя, зур эстетик идеаллар, Казан шәһәренең гыйльми ачышлары ...белән тулы югары бер мохитендә авыллыгына кайтып ала да рәхәт чигә, кечкенә генә бер детальдән канәгатьлек ала. Ә контрастлар зур". Мондый мөнәсәбәт әлеге бүлектә еш кабатлана. "Әйтик, автор дәрәҗәле бер гыйльми совет утырышында", "бу инде авылда кычыткан ашап исән калган буын түгел, автор мона кызыгып карый", "янында утырган деканга пышылдап кына автор болай ди".

"Шул көнне автор газетадан укып белә" дигән җөмләдән соң авторга читтән карап тору бетә, ягъни хикәяләүче үзе янә автор белән керешеп китә.

Текст тышында кала торган автор-язучы һәм текст эчендә булган автор-геройның, һәр икесенең дә, тормыш-чынбарлыкка мөнәсәбәте субъектив. Бу субъективлык бөтен нәрсәне күзәтеп торучы рольдә, автор идеясендә, автор концепциясендә сизелә. Тәүге тапкыр әлеге концепция импрессионистик романга нигез салучы язучы Марсель Пруст иҗатында чагылыш таба. "Бәхилләшү"дә дә шулай: язучы-авторның гына түгел, әсәрдәге автор образының да роле повестьның сюжет сызыгында, әсәрнең композицион төзелешендә һәм бөтенлегендә, бүлекләр, вакыйгаларның башлануы, эпиграфлар һ. б. чагыла.

Повестьта субъектив хәтер кануннары идарә итә. Автор буларак, М. Мәһдиевнең субъектив мөнәсәбәте әсәрнең "рамкалы компонентларында" ачык күренә. Төрле вакыт аралыгында булган вакыйгалар бер бүлек эчендә бер-берсенә керешеп китә, ягъни автор, геройлар арасыннан берүзе генә бер вакыт аралыгыннан икенчесенә иркен күчеп йөри—әле үткәненә, әле бүгенгесенә кайтып "килә". Шул сәбәпле, "вакыт" категориясе үзен аеруча нык сиздерә. Нәтиҗәдә, "пространство" категориясе дә активлаша, укучы да автор белән бергә, үткән белән бүгенге арасында сәяхәт итә. Мәсәлән, "Без улым белән Кесмәс болынында йөрибез. Икебез дә велосипедта..." дип башланып киткән җиденче бүлектә башта вакыйгалар бүгенгедә, Кесмәс болынында, аннан балачакта бара. Бүлектә сүз бер-ике биттә әнә шул велосипед һәм аны күрү, ана утырып йөрүдән туган балачак тәэсире турында булса, аннан соң тагын бүгенгегә кайта хикәяләүче-автор. Аннары "хәтер" дип аталган өлеш сурәтләнеп китә (73 б.) Һәм бу өлеш авторны Курса сабан туена "алып кайта".

Ләкин бүлек велосипед яки сабан туе хакында гына түгел, бүлек кешенең мәңгелек йорты хакында икәнен укучы алдан ук аңлап ала. Моңа исә язучы-автор биргән эпиграф бер кат искәртсә, икенчесендә укучы әлеге образ белән һәм "авылыма кайтарып күмегез" дигән гыйбарәләр белән бүлек ахырында очраша. Шушы бүлектә автор кешеләр, кем генә булса да, кайда гына яшәсә дә, ничек кенә ашаса, киенсә дә,—барысы да охшаш, тигез ди, чөнки "авылыма кайтарып күмегез" дип гозерләнәләр. Автор монда үзенең танышлары Зарифны, Сәлихне, укучыга яхшы таныш булган Исламгалинең улы Хәмитне искә ала.

Әсәрдә авторның субъектив ролен без тагын повестьның исемендә, эпиграфларда, бүлек башында һәм ахырында күрәбез. Алар барысы тупланып метатекст тудыралар. Бүлекләрнең башында китерелгән эпиграфлар бүлекнең эчтәлеген ача, аны аңларга, автор идеясен табарга булыша. Мәсәлән, Хәерниса турындагы бүлеккә "Ләкин, әгәр дә бүгенге заманны күрсәтәсең икән—син инде алдашма. Һәм кешене, ничек бар, шулай сурәтлә" (М. Горький), үз ана теленнән баш тарткан Фәләхетдин турындагы бүлеккә:

"Кил, өйрән, и туган, бер башка телне,
Бүтән телләр белү яхшы һөнәрдер,
Катыштырма вәләкин телгә телне,
Тел уйнатмак наданлыктан әсәрдер".

"Урысча күп сүзен, азы татарча,
Белалмыйм, кем син—урысмы, татармы?
Ничектер белмәдек исме шәрифеңә
Хәсәнме, юкса Иванмы, Макармы?"

(Дәрдмәнд)—дигән эпиграф куелган.

Мәһдиев әсәрләрендә күбесенчә, "Торналар төшкән җирдә", "Кеше китә—җыры кала" һәм, әлбәттә инде, "Бәхилләшү"дә дә бүлек ахырында авторның фәлсәфи фикерләре, вакыйгаларның нәтиҗәсе бирелә. Мәсәлән, Исламгалинең малае Хәмид язган русча фикер йөртүле хатка һәм, гомумән, татар кешесенең, яшьләренең бүгенге сөйләм, язу теленә мөнәсәбәттә әйтелгән "Менә бит ничек сөйләшәсе икән. Менә

бит культуралы кеше ничек шәп сөйләшә ул. Һай, һай, һай... Идрит-кудрит...” дип, икенче бүлектә Сәмигулланың кешелекле мөнәсәбәтенә, аның улларының имансызлыгына бәйләп имән, каен агачлары мисалында болай ди: “Безнең буын күз алдында гына да, өч сугыш узып, анда күпме таза ирләр-егетләр кырылды. Алар урынына Сәмигулла малайлары үсеп чыкты. Гомеренең соңгы елларында.

—Мичкә ясарга имән юк,—дип зарланды ул, бичара. Хәер, Сәмигулла үзе дә дөньяда юк инде хәзер” дигән нәтиҗә, башка бүлекләрдә—“Мин нәрсәнедер югалттым бу минутта. Шунда күңелемә теге җыр килде:

—Хуш, авылым, минем...” (70 б.) яки: “Теге тальянның иске моңында авыл, аның тарихы ыңгыраша, авыл үзенең үткәне, бүгенгесе белән хушлаша, елый-елый аерылыша иде” (85 б.) һ. б., һ. б. Әлеге бүлек ахырлары әсәрнең сюжетын, аның бөтенлеген тәэмин итәләр.

Повесть “Бәхилләшү” дип юкка гына аталмаган. Монда язучы үзенең яшьлеге, сабый чагы узган, әтисе-әнисе яшәгән авыл белән дә, татар халкының гореф-гадәтләре (мәсәлән, ипи салу, печән чабу турында язып), татар кешесенә генә хас сыйфатлар белән дә (җор теллелек, зарланмаучанлык, баланы милли мәдәнияткә нигезләнгән алымнар белән тәрбияләү, үз туган җирен ярату, табигатьне ярату, хөрмәт итү, өлкәнне санлау, кечеләргә ярдәм итү кебек сыйфатлар белән) хушлаша. Әлеге сыйфатлар бүгенге татар яшьләрендә һәм, язучы аңа кат-кат басым ясый, шәһәргә киткән авыл кешеләрендә юк, калмаган. Монысын без Хәмит, Зариф, Фәләхетдин, Хәерниса һ. б. мисалында күрәбез.

Сурәтләүнең максаты һәм сурәтләү предметының язучының субъектив хәтереннән гыйбарәт булуы вакыйга, күренешләрнең масштабын, әһәмиятен үзгәртә. Сугыш вакыйгаларын тыңлау, әтисен алып китү, алардан алган тәэсирләр, икмәк исе, чалгы кайрау, Кавказ таулары төбәсендә киерелеп печән чабу, зиратта хатирәләр яңартып йөрү—болар барысы да бергә кушылып, татар дөньясының гомуми картинасын тудыралар. Шушы өлешләрнең берсен генә җую да (мәсәлән, автор икмәк пешерүнең, печән чабуның онытылуын, бетә баруын искәртә) язучы өчен милли яшәешнең, милли характерның бөтенлеген югалтуга тиң.

Димәк, төп идея үткән белән бүгенге арасында калган “югалган вакыт” дигән төшенчә белән дә бәйле. “Югалган вакыт” әсәрдә һәрдаим үзен сиздереп тора: автор аңа кабат-кабат кайта, яна пешкән икмәк, яңа чапкан печән исләрен “исни-исни”, сыерчыкларның оя коруын, саесканнарның “хыянәтен” “күзәтә-күзәтә” кире кайта ул аларга. Әлеге образ да М. Мәһдиев иҗатында чагылыш тапкан импрессионистик эстетиканың бер билгесе.

“Бәхилләшү” повесте сатирик пафос белән язылган. Шуңа да анда хикәяләүченең аерым төре чагыла. Бу—“ярымгерой”, “ярымавтор”. Мәһдиев үзе тудырган бу дөньяның герое да, авторы да. Герое, чөнки ул барлык вакыйгаларны, диярлек үзе кичергән, яки аларны карап торган, аларда катнашкан кешеләр белән турыдан-туры үзе сөйләшкән. Шул вакытта ул автор да, чөнки югарыда күрсәткәнчә, әлеге вакыйгаларны бирү тәртибен, сюжет сызыгына персонажларны кертү тәртибен ул үзе хәл иткән. Геройларга характеристиканы да без күбрәк аның авызыннан, аның позициясеннән ишетәбез.

Күренекле рус галиме М. Бахтин фикеренчә, һәр әдәби әсәрнең объектив-художестволы үзәге ул автор һәм автор үз әсәре белән үз укучысын үзе сайлый. Әсәр, димәк, аны көтеп тора, шунда автор укучы белән әңгәмәгә, диалогка керә. Галим авторны укучының авторитетлы җитәкчесе дип атый. “Бәхилләшү” повестенда да без укучы автор артыннан ияреп бара, автор аның рухи “җитәкчесе” дип саныйбыз, чөнки бу ярымавтобиографик әсәр. Монда автор позициясе өстенлек итә, вакыйгаларны автор үзе шәрехләп бара. Шулай да кайбер вакыйга, моментларны укучы үзенчә анализлый ала.

Әдәбият галиме А. П. Скафтымов укучыны бары автор гына үзенә ияртеп алып бара, шуңа күрә авторны тыңлау, аның ниятенә буйсыну кирәк дип саный. Әлеге повестька карата да без шушы фикерне яклыйбыз. Бу әсәр М. Мәһдиевнең хатирә дәфтәре, ана тыкшыну, анда автор позициясен санга сукмау мөмкин түгел.

**Алсу ШӘМСУТОВА,**
*филология фәннәре кандидаты.*

*Казанның 1000 еллыгына*

# КАЗАН УРАМНАРЫ НИ СӨЙЛИ?

Мәгълүм ки, соңгы дистә ел дәверендә яшәешебезгә искитмәле тәэсир ясаган үзгәрешләр, тамырдан үзгәртеп корулар булды. Әмма дә ләкин бередә шунысы сәер, шунысы гаҗәп: ни өчендер, республикабызның топонимикасына бу үзгәрешләр кагылмады. Инде югыйсә коммунизм төзүдән дә ваз кичтек, бәйсезлек тә игълан иттек сыман, ә менә атамаларыбыз элеккечә үк, обком биргәнчә калды: Маркс, Ленин, Коммунистик һәм башкалар. Атамаларның калган өлеше исә, нигездә, кече яшьтәге мәктәп балалары өчен чыгарылган урыс әдәбияты һәм география дәреслекләрендәгечә: Пушкин, Жуковский, Беломорская... Югыйсә, мәркәзебез Казан инде үзенең мең еллыгын билгеләп үтәргә җыена, ә урам атамаларына карасаң, баксаң-күрсәң, аңа әле 1917 нче елда гына нигез салынган диярсең...

Мисалны Дәрвишләр бистәсеннән башлап җибәрик. Бередәге урам исемнәрен кайчандыр каланың яшелләндерү хуҗалыгында плакатчы-рәссам булып эшләгән түрә уйлап тапкан ахры: Мир, Труд, Солидарность, Кленовая, Тополевая... Бистәдә кеше исемен йөрткән бер генә урам бар—Советлар Союзы Герое Николай Липатов урамы. Әмма әле анда да урысча агач исеме бар: "Липа"...

Инде Себер тракты буйлап үзәккә табан юл тотыйк. Бередәге урамнар ни хакында сөйли икән? Бу юл Себергә таба барган кебек, әллә инде Космонавтлар урамы да Байконурга илтә микән? Әле монда тагын 8 март урамын да искәртеп узарга кирәк. Урамны болай атау, авторларның фикеренчә, юл төзү эшендә чиләнүче гүзәл затларыбызны асфальтны өчләтә күбрәк ыргытырга өнди-чакыра торгандыр инде. Ә бит, югыйсә, кадерле хатын-кызларыбызга чын-ихлас хөрмәт күрсәтеп, ошбу урамны якташыбыз, легендар очучы, Советлар Союзы Герое, керәшен татары кызы Ольга Санфирова исеме белән атау мантыйкка ярашлырак булыр иде. Хатын-кыз исемен йөрткән урамнарыбыз болай да бармак белән генә санарлык ич. Инде дә килеп, Пионер, Искра урамнары. Бу урамнар һич кенә дә мең еллыгын тутырып баручы борынгы калага түгел, ә бәлки "Артек" пионер лагере өчен кулайрак булыр иде. Милләтебез өчен, республикабыз өчен тырышкан, җан аткан, бу җәһәттән олуг эшләр башкарган лаеклы шәхесләребез дә җитәрлек бит.

...Алга таба атласак, Искра урамын Патрис Лумумба атлысы кисеп үтә. Африка углының Татарстанга нинди мөнәсәбәте бар икән соң, ә? Пушкинның бабалары күк, Эфиопиядән чыкса, әле бер хәл... Янәшәдә генә—Гвардия, Кызыл Позиция урамнары. Кайсы да булса бер хәрби шәһәрчектә бу атамалар бик тә табигый яңгырар иде әлбәттә, әмма һич кенә дә безнең Казанда түгел! Әгәр дә "гвардия"не тәгаенләштереп, бу урамга гвардия өлкән сержанты, рейхстагка иң тәүге Җиңү Байрагын элгән татар егете Гази Заһитов исемен бирсәк, мантыйкка бик тә ярашлы булыр иде. Өстәвенә, быел бу каһарманыбызга сиксән яшь тулыр иде. Янә бер юбилей—Казан университетына ике йөз ел якынлашып килә. Бу уңайдан, студентлар шәһәрчеге урнашуын күздә тотып, Кызыл Позиция урамын йә күренекле галим, профессор Казембәк, йә өч буын татар мәгърифәтчеләре Сәгыйть, Исхак һәм Ибраһим Хәлфиннәрнең исеме белән атау бик тә мәслихәт булыр иде.

Аз гына ары китсәк, Товарищеская урамына килеп төртеләбез. Күршедәге генә Шмидт, Достоевский, Вишневский, Калинин урамнары ул кадәр үк "иптәшләрчә" түгел дип уйлаганнар инде, күрәсең. Бу урамга һичшиксез лаеклы исем бирергә кирәк! Мәсәлән, күренекле галим һәм әдип Нәкый Исәнбәт исемен!

Инде, ниһаять, Николай Ершов урамы буйлап барабыз да, Ершов кырына килеп чыгабыз. Ул гасырлар дәвамында Арча кыры дип аталган, хәер, халык хәзер дә аны шулай атый. Казан тарихында бер мизгеллек гамәл кылган прапорщик Н. Ершовка бередә әле бюст та куелган. Ә нигә әле аның исемен йөрткән урамга Максим Горький исемен биреп, шул рәвешле аны Үзәк парк белән бәйләмәскә!? Бүгенге Горький урамына исә Салих Сәйдәшев исеме бирелергә тиеш! Чөнки татарның моң чишмәсе Мулланур Вахитов исемендәге химия комбинаты янында түгел, ә нәкъ менә шушы урамда яшәгән һәм иҗат иткән.

Ә менә Карл Маркс урамына борынгы Арча исемен кайтару фарыз. Бу җәһәттән шунысын да әйтү урынлы: биредә урнашкан бихисап сәүдә вә башка эшкуар фирмалары һич кенә дә марксизм идеяләре белән янмыйлар, аларда бер генә уй вә ният—ничек тә булса күбрәк капитал туплау. Унда Большая Красная (Зур Кызыл) урамы кала. Ни мәгънә: нигә зур, нигә кызыл? Югыйсә, ошбу мәгънәсез исемнән котылып, ана бөек сынчыбыз Бакый Урманче исемен дә бирергә йөрделәр. Ниһаять, бу изге гамәлне тормышка ашырырга иде бит. Кремль тирәсендәге Подлужная, Нагорная һәм башка шундый урам атамалары борынгы башкалабыз хакында ни сөйлиләр? —Мина калса, берни дә! Югыйсә, XVI гасырның дәүләт эшлеклеләре, шагыйрьләре Мөхәммәт Әмин, Кол Шәриф кебек каһарман бабаларыбызның исемнәрен ошбу урамнарда да мәңгеләштерү ифрат дәрәҗәдә изге гамәл булыр иде кана.

Инде хәзер Куйбышев урамы исәбенә озынайтылган Пушкин урамы буйлап Тукай мәйданына төшеп китик. Кремльгә таба уң тарафка Профсоюз урамы юл тота. Хәтерегездә булса, элек профсоюзларны "коммунизм мәктәбе" дип атыйлар иде. Ә менә хәзер алар ни-нәрсә белән шөгыльләнәләрдер, монысын аларның "галиҗәнаб" житәкчеләре генә белә торгандыр. Казанны коткарыр өчен үзен һәм улы Үтәмешгәрәйне корбан иткән Сөембикә бу урам исеменә лаек түгелмени?!

Сулда—Некрасов, Бутлеров, Свердлов урамнары, Щербаков тыкрыгы. Свердловның Казан, гомумән, Россия тарихында тоткан роле бик томанлы: ул патша гаиләсен һәм башка адәмнәрне аттыруны оештырган, дип тә шикләнәләр. Һәрхәлдә, бу урам олуг гуманист шагыйрь Мөхәммәдьяр исемен йөртергә бик тә лаек. Халкыбыз тарихында күренекле урын алып торган бу шәхеснең тууына биш йөз ел тулган көн ЮНЕСКО тарафыннан да билгеләп үтелде.

Каршыда гына—Татарстан башкаласының үзәк урамы—Бауман урамы, үзенә күрә бер Арбат, Невский проспекты шикелле. Тарихи гаделлек бу урамга Ярминкә мәйданын да кушып, уртак "Ташаяк" исемен кайтаруны таләп итә. Тарихтан билгеле булганча, элек бирдә атаклы Ташаяк базары гөрләгән. Сүз уңаеннан шунысы да мәгълүм булсын: безнең бабайлар Россиядә "ярмарка" дигән алман сүзе таралганчы шактый элек сәүдә итә башлаганнар.

Янәшәдә Николай Островский урамы урнашкан. Бу шәхеснең дә Казан тарихына керткән өлеше мәгълүм түгел, әмма дә әлеге күренекле драматург үз исеме белән аталган урамны безнең мәшһүр якташыбыз, "урыс поэзиясенең кояшы" һәм намуслы дәүләт эшлеклесе, Казан турында бик җылы итеп язып калдырган Державин белән бүлешергә һич тә каршы булмас иде. Бераз баргач, Пушкин урамы тарихи Болак буена килеп чыга. Ике якта ике урам—Уң як һәм Сул як Болак урамнары. Бер яктагы йортлар так саннар, ә икенче якта җөп саннар белән тамгаланган. Әгәр дә бу урамнарны бер уртак исем белән—"Болак" дип кенә калдырсак, башкалабыз отар гына иде инде югыйсә. Янәшәдә генә Париж Коммунасы урамы елышкан. Бу урамны исә, һәртөрле аңлашылмаучанлыклардан котылу җәһәтеннән, атаклы француз галиме, сәяхәтчесе Жан Кусто исеме белән атау бик кулай булыр иде. Өстәвенә, ул—мөселман кешесе дә. Бераз гына югарыда—Астрономик урамы. Монысын инде борынгы галим вә шагыйребез, әле Коперникка кадәр үк галәм төзелешен бәйнә-бәйнә аңлатып биргән Сәеф Сараи исеме белән тәгаенләштерү бик тә максатка ярашлы гамәл булыр иде.

Менә, ниһаять, Татарстан урамына килеп керәбез. Башкалабыз кунаклары һичшиксез аяк баса торган урын. Әгәр дә бу исем-атама Татарстаннан читтәге берәр кала урамына бирелсә, халкыбызга да, республикага да олуг ихтирам билгесе булыр иде. Ә бу хәлендә ул бирдә үзенең бәйрәм киемен көн саен киеп йөрергә мәҗбүр булган бәндәне хәтерләтә. Әлеге үзәк урам, һичшиксез, бөек шагыйребез Кол Гали исемен йөртергә тиеш. Бүтән милләттә булса, бу олуг исемне бик югары күтәрерләр иде. Ә менә без исә аның исеме белән шәһәр читендәге бер урамны, урам да түгел әле, кем әйтмешли, җиде-сигез йортлы бер аулак тыкрыкны атадык та, шуның белән—беттекитте—вәссәлам. ЮНЕСКО тарафыннан 800 еллыгы билгеләп үтелгән шагыйребезнең кадерен белергә, олыларга иде дә бит...

Үзәктән әлләни ерак түгел—Спартаковская урамы. Халык телендә ул Башмакчы урамы дип йөртелә. "Спартак" аяк киемнәре берләшмәсенә кагылышлы исем. Бу берләшмә гомер-гомергә эт тиресеннән эшләнгән унтылары белән данлыклы булды. Югыйсә, бирдә Спартакның бер катнашы да юк инде: безнең бабайлар атаклы болгар читекләрен унынчы гасырда ук теккәннәр. Минемчә, Спартак урамын моннан мең ел элек үк гарәп илчелеге башында безнең якларга килеп чыккан мәшһүр Әхмәд Ибен Фадлан исеме белән алыштыру яхшы булыр иде.

Бераз баргач, Луковский урамына килеп чыгабыз. Бу урамның түренә Татарстан хәрби комиссариаты урнашкан. Әфганстанда иң беренче Советлар Союзы Герое исеменә лаек булган якташ очучыбыз Вячеслав Кәбир улы Гайнетдинов исеме бирдә бик тә ятышлы яңгырар иде. Ул хәрби бурычын үтәгәндә һәлак булган. Аның исемен

мәңгеләштерүдәге хокукы Айдиновныкыннан (күршедәге урам хулиганнар кулыннан һәлак булган студент Артем Айдинов хөрмәтенә шулай атала) һич тә ким түгел.

Островский урамыннан Газовая урамына килеп чыгабыз. —Югыйсә, урам газ торбасы да, плитәсе дә түгел инде. Моны хәтта башлангыч сыйныф укучысы да белә һәм аңлатып бирә ала лабаса. Әмма дә урамның газ белән агуланган, ягъни "загазованная" булуы бик тә ихтимал... Бу урамда Россия ислам университеты урнашкан. Мәшһүр мәгърифәтче, тарихчы һәм дин белгече, җәмәгать эшлеклесе Риза Фәхретдин исеме биредә бик тә лаек вә табигый яңгырашка ия. Янәшәдә генә—Эсперанто урамы. Еш кына аны "Аспирант урамы" дип бутыйлар. Ясалма телнең бу урамга нинди мөнәсәбәте бардыр—анысы билгесез. Кайчандыр бу урамга Анна Ахматова (татар токымы, әбисе—Казаннан!) исемен бирергә дә ниятләгәннәр иде. Бу мәсьәләне янәдән күтәрү зарур. Күршедәге Павлюхин урамын исә шагыйрәнең улы, танылган галим, татар халкын гомере буе хөрмәт иткән Лев Гумилев исеме белән атау бик тә күркәм гамәл булыр иде.

Бераздан Высотная урамыннан Даурия (Даурская) урамына килеп чыгабыз. Даурия? —Ни-нәрсәне аңлата бу исем, каян эзләп тапканнар аны? Латыш укчыларының да Казаныбызга нинди файдасы тигән?! Гомумән, латыш укчыларына бездә ниндидер бер чиксез мәхәббәт сизелә: Вольдемар Азин, Ян Юдин исемнәре белән тулы бер район, бистә һәм урамнар аталган. Озакламый өченче һәм дүртенче Азин бистәләре дә пәйда булачак икән. Болай номер сугуны кем уйлап тапты икән? Әллә бу Америкадагыга, бишенче, жиденче авеню дигәнгә мәгънәсезләрчә иярүме, әллә—элеккеге казарма социализмы шаукымының билгеләреме?

Инде менә, ниһаять, Родина урамы. Ә нигә Родина? Татарстан буйлап сибелгән бихисап "Родина" колхоз-совхозлары кебек үк, бу да, минемчә, Ватан төшенчәсенең төп мәгънәви асылын киметә генә. Ары таба—Юлиус Фучик урамы. Ул бик озын, күп чакрымнарга сузылган. Монда берьюлы Кол Гали, Советлар Союзы Геройлары Гани Сафиуллин, Мәгубә Сыртланова урамнары шикелле уңлап урам сыя алыр иде. Бик күп лаеклы шәхесләребез исеме белән хәтта тыкрык та аталмаган бер чакта, бу гаделсез исрафлык галәмәте булып тора. Ә нигә, мәсәлән, Фучик урамының бер өлешен күренекле шагыйрь, фашист тоткынлыгында батырларча һәлак булган подполковник Хәйретдин Мөҗәй хөрмәтенә атамаска? Узган ел моның өчен кулай вакыйга да булды: шагыйрьнең тууына йөз еллык билгеләп үтелде.

Елга аръягына күчсәк, аның байтак өлешен Большая, Деловая, Боевая, Окольная, Хороводная һәм башка шуныңише исемдәге урамнар биләп алган. Бүтән районнардагы кебек, биредә дә, ни кызганыч, татар исемнәре юк дәрәҗәсендә. Казанның мең еллыгы уңаеннан бу районга Бишбалта исемен кире кайтару кирәк, югыйсә.

Инде дә килеп—Восстание урамы. Ул ни хакында сөйли? Кайсы "восстание"? Спартакныкымы, Батыршаныкымы, әллә инде яна баш күтәрүләргә өндәүме бу—билгесез... Әлеге урамга татар, башкорт һәм казакъ халкының уртак дуслык билгесе булган Мифтахетдин Акмулла исемен бирү муафыйк булыр иде. Әле күптән түгел генә бу олуг шәхеснең тууына йөз илле ел билгеләп үтелде. Авиатөзелеш районында берничә урам (!) Ленинградская дип атала. Декабристлар урамы исә ярты шәһәр буена сузылган. Ул декабристлар халык өчен ни-нәрсә эшләргә җыенганнардыр, анысы—нәмәгълүм, ә менә аларның халыктан гаять ерак торуын, өстен катлау-дворяннарның хокукын арттыру өчен кылган гамәлләрен һәммәбез дә белә. Декабристлар урамының "Идел-Пресс"тан Восстаниегә кадәрге өлешен кешелек дөньясы өчен һәлак булган фидаилар—Җәлилчеләр исеме белән атау зарур.

Воровский урамы... Ул "Воровская", ягъни "Караклар" урамы булып яңгырый. Адоратский урамын, минем карашымча, Худяков урамы дип атау мәгькуль. Заманында ВКП(б) тарихын Сталин теләгәнчә итеп язып биргән В. Адоратский кем дә, Казан ханлыгы тарихын чын асыл итеп тасвирлаган өчен репрессиягә эләгеп һәлак булган Михаил Худяков безнең өчен кем?!

Язмамның азагында бик тә мөһим бер мәсьәләгә тукталасым килә. Без (белепме, белмичәме?) йөз чөергән, оныткан исемнәр асылда бездән гайре бик азларны гына кызыксындыра. Утыз Имәни, Курсави, Фатих Кәрими, Бәхтияр Канкаев, Батырша, Гаяз Исхакый, Дәрдмәнд, Гаспралы, Еники, Габәши, Ключарев һәм янә бик тә күп исемнәрне Татарстаннан читтә мәңгеләштерү мөмкинме? Безгә үз-якын булган Михаил Лермонтов, Сергей Аксаков, Алексей Куприн кебек әдипләрне дә онытмаска иде. Һәм, гомумән, урамнарга яңа, лаеклы исемнәр кушуны Мәскәүдәгечә тиз арада, бәхәссез һәм катгый рәвештә гамәлгә ашырырга кирәк. Тузган йортлар белән бергә, һәртөрле ерганаклы-ботаклы, аркылы-буйлы исемнәрдән дә котылырга иде бит, җәмәгать! Мең еллык тарихы булган башкалабыз урамнары безнең хакта, үзе хакында күркәм вә лаек мәгълүмат җиткерсен иде.

**Фәрит МИҢНЕГАЛИ**

*Халык иҗаты*

# КАЗАНЛЫГА СӘЯХӘТ

Себер якларының фольклоры өйрәнелмәгән дип әйтеп булмый. Ул һәрвакыт галимнәрнең игътибарын үзенә тарткан, татар фольклорына багышланган беренче фундаменталь җыентык та Себер татарлары турында. Иртеш, Тубыл, Уб елгалары буйларында 1867-1868 елларда В. Радлов Себер татарларының халык иҗатын җыя. Галимнең ун томлык "Төрки кабиләләрнең халык әдәбияты үрнәкләре" дигән хезмәтенең дүртенче томын Себер татарлары фольклоры: дастаннар, риваятьләр, легендалар, җырлар, әкиятләр тәшкил итә. В. Радлов әлеге томның керешендә: "Халык иҗаты әсәрләре—әкиятләр, җырлар—ата-бабаларының каһарманлыкларын хәтерләтеп, яшен яшәгән картлар күңелендә генә сакланып калган. Халык рухын, ата-бабаларның батырлыкларын җырларда һәм әкиятләрдә ачыктан-ачык мактарга кыюлык биргән заманны, үзләренең яшьлек истәлекләрен бары алар гына хәтерләрендә саклыйдыр",—дип яза.

Былтыргы экспедиция, В. Радловтан соң гасырдан артык вакыт үтсә дә, Себер татарларында халык иҗаты әсәрләренең актив яшәештә һәм популяр булуын күрсәтте. Информантлардан авыл тарихы, Себер татарларының Ислам динен кабул итүе, аучы-мәргәннәр, Ислам изгеләре, мифологик персонажлар турында риваять-легендалар, бик күп ышанулар, истәлек-сөйләкләр язып алынды.

Бу як фольклорының берничә үзенчәлеге күзгә ташлана. Беренчедән, һәр вакыйганың конкрет урыны, вакыты, герое бар. Информант борын-борында булган вакыйганы түгел, ә шул авылдагы фәлән абый, яки фәлән мама (апа) белән булган вакыйганы бәян итә. Әлбәттә, бу—мифологик хикәятләр өчен мәгълүм алым. Әмма Себер информантлары еш кына үзләре дә шушы мифологик хикәятләрнең героена әверелә, яки аның әнисе-әтисе, бабасы белән булган хәлләр тасвирлана. Информантлар үзләре биргән материалга тулысынча ышана. Шул ук вакытта бер үк әсәрнең вариантларын һәр информант үзенеке итеп сөйли. Икенчедән, биредә аерым жанрлар бик популяр, халык хәтерендә яхшы саклана, аларны яше-карты белә. Болар—мифологик хикәятләр, Ислам изгеләре, Ислам кабул ителү турындагы риваятьләр, гыйбрәтле хикәяләр, аучы-мәргәннәр турындагы риваятьләр.

...Төмәннән алты сәгатьләр чамасы автобус белән баргач, район үзәге Вагайга килеп җиттек. Ул гомуми озынлыгы 300 чакрымга сузылган Вагай елгасының Иртешкә койган урынында урнашкан, елга буйлап сузылган берничә урамнан тора. Татарга хас булганча, урамнар—чиста, йортлар—зур. Һәр йорт яшеллеккә, чәчәккә күмелеп утыра. Вагай—тарихта билгеле авыл, монда 1919 елда легендар кызыл полководец Блюхерның штабы урнашкан була. Ә тагын да элегрәк, 1585 елда, Вагай елгасында Ермак үзенең үлемен таба...

Вагайда берничә сәгать булып, авылны карап чыкканнан соң, Казанлы авылына юл тотабыз. Янадан сәгать ярымнар автобуста баргач, Казанлыга килеп җиттек. Ул—урман эчендә урнашкан татар авылы икән. Авыл—чиста, йортлар—зур, коймалар—төзек. Авыл уртасында мәчет, янәшәсендә мәдрәсәсе дә бар. Авылның мулласы бөтен шартын туры китереп, моңлы тавыш белән халыкны намазга чакыра—азан әйтә.

Авыл халкы бай, иркен яши. Йортларда заманча җиһаз, ишек алдында җинел яки йөк машинасы. Әмма авылга кадәр юлның яртысы асфальтланмаган, яңгыр явып үтсә, ул сазга әверелә. Шуна күрә мондагы иң популяр транспорт—"болотоход", ягъни сазда йөрүче машина. Авылларга газ кермәгән. Һәр йортта зур-зур мичләр. Дөрес, җәй көне мич ягып тормыйлар, ишек алларында да мичләр бар—икмәк

мичләре. Көн аралаш шунда икмәк, бәлеш пешерәләр. Йортлар тышкы яктан буялмаган, кояш-яңгырларда каралып утыра. Әмма эчке яктан балчык белән сылап агартылган яки аксыл тәстәге обойлар ябыштырылган. Татарстандагы кебек биек капка-коймалар, өсте-өстенә салынган абзар-сарайлар да юк. Кечкенәрәк кенә терлек сараенда берничә сыер кыш чыга. Ә җәен сыерлар үз ирекләрендә: апрельдә үк бозауларын ияртеп чыгып китәләр дә, саудырырга әллә нигә бер генә кайталар икән.

Авылны чыгуга урман, ягъни тәс башлана. Нинди генә җиләк үсми ул төстә! Халык урман-сазлыкларда кара чия, кызыл чия (нарат җиләге), күк чия (кара җиләк), карагат (кара карлыган), астаган (кура җиләге), торнакүз (мүк җиләге) җыя. Мәһабәт кедр агачларында тәмле чикләвек өлгерә. Гомумән, бу якларда кедрларга хөрмәт бик зур. "Жырчы" кедрлар, аларның сихри көче турында ышану да таралган. "Жырчы" кедрлар бик сирәк кешегә очрый, очраса да аны күрер өчен кешенең күңел күзе ачык булырга тиеш! Ул агач янып торган төсле яктырып, балкып күренә икән. Шундый агачның кечкенә генә ботагын кулында тоткан кеше дә яшәү көче ала, барлык авыруларын оныта, дип сөйлиләр.

Экспедициянең беренче көнендә Себер татарларының үзенчәлекле диалектын аңлау кыенрак тоелса да, икенче көнне яхшы ук аңлый, өченче көнне "кәпләшә" үк башладык. Шәйхи Маннур бу авылларның теле турында: "Бу як кешеләре татар, башкорт, казакъ, үзбәк, монгол, остяк сүзләреннән укмашкан үзгә бер "тамыр шивәдә" сөйләшәләр икән. Аларны яхшы аңлар өчен ике-өч ай күнегү кирәк",— дип яза. Ул кайчандыр күрше Тугыз авылында "ыспа—читальный", ягъни уку өе ачкан. Биредә берничә ай гына эшләп алуына карамастан әдипне хәзер дә хөрмәт белән искә төшерәләр. Гәрчә аны күреп белүчеләр күптән вафат булса да. Ш. Маннурның "Агымсуларга карап" повестендагы "Өркемәгән кошлар иле" дигән бүлектә шушы авыллар, мондагы халык, аның тормышы, гореф-гадәтләре, көнкүреше турында сүз бара.

Без туктаган йорт хуҗалары Хәлим абый белән Нера апа Сәгыйдуллиннар, аларның кызлары Мәдинә белән Мөнирә кунакчыл хуҗалар гына түгел, искиткеч кызыклы, күп белүче информантлар да булып чыкты. Алар авыл тарихын да, истәлек-сөйләкләрне дә, риваять-легендаларны да, ышану-ырымнарны да бик күп беләләр икән. Бу мәкаләдәге мәгълүматларның күбесен нәкъ менә Хәлим абыйдан язып алдык.

Беренче көнне төп эшебезгә керешкәнче Казанлы астанасына барып кайттык. Астаналар—Тубыл-Иртеш якларындагы изгеләр каберләре. Монда шушы төбәктә Ислам динен таратышкан шәехләр күмелгән. Изгеләрне бу якларда яхшылар яки әүлияләр дип атыйлар.

Астаналарның кыскача тарихы мондый:

1394 елда бу якларга Бохарадан 366 шәех килеп чыга. Миссионерларга үзенең коралланган 1700 батыры белән Урта Азия далалары ханы Шаһбани да ярдәмгә килә. Халык Ислам динен үзе теләп кабул итмәгән очракта зур канлы бәрелешләр була. 366 шәехнең өч йөзе һәлак була. Өчесе генә Себердә яшәп кала. Әмма шуннан соң Ислам дине кабул иткән халыкны укыту-өйрәтү өчен Бохарадан шәехләр, дин белгечләре күпләп килә башлый. Байтагы шунда яшәп тә кала. Астаналар—менә шушы шәехләр күмелгән урыннар. Алар кайбер очракларда авыл, ә кайвакыт күмелгән шәехләрнең исеме белән атап йөртелә. Әлеге каберләр алты яки сигез почмаклы буралар белән әйләндереп алынган. Гомумән, Себернең татар зиратларында бездә кабул ителгән чардуганнар юк, аларны төрле биеклектәге дүрт почмаклы буралар алыштырган. Астанада әлеге кабер генә түгел, аның тирә-ягында үскән агачлык та изге урын санала. Монда агач сындырырга, җиләк өзәргә, кычкырып сөйләшергә дә ярамый. Казанлы астанасында агач кискән укытучының параличланып ятуы турында риваять итеп сөйлиләр. Ә ул үзе авылда беренче мәктәп ачкан, хөрмәтле зат була. Укучыларга: "берниндң изгеләр дә юк",—дип исбатлар өчен астанадан утынга агач кисә. Һәм шул ук көнне параличлана да, ай буе астанада намаз укып ятып—дөньядан үтә. Бу вакыйга авыл халкының астана яхшыларына булган ышануын тагын да ныгыта.

Астаналарны карап, чистартып торган нәселләр яки токымнар бар. Авыл халкының бу кешеләргә карата мөнәсәбәте бик яхшы. Ул токымнарны ярым изге итеп карыйлар. Әмма бу токымнан чыккан кешеләр берниндң гөнаһ эшләргә тиеш түгел, алар шунда ук җәзасын алалар икән. Берәр нәзере, теләге булганнар астананы карап торучыларга сәдака бирәләр. Яки сәдакаларны кызыл чүпрәк кисәгенә бәйләп юлчылар артыннан тугыз астанага җибәрәләр. Һәрбер астананың изге хайваны

бар. Казанлы астанасының изге хайваны—каз, ә күрше Тугыз авылныкы—үгез.

Тугыз авылында әлеге үгезне "Бохарадан яхшылар белән килгән үгез" яки "алтын үгез" дип аңлаталар. Үгез турында төрле ышанулар, риваятьләр сакланган. Тубыл дәүләт тарихи-архитектура музей-тыюлыгы белгече И. В. Белич Хәким ата астанасы турында бик күп материал туплаган. Хәким ата астанасы Вагай районының Баиш авылында урнашкан. Риваятьләр буенча 366 шәехнен берсе—Хәким ата була. Ул үгезгә атланып килә. Үгез туктап калган җирдә яшәп кала. Хәким ата бер байдан үгез тиресе кадәр җир сорый. Бай риза була. Хәким ата үгезне суеп тиресен телә дә, кушып бәйләп, бик зур территорияне уратып алырлык тасма ясый, шул җирдә яшәп кала. И. В. Белич изге үгез турында дистәләгән риваять язып алган. Тугыз авылында бу риваятьләрне тулысынча хәтерләүче юк, әмма алар биргән информация шул риваятьләрнең аерым өзекләре булса кирәк. Күрәсең, Бохарадан килгән шәехләр үзләре белән Хәким ата, ягъни Сөләйман Бакыргани турында риваятьләр дә алып килгәннәр.

Информантларыбызның иң кызыклысы Тугыз авылында яшәүче Шамратова Гөлҗамал апа булды. Ул—үзе риваять герое да ("Нугай алтыны"). Гөлҗамал апа риваять-легендаларны, йолаларны күп белә, бик матур җырлый да.

Себер татарларының бай иҗат фантазиясе аларның әйләнә-тирә дөньясын күп төрле фантастик персонажлар ярдәмендә тулыландыра. Монда мифик персонажлар турындагы хикәятләр бик популяр. Аларның берсендә мифологик персонажлар турында мәгълүмат тупланса, икенчеләрендә шулар белән аралашкан кешеләр тасвирлана. Бу затларны явызларга һәм зарарсызларга бүлеп була.

Информантлар белән сөйләшкәндә бу яклардагы иң популяр персонаж—Еш һәм Еш иянәр икәнен белдек. Ешлар безнең Шүрәлеләрнең якын туганы булып чыкты. Безнең Шүрәлеләр, "аларны асрап ятарлык" кап-кара урманнар булмау сәбәпле, юкка чыгу алдында булса, Ешлар бик матур гына яшәп яталар икән. (Дөрес, без аларны күрер өчен махсус урманга барсак та, туры китерә алмадык). Ешлар—хатын-кыз персонажлар. Өйләнмәгән аучылар аларны урманда адашкан хатын-кыз дип белеп, авылга алып кайтып өйләнгән очраклар да булгалаган. Әмма, берничә баласы туса да, Еш үзенең ешлыгын онытмый, кем икәнлеге ачылгач, ул тәрәзәдән чыгып китә, ди. Әмма, алар кешедән туган балаларын алып китә алмыйлар, алар әтиләре белән яшәп калалар. Авылларда Еш белән кеше никахыннан килгән нәселләр әле дә бар икән.

Ә Еш иянәр—ир-ат затыннан. Алар аучыларны, җиләк-гөмбә җыючыларны адаштырып үтерәләр. Еш иянәр сунарчыларны берәр кеше тавышы белән урман эченә чакырып кертәләр икән.

Гадәттә, Ешлар турында сөйләгәндә, вакыйганың вакытын, урынын, кешесен төгәл күрсәтеп сөйлиләр. Бу мифологик хикәятләр өчен мәгълүм алым булса да, күнелдә шик уяна. Ә бәлки чынлап та булгандыр бу вакыйгалар?

Алтайлыларның популяр персонажы Йилбегән дә яши икән Себердә. Йилбегән—бик борынгы персонажлардан. М. Кашгариның "Диване лөгатет-төрк" сүзлегендә дә (XI г.) "Йетү башлы Йелбүкә" дигән гыйбарә сакланган. Шамратова Гөлҗамалападан "Җиде башлы Йилбегән" дигән әкият язып алдык. Бу әкияттә Йилбегән кеше канын эчеп яшәүче явыз зат булып гәүдәләнә. В. Радлов язып алган "Кадым Мәргән" әкиятендәге Йилбегән исә безнең әкиятләрдәге диюгә күбрәк ошаган. Йилбегән—әкиятләрдә кеше канын эчеп, кеше ашап яшәүче явыз зат. Әмма ул Батыр Егет тарафыннан җиңелә. Бу образ Себер татарларына Алтай мифологиясеннән кергән булырга тиеш. Алтайлыларда Йилбегән кешеләргә һөҗүм итүче персонаж, кайвакыт батырларга аларны җиңәргә Ай белән Кояш та булыша. Йилбегәннәр бер, өч, җиде, унике башлы, кара һәм сары төстә булалар.

Себер татарлары мифологиясендә явыз затлар да шактый. Шуларның берсе—Купкан. Ул—үлгән кешенең, гадәттә, дөньядан, яшәүдән туймаган кешенең җаны. Купкан төннәрен җирләнгән җиреннән чыгып йөри. Башта кечерәк хайваннардан, аннары сыер, үгез кебек олыракларыннан кан эчә. Үзе дә башта мәче, эт, аннары сыер, үгез булып күренә. Шуннан кеше канын эчә башлый, үзенең кыяфәтендә йөри. Ә кеше кыяфәтендәге Купканны җиңүе кыенлаша. Бу образ татар мифларындагы Убырга якын тора. Купканның кабер өсте иләнгән төсле була, ди, ә үзе ул үз кабереннән түгел, ә үзеннән соңгы җиденче кабердән чыгып йөри икән. Әмма Купкан никадәр куркыныч булса да, муллалар аларны җиңә һәм кире каберенә кайтырга мәҗбүр итә ала.

Биредә шулай ук тере Купканнар, ягъни Мәцкә турында хикәятләр, ышанулар

да күп. Мәцкә—убырга әверелгән кешеләр, алар да кеше каны белән туклана. Мисал өчен Кече Уаттагы Дәүләтгали рухы, Меткә авылы Купканы, Тирән Аер авылы Мәцкәсе турында хикәятләрнең күп төрле вариантлары бар.

Себер халкы, параллель дөнья халкы булган җеннәр белән конфликтка кермичә, тыныч кына яши. Мәсәлән, кич белән мунчага керсәң, ишек шакып, юынып чыгарга рөхсәт сорыйсың. Чыкканда рәхмәт әйтү дә тәрбиялелегеңне генә күрсәтә. Күл, урман буйларындагы аучы йортларына: "Чык, иясе килде",—дип кисәтеп керәләр. Дөрес, бераз алдашулар да булгалый булгалавын. Мәсәлән, кич белән өенә кайтып барган кеше: "Мин хәзер фәләннәргә барам",—дип алдаша. Мескен җен, бу кеше килеп җиткәнче дип, тирләп-пешеп тегеләргә чаба. Яки шул җен, юл уңаеннан җигүле чанага яки арбага утырса, ат аны бик авырлык белән тарта. Бу очракта дуганы артын алга әйләндереп җигәләр, җен "болар кире кайта икән",—дип, үз юлы белән китә.

Җеннәр үзләре дә кешеләргә ярдәм сорап мөрәҗәгать итә икән. Мәсәлән, балалары туар вакыт җиткәч, җеннәр ярдәм сорап инәлекләрне (кендек әбисен) чакыралар.

Хозыр Ильяс турындагы риваятьләр эчтәлекләре белән гыйбрәтле хикәяләргә якын тора һәм тәрбияви характердагы әсәрләр. Хозыр Ильяс начар гына киенгән карт кыяфәтенә кереп урманда, сазлыкларда юл сорый, яки авылда юлчы булып кунарга кертүләрен үтенә. Үзенә ярдәм иткәннәргә ул рәхмәт әйтә, андый кеше баеп китә, баласызларның баласы туа, ә ярдәм итәргә теләмәгәннәр исә бик авыр хәлдә кала.

Себердә Алыпларны Полваннар дип атыйлар. Полваннар—(пәһлеваннар) зур гәүдәле, искиткеч көчле кешеләр. Еш кына алар аучы-мәргәннәр буларак тасвирлана. Бәлки бу риваятьләр—Себер татарларында бик популяр булган дастан кыйпылчыкларыдыр?

Аучы-мәргәннәр турындагы риваятьләрнең төп персонажы—аю. Бу очраклы түгел, чөнки авылларга урман "авып" тора. Анда аюларның берничә төре очрый. Авылда үз гомерендә 40 лап аю аткан мәргәннәр дә шактый булган. Аючылар турындагы бу хикәятләр тормышта булган вакыйгаларны бәян итә. Аларда уйдырма, фантастик элементлар юк диярлек. Колхоз терлекләренә һөҗүм итүче аюларга бергәләшеп ау кору, тирә-якта дан тоткан аючылар токымнары, аларның этләре турындагы мәгълүматлар, төрле мәзәк хәлләр саклана бу әсәрләрдә. Легендаларда исә аюга карата тотемизм элементлары да күзәтелә. Еш очраучы сюжетның берсендә аю белән хатын-кыз никахы турында сүз бара. Бер кыз җиләккә барган җирендә адашып, аны аю үз өенә алып кайткан... Яки кыз урманда адашып калып, кыш җитә башлагач аю өенә үзе төшкән. Аю белән кыш уздырган, яз көне игезәк уллары туган. Легенданың вариантлары шактый. Берсендә кыз туган авылына әйләнеп кайта, икенчесендә аю белән яшәп кала.

Информантлардан язып алынган материалның барысын да фольклорга кертеп булмый. Әмма телдән телгә, буыннан буынга күчеп, халык хәтерендә сакланган әлеге әсәрләр халыкның тормыш-көнкүрешен, гореф-гадәтләрен яхшырак аңларга ярдәм итә. Аларда аерым вакыйгаларга халыкның мөнәсәбәте саклана, халык үзенең тарихын нәкъ менә шушындый хикәятләр ярдәмендә хәтердә тота. Мәсәлән, биредә авылның беренче мәчетен салган Сәмигулла оста, яхшылар токымыннан булган укымышлы мулла Әбу Шахман турында яратып, хөрмәт белән сөйлиләр.

Сәгыйдуллина Нера апа үзе сөйләгән вакыйганың тормышта булганына ышана. Бу "документаль" легендада кошка әйләнгән малай турында сүз бара. Һәм әлеге әсәрне үткән елгы экспедициядә табылган материалларның "йөзек кашы" диеп була. Ул үзенчәлекле сюжетка ия, тирән трагизм белән күңелләрне җәлеп итә.

Табигать күренешен җанландыручы мифологик персонаж—Әләмәце турындагы ышану да кызыклы. Әләмәце—җил-буран белән йөрүче явыз рух. Ул көчле буран, өермә чыгарып очып йөри, балаларны урлый, кешеләргә зыян сала икән. Әләмәценең күңелен күрер өчен буранлы, җил-давыллы көннәрдә аңа икмәк яки башка ризык чыгарып куйганнар.

Себер татарларында үзенчәлекле йолалар белән дә таныштык. Мәсәлән, "чәч туе"н бары монда гына уздырганнар. Ир баланың 40 көне тулгач беренче чәчен алганнар, бу көнне аш-сулы зур мәҗлес-туй үткәргәннәр. Башта ат чабышлары булган. Баланың атасы ярышта алдан килүчеләргә бүләкләр әзерләп куйган. Скрипкалар уйнап торган. Скрипка—Себер татарларының яраткан уен коралы, монда гармунны белмәгәннәр. Дөррия Рамазанова 1995 елгы диалектологик экспе-

диция вакытында Тугыз авылында "Чәч туе бәете"ннән өзек язып алган. Бу бәет тә әлеге йоланы шактый яхшы күзалларга ярдәм итә. Туй вакытында авылга аю килә, шушы вакыйга аркасында әлеге "чәч туе" тарихка да кереп калган.

Монда тагын бер күренешкә игътибар иттек. Кешеләр бер-берсенә "инәш", "өннәш", "өннәкә", "олата", "аташ" дип мөрәҗәгать итәләр. Без бу сүзләрне башта "апа", "абый" дигән мәгънәне аңлата дип уйлаган идек. Алай булып чыкмады. "Инәш" дип әнисенең исеме бирелгән хатын-кызга дәшәләр. Ул аның икенче исеме кебек була. Ә атасының исемен йөрткән ир кеше "аташ" була. Ягъни ата белән ул—адашлар. Әбисенең исемен йөрткән кызга "өннәш" дип, яки яратып "өннәкә" дип мөрәҗәгать итәләр. Ә "олата" исә—бабасының исеме бирелгән кеше.

Бу авыллардагы халык медицинасы алымнарын саклаучылар турында да берике сүз әйтик. Бередә яшәүчеләр медицина оешмаларына йөрүгә караганда үз "табибларына" мөрәҗәгать итүне артыграк күрә. Авырулар тәннәренә-җаннарына шифа эстәп Казанлы авылында яшәүче Флера ханым Ватуловага киләләр, ул кешене теләсә кайчан кабул итә, чирен әйтә, дәвасын өйрәтә. Тугыз авылында яшәүче Сайра мама (апа) йөрәге авырткан, курыккан кешеләрнең йөрәген "сылый", баласыз интегүчеләргә дә булыша.

Казанлы һәм Тугыз авылларында без шушы якларда гына пешерелә торган милли ризыклардан да авыз иттек. Болар—бавырсак (пауырсак), кисмә, чигелтәк (цигелтәк). Бавырсак турында Ш. Маннур болай дип язган: "Балыктан соң кайнар, куе чәй килде, чәй табынына ак он камырыннан майда куырылган сап-сары бавырсак өелде. Аның һәрбере балалар такыясы төсле кабарып, түгәрәкләнеп пешкән. Авызга капсаң, шундук кетердәп эреп бетә. Бу як халкының традицион ашларыннан икән ул. Табын түбәсеннән бавырсак булмаса, мәҗлес тә, туй да булмый, сый да булмый, имеш". Өстәп шуны әйтергә мөмкин: бавырсак формасы белән эшләпәне хәтерләтә. Такыя бередә баш киеме дигән сүз. Зурлыгы—балалар эшләпәсеннән олылар эшләпәсенә кадәр.

Әлбәттә, бу кечкенә генә мәкаләдә бөтен легенда-риваятьләрне, ышануларны искә алу, күргәннәрне язып бетерү мөмкин түгел. Әле үзебезнең урманга кура җиләге җыярга баруыбыз турында да шактый язып булыр иде. Тугыз авылыннан Казанлыга (егерме чакрым ара) җәяү кайту үзе бер хикәя!

Авыл халкы безне: "аюлар—сентябрь аенда, бүреләр кыш көне генә куркыныч" дип, "юатып" җибәрде... Флера апага барып, киләчәгебезне белергә дә тырыштык... Гомумән, күңелдә яхшы тәэсир калдырган мизгелләр күп булды.

Казанга без бер дәфтәр фольклор материалы һәм биштәрләребезгә тутырып эрбет чикләвеге, ягъни "козык" төяп кайттык. Сез Себер татарлары фольклорын тулырак күзалдына китерсен өчен игътибарыгызга аның берничә үрнәген тәкъдим итәбез. Сөйләүчеләрнең тел үзенчәлеген сакларга тырыштык.

**Илсөяр ЗАКИРОВА,**
*Тел, әдәбият, сәнгать институтының өлкән фәнни хезмәткәре.*

## Еш ия

Еш ия—ир затыннан. Бер мәргән төскә чыккан. Еш ия белән урманда очрашкан да, бер избушкада кунган болар. Икесенең дә мылтыгы булган. Бер-берсеннән сораганнар болар, мәргән: "Сез ничек йоклыйсыз?"—дигән. "Без йоклаганда авыздан очкыннар чәчри. Ә сез ничек йоклыйсыз?"—дигән Еш ия. "Без йоклаганда үлгән кеше төсле",—дигән мәргән.

Бер-берсенен йоклаганын көткәннәр. Еш ия йокыга киткән. Мәргән бер бүрәнә алып үз урынына куйган, толыбы белән каплаган. Үзе чыккан. Еш ия уянган да, бүрәнәне мәргән дип белеп, чапкан. Мәргән, мылтыгын төзәп, агач артына качкан. Еш ия чыккач, аны аткан. Еш ия: "Тагын бер ат!"—дигән. Мәргән: "Егетнең—бер, ирнең—өч",—дигән. Тагын атса, Еш ия тереләсе булган икән.

*Тугыз авылында яшәүче Базметова Сөлҗамал Ситдыйк кызыннан язып алынды. 1926 елда туган.*

## Ияртеп китү

Төстә Еш ия, берәр кеше булып кычкырып, ияртеп китә. Андый кешенең, анына килсен өчен, куып җитеп аркасына сугарга кирәк. Торнакүзгә барган ханым-кызларны ияртеп китә. "Флера, бу якка кил!"—дигән тавыш килә, берәр кеше тавышы белән чакыра. Андый чакта урыныңнан кузгалмаска кирәк. Аннары: "Фәлән апа, мин шунда, килеп ал",—дип кычкырасың. Алар кешенең исен-акылын алалар.

Г. Гыйльмановның "Казан утлары"нда "Албастылар" дигән әсәре басылды. Ул фантастика түгел, язучы булган хәлләрне, шушы ешлар турында язган.

*Тугыз авылында яшәүче Сибгатуллина Флүрә Кинтә кызыннан язып алынды. 1938 елда туган.*

## Еш

Ауга баргач бер аучы урманнан бер хатын ияртеп кайткан. Яши башлаганнар. Балалары булган, дүрт балалары. Ире ауга йөргән. Кунып та калгалаган. Беркөнне ауга киткәч өйдә нәрсәдер онытканы исенә төшкән. Борылып өенә кайткан. Аның хатыны әйткән булган: "Аудан кайтсаң, ишекне шакымыйча кермә",—дигән. Шакымый керсә, хатыны бетен чүпләп, шуннан аш пешереп утыра. Хатыны моны күргәч: "Ишектән кердем, тәрәзәдән чыктым",—дип, тәрәзәдән чыгып киткән. Балалары калган. Әйтәләр, аның токымы бар диләр, чәчләре саргылт, күзләре кызгылт икән. Аучы күчеп киткәч, ул урында берәү дә яшәмәгән. Өй салып караганнар, яши алмаганнар. Ул урын әле дә утыра, буш.

*Казанлы авылында яшәүче Сәгыйдуллин Хәлим Харис улыннан язып алынды. 1949 елгы.*

## Җиде башлы Йилбегән

ЙОМАК

Җиде башлы бер йилбегән булган. Башында җиде мөгез булган икән. Өч туган булган. Икесе—ир туган, берсе кыз туган. Ир туганнары мәргәннәр булган икән. Зур абыйсының исеме Пайгана булган икән. Сенелләрен калдырып алар төскә чыгып китәләр. Алар төскә чыгып киткәч, җиде башлы йилбегән килә. Кереп кызны куркыта: "Абыйларыңа әйтмә",—ди икән. Инә-без белән уйнаган булып, кызның табанын тишеп канын эчә икән. "Абыеңа әйтсәң, мин сине йотам",—ди икән. Өч көн канын имгән. Кызның хәле беткән. Дүртенче көн, каны беткәч, яткан. Абыйлары сораса да, әйтми икән. Абыйлары үзләре өйдә калган дүртенче көн. Урамда берзаман давыл чыгып киткән. Башка җирдән керә алмаган, морҗага менгән. Морҗадан бер мөгезен төшергән, абыйсы мөгезне чапкан. Җидесен дә берәм-берәм төшергән, җидесен дә абыйсы чапкан. Җиденчесен тыкканда йилбегән әйткән: "Бүген ашап чыга торган көнем иде",—дигән.

Кыз яхшырган. Абыйлары белән яшәгәннәр. Мөгезләрендә көче булган, көче беткәч, йилбегән үлгән.

## Нугай алтыны

Олы Күлдә, күл читендә Нугай дигән авыл булган. Анда бер килендәш килеп төшкән була. Ул килендәш кырга чыккач, зур бер чүлмәк белән алтын күргән. Ул аны кулына алып уйнаткан. Икенче көнне дә барып уйнаткан. Өченче көн баруына алтын булмаган. Килендәш бик саран булган. "Үземә генә булыр",—дип уйлаган. Алтын шуңа күрә өченче көн баруына юкка чыккан. Аннары, алтын югалгач кына, иренә дә, халыкка да әйткән: "Шундый хәл булды, мин әйтмәгән идем",—дигән. Бер мулла карт палтар (фал) караган. Әйткән: "Котык (кое) токымнан бер кыз туар. Ап-ак чәчле, күк күзле, күз иясе кызыл булыр,—дигән.—Алтынны ул табар, унсигездә табар",—ди.

Минем әтием 25 яшьтә сугышка китә. Әтием сугышта үлә. Кайтмый. Мине алып

баручы булмый. Кырга мине алып чыгарга тиеш булганнар. Мин, пычак алып чыгып, алтын чыккач: "Мин шундый хайван суярмын, бу алтынны бөтен кардәшкә, ирмиргә бүләрмен",—дип әйтергә тиеш булганмын. Пычак белән жиргә кадарга.

Әгәр мин ала алмасам, 60 елдан тагын безнең токымнан шундый ук бала туарга тиеш була. 60 елдан, 1997 елда туды. Тимурның да минем төсле чәче ак, күзләре күк, күз иясе кызыл. Хәзер аңа биш яшь.

## Каракча (карак)

Элек Малай Уаттан (Кече Уат авылы) бер карт күршесенә ирмәккә кергән. Аннан чыгып килгәндә, төнге уникеләрдә, аны бер каракча көтеп торып, алып киткән. Карт бик курыккан. Мине үтерә инде бу дип. Каракча күл итәккә (янына) алып төшкән. Көймәгә утыртты картны, "Мине Агытбаш Семегә (Агыт елгасы башындагы сай урын) алып бар",—дигән. Карт алып киткән. Каракча мылтыклы булган. Семегә алып барган. Картны көймәсе белән өстерәп кырыйга чыгарган. Карт юлны Вершинга (авыл исеме) күрсәткән. Каракча картка: "Кәпәчеңне салып көймәгә утыр!"—дигән. Кәпәчкә тулганчы алтын койган, юл күрсәткәнгә рәхмәтен әйткән. Аннан соң картны этеп жибәргән. Карт кайтып житкән. Корткасы (карчыгы) белән бай яшәгәннәр.

Тугыз авылында яшәүче Шамратова Гөлжамал
Садыйк кызыннан язып алынды. 1937 елгы.

## Хозыр Ильяс турында

Безнең авылда Хәким бабай дигән мәргән яшәгән. Жиде тапкыр өйләнгән, баласы булмаган. Бер заман соңгы бичәсе белән яшәгәндә, боларга бер карт керә. Төссез (начар киенгән), картайган кеше. Каршы алалар, ашаталар, эчертәләр. Бу карт болардан хәл-әхвәлләрен, ни белән шөгыльләнүләрен сораша. Хәким бабай әйтә: "Күптәннән бирле йөрим, бер нәрсә эләктерә алмыйм. Ничә ел яшибез, балаларыбыз да юк." Гомумән, ярлы яшәүгә зарлана.

Иртә торып ашап-эчеп алгач, бу карт боларга теләк теләп чыгып китә. Баскычлары начар булганга озата чыгалар. Ишекне ачып карасалар, бер кеше дә юк, карда эз дә юк. Болар моның Хозыр Ильяс икәнен аңлый. Бер ел тулмый ир балалары туа.

## Меткә Купканы

Меткә авылында бер кеше—Купкан. Ул хайваннардан кан имә, аннары кешенең канын имә. Хайван канын имгәндә ул мәче, эт булып йөри, үгез, сарык булып йөри. Аннары үзе булып йөри. Йөрегәндә жиргә басканы күренми. Кешегә әйләнгәч, мулла аны жинә алмый. Меткәнең Купканы шулай йөри башлый. Ул кешенең каберен ачалар, үлгән кеше кып-кызыл булып шешенеп ята икән. Моның башын чабып, култык астына салып куйганнар. Бу башын култык астына кыстырып йөри башлаган. Янадан казырга курыкканнар. Казанлы авылыннан Муска (Муса) дигән кешене чакырганнар. Ул каберне казып усак казык каккан, әмма кәпәчен кабердә онытып калдырган. Өендә исенә төшә, кәпәч юк. Төнлә барып кәпәчне алып, янадан күмгән. Бу вакыйга сугышка кадәр була.

## Тирән Аер Мәцкәсе

Тирән Аер дигән авыл булган. Бу авылда бер сәбәпсез кешеләр үлә башлаган. Нидән икәнен белмәгәннәр. Бер көнне бер аучының тәрәзәсенә бер әйбер кулын тыга. Аучы теге кулны балта белән чаба. Кеше кулы була. Бу вакыт кояш байый торган була. Бу тере купкан була, ягъни Мәцкә. Хәзер уйлыйлар, кем кулы бу? Конторга халыкны жыялар. Яше-карты килә. Авылда бер корткаякның өенә киләләр. Кулын күрсәтми. Мылтык белән куркытып, карчыкның кулын күрәләр. Шуннан бу корткаякны яндыралар. Ул тере Купкан, яки тере Мәцкә була. Бу хәл революциядән сон була. Хәзер бу авыл юк, халык күчеп киткән.

Сәгыйдуллин Хәким Харис улы. 1949 елгы

## Тәүләт Али тухы

Борын-борын заманда Малай (кече) Уаттан Тәүләт Али дигән кеше урыслардан әйбер урлаган. Аннары урыслар аны сихерләгән. Ул авырып үлгән. Хәзер ул төстә йөри. Без аны белмибез, шуңа күрә, күрсәк тә, танымыйбыз. Чиягә барсак, төнлә өскә шалашны аудара. Ул, көрәк белән бәрә-бәрә, агач исәпләп йөри. Авылда аны белүче кешеләр үлеп беткәч, кайтачак.

Бахметова Сөлҗамал Ситдыйк кызы. 1926 елгы.

* * *

Тугыз авылында Нигъмәш дигән карт булган, бичәсе Хәтирә. Әле алар сиксәненче елларда гына үлделәр. Элек кеше күлдә туенган. Картның жиде яшьлек улы була. Бервакыт улы белән күлгә китә. Юлда көймәне туктатып, үзе корыга чыккан. Баласы көймәдә утырып калган. Төшсә, бала көймәдә булмаган. Баланы тапмаганнар. Китап ачтырганнар муллага, мулла әйткән: "Балагыз унсигез яше тулгач кайтыр",—дигән. "Тик кеше кыяфәтендә түгел, кош булып кайтыр. Әгәр барлык ишекләрне бикләп өлгерсәгез, балагыз кеше кыяфәтендә үзегездә калыр. Әгәр ишек-тәрәзәләрегезне ябып өлгермәсәгез, бүтән күрмәссез",—ди. Болар бу әйберне оныталар. Бәлки ышанмаганнардыр да.

Бервакыт, җәйге эссе көндә, өйгә кош очып кергән. Өйдә очып йөри. Болар авыз ачып карап утырган, онытканнар. Кош очып киткән. Болар кешеләр белән сөйләшкәч кенә исләренә төшергәннәр. Мулла әйткән булган, баланы су иясе ияртеп киткән, дигән.

* * *

Кыр якта бер хатын адашкан. Кыш житә башлагач, кышлар өчен өн ясарга теләп, агач төбен казыган. Бу аю өненә туры килгән. Аю белән кыш үткәргән. Яз көне баласы туган. Бу гел үзенең туган авылын уйлап йөргән, юл эзләп тапкан да, балаларын алып качкан. Кайтып бераз торгач, аю эзләп килгән. Кайберәүләр аю кире алып киткән, тагын балалары булган, дип сөйли. Аюны этләр талап үтергән, дип сөйләүчеләр дә бар.

## Әләмәце (әямәце)

Әләмәце—кар-буран, көчле җил белән йөргән. Кыен (пәри туе) төсле булып, бөтерелеп йөри икән. Аңа баскыч алдына чыгарып, икмәк, башка ризыклар куя торган булганнар, куймасаң, кешеләргә зыян салган.

## Аучы чаңгысы

Аучы-мәргәннәрнең чаңгысын эт өргән агачтан ясыйлар. Эткә каршы өрә ул агач. Ул агачны еллар буе эзләгәннәр. Ул агачны тапкач, аны башта бәйлиләр, югыйсә ул кеше өстенә егыла. Балта белән чапкач, тапчыгы (йомычка) читкә очып юкка чыккан. Шул агачтан ясалган чаңгыда йөргән вакытларда, аны туктату өчен, алдына эт тиресеннән тегелгән бияләй ташлаганнар. Шуның өстенә менеп кенә туктаган. Мәргәннәр ул чаңгыда очкан кебек йөргән. Аңны (пошины) куып җиткәннәр.

Казанлы авылында яшәүче Сәгыйдуллина Нера Бахметовнадан. 1952 елгы.

*Игътибар!*

## ДИСКУССИЯ: «БЕЗНЕҢ ЗАМАН ГЕРОЕ»

XX гасыр азагында һәм XXI гасыр башында кешелек дөньясының һәм икътисади, һәм рухи тормышында гаять тирән үзгәрешләр барлыкка килде. Элеккеге СССР җирлегендә—без яшәгән җәмгыятьтә—алар аеруча кискен һәм үзенчәлекле чагылыш тапты. Күп дистә еллар буе яшәешебезнең асылын тәшкил иткән икътисади тотрыклылык бетү белән бергә, әхлак критерийлары да сизелерлек какшады, сәяси ориентирлар үзгәрде. Моңарчы халыкның «уртак малы» саналган мөлкәт таланды, таратылды, бүленде; ясалма интернационализм кысаларына куып кертелгән, әмма асылда канәгатьләндерелмәгән милли ихтыяжлар милләтара мөнәсәбәтләрнең киеренкеләнүенә китерде, хәтта гражданнар сугышы учаклары хасил булды, яңа буыннарны тәрбияләүдә иҗтимагый идеаллар алышынды... Шул ук вакытта, җәмгыятьтә демократия чалымнары да үсеш ала башлады: сүз һәм вөҗдан ирекле, ил-дәүләтләр арасындагы «тимер чаршау»ның алып ташлануы, шәхси инициативага өстенлек бирелү әнә шундый уңай күренешләрдән саналырга хаклы.

Менә шушындый катлаулы, байтак язмышларны ботарлап ташлаган, хәтта катаклизмнарга кадәр барып җиткән җәмгыятьтә әдәбиятның, анығрак әйткәндә, матур әдәбиятның роле кимеде түгелме? «Әдәбият—тормыш көзгесе» дигән шигарьне өлге итеп алган күбебез өчен табигый борычлудыр бу. Моңа кадәр без әдәбиятны кеше аңын формалаштыруда иң төп факторларның берсе дип инанып килдек. Хәзерге вәзгыятьтә бу чыннан да шулаймы? Гомумән, әдәбиятның үзендә нинди процесслар бара? Сораулар күп. Без, бу очракта, әдәбият, тәрбия чарасы буларак, үз миссиясен югалтмаган дигән фикердә торып, мәсьәләнең бер ягына игътибарны юнәлтмәкче булабыз.

**—Бүгенге татар әдәбиятының (соңгы 20 еллар) каһарманнары кемнәр?**

**—Аларда яшьләр күңелен яуларлык нинди сыйфатлар бар?**

**—Язучыларның бу каһарманнар образын ачып салуда уңышлы һәм кимчелекле яклары нидән гыйбарәт? Гомумән, ихтирамга лаек олы язмышлы шәхесләр тиешле дәрәҗәдә чагылыш табамы?**

Әлбәттә, сорауларның формулировкаларын теге яки бу төсмердә үзгәртебрәк тә куярга мөмкиндер, әмма сөйләшү-әңгәмәгә чакыруның мәгънәсе бер: бүгенге татар әдәбиятында «безнең заман герое».

Әдәбиятыбызның бөтен жанрларын да инләргә тиешле бу сөйләшүдә язучылар, тәнкыйтьчеләр һәм, гомумән, әдәбият белән кызыксынган киң катлам укучылар актив катнашырлар дип өметләнәбез. Сөйләшүне 2004 елның гыйнварында башлап җибәрү күздә тотыла.

# ГАМЬЛЕ ГАМӘЛЛӘР КЫЛЫЙК!

Китап кадере... Әдип язмышы... Болар хакында язып торалар, мөнбәрләрдән сөйлиләр, ләкин көндәлек тормышта бу гаять тә мөһим төшенчәләр белән санлашучы сирәк. Яшәешне тар кысаларга өстерәп кертү өчен сәбәпләр байтак, бәндә көндәлек мәшәкатьләре белән каядыр ашыга, иҗтимагый вәзгыять тудырган чоңгылларга төшеп тартыша, сәясмән җәтмәләренә эләгеп җәфалана. Халык рухының сакчысы булган Әдәбият дигән газизе хакында уйланып торырга вакыт гел калмый. Бөек шагыйребез Кадыйр Сибгат бер шигырендә: "Рухың тузса, ямау салып кына саклап булмый икән җаннарны" дип кисәтеп куйса да, без рухиятны, кеше җанын күп очракта бутафор кыяфәттә күзаллыйбыз. Җаннар суына бара, тамырларда сут кибә, кеше рухы зәгыйфьләнә, һәм шушы шартларда да халыкны бар итүче төп билгеләрнең берсе булган, дөнья алдында аны таныткан биниһая бай һәм изге әдәбиятыбызга битарафлык хөкем сөрә. Әлеге язманы кәгазьгә төшерәм дип җилкәнеп йөргән көннәрдә берничә әдип якты дөньядан китеп бардылар. Илдар Әхсәнов. Рафаил Сибат, Гамил Афзал, Рәшит Шиһапов... Аларның милләткә, кешелеккә калдырган әдәби мирасы, әдәбиятта тоткан урыннары төрлечә, әмма алар әдәбиятка, димәк халыкка бар булганынча хезмәт иттеләр, аянычы—кайсысы гына яшәгән чакта әдипкә булырга тиешле чын игътибарны, зурлауны тоя алды микән? Ә бит һәр язучының гамәл дәфтәрен ачып карасаң, һәркайсының иҗаты халкыбыз җанын сафландыруга хезмәт итә, һәркайсы милләтебез язмышы хакындагы уйлардан гаҗиз...




Борын-борыннан китапка табыну яшәгән, китапка кереп калган акыл вә гамь—мәңгелек, рухиятның тузмый, искерми торган алтын фонды, шуңа күрә дә мең еллар дәвамында китапка аеруча сак караш тәрбияләнгән. Кешеләр "яу килгәндә, китапларны әнә-ә теге тау башына күмгәннәр. Хәзер урынын белгән кеше дә юк..." Әлеге, укып чыгуга күңел түрен айкап ала торган картлар сүзен күренекле замандашыбыз әдәби тәнкыйтьче, шагыйрь һәм нәшир Мөдәррис Вәлиев 1998 елда чыккан "Яшьлектән хат" дигән китабына теркәп куйган иде. Укыганга байтак еллар үтсә дә, еш искә төшә, уйландыра торган гыйбрәтле тарих, риваять булып яши ул миндә. Китап язмышы турында сөйләгәндә аны искә алмый мөмкин түгел—саклап калу өчен күмелгән китаплар, уткылыч белән юкка чыгарылган кавем һәм... эзсез югалган язулар... Бар нәрсә онытылган, калалар көлгә әйләнгән, китапка бәйле Хәтер генә яши.

Инде кулымда—Мөдәррис Вәлиевнең яңа китабы. Үтә зәвык белән эшләнгән, саллы җыентыкның мәгънәви

Мөдәррис Вәлиев. "Гамәл дәфтәре".–Казан: Татарстан китап нәшрияты. 2003.–447 б.

кыйммәте, укучы күңеленә салынырга тиешле "нагрузкасы" исеменнән үк күренеп тора: "Гамәл дәфтәре". Татарстан китап нәшрияты әдәбият сөючеләр өчен матур бүләк әзерләгән. Инде дистә елдан артык китаплар нәшир итүдә армый-талмый эшләүче туры мәгънәдәге "хезмәт иясе" "Мәгариф" нәшриятын оештырган, аның директоры булып эшләүче Мөдәррис Вәлиев бу китабында гадәттәгечә бер чиктән икенчесенә ташланмыйча эзлекле рәвештә әдәбият призмасы аша халкыбыз тормышына тәэсир итәрлек асыл һәм хәтәр сыйфатларны, без игътибар итәргә тиешле фәлсәфи категорияләрне барлый. Мөдәррис Вәлиев—эстет, китапка кергән эссе тибындагы һәр мәкалә тукымасында югары зәвык, һәр әсәрдә караш иркенлеге ярылып ята. Язмамны юктан гына Хәтер төшенчәсеннән башламадым. "Гамәл дәфтәре" китабына кергән "Ачы әрем исе" дигән мәкалә үк укучыны җәлеп итә, анда—хис-тойгылар өрмәсе уйный. Үзем укыйм, колакта Әмирхан Еникиның "Сезнең онытырга хакыгыз юк, аңлыйсызмы?.."—дигән эпиграф-сүзләре чыңлап торган кебек. Автор сүзне балачактан, сабый күңеленә уй, гамь орлыклары салып калдырган алтын чордан башлый. Мөдәррис Вәлиевнең балачак хакындагы монсу хикәятендәге Әдрәпи әби тетрәндерә. "Әйтелмәгән васыять" тәге Акъәби фаҗигасенең тирәнлеген тояр өчен кирәк ул авылдан авылга каңгырып йөрүче Әдрәпи әбине искә төшерү. Шушы кыска гына тасвирлауда тулысынча ачылып беткән Әдрәпи әби. Шомырт тамырыдай кара бармакларына сырышкан саргылт балдаклар, җәйге чиләдә дә кәбестә кебек катлы-катлы киенеп йөрүе, иреннәрен үзалдына мыдыр-мыдыр кыймылдатып болдыр баскычыннан менеп килүе, итәкләренә абынмас өченмедер, вак-вак атлап килеше—барысы да күз алдына тере кешене китереп бастыралар. Тере, әмма... хәтерсез җан иясе. Инде үлдегә саналган карчык бер шәп вакыйгага туры китереп янә-янә авылга килеп чыга, ике сүзнең берендә: "Адашканмын шул мин... Адашып ла калганмын!"—ди. Әби авылның олысын кечесен белә. Әллә кайчангы вакыйгаларны, килеп-киткән кешеләрне искә ала, тик үзен генә югалткан. Үзе хакында үзе дә, башкалар да берни дә белми... "Мин адашканмын шул... Әле дә булса үзебезнең авылны, нәнәмне таба алмыйм бит!"—дип такмаклый... Хәтеренә балта чабылган зат кызгандыра, уйландыра. Ихлас әйтәм, татар әдәбияты янә бер классик образ—Әдрәпи әби образы белән баеды. Акъәбинең онытгы "Я— башкирин, бабушка, башкирин!"—дип лаф оручы Геннадий, Илдар Юзеевның "Сандугачлар килгән безгә" драмасындагы Хәмзин, фантаст язучы Адлер Тимергалинның "Уян, сөеклем" әсәрендәге "ярымкешеләр" образлары аша автор безне Чыңгыз Айтматовның Найман-ана, Валентин Распутинның Анна әби образларына алып чыга, манкортлык, киләчәк буынның миһербансызлыгы, шәүкәтсезлеге зур әдипләрнең уртак проблемасы, һәр халыкның хәсрәте, һәр милләткә хас яман авыру булуын искәртә.

Әгәр дә әдип яшәү рәвеше итеп гел тискәре нәрсәләр генә күрсәтүне максат итеп куйса, замандашлар арасыннан җаннарны сафландырырлык уңай образлар күрә алмаса (кызганыч, халык җаныннан кер эзләүдән аерым тәм табучы, соңгы дистә ел эчендә милләт яшәешеннән телгә алырлык бер уңай сыйфатны калку итеп күрсәтә алмаган язучыларыбыз да бар) андый әдәбият халыкны төшенкелеккә сабыштырыр, өметсезлеккә юл тотарга мәҗбүр итәр иде. Бәхеткә диик, әдәбиятыбызда матур үрнәкләр дә җитәрлек. Намус, Ватан, хәтерсезлеккә каршы тора алган Хәтер, Мәхәббәт кебек изге төшенчәләр дә бар һәм аларны әдәби биеклеккә күтәргән әсәрләребез дә аз түгел. Андый әсәрләрдә рухи хәзинәләр, тарихыбызның зурлыгы, милләт акылы, фәлсәфәсе югары кимәлдә тасвир кылына. Автор, мисал рәвешендә, Муса Җәлилнең Тузгак анасын искә ала, Илдар Юзеевның "Соңгы сынау", Туфан Миңнуллинның "Моңлы бер җыр", Сибгат Хәкимнең "Васыятьләр" кебек әсәрләренең әдәби кыйммәтен билгели. Бабайлардан калган рухи мирасны, тарихны, традицияләрне үзләштерүгә сәләтле милләтнең генә киләчәге бар. Бу яктан да уйланырга сәбәпләр байтак. Хәтер һәм хәтерсезлек, шәхеснең рухи дөньясына авылдагы үзгәрешләр һәм шәһәр һавасының кире йогынтысы, табигать һәм кеше, дәвер һәм шәхес мөнәсәбәтләрендәге үзгәреш-каршылыклар хакында тирән уйлануларны эченә алган әсәрен йомгаклап Мөдәррис Вәлиев Хәтер төшенчәсенең рухиятны бар иткән асыл мәгънәсен билгели: хәтер—"үткән көннәр көле түгел, иртәгә туасы таңның кояшы икән ул,"—дип күрсәтә автор. Оптимизм кешене алга әйдәүче көч бит ул, әдипнең халкын алга әйдәкләвен, мәңгелек фонында югалмас бер асылташ кебек балкуын күрергә теләвен ничек хупламыйсың ди!

Кеше рухын саклап торучы иң зур көчләрнең берсе, мөгаен, Табигатьтер. Табигатьнең кеше җанына йогынтысы

хакында Мөдәррис Вәлиев ныклап уйлана, төпле гомумиләштерүләр ясый. "Тәллитут" әсәре нәсергә хас алым белән язылган. Табигатьтә һәр нәрсәнең кеше аңына йогынтысы тоемлана, шул нисбәттә аның һәр нарасыена адәм заты исем дә кушкан. Исем ул—яшерен метафора, хәтер төене. Бу әсәргә дә импульс бирүче аңасты—Хәтер. "Тәллитут"... Хәтер кузы, хәтер сагышы, хәтер уянуы... Автор безне үзе туып-үскән Әлки төбәгенә алып кайта. Алар тал песиен сәер исем белән атаганнар—тәллитут дип йөрткәннәр икән. Чын мәгънәсен табып кара инде! Әмма автор безне "еракkарак" алып кереп китә. Арча ягында юкка чыккан "алласыз" урыс авылы Надеждиноның язмышы. Авылы булган, ә менә инешенең исеме юк. Язмыш шаяруымы бу, әллә башка нәрсәме?.. Татар халкы табигатьнең һәр күренешенә шигъри исем куша белгән, төбенә төшә алсаң, һәр атаманың тирән мәгънәгә ия икәнен күреп шаккатасың. Балага табигатькә мәхәббәт ана сөте, ана аңы аша керә, менә хикмәт нәрсәдә. "Әни миндә табигатьтәге бар нәрсәнең дә жаны бар икән, чишмәләр генә түгел, йолдызлар да, җилләр дә сөйләшә икән дигән "иман" тудырды", дип язган Хәсән Туфан. Шушы урында үземнең әнкәем Нурсаниянең мине—орчык кадәр малайны болынга ияртеп алып барып, "күгәрчен күзе" дигән дөньяга шундый саф, самими карап балкучы чекрәеп торган нәни чәчәкне күрсәтеп, сокландырганын, гөлне өзәргә үрелгән нәни кулымны сак кына читкә этәргәнен искә алмый китәлмим. Баксаң, Иман формуласы катлаулы икән бит, безгә аны гадиләштереп аңлатырга маташучылар да аз түгел. Имеш, намаз укысаң—иманлы, укырга өлгереп җитмәсән—имансыз буласың... Туфан әйткәнчә, аз да түгел, күп тә түгел иман кадәр иман тууга сәбәпче Табигать-анага бүгенге буынның карашы ничек соң? Табигать—байлык туплау сферасы, чимал чыганагы, кәеф-сафа кору урыны... Тагын ни? Күкрәп печән үскән болыннар, шаулап үскән урманнар, гөрләп аккан инешләр, баш очында сайрап туймаган тургай... Һәм табигать белән тиңдәшсез алышка чыккан сөмсез адәм баласы. Туган җирен яраткан кеше табигатькә миһербансыз була алмый. Ана сөте белән кергән изге иманны мәктәп елларында тагын да ныгытасы иде. Зур тормышка адәм баласы җимерүче психологиясе белән түгел, җир-суының кадерен белгән, аңа сак караш тәрбияләнгән Шәхес булып аяк атласын иде.

Мөдәррис Вәлиев әдәбиятның аңга тәэсир итү җегәрен, китап сүзенең кадерен яхшы белгән әдип. Китаптагы кайсы гына әсәрне алма, аның кабатланмас йөзе, кыйммәте бар. Хәсән Туфан, Нәҗар Нәҗми, Нәби Дәүли, Хисам Камал, Вакыйф Нуруллин, Аяз Гыйләжев, Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Гәрәй Рәхим, Рәдиф Гатауллин, Роберт Миңнуллин иҗатларын, әлеге олпат әдипләребезнең аерым әсәрләрен анализлаган мәкаләләрне укыгач, авторның тирән белемле әдәби тәнкыйтьче булуына игътибар итми мөмкин түгел. Төрле авторлар турында бер каләм белән язу җиңел эш түгел. Әмма Мөдәррис Вәлиев максатына ирешкән дип әйтә алабыз. Ни өченме? Беренчедән—тәнкыйтьче төп материалны—татар әдәбиятын дөнья әдәбияты биеклегеннән торып күзәтә, сүз кузгаткан авторның иҗатын, тормышын, акыл йөртү рәвешен, иҗади стилен яхшы белә, икенчедән—ул аларга хәерхаклы, укучыда бу авторларның шәхесенә, иҗатына кызыксыну тудыра алырлык каләм куәсенә ия, өченчедән—шулай ук мөһим нәрсә, күпсүзлелек юк, дүртенчедән—алар мактауга гына корылмаган, әйтеләсе фикер кирәк кадәр, сендереп әйтелә. "Шигырь дәрәҗәсен төшерүче сәбәпләр күп,—дип резюме ясый ул "Чынлап та шулаймы соң?" дигән мәкаләсендә. Һәм дәвам итә:—Шигырь арты шигырь укыйсың: барысы да дөрес, барысы да мәгълүм... Һич аңлашылмый: нинди максат белән әле Кояш системасы өчен кайгыртучы "фәйләсуф" булып күренергә тырышабыз? Газета хәбәрләрен нигә дип рифмалаштырабыз? Модасы шулмы, заман гаме белән янган булып күренәсебез киләме? Авторның чын йөзе, тормыш позициясе урынын тышкы кыяфәт—поза ала бара. Бер табылган алымнар, темалар, образларны ахыргача сыгу хәтта иҗатлары белән танылып өлгергән шагыйрьләрнең дә кызыклы дөньясын кызганыч хәлгә китерә—ахыр чиктә бер даирә эченә бикли бара. Аларда шигырь—тәкә мөгезе шикелле—үз эченә бөтерелеп, башына кайтарылып үсә башлый: гамәлгә яраксыз, гарип бер нәрсәгә әйләнә." Бу мәкаләгә кергән бүлекчә исемнәре укучының игътибарын җәлеп итәләр, күңел дулкыннарын бер фокуска җыеп, кызыксыну тудыралар, авторның әдәбияттагы житешсезлекләргә карата килешмәүчән, ныклы позициясе барлыгын күрсәтәләр: "Тәнкыйтьченең эчендә тагын бер тәнкыйтьче утыра", "Күңелне кузгатмый, ә тәнне дерелдәтә", "Ни өчен уртакул-

ның базары югары?", "Тәрәзәсез—ишексез өй..." ...Шушы кайнарлыкны, әдәбият өчен ихлас януны күргәч үк, китапның кыйммәте артып китә кебек.

Китап кадерен, әдип язмышын аңлауга, рухи биеклекне тоярга без нәкъ менә булдыклы әдәби тәнкыйтьчеләребез язганнар аша киләбез. Кызганыч, соңгы елларда Ибраһим Нуруллин, Фәрваз Миннуллин кебек әдәбиятчы галим дә, әдәби тәнкыйтьче дә булган шәхесләребез сирәгәя бара. Аларга алмашка килүче Дания Заһидуллина, Өлфәт Закиржанов кебек яшьләрнең әдәби мохиткa ныклы адымнар белән кереп килүен күреп күңел сөенә билгеле. Тик зур әдәбиятны тулаем аналилитик фикер платформасына күчереп куярга аларның гына вакыты, җегәре җитеп бетмәс шул.

"Авыл халкына ни җитми", "Тапшырылмаган хатлар", "Иске сәгать дөрес йөри", "Көндәлек сәхифәләр" дип исемләнгән мәкаләләрдә Мөдәррис Вәлиев иҗатын бар иткән публицистик накал тагын да бер баскычка үсеш кичерә. Ул бу өлкәдә дә үзен милләт яшәешенә, әдәбият үсешенә, китап язмышына йогынты ясый алырлык күп проблемаларны нәкъ вакытында һәм калку итеп күтәрә алган публицист итеп тә таныта. Мөдәррис Вәлиев үзәкләргә үтәрлек итеп, кайчандыр, кемдер уйламыйчамы, уйлапмы "кечкенә" дип тамга салынган авыллар проблемасын күтәрә. "Кечкенә" дип тамга салыну бу авыллар өчен приговор, иң хәтәр приговор, иртәме, соңмы, мондый салалар җир йөзеннән бетәргә мәхкүм... Уйлап карасаң, кеше өчен туган авылы "кечкенә" яки "зур" була аламы?.. Һәр кешенең иң ватаны беренче чиратта ул аның—туган авылы. Иң зур Ватан—туган нигез! Туган нигезеннән яшәеше өметле булганнар гына Илватан төшенчәсен җан-кан дәрәҗәсендә якын тоя алалар, аның төптән кадерен белә алалар. Нигезе юкка чыкканнарның күп нәрсәләр белән исәп-хисабы өзелә... Авылны юкка чыгарасың килсә—аның мәктәбен бетер. Сабыйны башка авылга йөртеп, җанын корыт, аның күңеленә илгә нәфрәт орлыгы сал. "Мин өч авыл баласы: берсендә туганмын, икенчесендә үстем, өченчесе мина белем бирде. Берберсенә сыенып диярлек утырган өч авыл. Дөрес, үскән авылым туган авылдан да якынрак булса, мәктәпле авыл исә "килмешәк" икәнлегебезне онытырга бирмәде... Адашып калырлык бураннарда, коры җеп бөртеге калмаслык итеп чылаткан яңгырларда, ни дип кенә ашыга-кабалана барганбыздыр инде? Дәресенне белмәгәнгә түгел, шул гарасатта юлга чыгып, адашып үлмичә, мәктәп капкасын тапкан, әмма биш минутка соңга калган өчен бөтен әрхурны күтәрергә дипме? Мәктәп залында "унган авылдашлар" дигән стенд эленеп тора: бер үк хуҗалыкка хезмәт итеп, эштә алдынгыларның алдынгысы булса да, анда синең авылың кешеләре юк,"—дип яза автор ачынып. Бу юлларны укыгач ирексездән күңелем кузгалды. Миңа бик тә таныш болар. Иртән таңнан унике чакрым ераклыктагы мәктәпкә җәяүләп чыгып китүләр, керфеккә сылашып күзне ачылмас хәлгә җиткергән кара буран, йөзчырайның әкеренләп тоташ бозга әверелә баруы—инде аны күшеккән кул белән чистартып өлгереп булмый башлый, юл саташтырып кар диңгезләрен ермачлаулар һәм... мәктәп коридорына килеп керүгә укыту мөдиренең зәһәр тамгасы: "Әмәкәйләр, тәнкыйтьтән түбәннәр... Тагын берәр сәгать йоклап ятарга иде..." Мөслим районы төбәгенә багышланган китап кулга килеп керде. Зур хезмәт бу. Әмма Күбәк урта мәктәбендә белем алган язучылар исемлегенә дә мине кертеп торуны кирәк тапмаганнар. "Чит" авылныкы шул без...

Мөдәррис Вәлиев әгәр (әгәр дим, чөнки автор үзе болай дип яза: "...Төрле сәбәпләр аркасында, берара кулымдагы каләмне, әдәби хәрәкәт барышыннан бигрәк, китап нәшер итү хәлләрен тасвирлауга җәлеп итеп тордым. Бәлки, бу хәлне үзем өчен югалтуга да санар идем,—әгәр шул елларның әдәби тормышында башка рәвешле, бүтән сыйфатта катнашырга туры килмәсә, "көнем өчен түгел, денем өчен" яшәмәсәм,"—дип искәртә), әгәрен ки гел әдәби тәнкыйть, публицистика өлкәсендә генә эшләсә, шактый әче телле, туры сүзле әдип буларак танылу алыр иде. Сурәтләүдә фикере ачык, урыны белән ирония дә сизелә. Заманында Игорь Северянин "Ирония—вот мой канон"—дип язган икән, юкка түгел инде бу. Ироник сурәтләү куәсенә ия булу—авторның холкын күрсәтүче сыйфатларга ишарә ул—аек акыллы, вакланмаска омтыла, кирәк чакта усал да була белә... Болар тәнкыйтьче өчен иң кирәкле сыйфатлар. Хәтта бер фото астына язылган: "Тәнкыйтьчеләр йөри иде төркем-төркем,"—дигән сүзләргә ирония дә, ачыну да салынган. Күтәреп алсаң, әллә никадәр проблемалар ята ул сүзләр астарында. Яки "Тапшырылмаган хатлар" мәкаләсе: "Көннәрнең берендә мин Николай Иванович Рыжков булып уяндым..."—дип башланып китә. Онытмаган булсагыз, бу кеше заманында СССР дип аталган мәрхүм коммун ватаныбызның

премьер-министры иде. Алга табан әлеге мәкаләнең эчке җегәренә игътибар итегез: "Кайчандыр күкрәгенә "әллә нинди кара көчләр" басып торганга гына уяна алмаган халык өстенә янә җитмеш кат вәгъдәләр юрганы ябылган. Россиядә сан ягыннан икенче булган милләт—Урал, Казакъстан, Урта Азиягә яңа дәвер мәдәниятеннән ут алып биргән милләт—чыра яктысы кебек бердәнбер нәшриятка карап калды. Дөнья базарына "кара алтын", мех чыгарган, автомобиль, очкычлар төзү, химия, хәрби комплекс гигантларын иңенә күтәргән Татарстан җире бүген "эштән чыгарылган татар кызы" хәлендә... Ә шул ук вакытта, үзен милләт хадиме дип санаган агай-эне (ни аяныч!) өч хәрефкә койрык ялгамакчы булып мәш килә, "татармы без, болгармы?" дип дөнья болгата, дини китапчыклар белән спекуляция ясый..." 1991 елда язылган сүзләр, ул вәзгыятьтә усалланмый калып кара! Хәер, бу нәрсәләр хакында әле дә ызгыш-тартышлар бара, тик хәзер инде федераль дәрәҗәгә менеп... Гомумән, тәнкыйтьченең сурәтләү стилен күзәтсәң, гаять кызыклы гомумиләштерүләр ясарга мөмкин булыр иде. Бу тикшерелмәгән өлкә, ачылмаган китап.

Яшермим, бу китапны укыганчы Мөдәррис Вәлиевнең иҗатын да, шәхес буларак та беләм дип әйтә алмый идем. Ятим үскән Мөдәррискә тормышта нәрсәгәдер элгәшү, үрләр яулау җинел бирелмәгәндер. Ул булганның кадерен белеп, киләчәккә карап яши. Ихлас әйтәм, каләмдәшләремнең иҗатларына сөенәм, игътибарга лаек иҗатны күрмәү, танымау минем өчен гайре нәрсә. "Гамәл дәфтәре" китабын укып чыккач, кулым каләмгә үрелде—Рәсүл Гамзатовның мәгълүм мәзәге искә төште, кайбер дус-ишләргә "шәп китап" дип мактап үткәнче, язып чыгуга ни җитә! Әдипкә карата фикерем ныгыды, үземә калса, байтак ачышлар ясадым. Баксаң, аны шәхес һәм әдәби тәнкыйтьче буларак бөекләребез "күптән ачканнар" икән инде. "Ярый әле мин исән чакта очрадың... Синең "Казан утлары"нда чыккан мәкаләң мине бер дә булмаган олы шатлык белән тетрәтте. Бу—минем иҗатым турында беренче олы сүз..." (*Нәби Дәүли*), "Арабызга беренче адымнарыннан ук ышаныч тудырган ныклы адымлы, туры сүзле иптәш килә. Без аны көтә идек..." (*Аяз Гыйләҗев*), "Салих Маннапов (*Мөдәррис Вәлиевнең әдәби тәхәллусе. Ф. С.*) беренче мәкаләләреннән үк укыла торган тәнкыйть язарга омтылды (кызганыч, әмма тәнкыйтьнең укылмый торганы да була шул!), аның стиле җыйнак, теле гади, аңлаешлы. Ул укучы белән ихлас сөйләшү формасын шактый урынлы куллана. Кайвакыт әдәби тәнкыйть мәкаләсен лирик чигенешләр яисә публицистик рухта язылган өзекләр белән аралаштырып бара" (*Рафаэль Мостафин*). "Салих Маннапов һәр язучының, шәхеснең үзенә генә хас сыйфатын, характерын, иҗади үзенчәлеген оста тотып ала... Күңелгә сеңеп калган фикерләр, күз алдына баскан сурәтләр күп..." (*Нажар Нәҗми*). "...Салихның күңел түрендә шигъри талант чаткылары, кешеләргә әйтер сүзе, табигать күренешләренә, кешеләрнең яшәешләренә, гомумән дөнья хәлләренә карата үзгә бер поэтик караш бар." (*Равил Фәйзуллин*). Житеп торыр булса кирәк. Китапны тулаем күздән кичергәч, горурлану белән: "мондый фидакарь затларыбыз булганда яшибез әле!" дип куйдым. Тик Хәтерне генә җуймаска кирәк. Язмамның башында әйтеп киткәнчә, ишеттерәсе рәхмәт сүзләре, күрсәтеләсе илтифат зур шәхесләребезгә вакытында барып ирешсен иде. Әдипнең күңел йолдызлары һаман яктылык сирпиләр, җаннардагы битарафлыкны куарга, безне гамьсезлектән араларга тырышып яналар-яналар. М.Вәлиев үзе әйткәнчә: "Беләсезме, ул йолдызлар сезгә юл булса да күрсәтик дип, тилмерәләр..." Бу җан авазын ишетик тә, хәрәкәтчәнрәк, кыюрак, эшлеклерәк булыйк. Күгебездә йолдызлар кимемәсен, рухыбыз ямаулардан азат булсын, гамьле көннәр артканнан арта торсын. Күптән түгел илле яшен тутырган әдипкә исә яңадан яңа иҗат уңышлары телик.

**Факил САФИН**, *язучы,*
*Гаяз Исхакый исемендәге*
*премия лауреаты.*

# ТӘКЪДИР ЮЛЛАРЫ

Бүген безнең өмет һәм ышаныч тулы карашларыбыз татар әдәбиятының проза тармагына юнәлгән...

Ә ни өчен нәкъ менә прозага?

Ин башта шушы сорауга җавапны ачыклап китик.

Проза тармагының аерым бер игътибарга дучар булуына ин төп сәбәпләрдән берсе шулдыр: соңгы дистә елларда илдә вакыйгалар бик тә куерып китте, адәм балаларының язмышлары да нык кына катлауланды, алар алдына килеп баскан четерекле хәлләр, ситуацияләр күбәйде. Россиядә бер иҗтимагый формациянең икенчесе белән алышына башлавы үзе генә дә ни тора! Кеше өчен никадәр психологик кичереш дигән сүз бит ул!




Менә шушы вакыйгаларны, аларның дәвамлы драматизмын, кеше язмышларына тәэсирен бары тик киң колачлы проза әсәрләре генә хәрәкәттә, үсештә күреп һәм тирәннән алып чагылдыра, тасвирлый ала. Безнең әдәбият сөюче замандашларыбыз үзләренең әйләнә-тирәләрендә күпләгән гыйбрәтле язмышлар күргәннән соң чын йөрәктән әрниләр һәм еш кына четерекле хәлләрдән чыгу юлларын эзләгәндә үзләренә рухи ярдәм, күп кенә сорауларга җавап көтеп кеше күңеленең инженерлары булган әдипләргә күз текиләр икән—биредә, әлбәттә, иң беренче чиратта прозаик әдипләр, алар иҗат итә торган роман һәм повестьлар күздә тотыла.

Шушы ук сәбәпкә ялганып, аның белән органик рәвештә тоташып китә торган тагын бер фактор: безнеке шикелле буталчык, адаштыргыч елларда—тормышның полюслары алышынган елларда— кеше үзен еш кына куе томан эчендә, яисә сазлыкта калгандай тоя һәм үзенә күңел тынычлыгы, ышаныч бирердәй рухи көч, мөхит, яшәеш дөньясын кирәксенә. Кеше җанын, күңелен шактый гомер биләп тора алучы, аны байтак вакыт билгеле бер образлар, каһарманнар арасында яшәтә алучы рухи дөнья, әлбәттә, шул ук проза әсәрләре.

Проза тармагының хәзер аерымрак, үзгәрәк хәлдә калуына тагын бер сәбәп: татар әдәбиятының шигърият һәм драматургия өлкәләре, күз тимәсен, әлегә әйбәт кенә үсеш кичерә. Ә менә проза тармагы турында әле андый сүзне әйтүе кыен. Соңгы дистә елларда проза әсәрләренең сыйфат ягы шактый түбәнәйде. Аның конкрет сәбәпләре (тормышта тотрыклылыкның—басылып һәм чын профессиональ кимәлдә иҗат белән шөгыльләнү өчен кирәкле рухи-әхлакый климатның—югалуы, җәмгыятьнең әдәбиятка булган игътибары кимү, проза тармагында зур тәҗрибә туплаган талантлы өлкән буынның китүе, бары тик иҗат белән генә шөгыльләнергә мөмкинлек бирердәй каләмхак түләнмәү һ. б.) турында безнең матбугатта инде байтак кына сүзләр булды. Ләкин хәлне аңлау һәм аңлату белән генә проза тармагын тиз арада үстерү, аны башка жанрлар янәшәсендә күрү мөмкин түгел шул.

Үткән XX гасырда татар прозасының бөтен дөнья күләмендә мактана алырдай сәнгати-фәлсәфи казанышлары булу һәм әлеге йөзьеллыкның ахырына таба прозабызның ул биеклекләрдән түбәнәюе, еш куандыра алмавы да бу тармакны укучылар каршында үзгә хәлгә—“бурычлы” хәлгә куя. Элегрәк татар прозасының татлы җимешләрен татыган укучының соңгы елларда да аннан тиешле рухи җимешләр көтәргә хакы бар, әлбәттә.

Әйе, югарыда санап кителгән һәм әле әйтеп бетерелмәгән башка кайбер сәбәпләр аркасында бүген безнең прозага карата әнә шундый аерым бер мөнәсәбәт хасил булды. Газета-журналларда басылган яисә нәшриятларда аерым китап булып дөнья күргән проза әсәрләрен әнә шуңа күрә без аеруча зур өметләр белән кулга алабыз.

Марат Әмирханов—үткән елларда безне “Гөлнәзирә”, “Дөя муены” һәм башка повестьлары белән сөендергән язучы. Аның соңгы елларда иҗат ителгән

Марат Әмирханов. Тәкъдир.–Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2003, –207 б.

"Тәкъдир" романы "Казан утлары" журналында басылып чыккач, кызыклы фикерләр уяткан иде. Менә хәзер шул роман Татарстан китап нәшриятында матур гына бизәлештә дөнья күрде.

Әсәр роман дип аталса да күләм ягыннан артык калын түгел—13 нәшер-хисап табагын тәшкил итә. Килешегез: бүгенге су буе романнар белән чагыштырганда бу инде "түзәрлек".

Хәзер кыскача гына романның эчтәлеге белән танышып үтик.

Студент чагында танышып өйләнешкән Мансур белән Җәмилә Корбаш дигән бистә мәктәбендә укыта башлый. Әсәр геройлары тормышы белән яшәп без җитмешенче еллар мәктәбенең типик күренешләре белән очрашабыз. Биредә татар теленең кысыла баруы да, яңа алым дигән булып техник чаралар белән артык мавыгу да, авыл укытучыларының урындагы эреле-ваклы җитәкчеләр тарафыннан кирәксә дә кирәкмәсә дә төрле эшләргә тартылуы да, укытучылар арасында булгалап тора торган гаугалар да—барысы да бар. Романның бу битләрен укыганда без авторның үзенең дә электә педагог булуына ышанабыз, ул мәктәп тормышын, укытучы дөньясын эчтән дә, тыштан да нык белеп, анлап, кичереп яза.

Төп геройның мәктәпкә килү белән балаларга белем бирүдә генә тукталып калмыйча, аларны яхшы кеше дә итәргә тырышуы—мисал өчен, мәктәптә тәмәкегә каршы көрәш башлап җибәрүе—күнелгә хуш килә. Бу унайдан Муса исемле яшүсмер һәм аның тол калган әнисенең язмышы да дулкынландыра, истә кала. Коллективтагы карт кызларга бәйле күренешләр дә Мансурның холык-табигатен ачуда уңышлы роль уйный, тиешле тәэсир тудыра.

Романның сюжеты алга таба үсә барган саен яшь гаилә өстендә фаҗига болыты куера—Җәмиләдә яман авыру билгеләре табыла... Күп кешегә хас булганча, яшь хатынның башта моңа исе дә китми, ә аннары—эшнең ни дәрәҗәдә җитди икәнен аңлап алгач—Җәмиләнең эчке дөньясында туган үтә киеренке хәлне, олы фаҗигане, аның үзен кая куярга да белмичә газаплануын тасвирлаганда автор каләм иясе буларак кына түгел, ә олы фаҗига белән күзгә-күз очрашкан нечкә күңелле кеше буларак та укучы зиһенен һәм игътибарын билэп, аны үзеннән аермыйча алып бара.

Мансурның шәхсән үз юлына да уңышсызлыклар килеп чыга: кафедра җитәкчесенең гаебе белән ул диссертациясен яклый алмый, мәктәптә дә өлкән сыйныфларны урысча укыта башлыйлар... Безнең герой үзенең яраткан эшен калдырып журналистикага күчәргә мәҗбүр... Җәмилә исә операциягә керергә тиеш... Аның бер күкрәген кисеп алалар. Хатын-кыз өчен бик зур тетрәнү булган бу вакыйганы тасвирлаган битләр һәм әлеге хәлнең ир-атка тәэсире—аеруча зур тәэсир көче белән язылган.

Ул арада гаиләнең бердәнбер һәм сөекле баласы—кызлары Ләйсән үлеп китә. Яшәү газапка әверелә, алар хәтта икесе бергә дөнья белән хушлашырга да уйлый—бу адымнан дуслары гына саклап кала.

Әмма ахыр чиктә яман авыру Җәмиләне барыбер җиңә... Мансур әсәр ахырында ялгызы кала...

Роман менә шундый фаҗигале аһәңнәр белән тәмамлана... Кеше яраткан хатынын һәм газиз баласын югалтып, Җир йөзендә бер үзе, бер ялгызы торып кала... Ләкин автор тормыш чынбарлыгына хыянәт итми, адәм балаларына салынган яшәү көченең күнел төпкелләрендә көйрәп яткан күмерләренә ул өмет тулы күзләр белән бага: вафат булган Җәмиләнең сеңлесе Рәхиләнең назлы һәм кешелекле йөрәге аша җылытмакчы була дөнья Мансурны.

Романның соңгы битләрен япкач күңелдәге тирән монсулык аша бер зур һәм җитди сорау калка:

—Әсәр белән танышу безгә нәрсә бирде? Ул безнең рухыбызны ни дәрәҗәдә баетты?

"Тәкъдир" романы үз битләрендә җитмешенче елларның тормышын гына түгел, ә шул чорда тәкъдир куйган сынауларны уза-уза, намусларын пычратмыйча яшәргә омтылган шәхесләрне сурәтли. Әсәрнең төп каһарманнары булган Мансур белән Җәмилә—иң беренче чиратта эшчән һәм намуслы гаиләдә үскән авыл балалары итеп бирелә. Язучы аларның туып-үскән якларын да шигъри чагыштырулар аша сурәтли. Туган өйгә кайту бәхете романда болай бирелә: "Мансурның күңеленә балачакны хәтерләтүче ниндидер саф, аһәнле, моңлы тавыш инде. Сихри җылы, йомшак, ләззәтле тавыш. Ул аның җанын, тәнен, рухын берьюлы биләп алды. Бишектә тибрәлгәндәй тибрәлде. Өнме бу, төшме, йоклыймы ул, уяумы? Ләкин ничек булса да Мансур бу халәтнең озак, бик озак дәвам итүен теләде."

Төп геройның намуслы булып үсүен автор романда тагын бер яктан сипләп, нигезләп куя—ул затлы нәселдән икән:

"—Һы, кара син аны, мулла нәселеннән икәнен оныткан икән шельма малай. Бабаң Әмирҗан да бик гыйлем кеше ие. Искечәне дә, яңачаны да су күек эчә ие. Әткәсе, минем каенатам Әкрам картның туганы Әхмәтҗан абдый сәүит вакытында да хәдрәт булып торды әле. Халык бик

ярата иде. Себергә сөреп кенә башын ашадылар..." Геройның әнисе Мәдинә апа менә шундый сүзләр белән үз улына нәселен искә төшерә. Җәмиләнең әтисе Нурулла абзый исә әсәрдә елдамлык, хәрәкәтчән эшмәкәрлек мисалы итеп бирелә.

Ләкин роман каһарманнарына бүтән төрле затлар белән очрашырга, эш итәргә туры килә. Менә мәктәптәге рус теле укытучысы Фирая Сабировна:

—Бөек рус телен, Пушкин, Маяковскийлар телен мин соңгы сулышыма чаклы пропагандалаячакмын!

Педсовет утырышында әйтелгән шушы кыска гына бер җөмләдә никадәр ышаныч, пафос, усаллык, ярсу һәм... һәм—ялагайлык! Олы ялагайлык, чөнки житмешенче елларда яшәүче бу ханым илдәге көчнең кемнәр кулында икәнен бик яхшы белә. Һәрбер тармак буенча (бигрәк тә идеологиядә) орден-медальләрнең дә иң башта кемнәр түшенә менеп кунаклавын бик яхшы аңлый. Ләкин менә бүтән милләтләрнең дә Тукайлар, Райнислар, Байроннар кебек бөек шагыйрьләр тудыра һәм үстерә алуын ул ни өчендер "оныта". Бер генә телне яшәтеп калдырырга теләүнең "табигатьтә бары тик бер генә агач калсын" дигән омтылыш сыман ук ахмак идея булуын ул чагында (һәм әле хәзер дә!) бик күп "акыллы" кешеләр оныттылар шул!

Югары уку йортына керә алмавы аркасында мәктәпне гаепләп үпкә хаты язган Гүзәл исемле кыз сәбәпче булган әлеге вакыйга безнең бүгенгебез өчен дә үтә актуаль түгелмени?! Югары белем бирү үз телебездә булмагач бүген дә бик күп әти-әниләр үз балаларын татарча укытудан баш тарта бит! Әле һаман шушы ук "таш кыя"га килеп төртелә бит милләтебез корабы!

Шул унайдан романда бирелгән мәгариф министры образы да кызыклы. Ул урыннарда булганда, укытучылар белән очрашкан чакларында үзен бик гади, чын кешеләрчә тота, алдынгы карашларны чын күңелдән яклый, җирле түрәләрне тәнкыйтьли, чибәр-чибәр укытучы кызлар белән шәхси "дуслык" та урнаштыра, милли мәсьәләдә дә "үзебезнеке" булып күренергә тырыша... Әмма шул ук вакытта бу министр әфәнде әкрен-әкрен рус мәктәпләрен, сыйныфларын да күбәйтә бара. Башкаладагы зур түрәнең менә шушындый "ике яклы пычак" булуы романда бик реаль рәвештә һәм ышандырырлык итеп тасвирлана.

Тагын бер түрә, өлкә комитетында бүлек мөдире урынын биләүче Сафа дигән тип, элеккеге танышы Мансурга болай ди:

—Мансур иптәш, без агай-энеләр белән ресторанда утырмыйбыз. Бу—обком! Монда фәкать эш турында гына сөйләшәләр. Сез дә эш буенча чакырулы...

Сафа бераздан болай дип тә дәвам итә:

—Мөштәри, Камай ише милләтчеләргә без партия матбугатында урын бирә алмыйбыз!

Совет империясендә урнаштырылган әнә шундый сәяси һәм рухи климат романдагы һәрбер геройның яшәешендә чагыла. Төп каһарман Мансурныкында бигрәк тә. Яшүсмер вакытта, күрше авылга йөреп укыганда ук, аның куркып калуы әсәрдә хәтта аллегорик мәгънә дә ала. Аның бөтен рухын әлеге кышкы кичтә очраган өрәкләр басып, изеп тора сыман. Чыннан да, безнең барыбызны да кечкенәдән үк "сүзне тыңламасаң, тәртипле булмасаң—урыс апкитәр!"— дип өйрәттеләр бит! Яшүсмернең башта авылда ук куркып калуы, аннары яраткан эшенә—туган телен укытырга керешкәч—тулы бер система тарафыннан кысылуы, диссертациясенең дә яклана алмавы, шәхси тормышындагы бүтән фаҗигаләр—боларның барысы да романда тирән мәгънә ала. Чын иреклe ил, ирекле яшәү, туган теленнең ирекле халәте хакында янәдән-янә уйландыра.

Ә шулай да бу романдагы иң зур мәгънәгә ия аллегорик образ ул—Тума кош. Ягъни житлекмичә туган бала символы. Тума кош романның беренче битләрендә үк күренә һәм әсәрне укыганда ара-тирә искә төшә-төшә, үзенчә бер мәгънәви фон ясап, ахыргача озата бара... Әсәрнең иң соңында мондый җөмлә бар: "Тагын алты айдан баш очындагы Тума кошның канатлары киселеп төште."

Романның беренче битләрендә Зур Авыл мулласы әйткән менә мондый сүзләр дә бар иде бит әле:

—Тума үлмәсә, илгә бәла кала!

Шулай итеп романда сурәтләнгән житмешенче еллар тормышы һәм әсәрдә геройларны баштан алып ахыргача озата барган Тума кош—житлекми туган бала—образы сәнгати һәм фәлсәфи яктан тәгәлләнү таба. "Житлеккән социализм" белән "житлекмәгән бала" бергә килеп ялгана. Һәм менә шушы тоташу, мәгънәви ялгану фонында геройлар башыннан кичкән фаҗигаләр...

Ләкин шуның белән бергә Тума кош унаеннан күңелдә бераз гына шикләнү дә бар: романга бик уңышлы кереп урнашуга карамастан укучы аны аңлап, төшенеп житәрме икән? Автор, билгеле, бу идеяны бәләкәй кыз Ләйсән язмышы белән дә көчәйтә һәм ассызыклый сызыклавын—ул да елан елында һәм житлекмичә туа, шулай ук иртә вафат була... Боларга да карамастан авторга бәлки әлеге мәгънәне

тагын да ныграк ачу юнәлешендә тагын бер-ике киная кирәк булгандыр диясе килә.

Минемчә, "Тәкъдир" романының мәгънәви яктан тирән һәм актуаль эчтәлеккә ия икәнлеген раслау белән бергә, шулай ук аны сәнгати яктан тагын да камилрәк итүдә файдаланып бетерелмәгән урыннар калган әле.

Романның беренче бүлеге сугыш башланган елның печән өстенә, печән өмәсенә багышланган. Гәрчә бу Җәмиләнең туган елы һәм автор алган идеяга булыша торган елан елы булса да әйтмичә кала алмыйбыз: ул елның печән өмәсе безнең әсәрләрдә йөзләгән мәртәбә язылды бит инде! Җәмиләнең елан елында һәм житлекмичә тууы минемчә тәэсирлерәк итеп, бүтәнчәрәк бирелергә тиеш иде романда.

Шулай ук төп герой Мансурның үз диссертациясенең яклана алмаячагын белгәч, житәкчесенә телефоннан шылтыратып кына мыскыллавы ничектер бу образның романда без белгән холыктабигатенә ят сыман тоела. Аннары, гомумән, фәнни эш бу кеше өчен артык мөһим дә түгел бит әле. Без Мансурның яшәешендә диссертациягә бәйле уйларны, фикерләрне, проблемаларны бөтенләй күрмибез дә диярлек.

Романны укыганда бик тә тешкә тия торган тагын бер нәрсә бар, ул да булса әсәр тукымасына һич тә ябышмый торган публицистик стильнең килеп керүе. Китапның 17 битендә мондый сүзләр урын ала: "Шулай булмыйча, нинди иләк аша узды бит. Бик нык сайладылар. Гимнастика белән шәһәр кызларыннан күпкә соң шөгыльләнә башлаган Җәмилә өчен бу киртәне үтү җиңел булмады. Көч күп сарыф итүне сорый торган снарядларда ул үзен иркен хис итә. Бу яктан аны уздыручы юк. Ә менә сыгылмалылыкта башкалардан калыша. Шуңа күрә әлеге аерманы бетерү, һич югы, кимерү өчен һәр мөмкинлектән файдаланырга тырыша... Спортка кагылышсыз каршылыклар да килеп чыкты."

Алга таба китсәк 37 биттәге: "Мирзанур Мостафин алтмышынчы еллар дулкынында күтәрелгән демократик карашлы кеше..."— дип башланып киткән абзац та нәкъ менә шушы коры рухта бара һәм китап битенең яртысын алып тора! Мондый урыннар китапның беренче яртысында аеруча күп очрый һәм кәефне кыра.

Ә бит романда безне шигърилеге, тәэсир көче белән соландырган менә мондый урыннар да бар. "Тел өсте баллы булса да, тел асты тозлы икән апабызның" (38 бит), "Бәхетленең көймәсе корыдан йөри" (57 бит), "Төртмә кода, үзем белөм, үлсәм дә хак сүземне әйтеп үләм" (62 бит), "Язбикә үзе дә хатынкызга Зөһрә сылуның затлы шәлен яба. Хатын-кыз күзгә күренеп нурлана, мөлаемлана, чибәрләнә, атлап йөрүләре үк үзгәрә. Бөреле агачтай эче-тышы мәхәббәт суты белән тула..." (92 бит), "Җәмилә, җил җилфердәткән ефәк шәл шикелле, янә иренә уралды" (135 бит) һ. б.

Менә шушындый чын әдәби тел белән яза алган авторның әсәренә алдарак күреп киткән җөмләләр ни өчен килеп кергән микән соң?

Күрәсең мондый очраклар соңгы елларда безнең прозада шактый еш күзәтелә торган бер тенденциянең типик чагылышы булып тора. Беренче чиратта, әлбәттә, авторларның үз-үзләренә, үз иҗатларына таләпчәнлеге кимү дип әйтергә туры килә. Аннары, әдәби жанрларның үзара кушылып китүе турында матбугатта күренгәләп ала торган фикерләр дә кайсыбер каләм ияләренә аклану өчен җирлек, нигез бирә кебек. Озынозын шигырьләрне "поэма" дип билгеләп редакцияләргә алып килү дә әнә шул тенденциянең начар бер җимеше шикелле. Роман һәм повестьларда исә бу "авыру" сюжет җебенең ныклы булмавы, эчтәлекнең көпшәклеге һәм, нәтиҗәдә, әсәрләрдә күләмнең бүселүе, башка әдәби җитешсезлекләр булып чагыла.

Марат Әмирхановның без сүз алып барган "Тәкъдир" романында әлеге җитешсезлекләр күп күренә дип әйтә алмыйм, әмма вакыйгалар чылбырын төзегрәк һәм киеренкерәк итү, шул максаттан диссертация җитәкчесе Габбас Ярмиевич кебек кайсыбер кирәкмәгән персонажлардан арыну турында ныклап торып уйларга җирлек бар.

Ә роман хәтле роман турындагы бу кыскача сүзгә йомгак ясап әйткәндә, ул үткән гасырның җитмешенче еллары тормышының социаль һәм рухи-психологик панорамасын җанландыруда җитди бер адым булып тора. Марат Әмирханов каләменең "роман" дип аталган җитди жанрда тәҗрибәсе һаман арта баруын, эпик әсәрләр иҗат итүдә торган саен уңышлырак адымнар ясавын раслый.

Ә күңел... Ә күңел дигәнең исә безнең проза жанрында Әмирхан Еникиләрнеке, Мөхәммәт Мәһдиевларныкы шикелле онытылып, сәнгать көче белән чынчыннан тылсымланып укырдай әсәрләр көтә. Без биредә сүз алып барган Марат әфәнде Әмирхановның үз иҗаты белән әлеге әдипләр янәшәсенә басарга бөтен мөмкинлеге дә бар.

**Мансур ВӘЛИ-БАРҖЫЛЫ**





# 56—ВАКЫЙГА (ВАКЫЙГА) СҮРӘСЕ

*(Вакыйга сүрәсе 96 аятьтән тора. Мәккәдә иңгән).*

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Ул вакыйга *(Кыямәт)* вакытында **(2)** *(Кыямәт булмаячак дип)* беркем дә ялганлый алмас. **(3)** Ул чакта кемдер бичара, кемдер абруйлы булыр. **(4)** Җир дәһшәтле тетрәнү белән кубарылыр. **(5)** Таулар җимерелеп төшәр, **(6)** таралып, тузан хәленә килер. **(7)** Һәм сез дә өч катламга аерылырсыз *(шәһидләр, фәрештәләр, пәйгамбәрләр; гади тәкъвалар; җәһәннәмгә керүче гөнаһкярлар).* **(8)** Уң яктагылар никадәр бәхетле булыр. **(9)** Сулдагылар никадәр бәхетсез булыр. **(10)** *(Игелек кылуда)* алда барганнар алдан әҗерен алыр. **(11, 12)** Менә шулар инде Нәгыйм җәннәтләрендә *(Аллаһка)* иң якын торучылар булыр. **(13)** Аларның күбесе әүвалге өммәтләрдән булыр. **(14)** Беразы–соңгыларыннан. **(15, 16)** Җәүһәрләр белән эшләнгән канәфиләрдә кара-каршы, кырын ятып *(ләззәт алырлар).* **(17)** Яннарында *(хезмәт өчен)* үлемсез яшь егетләр булыр. **(18)** Кулларында мәңге корымас чишмәдән кувшиннар, тустаганнар, касәләргә тутырып алган **(19)** эчемлек булыр. Ул эчемлектән баш авыртмый, ул хәлне дә *(акылны да)* алмый. **(20)** Аларга үзләре теләгән җимешләр, **(21)** җаннары теләгән кош итләре, **(22, 23)** күз алмасы кебек сакланган энҗедәй, зур кара күзле хур кызлары **(24)** игелекләренә әҗер буларак бирелер. **(25)** Анда буш сүзләр сөйләнмәс, гөнаһ вәсвәсәсенә тартылу булмас. **(26)** Бары тик: сәлам сезгә *(иминлек телим)* кебек сүзләр генә ишетелер. **(27)** Уңдагылар никадәр бәхетле булачак. **(28)** Чәнечкесез, баллы чия агачлары, **(29)** җимешләр белән каплаган банан агачларыннан **(30)** төшкән күләгәләр, **(31)** челтерәп агучы чишмәләр, **(32, 33)** бетмәс-төкәнмәс һәм ашарга тыелмаган җиләк-җимешләр арасында, **(34)** кабартылган түшәкләр өстендә истирахәт кылырлар. **(35)** Хактыр ки, без хур кызларын алар өчен махсус булдырдык. **(36, 37)** Аларны саф кызлар итеп, ирләрен сөя торган итеп яраттык. **(38)** Менә бу әҗер–уңдагы мөэминнәрнең әҗере. **(39)** Боларның байтагы борынгыда яшәгән өммәтләрдәндер. **(40)** Байтагы исә соң заманнарда яшәгәннәрдән.

**41.** Сулдагыларның язмышын башкаларга күрсәтмәсен! Коточкыч язмыш! **(42)** Кайнар ялкын, кайнар су эчендә, **(43, 44)** җиләслеге һәм рәхәтлеге булмаган капкара төтеннән торган энгердә интегерләр. **(45)** Чөнки алар моннан алда *(дөньяда)* кәеф-сафа корып, типтереп яшәде. **(46)** Үҗәт рәвештә зур гөнаһлар кылып яшәгәндә **(47)** әйтәләр иде:

–Без үлгәнебездән соң, туфракка әверелеп, сөякләребез черек өемгә әйләнгәннән соң яңадан терелү булмас,–диләр иде.–**(48)** Бездән элек үлгән бабаларыбыз да терелчәкме? *(Без моңа ышанмыйбыз.)* **(49)** Әйт син аларга:

–Әүвәл үлгәннәр дә соңрак үлгәннәр дә *(терелчәк),*–диген. **(50)**–Билгеләнгән көннен

---

Журнал өчен **Рабит БАТУЛЛА** әзерләде.

билгеләнгән сәгатендә һичшиксез, барыгыз да тупланачаксыз. **(51)** Ахырда сез, хәттин ашканнар, ялганчылар, **(52)** әлбәттә бер агачтан, зәкъкум агачыннан *(агу, зәһәр)* ашаячаксыз. **(53)** Ашказаннарыгыз шуның *(агу)* белән тулачак. **(54)** Өстәвенә кайнап торган су эчәчәксез. **(55)** Сусаган дөяләр ничек суга йотыкса, сез дә шулай кибегерсез, кайнар су эчәргә мәҗбүр булырсыз. **(56)** Менә җәза Көнендә аларга биреләчәк «сый» шул булыр. **(57)** Сезне Без яралттык. Шулай булгач нигә сез *(җан алып, җан иңдерүебезгә дә)* ышанмыйсыз? **(58)** Алайса, әйтеп бирегез: *(хатыннарыгызның аналыгына)* агызылган мәни–ул нәрсә? **(59)** Аны сез барлыкка китердегезме? Әллә Без ясаган нәрсәме ул? **(60)** Үлемегезне сезгә Без тәкъдир иттек. Һәм Без җиңелә торганнардан түгел. **(61)** Сезнең урынга башка бер токымны китерергә вә сезнең хәбәрегез булмаган башка галәмдә *(Кыямәттә)* яңадан терелтергә дип *(сезгә әҗәл билгеләдек)*. **(62)** Хактыр ки, сез беренче яралтылышны белдегез инде. Уйлап гыйбрәт-сабак алсагыз, яхшы булыр иде. **(63)** Хәзер инде сез Миңа чәчү орлыгының асылын аңлатып бирегез. **(64)** Аны *(игенне)* сез үстерәсезме, әллә игенне Без үстерәбезме? **(65)** Ихтыяр итсәк, игеннәрегезне *(орлыксыз)* коп-коры салам-кибәк чүбенә әверелдерер идек тә сез шашып калыр идегез. **(66)** Һәм:

–Аһ, без бурычка баттык. **(67)** Турысын гына әйткәндә, без хәер сорашырга калдык,–дип әйтер идегез.

**68.** Эчә торган суыгыз турында ни әйтерсез? **(69)** Болыттан аны сез яудырасызмы? Әллә без яудырабызмы? **(70)** Ихтыяр итсәк, ул яңгырны Без *(эчмәслек дәрәҗәдә)* тозлы итәр идек. Сез *(Аллаһка)* шөкер итәргә тиеш түгелме икән? **(71)** Тагын сез Миңа әйтегез: файдалана торган утны ясап, **(72)** утынны сез үстердегезме, әллә аларны яралтучы Безме? **(73)** Без аны бер гыйбрәт булсын дип, вә чүлдән килеп киткәннәргә *(юлдагыларга)* файда булсын, дип яралттык. **(74)** Шулай булгач, бөек Раббыгызның исемен олылагыз.

**75.** Хәер, йолдызларның батып сүнгәне илә әйтәмен ки, **(76)** әгәр сез белсәгез: чыннан да, бу бер бөек ант–**(77, 78)** Ләүхел Мәхфүздә кадерләп саклана торган Китап–изге Коръәндер. **(79)** Аңа бары тик пакь, тәһарәтле кеше генә кагылырга хаклы. **(80)** Ул галәмнәрнең Раббысыннан иңдерелде. **(81)** Хәзер инде сез шул *(изге)* сүзне кимсетергә уйлыйсызмы? **(82)** Коръәндәгеләрне ялганга чыгарасыз. Аллаһ биргән ризыкка шөкер итүегез шул булдымы?

**83.** *(Үлем түшәгендәге кешенең)* җаны бугазына җиткәч, **(84)** сез аңа карап торасыз. **(85)** Без аңа сездән дә якын торабыз. Әмма сез күрмисез генә. **(86)** Әгәр дә сез *(Аллаһның)* җәзасыннан азат икәнсез, **(87)** әгәр сез хаклы икән, *(җан бирүченең)* җанын кире кайтарыгыз. **(88)** Ләкин *(җан биргән кеше Аллаһка)* якын икән, **(89)** аңа рәхәтлек, татлы ризык вә Нәгыйм җәннәтләре бар.

**90.** Әгәр дә ул уң яктагылардан икән, **(91)**

–Әй, уң яктагы кеше, сиңа сәлам-иминлек булсын!–дип әйтербез.

**92.** Әмма ялганчылардан, хәттин ашканнардан була икән, **(93)** менә аңа да кайнар судан «сый» булыр. **(94)** Һәм аның өлеше җәһәннәм. **(95)** Шик юк ки, бу кырыс чынбарлык. **(96)** Шулай булгач, галәмнәрнең бөек Раббысы–Аллаһның исемен мактап, тәсбих әйтегез.

## 57—ХӘДИД (ТИМЕР) СҮРӘСЕ

*(Хәдид сүрәсе 29 аятьтән тора. Хәдид–тимер дигән сүз. Мәдинәдә иңгән).*

Бисмилләһир-рахмәнир- рахим.

**1.** Күкләрдә вә Җирдә булган барчасы Аллаһка тәсбих әйтә Аллаһ–җиңелү белмәс кодрәт һәм хикмәт иясе. **(2)** Күкләрдәге, Җирдәге бөтен милек-байлык Аныкы. Җан биргән дә, җан алган да–Ул. Аның бар нәрсәгә дә кодрәте җитә **(3)** Ул беренчедер, соңгысыдыр, ул кылганнары белән күренә дә, Үзе яшерен да Ул барысын да белеп торучы. **(4)** Ул күкләрне вә Җирне алты көндә *(дәвердә)* барлыкка китерде. Соңыннан Гарешкә урнашып, хөкемдарлык кыла башлады. Җирдән ни чыга, Җиргә ни керә

Күктән ни иңә, Күккә ни менә—барысын да Ул белеп тора. Сез кайда гына булсагыз да, Аллаһ сезнең янда булыр. Аллаһ гамәлләрегезне күреп тора. **(5)** Күкләрнең вә Җирнең милке-байлыгы Аныкы. Бөтен эшләр бары тик Аның хозурына кайтыр. **(6)** Төнне көнгә катыштырыр, көнне төнгә катыштырыр. Күңелегездә ни бар—Ул шуны белеп торыр.

**7.** Аллаһка вә аның Рәсүленә иман китерегез. Мираска калдырылган малларыгызны *(Аллаһ юлында)* сарыф итегез *(хәер-садака-зәкят бирегез)*. Иман китереп, *(Аллаһ ризалыгы өчен мал)* сарыф иткән кешеләргә бөек әҗер хәзерләнгән.

**8.** Пәйгамбәр сезне: Раббыгызга иман китерегез, дип үгетләгәндә, ни өчен Аллаһка баш ормадыгыз? Гәрчә аңа сүз бирдегез. Әгәр Аңа инаначак булсагыз.

**9.** Сезне караңгылыктан яктылыкка алып чыгар өчен, илчесенә ап-ачык аятьләр иңдергән Аллаһ булыр. Шик юктыр ки, Аллаһ сезгә бик тә мәрхәмәтле һәм шәфкатьле.

**10.** Сезгә ни булды, и, кешеләр! Аллаһ юлында чыгымнар тотмыйсыз. Гәрчә күкләр вә Җир—Аллаһның мирасы. *(Кяферләрне)* җиңеп, *(Мәккәне)* алганга кадәр *(дин юлында мал)* сарыф иткән һәм сугышкан кеше белән җиңүдән соң сарыф итеп, сугышкан кеше тиң булмас. Алдагыларының дәрәҗәсе соңгыларыныкыннан күпкә өстен. Шуңа да карамастан, Аллаһ һәр икесенә дә бөек әҗер вәгъдә итә. Сезнең гамәлләрегез Аллаһка мәгълүм. **(11)** Кем дә кем Аллаһка *(игелекле гамәлләрен)* бурычка биреп тора *(ягъни, савап өчен игелек кыла)* Аллаһ аңа кат-кат нигъмәт бирер һәм аның өчен бик тә мөһим әҗер булыр.

*(«Бурыч» сүзен болай да аңлатучылар бар. Бер кеше икенчесенә бурыч бирә икән, ул аңа рибасыз (процентсыз) бирергә тиеш. Бурычны биргән күләмнән арттырып алу—гөнаһ. Рибасыз бурычка биреп тору—Аллаһ ризалыгын казану, дигән сүз.)*

**12.** Кыямәт көнендә син мөэмин ирләр белән мөэминә хатыннарны күрерсең. Аларның алдыннан да, уңыннан да *(дөньяда кылган игелекләренең)* нурлары яктыртып барыр.

—Бүген сезгә сөенче! Арыкларыннан чишмәләр агып торучы җәннәтләргә керерсез. Сез анда мәңгегә калырсыз,—дип чакырырлар. Бөек морадка ирешү шушы булыр.

**13.** Монафикъ ирләр белән монафикъ хатыннар мөэминнәргә:

—Безне көтеп торыгыз, ашыкмагыз, яктылыгыгыздан ичмасам бер нур алып калыйк,—дип ялвардылар. Аларга:

—Узганыгызга кайтып, яктылык эзләгез,—дип әйтерләр. Ниһаять, алар арасында капкалы койма барлыкка килер. Ул койманың бер ягында Сәгадәт, икенчесендә газап булыр.

**14.** Монафикълар аларга:

—Без дә бит сезнең белән бергә яшәдек, *(нигә безне ташлап китәсез)*?—дип әйтерләр.

—Әлбәттә, бергә яшәдек, ләкин сез үз башыгызны үзегез бәлагә тыктыгыз. *(Мөселманнарны харап итәргә)* форсат көттегез. *(Ислам дине хакмы, ялганмы дип)* икеләнеп, шикләнеп калдыгыз. Шул шикләнүләрегез сезне төп башына утыртты. Вәсвәсәләр сезне аздырды, Аллаһ юлыннан яздырды. Ниһаять, сезне Аллаһның әмере килеп тотты.

**15.** Бүген инде мөселманнардан да, инкарьчылардан да фидия кабул ителмәс. Барасы җирегез—ут. Сезгә шул хас. Коточкыч җир ул—барасы җирегез.

**16.** Иман китергән кешеләрнең Аллаһны вә Аннан иңгән Коръәнне зикер итеп, күңелләренең мәхәббәт белән йомшарган заман килде түгелме? Әүвәл үзләренә Китап бирелеп тә, байтак вакытлар узып, күңелләре *(бозыклык, тәкәбберлек белән)* каралып беткән кяферләргә охшамасыннар иде алар. Аларның байтагы фасикъ адәмнәр.

**17.** Шул хакыйкатьне белеп торыгыз, үлеп беткән туфракка Аллаһ җан өрә. Хактыр ки, Без, акылыгызга барып җитсен дип, аятьләрне ачык итеп иңдердек.

**18.** Хактыр ки, садака биргән ирләр белән садака биргән хатыннар вә Аллаһка чын күңелдән бурыч *(гыйбадәт, хәер)* биргәннәргә кат-кат саваплар бирелер. Алар өчен бик тә абруйлы тагын башка әҗер дә булыр.

**19.** Аллаһка вә аның пәйгамбәрләренә иман китергән бәндәләр–алар үзе дә сүзе дә тугры булганнар, Аллаһ хозурында шаһитлек кылганнар. Аларның әҗере дә нурлары да булыр. Аятьләребезне ялганга чыгарган имансызлар җәһәннәм әһелләре булыр.

**20.** Шуны белеп торыгыз ки, дөнья тормышы ул бары тик уен гына, күңел ачу, зиннәтләр-бизәкләр эчендә типтерү, арттыра-арттыра бер-береңне үтереп мактау-мактанышу, тагын байлык һәм күп балалы булырга тырышу кебек мәшәкатьләрдән тора. Нәкъ менә яңгыр кебек инде. Ул игенчеләрнең һушына китә *(яңгыр–сөенеч)*. Соңыннан иген-үлән корый, сап-сары кыр була. Ахырда кибәк-чүп булып кала. Ахирәттә исә хәтәр газаплар бар. Анда Аллаһның ярлыкавы да, ризалыгы да булыр. Дөнья тормышы тиз уза торган, алдавыч кына, башка түгел.

**21.** Раббыгызның ярлыкавын казанырга тырышыгыз. Аллаһка вә пәйгамбәрләренә инанган кешеләр өчен хәзерләнгән җәннәткә керергә ашыгыгыз. Ул җәннәт Күк белән Җир мәйданы чаклы киң. Аллаһның Сәгадәте шулдыр. Ул аны үзе ихтыяр иткән кешесенә бирер. Хакыйкатән, Аллаһ–бөек, чиксез юмарт һәм мәрхәмәтле.

**22.** Без бар итмәстән алда, Китапта язылмаган килеш, Җир йөзенә һәм сезнең башыгызга һичбер кайгы килмәс. Бу эшләр безгә бер дә кыен түгел.

**23.** Кулларыннан ычкынган *(малга, дан)*га кайгырмасыннар, Аллаһ биргән нигъмәтләр *(казанган байлыклары)* белән мактанмасыннар, дип язып куеп, алдан хәбәр итәбез, кисәтәбез. Аллаһ үз-үзләрен генә сөйгән тәкәббер кешеләрне хупламый. **(24)** Алар үзләре саран һәм башкаларга да саран булырга кушалар. *(Аллаһ юлында хәер-садәка-зәкят, мәчет корырга акча бирмәгән сараннар.)* Кем *(Аллаһ юлында зәкят бирүдән)* баш тартса, *(хафага урын юк)* Аллаһ үзе бай, бернигә дә мохтаҗ түгел, мактауга лаек.

**25.** Хактыр ки, Без пәйгамбәрләребезне ачык дәлилләр белән күндердек вә инсаннар гаделлек урнаштырсын дип, Китап белән бергә *(гаделлек)* бизмәнен дә индердек. Без тимерне дә индердек, чөнки анда *(сугышыр өчен)* хәтәр куәт бар һәм ул *(тыныч хезмәттә)* инсаннарга файдалы. Бу–Аллаһның үзен күрмәгән килеш ышанып, Аның диненә вә пәйгамбәрләренә кешегә күрсәтмичә генә ярдәм иткәннәрне ачыклау һәм сынау өчен шулай эшләнде. Шик юк ки, Аллаһ–куәт иясе, җиңелү белмәс өстен.

**26.** Хактыр ки, Нухны вә Ибраһимны күндердек, пәйгамбәрлекне дә, Китапны да аларның токымына бирдек. Кайсылары тугры юлны сайлады. Күбесе юлдан язды.

**27.** Соңыннан болар эзеннән бер-бер артлы башка пәйгамбәрләрне күндердек. Мәрьям улы Гайсәне күндердек, аңа Инҗилне бирдек. Аңа ияргәннәрнең күңеленә шәфкать һәм миһербан индердек. Без аларга: руһбанлыкка күчегез, дип боермадык. Ләкин алар *(тормыш мәшәкатьләреннән аерылып, артык дини булып, аскетлыкка, руһбанлыкка, монахлыкка)* үзләре күчте.

Без аларга Аллаһ вә Пәйгамбәр кушканча эш кылырга әмер бирдек. Әмма алар кирәгенчә итагать итмәде. Без дә аларның ихлас иман китергәннәренә генә саваплар бирдек. Аларның күбесе юлдан язды.

**28.** Әй, иманлы кешеләр, Аллаһның җәзасыннан куркыгыз вә пәйгамбәренә ышаныгыз, Аллаһ сезгә кат-кат рәхмәт бирсен һәм сезнең юлыгызны нур белән яктыртсын. Сезне ярлыкасын. Аллаһ–ярлыкаучы, чиксез мәрхәмәтле, кичерүче.

**29.** Китап әһелләре Аллаһның нигъмәтеннән һичбер нәрсә ала алмаячакларын белеп торсыннар. Нигъмәтләрнең барысы да Аллаһ хозурында, ул бары тик Үзе ихтыяр иткәндә, теләгән бәндәсенә генә нигъмәтен бирер. Аллаһ–бөек миһербан иясе.

# 58—МҮҖАДӘЛӘ (БӘХӘС) СҮРӘСЕ

*(Мүҗадәлә сүрәсе 22 аятьтән тора. Мүҗадәлә–бәхәс, сүз көрәштерү.)*

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Ире турында синең белән бәхәсләшеп торган хатынны һәм аның Аллаһка

зарланганын Аллаһ Үзе ишетеп торды. Аллаһ сезнең әңгәмәгезне дә тыңлап торды. Аллаһ ишетеп, белеп торучы.

*(«Хәүлә исемле бер хатын иренең бер теләгән үтәмәде. Ире Самат углы Әүеснең ачуы чыкты, ул хатынына: «Син миңа анамның аркасы кебек»,–диде. Наданлык заманасындагы гарәпләрдә шундый, «Зиһар» дигән бер гадәт бар иде: бу сүзне әйткәч, хатын иренең анасы кебек була, ягъни хатын аерылган хисаплана башлый. Хәүлә Пәйгамбәр янына килеп, иренең шушы гамәлен сөйләп бирде. Пәйгамбәр исә: «Син иреңә харам булдың инде»,–диде. Иреннән аерылырга теләмичә, Хәүлә ялвара башлады: «Минем кечкенә балаларым ятим кала»,–диде. Шуннан соң Пәйгамбәр: «Бу турыда Аллаһтан әмер килмичә, талактан башка һични дә әйтә алмыйм»,–диде. Шуннан соң Хәүлә Аллаһка ялварып дога кыла башлады. Аңа җавап итеп, аятьләр иңде».*

Али Тургут тәфсиреннән.)

**2.** Зиһар кылып, хатынын талак иткәннәрнең хатыннары аларга аналары кебек булмас. Аларның аналары бары тик аларны тудырган хатыннар, *(зиһар ителгән хатын иренең анасы була алмый)*. Шик юк, алар чирканыч сүз әйтә һәм ялган сөйли. Шөбһәсез ки, Аллаһ–гафу итүче, ярлыкаучы. **(3)** Хатынын зиһар белән талак итеп, соңыннан сүзеннән кире кайтырга теләгән ир, хатыны белән якынлык кылганчыга кадәр, бер колын азат итәргә тиеш. Сезгә үгет шул булыр. Аллаһ сезнең кылмышларыгыздан хәбәрдар.

**4.** *(Колы булмаса яки азат итәргә)* мөмкинлеге булмаса, хатынын анасына охшаткан ир хатыны белән якынлык кылмастан, ике ай ураза тотар. Моңа да көче җитмәгән кеше алтмыш фәкыйрьнең тамагын туйдырыр. Бу шартлар Аллаһка вә аның Рәсүленә ихлас ышанырга тиешлегегез өчен. Болар–Аллаһ хөкеме. Кяферләр өчен әче газап бар.

**5.** Аллаһка вә аның Рәсүленә каршы килүчеләр үзләреннән алда җәзаланганнар кебек җәзаланачак. Без аңлаешлы аятьләр иңдердек. Кяферләрне бичара хәлгә калдырырлык газап бар.

**6.** Ул Көнне Аллаһ барыгызны да терелтәчәк вә кылган гамәлләрегез турында хәбәр итәчәк. Аллаһ алар үзләре оныткан гамәлләрен санап барды. Аллаһ–һәрнәрсәнең шаһите.

**7.** Күкләрдә вә Җирдә булганнарның барчасын да Аллаһ белеп торганын күрмисеңмени? Өч кеше сөйләшеп торганда, дүртенчесе Аллаһ булыр. Биш кеше серләшеп торганда, әлбәттә, алтынчысы Аллаһ булыр. Шуннан аз яки күбрәк кеше сөйләшкәндә дә Аллаһ, һичшиксез, алар янында булыр. Ахырда Кыямәт көнендә ул бу турыда хәбәр итәчәк. Хактыр ки, Аллаһ һәрнәрсәне белеп тора.

**8.** Яшерен сөйләшүләрне тыйганнан соң да, астыртын эш йөртүчеләрне күрмисеңмени? Алар гөнаһ эшләү, дошманлык җәтмәсе кору вә Пәйгамбәргә каршы көрәшер өчен яшеренеп, фетнә әзерлиләр. Синең янга килгәч, алар Аллаһ сине сәламләгәннән дә артык сәламлиләр. Үзләре:

–Сөйләгән кәферлекләребез өчен Аллаһ нигә соң безне җәзаламый?–диләр. Җәһәннәм аларга җитәр. Алар шунда керәчәк. Ай-һай, хәтәр дә яман урын ул җәһәннәм.

**9.** Әй, иман китергән адәмнәр! Үзара сөйләшкәндә гөнаһ кылу, дошманлык турында вә Пәйгамбәргә каршы сүзләр әйтмәгез. Игелек һәм пакьлек турында гына сөйләшегез. Аллаһ хозурында җавап бирүдән куркыгыз. **(10)** Яшертен-пошыртын-астыртын сөйләшүләр шайтаннан килә, мөэминнәр арасында гауга чыгарыр өчен. Әмма шайтан Аллаһның әмереннән башка мөэминнәргә һичбер зарар китерә алмас. Мөэминнәр Аллаһка сыенып котылалар.

**11.** Әй, иманлы кешеләр! Мәҗлестә сезгә:

–Урын бирегез,–дисәләр, урын бирегез. Аллаһ сезгә дә *(җәннәттә)* урын бирер.

–Басыгыз,–дисәләр, басыгыз. Аллаһ та иманлыларның, гыйлем ияләренең дәрәҗәсен арттырыр. Аллаһ бөтен кылмышларыгызны белеп тора.

**12.** Әй, иман китергән инсаннар! Пәйгамбәргә яшертен генә берәр нәрсә сөйлисе булсагыз, сөйләшер алдыннан садака бирегез. Бу сезнең өчен тагын да хәерлерәк һәм пакьлек булыр. Бирергә нәрсәгез булмаса, һичшиксез, гөнаһ булмас. Аллаһ–гафу итүче,

чиксез мәрхәмәтле. **(13)** Яшерен әңгәмәгездән алда садака бирергә кыймагансыздыр, бәлки. Аллаһ монысын да гафу итәр. Сез намаз калдырмагыз, зәкят бирегез, Аллаһка вә аның Рәсүленә итагать кылыгыз. Аллаһ кылган гамәлләрегезне төгәл белеп тора.

**14.** Аллаһның ләгънәте төшкән халыкны үзләренә дус иткән бәндәләргә игътибар иттеңме? Алар сезнеке дә түгел, аларныкы да түгел. Антларын бозачакларын алдан ук белгән көенчә алар ант итәләр. **(15)** Алар өчен Аллаһ хәтәр җәза хәзерләп куйган инде. Аларның кылган гамәлләре бик тә яман. **(16)** Антларын калкан итеп тоталар вә шулай итеп, кешеләрне Аллаһ юлыннан яздыралар. Аларны мескен хәлгә төшерә торган газап бар. **(17)** Аларның маллары да, угыллары да Аллаһның газабыннан котылырга ярдәм итә алмас. Алар җәһәннәмгә теркәләчәк һәм шунда мәңгегә калачак. **(18)** Кыямәт көнне аларны Аллаһ терелтер. *(Без саф мөселманбыз дип)* сиңа ант иткәннәре кебек, *(бу ялган анттан файда күрербез дип)* Аллаһ алдында да ант итәчәкләр. Белеп торыгыз ки, чын ялганчылар шулар булыр. (19) Шайтан аларны үз химаясенә алды да, Аллаһны оныттырды. Менә болар, шайтанның гаскәре, шундый теләктәшләреннән тора. Белеп торыгыз, коточкыч һәлакәткә дучар булганнар–шайтан тарафдарлары. **(20)** Аллаһка вә аның Рәсүленә каршы килгәннәр иң түбән җанлылар арасында булыр.

**21.** Аллаһ язды:

–Миндә җиңелмәслек кодрәт бар, Рәсүлләрем дә өстен чыгачак. Шөбһә юктыр ки, Аллаһ–тагын да куәтлерәк җиңүче.

**22.** Аллаһка вә Ахирәт көненә иман китергән бер кавемнең Аллаһка вә аның Рәсүленә каршы килгән кяферләр белән якын дус булганын күрмәссең. Хәтта, алар якын кардәш, ата һәм угыллары булса да. Менә болар күңелләренә иман сеңдергән вә Аллаһтан иңдерелгән рух белән куәтләндерелгән шәхесләр булыр. Аларны арыкларыннан чишмәләр агып ята торган мәңгелек җәннәтләргә урнаштырыр. Менә шулар Аллаһ тарафын тотучылар булыр. Аллаһ алардан разый булыр. Алар да Аллаһтан канәгать калыр. Белеп торыгыз, чынлап котылуга ирешкәннәр, әлбәттә, шулар булыр.

# 59—ХӘШЕР (СӨРЕП КУУ) СҮРӘСЕ

*(Хәшер сүрәсе 24 аятьтән тора. Мәдинәдә иңгән. Хәшер–сөрелү, куып чыгару; бер урынга туплау, җыйнау мәгънәләрендәге сүз. 2-7 нче аятьләрдә яһүд кабиләсе Надир токымын сөреп чыгару турында сөйләнә. Сүзнең беренче мәгънәсендәге исемне алган сүрә.)*

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Күкләрдә һәм Җирдә булганнарның барысы да җиңелү белмәс, хикмәт иясе–Аллаһны мактап тәсбих әйтә

**2.** Китабы булган халыкның иман китермәгәннәрен *(Тәүратлы яһүдләрне)* әүвәлгесендә йортларыннан сөреп чыгарган–Аллаһтыр. Сез аларның сөреләчәген күз алдына да китерә алмый идегез. Алар: кальгаларыбыз безне Аллаһтан саклар, дип өметләнә иде. Әмма Алланың җәзасы аларга көтмәгән яктан килде. Ул аларның йөрәкләренә курку салды. Алар өйләрен үз куллары белән һәм дә мөэминнәрнең кулы белән харап иттеләр. Әй, сез! Башында акылы булганнар, моннан гыйбрәт алыгыз. **(3)** Әгәр дә Аллаһ аларның тәкъдиренә сөреләчәкләрен язып куймаган булса, әлбәттә, аларны дөньяда ук җәзалаган булыр иде. Ахирәттә дә алар өчен җәһәннәм газабы бар. **(4)** Бу *(сөрелеш вә җәзалар)* аларның Аллаһка вә аның Пәйгамбәренә каршы килүләре аркасында булды. Аллаһка каршы килгән кеше белеп торсын, Аллаһның җәзасы бик тә хәтәр булачак.

**5.** Хөрмә агачларының берсен генә кисүегез дә яки кисмичә калдыруыгыз, Аллаһның рөхсәте белән генә булыр. Аллаһ юлдан язганнарны бичара хәлдә калдыру өчен шулай эшли.

**6.** Аллаһ ярдәме илә алардан алган ганимәт маллары Пәйгамбәргә тиеш; чөнки сез ул малны алыр өчен ат менеп, дөягә атланып килмәдегез. Аллаһ пәйгамбәрләрен аерым кешеләрдән өстен кылыр. Аллаһның һәрнәрсәгә кодрәте җитә **(7)** Аллаһ

ярдәмендә яулап алынган илләрдәге байлык–ганимәт Аллаһка, Пәйгамбәргә аның якыннарына, ятимнәргә, юксылларга вә юлда калган юлчыларга булыр. Шулай булгач, бу маллар, бу байлык бары тик байлар арасында гына бүлешер өчен була алмый. Пәйгамбәр сезгә ни бирсә, шуны алыгыз, нәрсәне алырга тыя икән, аны алмагыз. Аллаһның җәзасыннан куркыгыз. Аллаһның җәзасы бик тә хәтәрдер. **(8)** *(Аллаһ биргән бу ганимәт маллары)* йортларыннан куылган вә маллары таланган, Аллаһтан бер нигъмәт вә ризалык өмет иткән, Аллаһның диненә вә Пәйгамбәренә ярдәм иткән фәкыйрь мөһаҗирләргә бирелергә тиеш. Менә алар–тугры юлдагылар. **(9)** Байтактан әүвәл Мәдинәне ватан итеп, ихлас күңелдән иман китергән кешеләр үзләре янына күчеп килгән мөһаҗирләрне якын итеп каршы алырлар, аларга бирелгән мал *(ганимәт)* аркасында *(күпсенеп)* көнләшү хисе тоймаслар. Хәтта үзләре кыен хәлдә *(ач)* булсалар да, алар *(мохтаҗларның, мөһаҗирләрнең)* ихтыяҗын алга куяр. Кем нәфесен *(малга хирыслыгын)* тыя белә, шул морадына ирешкәннәрдән булыр.

**10.** Болардан соң килүчеләр әйтер:

–Раббыбыз, безне һәм бездән элек килеп киткән иманлы кардәшләребезне, зинһар, ярлыка; күңелләребездә иман китергәннәргә каршы һичбер хөсетлек калдырма. Раббыбыз, шик юк ки, Син–чиксез мәрхәмәтле, чиксез рәхмәтле.

**11.** Монафикъларны бер дә күргәнең юкмыни? Китаплы халыкның кяфер булган кардәшләренә әйтteләр:

–Әгәр сез йортыгыздан куылсагыз, шик юк ки, без дә сезнең белән бергә китәчәкбез; сездән башка һичберәүгә дә иярмәбез. Әгәр сугышка керер булсагыз, әлбәттә, ярдәм итәрбез,–дигән сүзләрен ишетмәдеңме? Аллаһ шаһиттер ки, алар, әлбәттә, ялганчы.

**12.** Чыннан да, әгәр алар куылса, монафикълар йорт ташлап, аларга иярмәс. Тегеләре сугышка керсә, ярдәмгә килмәс. Табаннарын ялтыратып, сугыш кырын ташлап качарлар. Ахырда аларның үзләренә дә ярдәм итүче булмас.

**13.** Шунысы көн кебек ачыктыр ки, сездән курку аларның йөрәкләренә кереп урнашкан. Бу курку Аллаһ газабыннан куркуга караганда көчлерәк. Алар–*(Хакыйкатьнең кайсы якта икәнен)* аңламый торган нәсел.

**14.** Алар *(имансызлар)* бердәм булып сезгә каршы сугыша алмаслар; ныгытылган кальгалар артына яки таш диварларга посып кына сугышырлар. Үз араларындагы сугыш каты булыр. Гәрчә алар сиңа бердәм булып күренер, әмма аларның күңелләре аеры-чөере. Алар–акылга утырмаган бер халыктыр. **(15)** Аларның хәле үзләреннән алда гына яшәп-киткән һәм гөнаһларына күрә җәзасын да алган кавемнәрнеке кебек. Аларга хәтәр җәза бар.

**16.** Монафикъларның хәле исә нәкъ шайтанның хәле кебек. Шайтан кешегә:

–Инкарь ит!–диде. Кеше инкарь иткәч:

–Мин сездән ерак торам, чөнки мин галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһтан куркам,–ди. **(17)** Икесенең дә ахыры–мәңгелек ут булыр. Алар анда калачак. Менә бу *(җәһәннәм)*–залимнәрнең җәзасы.

**18.** Әй, иман китергән бәндәләр! Аллаһның җәзасыннан куркыгыз вә һәркем, киләчәк өчен ни хәзерләгәнлеге турында уйлансын. Аллаһның җәзасыннан куркыгыз. Аллаһ сезнең ни кылганыгыздан хәбәрдар. **(19)** Аллаһны оныткан һәм шуның аркасында Аллаһ та аларга *(яхшылыкның)* ни икәнен оныттырган кешеләр кебек булмагыз. Алар–Аллаһ юлыннан язган бәндәләр. **(20)** Җәһәннәмгә кергәннәр белән җәннәткә кергәннәр тиң булмас. Җәннәттәгеләр–морадларына ирешкән мөэминнәр.

**21.** Әгәр дә Без бу Коръәнне тау башына индергән булса идек, ихтимал, Аллаһтан куркудан тетрәп, тау урталай ярылган булыр иде. Бу мисалларны Без кешеләргә сабак булсын дип китерәбез.

**22.** Аллаһның сыйфаты шулдыр ки–Аннан башка олуг кодрәтенә ия зат юк. Күренмәгәннәрне дә, күренгәннәрне дә белеп торучы. Аллаһ–ярлыкаучы, Аллаһ–кичерүче. **(23)** Аллаһның сыйфаты шулдыр ки–Аннан башка олуг кодрәткә ия зат юк. Ул бөтен мөлкәтнең берданбер хуҗасы, кимчелексез, изгедер, иминлек өләшүче, ышаныч бирүче, сәламәтлек иясе. Күзәтеп, иминлек саклап торучы. Җиңелү белмәс. Теләгәнгә юл куючы. Олуглыкта тиңе булмаган. Ана тинләштерелгәннәрнең барча-

сыннан өстен–бер Аллаһ. **(24)** Аллаһ шулдыр ки, Ул *(галәмнәрне)* барлыкка китерүче; яралтучы *(юктан бар итүче)*, хасил иткәннәргә рәвеш *(тәртип, сурәт, система)* бирүче–Аллаһ. Иң матур исемнәр Аллаһта гынадыр. Күкләрдә вә Җирдә булганнарның барчасы Аңа тәсбих әйтә. Ул–һәрвакыт кодрәт һәм хикмәтләр иясе.

*(«Аллаһның үзгәрмәс өч сыйфаты бар. Беренчесе: ибда–иҗат итү, юктан бар ясау, барлыкка китерү. Галәмдә Аллаһтан башка һичбер нәрсә юк иде. Аллаһ галәмне барлыкка китерде. Икенчесе: халикъ итү, бер нәрсәдән башка нәрсә ясау куәсе (сәләте). Җисемне, әйберне, матдәне–галәмнәрне Аллаһ юктан хасил итте. Шул җансыз матдәдән-туфрактан Адәмне ясады. Җенне төтенсез уттан яралтты. Хайваннардан, үсемлекләрдән, ташлардан аермалы буларак, Адәмгә акыл, сүз, фикерләү сәләтләре бирде. Өченчесе: тәдбир. Бу–галәмтабигатьтәге хәрәкәт, сөрешләр белән алдан күреп идарә итү сыйфаты. Хайваннар, киекҗәнлекләр, кош-кортлар, балыклар, бөҗәкләр, үсемлекләр, галәмдәге җисемнәр, җир-коялар эчендәге кодрәтләр белән катгыян тәртиптә идарә итү. Чыннан да, Аллаһ–бөек хөкемдар, җиңелү белмәс кодрәт иясе, ару-талуны белмәс көчкә ия».*

Хәсән Чантай тәфсиреннән.)

# 60—МҮМТӘХИНӘ (ХАТЫН–КЫЗНЫ СЫНАУ) СҮРӘСЕ

*(Мүмтәхинә сүрәсе 13 аятьтән тора. Мәдинәдә иңгән. Мүмтәхинә–сыналуга дучар хатын, дигән сүз.)*

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Әй, иман китергән халык, әгәр Минем юлымда сугышырга һәм ризалыгымны алырга теләсәгез, Минем дә дошманым, сезнең дә дошманыгыз булганнарга хөрмәт күрсәтеп, яшерен мәхәббәт тәрбияләгәннәрне дус итмәгез. Чөнки алар сезгә килгән Хакыйкатьне *(Коръәнне)* инкарь итте. Аллаһка инанганыгыз өчен, Пәйгамбәрне дә сезне дә ватаныгыздан кудылар. Мин сезнең яшерен эшләрегезне дә ачык кылмышларыгызны да бик яхшы белеп торам. Кем моны кылса *(имансызларны дус итсә, аларга мәхәббәт тотса)*, шул тугры юлдан язган хисапланыр.

**2.** Әгәр дә инде алар сезне тоткын итсә, дошманлык кылсалар, куллары һәм телләре белән сезне рәнҗетеп, *(Аллаһны инкарь итеп, динегездән)* ваз кичтерсәләр, **(3)** Кыямәт көнендә якын кардәшләрегез дә, балаларыгыз да сезгә файда итә алмас. Аллаһ сезне алардан *(якыннарыгыздан)* аерыр. Аллаһ бөтен гамәлләрегезне күреп тора.

**4.** Хактыр ки, Ибраһим да вә аның белән бергә булганнар да сезнең өчен гүзәл бер үрнәк булып тора. Алар кавемнәренә әйттеләр:

–Без сездән һәм Аллаһны инкарь итеп, башка нәрсәләргә табынганнардан катгыян баш тартабыз. Сезне *(туганнарыбыз дип)* танымыйбыз. Сез бары тик бер Аллаһка иман китергәнегезгә чаклы, арабыздагы дошманлык, ачу-үпкә бетмәячәк. Ләкин Ибраһим атасына әйтте:

–Әлбәттә, мин **(Аллаһ)** сине кичерсен дип **(дога кылып)** ялварачакмын. Ләкин Аллаһтан сиңа киләчәкне **(бер генә җәзаны да)** мин тоткарлый алмаячакмын,–диде. Мөэминнәр әйтте:

–Раббыбыз, бары тик сиңа гына сыендык, сиңа гына юнәлдек. Кайтыш та бары тик Синең тарафка гына булачак.

*(«Хәзрәти Ибраһим иман китермәгән атасына, иман китерер өчен форсат вакыты бирә, һәм шул арада атасы өчен ярлыкау сорап, Аллаһка ялвара, ләкин инде соң була, Ибраһимның атасы инде Аллаһ тарафыннан ярлыканмас дәрәҗәдәге кяферләр рәтенә куела. Чөнки Аллаһның: кяферләр өчен ярлыкау булмас, дигән әмере бар».*

Али Тургут тәфсиреннән.)

**5.**–Раббыбыз, безне инкарьчылар хөкеменә тапшырып, тәҗрибә-сынау кешеләре итмә Ярлыка безне. Йа, Раббыбыз! Бердәнбер җиңүче вә хикмәт иясе бары тик Син Үзең генә

**6.** Хактыр ки, алар *(пәйгамбәрләр белән сәхабәләре)* сезнең өчен, Аллаһка вә ахирәт-

кә ышанганнар өчен гүзәл үрнәк. Кем йөз чөерә *(шул һәлакәткә дучар)*. Һичшиксез, Аллаһ бай *(берниgә дә мохтаҗ түгел)*. Ул мактауга лаек.

**7.** Ихтимал, ике арадагы *(иман китергән туганнар белән иман китермәгән туганнар арасындагы)* дошманлыкны бетереп, Аллаһ сезне озакламый дуслаштырыр да. Аллаһның көче җитәрлек. Аллаһ–ярлыкаучы, чиксез мәрхәмәт иясе.

**8.** Сезнең яктан дин юлында сугышмаса да, сезне ватаныгыздан кумаган кешеләргә игелек кылуыгызны һәм аларга гадел булуыгызны Аллаһ тыймас. Аллаһ гадел булганнарны сөя.

**9.** Динегезгә каршы сезнең белән сугышып, сезне ватаныгыздан куып чыгарганнарны һәм куып чыгаруда кяферләргә ярдәм итешкәннәрне дус итсәгез, Аллаһ хупламас. Кем шундыйлар белән дуслаша, шулар залимнәр булыр.

**10.** Әй, иман китергән адәмнәр! Мөэминә хатыннар һиҗрәт итеп, сезнең янга килсә, аларны сынагыз. Алар иманлымы-юкмы икәнен Аллаһ бик яхшы белә. Аларның иманлы хатыннар икәненә ышангач, аларны кяферләргә кайтармагыз. Бу хатыннар аларга хәләл түгел. Тегеләре дә бу хатыннарга хәләл булмас. Аларның ирләре биргән мәһәрләрен кире кайтарыгыз. Мәһәрләрен ирләренә кире кайтарган очракта, аларга өйләнү гөнаһ булмас. Кяфирә хатыннарны никахыгызда тотмагыз, алар өчен булган чыгымнарны таләп итегез. Алар да шулай ук үз якларыннан булган чыгымны сездән сорасын. Аллаһның хөкеме шундый. Арагызны Аллаһ хөкем итә. Аллаһ барысын да белеп тора. Ул–хикмәт иясе.

**11.** Әгәр дә берәр мөэминнең хатыны ташлап, кяферләргә качып китсә, сез алар белән сугышыгыз, җиңгәннән соң, хатынсыз калган иргә *(качып киткән хатынга тоткан чыгымнары кадәр)* ганимәт малыннан өлеш бирегез. Үзегез иман китергән Аллаһ каршысында гаделсезлек кылудан сакланыгыз.

**12.** Ий, пәйгамбәр! Иманлы хатыннар сиңа килеп:

–Аллаһка тиңдәшләр уйлап чыгармабыз, угрылык кылмабыз, зина эшләмәбез, үз сабыйларыбызны үтермәбез *(көмәнебезне төшермәбез)*, кулларыбыз белән аякларыбыз арасында булганнарны ялганлап *(яшерен уйнаштан туган балабызны)* башка иргә сылтамабыз, игелекле эшләрдә сиңа каршы булмабыз, дип ант итсәләр, антларын кабул ит вә алар өчен Аллаһтан ярлыкау сора. Шик юктыр ки, Аллаһ–ярлыкаучы һәм чиксез мәрхәмәтле.

**13.** Әй, иман китергән адәм балалары, Аллаһ җәзага тарткан кавемне дус итмәгез. Чөнки алар Ахирәт көненнән өмет өзде. Кяферләр *(мәетләрнең терелеп)* кабердән чыгуларына ышанмады.

## 61—САФ (РӘТ) СҮРӘСЕ

*(Саф сүрәсе 14 аятьтән тора. Мәдинәдә иңгән. Аллаһ юлындагы изге сугыш–Җиһадта сугышучыларның гаскәр сафы турындагы сүрә.)*

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Күкләрдәге *(фәрештәләр, кошлар, җисемнәр)* һәм Җирдәге *(кешеләр, хайваннар, үсемлек, таулар, диңгезләр)* Аллаһка гыйбадәт кыла. Аллаһ өстендер, хикмәт иясеңдер.

**2.** Әй, иман китергән кешеләр! Эшли алмаган, эшләмәячәк нәрсәләрегез турында нигә шапырынасыз? **(3)** Эшләмәячәгегез турында эшлим, дип шапырынуыгыз Аллаһның нәфрәтенә дучар.

**4.** Аллаһ Үз юлында сугышканда *(дошман түгел, җил дә үтеп керә алмаслык)* тоташ саф булып орышканнарны хуплый.

**5.** Бервакыт Муса кавеменә:

–Әй, халкым, минем Аллаһ тарафыннан күндерелгән пәйгамбәр булуымны белгәнегез көенчә, нигә мине рәнҗетәсез?–диде.

Алар тугры юлдан чыккач, Аллаһ аларның күңелләрен дә адаштырды. Аллаһ фасикълар өерен тугры юлга күндермәс.

**6.** Исегездәме соң, Мәрьям углы Гайсә:

—Әй, Исраил токымы, мин Аллаһның сезгә җибәргән илчесе буламын, миннән алда килгән Тәүратны дөресләүче вә миннән соң да киләчәк Әхмәт исемле бер пәйгамбәр турында сөенечле хәбәр китердем,—диде. Бу хакта ул ышанычлы дәлилләр китергәч, алар:

—Бу—көн кебек ап-ачык бер сихер,—диделәр.

**7.** Исламны кабул итегез, дип үгетләп тә Аллаһ хөкемнәре турында ялган сөйләгән кешедән дә кабахәтрәк кеше бармы икән! Аллаһ кабахәтләр өерен тугры юлга юнәлтмәс. **(8)** Алар авызы белән Аллаһның нурын сүндерергә тели, кяферләр ул нурны кирәксенмәсәләр да, Аллаһ нур иңдерүдән туктамас. **(9)** Мөшрикләр теләмәсә да, Исламны бөтен диннәрдән дә өстен итәр өчен Пәйгамбәрен тугры юл һәм Хаклык илә күндергән—Аллаһтыр.

**10.** Әй, иманга килгән кешеләр, сезне әче газаптан коткарачак бер алыш-биреш ысулын сезгә күрсәтимме? **(11)** Аллаһка вә аның Рәсуленә инаныгыз, малларыгыз белән, җаныгыз белән Аллаһ юлында Җиһад итегез. Белеп торыгыз, бу сезнең өчен бик тә хәерле гамәл булыр.

**12.** Бу тәкъдирдә Аллаһ сезнең гөнаһларыгызны кичерер, сезне арыкларыннан чишмәләр агып ятучы җәннәтләргә, Гаден җәннәтендәге мәһабәт сарайларга урнаштырыр. Менә, бөек моратка ирешү шул булыр. (13) Күңелегезгә хуш килә торган тагын бер нәрсә булыр: сезгә Аллаһтан ярдәм килер, аннан соң озак та узмас, бөек җиңү булыр. Шулар турында хәбәр итеп, син мөэминнәрдән сөенче ал.

**14.** Әй, иманга килгән бәндәләр! Аллаһның динендә пәйгамбәрләргә ярдәмче булыгыз. Мәрьям углы Гайсә үзенең хавариларына *(сәхабәләр кебек якыннарына)* әйткән иде:

—Аллаһ юлыннан киткәнемдә миңа кем ярдәмче булыр?—диде. Хаварилар исә:

—Аллаһ юлында сиңа без ярдәмче булырбыз,—диделәр. Исраил токымыннан бер төркем халык иман китерде, башкалары инкарь итте. Ниһаять, Без иманлыларны дошманнарыннан өстен чыгардык. Иманлылар җиңүче булды.

# 62—ҖОМГА (ҖОМГА) СҮРӘСЕ

*(Җомга сүрәсе 11 аятьтән тора. Мәдинәдә иңгән.)*

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Күкләрдә вә Җирдә булганнарның барысы да дөнья милкенең хуҗасы, кимчелектән азат, галәмнәрнең Раббысы, хөкемдар—Аллаһка тәсбих әйтә.

**2.** Хәреф танымаган наданнар арасыннан чыгып, үзләренә аятьләр укыган, аларны сафлыкка өндәгән, аларга Китап вә хикмәтне өйрәткән бер Пәйгамбәр күндерүче Аллаһ булды. Хактыр ки, алар башта кыйбласыз адашып йөрүче кавем иде.

*(Яһүдләрдән, христиannардан аермалы буларак, гарәпләргә алардан алда китап иңдерелмәгән иде.)*

**3.** *(Пәйгамбәрне Аллаһ)* мөэминнәргә генә түгел, аларга катнашы булмаган башка халыкларга да иңдерде. Аллаһ—чиксез кодрәт һәм хикмәт иясе.

**4.** Бу—Аллаһның мәрхәмәтедер. Ул теләгәненә рәхмәтен иңдерер. Аллаһ—чиксез миһербан иясе.

**5.** Тәүрат китабы бирелеп тә, аның буенча гамәл кылмаган бәндәләрнең хәле таутау китап төягән ишәкнеке кебектер. *(Күп китап ташыса да, ишәккә белем кермәс.)* Аллаһның аятьләрен бозып күрсәтүче кавемнең хәле бик тә яман. Аллаһ залимнәр өерен тугры юлга күндермәс.

**6.** Әйт син:

—Әй, яһүд халкы!—диген.—Сез бөтен халыкларга караганда да без генә Аллаһка якын дус, дип расламакчы буласыз, әгәр сүзегез хак икән, әйдәгез, тизрәк үлегез

*(Аллаһка тизрәк якынаерсыз, чөнки Аллаһның дуслары Ахирәткә ышана.)* **(7)** Ләкин эшләнгән гөнаһларыннан куркып, алар үлемне ашыктырмаслар. Аллаһ залимнәрне бик яхшы белеп тора.

**8.** Әйт син:

–Сез үлемнән качсагыз да, ул сезне якалаячак. Ахырда күренгәнне һәм яшеренне белгән Аллаһ хозурына китереләчәксез. Аллаһ ни кылганыгыз турында сезгә хәбәр бирәчәк.

**9.** Әй, иман китергән кешеләр! Җомга көнне намазга чакыргач *(азан әйтелгәч)*, Аллаһны зикер итәргә ашыгыгыз вә алыш-биреш не калдырып торыгыз. Беләсегез килсә, бу эш *(намаз уку)* сезнең өчен тагын да хәерлерәк булыр.

**10.** Намаз укылып бетүгә үк кайсыгыз кая таралыгыз һәм Аллаһтан нигъмәт сорагыз. Аллаһны күп зикер иткән кешенең Сәгадәткә ирешүе ихтимал.

**11.** Алар берәр җирдә әйбер сатканнарын күрсәләр яки берәр тамашага юлыксалар, синең ялгызыңны калдырып, китеп барырлар. Әйт син:

–Аллаһка якын тору *(намазда, сәҗдәдә, догада булу)* тамашадан да, сәүдәдән дә яхшырак,–диген. Аллаһ ризык бирүчеләрнең иң хәерлесе.

# 63—МОНАФИКЪЛАР (ИКЕЙӨЗЛЕЛӘР) СҮРӘСЕ

*(Монафикълар сүрәсе 11 аятьтән тора. Мәдинәдә иңгән.)*

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Монафикълар синең яныңа килгәч:

–Шаһитлык итәбез ки, чыннан да, син Аллаһның Пәйгамбәре,–диләр. Әйе, Аллаһ та бу турыда белә син, әлбәттә Аллаһның Пәйгамбәре. Аллаһ монафикъларның алдакчы икәнлекләрен яхшы белә (2) Антларын калкан итеп, алар–Аллаһ юлыннан яздыручылар. Чыннан да, аларның гамәлләре бик тә яман. **(3)** Чөнки алар башта иман китерде, ахырда иманнан чыкты. Шуңа күрә (иман өчен) аларның күңеле йозаклы. Алар инде хәзер һични аңламый. **(4)** Аларның кыяфәтенә баксаң, исең китәр, әңгәмәдәге сөйләшүләрен тыңласаң, сүзләре һушыңны алыр. Ләкин алар коймага сөяп куйган таяк кебек *(койманы да терәтеп тормый, үзе дә авып китми)*. Алар һәр кычкыру тавышын үз башларына *(килгән җәза)* дип, кабул итә. Алар–дошман халык. Алардан саклан. Аллаһ *(куркытып)* аларның җаннарын алачак. Ничек итеп алар шушы мөшкел хәлгә төште соң?

**5.**–Килегез, Аллаһның Пәйгамбәре сезнең өчен ярлыкау теләсен,–дигәч, алар йөзләрен чөереп китә. Син аларның ераклаша барган тәкәббер кыяфәтләрен күреп калырсың. **(6)** Ярлыкау сорасаң да, сорамасаң да аларга барыбер. Аллаһ аларны берничек тә ярлыкамаячак. Юлдан язганнарны Аллаһ тугры юлга күндермәс. **(7)** Алар:

–Аллаһ илчесе янында булганнарга бернинди дә чыгым түкмәгез (хәер, садака бирмәгез, ярдәм итмәгез), кадалып китсеннәр,–ди. Күкләрнең вә Җирнең хәзинәләре–Аллаһныкы. Ләкин монафикълар моны белми. **(8)** Алар:

–Хактыр ки, әгәр Мәдинәгә кайтсак, өстен булганнар, бай кяферләр бичара хәлдәгеләрне *(фәкыйрь мөэминнәрне)*, һичшиксез, куып чыгарачаклар,–диләр.

Гәрчә чын өстенлек бары тик Аллаһта, Пәйгамбәрендә, мөэминнәрдә булыр. Ләкин монафикълар моны белми.

**9.** Әй, иман китергән халык, малларыгыз *(байлыгыгыз)*, балаларыгыз Аллаһны оныттырмасын. Кем Аллаһны оныта, шул зыян-зәхмәт күрер.

**10.** Әҗәле килгән кеше:

–Раббым, миңа кыска гына вакытка булса да гомер бир. Валлаһи, мин садака бирер идем, игелекләр кылыр идем,–дип әйткәннән күпкә әүвәл Без биргән ризыкларыгыздан садака бирергә кирәк иде.

**11.** Аллаһ әҗәле килгән бер генә кешенең дә үлемен кичектермәс. Аллаһ ни кылганыгызны белеп тора.

# 64—ТӘГАБҮН (АЛДАНУ) СҮРӘСЕ

*(Тәгабүн сүрәсе 18 аятьтән тора. Мәдинәдә иңгән. Тәгабүн—алдану дигән сүз.)*

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Күкләрдә вә Җирдә ни булса, барысы да Аллаһны мактый. Милек-байлык—Аллаһныкыдыр. Мактау—Аллаһкадыр. Аллаһның кодрәте һәр нәрсәгә җитә **(2)** Сезне яраткан—Аллаһтыр. Кайсыгыз—кяфер, кайсыларыгыз мөэмин булдыгыз. Аллаһ сезнең гамәлләрегезне күреп торучы. **(3)** Күкләрне вә Җирне юктан бар итте. Сезгә сурәт-кыяфәт бирде һәм сезнең рәвешегез бик тә гүзәл булды. Кайтыш та—Аллаһкадыр. **(4)** Аллаһ күкләрдә вә Җирдә булганнарның барысын да белеп тора. Яшереп-качырып кылганнарыгызны да, ачыктан-ачык гамәлләрегезне дә белеп тора. Аллаһ күңелләрдә нинди теләк, башларда нинди фикер булганны да белә

**5.** Байтактан әүвәлге яшәешләрендәге инкарьчыларның хәл-хәбәре сезгә килеп ирешмәдемени? Алар кылмышларына күрә җәзасын да татыды. Алар өчен әче газап хәзерләнгән иде. **(6)** Пәйгамбәрләр аларга ап-ачык дәлилләр китергән иде, ләкин алар:

—Гап-гади бер бәндәме безне тугры юлга юнәлтәчәк?—дип инкарь иттеләр, йөз чөерделәр. Аллаһ та һичбер нәрсәгә мохтаҗ түгеллеген күрсәтте. Аллаһ—байдыр, мактауга лаектыр. **(7)** Кяферләр белән мөшрикләр үлгәч яңадан терелүне катгыян инкарь иттеләр. Әйт син аларга:

—Валлаһи, сез, һичшиксез, яңадан тереләчәксез, ахырда гамәлләрегез турында сезгә хәбәр биреләчәк,—диген.—Бу эш Аллаһ өчен бер дә кыен түгел. **(8)** Шулай булгач, Аллаһка, аның Пәйгамбәренә һәм индерелмеш нурына *(Корьәнгә)* иман китерегез. Аллаһ сезнең гамәлләрегездән хәбәрдар. **(9)** Мәхшәр көне—барыгыз бергә туплана торган көн *(исәп-хисап, югалтулар, алданулар һәм табышлар көне)*. Аллаһка иман китереп, игелек кылган кешенең хаталарын Аллаһ кичерер, андыйларны Аллаһ арыкларыннан чишмәләр агып ятучы җәннәтләргә урнаштырыр. Алар анда мәңге калачак. Менә, бөек Максат—Сәгадәт шул булыр.

*(«Кыямәт көнендә кяферләр фани дөнья тормышына алданып, форсатны ычкындырганнарын аңларлар. Яумүтүн тәгабүн—котчыккыч алдану, зарар күрү көне».*

Али Тургут тәфсиреннән.)

**10.** Инкарьчылар белән аятьләремне ялганга чыгаручылар җәһәннәмгә теркәлер. Алар анда мәңге калачак. Ай-һай, хәтәр җир ул—алар барачак җәһәннәм.

**11.** Бер генә кайгы да Аллаһ әмереннән башка төшмәс. Аллаһка инанган кешенең күңелен Аллаһ тугры юлга юнәлтер. Аллаһ бар нәрсәне дә белеп тора. **(12)** Аллаһка итагать итегез. Пәйгамбәргә дә итагать итегез. Йөз чөерәсез икән, чөерегез *(аннан Раббыга да, Пәйгамбәргә дә зыян булмас)*. Пәйгамбәр бары тик үз вазифасын ачык итеп белдерүче генә **(13)** Аллаһтан югары һичбер башка кодрәт иясе юк. Мөэминнәр фәкать Аллаһка сыенып, Аңа ышанып яшиләр. **(14)** Әй, иманлы кешеләр, хатыннарыгыз һәм балаларыгыз арасында да сезгә дошман булганнар бар. Алар белән сак эш итегез. Әмма аларны гафу итсәгез, хаталары аркасында аларны какмасагыз, ялгышларын каплап калгаласагыз, белеп торыгыз ки, Аллаһ—ярлыкаучы, чиксез миһербанлы кичерүче. **(15)** Дөресен генә әйткәндә, байлыгыгыз һәм балаларыгыз сезне сынар өчен генә. Бөек әҗер исә Аллаһ янында булыр. **(16)** Шулай булгач, булдыра алганча, сез Аллаһка каршы баш күтәрмәскә тырышыгыз. *(Аллаһ әмерләрен)* тыңлагыз, итагать итегез, үз мөмкинлекләрегездән чыгып, хәер-садәка бирегез. Нәфесен тыя белгән кеше Сәгадәткә ирешер. **(17)** Аллаһ ризалыгы өчен бурыч бирсәгез *(саваплы эш башкарсагыз)* Аллаһ сезнең әҗерегезне кат-кат арттырыр һәм сезне ярлыкар. Аллаһ әҗерне мул бирер, Ул җәза бирергә ашыкмый. **(18)** Яшерелгәнне дә, яшерелмәгәнне дә Аллаһ белеп тора. Ул өстендер, хикмәт ияседер.

*Хәтер*

# ТУГАН ЯКНЫҢ КИТМӘС КОШЫ

Без еш кына: "Шагыйрьлек—профессия түгел!"—дибез. Бәлки бу чыннан да шулайдыр. Ләкин, алай бик гади икән, нигә соң әле көндәлек эше итеп әдәбиятка хезмәт итү юлын сайламаган, чын мәгънәсендә әдәбият хадиме, телисез икән, әдәбият корбаны булырга теләмәгән кайберәүләр дә гомерләре буена "жыру" чыгаралар? Хикмәт шунда ки: әйе, шагыйрьлек профессия түгелдер, әмма ул, ышанып әйтергә мөмкин, күңел балкышы, әйләнә-тирәне үзенчә кабул итүнең гыйбрәтле бер билгесе, халәте рухиянең тәэссорат чишмәләре исән-сау икәнлеген искәртеп торучы тынгысыз кыңгырау буларак, һәркемне әсир, сәййәх итәргә сәләтле могжизаи бер көчтер, тылсым ияседер. Чыннан да, шигъриятнең "тозлы бал" тәмен татып караган, күкрәгендә "илһам камчысы"ның татлы эзләрен тойган кешеләр, гадәттә, анарга—үтә дә нәзберек холыклы Ханымга—хыянәт итмиләр, дөресрәге, хыянәт итә алмыйлар. Чөнки ул синең бөтен барлыгынны биләп ала; чөнки Ижат—ләззәтле газап! Ф. М. Достоевский сүзләре белән әйтсәк, үз теләгең белән газап чигүдән дә бөегрәк ләззәт юк ул! Корифейлар өчен генә түгел, ә бәлки көне буе завод-фабрикаларда яки басу-кырларда тир түгеп кайтканнан соң жан сурәтен ак кәгазьгә төшерү өчен кулына каләм алган күп, бик күп әһле ижат өчен дә бу изге хис таныштыр дип уйлыйм.



Бүгенге татар әдәбиятын менә шушындый Ижат эшен икенчел шөгыле итеп яшәүче каләм ияләреннән башка күз алдына китерүе дә кыен. Миңа калса, алар татар әдәбияты күперен иннәрендә күтәреп баручы үзәк баганаларга терәк булып хезмәт итәләр.

Марсель Гыймазетдинов—шундый ижаткярләрнең берсе иде. "Шигырь язу минем һөнәр түгел" дисә дә, аның кулыннан каләме төшкәне юк. Ул—жир кешесе! Халык әйтмешли, ул кендеге белән жиргә берегеп үскән. Шигырьләре дә изге туган туфрактан шытып чыкканнар. Аның шигырьләре аяз иртәләр шикелле үтә күренмәле, саф, самими; авыл өйләре тәрәзәседәй якты өлгеле, ачык хисле шигырьләр дияр идем мин аларны.

Яз Кояшы жирдә.
Гөрләвекләр
Язгы ташкын булып йөгерә.
Якты көннең якты бизәкләрен
Алып була хәтта өлгегә...

Татарстан радиосыннан ясаган бер чыгышында ул үзенең ижаты турында фикер йөртеп болайрак дигән иде:

—Мин Менделеевск районында колхоз рәисе булып эшлим. Билгеле инде, ярты гомерем басу-кырларда үтә. Яз уянып кына килгән бер мәлдәме, яисә жәйге иртә-кичләрдәме, йә булмаса көзгә кергәчме—кырлар түренә карап уйланып торасын да, ирексездән күңелгә шатлык хисләре тула һәм үзен дә сизмәстән: "Матур бу дөнья!"—дип куясын. Мондый чакларда тормышның, вак-төяк мәшәкатьләре бердән онытылып китә, иркен сулыш белән яшисе килә баш-

лый. Һәм мин шул уй-хисләремне, кодрәтемнән килгәнчә, кәгазьгә төшереп барырга тырышам.

Ак кәгазьгә төшкән ак хисләр!.. Әйе, шундый бер мизгел өчен генә дә яшәргә ярый бу дөньяда. Марсель Гыймазетдинов моны яхшы аңлап яшәде. Әгәр ул:

Китәсем юк сездән аерылып,
Ишетәсезме, басу-кырларым!
Гомеремне сезгә багышладым,
Сезгә булсын туар җырларым,—

дип әйтә алган икән, монда бернинди дә арттыру юк, бу чыннан да шулай иде. Шигырьләре—моның ачык дәлиле. "Гомерен басу-кырларга багышлаган шагыйрьнең" җырларына әле башаклар шавы, тургайлар моңы килеп кушыла ("чыксам әгәр иркен басуларга, тургай җыры чыңлый колакта"); анда "бразналар кояш назлавыннан кара икмәк кебек күренә"; кырларда аның "йөрәккәе бәйгедәге аттай җилкенә" башлый. Ул тормышның, тәмен белеп яшәде, ул—оптимист иде.

...Ак томаннарга төренеп.
Тездән чык ярып кайтам.
Сагышларым—якты сагыш—
Гомеремне озайта.

Кыскасы, Марсель Гыймазетдинов авыл тормышының бай палитралы сурәтен тасвирларга омтылды, авыл кешесе—игенчегә мәдхия җырлады.

Җырлады дигәннән, аның бик күп шигырьләренә төрле композиторлар тарафыннан матур-матур көйләр язылуның сере дә әнә шунда, шигырь нигезенә җыр хасиятләре салынуда түгел микән әле? Ни генә булмасын, без бүген Марсель Гыймазетдиновны бик күп популяр җырлар авторы буларак беләбез. Аның "Аккош канат кагына", "Килмисең син көлеп", "Язлардан алалмыйм күземне", "Туган якның китмәс кошлары без" кебек җырлары эстрада сәхнәсеннән төшми диярлек. Шагыйрь:

Язгы күкрәү кебек,
Яздай карый көлеп—
Эреп аксын салкын кышлары.
Без—җилкенеп очкан,
Зәңгәр күкне кочкан,
Туган җирнен китмәс кошлары,
Яз ясаучы китмәс кошлары,—

дип язган иде. Амин, нәкъ менә шулай, "туган якның китмәс җырчы кошы" булып, җирдә яз ясап яшәргә язды аңарга.

**Наис ГАМБӘР**

# МАРСЕЛЬ ГЫЙМАЗЕТДИНОВ

## ТУГАН ҖИРНЕҢ КИТМӘС КОШЛАРЫ БЕЗ

Чәчәкле җәй үтте,
Монсу көзләр житте—
Очар кошлар китте тезелеп.
Һаваларда очкан,
Зәңгәр күкне кочкан
Кошлар кебек идек без элек.

Очар кошлар очсын,
Зәңгәр күкне кочсын—

Ә без калыйк туган төбәктә.
Туган җирнең яме—
Яшәешнең тәме.
Тамыр җәйгән безнең йөрәктә.

Яшел яздар җирдә,
Сагыну моңы җилдә—
Киткән кошлар кайта ашкынып.
Гел яшисе килә,
Бер яшьнисе килә—
Җанга тула бәхет ташкыны.

Язгы күкрәү кебек,
Яздай карыйк көлеп—
Эреп аксын салкын кышлары.
Без—җилкенеп очкан,
Зәңгәр күкне кочкан,
Туган җирнең китмәс кошлары,
Яз ясаучы китмәс кошлары.

## КАРЛАР ЯУСЫН...

Күзләр озата килде, күрәсеңме,
Безнең якка ап-ак кошларны.
Әле күптәнме соң җылы якка
Озатып калган идек кышларны.

Талгын гына мамык карлар ява,
Ак юрганга ябып кичләрне.
Язмышларга пакьлек өстәгәндәй,
Акландыра сыман хисләрне.

Ябалак карлар ява. Ястык кебек
Бер көндә бит җирне каплады.
Ак карлардан язмышыма табан
Акрын гына гүя атладым.

Шул карларда эзләр ятып калды,
Эзләремдә—сөю ялкыны.
...Карлар яусын, тик керә күрмәсен
Арабызга карлар салкыны.

## ГОМЕРЕМНЕ НАЗЛЫ ҖЫР ИТТЕҢ

Көтмәгәндә генә очраштык та,
Бар булганым биләп алдың син.
Гомерем буе эзләгәнмен икән—
Язмышыма кереп калдың син.

Көтмәгәндә генә очраштык та,
Йөрәкләр дә вәгъдә бирделәр.
Серле карашларын күңелемә
Сөю уты алып килделәр.

Назлар килде шул карашлар белән,
Зәйтүн гөлем, сина мен рәхмәт.
Синең белән бу якты дөньяда
Яшәүләре, ихлас, бик рәхәт.

Очраштык та гомер уртасында
Язмышларны иттек бер бөтен.
Синсез яшәү монсыз җыр булган бит—
Гомеремне назлы җыр иттең.

*Берлекнең яңа әгъзалары*



## Зөфәр Дәүләтов

Зөфәр Мирхәйдәр улы Дәүләтов 1953 елда Татарстанның Мөслим районы Яңа Сәфәр авылында туган. Мәктәпне тәмамлагач училищеда тракторчы һөнәрен үзләштергән. Армия хезмәтеннән соң Уфа шәһәрендә Башкортстан биохимия комбинатын төзүдә катнашкан. Соңрак электр-механика техникумын, Төркмәнстандагы Бируни исемендәге политехника институтын тәмамлаган.

1995 елларда гаиләсе белән Әлмәткә күчеп килә. Моңа кадәр җирле газет-журналларда русча язып, иҗат иткән Зөфәр туган төбәктә, татар мохитендә киң сулыш алып, иҗади яктан ачылып китә.

Әлбәттә, бу рухи янарышка Әлмәттә иҗат итүче Г. Афзал, Н. Әхмәдиев, М. Юныс, Ә. Маликовларның өлеше зур.

Соңгы елларда Зөфәр Дәүләтовның кайбер әсәрләре көндәлек матбугатта, шулай ук безнең журналда да дөнья күрде. Әлегә кадәр иҗат иткәннәренең нәтиҗәсе булып быел аның Татарстан китап нәшриятында «Төзәлмәс яра» дип исемләнгән китабы басылып чыкты. Бу китапка кергән «Уйландырган замана» язмасы очерк-публицистик рухта язылган. Татарстан-Германия уртак предприятиесе «Татойлгаз»да техник бүлек начальнигы булып эшләгәндәге уй-кичерешләр аның бу әсәрендә.

Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең сентябрь аенда узган утырышында Зөфәр Дәүләтов Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп кабул ителде (Тәкъдимнамә бирүчеләр: Г. Афзал, Ф. Садриев, Н. Әхмәдиев). Күптән түгел, Әлмәт язучылар берлеге үзенең 40 еллык юбилеен үткәргән көннәрдә, ул бу оешманың җитәкчесе итеп сайланды. Зөфәр Дәүләтов шулай ук Бөтендөнья татар Конгрессының Әлмәт бүлеге рәисе дә.



*СССР Язучылар Съездының VIII съездына килгән Татарстан вәкилләре. Сулдан уңга– Р. Гаташ, Н. Фәттах, Н. Орешина, Г. Рәхим, Д. Зарипова, Ә. Еники, Т. Галиуллин, Р. Харис, И. Юзеев. Мәскәү. Кызыл мәйдан. 1986 ел.*



*«Дуслар белән җырлар көчле яңгырый». Туфан Миңнуллин. Г. Тукайның тууына 100 ел тулу уңаеннан Кырлай урманында җыен. 1986 ел.*



*Зәй ягы әдипләре. Сулдан уңга—Мөдәррис Әгъләмов, Аяз Гыйләҗев, Рабит Батулла. 1995 ел.*



*«Казан утлары» журналының 80 еллык юбилее уңаеннан төшерелгән рәсем. Сәхнәдә—журнал коллективы. Казан милли мәдәният үзәге. 2002 ел.*

*Балалар өчен хикәяләр*

## “ИСӘНМЕ, ЯПОН МАЛАЕ!..”

Сигезенче класс укучысы Шәйхуллин Шәрип суган үстерүдә беренче урынны алды. Шуның өчен аны “Артек”ка җибәрделәр. Анда ул Сокико исемле япон малае белән танышкан. Кара диңгез буеннан кайтып ике-өч атна вакыт узуга Шәрипкә Токиодан хат килеп төште.

“Исәнме, Шарп!–диелгән иде анда.–Сиңа Сокико хат яза. “Артек”тан кайтуга ук сиңа язарга булдым. Бездә эссе. Кофе эчәбез, банан ашыйбыз. Шортиктан йөрибез. Сездә нинди кызыклар бар? Һәммәсен язып җибәр. Көтәм...”

Шәрип, хатны алуга ук җавап язарга утырды:

“Исәнме, япон малае! Минем хәлләр бер көе. Бездә салкын, яңгырлар ява. Катык эчәбез, токмачлы аш ашыйбыз. Кофе эчеп, банан ашасак, без дә шортиктан йөрер идек (чалбар алырга акча җитмәс иде, диюем)...

“Артек”тан кайтуга ук колхоз чөгендерен алырга чыктык. Рәхәт. Укыйсы юк. Дөрес, соңыннан без укылмаган дәресләрне куып тоту өчен кырык биш минут эчендә сигезәр параграфны дөмбердәтәчәкбез. Зато хәзер күңелле. Чөгендерне йолкып “сто песят” арбасына ыргытабыз... Бер-беребезгә балчык бәрешәбез... Җиргә егып салу өчен кызларны куып йөрибез... Кайтышлый икешәр чөгендерне култык астына кыстырабыз. Әз булса да сыерга ризык була...”

“Исәнме, Шарп! Нигә син миңа исемем белән дәшмисең? Миңа, мәсәлән, синең исем бик ошый. Чөнки бездә телевизор-магнитофонар җитештерә торган шундый атаклы фирма бар.

Шарп! Мин кайбер нәрсәләрне аңлап җиткермәдем. Нәрсә ул “сто песят”? Ни өчен бер-берегезгә балчык бәрәсез? Авыртадыр бит?.. Ни өчен кызларны җиргә егасыз? Алар бит нәфис затлар! Бездә киресенчә, кызларга хөрмәт күрсәтәләр, аларга морожный, чизбургер алып бирәләр... Кайтышлый ике данә чөгендер урлап кайтуыгыз да аңлашылмый. Аның белән генә сыерның тамагы туймый бит? Нигә чөгендерне күп итеп сатып алмаска? Җавап көтәм. Сокико”.

“Исәнме, япон малае! Исемең белән дәшмәгәнгә ачуланма. Бездә ул сүгенү сүзе төслерәк яңгырый. Сезнең телевизорлар бездә дә бар. Абыйга “уборка”да икенче урынны алган өчен бирделәр. Аның пульты чикләвек ватканда сынды. Чыдам әйбер түгел икән. Телевизоры да юньләп күрсәтми. Әти аңа исерек чагында “дамашни” бәргән иде...

Япон малае! Сорауларыңа җавап бирәм. 1) “Сто песят” ул зу-ур трактор. 2) Балчык әләккәч тән авыртса да, башкаларныкы авырткanын күрү рәхәт. 3) Авылда мороженый сатсалар, кызларга бирмәс идек әле–үзебез ашар идек. Аларны җиргә егу гына аз, хезмәт укытучысы Хафиз абый ачуланмаса, вабще, муеннарына балчык тутырыр идек әле ул әләкчеләрнең. 4) Чөгендер апкайтуга килгәндә, мин–икене, абый икене, әти белән әни–икешәрне кыстырып кайтса, сыерыбыз тук корсагын сыпырып җырлап ук җибәрәчәк...

(“Чизбургер”ның ни икәнен Казанда, институтта укучы апамнан сорап белештем. Шундыерак әйберне без хайван суйганда пешерәбез–үпкә-бавыр пәрәмәче дип атала)”.

“Шарп! Миңа һаман күп нәрсә аңлашылмый. Нәрсә ул “уборка”? Өй җыештырумы? Ни өчен сез чикләвекне телевизор пульты белән ватасыз? Нәрсә ул “дамашни”? Аны ни өчен телевизорга бәрәләр? Сездә әләкче кызларның муеннарына балчык салу традициясе бармыни? Гаиләгез белән чөгендер урлау–хөкүмәт милкен үзләштерү була түгелме? Бездә моның өчен төрмәгә утырталар...”

“Исәнме, япон малае! Ачуланма, япон малае, мин синең сорауларыңа җавап бирә алмыйм. Дөресрәге, җавап бирсәм дә, син барыбер аңламаячаксың. Безнең илне аңлау өчен сиңа монда туарга, монда үсәргә кирәк. Сиңа бәлки безнең тормыш кыргый, сәер тоеладыр. Әмма үзебезгә ул бик якын, бик кадерле. Ни дисәң дә, туган җир бит! Сау бул, япон малае, хат яз, әмма сораулар белән башымны катырма. Шәрип”.

## ДИАНАЛАРДА КУНАКТА

Уйламаганда-көтмәгәндә, беркөнне Диана миңа дуслар булырга тәкъдим итте һәм шул ук көнне үзләренә кунакка да чакырды.

Бу–колорадо кортының кире Америкага очып китүе кебек гайре табигый хәл иде. Диана–безнең класста гына түгел, бөтен мәктәбендә иң чибәр кыз. Аның артыннан йөгереп йөргән малайларның күплеген күрсәгез! Тик ул аларның берсенә дә әйләнеп карамый, аксыл-сары чәчле башын югары чөеп, «фырт» кына уза да китә. Шуңа да, аның нәкъ менә мине тиктомалга кунакка чакыруы сәер дә, әйтеп бетергесез куанычлы да иде. Што сез! Үзе чибәр, акыллы, гел «5»легә генә укый...

Вубшем, матур киенеп, абыйның одеколонына коенып, киттем мин ул көнне Дианаларга.

Ишекне кызның әнисе ачты һәм ботинкамны салырга кушты. Аннары кулыма йомшак башмаклар тоттырды. Шундук табынга да дәштеләр.

Уһу! Өстәлләрендә ни генә юк! Әллә ничә төрле салат, балык, тавык, банан, тозлы кыяр... Ирексездән авызга сулар килде. Кулларым миңа буйсынмыйча, үзләреннән-үзләре өстәл уртасындагы ананаска үрелде... Әлеге сусыл көньяк җимешен шартлатып тешлим дигәндә генә...

–Үскәнем, кем исемле әле син?

–Ә?.. Нәрсә?..

Диананың әнисе дәшә икән.

–Рамай!–дип чатнатып әйттем мин һәм ананасның урта бер җирен «шаторт!» иттереп тешләп тә алдым.

–Беренчедән, Рамай, син әле кулларыңны юмадың, икенчедән, ананасны пычак белән кисеп ашыйлар...

Кулымны юып килгәч, минем тәлинкәгә дүрт төрле салат салдылар. Мин аларның дүртесен бергә бутадым да, үзем «иҗат иткән» «силос»ка сокланып, тәмләп ашыйм дигәндә генә...

–Рамай, беренчедән, һәр салатны аерым ашыйлар, икенчедән, салатны чәнечке белән ашыйлар, аш кашыгы белән түгел...

Кыскасы, табын яныннан торып киткәнче, күкәйне маңгайга бәреп ваткан өчен, кашыкның сабы белән чәй болгаткан өчен, тәлинкә төбен ялаган өчен һәм тагын нәрсәләрдер өчен миңа әлеге «беренче», «икенче»ләрне шактый ишетергә туры килде.

Аннары Диана мине үзенең бүлмәсенә алып кереп китте. Әл-лә-лә-лә... Мондагы пөхтәлекне күрсәгез! Музей залына килеп кердекмени!.. Матур итеп җыештырылган бүлмә. Стенка, диван, җыйнак кына өстәл. Стеналарда берничә картина, тәрәзә буенда гөлләр...

–Рамай, син музыка тыңларга яратасыңмы?–кыз семафор төсле төпсез зәңгәр күзләрен миңа төбәде.

–Яратам.

–Алайса, утыр, әнә, теге диванга.

Ул аристократларча нәзакатлелек белән генә өстәлдәге магнитофонга ниндидер кассета куйды, үзе дә минем яныма килеп утырды һәм чәч толымнарын боргалый-боргалый музыка башлануын көтте.

Кинәт колакны әче скрипка тавышы ярып керде.

–Бу–Моцарт,–дип аңлатты Диана ягымлы елмаеп.–Җиденче симфония.–Үзе аксыл-сары башын артка ташлап күзләрен йомды.

«Җиденче симфония»дән минем күңелем болгана башлады.

–... Бүтән юньлерәк кассетаң юкмы соң синең?

Кыз кинәт кенә «бу дөньяга» кайтып, күзләрен зур итеп ачты:

–Нәрсә дисең, Рамай?

–Юньлерәк кассета юкмы, дим? «Скутер», «Мумие Тролль»ме шунда...

–Кем, кем?–Диананың күзләре зур булып ачылды.

–Ну... «Исхак Хан»да ярый...

Кызганычка каршы, Дианаларда «Скутер» да, «Мумие Тролль» да юк иде. Ә инде «Исхак Хан»ның кем икәнлеген ул бөтенләй белми икән.

–Әйдә, бер кызык әйбер күрсәтәм,–дип ул магнитофонны сүндерде дә, кулларымнан җитәкләп мине тәрәзә буена, гөлләр янына алып килде.

–Бусы–Роза...–дип сөйләп китте кыз бер гөлгә, бер миңа карый-карый.–Роза–мәхәббәт гөле. Ә болары–яран гөл, миләүшә... ә бусы–кактус... Кактус турында бер легенда сөйлимме?..

Минем кактус турындагы легенданы әз генә дә тыңлыйсым килми иде.

–Әйдә, лутчы корабль батырыш уйныйбыз,–дидем.

–Юк, мин андый уенны белмим!

–Алайса, бәлки, кәрт сугарбыз?

–Карта–азартлы уен, карта безнең өйдә гомумән юк!

–Домино, шашка?..

Мин кактус турындагы легенданы тыңламас өчен мозаика төзеп утырырга да әзер идем.

Әмма, нихәл итәсең, «кунак–хуҗаның ишәге» диләрме әле?.. Дианалардан чыгып тайганчы миңа кактус турындагы легенданы ишетергә дә, Моцартның җиденче, Бетховенның бишенчеме, егерме бишенчеме симфониясен тыңларга, стенадагы ниндидер картинага карап торырга һәм «макраме» серләренә төшенергә дә туры килде.

...Урамга чыккач үз гомеремдә беренче тапкыр дөньяның нинди матур икәнлеген күрдем. Ю-у-ук, мөгаен бүтән килмәм мин бирегә. Әллә ни кызык түгел бугай Диана белән дус булуы. Аннары... чибәр дә түгел бугай ул... Мин лутчы арткы партада утыручы «труешник» Нәсимәләргә кунакка барырмын. Аның белән хет корабль батырыш уйнарга була. Вәт!

**Алмаз ГЫЙМАДИЕВ**

# 2003 елда журналда басылган әсәрләр исемлеге

Татарстан Республикасы Президенты Указы. 2003 елда Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен бирү турында. №6

## ЗАМАН һӘМ ШӘХЕС

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин белән язучы Разил Вәлиев әңгәмәсе. №11

## КАЗАННЫҢ 1000 ЕЛЛЫГЫНА

Миңнегали Ф. Казан урамнары ни сөйли? №12

Миңнегулов Х. Мөхәммәд Әмин ханның хат-бетеге. №11

Солтанов Р. Ханлык чорында Болак аръягы Казаны. №2

Солтанов Р. Ханлык чорында Казан шәһәренең фортификациясе. №10

## БАШ МӨХӘРРИР СҮЗЕ

Фәйзуллин Р. Иле барның—теле бар. №1

## ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Әмирханов М. Тояк эзе. Роман. №№1-3

Вәли-Барҗылы М. Идел яры. Повесть. №1

Вәлиева Г. Олылар өчен ике әкият. №4

Газиз Р. Ак болыт. Эссе. №12

Галиева Г. Өзелгән өмет. Повесть. №5

Галиуллин Т. Төнге юллар. Роман. №№6-8

Гаффар Ә. Хикәяләр. №1

Гыймадиев А. Балалар өчен хикәяләр. №12

Дәүләтов З. Тәре баганасы. Хикәя. №12

Җамалетдинова Ф. Алма. Хикәя №6

Зыялы С. Югалту. Повесть. №11

Ибраһимов Р. Очучы язмалары. №3

Камалов Б. Соңгы көннәрдә. Хикәя. №2

Кәримов К. Сакау күке. Роман. №№7-9

Латыйп К. Әдрән диңгез. Повесть-истәлек. №12

Латыйфи Ф. Себер хикәяте. Хикәя. №9

Маликова М. Мендем биек тауларга. Повесть. №10

Мөдәррисова Х. Яр. Повесть. №12

Нурзилә. Хикәяләр. №1

Салах Ә. Каеннар юлы. Повесть. №6

Сафин Ф. Саташып аткан таң. Роман. №№10,11

Сибат Р. Инабәт. Фәлсәфи роман. №4,5

Хәбибуллина Р. Яшьлегем серләре. Повесть. №4

## ШИГЪРИЯТ

Аймәт Р. Ә хакыйкать-ап-ак җилкән кебек... Шигырьләр. №7

Әхмәтҗан Р. Офык арты офык... Шигырьләр. №4

Баян Ә. Яңа гасыр. Шигырьләр. №10

Габдерәхим Ф. Милләт бурасына бөртекләрем. Шигырьләр (С. Сафуановның кереш сүзе белән). №1

Гадел Ә. Әй, тормыш, әй, кеше! Шигырьләр. №11

Гаделша Ш. И. Себер татарым, ни диим? Шигырьләр. №6

Галиев М. Кеше яшәр өчен илләр бар. Шигырьләр. №4

Гариф Р. Ак манара. Шигырьләр. №3

Гыйззәтуллина Ф. Милли моң. Шигырьләр. №9

Гыйләҗев И. Татарның нәкъ үзе кебек. Шигырьләр. №2

Җамалетдинова Ф. Өр-яңа әкият. Шигырьләр. №3

Закир М. Көяшлы төн. Шигырьләр. №12

Зәйдулла Р. Сәер сөю сурәте. Шигырьләр. №9

Зыялы С. Тылсым. Шигырьләр. №6

Зыятдинова Ф. Тынма, җаным. Шигырьләр. №3

Зөлфәт. Күктән күпме йолдыз карап тора. Шигырьләр. №2

Идиятуллин Р. Дүртенче кыш. Шигырьләр. №6

Исхаков Ә. И гомер агышлары. Шигырьләр. №6

Корбан Р. Бишек җыры. Шигырьләр. №9

Левадная О. Юка бозда миннән эз дә калмас. Шигырьләр. №3

Мингалим Р. Җаным чаңы. Шигырьләр. №4

Мирза М. Киек каз юлында. Шигырьләр (М. Әгъләмнең кереш сүзе белән). №1

Морат Г. Туган йортта кабат туам мин. Шигырьләр. №5

Мөдәррисова Х. Миндә-син, һәм бездән-җыр калыр. Шигырьләр. №4

Низами Р. Вакыт агачы. Шигырьләр. №3

Низами Р. Азатлык төме. Шигырьләр№8

Рәфыйков Б. Хәтер мизгелләре. Шигырьләр№5

Рахман Р. Ялгышканмын... Шигырьләр. №5

Рәхимова Б. Болгарыма барам әле. Шигырьләр. №9

Рәшит Ә. И заман! Шигырьләр. №10

Садә Г. Галәм «модуле». Шигырьләр. №12

Сафина Н. Яшел уй—бөре очында. Шигырьләр. №7

Синугыл Ә. Фәрдләр. №10

Сирай Д. Утырып кына яңгыр ява... Шигырьләр. №12

Солтан Ф. Уйлар, юллар. Шигырьләр. №8

Фәйзи Ә. Тышта яз. Шигырьләр№3

Фәйзуллин Р. Яңа шигырьләр. №3

Фатыйхов В. Дүртьюллыклар. №2

Хәлим А. Кечке жайдак. Шигырьләр. №1

Шәрифуллина Э. Ел әйләнә гүзәл булу. Шигырьләр. №10

Юзеев И. Кәккүккә гомерләр юрыймын. Шигырьләр. №1

Янсуар Л. Без, ахры, өметләр яшендә. Шигырьләр. №8

Яруллин Ф. Юлым илтә һаман тирәнгә. Шигырьләр. №2

## ТАТАР ХИКӘЯЛӘРЕ ХӘЗИНӘСЕННӘН

Мөхәммәтшин Г. Ике әби бәрәңге ала... №12

## ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ

Зәйнашева Г. Нәрсә булды безгә? Трагедия. №1

## ӘДӘБИ МИРАС

Әхмәтова-Урманче Ф. Документларның да үз язмышлары. №9

Идегәй. Татар халык дастаны. №9

Хәсәнов М. Бичура җиңги. Хикәя. №3

## ПУБЛИЦИСТИКА

Гариф Н. Үткәннәргә сәяхәт. Юльязма№4

Гариф Н. Авылым кайтавазы. №9

Гамбәр Н. Әткәй белән сөйләшү. №7

Мушинский Ә. Җан авазы. №2

Хәлим А. Кырымда күргәннәрем. №№5,6

Хәлиуллин Й. Дипломат язмалары. №№10-12

## ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Акмал Н. Шигырьне сагыну. №11

Гаташ Р. Шагыйрь турында замандашлары. №10

Гыйльманов Г. Такташка кайту. №2

Гыймранова Д. Театрга гашыйк булыгыз! №2

Зарипов Р. Кашка тәкәме, кәҗә тәкәсеме? №9

Заһидуллина Д. Яңа дулкында. №1

Заһидуллина Д. Тәнкыйтьсез үсеп булмас. №8

Зәйдулла Р. Куркытмагыз кошлар авазын (2002 ел шигъриятенә бер караш). №7

Латыйфи Ф. 2002 ел прозасына бер караш. №5

Мәхмүтов Х. Шигъриятнең тирән тамырлары. №10

Поварисов С. Акыл һәм хис дулкыны (Роберт Миңнуллин публицистикасына бер караш). №9

Рахмани Р. Шагыйрәнең язмыш келәме. №4

Сверигин Р. Аны беләбезме? (Фәнис Яруллинга 65 яшь тулу уңаеннан) №2

Тарихыбыз тулымы? («Татар әдәбияты тарихы»ның VI томы басылып чыгу уңаеннан). №5

Фәтхрахманов Р. Йөрәкнең җеназасы. №11

Шәрәфиев Р. «Хакны әйтүчеләр илдә бер». №8

## ҮТКЕН МӘСЬӘЛӘ

Латыйфи Ф. Тоталитаризм шәүләсе. №1

## ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫ

Миңнегулов Х. Урта гасыр татар әдәбияты. №7

Миңнегулов Х. Сулмас гөлләрнең берсе. (Котбның «Хөсрәү вә Ширин» әсәре язылуга 660 ел) №1

## ФӘН

Бубый Г. Кульязма әсәрләрдән үрнәкләр. №11

Галиев Б. «Төсле тоемлау»-могҗизамы, әллә гадәти бер «Күз буумы?». №6

Мәхмүтова А. Габдулла Бубыйның язма мирасы. №11

Мәхмүтов Х. Халык афоризмнарында магия һәм яшерен тел эзләре. №2

Рамазанова Д. Ишәле авылы җырлары турында. №9

Сафина Г. Татар шигъриятендә синестезия күренешенә кайбер мисаллар. №6

Урманче Ф. «Олыгайгач, бер дога» («Борынгы миф һәм бүгенге шигырь» циклыннан: Рәдиф Гаташ иҗаты турында). №4

Хисамов Н. Өч халыкның өч шагыйре. №5

Шәмсутова А. М. Мәһдиев иҗатына бер караш. №12

Шәфигуллина Р. XX гасыр татар әдәбиятында йорт-нигез образы һәм милли эстетика. №10

## ТАРИХ

Мәрданов Р., Һадиев И. Әгерҗе төбәге тарихы. №9

## ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫ–ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ

Мөслимов Ф. Истанбулда әдәбият көннәре. №7

Шестинский О. Җирәнчәч. Хикәя. №12

## ДӨНЬЯ ӘДӘБИЯТЫННАН ҮРНӘКЛӘР

Кристи А. Гаепләүче шаһит. Хикәя. №3

Шагыйрьҗан Л. Япон шигъриятенең асылташлары. №7

Япон танкалары (Борынгы җыентыклардан). №7

## ЮБИЛЕЙЛАР

### КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫНЫҢ 200 ЕЛЛЫГЫНА

Михайлова С. Поляк зыялылары Казанда. №8

ГАЯЗ ИСХАКЫЙНЫҢ ТУУЫНА 125 ЕЛ

Мөхәммәтшин З. Гаяз Исхакыйның сәяси карашлары. №2
Исхакый Г. Дөнья әхвале. №2

ӘХМӘТ ФӘЙЗИНЕҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Фәйзи Ә. Төрле еллардан шигырьләр. №3

ГАДЕЛ КУТУЙНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Кутуй Г. Сагыну. Нәсер. №11

«МӘГАРИФ» ЖУРНАЛЫНА 90 ЕЛ

Шәрифуллин Ф. Үткән елларга бер күз салсак. №3

ЛӘБИБӘ ИХСАНОВАГА 80 ЯШЬ

Гыймадиев А. Балачакның тугры илчесе. №8
Ихсанова Л. Җан газабы. Хикәя. №8

МӘХМҮТ ХӨСӘЕННЕҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Кәримов К. Йөремсәк командир. №4

РИЗА ШӘФИГӘ 80 ЯШЬ

Редакция котлавы. №2

АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВНЫҢ ТУУЫНА 75 ЕЛ

Латыйфи Ф. Юксыну. №2
Гыйләҗев А. Үги ана яфраклары. №2

ЛОКМАН ЗАКИРОВКА 75 ЯШЬ

Редакция котлавы. №2

МИРФАТЫЙХ ЗӘКИЕВКӘ 75 ЯШЬ

Асылгәрәев Ш. Үсеш баскычлары. №8

НУР ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНГА 75 ЯШЬ

Исламов Р. Нур аганың нурлы эшләре. №6

РӘИС ДАУТОВКА 75 ЯШЬ

Хәмидуллин Л. Осталарның остазы. №3

САИМӘ ИБРАҺИМОВАГА 75 ЯШЬ

Юзеев И. Ачылган чәчәк кебек. №3

ШӘҮКӘТ ГАЛИЕВКӘ 75 ЯШЬ

Корбан Р. Югары бәяләнгән иҗат. №11
Галиев Ш. Һаман күкләр якламас, җирдә үзең йоклама. №11

ЗАҺИД ФӘЙЗИГӘ 70 ЯШЬ

Редакция котлавы. №2

ЗӘКИ ЗӘЙНУЛЛИНГА 70 ЯШЬ

Зәйнуллин З. Йәнбикә. Яшьлек хатирәсе. №7
Рәшит Ә. Көрәшче. №7

ИЛДАР ЮЗЕЕВКА 70 ЯШЬ

Поварисов С. Моң эчендә асылташ. №1
Шагыйрь турында каләмдәшләре. №1

МАРС ШАБАЕВКА 70 ЯШЬ

Фәйзуллин Р. Өлкәнебез. №7
Шабаев М. Җиллә жырлый жикән камыш. №7

ТАҺИР НӘБИУЛЛИНГА 70 ЯШЬ

Сафин Ф. Үткәнне киләчәккә ялгаучы. №3

РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИНГА 60 ЯШЬ

Фәйзуллин Р. Һәр елдан-берничә юл. Шигырьләр (Кереш сүз белән). №8

ФЛҮС ЛАТЫЙФИГА 60 ЯШЬ

Заһидуллина Д. Милли реализм юлыннан. №6

РӘФИКЪ ЮНЫСКА 60 ЯШЬ

Акъегет Р. Көндезге йолдызлар. №3

МӨДӘРРИС ВӘЛИЕВКӘ 50 ЯШЬ

Истәлекләр. Хатлар. Документлар. №5

ЛЮЦИЯ ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНАГА 50 ЯШЬ

Редакция котлавы. №11

**КОРЪӘН ТАТАР ТЕЛЕНДӘ**

37-Саффат (Сафлар) сүрәсе. №1
38-Сад (Даут) сүрәсе. №2
39-Зүмәра (Халык өере) сүрәсе. №2
40-Мөэмин (Мөэмин) сүрәсе. №3
41-Фуссиләт (Аңлатылды) сүрәсе. №4
42-Шура (Киңәш) сүрәсе. №6
43-Зухруф (Алтын хәзинә) сүрәсе. №7
44-Духан (Төтен) сүрәсе. №7
45-Җасия (Тезләнү) сүрәсе. №7
46-Әхкаф (Ком тавы) сүрәсе. №8
47-Мөхәммәд (Мөхәммәд) сүрәсе. №8
48-Фәтех (Җиңү) сүрәсе. №9
49-Хөҗурәт (Бүлмәләр) сүрәсе. №10
50-Каф (Каф) сүрәсе. №10
51-Зарият (Таратучылар) сүрәсе. №10
52-Тур (Тау) сүрәсе. №10
53-Нәҗем (Йолдыз) сүрәсе. №10
54-Камәр (Ай) сүрәсе. №11
55-Рахмән (Рахман) сүрәсе. №11
56-Вакыйга (Вакыйга) сүрәсе. №12
57-Хәдид (Тимер) сүрәсе. №12
58-Мүҗадәлә (Бәхәс) сүрәсе. №12
59-Хәшер (Сөреп куу) сүрәсе. №12
60-Мүмтәхинә (Хатын-кызны сынау) сүрәсе. №12
61-Саф (Рәт) сүрәсе. №12
62-Җомга (Җомга) сүрәсе. №12
63-Монафикъләр (Икейөзлеләр) сүрәсе. №12
64-Тәгабүн (Алдану) сүрәсе. №12

**СӘНГАТЬ**

Арсланова Ф. Хор сәнгатендә өлеше зур. №11
Гыймранова Д. Түгәрәк дөнья уртасында. №9

Дәрзаман Җ. Арсланнар кирәк булган икән. №7
Закир М. Җан аһәне. №6
Кадыйрова Ф. Сәхнә сәнгатенә бер караш. №1
Монасыйпов Ш. Батырлыкка сусау. №3
Солтанова Р. Бакый Урманче-сәхнә бизәүче остаз. №4

## ХӘТЕР

Әмирханова Р. Абыем турында истәлекләр (Р. Әмирханның кереш сүзе белән). №7
Гыймазетдинов М. Туган якның китмәс кошлары без (Н. Гамбәрнең кереш сүзе белән). №12
Надиров И. Рәхимов С. Мәшһүр төрек-татар тарихчысы. №4
Нуруллина Р. Томаннарга еллар күмелде. №№5,6
Фәйзуллин Р. Авылдаш. №10
Шабай М. Кыр казы (Мин Шабайның тууына 90 ел). №4

## ХАЛЫК ИҖАТЫ

Закирова И. Казанлыга сәяхәт. №12

## КИТАП КҮЗӘТҮ

Бәшир Ф. Кеше күңеле–карурман. №3
Вәли-Баржылы М. Мулла абзый китап яза. №6
Вәли-Баржылы М. Тәкъдир юллары. №12
Гарипова Ф. Хәзинәдә-алтын бөртекләре. №3
Гыйлаҗев Т. Онытгырылган әсәрләр. №10
Заһидуллина Д. Татар әдәбияты шигърияттән башлана. №4
Латыйфи Ф. Тылсымлы ачкыч. №10
Мөхәммәтшин З. Кальбеңдә ни сер бар?№11
Рамазанова Д. Үзәктә-зур мәсьәлә. №5
Сафин Ф. Гамьле гамәлләр кылыйк! №12
Сверигин Р. Нурзилә новеллалары. №6
Хисамова Ф. Әдәби телебезнең кыйммәтле ядкяре. №8
Шәрипов Ә. Төрки сүз сәнгате кайлардан башлана? №2

## ЯҢА ИСЕМНӘР

Әхмәтҗанова С. Оч ирекка, җырым. Шигырьләр. №11
Бәйрәмова Г. «Көзге моң» романсын тыңлаганда. Шигырьләр. №11
Гарифуллина Р. Хәлләремне белим дисәң... Шигырьләр. №11
Гыйбадуллина Л. Хыял бизәкләре. Шигырьләр. №11
Кәшфиева Л. Тәтешле ягы. Шигырьләр. №11
Мөхияр Р. Ике ут. Шигырьләр. №11
Фазлетдинов И. Эх, егылмас идем... Шигырьләр. №11

## НӘНИЛӘР ДӨНЬЯСЫ

Нуретдинова А. Бөркетле кыя. Әкият. №4

## ЮМОР-САТИРА

Баттал Ф. Хикәяләр. №4
Галиев М. Азнакай чалымнары. №11
Дусай М. Алай түгел, болай ул... №2
Зарипов Р. Тотынырга салам бармы? №7
Лерон Л. Аулак почмак. Шигырьләр. №6
Нәҗмиев Т. Саба мәзәкләре. №10
Шәрипова Р. Шул кирәк аларга! (Сәхнә монологы). №9

## УКУЧЫ СҮЗЕ

Болгарская Ф. Юк, өметләр өзелмәгән иде шул. №10
Габдерәфыйков Р. Рәхмәттән соң кечкенә төзәтү. №10
Исхаков М. Милаев Ф. №2
Мөлеков Ә. Тормышыма ямь бирә. №8
Ногманов Н. №1
Хуҗин Ф. №4

## БЕРЛЕКНЕҢ ЯҢА ӘГЪЗАЛАРЫ

Сабиров Ирек. №2
Якупова Венера. №2
Гыйсметдин Дамир. №3
Чурагулов Рамил. №3
Таңчулпан (Чулпан Әхмәтова). №5
Хисмәт Рифкать. №5
Мөхиярова Рәзинә. №6
Фәхретдинов Равил. №6
Габделхакова Рәмзия (Юнысова). №8
Кәшфи Ләйсән. №9
Дәүләтов Зөфәр. №12

## БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

Нәҗип Думавиның тууына 120 ел. №5
Гариф Галиевнең тууына 100 ел. №5
Мөхәммәт Гайнуллинның тууына 100 ел. №8
Риза Ишморатның тууына 100 ел. №10
Әминә Бикчәнтәеваның тууына 90 ел. №2
Мөхәммәт Садриның тууына 90 ел. №5
Сөббух Рәфыйковның тууына 90 ел. №7
Тихон Журавлевның тууына 90 ел. №8
Шаһиморат Зәйнинең тууына 90 ел. №3
Хәкимҗан Халиковның тууына 70 ел. №2

## ТЫШЛЫКТАГЫ СУРӘТЛӘР

Шаһиева Р. Ханнар хәзинәсе ядкаре. №5

## ЛАТИН ИМЛАСЫНДА БАСЫЛГАН ӘСӘРЛӘР

Госманов М. Картлар һәм... кызлар. №6
Лерон Л. Үртәмешләр. №1
Садри М. Мин Берлинны алдым. Шигырьләр. №5
«Казан утлары» архивыннан №№1-12
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. №№1-12

## Ictimagi-mədəni tormışıbızdan
## Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

### ТАҖИ ГЫЙЗЗӘТКӘ ҺӘЙКӘЛ

11 ноябрь көнне Әгерҗенең яңартылган вокзалы мәйданында күренекле татар әдибе Таҗи Гыйззәткә һәйкәл ачылды.

Һәйкәлне ачуга багышланган тантаналы митингта Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев, Удмуртия Республикасы Президенты Александр Волков, ТР Премьер-министры Рөстәм Миңнеханов, "Россия тимер юллары" ААҖ президенты Геннадий Фадеев, Әгерҗе районы хакимияте башлыгы Фәрит Габбасов һ. б. катнашты.

Митингта чыгыш ясап, Минтимер Шәймиев күренекле татар язучысы, драматург һәм режиссер Таҗи Гыйззәтнең татар халкы мәдәни мирасына бәя биреп бетергесез өлеш керткәнлеген искәртте. Әгерҗе җирендә туган Т. Гыйззәтнең әсәрләре иң мәгълүм сәхнәләрдә күп дистә еллар дәвамында куелып килде, алар милли драматургиянең "алтын" фондына әверелде. М. Шәймиев үлемсез булып әверелгән күп кенә пьесаларны санап узды: "Наемщик", "Башмагым", "Ташкыннар"...

Татарстан Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин һәйкәл ачуны Т. Гыйззәт якташларының татар драматургиясе һәм сәхнә сәнгатенә нигез салучыларның берсенә ихтирам билгесе булуын әйтте. Тантаналы митингта язучының улы—философия фәннәре докторы, профессор Казбек Гыйззәтов республика һәм район җитәкчелегенә рәхмәт белдереп чыгыш ясады.

2005 елда Таҗи Гыйззәтнең тууына 110 ел тулу билгеләп узылачак. Минтимер Шәймиев белдерүенчә, бу вакыйга киң колач белән үткәреләчәк.

### ӘЛМӘТ ЯЗУЧЫЛАРЫ БӘЙРӘМЕ

Әлмәт язучылар оешмасы төзелүгә 40 ел тулды. Шушы уңайдан нефтьчеләр башкаласының Татар дәүләт драма театры бинасында "Озын юллар, җырлы еллар" дип исемләнгән юбилей тантанасы булды. Анда Әлмәт районы һәм шәһәре хакимияте башлыгы Ришат Әбүбәкеров, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин, Татарстанның халык шагыйре, "Казан утлары" журналының баш мөхәррире Равил Фәйзуллин, шагыйрә Клара Булатова, Чаллы язучылар оешмасы җитәкчесе Вахит Имамов һ. б.лар тәбрикләү сүзе белән чыкты. Театрга җыелган тамашачылар Казаннан бәйрәмгә махсус килгән каләм әһелләре, галимнәр, газета һәм журналларның баш мөхәррирләре, нәшрият директорлары—Мөсәгыйт Хәбибуллин, Флера Гыйззәтуллина, Хатип Миңнегулов, Шәһидә Максудова, Рәфкать Кәрами, Марсель Галиев, Зиннур Мансуров, Рашат Низами, Җәүдәт Дәрзаман, Данил Салихов, Рәдиф Сәгъди, Мөдәррис Вәлиев, Дамир Шакиров һ. б. ларны алкышлап каршылады. Юбилей тантанасында Азнакай, Мөслим, Сарман һ. б. төбәкләрдән, шулай ук Башкортстаннан килгән язучылар да катнашты.

Әдәби-музыкаль кичәдә Әлмәт төбәге язучылары иҗат иткән әсәрләр яңгырады, спектакльләрдән өзекләр күрсәтелде. Аларны драма театры артистлары, үзешчән коллективлар башкарды. Әлмәт язучылар оешмасы җитәкчесе Нур Әхмәдиев кунакларга ихлас рәхмәтен белдерде.

### РЕСПУБЛИКААРА ЯШЬ ЯЗУЧЫЛАР БӘЙГЕСЕ

17-19 октябрьдә "Иделем акчарлагы" республикаара яшь язучылар бәйгесенең йомгаклау өлеше булып үтте. Татарстан Язучылар берлеге, республика Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы, "Идел" яшьләр үзәге тарафыннан оештырылган тантанага төрле төбәкләрдән дистәләрчә өметле яшь каләм ияләре чакырылган иде. Татарстан вәкилләреннән тыш, биредә Мари-Элдан, Курган өлкәсеннән, Удмуртиядән, Владимир һәм Тольятти шәһәрләреннән килгән кызлар, егетләр дә бар иде.

Яшь язучылар алдында Татарстан Министрлар Кабинеты Аппаратыннан бүлек начальнигы Ким Миннуллин, Бөтендөнья Татар Конгрессы Башкарма комитеты рәисе урынбасары Дамир Гыйсметдинов, "Идел" яшьләр үзәгеннән директор вазифаларын башкаручы Игорь Кнайнов, "Мәгариф" милли нәшрияты директоры Мөдәррис Вәлиев, Татарстан китап нәшриятының бүлек мөдире Рафис Корбанов, "Иделем акчарлагы" бәйгесенең жюри рәисе, "Мәдәни җомга" газетасының баш мөхәррир урынбасары Газинур Морат һ. б. чыгыш ясап, аларга үзләренең иң изге теләкләрен җиткерделәр, файдалы киңәшләр бирделәр. "Мәдәни җомга" газетасының баш мөхәррире Зиннур Мансуров, "Идел" журналының баш мөхәррире Рашат Низамиев, "Ялкын" журналының әдәбият-сәнгать бүлеге мөдире Фәйрүзә Мөслимова, "Салават күпере" һәм "Сәхнә" журналларының җаваплы сәркатибе

Ләбиб Лерон һ. б. яшь каләмдәшләрен газета-журнал редакцияләре белән тыгыз бәйләнештә торырга өндәделәр, аларның кызыклы язмаларына мәйданны һәрчак түрдән бирәчәкләренә ышандырдылар.

Икенче көнне "Чишмәкәй" лагерында яшь авторларның ел буе барган иҗади бәйгесенә йомгак ясалды. Бу юлы "ГРАН-ПРИ"га Актаныш кызы Лилия Гыйбадуллина (шигърият буенча) һәм Мөслим районыннан килгән Гөлчәчәк Хафизова (проза) лаек булды.

Чәчмә әсәрләр язучылар арасында лауреатлар булып Ләйсән Мөгътәсимова (Мамадыш районы), Лилия Закирова (Буа), Илгиз Зәйниев (Аксубай), тезмә әсәрләр иҗат итүчеләрдән Эльмира Нигъмәтҗанова (Удмуртия, Ижау каласы), Ландыш Әбүдәрова һәм Ленар Шәехов (икесе дә Актаныштан) табылды.

Болардан тыш, Владимир каласыннан килгән өметле яшь шагыйрә Аделя Батыршинага, Курган өлкәсенең Сафакүл авылы егете, прозаик Вадим Исламетдиновка, Мари-Элнең Бәрәнге районындагы Куян авылы кызы шагыйрә Лилия Сәфәрхановага, Тольятти шәһәрендә яшәп иҗат итүче Гүзәл Нәфигуллина белән Марс Хөснуллинга махсус бүләкләр тапшырылды.

## ҖИҢҮЧЕЛӘР АЧЫКЛАНДЫ

10 октябрьдә Татарстан Язучылар берлегенең Г. Тукай исемендәге клубында "Каурый каләм" иҗат конкурсына йомгак ясалды. Республикабызның Язучылар берлеге һәм "Сабантуй" газетасы инициативасы белән оештырылган балалар һәм яшүсмерләрнең ике ел дәвамында барган бу конкурсында 25 яшь каләм иясенең әсәрләренә бәя бирелде, җиңүчеләргә бүләкләр тапшырылды. Йомгаклау тантанасында Язучылар берлеге вәкилләре—рәис урынбасарлары—Ш. Мостафин, Г. Гыйльманов, "Сабантуй" газетасы вәкиле—Татарстанның халык шагыйре И. Юзеев катнашты.

## АЛИШ ТУГАН АВЫЛДА

Каһарман әдип Абдулла Алишның тууына 95 ел тулуга багышлап, аның туган ягында—Спас төбәгенең Көек авылында зур тантана булып үтте. Анда районадгы мәктәпләрнең татар теле һәм әдәбияты укытучылары, мәгариф хезмәткәрләре, укытучылар җыйналган иде. Казаннан Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин, аның урынбасары Шаһинур Мостафин, Казанның 55 нче мәктәбендә А. Алиш музеен оештыручы, аның бүгенге көндәге җитәкчесе Илсөяр Сөнкишева, "Мәгариф" нәшрияты директоры, Муса Җәлил премиясенең быелгы лауреаты Мөдәррис Вәлиев, "Салават күпере" журналы мөхәррире Ләбиб Лерон, Татарстан китап нәшриятының бүлек мөдире Рафис Корбанов, Татарстанның халык артисты Мингол Галиев, язучы Җәүдәт Дәрзаман килделәр. Кунакларны район чигендә Спас районы хакимияте башлыгының беренче урынбасары Рафыйк Игламов һәм башка җитәкчеләр каршы алды. Тантана Көек авылы мәдәният йортында һәм мәктәптә барды. Абдулла Алиш һәйкәленә чәчәкләр куелды, митинг булды. Быелгы Абдулла Алиш премиясенә лаек булган лауреатлар—Илсөяр Сөнкишева һәм Рафис Корбановка дипломнарны Фоат Галимуллин тапшырды. Мәктәп коллективы, район хакимияте әлеге тантананы оештыруга зур тырышлык куйган. Көек авылы мәктәбенә А. Алиш исеме бирелде.

## ШАГЫЙРЬНЕ ХАЛЫК ОЛЫЛАДЫ

***

26 сентябрьдә Татарстан Республикасы милли музеенда халык шагыйре Равил Фәйзуллин белән очрашу булды. Шагыйрьнең 60 яшьлек юбилеена багышланган, "Шагыйрь күңелендә ниләр бар?" дип исемләнгән бу әдәби җыенга башлыча яшьләр килгән иде. Кичәдә юбиляр үз шигырьләрен укыды, күп сорауларга җаваплар бирде. Очрашуга шагыйрь белән бергә күренекле язучы-публицист Рафаэль Мостафин, "Мәдәни җомга" газетасының баш мөхәррире, шагыйрь Зиннур Мансуров килгән иде. Алар Равил Фәйзуллин иҗаты турында үз фикерләрен әйттеләр. Очрашуга килүчеләр шагыйрьнең яңа җыентыклары һәм аның турында чыккан китаплар белән дә таныша алдылар.

***

31 октябрьдә С. Сайдашев исемендәге Зур концерт залында Татарстанның халык шагыйре, Г. Тукай исемендәге Дәүләт, М. Җәлил исемендәге республика премияләре лауреаты, "Казан утлары" журналының баш мөхәррире Равил Фәйзуллинга 60 яшь тулуга багышланган юбилей тантанасы булды.

Шагыйрьнең иң күренекле әсәрләрен үзәккә алып оештырылган әдәби-музыкаль кичә мәдәниятебезнең зурлыгын чагылдыручы чын шигърият бәйрәменә әверелде. Әдәбият-сәнгатебезне әтрафлы белүче Илбашыбыз Минтимер Шәймиевнең, сайлау алды ялында булуына карамастан, сәхнә түренә күтәрелүе иҗат кичәсенең якты рухын тагын да күтәреп җибәрде. "...Шагыйрьнең ничек фикер йөрткәнен, фикер мәгънәсен беләсең килсә, аның шигырьләрен ешрак тыңларга кирәк,— диде ул. —Анда барысы да әйтелгән...

Ишек катындамы, түрдәме,
урыным минем—
вөҗданлы кешеләр янында,—
дип тикмәгә язмаган шагыйрь".

Журналистлар белән очрашу вакытында Президент М. Шәймиев шагыйрь иҗатына янә югары бәя бирде: "Равил Фәйзуллин— чын мәгънәсендә халык шагыйре, һәм ул бу югары исемне аклый да. Аның совет чорында язганнары да, кичә һәм бүген язганнары да бердәй дәрәҗәдә талантлы. 70 нче елларда ул чактагы зур ил халыклары татар шигърияте белән якыннан танышсын өчен аның буыны бик күп көч куйды".

Юбилей кичәсендә Татарстан мәдәният министры Илдус Тарханов, Президент исеменнән, Равил Фәйзуллинга Татарстан Республикасының Мактау грамотасын һәм истәлекле бүләк тапшырды.

Кичә барышында шагыйрьне олы бәйрәме белән Татарстан Дәүләт Советы, Язучылар берлеге һәм Татар ПЕН-үзәге исеменнән язучы Туфан Миңнуллин, юбилярның якташлары исеменнән Балык Бистәсе районы хакимияте башлыгы Равил Хәйруллин, шулай ук Казан һәм Чаллы шәһәрләре хакимияте башлыгы урынбасарлары Әлфия Тутаева, Фәйрүзә Мостафина, "Татнефть" исеменнән шагыйрь Нур Әхмәдиев, Красноярск һәм Мәскәүдән килгән күренекле әдипләр Роман Солнцев, Рауль Мир-Хәйдәров һ. б. лар тәбрикләде.

Кичәдә яңгыраган шигырьләрне, поэмадан өзекләрне, җырларны республикабызның танылган артистлары һәм музыкантлары башкарды. Фойеда юбилярның тормышына һәм иҗатына багышланган махсус күргәзмә эшләде.

* * *

14 ноябрьдә халык шагыйре Равил Фәйзуллинның 60 яшьлегенә багышланган юбилей тантаналарының дәвамы булып әдәби-музыкаль кичәләр Балык Бистәсендә һәм шагыйрьнең туган авылы Балтачта (Юлсубино) да үткәрелде. Әдәбият бәйрәме булып үткәрелгән бу тантаналар Казанда югары дәрәҗәдә узган кичәнең дәвамы булып яңгырады. "Шагыйрьне беләсең килсә, аның Ватанын барып күр" дигән тәгъбир бу очракта бик урынлы булыр: бик зурладылар шагыйрьне якташлары. Юлсубино урта мәктәбенә Равил Фәйзуллин исемен бирделәр, район үзәгендә яңа төзелгән бер урам шагыйрь исемен йөртәчәк. Авыл мәктәбе укучылары кунакларга шагыйрь сүзләре чигелгән кульяулыклар бүләк иттеләр. Районның бөтен мәктәпләре шагыйрь иҗатына багышланган махсус кульязма газеталар чыгарган иделәр.

Балык Бистәсе Мәдәният йортында узган кичәдә, районның җитәкче даирәләре һәм зыялылары белән бергә, Казаннан килгән кунаклар да бар иде: Татарстан премьер-министр урынбасары З. Вәлиева, Язучылар берлеге рәисе Ф. Галимуллин, Рәссамнар берлеге рәисе А. Абзгильдин, "Мәдәни җомга" газетасының баш мөхәррире З. Мансуров, язучылар Г. Рәхим, М. Галиев, И. Сирматов, Татарстан радиосының өлкән редакторы Р. Фәйзуллин (Акъегет), шагыйрьнең беренче шигырьләрен бастырган язучы-журналист Р. Гарипов һ. б. Юбилярны Балык Бистәсе районы хакимияте башлыгы Р. Хәйруллин, хуҗалык җитәкчеләре, интеллигенция вәкилләре котлады. Мәдәният йорты фойесында Равил Фәйзуллинның тормыш юлы һәм иҗатына багышланган зур күргәзмә дә оештырылган иде.

## ӘДИПНЕҢ ИҖАТ БӘЙРӘМЕ

Күренекле язучы һәм публицист Флүс Латыйфига 60 яшь тулу уңаеннан Мөслим районы хакимияте ел дәвамында зур бәйрәм чаралары уздырды. Китапханәләрдә язучы әсәрләреннән махсус стендлар булдырылды, аның әсәрләре буенча укучылар конференцияләре, кичәләр үткәрелде. Район мәгариф бүлеге исә барлык мәктәпләргә дә язучының әле күптән түгел генә басылып чыккан өч томлык "Сайланма әсәрләр"ен алып бирде.

18 октябрь бәйрәмнең югары ноктасына әверелде. Якташлары белән очрашуга Флүс Латыйфи белән бергә аның каләмдәш дуслары— Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин, "Казан утлары" журналының баш мөхәррире, Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин, Татарстан мәдәният министры урынбасары Илфак Ибраһимов, якташлары—күренекле шагыйрь Зөлфәт, "Яңа гасыр" радиосының баш мөхәррире, шагыйрә Шәмсия Җиһангирова, "Татарстан" телерадиокомпаниясенең әдәби тапшырулар мөхәррире, язучы Индус Сирматов кайтты. Аларга Чаллыдан "Мәйдан" журналының баш редакторы, шагыйрь һәм прозаик Факил Сафин, Чаллы язучылар оешмасы рәисе, прозаик һәм тарихчы Вахит Имамов, Мөслимдә яшәп иҗат итүче әдип Фоат Садриев кушылды. Әдипләр Мөслимдәге 1 нче урта мәктәптә һәм Салавыз Мухан урта мәктәбендә укучылар һәм укытучылар белән очраштылар, Мөслимдә туып-үскән язучы Ф. Латыйфи иҗаты хакында тәфсилле әңгәмәләр үткәрделәр, күпсанлы сорауларга җавап бирделәр.

Кичен район мәдәният йортында әдәби-музыкаль кичә булды. Үзешчән сәнгать осталары юбилярның әсәрләре буенча сәхнә күренешләре, концерт әзерләгәннәр иде.

—Мөслим ягы—чын мәгънәсендә талантлар ягы. Бүгенге көндә татар әдәбиятының арка терәген тәшкил итүче Флүс Латыйфи кебек әдипләребез белән без хаклы рәвештә горурланабыз,— диде кичәне ачып җибәргәндә район хакимияте башлыгы Ришат Хәбипов. — Прозада аның белән янәшә Фоат Садриев һәм Факил Сафин, шигърияттә Зөлфәт һәм Харрас Әюпов, Наис Гамбәр һәм Шәмсия Җиһангирова, балалар әдәбиятендә Мөҗәһит Әхмәтҗанов кебек якты талантлар иҗат итә. Әдәби тәнкыйть, әдәбият белеме өлкәсендә Флүн Мусин, Марсель Бакиров, Дания Заһидуллина исемнәре күпләргә мәгълүм.

Аның фикерен шагыйрь Равил Фәйзуллин

тагын да үстереп җибәрде:

—Флүс Латыйфи бүгенге татар прозасының иң күренекле вәкилләренең берсе булу белән бергә, татар прозасы чисталыгы сагында торучы каләм әһеле дә,— диде ул. —"Казан утлары" журналының баш мөхәррире урынбасары буларак, һәрбер чәчмә әсәр иң беренче чиратта аның кулына килеп керә, аның фатихасын алмыйча дөньяга чыкмый. Элеккерәк елларда әдәбиятның нигез ташын Арча төбәгеннән чыккан олугларыбыз тәшкил итә иде. Соңрак мәйданга Балык Бистәсе районы талантлары килеп керде. Ә бүгенге көндә Мөслим ягыннан чыккан язучылар әдәбиятның зур көчен тәшкил итә. Тел чисталыгын, әдәбиятның сафлыгын алар гарантияли. Алда саналган исемнәр—шуның ачык мисалы. Аларга яшь алмаш үсеп килүе тагын бер куаныч.

Кунаклар һәм чыгыш ясаган әдәбият сөючеләр мондый бәйрәмнәр ешрак үткәрелсен иде, дигән фикер белдерделәр. Чөнки Мөслим ягы талантлары моңа лаек. Якташлар алдында иҗади хисап тоту—һәр язучы өчен олы мәртәбә һәм җаваплы гамәл ул.

## ШАГЫЙРЬ ЛАЕКЛЫ БӘЯСЕН АЛДЫ

Башкортстанда яшәп иҗат итүче татар шагыйре Марат Кәримовка Башкортстанның халык шагыйре дигән мактаулы исем бирелде. Марат ага Кәримовның бу исемгә ирешүе Башкортстандагы татарлар, гомумән, бөтен татар халкы өчен куанычлы вакыйга.

М. Кәримов соңгы елларда Башкортстан Язучылар берлегенең татар язучылары берләшмәсен житәкли. Аның тырышлыгы белән күп кенә татар иҗатчылары әдәбият мәйданына килде һәм танылу алды. Өлкән яшьтә булса да, татар язучылары берләшмәсе эшен гөрләтеп алып бара әле ул. Районнарда әдәби кичәләр оештыра, яшь һәм башлап язучыларның җыентыкларын әзерләү өчен күп көч сала. Башкортстанның халык шагыйре исеменә лаек булуын ул үзе бик тыныч кабул иткән. "Беркайчан да мактаулы исемнәр дип иҗат итмәдем, хезмәтемне шулай югары бәяләүләре өчен зур рәхмәт",— ди ул.

## КАЛӘМ ИЯЛӘРЕ БҮЛӘК АЛА

Сәүдә-сәнәгать палатасында Татарстанда кече эшмәкәрлекне үстерү буенча "Без—урта сыйныф!" дигән журналистлар конкурсында җиңүчеләрне бүләкләү тантанасы узды. Каләм ияләре бәйгесендә катнашучыларны һәм җиңүчеләрне Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин һәм Премьер-министрның беренче урынбасары Р. Моратов котлады.

Ике номинациядә катнашу өчен республиканың 30 районыннан 46 газета редакциясе, 8 телевидение компаниясе гариза биргән иде. Жюри 747 язманы, 25 телепрограмманы карап тикшерде.

"Татарстанда эшмәкәрлекне үстерү проблемалары һәм перспективалары" дигән номинациядә басма массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләренә ике приз бирелде. Казан журналистлары арасында Венера Сабирова ("Банковская газета"), район журналистлары арасында Рөстәм Сабитов ("Зеленодольская правда") беренче урынны алды. Телевидениедә эшләүчеләр арасында шул ук номинациядә Рәмис Латыйпов җиңде ("Республика" программасы, "Эфир" телеканалы), ә "Эшмәкәрлектә шәхес" номинациясендә "Урта сыйныф" программасы белән Әнвәр Минһаҗев ("Татарстан" дәүләт телерадиокомпаниясе) беренче урынга лаек булды.

Җиңүчеләрне котлау тантанасында "Татмедиа" массакүләм коммуникация агентлыгы генераль директоры Марат Моратов катнашты.

## БОЛГАРЛАР КИНО ТӨШЕРӘ

Татарстанга Болгариядән тарихчы галимнәр һәм телережиссерлар бригадасы килде. Алар Идел буе Болгарстаны турында фильм төшерергә ниятли.

Тарихи чыганакларга караганда, төрки кабиләләрнең берсе булган болгарлар Дон һәм Азов буйларында яшәгән. 630 елларда хәзәрләр кысрыклавы астында аларның бер өлеше Дунайга китеп, хәзерге Болгариягә нигез салган, ә икенче бер өлеше якынча хәзерге Татарстан территориясенә килеп Идел буе Болгарстанын төзегән. Татарстан мәдәният министры урынбасары Рафаэль Вәлиев әйтүенчә, Болгариядә Идел буе Болгарстаны, аның көнкүреше, гореф-гадәтләре турында аз санлы тарихчы галимнәр генә белә икән. Әлеге фильмны төшерүнең максаты—Болгариянең киң җәмәгатьчелегенә бу мәгълүматны җиткерү. Эш барышында режиссерлар Кремльдә, Биләрдә, иске Казанда булды.

## ЭРОТ ЗАРИПОВ КҮРГӘЗМӘСЕ

10 октябрьдә Татарстан Рәссамнәр берлегенең Күргәзмәләр залында Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Эрот Зариповның тууына 65, иҗат эшчәнлегенә 50 ел тулуга багышланган зур шәхси күргәзмә ачылды.

Күргәзмәдә 120 дән артык әсәр куелган иде. Алар арасында 50 линогравюра, калганнары татар зыялыларына һәм язучыларына багышланган төсле портретлар.

Күргәзмәне Татарстан мәдәният министры Илдус Габдрахман улы Тарханов ачты. Казан шәһәре хакимияте рәисе урынбасары Әлфия Әмир кызы Тутаева Эрот Зариповның иҗатын хөрмәтләп Мактау Грамотасы тапшырды.

Татарстан Рәссамнәр берлеге идарәсе рәисе Абрек Әмир улы Абзгильдин рәссамның иҗат эшчәнлегенә югары бәя бирде һәм аңа республика хөкүмәтенең котлау телеграммасын укып тапшырды.

Күргәзмәдә рәссамның замандашлары: бер төркем язучылар, сәнгать әһелләре катнашты.

# ХУШЛАШУ СҮЗЕ



Озакка сузылган быелгы көзнең соңгы көннәрендә редакциябез авыр югалтуга дучар булды: җаваплы сәркәтип урынбасары вазифаларын башкаручы, озак еллар иңгә-иң торып эшләгән хезмәттәшебез **Тәслимә Гариф кызы Сибгатуллина** 15 ноябрьдә көтмәгәндә кинәт вафат булды.

1979 елның августыннан, Казан дәүләт университетының журналистика бүлеген тәмамлап килгәннән бирле, ул «Казан утлары»на тугрылыклы калды, бөтен язмышын, белемен һәм сәләтен, күңел җылысын журнал язмышы белән бәйләде. Озак еллар корректор булып эшләде, соңрак техник редактор итеп билгеләнде, соңгы вакытта җаваплы сәркәтип урынбасары вазифаларын башкара иде. Журналның үз вакытында, сәнгати һәм полиграфик яктан югары кимәлдә эшләнүендә аның хезмәте бәяләп бетергесез. Болардан тыш, редакция белән типография арасындагы гаять күпкырлы мөнәсәбәтләр кебек тавык чүпләсә дә бетмәслек четерекле эшне дә ул дистә еллар буе бер дә авырыксынмыйча башкарып килде, әдипләр белән дә, типография һәм нәшрият хезмәткәрләре белән дә уртак тел таба белде. Хезмәт юлы таныш булган кебек, тормыш юлы да күз алдыбызда. Үзе кебек үк тырыш һәм тыйнак Хәйдәр исемле егеткә кияүгә чыкты, бер-бер артлы малай белән кыз табып, күңел җылысын аларга багышлады, тәпле белем һәм милли тәрбия бирергә омтылып яшәде. Балалары Алмаз белән Гөлназ үсеп җитеп инде институтларда укый башлаганнар иде.

Зарлана белми иде Тәслимәбез. Сырхаулап, кәефсезләнеп торган чакларын хезмәттәшләренә, килгән-киткән кешегә сиздермәде. Йөзендә һәрчак елмаю, телендә һәрчак ягымлы сүз булды. Туган якларында – Алабуга районының Илмәт авылында көн күреп ятучы, инде туксанны куып баручы газиз әнкәсе янына печәнен, утынын әзерләшергә дә юк вакытын бар итеп кайтып килер иде. Бер үзенә өч йөкне тарту җиңел булмагандыр. Монысын да кеше үлгәч кенә аңлыйсың икән.

Сине юксынабыз, сагынабыз Тәслимә. Якты истәлегең күңелләребездә мәңге сакланыр.


*«Казан утлары» хезмәткәрләре*

## *Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Татар кызы. Рәссам **Әнвәр Сәйфетдинов** эше.
*Тышлыкның дүртенче битендә:* шагыйрь **Әнәс Исхаков**.

# ЯҢА КИТАПЛАР

**Туфан Миңнуллин. Татарның бер баласы.** — Казан: «Рухият» нәшр., 2003.—408 бит. Тиражы—2000 данә.




Туфан Миннуллин—күп рәсми титулларга һәм премияләргә ия шәхес. Татар язучыларыннан беренче булып аның ун томлык «Сайланма әсәрләре» дөнья күрде. Ә бу китап аның бүтән китапларыннан аерылыбрак торган басма: биредә авторның шәхси тормышы, иҗат биографиясенең «кардиограммасы», җәмәгать эшлеклесе буларак, Ватан, Милләт, Киләчәк турында уйланулары...

«Әлеге китап шул уйлануларның чорналып бетмәгән йомгагы. Кем идек тә кем булдык дигән мәңгелек сорауга җавап эзләргә тырышу»—ди автор үзенең кереш сүзендә.

Китап әдипнең тормыш юлына һәм иҗатына бәйле фотоиллюстрацияләр белән бизәлгән.

Мөхәррире—А. Юнысова.

**Лена Шагыйрьҗан. Божра вә Хөжрә: шигырьләр һәм поэмалар.** —Казан: Татар. Кит. Нәшр., 2002.—368 бит. Тиражы—2000 данә.




Лена Шагыйрьҗанның (Лена Шакиржанова) бу китабы шагыйрә иҗатын чагылдырган иң тулы басма. Томлыкка нигездә шагыйрәнең соңгы 10-15 ел эчендә язылган шигырьләре һәм поэмалары тупланган. «Шагыйрә бу китабы белән гүяки XX гасыр ахырындагы татар рухи дөньясына, аның хыялларына һәм омтылышларына, уңышларына һәм мөмкинлекләренә, гыйбрәт һәм үкенечләренә, психологик халәтенә һәм фәлсәфи тәҗрибәсенә шигъри бер йомгак ясый шикелле» диелә аннотациядә.

Китапта өч йөзгә якын шигырьләр белән беррәттән аның дүрт поэмасы, шул исәптән җәмәгатьчелеккә киң мәгълүм «Дөнья базары яхут яңа «Америка фаҗигасе» дигән поэмасы да урын алган.

Китапның мөхәррире—Р. Корбан. Рәссамы—З. Хәкимов.

Индекс 73210



Әнәс Исхаков

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)